АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**Институт языка, литературы и искусства
имени Г. Ибрагимова**

# ТАТАРСКАЯ ГРАММАТИКА

Издание 2-е, дополненное

В трех томах

**Том III**
**Синтаксис**

Казань
2017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
**Г. Ибраһимов исемендәге**
**Тел, әдәбият һәм сәнгать институты**

# ТАТАР ГРАММАТИКАСЫ

Тулыландырылган 2 нче басма

Өч томда

**III том**
**Синтаксис**

Казан
2017

**УДК 811.512.145'36**
**ББК 81.2Тат-2**
**Т 12**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

«2014–2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен
һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү»
дәүләт программасы кысаларында басыла

**Проект җитәкчесе һәм автор –** филол. фән. докт., проф. **М.З. Зәкиев**

**Фәнни редактор –** филол. фән. докт., проф. **Ф.М. Хисамова**

**Җаваплы редактор –** филол. фән. канд. **Л.М. Гыйниятуллина**

**Рецензентлар:**
филол. фән. докт., проф. **Г.Р. Галиуллина,**
филол. фән. докт., проф. **К.Р. Галиуллин**

**Т 12** **Татар грамматикасы:** өч томда / проект җит. һәм автор М.З. Зәкиев. – Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – III. т. – 536 б.
ISBN 978-5-93091-247-0

Бу монографик хезмәттә татар синтаксисы фәненең тарихы, формалашуы, үсеше, актуаль мәсьәләләре яктыртыла. Гади һәм кушма җөмлә, текст синтаксисы мөмкин кадәр эзлекле һәм тулы итеп бәян ителә.

Китап татар теле белгечләренә, укытучыларга, югары уку йортлары студентларына, аспирантларына һәм магистрларына, татар теленең синтаксик төзелеше белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.

**ISBN 978-5-93091-247-0**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2017

# СҮЗ БАШЫ

«Татар грамматикасы»ның III томы татар әдәби теле синтаксисының тарихын һәм бүгенге торышын тасвирлауны максат итеп куя. Татар теленең академик грамматикасына нигез булырдай хезмәтләр язу узган гасырның 60 нчы елларында аеруча җанлану кичерә. Алар арасында татар теленең синтаксисын өйрәнүгә багышланган «Хәзерге татар әдәби теле. Синтаксис» (1966) фундаменталь хезмәте зур урын тота. Ул 1971 елда рус телендә дә дөнья күрә.

1969–1971 еллар аралыгында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында әзерләнгән беренче академик грамматика басылып чыга [Современный татарский..., 1969; Современный татарский..., 1971].

Татар теленең яңартылган икенче академик грамматикасы 1992–1993 елларда рус телендә өч томда нәшер ителә. Бу академик грамматиканың татарча варианты 1998–2002 еллар аралыгында (өченче томы – «Синтаксис» 1999 елда) фәнни җәмәгатьчелеккә барып ирешә.

2000 еллардан башлап, бүгенге көнгә кадәр татар теленең синтаксик төзелешенә багышланган шактый күп хезмәт языла. Ф.С. Сафиуллина, М.З. Зәкиев [Зәкиев, 2005; Сафиуллина, Зәкиев, 2002, 2006], Ф.Г. Галләмов [Галлямов, 2006], З.В. Шәйхразиева, Н.В. Максимов [Шәйхразиева, Максимов, 2014] хезмәтләрендә синтаксисның актуаль мәсьәләләре яктыртыла.

2000 елдан алып, хәзерге көнгә кадәр Ф.С. Сафиуллина [Сафиуллина, 2000], Ф.Г. Галләмов [Галлямов, 2007], А.А. Билаловалар

[Билялова, 2011] тарафыннан якланган докторлык диссертацияләре; Р.К. Сәгъдиева [Сагдиева, 2000], Л.М. Рәхимова [Рахимова, 2001], Г.Ә. Нәбиуллина [Набиуллина, 2002], М.С. Азисова [Азисова, 2004], Н.Р. Харисова [Харисова, 2004], А.А. Билалова [Билялова, 2004], Н.Х. Шакирова [Шакирова, 2006], Ф.Б. Ситдыйкова [Ситдикова, 2007], Л.А. Янсаева [Янсаева, 2008], Л.Г. Вәлиеваларның [Валиева, 2012] кандидатлык диссертацияләре татар теле синтаксисын өйрәнүгә үз өлешен кертте. Болардан тыш, күп кенә җыентыклар, ярдәмлекләр, фәнни мәкаләләр әзерләнде һәм бу эш бүгенге көндә дә дәвам итә.

Сезнең игътибарга тәкъдим ителә торган хезмәт – «Татар грамматикасы»ның 1999 елда басылып чыккан III томының яңа фәнни чыганаклардагы төп фикерләргә таянып тулыландырылган, төзәтелгән басмасы. Бу хезмәтне басмага әзерләүдә Л.Г. Вәлиева, З.В. Шәйхразиева, Л.М. Гыйниятуллина катнашты.

Хезмәт татар теленең синтаксисы белән кызыксынучыларга, белемнәрен тирәнәйтергә теләүчеләргә һәм тел белгечләренә тәкъдим ителә.

# КЕРЕШ

## СӨЙЛӘМ ТӨЗЕЛЕШЕ СИСТЕМАСЫ ТУРЫНДАГЫ ФӘН БУЛАРАК СИНТАКСИС

**§ 1. Синтаксис һәм аның төп өйрәнү объекты**. Синтаксис сүзе – грек теленнән кергән термин. Грекча *syntaxis* – ‘төзү’ яки ‘төзелеш’ дигән сүз. Бу термин ике мәгънәдә кулланыла: телнең сөйләм төзелешен дә, шул төзелешне өйрәнә торган фәнне дә синтаксис диләр.

Игътибар итәргә кирәк: телнең сөйләм төзелешен өйрәнә, дидек, ә тел төзелешен түгел. Ни өчен? Чөнки тел һәм сөйләм төшенчәләре бер үк түгелләр, алар бер-берсеннән аерылалар. Тел – ул аралашу коралы, ә сөйләм – аралашу ысулы, димәк, сөйләм – телнең хәрәкәттәге чагы. Синтаксис телнең әнә шул хәрәкәттәге халәтен өйрәнә.

Телне һәм сөйләмне аерып карауны XIX йөз ахырында һәм XX йөз башында яшәгән швейцарияле лингвист Фердинанд де Соссюр фәнни нигезләгән. Аңа кадәр синтаксисны да тел төзелешен яисә телдәге җөмләләр төзелешен өйрәнә дип билгели торган булганнар, телне кулланганда (сөйләп торганда) туган үзенчәлекләренә игътибар итеп җиткермәгәннәр. Ф. де Соссюрдан соң телне һәм сөйләмне аерып карау, әкренләп, рус синтаксисына да керә башлаган. Татар синтаксисына ул XX йөзнең 60 нчы елларында кабул ителгән. Ләкин синтаксис сөйләм төзелешен өйрәнә дигәннән, ул тел төзелешеннән читләшә икән дип уйларга ярамый. Ул бер үк вакытта тел төзелешен дә өйрәнә, ләкин аны язуга төшерелеп куйган хәлендә алып түгел, ә хәрәкәттәге хәлен күз алдында тотып.

Телнең хәрәкәттәге халәте, ягъни сөйләм, телдән киңрәк. Теге яки бу телне белүче коллективның аңына беркетелгән лексик берәмлекләр, җөмлә калыплары, сүзләрне үзара бәйләүче кушымчалар, бәйләгеч сүзләр һәм телгә хас булган тавыш хәрәкәте (интонация, просодика)

тел яссылыгында карала, ягъни сөйләшү өчен әзер булган корал дип атала торган тел өлешләре булып санала. Ә сөйләмдә болардан башка әле аерым сөйләшләргә, аерым кешеләргә генә хас булган очраклы (окказиональ) сүзләр дә, очраклы җөмлә калыплары да, сүзләрне үзара бәйләүче чаралар да, ятрак интонация дә кулланылырга мөмкин. Алар сөйләмгә күбрәк башка тел йогынтысы буларак килеп керәләр. Бу очраклы сүзләр, калыплар һәм формалар, күпчелеккә аңлашылырлык дәрәҗәгә җиткәнче, тел яссылыгына кертелмичә, сөйләм яссылыгында гына каралалар. Синтаксис фәне, тел яссылыгында урын алып, тел коллективы өчен гадәти булып киткән әдәби сөйләм нормаларын үзенең төп өйрәнү объекты итеп санаса да, бары сөйләм яссылыгында калган элементларның кулланылышын да игътибарсыз калдырмый.

Гомумән караганда, тел берәмлекләре сөйләм берәмлекләре белән туры килә: сүз, җөмлә калыплары, бәйләүче һәм ясагыч чаралар. Аерма бары шунда: болар сөйләм берәмлеге булганда, сөйләгәндәге барлык интонацион һәм форма үзенчәлекләре белән бергә алыналар.

Сөйләм ул гаҗәеп катлаулы күренеш, аны гомумән алып, бергә җыеп өйрәнү мөмкин түгел. Шундый катлаулы күренешне өйрәнү тәртипле барсын өчен, иң элек сөйләмнең барлык төп үзенчәлекләрен дә үзендә туплаган төп берәмлеге булган җөмлә аерып алып тикшерелә. Соңыннан җөмләләрнең үзара оешып, сөйләм (текст) оештыру ыссулларына игътибар ителә.

**§ 2. Сөйләм, фикер, әйтү максаты, чынбарлык, сөйләүче һәм тыңлаучы.** Синтаксис телдәге җөмләләрнең төзелешен өйрәнә дип билгеләгән чагында, бу параграфта саналган төшенчәләр синтаксик эзләнүләрдә аерым урын алмыйлар иде. Синтаксис телнең хәрәкәттәге халәтен (сөйләмне) өйрәнүче фән буларак боларга да сөйләм элементлары итәрәк тиешле урын бирә, чөнки сөйләм фикердән (эчтәлектән), чынбарлыктан, сөйләүче (язучы) һәм тыңлаучыдан (укучыдан) башка оеша алмый. Сөйләм процессында болар үзара бик тыгыз мөнәсәбәттә булалар.

Синтаксиста сөйләм ике мәгънәдә кулланыла: киң мәгънәдә, ягъни сөйләмне эчтәлек (фикерләү) белән бергә алып; тар мәгънәдә, ягъни фикерне белдерүче форма мәгънәсендә генә. Моны дөнья фәнендә кулланыла торган терминнарга салсак, болай була: сөйләм ул – чынбарлыктагы бер күренеш, билге (знак). Аның **семантикасы** (эчтәлеге, фикере)

бар, һәм аның **синтактикасы** (формасы, тышкы кабыгы) бар, өйрәнгәндә боларның ни өчен хезмәт итүләрен билгеләү зарури, бу соңгысы сөйләмнең **прагматикасы** буларак аерып күрсәтелә. **Марксистик диалектикага** таянып, элек бары форма белән эчтәлек кенә аерылып карала иде. Дөньядагы теләсә нинди күренешне, билгене фәлсәфи өйрәнә торган **семиотика** методы форма һәм эчтәлек төшенчәләренә әйбернең-төшенчәнең яшәү максатын, ягъни прагматикасын билгеләү зарурлыгын да өстәде. Сөйләмнең прагматикасын өйрәнү – аның хәбәрлеген (предикативность), ягъни хәбәр итәргә сәләтен һәм модальлеген, ягъни сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәт белдерүен ачыклауга кайтып кала.

Шулай итеп синтаксис сөйләмне синтактика (ягъни форма) ягыннан (сөйләмне тар мәгънәсендә форма дип), аның семантикасын (эчтәлеген), ягъни сөйләмдәге фикерне аерым алып, һәм боларның прагматикасын, ягъни әйтү, сөйләү максатын билгеләү юнәлешендә тикшерә.

**Искәрмә**. Сөйләмне семиотик яктан өйрәнүчеләр синтактика терминын еш кына синтаксис атамасы белән алмаштыралар. Бу – төшенчәләрне буташтыруга китерә. Синтаксис атамасы электән семантика һәм синтактика берлеге мәгънәсендә йөргән, хәзер дә аны шулай куллану максатка ярашлы була. Семантика – эчтәлек, ә синтаксис форма гына түгел, ул – семантика плюс синтактика.

Сөйләмнең барлыкка килүе фикер әйтү зарурияте булуга бәйләнгән. Фикер үзе чынбарлыкның кеше аңында чагылышы буларак туа. Чынбарлыктагы әйберләрне, күренешләрне кеше сизү органнары аркылы үзенчә танып белә, димәк, чынбарлыктан яңа информация ала. Кеше миендә бу яңа информация электән истә калганнар белән бергә анализлана, уй йөртү тәртипкә салына, нәтиҗәдә эчке сөйләм ярдәмендә фикер формалаша һәм ул тышкы (язма яки әйтмә) сөйләм ярдәмендә тыңлаучыга җиткерелә.

Чынбарлык, фәлсәфи мәгънәдә, кеше аңыннан тыш реаль яши торган күренешләр дигән сүз (аңа табигать күренешләре, кешелек җәмгыяте һәм кеше аңы керә). Сөйләмне тикшергәндә, чынбарлык атамасы шушы киң мәгънәсендә дә кулланыла һәм үз эченә сөйләмне, аның эчтәлеген, сөйләм обстановкасын (вакытын, урынын, сәбәбен, максатын, шартын һ. б.), сөйләүчене һәм тыңлаучыны да ала. Таррак мәгънәсендә кулланганда, чынбарлыктан сөйләүчене аерып чыгаралар, ягъни аны сөйләүчедән тыш күз алдына китерәләр, сөйләүче белән каршы куялар, чөнки синтаксиста сөйләүченең чынбарлыкка

(дөресрәге, аның сөйләүчедән тыш булган өлешенә – тыңлаучыга, сөйләмгә, сөйләм максатына, сөйләм эчтәлегенә, сөйләм обстановкасына, сөйләм эчтәлеге белдерә торган реаль күренешләргә) мөнәсәбәтен тикшерергә туры килә.

Ниһаять, синтаксиста сөйләүчене (язучыны) һәм тыңлаучыны (укучыны) аерып карыйлар. Сөйләмнең төзелү шартларын тикшергәндә, без аның сөйләүчедән тыңлаучыга хәрәкәтен дөрес итеп күз алдына китерергә тиешбез. Аралашу процессында сөйләүче һәм тыңлаучы әледән-әле рольләрен алмашып торалар, ләкин тикшерүне ансатлаштыру өчен, без сөйләмнең сөйләүчедән тыңлаучыга хәрәкәт итүен генә алабыз, ягъни аны ясалма рәвештә берьяклы процесс итеп карыйбыз. Сөйләмне тикшергәндә, сөйләүче һәм тыңлаучы төшенчәләре үзәктә тора, чөнки сөйләм тууның төп сәбәбе – сөйләүче һәм тыңлаучы арасында аралашу ихтыяҗы.

Фикернең эчке сөйләм ярдәмендә формалашып, тышкы әйтмә яки язма сөйләм аркылы тыңлаучыга җиткерелүен түбәндәге схема рәвешендә сурәтләргә мөмкин.



**§ 3. Синтаксис һәм логика, сөйләм һәм фикерләү арасында мөнәсәбәт**. Синтаксис – билгеле бер телдә сөйләм төзү закончалыкларын, сөйләмнең төзелешен, логика исә фикерләүнең (мышление) формаларын һәм закончалыкларын өйрәнә.

Антик дөньяда ук кешенең фикерләү формаларын һәм законнарын өйрәнә торган фән – логика барлыкка килгән, фикерләүнең күзаллаулар (представления), төшенчәләр (понятия), хөкемләү (суждения), уйлау нәтиҗәләре (умозаключения) аркылы объектив чынбарлыкны чагылдыру икәнен аңларга тырышканнар. Фикерләүнең төп берәмлеге – хөкемләү, хөкемләүнең төп өлешләре – субъект, предикат һәм бәйләү (связь) булуын ачканнар.

Ләкин башта әле фикерләү белән телне (сөйләмне) аерып карый белмәгәннәр. Шул чорда логика эчендә әкренләп синтаксис дигән фән туган. Синтаксисның берәмлекләре дә турыдан-туры логикадан чыгып билгеләнгәннәр, алар башта хәтта фикерләү берәмлекләренең исемнәре белән аталып йөртелгәннәр. Мәсәлән, тел белемендә һәм логикада җөмлә белән хөкемләүне аермыйча, икесен бер исем белән атап йөртүләр, субъектны ия белән, предикатны хәбәрдән аермыйча, аларның икесенә дә бер үк атама кушулар әле XIX йөздә дә булган. Хөкемләүдә бәйләү (*copula*) булгач, җөмләдә дә өченче баш кисәк сыйфатында бәйләү яки бәйләгеч (связь) булырга тиеш дип санаганнар.

Бу мәсьәләдә капма-каршы чиккә ташланучылар да булган, ягъни кайберәүләр сөйләм белән фикерләү арасында бернинди бәйләнеш тә юк дип уйлаганнар.

Фикер әйтергә кирәклектән сөйләм оеша, димәк, сөйләм фикерләүне формалаштыра һәм аралашу процессында шул фикерне тыңлаучыга җиткерә. Сөйләм белән фикерләү, форма белән эчтәлек кебек үк, бәйләнештә торалар. Форма эчтәлек түгел, эчтәлек форма түгел, шул ук вакытта форма эчтәлектән башка, эчтәлек формадан башка була алмый. Шуның кебек үк сөйләм фикерләү түгел, фикерләү сөйләм түгел, шул ук вакытта сөйләм фикерләүдән башка, фикерләү сөйләмнән башка була алмый.

Фикерләүне, алда әйтелгәнчә, логика фәне өйрәнә, тирәнрәк керөп тикшерә башласаң, фикерләүнең үзенә генә хас үзенчәлекләре ачыла. Сөйләмне синтаксис фәне өйрәнә, җентекләбрәк өйрәнгәндә, сөйләмнең үзенә генә хас үзенчәлекләре табыла. Мисал өчен сөйләм һәм

фикерләү берәмлекләренең төрле яссылыкта туры килү-килмәвенә күз салыйк.

I яссылык – сөйләм белән фикерләү яссылыгы. Болар арасында форма белән эчтәлек арасындагы кебек диалектик бәйләнеш. Фикерләүне җәмгыятьтә эчке яки тышкы сөйләмнән башка гамәлгә ашырып булмый, башкаларга фикерне әйтү, алардан фикер алу, шул юл белән фикерне тагын да үстерү сөйләм (тышкы сөйләм) аркылы тормышка аша. Икенче яктан караганда, сөйләм дә фикерләүсез була алмый.

II яссылык – җөмлә белән хөкемләү яссылыгы. Хөкемләү нәрсәнеңдер булу-булмавын раслый, ягъни анда нәрсә булса да раслана яки инкяр ителә. Хөкемләү һәрвакыт җөмлә белән бирелә, ләкин барлык җөмләләр дә хөкемләүне тулы килеш белдерә дип әйтеп булмый. Мәсәлән, хикәя җөмләләр һәрвакыт хөкемләүгә туры киләләр, ә сорау һәм боеру җөмләләр хөкемләүне әзерләүдә яки аны дәвам итүдә күбрәк катнашалар. Күренә ки, бу яссылыкта сөйләм һәм фикерләүнең үзләренә генә хас үзенчәлекләре әкренләп арта бара.

III яссылык – субъект һәм предикат, ия һәм хәбәр яссылыгы. Субъект – аның турында ниндидер яңалык әйтү өчен алынган төшенчә. Предикат – алынган төшенчә турында әйтелгән яңалык. Алар, икесе бәйләнешкә кереп, алынган төшенчәдә ниндидер билгенең булу-булмавын хәбәр итәләр. Кайбер очракта субъект – ия яки җәенке җөмләдә ия группасы белән, ә предикат хәбәр яки хәбәр группасы белән бирелә. Мәсәлән, *Көн эссе. Завод эшчеләре көнлек норманы тутырдылар*. Бу хөкемләүләрдә һәм җөмләләрдә: субъект (*S*) – *көн* һәм *завод эшчеләре*; ия – *көн* һәм *эшчеләр*; предикат (*P*) – *эссе* һәм *көнлек норманы тутырдылар*, хәбәр – *эссе* һәм *тутырдылар*. Күренә ки, беренче мисалда логик һәм синтаксик берәмлекләр ныграк туры киләләр, икенчесендә синтаксик берәмлекләр логик берәмлекләрнең үзәгендә генә торалар.

Кайчагында субъектның – ия, предикатның хәбәр белән бирелмәве дә мөмкин. Мәсәлән, *Сез синтаксисны кайчан үтә башлыйсыз*? дигән сорауга *Без синтаксисны өченче курста үтә башлыйбыз* дип җавап бирелсә һәм җавапны бу конкрет обстановкадагы хөкемләү буларак тикшерсәң, анда хәбәр итү өчен алдан алынган төшенчәне, ягъни субъектны, *Без синтаксисны үтә башлыйбыз* җөмләсе белдерә, шул алдан билгеле булган төшенчәнең яңалыгын *өченче курста* сүзләре

белдерә, димәк, *өченче курста* – предикат була. Ул җавапны җөмлә буларак тикшерсәң, анда ия – *без*, хәбәр – *үтә башлыйбыз* булыр.

Болардан нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: сөйләм белән фикерләү арасында диалектик бәйләнеш бар, алар бер-берсеннән башка була алмыйлар, ләкин алар бер үк нәрсәләр дә түгел. Фикерләүнең үзенә хас, сөйләмнең үзенә хас структурасы һәм закончалыклары бар. Шуңа күрә аларның икесен ике фән – логика һәм синтаксис өйрәнә. Синтаксис фәнен җентекләп өйрәнгәндә, логика нигезләре белән дә таныш булырга кирәк, шунсыз аны аңлавы кыен булачак.

**§ 4. Сөйләмнең төп үзенчәлеге: хәбәрлек һәм модальлек.** Күргәнебезчә, сөйләм ул телнең хәрәкәттәге халәте, ул – аралашу процессы. Ә аралашу кешеләрнең бер-берсенә нәрсәдер хәбәр итүе аркылы тормышка ашырыла. Димәк, сөйләмнең беренче төп үзенчәлеге – хәбәр итү, башкача әйткәндә, аралашуны тәэмин итү. Сөйләмнең хәбәр итү үзенчәлеген синтаксис фәнендә *хәбәрлек* диләр.

Хәбәр итүне сөйләүче чынбарлыктан алып оештыра, тыңлаучыга җиткерә, шуңа күрә хәбәр итү сөйләүченең чынбарлыкка (тыңлаучыга, хәбәр ителә торган фикергә, фикерне тудыруга сәбәп булган чынбарлык күренешләренә, фикернең формасына – сөйләмгә, сөйләм максатына, сөйләм обстановкасына) ниндидер бер мөнәсәбәтеннән тыш була алмый: сөйләүче чынбарлыкны, булганынча, үз кичерешләрен кушмаска тырышып, я күбрәк үз кичерешләрен кушып (хәбәр ителә торган күренеш булганга шатланып, кайгырып, гаҗәпләнеп, шикләнеп) хәбәр итә, вакыйганың булуын мөмкин яки мөмкин түгел дип карый, булуын яки булмавын тели, сөйләмнең төгәл яки җитешсез формалашуына игътибар итә, тыңлаучыга уңай яки кире мөнәсәбәтен дә сөйләмнең бер деталендә чагылдыра. Димәк, сөйләмнең икенче аерылгысыз билгесе, үзенчәлеге – сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерү. Моны сөйләмнең *модальлеге* диләр.

Хәбәрлек һәм модальлек, нигездә, сөйләмнең прагматикасын тәшкил итәләр, ягъни сөйләм оештыруның максатын тулыландыралар.

Шулай итеп сөйләмнең ике төп үзенчәлеге була, алар – хәбәрлек һәм модальлек. Хәбәрлек – гомумән хәбәр итү, модальлек – ничек хәбәр итү. Сөйләмнән башка хәбәрлек һәм модальлек булмый, хәбәрлек һәм модальлектән башка сөйләм булмый. Хәбәрлектән башка модальлек юк, модальлектән башка хәбәрлек юк.

**Искәрмә**. Тел гыйлемендә хәбәрлек (предикативность) һәм модальлек (модальность) төшенчәләренә күптөрле билгеләмәләр бирелгән. Рәсми сүзлекләргә кертелгән һәм күбрәк очрый торган билгеләмә түбәндәгечә яңгырый: хәбәрлек – әйтелә торган фикернең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерү; модальлек исә – сөйләүченең әйтелә торган фикергә мөнәсәбәтен белдерү, яки әйтелә торган фикернең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерү. Бу билгеләмәләрдә, бердән, хәбәрлек белән модальлек төгәл аерылмаган, икенчедән, әйтелә торган фикер чынбарлыкка беркайчан да турыдан-туры мөнәсәбәттә тормый, андый мөнәсәбәт бары сөйләүче аңы аркылы гына урнаша. Димәк, әйтелә торган фикернең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерү дигән бик якынча билгеләмә хәбәр итү дигән конкрет төшенчә эчтәлегенә тулысынча кереп бетә. Шуңа күрә без хәбәрлек һәм модальлек төшенчәләрен югарыдагыча конкрет билгеләүне кирәк санадык.

Синтаксиста тагын сөйләм семантикасының чынбарлыкка булган мөнәсәбәтен дә аерым алып өйрәнәләр, һәм аны репрезентация яисә референция дип атыйлар. Бу термин чынбарлыкны референт дип атаудан килә.

Сөйләм семантикасының тыңлаучыга мөнәсәбәтен дә аерып алалар, әйтү максаты тыңлаучыга юнәлгәнлектән, бу мөнәсәбәтне прагматик мөнәсәбәт дип атыйлар. Референция дә, прагматик мөнәсәбәт тә хәбәрлек һәм модальлектә тулы чагылыш табалар.

**§ 5. Сөйләм берәмлекләре.** Синтаксисның өйрәнү объекты – сөйләм, дигән идек. Сөйләм ул колач җитмәслек чиксез бер күренеш, шуңа күрә аны гомумән алып өйрәнеп булмый. Бу эшне башкару өчен, синтаксис фәне иң элек сөйләмнең берәмлекләрен аерып чыгара. Сөйләмнең үзен алмаштыра алырлык берәмлек – **текст**. Текст итеп аерым кыска әсәрләр (кечкенә хикәя, анекдот, мәсәл, мәзәк, мәкалә, гариза, справка, беркетмә һ. б.), әсәрләрнең бүлекләре, бүлекчәләре, параграфлары да, берничә абзацтан торган өлешләре дә, абзацлар да алына. Текстның бер темасы булырга, ул һәрьяклап censorbөтен төзергә тиеш. Хәбәрлек тә, модальлек тә текстта ачыграк чагыла.

Текстны тәртипле итеп өйрәнү өчен, иң элек текст эченнән сөйләмнең төп үзенчәлекләрен үзендә туплый алган, ягъни хәбәрлегә һәм модальлегә булган, иң кыска берәмлегә аерып чыгарыла. Сөйләмнең хәбәрлеккә һәм модальлеккә ия булган иң кыска берәмлеге – **җөмлә**. Ләкин җөмлә аралашу процессында үзе генә катнаша алмый, ул текст (шулчакта барлыкка килгән сөйләм) эчендә генә кулланыла. Димәк, җөмләне аерып алып өйрәнсәк тә, аның нинди текст эчендә килүен

бервакытта да истән чыгарырга ярамый. Текстны өйрәнгәндә дә җөмлә белән эш итәргә туры килә, шуңа күрә җөмлә сөйләмнең төп берәмлеге дип тә йөртелә.

Җөмләнең үзен эзлекле итеп өйрәнү барышында – сүзләр белән, җөмлә кисәкләре белән, җөмләдә сүзләр бәйләнешен тикшергәндә, сүзтезмәләр белән эш итәргә туры килә. Шуңа күрә синтаксиста, сөйләм берәмлекләре буларак, **сүзләр**, **җөмлә кисәкләре** һәм **сүзтезмәләр** дә сөйләгәндә алган үзенчәлекләре белән бергә аерып чыгарыла.

Шулай итеп сөйләм берәмлекләре: текст, җөмлә, сүзтезмә, сүз, җөмлә кисәге; шушылар ук синтаксик берәмлекләр дип тә йөртеләләр.

Сөйләмнең барлык үзенчәлекләрен дә үзендә чагылдыра ала торган берәмлекләр бары икәү генә: текст һәм җөмлә.

Җөмлә өйрәнүдән текст (сөйләм) өйрәнүгә бару юлы түбәндәгечә була: иң элек **гади җөмлә** җентекләп тикшерелә, аннан соң текстта мөстәкыйль булмаган җөмләләрнең үзара кушылып килүләре, ягъни **кушма җөмлә** оештырулары һәрьяклап карала, соңыннан мөстәкыйль җөмләләрнең яисә абзацларның **текст** (**сөйләм**) оештыру юллары анализлана. Шуңа күрә синтаксис төп өч өлештән тора да: гади җөмлә синтаксисы, кушма җөмлә синтаксисы, текст синтаксисы.

**§ 6. Җөмләнең төп үзенчәлеге булган хәбәрлек һәм модальлекнең белдерелүе**. Җөмләгә түбәндәге билгеләмәне биреп булыр иде.

Сөйләмнең фикерне, кичерешне һәм ихтыярны хәбәр итә һәм сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерә торган иң кыска берәмлеге җөмлә дип атала. Сөйләм җөмләләрдән тора, һәм җөмлә, сөйләмнең төп берәмлеге буларак, аның ике төп үзенчәлеген – хәбәрлекне һәм модальлекне – үзендә чагылдыра.

Фикерне, кичерешне һәм ихтыярны хәбәр итүе, ягъни аларны чынбарлыктан алып чынбарлыкка төбәп әйтүе **җөмләнең хәбәрлек белдерүе** дип атала. Хәбәрлек – җөмләнең иң төп бер билгесе, һәм ул җөмләгә хас. Хәбәрлек я ике сүзнең үзара хәбәрлекле мөнәсәбәткә керүе формасында (ике составлы җөмләләрдә – *Кар эреде.*), я бары бер генә сүзнең хәбәр итә торган үзәк төзүе формасында (бер составлы һәм ким җөмләләрдә – *Кыш. Салкын һава. Язам. Укыйсың.*) бирелә. Хәбәрлек белдерүдә заман формалары, вакыт һәм урын белдерүче сүзләр дә катнаша, чөнки хәбәрлек – сөйләмнең билгеле

бер урын һәм вакыт эчендә алынган чынбарлыкны хәбәр итүе ул. Хәбәрлек нинди генә формада бирелмәсен, ул хәбәр итү интонациясеннән аерылгысыз.

Сөйләүченең чынбарлыкка, тыңлаучыга, сөйләмгә мөнәсәбәт белдерүе **җөмләнең модальлек белдерүе** дип атала. Модальлек – җөмләнең шулай ук иң төп билгесе, һәм ул җөмләгә хас.

Модальлек хикәя, сорау, боеру һәм тойгылы җөмләләрне формалаштыручы чаралар белән бирелә. Биредә хәбәр формалары да зур роль уйный. Мәсәлән: *Болытлар таралдылар. Кояш якты нурларын чәчеп җибәрде. Кояш ничәдә чыга? Син киләсеңме? Тере килеш алыгыз! Берсен дә качырмаска! Нинди иркен минем туган илем! Их! Кичә үк күреп сөйләшкән булсам!*

Сөйләүче сөйләгәндә үзенә, тыңлаучыга һәм сөйләмдә катнашмаган өченче бер затка да үзенең мөнәсәбәтен белдерә. Мондый модальлек зат, тартым кушымчалары, зат алмашлыклары һәм эндәш сүзләр белән дә бирелә. Мәсәлән: *Мин озаттым аны сугышка, йөрәгемнең сүнмәс кояшын* (М. Җәлил). *Шуңа күрә теге малай «балык» дигән сүзне авызга алу белән*:

*– Ну, таптың, малай! Китәбез, валлаһи, китәбез! – дип кычкырып җибәрдем* (Г. Ибраһимов).

Модальлек төрле ярдәмлек һәм мөстәкыйль сүзләр, хәтта җөмләләр белән дә бирелә. Мәсәлән: *Ул арада боларны кайсыдыр күреп алды булса кирәк* (Г. Бәширов). *Күңел ул, күрәсең, һаман да күңел, унбиштә дә күңел, утыз биштә дә шул ук күңел* (Ш. Камал). *Күпләрнең гаҗәпләнүләренә каршы, онытыла язган татар телен дә бик тиз арада тергезеп алды* (Г. Ибраһимов). *Аларны бит, гафу итегез, һавадан ясап булмый* (М. Максуд).

Модальлек һәрвакыт үзенә күрә бер төрле интонациягә төренгән була. Тойгыга бай булган модальлекне белдерүдә интонация башка чараларга караганда да зуррак роль уйный. Мәсәлән: …*Урманлы тау уртасында зур түгәрәк сихерле күл ялтырый. Ничаклы матурлык!* (Г. Ибраһимов) *Һе! Тапкансың икән урын! Күләгәдә җилләнә торган чакмыни хәзер?!* (К. Тинчурин).

Хәбәрлек һәм модальлек – җөмләнең аерылгысыз билгеләре. Хәбәрлексез һәм модальлексез җөмлә була алмаган кебек, җөмләсез дә хәбәрлек һәм модальлек була алмый. Хәбәрлек белән модальлек үзара

да аерылгысыз бәйләнештә торалар. Хәбәрлек булмаса – модальлек, модальлек булмаса – хәбәрлек була алмый.

Телдәге барлык категорияләр хәбәрлек һәм модальлек белдерү процессында барлыкка килгәннәр, үсә барганнар, шомарганнар.

**§ 7. Синтаксис фәнендә төрле юнәлешләр.** Телнең җөмлә төзелешен, гомумән сөйләмне өйрәнү процессында методларның төрлечәрәк булуыннан, сөйләмнең аерым өлешләренә игътибар бирүдән синтаксис фәнендә төрле юнәлешләр барлыкка килгән, һәм алар синтаксис фәнен төрле яктан баетканнар, тирәнәйткәннәр. Грамматиканың бер бүлеге буларак синтаксис, икенче төрле әйткәндә, **грамматик синтаксис** тарихта булган һәм хәзер дә яши торган барлык юнәлешләрдән дә файдалана, сөйләм төзелешен өйрәнүне тирәнәйтүдә аларның тикшерену алымнарын һәм нәтиҗәләрен гомуми эшкә җәлеп итә. Шул юнәлешләр белән кыска гына танышу урынлы булыр.

Синтаксис, яралганда ук, логика фәне белән бергә гомуми фәлсәфә эчендә булган. Логик категорияләр барлык телләр өчен дә бер төрле булганга, синтаксис та барлык телләр өчен бер төрле булырга тиеш дип уйлаганнар. Шулай итеп башта ук синтаксиста **логик юнәлеш** өстенлек алган һәм аны, барлык телләр өчен дә уртак булганга, **универсаль синтаксис** (универсаль грамматиканың бер өлеше) дип атаганнар. Бу юнәлеш әле хәзер дә очрый. Кайбер галимнәр синтаксиста да логика терминнарын кулланып эш итәләр: ия урынына субъект, хәбәр урынына предикат, тәмамлык урынына объект дип язуны дәвам итәләр.

Логик универсаль синтаксис эчендә әкренләп **грамматик синтаксис** формалаша. Ул сөйләмдә һәм аның берәмлекләрендә семантиканы (фикерне) дә, синтактиканы (сөйләмне-форманы) да ачык аера, икесен дә бер үк дәрәҗәдә тикшерергә тырыша: сөйләм төзелешеннән фикер төзелешенә күчә яисә фикер төзелешеннән башлый, сөйләм төзелеше белән тәмамлап куя. Фәнни тикшеренүдә шушы ике юл булганда гына, синтаксис тулы була, һәм менә шундый синтаксисны гына грамматик синтаксис дип атыйлар.

Кайбер галимнәр бары беренче юл белән генә мавыгалар, ягъни сөйләмне форма буларак кына тикшереп чикләнмәкче булалар, семантиканы читтә калдыралар. Алар шулай итеп **формаль синтаксис** тудыралар. Ләкин алар сөйләмне форма итеп кенә өйрәнергә никадәр тырышмасыннар, барыбер семантикага, фикергә игътибарсыз кала алмыйлар.

Лингвистларның кайберләре сөйләмдә бирелгән семантика-фикер төзелешен ачуны гына үз бурычлары итеп саныйлар, шуның белән генә шөгыльләнергә тырышалар һәм **семантик синтаксис** тудырырга омтылалар. Ләкин никадәр генә омтылмасыннар, алар сөйләмне дә форма буларак читтә калдыра алмыйлар, теге яки бу дәрәҗәдә грамматик синтаксиска якынаялар.

**Грамматик синтаксис** кына сөйләмне тулы килеш һәм төрле яктан өйрәнә, төрле юнәлешләрне үзендә берләштерә ала.

Сөйләмнең аерым өлешләрен өйрәнүгә һәм нинди алым куллануга карап, синтаксисның түбәндәге өлешләре һәм юнәлешләре очрый:

1. Сүзтезмә синтаксисы, гади җөмлә синтаксисы, кушма җөмлә синтаксисы, текст синтаксисы.

2. Коммуникатив синтаксис җөмләдә тыңлаучы өчен алдан билгеле булган һәм яңа төшенчәне (актуаль кисәкләрне) аерырга тырыша һәм аралашу (коммуникация) процессында җөмләнең ролен билгеләргә омтыла.

3. Функциональ синтаксис җөмләнең аралашу процессындагы функциясен ачуны үз максаты итеп куя: ул нindидер бер фикерне объектив хәбәр итәме, тыңлаучыда төрле тойгылар уятырга тырышамы, аны нindидер активлыкка чакырамы һ.б.

4. Прагматик синтаксис үзенә шундый бурыч куя: сөйләм фикерне тыңлаучыга бөтен тулылыгы белән җиткерә аламы, юкмы? Прагматик синтаксис, бер яктан, стилистик синтаксис белән туры килә, чөнки фикернең нинди чаралар аркылы тыңлаучыга тулырак җиткерелүен тикшерә. Шуның белән бергә ул чынбарлыкның (референтның) фикердә чагылу дәрәҗәсенә игътибар итә.

5. Структур синтаксис сөйләмнең семантик һәм синтактик структурасын, төзелешен аерып алып тикшерә, аларның ни өчен хезмәт итүләренә, ягъни функцияләренә игътибар бирмәскә тырыша. Структур синтаксис, сөйләм структурасының эчке закончалыкларын ачканда, еш кына җөмлә төзелешен үзгәртеп карау юлы белән эш итә, шуңа күрә аны трансформацион синтаксис дип тә атыйлар, кайчакта порождающий һәм генератив дигән атама да кулланалар.

6. Вариантлар синтаксисы (Көнбатыш һәм рус лингвистикасында полилектуальный яки вариативный синтаксис дигән исемнәре бар) синтаксик берәмлекләрнең вариантларын өйрәнә, шуңа күрә әдәби

норма булып җитмәгән, диалектларда, аерым кешеләрнең сөйләмендә генә кулланыла торган вариантларны да үзенең өйрәнү объекты итә.

7. Экспрессив синтаксис сөйләмдә тойгы белдерү юлларын өйрәнә.

8. Диалекталь синтаксис теге яки бу диалекттагы көндәлек сөйләмне өйрәнә.

9. Семиотик синтаксис сөйләмне һәм аның берәмлекләрен өч яклап өйрәнә: синтактикасын (формасын), семантикасын һәм прагматикасын (яшәү максатын). Бу яктан ул грамматик синтаксиска якын, дөресрәге, грамматик синтаксис соңгы елларда семиотик синтаксиска якыная бара.

Гомуми грамматик синтаксис та, аның аерым юнәлешләре дә 1) тарихи (диахроник), 2) тасвири (синхроник), 3) чагыштырмалы-тарихи, 4) контрастив (төрле типтагы телләрне чагыштырулы – сопоставительно-типологический, башкача әйткәндә, контрастив) була ала.

Искә алынган күп юнәлешләр үз методларын аклау юнәлешендә бер-берсен түбәнәйтергә тырышалар, ләкин бу төп максатка – сөйләмне мөмкин кадәр тирәнрәк өйрәнү эшенә зыян гына китерә. Барлык юнәлешләр дә үз урынында кирәкле, һәм шуңа күрә грамматик синтаксис аларның һәммәсеннән дә файдаланырга тиеш.

## ТАТАР СИНТАКСИС ФӘНЕНЕҢ КЫСКАЧА ТАРИХЫ

**§ 8. Милләт формалашу чорында татар синтаксисы фәне**. XIX йөзгә чыкканда, татар халкының тагын да тыгызрак этник төркемгә – милләткә оешу билгеләре шактый ачык күренә башлый. Шул гасырның уртасында бу билгеләр өстенлек алып, татар милләтенең оешуы ныклап башланып китә. Моны тудырган иҗтимагый күренешләр татар телен төрле яклап өйрәнүгә дә китерә, әкренләп синтаксис фәне дә борын төртергә тотына.

Татар сөйләм төзелешен тикшерүнең беренче адымы Казанның рухани уку йортларында татар теле укыткан **Александр Троянский** тарафыннан 1814 елда ясала [Краткая татарская грамматика. СПб., 1814; икенче басмасы – Казань, 1824]. Ул синтаксис фәнен «Сүзләр тезелүе» (сочинение слов) дип атый, аныңча, бу фән сүзләрнең бергә килүен һәм сөйләм оештыруын өйрәнә [Беренче басмасы, 145 б.]. А.Троянский әле сүзләрнең бәйләнеш төрләрен билгели алмый, җөмлә дигән төшенчә дә әле анда юк.

1842 елда Казан университеты типографиясендә Оренбург хәрби мәктәп укытучысы **Мартиньян Иванов** «Татарская грамматика» дигән хезмәт бастыра. Анда «Сүзләр бәйләнеше турында» («О сочинении слов») дигән аерым бүлек бирелгән. Иң элек М. Иванов һәр сүз төркеменең сөйләмдә кулланылышын тикшерү омтылышы ясый, ләкин әле ул теге яки бу сүз төркеменең кайсы кисәк булып килүен, тәгәлләүче һәм тәгәлләнүче (ачыклаучы һәм ачыкланучы) сүзләрне, бәйләүче чараларны күрсәтүнең кирәклеген тою дәрәҗәсенә җитмәгән була.

Шул чордагы рус грамматикаларына ияреп, М. Иванов җөмлә кисәкләреннән ия, хәбәр, бәйләгеч (связка), тәмамлык һәм аергычны билгели. Аның фикеренчә, хәбәргә буйсынган тәмамлык туры була, башка кисәкләргә буйсынса, кыек була.

Кушма җөмләләрдән М. Иванов бары тезмә кушма җөмләләрне генә тулырак күрсәтә, татар теленә хас иярчен җөмләләр дип аларның синтетик төрләрен саный, аналитик кушма җөмләләрнең *кем*, *ки* белән бәйләнгәннәрен генә күрә һәм аларны, татар теленә хас түгел, ди.

**Александр Казимбәк** 1846 елда Казан университеты типографиясендә «Общая грамматика турецко-татарского языка» дигән хезмәт чыгара. Монда «сүзләрнең тезелүе» турындагы өйрәтмә икенче планга калдырыла, рус һәм немец грамматикаларыннан җөмлә һәм хөкемләү турындагы өйрәтмә килеп керә. «Һәр телнең синтаксисы этимология белән логиканың бәйләнеш ысулыннан тора», – ди Казимбәк (342 б.). Аныңча, баш кисәкләр өчәү, һәм алар субъект, предикат, бәйләгечкә туры киләләр. Бөтен синтаксис А. Казимбәк хезмәтендә өчкә бүленә. Беренче бүлектә ия белән хәбәрнең ярашуы тикшерелә. Башка тел грамматикаларыннан механик күчереп, ул: ия җанлы әйберләрне белдерсә хәбәр белән яраша, җансыз предметларны белдерсә – ярашмый дигән караш үткәрә. Икенче бүлектә башкару һәм янәшәлек юлы белән ясалган тезмәләр тикшерелә. Фигыльләрнең башка сүзләрне ияртүләре аеруча җентекле өйрәнелгән. Өченче бүлек җөмләләрнең үзара бәйләнешләрен, фраза төзелешенең гомуми системасын анализлауга багышланган. Ләкин әле монда кушма җөмләләрне тезмә һәм иярченле төрләргә бүлү юк.

1857 елда **Мөхәммәтгали Мәхмүдев** «Практическое руководство к изучению татарского языка» исемле хезмәт чыгара. Моңа чаклы чык-

кан грамматикалар гомуми иске төрки әдәби телгә нигезләнеп язылган булсалар, М. Мәхмүдев кулланмасы Казан татарларының сөйләмә теленә якынайтыла башлаган телгә – милли әдәби телгә таянып төзелгән. Автор монда синтаксис буенча махсус бүлек ачмаган, ләкин морфология бүлегендә татар теленең күп кенә синтаксик үзенчәлекләрен дөрес итеп билгели алган. Мәсәлән, өченче затта ия белән хәбәрнең санда ярашуы мәҗбүри түгел һәм бу күренеш, А. Казимбәк уйлаганча, иянең җанлы яки җансыз әйберләрне белдерүенә дә бәйләнмәгән; сан белән бирелгән аергыч янында аерылмыш һәрчак берлектә була (*биш кешеләр* түгел, *биш кеше*); татар телендә фигыль үзенә буйсынган исемнең иялек килешендә килүен беркайчан да таләп итми. Бу фикерләр М. Мәхмүдевнең зирәк, күзәтүчән галим булуы турында сөйлиләр.

Китап ахырында М. Мәхмүдев татарча һәм русча җөмләләр төзеп күрсәтә. Моны укыган кеше татар теле җөмләләренең төп төрләре белән гамәли рәвештә таныша ала.

1860 елда **А. Троянскийның** «Краткая татарская грамматика» исемле китабы өченче мәртәбә басыла. Бу басма А.Троянскийның шәкертләре тарафыннан әзерләнгән, һәм ул, синтаксисны бирү ягыннан караганда, элекке басмалардан бик нык аерыла. Синтаксисның гомуми төшенчәләре һәм калыбы бу басмада А. Казимбәк кулланмасыннан алынган.

1860 елда бөек татар мәгърифәтчесе **Каюм Насыйри** «Краткая татарская грамматика, изложенная в примерах» исемле кулланма чыгара. Бу – шул чорда иң тулы төзелгән грамматикаларның берсе. К. Насыйри җөмләләрне өч төргә бүлә. Аныңча, хәбәре исем белән бирелсә (ә исемгә ул фигыльдән һәм ярдәмлекләрдән башка сүз төркемнәрен кертә) – исем җөмлә, хәбәре фигыль белән бирелсә – фигыль җөмлә, составында урын хәле булса – хәл җөмлә була. Моннан тыш, К. Насыйри тиңдәш ияләре һәм тиңдәш хәбәрләре булган җөмләләрне аерым күрсәтә. Ул ике иярчен кисәк саный: аергыч һәм тәмамлык; аларның нинди сүзләр һәм формалар белән бирелүен җентекләп анализлый. Тәмамлык сүзләрне, бәйләнеш төренә карап, икегә бүлә: ияртүче сүзгә килеш кушымчалары ярдәмендә бәйләнгән тәмамлыклар, ияртүче сүзгә бәйлекләр аша буйсынган тәмамлыклар.

Каюм Насыйри, кушма җөмлә эчендәге җөмләләрнең үзара бәйләнешен тикшереп, бәйләүче чаралар өч төрле була дип саный: а) *димәк*

ярдәмче фигыле, ә) хәл фигыль формалары, б) теркәгечләр. Бу бүленештә әкренләп кушма җөмлә төзелешенә керә башлау сизелә, ләкин әле бу чорда татар теленең кушма җөмләләргә дә бай булуы ачылмаган була, шуңа күрә аларны классификацияләү дә фәнни югарылыкта тормый.

Каюм Насыйри, татар телен яхшы тойганлыктан, синтаксис эчендә заман, төр (наклонение), юнәлешләрне бик җентекләп өйрәнә, аларның модаль мәгънәләрен тикшерә, ия, тәмамлык, субъект (эш башкаручы), объект арасындагы мөнәсәбәтләргә фигыль юнәлешләренең тәэсирен күрсәтә.

Тиңдәш кисәкләрнең соңгысына гына кушымча ялгана (*чәй, шикәргә акча кирәк*) дип билгеләве дә К. Насыйриның күзәтүчән тел галиме булуы турында сөйли.

1895 елда Каюм Насыйриның татарча язылган **«Әнмүзәҗ»** дип аталган грамматикасы басылып чыга. (*Әнмүзәҗ* – гарәпчә сүз, үрнәк, мисал мәгънәсен бирә). «Әнмүзәҗ»не 1860 елда русча чыгарылган грамматиканың тулыландырылган варианты дип санарга мөмкин.

Татар теленең синтаксисы «Әнмүзәҗ»нең дүртенче бүлегендә бирелә, һәм анда синтаксис «Тәркиб вә тасниф кагыйдәләре» дип атала, ягъни бу – сүзләрнең үзара бәйләнеше һәм шул бәйләнешләрне төрләргә бүлү (классификацияләү) кагыйдәләре дигән сүз. Синтаксисны К. Насыйри төрле бүлекләргә аерып тормый, аны түбәндәге тәртиптә яктырта.

Ул, сүзтезмәләр (тәркибләр) ике төрле була, ди: ким тезмәләр (тәркиб нәкыс), тулы тезмәләр (тәркиб тамь). Аныңча, ким тезмәләр үзләре ике төрле булалар: тәркибе изафә һәм тәркибе тусыйфый.

Тәркибе изафәне, бәйләүче чаралары һәм мәгънәсе буенча, К. Насыйри күп кенә төрләргә бүлә. Изафәнең соңында ***-ы, -сы*** кушымчалары булса, ул төшеп кала алмый, ләкин иялек килеше кулланылмаска мөмкин, ди автор. *Агачның ботагы* изафәсен *агач ботагы* дип әйтеп була, ә *агачның ботак* дип булмый. Иялек килеше кулланылу-кулланылмауга карап, изафә мәгънәсенең үзгәрүен К. Насыйри дөрес билгели: *агач күләгәсе* дигәндә, билгесез агач турында, *агачның күләгәсе* дигәндә, билгеле агач турында сүз бара, ди ул. К. Насыйри иялек килеше белән килгән изафәләрне мәгънә төрләренә бүлми, ә иялек килеше белән булмаганнарын түбәндәге мәгънә белдерүчеләргә бүлә:

нисбәт – *Казан сәүдәгәре*, *авыл халкы*; милек – *әти чапаны, агам бүреге, мужик чабатасы;* төр – *чикләвек агачы, кура җиләге;* җенес – *арыш оны, борай ярмасы.*

Тәркибе тусыйфыйлар: *көмеш сәгать, алтын балдак, камчат бүрек, ак кәгазь, кара кара, тугры юл, яхшы сүз, өченче көн, гакыллы адәм*. Телдә сыйфат күплек кушымчасын ала алмый, бәлки исем генә ул кушымчаны алырга мөмкин, ди К. Насыйри. Мәсәлән, *авырлар ташлар* булмый, *авыр ташлар* була.

Тулы тезмәләрне К. Насыйри, икенче төрле, җөмлә дип атый, аларны хәбәр, ия һәм иярчен кисәкләрнең булу-булмавына, характерына карап төрләргә бүлә: исем җөмләләр – *Кәгазь актыр. Көн аяздыр. Кичләр озындыр;* фигыль җөмләләр – *Бала йоклый. Утны сүндер;* инкяр җөмләләр – *Көн аяз түгел. Мин йокламадым;* иясе алмашлык булган җөмләләр – *Мин чыдам. Мин яздым;* иясе инфинитив җөмлә – *Укымак яхшыдыр;* иясе изафә булган җөмлә – *Диңгез суы тозлыдыр;* сорау җөмлә – *Көн аязмы? Урам былчыракмы? Кайда торасың?* Урын җөмлә – *Чәй тартмададыр. Атам Казанда торадыр;* ике җөмләдән киметелгән җөмлә – *Чәй, шикәр бетте* (*чәй бетте* + *шикәр бетте*); тиңдәш хәбәрле җөмләләр – *Ул бер дә ашамады, эчмәде, кайтып китте* һ.б. Болардан тыш, К. Насыйри төрле сүз төркемнәренең, җөмлә эчендә төрле формалар алып, төрле мәгънәләрдә кулланылуларын җентекләп тикшерә.

Кушма җөмлә синтаксисы да «Әнмүзәҗ»дә шактый урын ала, ләкин автор кушма җөмлә эчендәге җөмләләрнең җөмләлек дәрәҗәсен, мәгънәсеннән чыгып, рус яки гарәп теленә чагыштырып кына билгели, җөмләнең иясе һәм хәбәре булу-булмавына игътибар бирми. Мәсәлән, *Мәскәүдәге абыем кайтты*, аныңча, кушма җөмлә, чөнки *Мәскәүдәге* «который живет в Москве» мәгънәсен бирә. «Әнмүзәҗ»дән мисаллар: *Син килерсең дип*, *мин чыкмый тордым* (бәйләүче чара – *дип*). *Син язган китапны мин укыдым; Гадәләт белән торган кеше изгелек арттырыр; Без кайтканда, ягъмур яуды; Сездән сорасы сүзем бар; Кулыңдагы каләм минеке түгелме? Син боерсаң эшләрмен; Син аны белсәң дә әйтмәссең; Акчасы бар кеше нишләргә белә; Син яза торган каләм яхшырак* һ.б.

Күренә ки, татар теле синтаксисының төп бүлекләрен эшләүгә Каюм Насыйри күп кенә өлеш керткән, татар сөйләменең күп кенә

үзенчәлекләрен дөрес итеп билгели алган. Шулай да әле аның синтаксисына турыдан-туры морфологиягә караган темалар да килеп кергән.

1894 елда Оренбургта **А. Архангельскийның** «Грамматика народно-татарского языка» дигән хезмәте басыла. Бу – керәшен теле грамматикасы. Анда элекке грамматикалардагы карашлар гомумиләштереп бирелә. Синтаксис бүлеге сүзтезмәләрне, җөмләләрне, җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен тикшерүдән башлана. Автор кушма җөмләләрне дә бик җентекләп өйрәнгән. Ул беренче мәртәбә: хәл фигыль иярчен җөмлә булсын өчен, аның үзенә генә караган иясе булырга тиеш, дигән фикерне әйтә; *Давид үлгәч, аның урынына улы Соломон патшалыкка утырган* мисалын китерә. Мәгънә ягыннан иярчен тәмамлык җөмләне (*Сукыр кешеләр Иисус күзләрен төзәткәнне бар җирдә кычкырып әйтеп йөргәннәр*), иярчен аергыч җөмләне (*Аның җанында чирлеләр җата торган биш бүлмә бар*), иярчен максат җөмләне (*Мин аңа укы дип кенәгә бирдем*) һәм башка төрләрен билгели.

Рус теленнән аермалы буларак, ди ул, татар телендәге хикәя җөмләләрдә сүз тәртибе түбәндәгечә була: иң элек вакыт, урын хәлләре, аннары иянең аергычлары үзләренең кирәклек дәрәҗәләре буенча урын алалар, аның янында – ия, иядән соң үзенең аергычлары белән кыек тәмамлыклар, аннан соң туры тәмамлыклар, аннары рәвешләр, соңыннан хәбәр килә. Бу тәртипне, еш кына, логик басым бозарга да мөмкин, ди Архангельский.

Шулай итеп, XIX йөздә милләт формалашу чорында татар синтаксисына нигез салына. Төп синтаксик категорияләрне билгеләгәндә, рус теле грамматикалары файдаланыла, рус теле белән чагыштырып, татар сөйләменең үзенчәлекләрен ачуга ныклы омтылыш ясала.

**§ 9. Милләт формалашкач, синтаксис фәненең үсеше.** Элегрәк татар грамматикаларын миссионерлык юнәлешендә русча язу өстенлек алса, милләт формалашкач, милли тел мәктәпләрдә укытыла башлый һәм шуңа бәйле рәвештә татарча дәреслекләр язу еш күренә башлый, аларда синтаксис та үз урынын ала.

**Ш. Иманаев** үзенең 1910 елда чыккан «Татар теленең нәхүе вә сарыфы» дигән китабында, рус, фарсы, француз, гарәп грамматикаларына ияреп, татар телендә җөмләләрнең 14 төрен күрсәтә: 1) гади җөмлә, 2) кушма җөмлә, 3) иярченле кушма җөмлә, 4) тезмә кушма җөмлә, 5) алмашлыклар белән бирелгән ияләре төшеп калган җөмләләр,

6) бер составлы җөмләләр, 7) кире җөмләләр, 8) сорау, 9) тойгылы, 10) боеру, 11) хикәя җөмләләр, 12) туры сөйләмле җөмләләр, 13) кереш сүзле җөмләләр, 14) теземнәр. Бу грамматикада беренче мәртәбә кушма җөмләләр тезмә һәм иярченле дигән төрләргә бүленгән, тезем-нең интонацион яктан күтәрелү һәм төшү бүлекләре бирелгән.

Иярченле кушма җөмләләр бүлегендә Ш. Иманаев рус яки француз теленә җөмлә белән тәрҗемә ителә торган иярчен кисәкләрне дә иярчен җөмлә дип карый. Ул ия, аергыч, тәмамлык, урын, вакыт, максат, сәбәп, рәвеш иярчен җөмләләрне күрсәтә, билгелелекнең *бу, шул, теге* алмашлыклары һәм төшем килеше формасы белән бирелүен, билгесезлекнең *бер* сүзе аркылы һәм *-ны* кушымчасын төшереп калдырып бирелүен тикшерә. Ш.Иманаев әле нигездә гарәп терминнарын куллана, ләкин берлек, күплек, үткән заман, хәзерге заман, баш җөмлә, тыныш билгеләре дигән терминнарны да тәкъдим итә.

1910 елда **Әхмәтһади Максудовның** «Төрки нәхүе» дигән китабы чыга. Автор монда, мәгънәгә карап, иярчен кисәкләрне – егермегә, кушма җөмлә төрләрен егерме бишкә җиткерә. Ул синтаксиста гарәпчә терминнарны тулысынча саклый.

Татарның күренекле тел галиме **Гыймад Нугайбәк** унынчы елларда телне чит сүзләрдән чистарту (пуризм) юнәлеше белән мавыга һәм 1911 елда үзенең «Төрлек» дигән китабын чыгара. «Төрлек» сүзе нигездә морфологиягә туры килсә дә, анда синтаксис буенча да мәгълүмат бар. Ләкин алар шул чордагы башка авторларның мәгълүматларыннан аерылмыйлар, анда бары пуристик терминнарның булуы гына бераз оригинальлек тудыра. Мәсәлән, тезмә – җөмлә, башлык – баш кисәк, ачкыч – иярчен кисәк, билгелек – аергыч, тутыргыч – тәмамлык, тормышлар – хәлләр, текәп әйтү – эндәш, җитәкчеләр – бәйләүче чаралар мәгънәсендә кулланылганнар.

1911 елда **Галимҗан Ибраһимовның** «Татар нәхүе» дигән махсус синтаксис китабы басыла. Бу китап үзенең куелган һәм чишелгән мәсьәләләре, тәкъдим ителгән терминнары белән шул дәрәҗәдә игътибар казана ки, аны 1919 елга кадәр ел саен дип әйтерлек чыгарып торалар.

Г. Ибраһимов, синтаксиста карала торган темалар дип, түбәндәгеләрне саный: җөмлә, җөмләнең баш вә иярчен кисәкләре, җөмләнең төрләре, кушма җөмлә, тыныш, тезем.

«Ишетүчегә бер уй бирерлек булып бергә кушылган сүзләр җөмлә дип атала», – ди Г. Ибраһимов. Баш кисәкләр (ия һәм хөкем), хөкемнең гади һәм кушма төрләре, ия белән хәбәрнең ярашуы мисаллар өстендә анализлана. Иярчен кисәкләргә автор түбәндәгеләрне кертә: вакыт, урын, рәвеш, сәбәп, тәмамлык, аергыч, эндәш, кереш сүз. Күренә ки, Г. Ибраһимов иярчен кисәкләрне, мәгънәләреннән чыгып, бик күп төргә бүлә, шунда ук модаль кисәкләрне дә өсти. Тиңдәш кисәкле җөмләләрне автор оешкан җөмләләр дип атый, аларны ул ике яки өч җөмләдән оешкан дип саный. Мәсәлән, анычча, *Кояш һәм ай батар* җөмләсе *Кояш батар, Ай батар* җөмләләреннән оешкан булып чыга.

«Җөмлә төрләре» дигән бүлектә Г. Ибраһимов иясез җөмләләрне, ким җөмләләрне, сөаль (сорау) җөмләләрне, эстәү (боеру, теләк) җөмләсен, нида (тойгылы) җөмләсен билгеле.

Баш һәм иярчен җөмләләр бүлегендә Г. Ибраһимов: «…бер җөмлә икенче җөмләгә кисәк булып төшсә, аны иярчен җөмлә дип атыйлар», – дип яза һәм дәвам итә: «Җөмләнең барлык кисәге ун икәнен беләбез. Ләкин болардан баш кисәкләрнең җөмлә булып йөртелүе юк. Шулай ук иярчен кисәкләрдән дә эндәш белән урын җөмлә була алмый. Кереш сүз җөмлә була алса да, нәхү кануны буенча тегеләргә охшамаганга, алар арасына кертелми. Кала иярчен кисәкләрдән бишесе. Шунлыктан иярчен җөмләләр дә биш төрле була, алар ошбулар: 1) вакыт җөмлә, 2) рәвеш җөмлә, 3) сәбәп җөмлә, 4) тәмамлык җөмлә, 5) аергыч җөмлә». Г. Ибраһимов иярчен җөмләләрнең үзләренә караган хәбәрләре булырга тиеш дигән кагыйдәне танымый, шуңа күрә иярчен җөмләләр арасына иярчен кисәкләрне дә кертә. Мәсәлән, вакыт җөмләгә, *Май кергәч, көннәр бигрәк матурланып китте* мисалы белән рәттән, *Сагынганда айга карыйм* мисалын да китерә.

Иярчен кисәкләргә туры килми торган иярчен җөмләләрдән Г. Ибраһимов шарт һәм кире җөмләләрне күрсәтә: *Яз җитсә, кошлар килә. Чакырсам да килмәде; Күк күкрәсен, ялтыр-йолтыр килсен яшен, Төн буена нинди каты җил исмәсен, Ни булса да, бары да бер аның өчен, – Уянмый ул, селкетми дә борын очын* (Г. Тукай).

Г. Ибраһимовның кушма җөмләләрне төрләргә бүлүе дә бик үзенчәлекле. Иярчен һәм баш җөмләдән торган кушма җөмләләрдә ул – ияртү юлы, башкаларында тәэлиф (тезү) юлы күрә. Анычча, тәэлиф юлы белән бәйләнгән җөмләләр дүрт төрле була: берек җөмлә (*Шау-*

*лый диңгез, җил өрәдер, җилкәнен киргән кораб*); каршык җөмлә (*Күңел күпне тели, ләкин булдырып булмый*); бүлем җөмлә (*Бүген я син калырсың, я мин китмәм*); дәлил җөмлә (*Сабырсыз булма күңел: бәла бер сиңа түгел; Сабакка бара алмыйм, чөнки авырыйм; Авырыйм, шунлыктан (шуңа күрә) сабакка бара алмыйм*).

Димәк, Г. Ибраһимов синтетик иярчен җөмләләрне генә иярчен җөмлә дип таный, аналитик иярчен җөмләләре булган кушма җөмләләрне, тезмә кушма җөмләләр белән бергә, аерым алып тикшерә.

Теземне Г. Ибраһимов кушма җөмләнең бер төре итеп карый һәм мисалга Г. Тукайның «Китап» шигырен китерә. Теземнең ике өлештән торганын билгели.

Октябрь инкыйлабына кадәр тагын күп кенә дәреслекләр чыга. Мәсәлән, **Г. Сәгъдинең** «Үз телемезчә мөкәммәл сарыф, нәхү», шул ук елда **Җ. Вәлидинең** «Татар теленең имла һәм сарыф вә нәхү кагыйдәләре» китаплары, тагын башка авторларның дәреслекләре дөнья күрәләр. Аларда синтаксис, нигездә, Г. Ибраһимов буенча язылган.

Йомгак ясап, шуны әйтергә кирәк: милләт формалашу татар телен, димәк, татар милләтен саклау, үстерү идеяләрен дә алып килә. Телне иҗтимагый тормышта куллану киңәя, аның грамматикалары татарча языла, башка тел грамматикалары тәҗрибәсе актив кулланыла. Синтаксис фәне һәм гыйльми атамалар системасы ныклап аякка баса.

**§ 10. Милли күтәрелеш елларында татар синтаксисы фәне.** Марксист-ленинчылар хакимиятне кулга төшерү эшенә Россиядәге барлык халыкларны да җигү юлын сайладылар. Аларның милли сәясәте буенча, а) һәр халык, һәр милләт тигез хокуклы, ә) бер генә милләт тә (хәтта рус милләте дә) үзен башкалардан өстен куя алмый, б) һәр милләт үзбилгеләнү хокукына ия, ягъни ул үз дәүләтен төзеп яши ала, хәтта Россиядән аерылып чыгарга да мөмкин. Моңа ышанган татар социал-демократлары, большевиклары ленинчыларга хакимияткә килергә булышлык күрсәттеләр. Большевиклар Идел–Урал штатын, Татар-башкорт республикасын төзү омтылышына каршы астыртын көрәш алып барсалар да, Татарстан республикасын төзүгә каршы килмәделәр. Болар барысы да татарда яңа милли күтәрелеш, үсеш чоры башлануына сәбәп булдылар. Бу, үз чиратында, татар лингвистикасының үсешенә дә китерде. Чөнки рәсми учреждениеләрдә, җыелышларда милли телдә сөйләү, эш йөртү хокукы бирелгәнлектән, дәүләт

хисабына эшли торган мәктәпләрдә ана телендә белем алу мөмкинлеге ачылганлыктан, татар телендә дә дәреслекләр төзү, укытучылар әзерләү, телне гыйльми яктан эшкәртү ихтыяҗы туды, аның буенча башта киң күләмле дәреслекләр, соңрак махсус фәнни хезмәтләр чыга башлады. Югары уку йортларында татар теле кафедралары, татар телен тикшерүче гыйльми бүлекләр барлыкка килде. Татар теле фәненең тормыш белән, башка фәннәр белән бәйләнеше бик нык үсеп китте. Шундый шартларда, әкренләп, аның синтаксик төзелеше дә өйрәнелде, синтаксис фәне төзелде.

1919 елда **Җ. Вәлиди** югары уку йортлары студентлары, укытучылар курслары һәм мәктәпләр өчен «Татар теленең грамматикасы» дигән зур кулланма чыгарды. Монда, бердән, К. Насыйри «Әнмүзәҗ»е традицияләре дәвам иттерелә, икенчедән, үз чорының синтаксис буенча яңалыклары гомумиләштерелә.

Бу грамматикада җөмлә әле сүзтезмә эчендә карала. Сүзтезмә (тәркиб) өч төрле була, ди автор: аеру тәркибе (*яхшы кеше, барган кеше, бер шәкерт*), теркәү тәркибе (*шәкертнең китабы, Урал тавы* һ. б.), хөкем тәркибе (*Без барабыз*, *Ул – кеше*). Җ. Вәлиди исем сүзтезмәләрне генә тәркиб дип саный, фигыль сүзтезмәләрне иярчен кисәк буларак тикшерә. Иярчен кисәкләрдән ул аергычларны һәм тәмамлыкларны таный, мәгънә һәм формаларына карап, аларны төрләргә бүлә. Мәсәлән, ул түбәндәге тәмамлыкларны күрсәтә: күчем тәмамлыгы, төшем тәмамлыгы, юлдаш тәмамлыгы, юнәлеш тәмамлыгы, урын тәмамлыгы, вакыт тәмамлыгы, сәбәп тәмамлыгы, максат тәмамлыгы, рәвеш тәмамлыгы. Хәзерге көндә без хәл дип таныган кисәкләр дә бу грамматикада тәмамлык төркеменә кертелгәннәр.

Шул чордагы рус теле грамматикаларына ияреп, Җ. Вәлиди эндәш һәм кереш сүзләрне җөмләгә бәйләнмәгән кисәкләр дип карый.

Мәгънә ягыннан җөмләләр дүрт төрле булалар, ди: хәбәр (хикәя) җөмлә, сөаль (сорау) җөмлә, эстәү (боеру һәм теләк) җөмлә, нида (тойгылы) җөмлә.

Кушма җөмләләрне билгеләүдә әле шул чорда хөкем сөргән буталчыклык бу грамматикада да бик нык урын алган. Җ. Вәлиди, кушма җөмләләрне билгеләгәндә, бары мәгънәдән һәм аның рус яки гарәп теленә ничек тәрҗемә ителүеннән чыгып эш итә; кушма җөмлә составында ике (яки күбрәк) җөмлә дип танырлык синтаксик берәмлекләр

бармы-юкмы, андый таләпне автор әле куя алмый. Шуңа күрә ул типик гади җөмләләрне дә кушма дип саный. Аныңча, кушма җөмләләр ике төрле булалар: ияртү юлы белән ясалганнары һәм бәйләү юлы белән ясалганнары.

Ияртү юлы белән ясалган кушма җөмләләрдәге иярчен җөмләләрне Җ. Вәлиди, мәгънәсеннән чыгып, уналты төргә бүлә, ә бәйләү юлы белән бәйләнгәннәрен егерме өч төрле була, ди. Бу классификациядә нинди дә булса принцип һәм тәртип табу бик кыен, шулай да җөмләләр һәм җөмлә кисәкләре арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләрен билгеләүдә бу бүленештә бер адым алга китеш ясалган.

1919 елда мәктәпләр өчен синтаксистан тагын бер кулланма басыла. Ул – **М. Корбангалиев** һәм **Х. Габделбәдигъның** «Ана теле нәхүе». Бу кулланма шул чорга кадәр булган карашларны җыеп бирүдә, рус теле грамматикаларындагы бүленешләрне татар грамматикаларына күчерүдә шактый гына зур роль уйный. Терминнар Г. Ибраһимов хезмәтендәге кебек татарчалаштырып биреләләр.

Мәктәпләр өчен совет чорында төзелгән бу беренче дәреслек башка синтаксис дәреслекләренә дә нигез була. М. Корбангалиевнең (Г. Хисмәтуллин белән бергә), С. Атнагуловның һәм Г. Алпаровның мәктәпләр өчен чыгарылган синтаксис дәреслекләре шушы кулланманың үстерелгән вариантлары дип карала алалар.

Татар теле буенча дәреслекләр төзүнең яңа бер баскычка күтәрелүен Г. Ибраһимов тарафыннан җитәкләнгән гыйльми үзәк тәэмин итә. 1922–1925 елларда ул өч кисәктән торган **«Гамәли тел сабаклары»** дигән күләмле дәреслек чыгара. Моның Г. Ибраһимов, М. Корбангалиев, Г. Ходаяров, Ф. Сәйфи-Казанлы һәм Х. Габделбәдигъ тарафыннан төзелгән өченче кисәгендә синтаксиска киң генә урын бирелгән. Элеккерәк чыккан синтаксистан аермалы буларак, монда хәл дигән кисәкләр тәмамлыктан аерылганнар һәм шуның белән иярчен кисәкләр өчәү дип саналганнар: аергыч, тәмамлык, хәл.

Җөмләләр: а) хәбәргә карап, ә) иягә карап, б) иярчен кисәкләренә карап, в) эчтәлекләренә карап төркемләнгәннәр.

Хәбәрләренә карап, җөмләләр барлык җөмлә, юклык җөмлә дигән төрләргә бүленәләр. Болар хәзерге раслау һәм инкяр җөмләләргә туры киләләр.

Ияләренә карап, ияле җөмләләр һәм иясез җөмләләр булалар. Ияләре нинди сүз икәне бөтенләй аңлашылмый торган җөмләләр иясез җөмлә дип аталалар. Башка төрләре ияле җөмләгә керәләр.

Иярчен кисәкләргә карап, таркау җөмләләр һәм җыйнак җөмләләр булалар.

Эчтәлекләреннән чыгып, сорау, өндәү, хикәя җөмләләр күрсәтеләләр. Шулай итеп, монда өндәү җөмлә боеру җөмләләрне дә, тойгылы җөмләләрне дә үз эченә ала булып чыга.

«Җөмләләрне кыскарту» дигән тема бирелеп, анда ике кыскарту юлы санала: 1) җөмләләрнең җиңел аңлашыла торган кисәкләрен төшерү юлы белән ким җөмлә ясала; 2) охшаш кисәкләрен берләштерү юлы белән оешма җөмлә (тиңдәш кисәкле җөмлә) барлыкка килә.

«Җөмләләрне кушу» дип исемләнгән бүлектә кушма җөмләләр тикшерелә. Авторлар кушма җөмлә ясауның ике юлын күрсәтәләр: **ияртү** юлы, **бәйләү** юлы. «Бер җөмләгә ияреп, аның кисәге булган җөмләләр иярчен җөмлә дип аталалар». Алар аергыч җөмлә, тәмамлык җөмлә, хәл җөмлә дигән төрләргә бүленәләр. Шарт һәм кире җөмләләр сәбәп хәле җөмләсенә якынайтып караладар. Димәк, авторлар иярчен җөмлә дип бары синтетик иярчен җөмләләрне генә таныйлар. Аналитик иярчен җөмләләрне алар, тезмә кушма җөмләләр белән бергә, бәйләү юлы белән ясалган кушма җөмләләргә караталар һәм аларга түбәндәге аңлатманы бирәләр: синтаксис кануны ягыннан куәтләре тигез булып, тик эчтәлекләре ягыннан бер-берсенә бәйләнгән аерым-аерым җөмләләрне бергә кушу җөмләләрне бәйләү дип атала. Күренә ки, җөмләләр арасында ияртү һәм бәйләү юллары принципиаль аерылганнар. Гамәли тел сабакларыннан соң чыккан мәктәп грамматикаларында иярчен җөмләләргә аналитик иярчен җөмләләр дә кертелә, икенче (бәйләү) төрендә бары тезмә кушма җөмләләр генә кала.

Бу кулланмадан соң чыккан һәм хәзерге көнгә кадәр чыгып килә торган дәреслекләр үз чорының рус теле грамматикалары һәм татар теле синтаксисы буенча гыйльми хезмәтләр тәэсирендә әкренләп баеп, тәртипкә салынып килгәннәр. Фәнни грамматикалар чыга башлагач, мәктәп дәреслекләренең фән үстерүдә рольләре бик нык кими, ләкин алар фәннең үсеш дәрәҗәсен чагылдыру ягыннан әһәмиятләрен югалтмыйлар.

Татар теленең чын фәнни максатларыннан язылган беренче грамматикасы – **Г. Алпаровның** «Шәкли нигездә татар грамматикасы».

Бу 1926, 1927 елларда басыла, аннан соң авторның 1945 елда чыккан «Сайланма хезмәтләр»енә кертелә.

Бу чорларда русларда формаль нигездә төзелгән грамматикалар модада иде. Г. Алпаров та, шуларга ияреп, татар теленең формаль грамматикасын төзүне үзенә бурыч итеп куя. Ләкин бу тискәре мәгънәсендәге формаль хезмәт түгел. Эш бары шунда: төрле бүленешләрнең нигезенә Г. Алпаров формаль күрсәткечләрне сала, ләкин һәр форманың мәгънәсен ачуга да җитәрлек игътибар бирә.

Г. Алпаровның шәкли (формаль) грамматикасы өч бүлектән тора: фонетика, морфология, синтаксис.

Г. Алпаров карашынча, синтаксис сүзтезмәләрнең тышкы күренешләрен өйрәнә, андагы фикер, мәгънә аңлату ягын тикшерү шәкли грамматиканың вазифасына керми. Соңгысы – логика эше. Сүзтезмәләрнең тышкы күренешләре – ялганмалык (сүзләрнең кушымчалар һәм кушымча урынында йөри торган ярдәмлекләр белән бер-берсенә ялгануы), тәртип, басым, аһәң, тыныш.

Г. Алпаров баш кисәкләрдән ия һәм хәбәрне күрсәтә, ләкин ияне хәбәрнең баш тәмамлыгы дип карый. Дүрт төрле иярчен кисәкнең барлыгын таный.

Тәмамлыклар – фигыльгә буйсынган сүзләр; аергычлар – исемгә буйсынган сүзләр; ачыклаулар – сыйфатка буйсынган сүзләр, дүртенчесе – ярдәмлекләргә бәйләнгән иярченнәр (соңгысына мисаллар: *килгәннән соң, былтырдан бирле, авылга таба, йөз белән, аю кебек, сезнең өчен*). Бу дүрт төрле иярченнәрнең формалары һәм җөмләдәге урыннары шактый җентекле тикшерелә.

Кушма җөмлә төрләрен өчкә бүлеп бирүне Г. Алпаровның катлаулы конструкцияләр теориясен үстерүгә керткән зур өлеше дип карарга мөмкин. Ул кушма җөмләләрне ияртүле, бәйләүле, тезмәле дигән төрләргә бүлә.

Ияртүле кушма җөмләләр иярчен һәм баш җөмләдән тора, ди Алпаров. Иярчен җөмлә дип бары синтетик иярчен җөмләләрне генә таный, шунда ук чит җөмләне (туры сөйләмне) кертә. Иярчен җөмләләр баш җөмләгә тәмамлык булып киләләр, ди ул һәм шуңа күрә синтетик аергыч җөмләләрне биредә карамый.

Бәйләүле кушма җөмлә, Г. Алпаров фикеренчә, тулы җөмләләрнең, янәшә килеп, ярдәмлекләр һәм алмашлыклар аша бәйләнүе

нәтиҗәсендә ясала. Бу төргә автор теркәгечле тезмә кушма җөмләләрне һәм мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә ясалган аналитик кушма җөмләләрне кертә.

Тезмәле кушма җөмлә бер-берсенә аһәң, тыныш ярдәмендә бәйләнгән җөмләләрдән тора. «Шуның белән бергә, – дип яза Г. Алпаров, – тезмәле кушма җөмләләрдә югарыда күрсәтелгән бәйләүче ярдәмлекләр, алмашлыкларны кушып әйтү мөмкин булырга тиеш». Хәзерге бүленештән чыксак, Г. Алпаров тезмәле кушма җөмләләргә теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрне һәм көттерү паузасы ярдәмендә төзелгән аналитик кушма җөмләләрне кертә.

Гади җөмләләр бу хезмәттә сорау, өндәү, хикәя, боерык, үкенеч дигән төрләргә бүленә. Тойгылы җөмләләрне Г. Алпаров, беренче буларак, өндәү термины белән атый. *Ах, нигә генә килдем икән монда!* җөмләсен үкенеч җөмләгә мисал итеп китерә.

Г. Алпаровның синтаксис өлкәсендә тагын бер зур гыйльми хезмәте – «Татар телендә иярчен җөмләләр бармы?» дигән мәкалә. Автор, алдан әйткәнебезчә, иярчен җөмлә дигәннән бары синтетик җөмләләрне генә күз алдында тота һәм аларның булуын исбатлый, үзләренә караган иянең килүен шарт итеп куя. «Иярчен җөмләләр үзләренең бер кабыргалары белән тулы җөмләләргә якын торсалар, икенче кабыргалары белән алар иярчен кисәкләргә якын торалар», – ди.

Большевикларның хакимияткә килү өчен тудырган милли хәрәкәтләре озакка бармый, 25–30 нчы елларда әкренләп сүнә. Милли азатлык өчен көрәшүчеләр репрессияләнә, бу татар лингвистларына да кагыла. 25–40 нчы еллар арасында синтаксис фәне бары мәктәп дәреслекләре төзү барышында гына яшәп килә. Аларда татар теленең үзенчәлекләрен ачу түгел, ә рус теле грамматикаларына иярү беренче планга куела.

**§ 11. Бердәм совет халкын төзергә омтылу чорында татар синтаксисы фәне.** 30 нчы елларда СССР ны тагын да киңәйтү юлы белән бөтен Җир шарында бер генә милләтле (димәк, милләтләрсез) коммунистик җәмгыять төзү, Ленин әйткәнчә, ерак еллар бурычы дип түгел, ә якын еллар, ягъни XX йөз бурычы итеп куела. Милләтләрнең бер милләт булып оешуы аларның үсүе һәм чәчәк атуы аркылы башкарылырга тиеш, диләр коммунистлар. Башта мәдәниятләре шактый үстерелгән күп милләтләрдән бердәм совет халкы төзелер, соңрак бу бер телле, бер мәдәниятле совет халкы бер милләткә әверелер дип уйлыйлар.

Милләтләрне чәчәк аттыру юлы белән ирекле рәвештә юкка чыгаруга кушылу соңрак татар коммунистларына да килеп җитә. Ләкин татар милләтен үстерергә омтылган зыялылар өчен бу юнәлешнең беренче өлеше – милләтне үстерү, чәчәк аттыру дигән өлеше күңелгә хуш килә. Бөек Ватан сугышы да коммунистлардан милләтләрнең үсешенә ныграк игътибар иттерүне таләп итә. Татарстан Тел, әдәбият һәм тарих институтында диссертацияләр язу тәртибе урнаша. 1944 елда Казан университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачыла. Бу бүлек татар теле һәм әдәбияты буенча галимнәр әзерләүдә зур роль уйный.

Болар барысы да татар тел гыйлеменең дә әкренләп яңадан җанлануына китерә. Синтаксистан да хезмәтләр язу башлана. Татар синтаксисы өлкәсендә беренче диссертацияне 1941 елда ук Тел, әдәбият һәм тарих институтында В.Н. Хангилдин яза. Бу эшендә ул татар сүзтезмәләрен алардагы сүзләрнең ярашу, башкарылу һәм янәшәлек юллары белән бәйләнеше буенча тикшерә.

50 нче елларда синтаксистан тагын берничә диссертация дөньяга килә. 1954 елда А. Кәримова – иярченле кушма җөмләләр, Х. Курбатов – чит сөйләм, М. Зәкиев – хәбәр, 1957 елда К. Сабиров – тыныш билгеләре буенча кандидатлык диссертацияләре яклыйлар. Бу авторлар үз проблемаларына бәйле рәвештә кайбер башка мәсьәләләрне дә тикшерәләр.

1956 елда Х. Курбатов «Татар теленең синтаксис һәм стилистика мәсьәләләре» дигән китап чыгарып, синтаксистан беренче киң күләмле тикшеренү үткәрде. Ләкин соңрак автор бары стилистика буенча гына эшләвен дәвам итте.

50 нче еллар ахырында татар синтаксисын монографик планда яктырткан ике хезмәт: 1958 елда **М. Зәкиевнең** студентлар өчен «Хәзерге татар әдәби теле. Синтаксис» дигән кулланмасы, 1959 елда **В. Хангилдинның** «Татар теле грамматикасы (морфология һәм синтаксис)» исемле монографиясе дөньяга чыга.

М. Зәкиевнең 1958 елда Казан университеты нәшриятында чыккан «Хәзерге татар әдәби теле. Синтаксис» дигән китабы шул чорларда чит ил һәм рус грамматикаларында булган яңа юнәлешләрне иҗади файдалану һәм шул нигездә татар сөйләм төзелешен җентекле өйрәнү ягыннан да зур яңалык алып килде. Ул югары уку йортлары студентлары өчен чыгарылган беренче дәреслек кулланма да иде. Нәкъ менә

шушы китаптан татар синтаксисының үсешендә аерым бер фәнни мәктәп оешуы башланды. Менә шушы академик грамматикада яктыртылачак проблемаларның теге яки бу яссылыкта, тирәнлектә куелышы һәм чишелеше дә шушы китапта урын алды. Бу китап, университетка нәшрият кайтарылгач, аның беренче эше булды һәм, университетта гыйльми эшләргә премияләр бирү тәртибе кертелгәч, университетның беренче дәрәҗәдәге беренче премиясенә лаек дип табылды.

М. Зәкиевнең 1958 елда чыккан бу китабында беренче мәртәбә синтаксисның өйрәнү объекты – сөйләм төзелеше, дигән караш аңлатыла, сүзтезмәләр белән җөмләләр арасында төгәл аерма үткәрелә, ачыклаулы (төгәлләүле) мөнәсәбәт, киң күләмдә сүз төркемнәренә бәйләп, сүзтезмә исеме астында өйрәнелә, фигыль хәбәрләрнең төрле мәгънә төсмерләрен белдерү ягыннан байлыклары күрсәтелә, ияртүле бәйләнеш хәбәрлекле һәм ачыклаулы (төгәлләүле) дигән төрләргә бүленә, сүз тәртибенең кире яки уңай булуы шушы бәйләнеш төрләренә нигезләп аңлатыла.

Кушма җөмләләрне М. Зәкиев, иң элек, бәйләгечле һәм бәйләгечсез дигән, аннан соң һәркайсын тезмә һәм иярченле дип аталган төрләргә аера. Бу китапта беренче мәртәбә аналитик һәм синтетик җөмләләрне билгеләүдә бәйләүче чараның иярчен җөмләдәге хәбәр формасын тәшкил итү-итмәве нигез итеп алына.

М. Зәкиевнең синтаксис буенча карашларына тукталырга түбәндә әле туры килер, чөнки синтаксис буенча башка китаплар да аның тарафыннан язылалар. Хәзер **В.Н. Хангилдинның** 1959 елда чыккан синтаксисына бик кыска гына күзәтү ясыйк.

В. Хангилдин бу хезмәтендә үзенә кадәр булган карашларны түземле һәм җентекле рәвештә санап, анализлап чыга. Ул иң элек сүзтезмәләрне җөмләләрдән аеру бурычын куя, ләкин башкарылу, ярашу, янәшәлек юлларын тикшерү өчен, аларны тагын бергә алырга мәҗбүр була. Ничек кенә булмасын, ул инде җөмләне сүзтезмә эчендә караудан котыла.

Бу хезмәттә җөмләләр 1) максат куелышы буенча, 2) кисәкләрендәге төрлелекләр нигезендә төркемләнәләр. Беренче билге буенча җөмләләр хикәя, сорау, боерык һәм өндәү дигән төрләргә бүленәләр. «Җөмләнең кисәкләре һәм шул нигездәге типлары» бүлегендә В. Хангилдин җөмләнең традицион кисәкләрен тикшерә һәм аның түбәндәге

төрләрен билгеле: ике баш кисәкле, бер баш кисәкле (ияле җөмлә, иясез җөмлә, инфинитив җөмлә, хәбәрлек җөмлә, атау җөмлә, сүз җөмлә), җыйнак, җәенке, тулы, ким җөмләләр.

Эндәш һәм кереш сүзләр җөмләгә грамматик бәйләнеше булмаган сүзләр дип карала. Аныклагыч дигән терминны В. Хангилдин беренче башлап куллана. Аларны: «Җөмләдә, аның теге яки бу кисәгеннән соң урнашып, шул кисәкнең мәгънәсен аныклау, төгәлләндерү яки тәрҗемә итү хезмәтен үтәүче сүзләр һәм сүзтезмәләре очрый», – дип аңлата. Аергычларның бер төре булган өстәмә сүзләрне дә таный (*Озакламый анда – кырларда ташпулатлар үсәр*. Ә. Фәйзи) һәм алардан тыш аныклагычлар бар дип саный (*Җавап көтмичә, кулындагы чәчәкләр бәйләмен (букетын) Хәяткә сонды (тәкъдим итте*). Шуның белән бергә В. Хангилдин аныклагычларны җөмләнең аерым кисәге дип тә танымый.

Бу грамматикада кушма җөмләләрнең төркемләнүе дә үзенчәлекле генә бирелгән. В. Хангилдин кушма җөмләләрне, иң элек, бәйләгечле һәм бәйләгечсез дигән төрләргә бүлә. Бәйләгечле кушма җөмләләр үзләре бәйләгечле тезмә кушма җөмләләргә һәм бәйләгечле иярченле кушма җөмләләргә аерылалар.

Кушма җөмләләрнең икенче зур төркеме – бәйләгечсез кушма җөмләләр. Алар да үз чиратында бәйләгечсез иялтүле, бәйләгечсез тезүле дигән төрләргә бүленәләр. Бәйләгечсез иялтүле кушма җөмлә составындагы буйсынып килгән җөмләне В. Хангилдин җәелдергеч җөмлә дип атый һәм аларның функцияләрен ачарга тырыша. Мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә төзелгән кушма җөмләләрне дә автор бәйләгечсез дип саный.

Иярчен җөмләләрне функциональ яктан төркемләгәндә дә В. Хангилдин бер үк мәгънә мөнәсәбәтләрен бүлгәләп күрсәтә. Мәсәлән, сәбәп нәтиҗә белән бергә генә йөри: берсе сәбәп булса, икенчесе нәтиҗә була. Шуңа карамастан, бу китапта сәбәп – аерым, нәтиҗә җөмлә аерым күрсәтелгән. Чагыштыруның максаты – рәвешне белдерү; бу искә алынмыйча, китапта рәвеш җөмләләр – аерым, чагыштырма җөмләләр аерым бирелгәннәр.

Кайбер кимчелекләре булуга карамастан, В. Хангилдин тарафыннан төзелгән синтаксис татар тел белеме фәнендә бик нык алга китеш иде. Ләкин аңа бу юнәлештәге эшен үстерергә, дәвам итәргә насыйп

булмады. Өлкән яшьтә булганлыктан, ул яңадан синтаксис буенча эзләнүләр алып бармады.

1961 елда **Г.С. Әмировның** рустагы приложениеләрне һәм татардагы аергычларны тикшерүгә багышланган «Из сопоставительного синтаксиса русского и татарского языков» дигән китабы дөнья күрә. Ләкин бу автор да соңыннан синтаксистан читкә китә.

1962 елда Башкорт университеты татар филологиясе бүлеге доценты **Ә. Фатыйхов** «Башкорт һәм татар телләрендә кушма җөмләләрнең кайбер үзенчәлекләре» дигән монография чыгара. Автор кушма җөмләләрне ияртүле, тезмә һәм теркәгечсез дигән төрләргә бүлеп өйрәнә. Төп игътибарны Ә. Фатыйхов шушы төрләрне бер-берсеннән аеруга юнәлтә, һәр төр кушма җөмлә эчендәге җөмләләрнең үзенчәлекләрен ачарга тырыша. Бу автор да үзенең синтаксик эзләнүләрен дәвам итми.

60 нчы елларда татар синтаксисы өлкәсенә М. Зәкиевнең аспирантлары килә башлый. С.М. Ибраһимов, Ф.С. Сафиуллина, Ш.Н. Асылгәрәев, А.А. Хәлилов, М.Ф. Зәйнетдинов, М.Ю. Ибраһимова, Р.М. Балтаева, Ф.Г. Галләмов татар синтаксисын баетуга үзләреннән шактый өлеш кертәләр.

1964 елда **С.М. Ибраһимов** «Аналитические конструкции в татарском языке» дигән темага диссертация яклый, аның бу эше шул ук елда «Татар телендә аналитик төзелмәләр» дигән исем белән аерым китап булып басылып та чыга. С. Ибраһимов татар телендә аналитик төзелмәләрнең үзенчәлекләрен билгеләүгә һәм аларның кулланыш үзенчәлекләрен тикшерүгә бик зур өлеш кертә. 1976 елда С.М. Ибраһимов «Татар телендә синтаксик синонимнар» дигән китап чыгара һәм татар телендә беренче мәртәбә вариатив синтаксиска нигез сала.

**Ф.С. Сафиуллина** 1966 елда «Порядок слов в современном татарском литературном языке» дигән темага кандидатлык диссертациясен яклый. Бу диссертация, тагын да эшкәртелеп, 1974 елда аерым китап булып басылып чыга.

Ф.С. Сафиуллина татар синтаксисының яңа юнәлешенә – әйтмә сөйләм синтаксисына нигез салды һәм аны аерым фән дәрәҗәсенә күтәрде. 1978 елда аның «Синтаксис татарской разговорной речи» дигән күләмле монографиясе дөнья күрде.

**Ш.Н. Асылгәрәев** үзенең 1968 елда яклаган диссертациясендә («Синтагматическое членение татарской речи) татар сөйләменең син-

тагмаларга бүленешен эксперименталь юл белән тикшерә һәм бу өлкәдә булган карашларга шактый яңалык өсти.

**Халилов Абдулманаф** татар һәм азәрбайҗан телендә җөмләләрнең үзара күрсәтү һәм сорау алмашлыклары белән бәйләнешен тикшереп, кандидатлык диссертациясе яклады (1974). Мөнәсәбәтле сүзләр белән бәйләнгән кушма җөмләләрнең, татар телендә генә түгел, азәрбайҗан телендә дә системалы рәвештә үскән булуын ачты.

Саратов педагогия институтында татар һәм рус телләрен чагыштырып укыткан **М.Ф. Зәйнетдинов**, җитәкчесе М.З. Зәкиев тәкъдиме буенча, 1972 елда рус һәм татар телләрендә сүзтезмәләрне өйрәнеп диссертация яклады һәм сүзтезмәнең күп кенә проблемаларына ачыклык кертте.

**М.Ю. Ибраһимова**, татар һәм инглиз телләрен чагыштырып, 1976 елда «Ирреальная модальность и средства ее выражения в современном английском и татарском языках» дигән темага диссертация яклады. Бу диссертация һәм авторның басылып чыккан мәкаләләре татар сөйләмендә ирреаль модальлек (ягъни сөйләүченең чынбарлыкка якынча-хыялый карашын чагылдыру) проблемаларын тикшергән беренче эш булды.

**Р.М. Балтаеваның** «Интонационная структура общего вопроса в современном татарском литературном языке» (1973) дигән кандидатлык диссертациясе татар синтаксисының яңа һәм катлаулы өлкәсен ачыклауга багышланган иде.

**Ф.Г. Галләмов**, татар әдәби телендә кабатлауларның лексик һәм грамматик (синтаксик) үзенчәлекләрен өйрәнеп, 1983 елда диссертация яклады һәм сүзләрне кабатлауның синтаксик системасын табуга зур адым алга атлады.

Татар синтаксисы өлкәсенә башка төрлерәк караштагы диссертантлар да кереп, аның аерым өлешләрен тикшерделәр. 1964 елда **М. Сәгыйтов** иясез җөмләләр турында диссертация яклады, ләкин синтаксис өлкәсе белән яңадан кызыксынмады. 1970 елда **Х.Г. Агишев** рус һәм татар телләрендә сүзтезмәләрнең аерым үзенчәлекләре буенча диссертация яклады һәм күп кенә мәкаләләр язды, сүзтезмәләр сүзлеген төзү өлкәсендә күп хезмәт куйды. Ул «Русско-татарский словарь словосочетаний» дигән зур хезмәт чыгарды [Казан, I т., 1996. 510 б.; II т., 1998. 528 б.].

Татар синтаксисының теоретик проблемаларын өйрәнүгә Башкорт университеты татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире **Р.Г. Сибәгатов** та шактый зур өлеш кертте. Башта ул «Некоторые синтаксические вопросы перевода с русского на татарский» темасына кандидатлык диссертациясе яклады, соңрак җөмләдәге һәм сөйләмдәге хәбәрлек һәм модальлек проблемалары буенча хезмәтләр язды, һәм 80 нче еллар башында, шул темаларны берләштереп, докторлык диссертациясе язып яклады.

Синтаксисны үстерүдә контрастив тикшеренүләрнең дә роле зур булды. Бу бигрәк тә татар синтаксисын рус синтаксисы белән чагыштырып язу тәҗрибәсендә күренде. Биредә 1977 елда чыккан өч китапны күрсәтү урынлы булыр: 1) Закиев М.З., Сафиуллина Ф.С. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. Ч. I. Простое предложение; 2) шуларныкы ук… Ч. II. Простое предложение; 3) Закиев М.З., Зиннатуллина К.З., Ибрагимов С.М. …Ч. III. Сложное предложение. Боларга өстәп, 1989 елда Л.К. Бәйрәмова һәм Ф.С. Сафиуллина тарафыннан чыгарылган «Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков» китабын да телгә алырга кирәк. Бу китап бүгенге көндә контрастив синтаксисның иң яхшы үрнәге булып санала.

Күренә ки, совет халкын формалаштырырга омтылу чорында да милли мәдәният үсешенә шактый нык әһәмият бирелә. Моны милләтләрнең үз зыялылары тырышып эшли. Бу гомуми җанлану синтаксис өлкәсендә дә чагылыш таба.

**§ 12. Татар синтаксисының гыйльми-методик кулланмалар, монографияләр һәм академик грамматикалар төзү барышында үсеше**. Татар синтаксисын тулысы белән яктырту бурычын куйган беренче махсус монография М.З. Зәкиевнең 1963 елда чыккан «Синтаксический строй татарского языка» дигән 464 битлек китабы булды. Бу монография дүрт төп бүлектән тора.

Беренче бүлектә сөйләмнең һәм җөмләнең төп үзенчәлекләре – хәбәрлек, модальлек һәм аларның татар телендә бирелеше тикшерелә. Хәбәрлекнең бирелү ысулына нигезләнгән ике составлы җөмләләрнең төрләре, җөмләнең модальлекнең бирелү ысулына нигезләнгән төрләре (раслау, инкяр, хикәя, сорау, боеру, тойгылы) һәм, модальлек белдерә торган кисәкләр буларак, эндәш, кереш сүзләр җентекле яктыртыла.

Икенче бүлектә сүзләр бәйленеше өйрәнелә. Тезүле һәм ияртүле бәйләнешнең хәбәрлекле, ачыклаулы (төгәлләүле) һәм аныклаулы мөнәсәбәтләрнең сөйләм оештырудагы рольләре ачыла. Сүзләр арасындагы ачыклаулы һәм аныклаулы мөнәсәбәтләр, тезүле бәйләнеш җентекләп тикшерелә.

Өченче бүлек сөйләмдә җөмләләрнең үзара бәйләнешен тикшерүгә багышланган. Биредә бик җентекле рәвештә кушма җөмләләр һәм синтаксик бөтеннәр (сложное синтаксическое целое) карала. Кушма җөмләләр, иң элек, тезмә һәм иярченле дигән төрләргә аерылалар. Иярченле кушма җөмләләрне автор синтетик һәм аналитик дигән ике төргә бүлә, аларның, стилистик вариантлар буларак, бер-берсен алмаштыра алуларын күрсәтә. Синтетик иярчен җөмләнең баш җөмләгә үзенең хәбәре формасы аша бәйләнүе, аналитик иярчен җөмләнең баш җөмләгә хәбәр формасын тәшкил итми торган формалар ярдәмендә бәйләнүе тулы бер система буларак тасвирлана. Мөнәсәбәтле сүзнең, алмашлык булып, иярчен җөмләне алмаштырып килүен күрү, баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүзнең һәм аның ярдәмендә бәйләнгән иярчен җөмләнең функцияләре бер үк булуны табу авторның синтаксис фәне өлкәсендәге ачышы дип карарга мөмкин.

М. Зәкиев монографиясенең «Татар сөйләменең структур төзелеше» дип аталган бүлегендә күптөрле проблемалар тикшерелә: татар сөйләменең синтагматик төзелеше, сөйләмдә сүзләр һәм җөмләләр тәртибе, татар сөйләмендә җөмләләрнең кимлеге, күп буынлы кушма җөмләләрнең структурасы, тезем үзенчәлекләре. Бу бүлектәге проблемалар, яңача куелыш табып, үзенчәлекле хәл ителгәннәр.

Татар теленең беренче академик грамматикасын төзү барышында да синтаксис фәне шактый үстерелде. Мәгълүм булганча, 60 нчы еллар башында ук СССР Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм тарих институтында беренче татарча академик грамматика төзү бурычы куела. Аның синтаксис бүлеген язу педагогия институты ректоры М. Зәкиевкә тапшырыла. Бу академик грамматиканың беренче томы «Хәзерге татар әдәби теле (лексика, фонетика, орфоэпия, графика һәм орфография, морфология)» исеме астында 1965 елда дөнья күрә (300 б.). Ул югары уку йорты студентлары һәм урта мәктәп укытучылары өчен дип чыгарыла.

Беренче академик синтаксис исә М. Зәкиев тарафыннан 1966 елда «Хәзерге татар әдәби теле (синтаксис)» дигән исем белән бастырыла (290 б.). Бу хезмәт тә студентлар һәм укытучыларга атап төзелә.

Татар теле төзелеше белән башка халыклар галимнәрен дә таныштыру максатыннан чыгып, тиздән бу академик грамматиканы русча эшкәртеп, яңартып чыгару бурычы куела. Күп тә үтми 1969 елда, Мәскәүдә, «Наука» нәшриятында аның «Современный татарский литературный язык. Лексикология, фонетика, морфология» дигән беренче өлеше басыла (380 б.). 1971 елда шунда ук аның М. Зәкиев тарафыннан төзелгән «Современный татарский литературный язык. Синтаксис» дигән томы дөнья күрә (310 б.).

Студентлар һәм укытучылар өчен кирәк булганлыктан, М. Зәкиев 1974 һәм 1984 елларда синтаксис монографиясен тагын да эшкәртеп, татарча бастыра. Аларның исемнәре: 1) Хәзерге татар әдәби теле (синтаксис) …Студентлар һәм …укытучылар өчен. Тулыландырылган икенче басма. Казан, 1974. 336 б.; 2) Хәзерге татар әдәби теле синтаксисы һәм пунктуациясе. Студентлар һәм укытучылар өчен кулланма. Казан, 1984. 256 б. Боларда автор синтаксис буенча киң күләмле өйрәтмәләрен бераз җыйнакландыра, җиңеләйтә һәм студентларга яраклаштырып бирә.

Педагогия училищелары, колледжлар һәм гимназияләр өчен дип, 1994 елда Ф.С. Сафиуллина һәм М.З. Зәкиев «Хәзерге татар әдәби теле» дигән монографик дәреслек чыгардылар. Ни өчен моны монографик дибез, чөнки анда лексикология дә, фонетика да, сүзьясалышы да һәм морфология белән синтаксис та урын алган. Синтаксис укучыларга яраклаштырып кыскартылган.

Шул ук елда Ф.С. Сафиуллина, татар текстын (тоташ сөйләмне) өйрәнүне тирәнәйтеп, текст синтаксисы буенча да монографик хезмәт язды.

Бу – синтаксисның иң авыр бер өлешен үстерү юнәлешендә бик уңай бер тәҗрибә дип каралырга тиеш.

Татар синтаксисы үсешенең кыскача тарихын академик планда язылган хезмәткә күзәтү белән тәмамлау дөрес булыр дип уйлыйм.

80 нче еллар башында галимнәр алдына татар теленең академик грамматикасын яңадан төзеп русча чыгару бурычы куела, һәм 1992–1993 елларда бу хезмәт М. Зәкиев җитәкчелегендәге авторлар

коллективы тарафыннан өч томда чыгарыла. 1994 елда «Татарская грамматика» дип аталган өч томдагы бу академик басма Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге дәүләт премиясенә лаек дип табыла.

М. Зәкиев тарафыннан төзелгән 488 битлек «Синтаксис» томына нинди яңалыклар кертелә соң? Шуңа кыска гына тукталу урынлы булыр. Китап «Гади җөмлә синтаксисы», «Кушма җөмлә синтаксисы» һәм «Текст синтаксисы» дигән бүлекләрдән тора.

«Гади җөмлә синтаксисы» бүлегендә, традицион булган «Сүзтезмәләр», «Җөмлә кисәкләре», «Сүз тәртибе», «Җөмлә төрләре» белән бергә, татар синтаксис фәне өчен бөтенләй яңа темалар да бирелгән. «Гади җөмләнең грамматик схемалары һәм модельләре» дигән яңа бүлектә татар теленә хас җөмлә калыплары тикшереп ачыклана, аларның модельләре күрсәтелә. Мәсәлән, татар әдәби сөйләмендә 52 калып-схема ачыла, аларның нинди мәгънә белдерүгә сәләтле булулары тикшерелә, формалары буенча төрләре (парадигмалары) ачыклана. Мәсәлән, Ия + Хәбәр-*макчы* калыбы-схемасы русча Под. – Ск. моделе белән күрсәтелгән. Семантикасы – ия белән бирелгән субъект башкарырга ниятләгән процессны хәбәр итү. Бу калыпның фигыльгә хас инкяре юк (*бармамакчы* димиләр), исемгә хас инкяре бар (*бармакчы түгел*). Ул телгә хас булган төрле парадигмалар белән *иде, ит, бул* фигыльләре ярдәмендә төрләнә. Менә шул рәвештә 52 калыпның һәммәсе дә тикшерелә.

Һәрбер җөмлә калыбының нинди формаларга һәм парадигмаларга керә алуын тикшерүгә автор аерым бер бүлекчә багышлый. Биредә һәрбер калыпның зат парадигмасы, төр (наклонение) парадигмасы җентекле күрсәтелә. Татар теленә хас җөмлә калып-схемаларының сөйләмдә гамәлгә керүләрен өйрәнү дә татар синтаксис фәне өчен яңалык. Шушында ук җөмләләрнең семантик кисәкләргә таркалуы да схема-модельләр белән күрсәтелгән.

«Кушма җөмлә синтаксисы» бүлегендә төп яңалык шул: традицион синтетик кушма җөмләләр, иярченле кушма җөмләләрдән аерылып, ябышкан (спаянные) кушма җөмләләр дип өйрәнелгәннәр. «Иярченле кушма җөмлә» дип төзелеше белән һинд-европа телләрендәге «Сложноподчиненные предложения»гә азмы-күпме туры килгәннәре генә, ягъни элек «аналитик кушма җөмлә» дип аталганнары гына

алынган. Бу бүленеш рус тюркологларының төрки телләрдә кушма җөмләләр әле һинд-европа дәрәҗәсенә үсеп җитмәгән дип расларга тырышуларының дөреслеккә туры килмәвен күрсәтү өчен үткәрелгән. Бу татарча «Синтаксис»та иярченле кушма җөмләләрне синтетик һәм аналитик дип бүлү яңадан кайтарылды.

Русча язылган академик синтаксиста «Текст синтаксисы» бүлеге дә яңа эзләнүләр белән баетылган.

Гомумән алганда, татар синтаксис фәне өч томлык академик грамматиканы төзегәндә бик нык баетылды, лингвистиканың дөньякүләм казанышларын мөмкин кадәр үз эченә алды. Укучыларга тәкъдим ителә торган бу татарча академик синтаксиста татар сөйләменең синтактик (шәкли) һәм семантик структурасын тагын да тирәнрәк ачу максаты куелды.

# ГАДИ ҖӨМЛӘ СИНТАКСИСЫ

**§ 13. «Гади җөмлә синтаксисы» бүлекләре турында гомуми мәгълүмат.** Сөйләмнең күптөрле үзенчәлекләре гади җөмләгә бәйле рәвештә өйрәнелә. Шуңа күрә синтаксис фәненең «Гади җөмлә синтаксисы» дигән бүлеге иң зур урынны алып тора. Бу бүлектә сөйләм интонациясе, сүзләр бәйләнеше, җөмлә кисәкләре, җөмлә калыплары (схемасы һәм модельләре), җөмлә төрләре, сүз тәртибе проблемалары җентекләп өйрәнелә.

## ИНТОНАЦИЯ ҺӘМ АНЫҢ СӨЙЛӘМДӘГЕ РОЛЕ

**§ 14. Интонация турында гомуми мәгълүмат.** Сүзләрдән җөмлә, җөмләләрдән сөйләм оештырганда, җөмләнең һәм сөйләмнең аерылгысыз элементы булып, интонация дә катнаша. Соңгы елларда интонациянең барлык төр чагылышларын да, бергә алып, тавыш хәрәкәте турындагы фән итәрәк, **просодия** дигән исем астында өйрәнә башладылар. Бу урында без просодия турында гомуми белем бирергә җыенмыйбыз, бары җөмләне һәм сөйләмне оештырганда, беренче чиратта игътибар ителергә тиешле тавыш хәрәкәте хакында гына башлангыч белем бирергә кирәк саныйбыз. Интонация, ягъни сөйләгәндә тавышның төрлечә хәрәкәте (күтәрелүе, төшүе, аерым урында көчлерәк яки көчсезрәк, сузыбрак яки кыска итеп, тиз генә әйтелүе, паузалар ясау һ.б.) җөмләдә кирәкле мәгънә бирү өчен хезмәт итә. Сөйләгәндә, төрле кешенең интонациясе төрлечә була, ләкин әдәби телдә сөйләүчеләр өчен интонациянең уртак бер нормасы да билгеләнә. Синтаксис фәне әнә шул норма итеп кабул ителгән интонацияне өйрәнә.

Интонациянең җөмлә төзүдә зур роль уйный торган һәм үзара тыгыз бәйләнештә булган өлешләре түбәндәгеләр: а) фраза басымы, ә) пауза, б) логик басым, в) тойгы басымы, г) җөмләнең билгеле бер көй белән әйтелүе, ягъни тавышның аерым урыннарда күтәрелүе яки төшүе, сузыбрак әйтелүе.

**§ 15. Фраза басымы** – бер яки мәгънә ягыннан бәйләнгән берничә сүзне (синтагманы) бер басым астына алып әйтү дигән сүз. Синтагмада берничә сүз булганда, басым шундагы бер сүзгә төшә, башкалары шул басымлы сүзгә кушылып китәләр. Бу күренеш, бердән, җөмләнең нормаль төзелешен саклауда роль уйнаса, икенчедән, ул сүзләрнең бәйләнешен дә тәэмин итә. Мәсәлән: *Табигый законнарны | үз белдегең белән | бозып булмый* дигән мисалда *табигый* һәм *законнар* сүзләре, бер фраза басымы белән әйтелгәндә генә, бер-берсенә бәйләнәләр; алар һәрберсе аерым фраза басымы белән әйтелсәләр, ягъни алар арасында пауза ясалса, үзара бәйләнмәсләр иде: *Табигый,| законнарны | үз белдегең белән | бозып булмый.*

**§ 16. Пауза.** Җөмләнең нормаль төзелешен һәм андагы сүзләрнең үзара бәйләнешен тәэмин итүдә, фраза басымы белән бергә, паузаның да роле бар. Чөнки һәрбер синтагма, ягъни фраза басымына тупланган сүзләр, башка синтагмалардан паузалар белән аерыла. Пауза синтагмаларны гына түгел, бәлки җөмләләрне дә бер-берсеннән аера, аерымланган иярчен кисәкләрне, эндәш һәм кереш сүзләне аерырга ярдәм итә.

**§ 17. Логик басым.** Җөмләдә мәгънәсе буенча иң әһәмиятле булган сүзгә төшә торган басымны логик басым диләр. Логик басым төшә торган сүзне, ягъни тыңлаучы өчен яңа булган төшенчәне хөкемләүнең предикатын белдерүче сүз дип атыйлар. Логик басымны күчерү белән, җөмләнең мәгънәсе дә үзгәрә, башка төрле хөкемләү барлыкка килә. Мәсәлән, *Без сезгә бер йомыш белән килгән идек* (К. Тинчурин) дигән мисалда логик басым *йомыш белән* кисәгенә төшә, һәм бу очракта җөмлә *Сез безгә ни өчен килгән идегез?* дигән сорауга җавап рәвешендә әйтелә. Логик басым шул ук җөмләдә *сезгә* яки *без*, яки *килгән идек* кисәкләренә дә төшәргә мөмкин: һәрбер очракта җөмләнең мәгънәсе үзгәрә. Язма әдәби телдә, логик басым хәбәрдән башка кисәккә төшсә, ул кисәк хәбәр алдыннан янәшә куела. Мәсәлән, югарыдагы мисалда логик басым *сезгә* яки *без* кисәкләренә төшсә, җөмлә, кагыйдә буларак, түбәндәгечә төзелергә тиеш: *Б е з  бер йомыш белән с е з г ә  килгән идек; С е з г ә  бер йомыш белән б е з  килгән идек.*

**§ 18. Тойгы басымы.** Тойгы басымы көчле тойгы белән әйтелгән җөмләләрдә аерым сүзләргә төшә һәм сөйләүченең чынбарлыкка нинди мөнәсәбәттә торуын белдерә. Тойгы басымы төшкән сүз сузыбрак

әйтелә. Ул күп вакыт логик басым белән бер урынга туры килә, аннан аерым да булырга мөмкин.

Мәсәлән: *Сезгәме со-оң гомуми эшләр артыннан йөрү-ү!* (К. Тинчурин); *Һәр икесе ике кулыңнан тоталар да, әйдә-ә-ә бөтен дөнья буенча сөйрәргә-ә!* (Г. Тукай).

**§ 19. Сөйләм көе.** Сөйләм көе тойгы басымы, логик басым һәм пауза белән аерылгысыз бәйләнгән. Сөйләмнең көенә карап, җөмләләрнең төрләре, сүзләр һәм җөмләләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләре, модаль мәгънәләр билгеләнә.

Интонация, үзенең көенә карап, берничә төргә бүленә.

1. Тулы интонация, ягъни күтәрелү өлеше, югары ноктасы һәм төшү өлеше булган интонация. Мәсәлән:




2. Әкренләп күтәрелеп бара һәм үзенең иң югары ноктасында кинәт туктап кала торган интонация. Мондый интонацияне күтәрелүче интонация диләр. Мәсәлән:




3. Төшүче интонация, ягъни үзенең югары ноктасыннан башланып, әкренләп төшеп баручы интонация.

Мәсәлән:

*Рәхәт тә*

*соң*

*шушы*

*олыларга*

*тагылып йөрү!* (И. Гази)

4. Катнаш интонация. Мәсәлән:

*йөрү!* (К. Тинчурин)

*соң* *артыннан*

*Сезгәме* *гомуми эшләр*

Катнаш интонациянең башка төрле вариантлары да очрый.

**§ 20. Интонациянең башка төрләре.** Интонация, сөйләм көенә һәм паузаның характерына карап, тагын түбәндәге төрләргә бүленә.

**Хәбәр итү интонациясе** теләсә нинди җөмләне тәмамлап куя. Бу төр интонация булмаса, сүзләрдән җөмлә оеша алмый. Хәбәр итү интонациясе хикәяләү, сорау, боеру, үтенү дигән төрләргә бүленә. Тойгыга бай җөмләләрдә хәбәр итү интонациясе бик күптөрле тойгы басымы белән төрләнә ала.

**Санау интонациясе** хәбәр итү интонациясеннән бик ачык аерылып тора. Мәсәлән, *Әминә, врач, Гали, инженер* дигән сүзләрне санау интонациясе белән әйтсәк, ул бары нәрсәдер эшләүчеләрне санап чыгу гына була: *Әминә, врач, Гали, инженер безгә кунакка килделәр.* Шул ук дүрт исемне хәбәр итү интонациясе белән әйтсәк, алар ике хәбәрлек төзиләр: *Әминә – врач, Гали – инженер*. Санау интонациясе тиңдәш кисәкләр һәм тиңдәш җөмләләрне үзара бәйләүдә катнаша.

**Каршылык интонациясе** бер-берсенә семантик каршы куелган сүзләр яки җөмләләр арасында була. Мәсәлән, *укыдым – аңламадым; килде – күрә алмады; матур, ләкин усал; Әминә – врач, ә Гали – инженер* һ.б.

**Көттерү интонациясе** кисәкләр яки җөмләләр арасында көттерү паузасы булуга бәйләнгән. Бер кисәк яки җөмлә әйтелә дә, «әле сүз бетмәде, тагын әйтәсе бар» дигән кебек көттерү паузасы ясала, шуннан соң гына калган сүз-кисәк яки җөмлә әйтелә: *Монда үсәләр: юкә, усак, каен, имән; Шунда күрәм: лампам эчендә май кими* (Г. Тукай). Көттерү паузасы булган урында һәрчак ике нокта куела.

Кайбер хезмәтләрдә интонация сүзен пауза сүзе белән дә алмаштырып йөриләр: хәбәр итү интонациясе – хәбәр итү паузасы, санау интонациясе – санау паузасы, каршылык интонациясе – каршылык паузасы, көттерү интонациясе – көттерү паузасы дип тә атала.

Интонациянең бу төрләре дә, телдәге башка чаралар кебек үк, мәгънә белдерүдә катнашалар, шуңа күрә алар тел-сөйләм чаралары рәтеннән каралалар.

## ҖӨМЛӘДӘ СҮЗЛӘР БӘЙЛӘНЕШЕ

**§ 21. Сүзләрнең үзара бәйләнеш төрләре һәм аларның сөйләмне оештырудагы рольләре.** Сөйләмдә сүзләр үзара ике төрле бәйләнешкә керәләр. Сүзләр бер-берсенә буйсынган булсалар, мондый бәйләнешне ияртүле бәйләнеш диләр. Сүзләр бер-берсенә буйсынмыйча, үзара тигез хокукта булсалар, бу бәйләнешне тезүле бәйләнеш дип атыйлар.

Тезүле бәйләнеш үзе генә җөмлә оештыра алмый. Ул җөмләдә ияртүле бәйләнеш белән бергә генә килә. Башкача әйткәндә, ияртүле бәйләнешсез сөйләм оеша алмый, тезүле бәйләнешнең исә сөйләмдә булуы мәҗбүри түгел.

Бер сүз берничә сүзне берьюлы буйсындырып, соңгылары буйсындыручы сүзгә бер үк мәгънә мөнәсәбәтендә торсалар, буйсынучы сүзләр арасында тезүле бәйләнеш була. Мәсәлән: *Дөресен әйткәндә, халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул* (Г. Тукай). Монда бер иягә берничә хәбәр берьюлы буйсынган, һәм шуңа күрә хәбәрләр арасында тезүле бәйләнеш барлыкка килгән.

Бер сүз берничә сүзгә берьюлы буйсынып, буйсынучы сүз буйсындыручы сүзләрнең һәрберсенә бер үк төрле мәгънә мөнәсәбәтендә торса, буйсындыручы сүзләр арасында тезүле бәйләнеш була. Мәсәлән: *Өйләр, коймалар, абзар-кура, агачлар, мал-туар юньләп күренми…*

(Ф. Садриев). Монда бер хәбәр берничә иягә берьюлы ияргән, шуңа күрә ияләр арасында тезүле бәйләнеш барлыкка килгән.

Сөйләм оештырудагы әһәмиятенә карап, ияртүле бәйләнеш өч төргә бүленә: хәбәрлекле, төгәлләүле, аныклаулы. Бу төр бәйләнешләрне мөнәсәбәт дип йөртү дә гадәткә кергән.

Хәбәрлекле мөнәсәбәт ия белән хәбәр арасында гына була, һәм бу вакытта ияргүче сүз (хәбәр) ияртүче сүз (ия) белдергән төшенчә турында нинди дә булса бер яңалык хәбәр итә. Хәбәр итү хикәяләгәндә генә түгел, сорауны, боеруны һәм эчке кичерешләрне белдергәндә дә була. Хәбәрлекле мөнәсәбәт нигезендә сөйләмнең төп берәмлеге – җөмлә барлыкка килә. Шуңа күрә ул – сүзләр арасындагы бәйләнеш төренең иң әһәмиятлесе булып санала, сөйләм оештыруда **беренче дәрәҗәдәге** рольне уйный.

Сүзләр арасында төгәлләүле мөнәсәбәт булганда, ияргүче сүз ияртүче сүздән аңлашылган әйберне (төшенчәне) шуңа охшаган башка әйберләрдән (төшенчәләрдән) аерып, конкретлаштырып килә. Ягъни бу чакта ияргүче сүз ияртүче сүзнең мәгънәсен төгәлрәк итә. Мәсәлән, *кызыл галстук* тезмәсендә *кызыл* сүзе (ияргүче) *галстук* сүзен (ияртүчене) ачыклый, төгәлли, ягъни галстукның кызыл булуын гына белдерә, аны башка төстәге галстуклардан аерып, конкретлаштырып күрсәтә. *Галстук* гомуми мәгънәле иде, *кызыл галстук* төгәлрәк мәгънәле. *Арыш уру* тезмәсендә дә шул ук хәл: *арыш* сүзе *уру* сүзенең гомумән уруны (мәсәлән, солы, бодай һ.б. уруны) белдермәвен, бәлки *арыш уруны* гына белдерүен күрсәтә. *Шәһәрдә яшәү* тезмәсендә *шәһәрдә* сүзе *яшәү* сүзен конкретлаштыра, төгәлли, ягъни аның теләсә кайда (мәсәлән, авылда, кырда) яшәүне белдермәвен, бәлки бары *шәһәрдә яшәүне* генә белдерүен күрсәтә. Төгәлләүле мөнәсәбәт бервакытта да үзе генә сөйләмне һәм сөйләмнең төп берәмлеген – җөмләне төзи алмый. Ул сөйләмдә бары хәбәрлекле мөнәсәбәт яки хәбәрлек белдерүче сүз янында гына катнаша. Төгәлләүле мөнәсәбәт, үзе ялгыз булганда, бары сүзтезмә генә төзи һәм сөйләм оештыруда **икенче дәрәҗәдәге** рольне уйный.

Аныклаулы мөнәсәбәт булганда, ияргүче сүз, ияртүче сүздән соң килеп, аңа өстәмә төгәллек, аныклык бирә: *Бервакыт, язга чыккач, Ильяслар классы мәктәп тәҗрибә участогында эшләргә калды* (Р. Төхфәтуллин). Бу җөмләдә *язга чыккач* дигән сүзләр ияртүче сүздән (*бервакыт* сүзеннән) соң килеп, аңа аныклык кертә.

Төгәлләүле мөнәсәбәттә торган сүзләр арасында буйсыну бер генә яклы була: иярүче сүз ияртүче сүзгә генә буйсына. Аныклаулы мөнәсәбәттә торучы сүзләр арасында бәйләнеш ике яклы була: *Сугыш беткәч, мин М ә с к ә ү г ә, и н с т и т у т к а, җибәрелдем* (М. Максуди). Бу җөмләдәге *институтка* сүзе, аныклагыч буларак, *Мәскәүгә* сүзенә буйсынып килә, шул сүзне аныклый. Бер ук вакытта ул, үзенең ияртүчесе булган *Мәскәүгә* сүзе белән бергә, *җибәрелдем* дигән хәбәргә буйсына, аның белән төгәлләүле мөнәсәбәткә дә керә. Бу җөмләдә аныклагыч та, аныкланмыш та, хәбәргә буйсыну өчен, юнәлеш килеше формасын алганнар (*Мәскәүгә, институтка*).

*Күрше малайлар – борынгы дуслар да килделәр* (Г. Ибраһимов) мисалында *дуслар* сүзе *малайлар* кисәген аныклый, аңа өстәмә төгәллек бирә һәм бер ук вакытта *малайлар* кисәгенә ияргән хәбәр белән хәбәрлекле мөнәсәбәткә керә (*малайлар килделәр – дуслар килделәр*).

Димәк, аныклаулы мөнәсәбәт сөйләм оештыруда я хәбәрлекле, я төгәлләүле мөнәсәбәт белән бергә генә катнаша ала, шуңа күрә сөйләм оештыруда **өченче дәрәҗәдәге** рольне уйный.

Хәбәрлекле мөнәсәбәт җөмлә төзи, төгәлләүле һәм аныклаулы мөнәсәбәтләр җөмләне төзи алмыйлар, бәлки җәенкеләндерәләр генә.

**§ 22. Хәбәрлекле мөнәсәбәтне белдерүче чаралар.** Хәбәрлекле мөнәсәбәттәге сүзләр түбәндәге чаралар ярдәмендә үзара бәйләнәләр:

1. Хәбәрлек кушымчалары. Мәсәлән: *Мин укучымын. Матурсың син, гүзәлсең син. Без инженерларбыз. Гали укытучыдыр.*

2. Зат һәм сан кушымчалары. Мәсәлән: *Мин язам. Син язасың. Без күрәбез. Сез күрәсез. Ул күрә. Алар күрәләр.* III затның аерым кушымчасы юк, ләкин I һәм II затлар мәҗбүри рәвештә кушымча алганлыктан, III зат кушымчасыз да, ягъни нуль форма белән, башка затлардан аерылып тора.

3. Сүз тәртибе, ягъни билгеле тәртиптә торганда гына, сүзләрнең хәбәрлекле мөнәсәбәткә керә алулары. Мәсәлән: *Өй биек. Һава саф.* Башка очракларда сүз тәртибе хәбәрлекле мөнәсәбәтне нормаль саклау хезмәтен үти.

4. Интонация. Сүзләр үзара нинди генә чаралар ярдәмендә бәйләнсәләр дә, әгәр дә алар киң мәгънәсендә хәбәр итү интонациясе

белән әйтелмәсәләр, хәбәрлекле мөнәсәбәт барлыкка килми. Кайбер тезмәләрдә исә хәбәрлекле мөнәсәбәтне белдерүдә хәбәр итү интонациясе төп рольне уйный. Мәсәлән, *Әминә – врач, Гали – инженер.* Шушы ике җөмләгә кергән сүзләр хәбәр итү интонациясе белән түгел, бәлки санау интонациясе белән әйтелсәләр, ул сүзләр арасында хәбәрлекле мөнәсәбәт бөтенләй югала. Мәсәлән: *Әминә, врач, Гали, инженер – һәммәсе бергә килде.*

Күрсәтелгән бәйләүче чаралардан тыш, хәбәрлекле мөнәсәбәттәге сүзләр арасындагы төрле мәгънә мөнәсәбәтләрен түбәндәге чаралар белдереп килә.

1. *-ныкы/-неке* кушымчасы. Мәсәлән: *Таулар авылында өч җил тегермәне бар, аларның берсе Мәлик байныкы* (И. Гази).

2. Чыгыш, юнәлеш, урын-вакыт килеше кушымчалары. Мәсәлән: *Мин күктән!* (Ф. Сафин). *Кеше барыбер кошлар нәселеннән* (С. Сөләйманова). *Бу хат сиңа. Тарих ул гел үсештә* (Р. Вәлиев). *Бабаң авыр хәлдә* (Р. Вәлиев).

3. *-лык/-лек* кушымчасы. Мәсәлән: *Кеше түгел – җансыз ташның салкын тәне авыртырлык* (Р. Харис).

4. Сәбәп-максат һәм чагыштыруны белдерүче бәйлекләр. Мәсәлән: *Тырышуым синең өчен. Авыл иркен болын шикелле* (Л. Зөлкарнәй). *Минем язмыш поезд язмышы кебек* (Р. Вәлиев). *Кырлар диңгез кебек* (М. Хуҗин).

Соңгылары чын мәгънәсендә бәйләүче чаралар була алмыйлар, чөнки алар, югарыда күрсәтелгән бәйләүче чараларның берсе яки берничәсе булганда гына, иярүче һәм ияртүче сүзләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтен белдерәләр. Сүзләр хәбәрлекле мөнәсәбәткә кергәндә, соңгы өч төрле чара белән бергә я сүз тәртибе, я хәбәр итү интонациясе, я күплек кушымчасы, я хәбәрлек кушымчасы килергә тиеш була. Мәсәлән: *Мин синең кебек түгелмен. Алар безнекеләр.*

Гомумән алганда, хәбәрлекле мөнәсәбәтне белдерүче чаралар һәрберсе аерым-аерым ялгыз гына йөрмиләр, бәлки аларның берничәсе берьюлы кулланыла.

**§ 23. Төгәлләүле мөнәсәбәтне белдерүче чаралар.**

1. Кушымчалар.

а) Килеш кушымчалары. Мәсәлән: *тормышны сөю, кырга чыгу, тәрәзәдән карау, шәһәрдә тору, укучының китабы.*

ә) Хәл (рәвеш) фигыль кушымчалары. Мәсәлән: *баргач карау, эшләп уку, белмичә сөйләү, киткәнче күрү.*

б) Шарт фигыль кушымчасы. Мәсәлән: *тырышсаң табу, белсәң генә әйтү.*

в) Инфинитив кушымчасы. Мәсәлән: *карарга килү, ачыкларга булышу* һ.б.

г) Сыйфат фигыль кушымчалары. Мәсәлән: *киләчәк көн, барасы юл, күрер күз, укыган кеше, ашый торган үлән, караучы кеше.* Сыйфат фигыль кушымчалары үзләре генә актив бәйләүче чара була алмыйлар. Алар һәрвакыт янәшә тору чарасы белән яки килеш кушымчалары белән бергә кулланылалар.

д) Сыйфат һәм рәвеш ясаучы кайбер кушымчалар. Мәсәлән: *-лы/-ле, -сыз/-сез, -дагы/-дәге, -ча/-чә, -дай/-дәй.*

Күрсәтелгән кушымчалар, сөйләм барышында кирәк булганда, төрле сүзләрне үзара бәйлиләр, алар арасында төрле мәгънә мөнәсәбәте урнаштыралар. Мәсәлән, сөйләм барышында ике процессның шарт, вакыт яки сәбәп ягыннан бәйләнешен күрсәтергә туры килсә, шул процессларны белдерүче фигыльләрне, гадәттә, *-са/-сә, -гач/-гәч* кушымчалары аркылы бәйләп китерергә кирәк була: *барсам әйтәм, күргәч әйтү, укымагач белмәү* һ.б.

Югарыда саналган кушымчаларның кайсы сүзләрне кайсы төркем сүзләргә бәйләп килүләрен түбәндәге таблицадан ачык күрергә була.

| Ияртүче сүз | Ияртүче сүз | |
|---|---|---|
| | исем яки исем ролендә килгән башка сүз | фигыль яки фигыль ролендә килгән башка сүз |
| Исем | -ның/-нең<br>-лы/-ле<br>-сыз/-сез<br>-дагы/-дәге, -гы/-кы<br>-лык/-лек<br>-чан/-чән<br>-чыл/-чел<br>-лач/-ләч<br>-дай/-дәй | -ны/-не<br>-га/-гә/-ка/-кә, -на/-нә<br>-да/-дә/-та/-тә<br>-дан/-дән/-тан/-тән<br>-ча/-чә, -нча/-нчә<br>-ын/-ен<br>-лай/-ләй<br>-лап/-ләп<br>-лата/-ләтә |

| | | |
|---|---|---|
| Фигыль | -ган/-гән<br>-а/-ә/-ый/-и +торган<br>-асы/-әсе<br>-учы/-үче<br>-ачак/-әчәк<br>-ыр/-ер | -ып/-еп/-п<br>-а/-ә/-ый/-и<br>-мыйча/-мичә<br>-гач/-гәч/-кач/-кәч<br>-ганчы/-гәнче/-канчы/-кәнче<br>-ырга/-ергә<br>-са/-сә |

2. Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр. Мәсәлән: *кош кебек очу, халык өчен тырышу, каләм белән язу, халык арасында эшләү, өй эченнән чыгу, урам буеннан йөрү, булсын дип эшләү, сандугач булып сайрау, бригадир итеп сайлау, юл буенча чабу.* Бу чаралар алда килгән сүзнең формасын тәшкил итәләр.

3. Сүз тәртибе. Кайбер тезмәләрдә буйсынучы һәм буйсындыручы сүзләрне үзара билгеле тәртиптә урнаштырганда гына, сүзләр арасындагы конкрет бер төрдәге мөнәсәбәт саклана ала. Мәсәлән: *кызыл яулык* – төгәлләүле мөнәсәбәт, *яулык кызыл* – хәбәрлекле мөнәсәбәт.

Сүз тәртибе, башка чаралар белән бергә килгәндә, синтаксик мөнәсәбәтләрне нормаль саклау хезмәтен дә үти. Мәсәлән: *бала ярату, киноны карау, аңа ярдәм итү, тәрәзәдән карау, кичен эшләү, югарыдан очу* кебек тезмәләрдәге сүзләрнең урыннары алмаштырылса, сүзләр арасындагы мөнәсәбәт нормаль булмас, бозылыр иде.

4. Янәшә тору. Кайбер тезмәләрдә сүзләр, бары янәшә торып кына, үзара синтаксик мөнәсәбәткә керәләр, янәшә торудан аерсаң, алар арасында мөнәсәбәт калмый. Мәсәлән: *Ул бүген абыйсы белән кино карады* җөмләсендә *кино* һәм *карады* сүзләре үзара янәшә тору чарасы аша бәйләнгәннәр, ягъни алар арасындагы мөнәсәбәт сүзләр янәшә торганда гына аңлашыла. Әгәр дә *кино* һәм *карады* сүзләрен бер-берсеннән аерсаң, алар арасында мөнәсәбәт, бәйләнеш бозыла: *Кино ул бүген абыйсы белән карады* дип сөйләү һәм язу әдәби норманы бозу була. Соңгы җөмләдә *кино* һәм *карады* сүзләре арасында мөнәсәбәт булдыру өчен, я ияртүче сүзгә -*ны* кушымчасын өстәргә кирәк (*Киноны ул бүген абыйсы белән карады*), я аны ияртүче сүз белән янәшә куярга кирәк (*Ул бүген абыйсы белән кино карады*). Бу

факт янәшә тору чарасының бәйләү көче кушымчаларның бәйләү көче дәрәҗәсендә дигән нәтиҗәне ясарга мөмкинлек бирә.

Янәшә тору чарасы аша бәйләнеш исемнәр арасында гына түгел, төп сыйфатлар, рәвешләр һәм саннар башка сүзләргә ияргәндә дә күзәтелә. Мәсәлән: *Ул һичкайчан кире әйтми* (Г. Әпсәләмов). *Аңа буйдан-буйга зәңгәр чәчәкләр төшерелгән* (Г. Бәширов).

5. Ф р а з а  б а с ы м ы. Бу чара төгәлләүле мөнәсәбәтне белдерүче башка чаралар белән бергә катнаша. Мәсәлән, *кызыл яулык, китапны уку, шәһәр бакчасы* кебек тезмәләрнең һәрберсен аерым фраза басымы белән әйткәндә генә, андагы сүзләр арасында төгәлләүле мөнәсәбәт була. Әгәр тезмәдәге һәрбер сүз санау интонациясе белән әйтелсә, төгәлләүле мөнәсәбәт булмас иде: *кызыл, яулык, китапны, уку, шәһәр, бакчасы.*

6. С ү з л ә р н е  к а б а т л а у. Кайвакыт иярүче сүз кабатланса гына, сүзләр үзара төгәлләүле мөнәсәбәткә керәләр. Мәсәлән: *чиләк-чиләк җиләк, вагон-вагон кеше, мичкә-мичкә кымыз, тәпән-тәпән май, эшли-эшли ару, вакыт-вакыт килү*; *К ө т ү - к ө т ү  б о л ы т ага җилдә Черем иткән йортлар өстеннән…* (Зөлфәт). Әгәр мондый тезмәләрдә иярүче сүз кабатланмаса, сүзләр арасында төгәлләүле мөнәсәбәт барлыкка килмәс иде. Димәк, сүзләрне кабатлау да төгәлләүле мөнәсәбәтне белдерүче чара була ала.

7. Л е к с и к  м ә г ъ н ә. Сүзләр бәйләнешендә лексик мәгънә һәрвакыт төп рольне уйный, ул барлык төр тезмәләрдә дә була һәм башка төрле бәйләнеш чаралары белән бергә йөри. Бары төгәлләүле мөнәсәбәткә нигезләнгән тезмәләрдә лексик мәгънә ялгызы гына сүзләрне бәйләп килергә, ягъни төгәлләүле мөнәсәбәт белдерергә мөмкин. Мәсәлән, *бүген генә урманнан кайту, юри әйберләр шалтыратып тавышлану* тезмәләрендә *бүген* һәм *кайту, юри* һәм *тавышлану* сүзләре арасындагы бәйләнешне тик сүзләрнең лексик мәгънәләреннән генә белергә мөмкин.

Соңгы очракны исәпкә алмаганда, барлык төр тезмәләрдә дә төгәлләүле мөнәсәбәтне белдереп, берничә чара берьюлы катнаша.

**§ 24. Аныклаулы мөнәсәбәтне белдерүче чаралар.**

1) Ияртүче теркәгечләрнең бер төре булган аныклаучы теркәгечләр һәм теркәгеч сүзләр: *ягъни, мәсәлән, хәтта, бигрәк тә, икенче төрле әйткәндә, башкача әйткәндә, аеруча* һ.б. Мәсәлән: *Авыллар, б и г р ә к*

*т ә Кара урман кебек ике тау арасында утырганнары, тагы бераз булса, бөтенләй кар астында калып югалыр мәртәбәгә якынлашканнар.* (Г. Ибраһимов). *Ул – сөйләүчеләрнең, а е р у ч а председательнең, бер сүзен дә ычкындырмыйча ишетеп калырга тырыша иде.* (А. Шамов). *Кызларның, б и г р ә к т ә Нуриянең, күзләре сокланудан ялтырап китте* (Г. Әпсәләмов).

2) Аныклау интонациясе. *Кызлар өй эчендә озак юанмадылар: бакчага чыктылар* (Ф. Әмирхан). *Мин бер атуда ике куянны алмак булам: бияне дә сакларга, балык та тотарга.* (Г. Ибраһимов).

**§ 25. Ярашу, башкарылу, янәшәлек.** Тел белемендә ияртүле бәйләнешне, анда кулланылган синтаксик чараларның төренә карап һәм ияртүче сүз таләбе буенча ияртүче сүзнең нинди форма алуыннан чыгып, төп өч төргә бүлү традиция булып киткән: ярашу, башкарылу, янәшәлек.

Иярүче сүз үзенең формаларын ияртүче сүз формасына карап яраштырса, мондый бәйләнешне я р а ш у дип атыйлар. Грамматик форма ягыннан ярашу чын мәгънәсендә татар телендә бары аныклагыч белән аныкланмыш арасында гына була. Мәсәлән: *Мине – а у л а к к а р а у р м а н у л ы н – Ни хикмәттер? – һаман су тарта!* (Зөлфәт). *Тукайның, б ө е к ш а г ы й р ь н е ң , әсәрләре халыкта туган телгә карата мәхәббәт тәрбиялиләр.*

Монда аныкланмыш (*мине, Тукайның*) һәм аныклагыч (*аулак кара урман улын, бөек шагыйрьнең*) бер үк килештә килгәннәр, димәк, килештә ярашканнар. Моннан тыш ия белән хәбәр арасында һәм тартымлы тезмәләрдә затта һәм санда ярашу була, мәсәлән, *мин укыйм, без укыйбыз, синең дәфтәрең.* Ләкин бу очраклар грамматик формада тулы ярашу булмыйлар, чөнки I, II зат алмашлыклары зат һәм сан белдерүче грамматик формаларны бервакытта да алмыйлар. Һәрбер зат аерым лексик берәмлек белән күрсәтелә. Димәк, биредә грамматик форманың билгеле бер лексик берәмлеккә ярашуы гына була.

Б а ш к а р ы л у юлы белән бәйләнеш булганда, ияртүче сүз иярүче сүзнең нинди дә булса бер килеш формасын алуын таләп итә яки кайсы да булса бер бәйлек белән килүен тели, мәсәлән: *укучының китабы, урманга бару, китапны уку, тәрәзәдән карау, әти белән килү, халык өчен тырышу, күпер аша чыгу.*

Ярашу да, башкарылу да булмаса, андый бәйләнешне я н ә ш ә - л е к юлы белән бәйләнеш дип йөрү гадәткә кергән. Димәк, янәшәлек

юлы белән бәйләнешкә хәл фигыль, шарт фигыль, сыйфат фигыль кушымчалары, кайбер сыйфат һәм рәвеш ясаучы кушымчалар, тартым кушымчасы, мөнәсәбәтле сүзләр, ияртүче теркәгечләр, сүз тәртибе, интонация, янәшә тору һәм лексик мәгънә аша бәйләнешләр кирә.

Шулай итеп бәйләүче чараларны ярашу, башкарылу һәм янәшәлек дигән төрләргә бүлүнең бернинди нигезе юк. Шуңа күрә хәзерге грамматик тикшеренүләрдә бу бүленеш кабул да ителми яки үзгәртелеп кулланыла. Мәсәлән, ярашу булганда, ияртүче һәм иярүче сүз икесе дә бер үк төрле грамматик форманы алалар; башкарылу булганда, бары иярүче сүз генә, ияртүче сүзнең таләбе буенча, нинди дә булса бер кушымчаны, бәйлекне яки бәйлек урынындагы сүзне ала; янәшәлек юлы булганда исә, сүзләр үзара янәшә тору чарасы, сүз тәртибе, интонация һәм лексик мәгънә аша гына бәйләнәләр, дип таныла.

Без конкрет бәйләүче чараларның үзләрен атап күрсәтүне генә таләп итәбез, аларның кайсы бәйләнешкә (ярашу, башкарылу, янәшәлеккәме) керүен сорамыйбыз. Мәсәлән, бәйләүче чара килеш кушымчасы икән, шул килеш кушымчасын атау җитә, ул башкарылуга керәме, янәшәлеккәме, анысын әйтүнең синтаксис өчен бернинди фәнни һәм практик әһәмияте юк.

**§ 26. Тезүле бәйләнешне белдерүче чаралар.** Тезүле бәйләнештәге сүзләр, үзара бер-берсенә буйсынмыйча тигез хокукта булсалар да, аерым-аерым нинди дә булса башка бер сүзгә буйсынган яки шул сүзне буйсындырган булалар (яисә ияртүле бәйләнеш үзеннән-үзе аңлашылып тора), һәм бары шуның нәтиҗәсендә генә алар үзара тезүле бәйләнештә тора алалар: *Мондагы тормыш борынгы гореф-гадәт, тарихи мирас, истәлекләр белән өретелгән* (М. Юныс).

Тезүле бәйләнешне белдерүче чаралар түбәндәгеләр: а) тезүче теркәгечләр (җыючылар – *һәм, да/дә, та/тә, ни–ни, шулай ук, вә, тагын, янә;* каршылык теркәгечләре – *ләкин, ә, бәлки, тик, әмма, мәгәр;* бүлүче теркәгечләр – *я, яки, яисә, әллә–әллә, әле–әле);* ә) санау интонациясы; б) каршылык интонациясы.

Санау һәм каршылык интонацияләре сүзләр үзара җыючы һәм каршылык теркәгечләре ярдәмендә бәйләнгәндә дә булалар, ләкин теркәгечләр кулланылмаганда, алар ачыграк сиземләнә.

Сүзләр үзара бүлүче теркәгечләре ярдәмендә бәйләнгәндә булган интонация санау һәм каршылык паузаларыннан бераз аерыла. Аны бүлгәләү паузасы дип атыйлар. Бүлүче теркәгечләрне төшереп калдырсак, ул сүзләрне аерым интонация белән бүлгәләү мәгънәсендә әйтеп булмый: алар, гадәттә, санау паузасы белән җыю мәгънәсендә әйтеләләр. Мәсәлән: *Я Сания, я Равил, яисә Азат килер – Сания, Равил, Азат килер.*

**§ 27. Сүзләр бәйләнешен өйрәнү тәртибе.** Сүзләр бәйләнешен өйрәнүне иң башта сүз төркемнәренә бәйләп алып барганнар: кайсы сүз төркеменең кайсы сүз төркеменә буйсынуын, нинди чаралар ярдәмендә буйсынуын һәм теге яки бу чараның сүзләр арасында нинди мәгънә мөнәсәбәте урнаштыруын тикшергәннәр. Моның өчен җөмләдән сүзтезмәләрне аерып чыгару кирәк булган. Аларны ияртүле сүзтезмәләр һәм тезүле сүзтезмәләр дигән төрләргә, ә ияртүле сүзтезмәләрнең үзләрен хәбәрлекле, тәмамлыклы, хәлле, аергычлы сүзтезмәләргә бүлеп йөрткәннәр.

Бераз соңрак сүзләр бәйләнешен җөмләне кисәкләргә бүлү юлы белән өйрәнә башлаганнар. Бик күп еллар буе (XIX йөз урталарыннан XX йөз урталарына кадәр) сүзләр бәйләнешен сүзтезмәләргә һәм җөмлә кисәкләренә бүлеп өйрәнү параллель алып барылган: кайбер галимнәр сүзләр бәйләнешен сүзтезмәләрдә өйрәнү җитә дип караганнар, кайберләре исә сүзләр бәйләнешен җөмлә кисәкләрен өйрәнүгә бәйле рәвештә тикшерүне алга сөргәннәр. Ләкин тегеләре дә, болары да сүз бәйләнешен өйрәнгәннәр: сүзтезмәләрне яклаучылар сүзләр бәйләнешен өйрәнүне, формадан башлап, мәгънәгә таба алып барганнар, җөмлә кисәкләрен яклаучылар, мәгънәдән чыгып, формага таба килгәннәр.

XX гасырның 50 нче елларында, кабатлау булмасын өчен, тел белемендә сүзләр бәйләнешен өйрәнүне түбәндәге тәртипкә салалар. Сүзләр бәйләнешенең барлык төрләрен дә җөмлә кисәкләренең бер-берсенә иярүен тикшерү тәртибендә өйрәнәләр. Ә җөмләне сүзтезмәләргә аеру юлын бары сөйләмдә иң күп очрый торган төгәлләүле мөнәсәбәтне тагын да җентекләбрәк өйрәнү өчен генә калдыралар.

Бу китапта да, иң элек, «сүзтезмәләр» бүлегендә төгәлләүле мөнәсәбәтне формадан чыгып эчтәлеккә таба өйрәнү, аннан соң барлык төр бәйләнешләрне «Җөмлә кисәкләре» бүлегендә мәгънәдән чыгып формага таба өйрәнү кабул ителде.

## СҮЗТЕЗМӘ

**§ 28. Сүзтезмә турында гомуми мәгълүмат.** Ике яки берничә мөстәкыйль сүзнең төгәлләүле мөнәсәбәткә керүе нәтиҗәсендә ясалган һәм төгәлрәк төшенчәне белдерә торган төзелмә сүзтезмә дип атала. Сүзтезмә төшенчәне башка шуңа охшаган төшенчәләрдән аерып, конкретлаштырып күрсәтә. Аерым сүз төшенчәне гомумән генә атый. Сүзтезмә төгәлләп атый. Мәсәлән, *тау* – аерым сүз, гомумән, теләсә нинди тауны атый; *шуа торган тау* – сүзтезмә, тауны башка төрле таулардан аерып (шуа торган икәнен әйтеп), конкретлаштырып атый, ягъни төгәлрәк төшенчәне атый. *Уй* – аерым сүз, теләсә нинди уйны атый, *матур уй* – сүзтезмә, уй төшенчәсен тарайта, конкретлаштыра, төгәлрәк итеп атый. *Язу* – аерым сүз, гомумән язуны атый, *хат язу* – сүзтезмә, язу процессын бераз тарайта, конкретлаштыра, төгәлрәк итә, бары хат язуны гына атый.

Сүзтезмәгә хәбәрлек һәм модальлек белдерү хас түгел. Шуның өчен сүзтезмә аралашу процессында шул килеш кенә кулланыла алмый. Ул аралашу процессына я, хәбәр итү интонациясе белән әйтелеп, җөмлә буларак килеп керә, мәсәлән: *Кыш. Салкын һава. Яфрак кадәрле кар төшә* (Г. Тукай), яисә җөмлә эчендә кулланыла, мәсәлән: *Утта булган кирпеч кире купмас, эштә булган тимер тутыкмас* (М. Җәлил) дигән җөмләдә *утта булу, утта булган кирпеч, эштә булу, эштә булган тимер* дигән сүзтезмәләр бар. Сүзтезмәдәге ияртүче сүз җөмләнең теләсә кайсы кисәге була ала, иярүче сүз исә бары иярчен кисәк булып кына килә. Җөмләдә нинди функция үтәүгә карап, сүзтезмә үзенең формасын да үзгәртә. *Студентлар өчен яңа торак төзелде. Студентлар яңа торакка күчтеләр. Студентлар яңа торакны бик яраттылар.*

Сүзтезмә ике яки берничә мөстәкыйль сүздән торырга тиеш. Шулай булмаса яки ул бер мөстәкыйль һәм бер ярдәмлек сүздән торса, аны сүзтезмә дип әйтеп булмый, чөнки ярдәмлек сүзләрнең лексик мәгънәләре юк, һәм шуңа күрә алар мөстәкыйль сүзләр белән төгәлләүле (ачыклаулы) мөнәсәбәткә керә алмыйлар.

Җөмлә төзүдә катнашканда, сүзтезмә кисәкләренең янәшә килүләре мәҗбүри түгел. Мәсәлән: «*Зәңгәр чишмә» – үзенең зур базары белән бөтен Агыйдел буенда дан тоткан авылларның берсе* (Г. Ибраһимов) дигән җөмләдә *зур базар, бөтен Агыйдел буе, дан*

*торкан авыл*, *авылларның берсе* сүзтезмәләренең кисәкләре янәшә урнашканнар; *үзенең базары, базары белән дан тоту* сүзтезмәләренең кисәкләре исә бер-берсеннәнераграк куелганнар.

**§ 29. Сүзтезмәләрне өйрәнү тарихыннан.** Татар телендәге сүзтезмәләрне өйрәнү XIX йөзнең беренче яртысыннан башлана. Бу эшне киң планда А. Троянский үзенең «Краткая татарская грамматика» (С.-Петербург, 1814) исемле китабында башкара. Автор теләсә нинди сүзләр тезмәсен, хәтта, исем белән бәйлектән торган тезмәне дә (*әти белән, синең өчен* кебек), сүзтезмәгә кертә. Ләкин ул әле иярүче һәм ияртүче сүзләргә, бәйләүче чараларга, сүзләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләренә бөтенләй игътибар итми.

XIX йөзнең урталарына таба грамматикада логик юнәлеш өстенлек алып, сүзтезмәләрне тикшерү иярчен кисәкләрне өйрәнү белән алмаштырыла. Тик Каюм Насыйри гына үзенең «Краткая татарская грамматика...» (1860) һәм «Әнмүзәҗ» (Казан, 1895) дигән китапларында сүзтезмәләрне аерым алып өйрәнә. Сүзтезмә хәбәр итүдә катнашса (*бала йоклый, утны сүндер* һ.б.) ул аны тулы сүзтезмә дип атый, ләкин тулы сүзтезмәгә ул, нигездә, фигыль сүзтезмәләрне кертеп бетерә. Исем сүзтезмәләрне к и м  с ү з т е з м ә  дип ала.

Сүзтезмәләрне тагын да тирәнрәк тикшерүче галим Җамал Вәлиди була. Ул үзенең «Татар теленең грамматикасы» (Казан, 1919) дигән хезмәтендә сүзтезмәләрне өч төргә бүлеп карый: аеру тәркибе – сүзтезмәсе (*яхшы кеше, бу кеше*), теркәү тәркибе (*шәкертнең китабы, Урал тавы*), хөкем тәркибе. Соңгысына автор барлык фигыль сүзтезмәләрне кертә.

К. Насыйри һәм Җ. Вәлиди үзара тезүле бәйләнештәге сүзләрне сүзтезмә дип танымыйлар, ләкин җөмләләрне сүзтезмәләрнең бер төре итеп карыйлар. Димәк, аларча, сөйләмнең иң зур төп берәмлеге – сүзтезмә, сүзтезмә эчендә генә җөмлә каралырга тиеш.

Соңгы елларда сүзтезмәгә үзара төгәлләүле мөнәсәбәттә торган сүзләрне генә кертеп өйрәнә башладылар һәм сүзтезмәләрне җөмлә эчендә генә карыйлар.

**§ 30. Сүзтезмәләрнең төрләре.** Сүзтезмәдәге мөстәкыйль сүзнең санына карап, сүзтезмәләр ике төрле булалар: г а д и  с ү з т е з м ә, к а т л а у л ы  с ү з т е з м ә. Ике генә мөстәкыйль сүздән торган сүзтезмә гади сүзтезмә дип атала. Мисаллар: *китапны уку, шәһәргә бару,*

*ике өстәл, теге урындык, урманнан чыгу, әти белән килү, синең өчен тырышу, авылга кайтып җитү, хатны укып чыгу.*

Икедән артык мөстәкыйль сүздән торып, гади сүзтезмәләргә таркалмый торган сүзтезмә катлаулы сүзтезмә дип атала. Мәсәлән, *әти белән шәһәргә бару* тезмәсе катлаулы сүзтезмә була алмый, ул – бары ике гади сүзтезмәдән (*әти белән бару* һәм *шәһәргә бару* сүзтезмәләреннән) төзелгән синтаксик төзелмә генә. *Ике чиләк су, киләсе атнага кайту, биш капчык он, билгеләнгән вакытка үтәү* кебек тезмәләр катлаулы сүзтезмә булалар, чөнки болар икедән артык мөстәкыйль сүздән торалар. Алардан бер сүзтезмә аерып чыгару мөмкинлеге булса да (мәсәлән, *ике чиләк, киләсе атна, биш капчык, билгеләнгән вакыт), чиләк су, атнага кайту, капчык он, вакытка үтәүне* мөстәкыйль сүзтезмәләр дип карап булмый.

Кисәкләре арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләренең югалу-югалмавыннан һәм шуның нәтиҗәсендә сүзтезмәнең ыгып калу-калмавыннан чыгып, сүзтезмәләр шулай ук ике төргә аерылалар: и р е к л е с ү з т е з м ә һәм ф р а з е о л о г и к с ү з т е з м ә.

Кирәк булганда гына, ягъни сөйләм барышында гына ясалган һәм кисәкләре арасындагы реаль мәгънә мөнәсәбәте югалмаган сүзтезмә ирекле (синтаксик) сүзтезмә дип атала. Мисаллар: *әтигә багышлау, Ватанны ярату, агачтан ясау, бер атнада тәмамлау, туганым белән язышу, яхшылыгы өчен хөрмәтләү, имтихан тоткан чор.* Ирекле сүзтезмәләр нинди дә булса бер төшенчәне белдерү өчен ныгып калган булмыйлар, чагыштырмача ирекле булалар.

Кисәкләре арасындагы реаль мәгънә мөнәсәбәте югалган һәм шуның нәтиҗәсендә ныгып калган сүзтезмә фразеологик сүзтезмә дип атала. Мисаллар: *җил куу, тырай тибү, үги ана яфрагы, эт шомырты, искә төшерү, хәтергә алу.* Фразеологик сүзтезмәләр теге яки бу әйберне атау өчен ныгып калган булалар һәм сөйләмгә, сүзләр кебек үк, әзер килеш кертеләләр. Фразеологик сүзтезмә ирекле сүзтезмә белән аерым сүз арасында тора. Ирекле сүзтезмәнең лексикалашуы, ягъни аерым сүзгә әйләнүе, фразеологик сүзтезмә аркылы бара.

Синтаксис фәне ирекле (синтаксик) сүзтезмәләр белән эш итә.

Фразеологик сүзтезмәләр тел гыйлеменең фразеология дигән бүлегендә өйрәнеләләр, бары сүзләр арасындагы бәйләүче чараларны тикшергәндә генә, алар синтаксиста да телгә алынырга мөмкиннәр.

Чөнки фразеологик сүзтезмәдәге сүзләр арасында мәгънә мөнәсәбәтләре югалган булса да, андагы сүзләр үзара татар теленә хас синтаксик чаралар ярдәмендә бәйләнәләр.

**§ 31. Өйрәнү бурычларыннан чыгып сүзтезмәләрне төркемләү.** Сүзтезмәләрне өйрәнүнең бурычлары, кыска гына әйткәндә, түбәндәге өч сорауга җавап бирү.

1. Кайсы сүз төркемнәре кайсыларын ияртә ала? Исем исемне ияртә аламы, исем фигыльне ияртә аламы, фигыль исемне ияртә аламы? һ.б.

2. Сүзтезмәдәге сүзләр нинди чаралар ярдәмендә бәйләнәләр? Мәсәлән, исем исемне ияртә икән, нинди чаралар ярдәмендә ияртә? һ.б.

3. Сүзтезмәдәге сүзләр үзара нинди мәгънә мөнәсәбәтендә торалар? Мәсәлән, исем исемне иялек килеше яки *-дагы* кушымчасы ярдәмендә ияртә икән, ул кушымча сүзләр арасында нинди мәгънә мөнәсәбәтләрен белдерә?

Менә шушы сорауларга җавап бирүне җиңеләйтү өчен, сүзтезмәләрне төрләргә бүләләр. Ияртүче кисәкнең кайсы сүз төркеменнән булуына карап, сүзтезмәләр җиде зур төркемгә бүленә: фигыль сүзтезмәләр, исем сүзтезмәләр, сыйфат сүзтезмәләр, сан сүзтезмәләр, алмашлык сүзтезмәләр, рәвеш сүзтезмәләр, хәбәрлек сүзле сүзтезмәләр. Һәрбер сүзтезмә үз эчендә, иярүче кисәкнең кайсы сүз төркеменнән булуына карап, тагын берничә төргә бүленә. Мәсәлән, исем сүзтезмә үзе исемле исем сүзтезмә, сыйфатлы исем сүзтезмә, фигыльле исем сүзтезмә дигән төрләргә бүленә һ.б.

Сүзтезмәләрдә сүзләрнең бәйләнешен билгеләүне җиңеләйтү, аларның үзенчәлекләрен төгәлрәк күз алдына китерү өчен, сүзтезмәләрнең модельләрен (калыпларын) төзеп күрсәтү дә таләп ителә. Моның өчен сүзтезмәдәге иярүче һәм ияртүче сүз төркеменең шартлы билгесе алына, бәйләүче чара үзе күрсәтелә. Мәгънә мөнәсәбәте әйтелә. Сүзтезмәләрнең модельләрен күрсәтү өчен, түбәндәге шартлы билгеләр алынды.

| | | |
|---|---|---|
| И – исем. | С – сыйфат. | Сан – сан. |
| Р – рәвеш. | А – алмашлык. | Ф – фигыль. |

Х – хәбәрлек сүз.

$И^2$, $Ф^2$ һ.б.ш. – сүзнең кабатланып килүе.

– (сызык) – сүзтезмә кисәкләре арасы.

+ (кушу билгесе) – бер кисәк ике сүздән торса, аларның арасы.
(вак.) – вакыт мәгънәсендәге сүз.
(ур.) – урын мәгънәсендәге сүз.
(хәр.) – хәрәкәтне белдерү.
(хәл) – хәл (состояние) белдерү.
(тою) – тоюны белдерү.
(уй) – уйлауны, фикерләүне белдерү.
(сөйл.) – сөйләү фигыле.
(йөк.) – йөкләтү юнәлеше.
(төш.) – төшем юнәлеше.
(с.ф.) – сыйфат фигыль.
(абс.) – абстракт.
(күч.) – күчемле.
(күчемсез) – күчемсез.

Сүзтезмәләрнең моделенә аның мәгънә мөнәсәбәтен язу да кирә. Мәсәлән: *тормышны сөю* сүзтезмәсенең моделе болай языла: И (*-ны*) – Ф (туры объект); *бер чиләк су* сүзтезмәсенең моделе: Сан + И – И (күләм).

## ФИГЫЛЬ СҮЗТЕЗМӘЛӘР

### ИСЕМЛЕ ФИГЫЛЬ СҮЗТЕЗМӘЛӘР

**§ 32. Исемле фигыль сүзтезмәләрдә ияртүче кисәкләр.** Ияртүче кисәк булып, исем генә түгел, исем функциясендәге алмашлыклар, саннар, сыйфатлар, сыйфат фигыльләр һәм исем фигыльләр дә килә: *аңа сөйләү, бирәүне күрү, укыганны ярату* һ.б. Болар барысы да исемле фигыль сүзтезмәләр бүлегендә каралалар.

### Фигыльнең исемне төрле кушымчалар аша ияртүе нәтиҗәсендә ясалган сүзтезмәләр

**§ 33. Бәйләүче чара – *-ны/-не*.** Бу кушымча аша күчемле фигыльләр туры объектны белдерүче сүзләрне ияртәләр, күчемсез фигыльләр исә башкарак мәгънәдәге сүзләрне дә ияртергә мөмкиннәр. Шуңа күрә мондый сүзтезмәләрдә ияртүче исем ияртүче фигыльдән

аңлашылган процессны төрле яклап ачыклый: а) процессның туры объектын белдерә: *халыкны азат итү, ватанны ярату, җырны багышлау.* Моделе: И (*-ны/-не*) – Ф (күч.) (*туры объект*); ә) процессның урын яки вакыт ягыннан күләмен белдерә: *ун чакрымны үтү, ике көнне (шәһәрдә) үткәрү.* Моделе: Сан + И (*-ны/-не)* – Ф (урын яки вакыт ягыннан күләм); б) физик хәрәкәтнең урынын яки урын ягыннан объектын белдерә: *урманны чыгу, болынны узу, җир шарын әйләнеп чыгу, елганы йөзеп чыгу, күперне чыгу.* Моделе: И (*-ны/-не*) – Ф (хәр.) (урын яки урын объекты); в) процессның үтәлү вакытын белдерә: (*узган) айны кайту, (бәйрәм) көнне озату.* Моделе: И (вак.) (*-ны/-не*) – Ф (вак.).

**§ 34. Бәйләүче чара – янәшә тору яки лексик мәгънә.** Иярүче исем баш килештә килә. Мондый сүзтезмәләрдә исем ияртүче фигыльдән аңлашылган процессны түбәндәгечә ачыклый: а) процессның туры объектын белдерә, ләкин объект тыңлаучыга алдан таныш булмый, аның турында беренче мәртәбә гомумән генә искә алына: *хат язу, утын кисү, китап тоттырмау.* Моделе: И – Ф (билгесез объект); ә) физик хәрәкәтнең урынын, вакытын яки күләмен белдерә: *урам урау, юл йөрү, тау шуу, һәр көн килү, иртә килү, биш чакрым килү.* Моделе: И – Ф (хәр.) (урын, вакыт); б) процессны башкаруда катнаша торган коралны белдерә: *чаңгы шуу, сабан сөрү, урак уру, пычкы яру, тырма тырмалау.* Моделе: И – Ф (корал).

**§ 35. Бәйләүче чара –** *-га/-гә (-ка/-кә).* Монда исем һәм фигыль арасында түбәндәге мәгънә мөнәсәбәтләре була: а) иярүче исем физик хәрәкәтне белдерми торган процессның кыек объектын күрсәтә: *укучыга өйрәтү, талантка баш ию.* Моделе: И (*-га/-гә*) – Ф (хәл) (кыек объект); ә) юнәлеш килешендәге исем корал мәгънәсендәге объектны да белдерә ала: *нургаману, тиргә бату.* Моделе: И (*-га/ -гә*) – Ф (корал мәгънәсендәге объект); б) физик хәрәкәтнең юнәлеш ноктасын белдерә: *урманга бару, авылга кайту, кырга чыгу, тиргә төшү, алга атлау.* Моделе: И (*-га/-гә*) – Ф (хәр.) (юнәлеш урыны); в) физик хәрәкәтнең максатын белдерә: *утынга китү, суга чыгу, эшкә бару, җиләккә китү.* Моделе: И (*-га/-гә*) – Ф (хәр.) (максат); г) процессның вакытын белдерә: *киләсе атнага кайту, билгеләнгән вакытка үтәү,* Моделе: Ф+И (*-га/-гә*) – Ф (вак.); д) процесска бәйле булган әйбернең хакын, бәясен белдерә: *ун тиенгә алу, өч сумга сату.*

Моделе: Сан + И (*-га/-гә*) – Ф (хак, бәя); е) процессның күләмен белдерә[1]: *биш чакрымга артта калдыру, ун көнгә соңга калу;* ё) процессның үтәлү-үтәлмәве өчен сәбәпче булган объектны белдерә: *суыкка калтырау, җылыга эрү, яхшылыкка эреп китү;* ж) процессның үтәлү рәвешен белдерә: *бөтен көчкә чабу, бөтен тавышка кычкыру, чүмәләгә җыю;* җ) процессны үтәүчене яки үтәргә тиеш булган әйберне, затны белдерә, ияртүче кисәк бер составлы җөмләнең баш кисәге булып килә: *Сиңа кая булса да китеп кәсеп эзләргә тиеш була* (Г. Тукай). *Ләкин Галкәй Хаҗиның бабасына барыбер тыныч яшәргә насыйп булмый* (К. Нәҗми).

**§ 36. Бәйләүче чара – *-дан/-дән* (*-тан/-тән*), *-нан/-нән*.** Монда иярүче кисәк ияртүче фигыльдән аңлашылган процессны түбәндәге яклардан ачыклый, төгәлли: а) физик хәрәкәтне белдерми торган процессның кыек объектын күрсәтә: *бүредән курку, укытучыдан сорау;* ә) кайбер очракта туры объектны да белдерә ала: *кулыннан тоту, чәйдән авыз итү, якасыннан эләктерү;* б) процессны барлыкка китерүдә катнашкан, шуның сәбәпчесе булган объектны белдерә: *бу хәбәрдән аптырап калу, дошман тубыннан башы өзелү;* в) *-лык/-лек* кушымчасы ярдәмендә ясалган исем булса, ул процессның үтәлү сәбәбен белдерә: *укыганлыктан белү, шатлыктан көлү;* г) йөкләтү юнәлешендәге ияртүчедән аңлашылган процессның үтәүчесен белдерә: *кешедән эшләтү, укучыдан сөйләтү.* Моделе: И (*-дан/-дән*) – Ф (йөк.) (үтәүче); д) процесска бәйле булган башка бер әйбернең материалын белдерә: *агачтан ясау, кардан өю, бу алка саф алтыннан тора;* е) физик хәрәкәтнең чыгыш ноктасын белдерә: *авылдан кайту, шәһәрдән килү, кибеттән алу, квартирадан күчү;* ё) процессның үтәлү урынын белдерә: *юлдан бару, урамнан үтү, идәннән тәгәрәү, болыннан бару;* ж) процессның үтәлү вакытын белдерә: *ике көннән кайту, бер атнадан укый башлау;* җ) процессның үтәлү рәвешен белдерә: *эшләпәдән йөрү, пальтодан утыру, күңелдән белү, эчтән сизү, беравыздан кычкыру;* з) процессның күләмен белдерә: *тездән бату, яртысыннан чыгып тору;* и) процесска бәйле булган башка объектның хакын, бәясен белдерә: *алты сумнан сату, ун тиеннән бирү.* Моделе: Сан + И (*-нан/-нән*) – Ф (бәя, хак).

---

[1] Моннан соң бик үзенчәлекле модельләр генә күрсәтеләчәк.

**§ 37. Бәйләүче чара – *-да/-дә* (*-та/-тә*).** Ияргүче кисәк ияртүче фигыльдән аңлашылган процессны төрле яктан ачыклый: а) процессның яки процесска бәйле булган объектның урынын белдерә: *университетта уку, урманда яшәү, күңелдә йөртү;* ә) процессның үтәлү вакытын белдерә: *җиде яшьтә укый башлау*; б) кыек объектны да белдерә ала: *игенчелектә җиңү, батырлыкта тиңләшү, ярышта алдынгылыкны алу;* в) процессның үтәлү рәвешен белдерә: *бер юнәлештә эшләү, туган телдә сөйләү;* г) процессның күләмен белдерә: *бер секундта чыгу, өч минутта таралу.* Моделе: Сан + И (*-да/-дә*) – Ф (күләм).

### Фигыльнең исемне төрле ярдәмлекләр аша ияртүе нәтиҗәсендә ясалган сүзтезмәләр

**§ 38. Бәйләүче чара – *белән* бәйлеге.** Монда ияртүче белән ияргүче арасында түбәндәге мәгънә мөнәсәбәтләре була: а) ияргүче кисәк процессны үтәүче затка яки процессның объектына юлдаш булган башка бер затны яки объектны белдерә: *әти белән бергә кайту.* Моделе: И – *белән* – Ф (юлдаш объект); ә) процессны үтәүдә катнаша торган коралны яки материалны белдерә: *балта белән кисү, карандаш белән язу, күзлек белән уку;* б) процессның объектын белдерә: *әдәбият белән кызыксыну, физкультура белән шөгыльләнү, халык белән тулу, дәрт белән яну;* в) процессның үтәлүе өчен сәбәпче булган яки, сирәгрәк, максат булган объектны белдерә: *кызулык белән әйтү, балалык белән оныту;* г) процессның үтәлү рәвешен белдерә: *кызулык белән тәгәрәү, тырышлык белән үзләштерү, каты тавыш белән кычкыру, кыенлык белән уку;* д) процессның урынын яки вакытын белдерә: *үз юлы белән китеп бару, таң белән уяну;* е) ияртүчедән аңлашылган процессның киресе булачагын белдерә: *Шундый м а т у р  т а в ы ш  б е л ә н хор түгәрәгендә к а т н а ш м ы й с ы ң* (С. Әдһәмова). *Т а з  б а ш ы ң  б е л ә н кайда у р е л ә с е ң инде син* (К. Тинчурин).

**§ 39. Бәйләүче чара – *өчен* бәйлеге.** Монда исем белән фигыль арасында түбәндәге мәгънә мөнәсәбәтләре була: а) ияртүче кисәк процессның үтәлү максаты булган объектны белдерә: *икмәк өчен көрәшү, халык өчен эшләү;* ә) процессның объектын белдерә: *Минем өчен шулай тоела. Болары инде саф күңелле Г а з и н у р  ө ч е н аерата газаплы кебек т о е л д ы* (Г. Әпсәләмов); б) процессның үтәлүе

өчен сәбәпче булган объектны белдерә: *яхшылыгы өчен хөрмәтләү, сүзең өчен җавап бирү;* в) процессны үтәргә тиеш булып та, үтәмичә калган затны белдерә: *Габдулла хатыны Газизә өчен эшләде* (С. Әдһәмова). Моделе: И – *өчен* – Ф (үтәмичә калган зат).

**§ 40. Бәйләүче чара – *кебек, шикелле, төсле, сыман* бәйлекләре.** Мондый сүзтезмәләрдә бер процесс, үтәлү рәвеше ягыннан, икенче шундый ук процесска чагыштырыла, ягъни ияртүче кисәк процессның үтәлү рәвешен белдерә. Ияртүче кисәк булып, я шул икенче процессны башкаручы (*аю кебек йөри – аю ничек йөрсә, ул да шулай йөри*), я шул процессның объекты (*биш бармагым кебек беләм – биш бармагымны ничек белсәм, аны да шулай беләм*) килә. Мисаллар: *Бер яктан яшел урман диңгез кебек җәелеп ята* (Г. Әпсәләмов). *Чөнки ул бөтен авылның яланнарын, тауларын, чокырларын биш бармагы кебек белә* (Г. Ибраһимов). *Төрле фәннәрнең нигезен үзләштерү су кебек кирәк* (К. Нәҗми).

**§ 41. Бәйләүче чара – *кадәр, хәтле, тикле* яки *чаклы* бәйлекләре.** Мондый сүзтезмәләрдә процесс үтәлү күләме ягыннан башка шундый ук процесска чагыштырыла, охшатыла: *синең кадәр үзләштердем.* Мисаллар: *Я ком, я туфрак бураны килеп, җиргә чаклы бөгеп, иелдереп китә.* (Г. Ибраһимов). *Савытларны төбенә чаклы бушатканнан соң, Абдул сөйли башлады* (Г. Ибраһимов).

Бу төркемгә кергән сүзтезмәләрдә башка төрлерәк мәгънә мөнәсәбәтләре дә очрый: а) ияртүче кисәктән аңлашылган зат процессны үтәү вакыты ягыннан башка заттан артта калган була: *җирнең ясалма юлдашын сиңа кадәр күрдек;* ә) ияртүче кисәк көтелмәгән үтәүчене яки көтелмәгән объектны белдерә: *баласына хәтле ачулана, гаризага кадәр язып керү, казларга кадәр каңгылдашалар* (И. Гази). *Деникинны җиңде, Врангельне җиңде, актык чиктә Махносына кадәр бетереп кайтты* (Г. Бәширов). Моделе: И – *кадәр* – Ф (көтелмәгән объект яки субъект).

**§ 42. Бәйләүче чара – башка төр бәйлекләр.** Түбәндә китерелә торган бәйлекләр ияртүче кисәк белән ияртүче фигыль арасында түбәндәге мәгънә мөнәсәбәтләре урнаштыруда катнашалар.

1. *Аша, аркылы* бәйлекләре белән килгән ияртүче кисәк, ияртүче фигыль физик хәрәкәтне белдергәндә – урынны, ияртүче физик хәрәкәтне белдермәсә – объектны күрсәтә: *урман аша чыгу, авыл*

*аркылы үтү, триер аркылы үткәрү, авыл аркылы агу, туган тел аркылы белү.*

2. *Саен* бәйлеге белән килгән иярүче кисәк процессның даими кабатлануын белдерә: *атна саен ял итү, авыл саен туктау, кеше саен өләшү.*

3. *Күрә* бәйлеге белән килгән иярүче кисәк процессның сәбәбен (*суыкка күрә калтырау),* рәвешен, күләмен (*соравына күрә җавап бирү, эшенә күрә түләү*) белдерә.

4. *Таба* бәйлеге белән килгән иярүче кисәк процессның якынча юнәлеш урынын яки вакытын белдерә: *мәктәпкә таба йөгерү, кичкә таба чакырып китерү.*

5. *Каршы* бәйлеге процессның хәрәкәт юнәлешен (мәсәлән: *пароходка каршы йөзү*), процессның иярүче кисәктән аңлашылган вакыт җитәр алдыннан үтәлүен (*кичкә каршы юлга чыгу, җәйгә каршы ял алу*), иярүче кисәк белдергән күренештән логик рәвештә чыгарга тиеш булган процессның киресе эшләнүен (*гаҗәпләнүгә каршы өйрәнә алу*) белдерә.

6. *Бирле* бәйлеге белән килгән иярүче кисәк процессның башланган вакытын белдерә: *кичәдән бирле йоклый алмау, шуннан бирле барып йөрү.*

7. *Башка, бүтән, тыш* бәйлекләре белән килгән иярүче кисәк процессны үтәгәндә катнашмаган затны яки объектны белдерә: *Карчыктан башка анда эш бармый* (Г. Әпсәләмов).

8. *Соң* бәйлеге процессның үтәлүе иярүчедән аңлашылган вакыттан соң булуын, иярүче кисәктән аңлашылган затның процессны башка бер затка караганда алданрак үтәвен күрсәтә: *Беренче сугулардан соң ук үлә язып идәнгә егылдым* (Н.Островский). *Без җирнең юлдашын сездән соң күрдек.*

9. *Турында, хакында* сүзләре белән килгән иярүче кисәк процесс турыдан-туры төшә торган объектны белдерә: *йорт турында уйлау, тургай хакында сөйләү.*

**§ 43. Бәйләүче чара – төрле ярдәмлекләр.** Түбәндә китерелә торган ярдәмлекләр иярүче кисәк белән ияртүче фигыль арасында түбәндәге мәгънә мөнәсәбәтләре урнаштыруда катнашалар.

1. *Катыш* сүзе белән килгән иярүче кисәк процессның үтәлү рәвешен белдерә: *шатлык катыш дулкынлану, өмет катыш куану, үпкә катыш назлану.*

2. *Тарафыннан* белән килгән иярүче кисәк процессны үтәүчене белдерә: *эшчеләр тарафыннан төзелү.*

3. *Карамастан* сүзе көтелгән процессның киресе булуын белдерә: *явымнарга карамастан җыылынып китү.*

4. *Карата* сүзе белән килгән иярүче кисәк процессның объектын белдерә: *әтисенә карата сүз әйтү.*

5. *Буе* сүзе белән килгән иярүче кисәк процессның урынын (*чишмә буенда йөрү*), күләмен (*бер ел буе шәһәрдә тору, гомер буе кайгырту*), рәвешен (*тәртип буенча сөйләү*) белдерә.

6. *Ас(т), өс(т), ал, арт, ян, эч, тыш, ара, урта, тараф, тирә* кебек ярдәмлек исем янында килгән ияртүче кисәк процессның урынын яки вакытын белдерә: *Идел өстендә йөзү, ун көн эчендә язып бетерү.*

Ярдәмлек исемнәр объект та белдерә алалар: *Малайлар, ялгыз калган саен, ул язулар өстендә эшлиләр булса кирәк* (Г. Ибраһимов).

7. *Сәбәпле, аркасында* сүзләре янында килгән иярүче кисәк процессның сәбәбен белдерә: *шуның аркасында һәлак булу, ...Ярлылыгы сәбәпле, мәктәп йөзе күрә алмады* (Г. Ибраһимов).

8. *Булып, буларак* сүзе янындагы иярүче кисәк процессның үтәлү рәвешен белдерә: *кара болыт булып җыелып тору.* Мондый төрдәге иярүче кисәк процессны үтәүчене дә белдерә: *укытучы булып эшләү.*

9. *Дип* сүзе белән килгән иярүче кисәк баш килештә булганда – объектны, юнәлеш килешендә булганда – максатны белдерә. *Бу картны һәммә кеше аз-маз белүче дип саный иде* (Г. Ибраһимов). *Орлыкка дип чүпләгәнебез менә монысы була* (Г. Бәширов).

10. *Итеп, иттереп* сүзләре белән килгән иярүче кисәк процессның үтәлү рәвешен белдерә: *үз итеп әйтү; Фәхрине... авыр йөккә төптән җигелгән өстерәүче итеп яраталар иде* (Г. Ибраһимов).

## САНЛЫ ФИГЫЛЬ СҮЗТЕЗМӘЛӘР

**§ 44. Бу төр сүзтезмәләрнең төп үзенчәлекләре.** Иярүче кисәк исем урынында килгән сан булса, алар санлы сүзтезмә ясамыйлар. Санлы сүзтезмә булсын өчен, сан үзенең туры мәгънәсендә килергә тиеш.

Сан, фигыльгә *мәртәбә, тапкыр, кат* сүзләре аша ияреп, процессның күләмен (*биш мәртәбә керү, бишәр мәртәбә сорау*), үтәлү тәртибе ягыннан ничәнче урында торуын (*икенче мәртәбә килде*) белдерә.

Тәртип саны, фигыльгә *булып, итеп* сүзләре аша ияреп, үтәүченең яки объектның процессны башкару ягыннан урынын белдерә: *икенче булып язу, бишенче итеп язу, дүртенче итеп үткәрү*. Моделе: Сан – *булып* (*итеп*) – Ф (тәртип).

Җыю саны процессны берьюлы ничә үтәүче башкаруын белдерә: *җидәү килделәр, дүртәү килеп төштеләр, бишәүләп язу, алтаулап сорау.*

*Дип, булып, сыман, төсле* белән килгән ияртүче сан процессның күләмен белдерә: *өченче булып күренү, дүрт дип белү, бишәү дип санау, биш сыман (төсле) тоелу.*

## РӘВЕШЛЕ ҺӘМ СЫЙФАТЛЫ ФИГЫЛЬ СҮЗТЕЗМӘЛӘР

### § 45. Бу төр сүзтезмәләрнең төп үзенчәлекләре.

1. Сыйфатларның һәм саф рәвешләрнең фигыльгә янәшә тору һәм лексик мәгънә аша бәйләнүе нәтиҗәсендә ясалган сүзтезмәләрдә ияртүче кисәк процессның үтәлү рәвешен белдерә: *матур тегү, күңелле генә елмаю, ялгыз калу.*

2. Фигыль сыйфатны юнәлеш яки чыгыш килеше кушымчасы аша ияртәндә, ияртүче кисәк, процессның үтәлү рәвешен белдерә: *турыга тегү, тоташтан уку.*

3. Сыйфатлар һәм рәвешләр фигыльгә *итеп, булып, дип* сүзләре аша иярсәләр, процессның үтәлү рәвешен белдерәләр: *куркыныч дип белү, зур итеп төяү.*

4. Сыйфатлар һәм рәвешләр фигыльгә *көе, көенчә, килеш, кебек, шикелле, сыман, төсле, хәлдә, рәвештә* яки *күрә* ярдәмлекләре аша иярсәләр, киң мәгънәдә процессның үтәлү рәвешен белдерәләр: *озын шикелле күренү, тиз кебек тоелу, күңелле хәлдә йөрү.*

5. Рәвешләр, фигыльгә янәшә тору чарасы белән иярәндә, процессны төрле яктан ачыклыйлар: күләм-чама рәвешләре – процессның күләмен, вакыт рәвешләре – вакытын, урын рәвешләре – урынын, сәбәп-максат рәвешләре – сәбәп-максатын белдерәләр: *озак көтү, мәңге кайгыру, быел уку, юкка тырышу.*

6. Ясалма сыйфатлар һәм ясалма рәвешләр, фигыльгә ияреп, аны төрле яктан ачыклап киләләр: а) процессның үтәлү рәвешен белдерә: *байларча яшәү, талчыбыктай бөгелү, яр буйлата бару, балтасыз бару, вакытлы яту;* ә) процессның дәвам итү чиген белдерә: *Һәркөн төшкәчә дәрес укый* (К. Насыйри). *Китәр көнгәчә шул хәл дәвам итте* (Г. Ибраһимов). *Чаршауны... стенагача тартып куясың* (Г. Ибраһимов); б) күтелмәгән объектны яки үтәүчене белдерә: *Туташ... тышкы киемнәренәчә киенде* (Г. Ибраһимов). *Күгәрченнәргәчә гөрләшәләр* (Г. Бәширов); в) процессның үтәлү вакытын белдерә: *Иртән алып китәләр, кичен китереп куялар* (Г. Бәширов).

Мисаллардагы ясагыч кушымчалар бер үк вакытта исемне фигыльгә бәйләү хезмәтен дә үтиләр, һәм шул бәйләү барышында сыйфат яки рәвеш ясала.

## ФИГЫЛЬЛЕ ФИГЫЛЬ СҮЗТЕЗМӘЛӘР

**§ 46. Хәл фигыльле фигыль сүзтезмәләр.** Боларны икенче төрле фигыльләрнең үзара хәл фигыль формалары аша бәйләнешеннән ясалган сүзтезмәләр дип атарга мөмкин. Хәл фигыльнең барлык формалары да фигыльне фигыльгә бәйләүдә катнаша.

Иярүче фигыль ияртүче фигыльдән аңлашылган процессны төрле яктан ачыклый: а) вакыт белдерә: *киенгәч утыру, кайткач күрү.* Моделе: Ф (*-гач/-гәч*) – Ф (вакыт); ә) рәвешен белдерә: *яктырып таң ату, изү чишеп, җиң сызганып эшләү;* б) күләмен белдерә: *җиткәнче бару;* в) сәбәбен белдерә: *аңламагач ачулану;* г) сөйләүче иярүче фигыльдән аңлашылган процессның булмавын, ияртүчедән аңлашылган процессның булуын тели, димәк, каршылык мәгънәсе бирелә: *Бай килене булганчы, ярлының кызы булсамчы* (мәкаль); кире мәгънә бирә: *Китеп тә, әллә ни кыла алмам кебек* (Г. Ибраһимов). *Әле без, инсаннар була торып та, кеше гыйлемен мыегы белән киеменнән үлчибез* (Г. Ибраһимов). *Уйлап-уйлап та очына чыга алмый* (Г. Ибраһимов); д) параллель процессларны белдерүче фигыльләр дә хәл фигыль формасы аша бәйләнә алалар: *Ү р т ә л е п  к а р ы й м суларга...* (М. Галиев). Моделе: Ф (*-ып/-еп*) – Ф (параллель процесслар).

**§ 47. Шарт фигыльле фигыль сүзтезмәләр.** Мондый сүзтезмәләрдә шарт фигыль ияртүче фигыльдән аңлашылган процесс-

ны төрле яктан ачыклый: а) ияртүчедән аңлашылган процессның үтәлү-үтәлмәве өчен шарт булып килә торган процессны белдерә: *килсә, эшли*; ә) ияртүчедән аңлашылган процессның киресе үтәлүен белдерә: *сөйли белсә дә, укый белми*; б) шарт формасы үзара тигез хокукта булган процессны бәйләргә мөмкин: *Узган ел Маратның «дүртле»ләре дә булса, быел ул уку елын «бишле»ләргә генә тәмамлады.*

**§ 48. Исем фигыльле һәм инфинитивлы фигыль сүзтезмәләр.** *-у/-ү* формалы исем фигыль фигыльгә төрле формалар аша иярә. Аның фигыльгә карата мөнәсәбәте күп очракта исемнәрнеке кебек була. Мондый очраклар исемле фигыль сүзтезмәләргә керәләр. Бу урында исем фигыльнең, исем урынында килмичә генә, фигыльгә ияру очраклары карала. Алар ияртүче фигыльне төрлечә ачыклыйлар: а) процессның вакытын белдерәләр: *керү белән күрде*, *баруга әзерләнү;* ә) процессның максатын белдерә: *тирләү өчен йөгерү*; б) процессның киресе булачагын белдерә: *Анасының кычкыруына карамастан, урагы белән арыш башагын кыеп йөри* (Г. Ибраһимов).

*-рга/-ргә* формалы фигыль, ягъни инфинитив, ияртүче фигыльдән аңлашылган процессны түбәндәгечә ачыклый: а) максатны белдерә: *китмәскә кайту, карарга дип бару;* ә) туры объектны белдерә: *мактанырга ярату, китәргә уйлау*; б) кыек объектны белдерә: *хат язарга ашыгу, сугышырга ирек бирмәү.*

*-мак/-мәк, -ыш/-еш* формасындагы исем фигыль, фигыльгә төрле формалар аша ияреп, аны төрле яктан ачыклый: а) вакытны белдерә: *барышлый карау, үтешли дәшү*; ә) максатны белдерә: *белешмәк өчен йөгерү. Гайшә белән Шәңгәрәй икесе бер үк вакыт әйтмәкче булып авыз ачтылар* (Г. Ибраһимов).

**§ 49. Сыйфат фигыльле фигыль сүзтезмәләр.** Сыйфат фигыльнең барлык формалары да, төрле чаралар ярдәмендә фигыльгә ияреп, ияртүче фигыльдән аңлашылган процессны төрле яктан ачыклый: а) сәбәбен белдерә: *юл йөргәнгә ябыгу*; ә) үтәлү вакытын белдерә: *калкынып караганда күреп алу, арыганнан соң йоклау*; б) үтәлү күләмен белдерә: *утырган саен әйтү*; в) үтәлү рәвешен белдерә: *утырган көйгә йоклау, уйламаганча эшләү, килгән итеп күрсәтү, белгән дип санау, сулыш алмастан тыңлау*; г) объектын белдерә: *кайтканын ишетмәү;* д) үтәлү максатын белдерә: *белер өчен килү.* Моделе: Ф – *өчен* – Ф (максат).

## ИСЕМ СҮЗТЕЗМӘЛӘР

### ИСЕМЛЕ ИСЕМ СҮЗТЕЗМӘЛӘР

**§ 50. Исемнең исемгә иялек килеше һәм тартым кушымчасы аша иярүеннән ясалган сүзтезмәләр.** Мондый сүзтезмәләрдә бер әйбер икенче әйбергә каратыла. Таррак лексик-грамматик мәгънә мөнәсәбәтләреннән түбәндәгеләр була: а) әйбер үзенең хуҗасына каратыла: *батырның бүләге, укучының китабы.* Моделе: И (*-ның/-нең*) – И (*-ы/-е*) (хуҗага каратылу); ә) әйбер үзенең булу урынына каратыла: *Донбассның күмерләре, Агыйделнең бозлары*; б) әйбер үзенең булу вакытына каратыла: *майның төне, җәйнең (туктаусыз) хезмәте*; в) туган-тумачалык мөнәсәбәтен белдерә: *малайның атасы, Байдебәкнең анасы*; г) әйбер үзенең булу максатына каратыла: *терлекләрнең азыгы, Гарифулланың өлеше*; д) әйбер үзенең барлыкка китерүчесенә каратыла: *суның һөҗүме, Гафиятнең ачуы, Зыяның тавышы. Т о р н а л а р н ы ң моңсу а к к о р д л а р ы Яңгырап китә кырлар иңендә* (Х.Камал); е) әйбер үзенең билгесенә каратыла: *көннең кызуы, өй эченең җыйнаклыгы, юлларның начарлыгы, төннең тынлыгы*; ё) өлеш бөтенгә каратыла: *агачның ботагы, тегермәннәрнең канатлары, алмагачларның төбе, урамның аргы башы*; ж) әйбер үзенең материалына каратыла: *итекнең күне, тупның резинкасы*; җ) процесс үзенең үтәүчесенә каратыла: *Зиннәтнең кайтуы, картның керүе*; з) процесс үзенең объектына каратыла: *флагның күтәрелүе, бурычның кайтарылуы.*

**§ 51. Исемнең исемгә янәшә тору һәм тартым кушымчасы аша иярүеннән ясалган сүзтезмәләр.** Бу төр сүзтезмәләрдә түбәндәге әйберләр (төшенчәләр) бер-берсенә каратылалар: а) әйбер конкрет билгеле әйбергә, затка каратыла: *Тукай шигырьләре, Рәхимовлар гаиләсе. Эшләпәле радиоалгычтан Б е т х о в е н м у з ы к а с ы агыла* (Р. Батулла); ә) әйбер бу очракта конкрет билгеле булмаган, гомумиләштерелгән әйбергә каратыла: *шәһәр бакчасы, авыл хуҗалыгы, диңгез суы, халык рухы, командир машинасы*; б) әйбер үзенә бәйле булган процесска каратыла: *чабыш аты, туктау урыны*; в) зат яки әйбер үзенең милләтенә яки исеменә каратыла: *башкорт егете, Агыйдел елгасы, Казан шәһәре*; г) ыру төргә каратыла: *шомырт чәчәге, нарат агачы;*

д) өлеш бөтенгә каратыла: *арыш башагы, чык бөртекләре, яулык очы, өй эче, тау түбәсе, көн уртасы*; е) иярүче кисәк әйбернең ни өчен булуын белдерә: *юл плащы, яшелчә базы, аш бүлмәсе*; ё) әйбер үзенең булу урынына яки вакытына каратыла: *Казан егете, август һавасы*; ж) әйбер үзенең материалына каратыла: *боз тавы, туфрак бураны, нарат урманы, печән кибәне*; җ) объект үтәүчегә каратыла: *мич яктысы, маяк сакчысы, итек остасы*; з) әйбер үзе чагыштырыла торган әйбергә каратыла: *хөррият кояшы, чәчәк диңгезе, дөнья бакчасы.* Моделе И – И (*-ы/-е*) (чагыштыра торган әйбергә каратылу).

**§ 52. Исемнең исемне янәшә тору чарасы аша ияртүеннән ясалган сүзтезмәләр.** Мондый сүзтезмәләрдә түбәндәге әйберләр (төшенчәләр) бер-берсе аркылы ачыкланалар: а) әйбер үзенең материалы аркылы: *ефәк күлмәк, хром итек, тимер көрәк.* Моделе: И – И (әйбернең материалы); ә) зат үзенең профессиясе аша: *тимерче Мостафа, кочегар Садыйк, артист Искәндәр;* б) ыру төшенчәсе төр төшенчәсе аша ачыклана: *Җиһанша бабай, Фатыйма бикә, Җәләш мулла, Сабир карт, Чумар карак;* в) әйбер үзенең төр исеме аркылы: *ир бала, үзәк комиссия, бер ярым Миңнулла;* г) иярүче кисәк әйбернең күләмен белдерә: *бер-ике чакрым җир, бер уч телеграмма, бер чиләк су, чиләк-чиләк җиләк, вагон-вагон кеше, мичкә-мичкә кымыз;* д) вакыт белдерүче исем шул вакытны белдерүче сүз аркылы ачыклана: *бала вакытлар, бәйрәм көн, туй көн*; е) бер әйбер икенче әйбергә охшатылып, чагыштырылып аңлатыла: *усал кеше, көмеш бөртекләр, алтын кылган, әрем тел, гөмбә баш.*

**§ 53. Исемнең исемне башка чаралар аша ияртүеннән ясалган сүзтезмәләр.** Исемне исемгә бәйләүдә чыгыш килеше кушымчасы, *хәтле, тикле, кадәр, чаклы, кебек, сыман, шикелле, төсле, күк* бәйлекләре, *турындагы, хакындагы, гыйбарәт, катыш, аралаш, буенча, дигән, каршы* ярдәмлек сүзләре катнаша.

Бәйләүче чараның төренә карап, исемнәр арасында түбәндәге мәгънә мөнәсәбәтләре була: а) әйбер, зат үзенең төре аша ачыклана: *дусларымнан Әхәт, кошлардан чыпчык, хатын-кызлардан белгеч;* ә) әйбер үзенең материалы, үзен төзегән әйбер аша ачыклана: *Татардан беренче крестьян отряды* (Г. Ибраһимов); *Ак тимердән бүрке бар* (К. Насыйри); *...сөттән гыйбарәт елга* (Г. Тукай); б) әйбер үзенең күләмен белдерүче әйбер аркылы ачыклана: *муеннан кар,*

*билдән су, шәһәр буенча конкурс;* в) әйбер күләме, формасы, төсе, эчке халәте һәм башка яклары буенча чагыштырыла торган әйбер аркылы ачыклана: *бүрек хәтле болыт, яфрак кадәр кар, күрәк күк сакал, фәрештә сынлы елан, таш төсле күңел;* г) максат, объект, чикләү һ.б. мәгънә мөнәсәбәтләре була: *мәхәббәт турында поэма, Алмачуардан башка ат, сандугач дигән асыл кош, Мәскәү дигән кала.*

### СЫЙФАТЛЫ ҺӘМ РӘВЕШЛЕ ИСЕМ СҮЗТЕЗМӘЛӘР

**§ 54. Ияртүче кисәге төп сыйфат яки төп рәвеш булган исем сүзтезмәләр.** Мондый сыйфат яки рәвеш исемгә һәрвакыт янәшә тору чарасы аша бәйләнә һәм исемнән аңлашылган әйберне, төшенчәне төрле яктан характерлый: а) төсен белдерә: *ал таң, кара болыт;* ә) күләмен белдерә: *киң сахра, тар сукмак, озын гомер;* б) формасын, рәвешен белдерә: *түгәрәк күл, текә яр, кинәт борылыш, чуалчык уйлар;* в) тәмен белдерә: *әче алма, төче катык;* г) эчке характерын, үзенчәлеген белдерә: *якын дус, туры карт, батыр кеше, изге күңел, нык кул, үткен күз, усал җилләр, яхшы ат.* Моделе: С (Р) – И (эчке характер).

**§ 55. Ияртүче кисәге ясалма сыйфат яки ясалма рәвеш булган исем сүзтезмәләр.** Мондый сүзтезмәләрдә ияртүче кисәкнең ияртүче белән янәшә торуы мәҗбүри булмый, чөнки сыйфат яки рәвеш ясаучы кушымчалар бер үк вакытта сүзләрне үзара бәйләүче чара булып та торалар, ягъни *-лы*/*-ле*, *-сыз*/*-сез*, *-гы*/*-ге*, *-дагы*/*-дәге*, *-лык*/*-лек*, *-дай*/*-дәй* кебек кушымчаларның исемнәрне исемгә бәйләү процессында ясалма сыйфатлар яки ясалма рәвешләр барлыкка килә, һәм соңгылары исемне төрле яклап ачыклыйлар: а) бер әйберне шул әйбердә булган яки булмаган әйбер, төшенчә аркылы ачыклыйлар: *алъяпкычлы хатын, чыбыркылы малай, ышанычлы кеше, игътибарлы күз, куәтле ялкын, урманлы тау, айлы кич, шатлыклы хәбәр, җигүле ат, ике генә тәрәзәле өй, күн киемле кеше, файдасыз түмгәк, тешсез Ибрай, кәефсезрәк вакыт, туктаусыз хезмәт;* ә) әйбер үзенең булу урыны яки вакыты аркылы ачыклана: *җәйге ял, язгы кояш, киләчәктәге дус, алдагы куак;* б) әйбер үзе чагыштырыла, охшатыла торган әйбер аркылы ачыклана: *кылгандай чәч, җырдай тормыш, таудай танк,*

*чәчәктәй кызлар, татарча спектакль;* в) әйбер үзенең үлчәве аркылы ачыклана: *йөз еллык имән, җиде еллык план, унбер еллык мәктәп, бер өстәллек материал, ике шкафлык такта.*

### САНЛЫ ИСЕМ СҮЗТЕЗМӘЛӘР

**§ 56. Санлы исем сүзтезмәләрнең төп үзенчәлекләре.** Сан исемгә янәшә тору чарасы аша иярә, ачыкланучы сүз күплек кушымчасы алмый, чөнки, сан белән ачыклану аркасында, күплек кушымчасына мохтаҗлык калмый. Ияртүче сан исемне төрле яктан ачыклый: а) әйбернең төгәл санын белдерә: *ике йөз батыр, җиде ел, җиде буын*; ә) әйбернең тәртип ягыннан ничәнче урында торуын белдерә: *беренче баскыч, дүртенче сыйныф, икенче курс;* б) әйбернең сан ягыннан чамасын белдерә: *ике-өч бөртек, биш-алты ел, өч-дүрт чакрым, уннарча укучы;* в) әйбернең тигез төркемнәргә туплануын һәм һәрбер төркемдә аларның ничә булуын белдерә: *икешәр алма, алтышар дәфтәр.* Моделе: Сан (-*шар*/-*шәр*) – И (әйбернең тигез төркемнәргә тупланучы).

### ФИГЫЛЬЛЕ ИСЕМ СҮЗТЕЗМӘЛӘР

**§ 57. Сыйфат фигыльле һәм инфинитивлы исем сүзтезмәләр.** Сыйфат фигыльнең барлык төрләре дә исемгә иярә алалар. Исемнән аңлашылган әйбер, төшенчә белән сыйфат фигыль белдергән процесс арасында төрле мәгънә мөнәсәбәтләре була: а) үтәүче зат процесс аша ачыклана: *укыган кеше, киләсе кунак;* ә) объект процесс аша ачыклана: *күтелмәгән вакыйга, җырланасы җыр, яулап алынган байрак.* Моделе: Ф (төш.) – И (объект процесс аркылы ачыклана); б) урын яки вакыт шул урында яки вакытта булган процесс аша ачыклана: *алмагач утыртасы урын, кайтыр юл, җитәр җире, туган-үскән җирләр, вәгъдәләшкән көн, ялга чыгачак вакыт, иртәгә китәсе дигән көн;* в) корал шул корал белән башкарыла торган процесс аша ачыклана: *куян ата торган мылтык, утын кискән пычкы;* г) процесс шул процесс булганда барлыкка килгән төрле күренешләрне, хәлләрне ачыклый: *курыккан төс, утлы күмер йоткан чырай, җиңгән кыяфәт.*

Инфинитивлы исем сүзтезмәләр телдә артык күп очрамыйлар. Иярүче инфинитив ияртүче исемнән аңлашылган күренешнең булу максатын белдерә: *белем алырга теләк, укырга мөмкинлек, кайтырга теләк, сыенырга урын, уйнарга исәп*.

### ХӘБӘРЛЕК СҮЗЛЕ ИСЕМ СҮЗТЕЗМӘЛӘР

**§ 58. Бу төр сүзтезмәләрнең кайбер үзенчәлекләре.** Хәбәрлек сүзләрдән *юк, кирәк, тиеш, мөмкин* кебек сүзләр, исемгә төрле чаралар ярдәмендә ияреп, исемнән аңлашылган әйберне, күренешне төрлечә ачыклыйлар. Бу вакытта иярүче һәм ияртүче арасындагы мәгънә мөнәсәбәте хәбәрлек сүзнең лексик мәгънәсе белән билгеләнә: *кирәк кадәр икмәк, каралырга тиешле материаллар, юк-бар әйбер.*

## СЫЙФАТ СҮЗТЕЗМӘЛӘР

### ИСЕМЛЕ СЫЙФАТ СҮЗТЕЗМӘЛӘР

**§ 59. Сыйфатның исемне юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килеше кушымчалары аша ияртүеннән ясалган сүзтезмәләр.** Монда исем белән сыйфат арасында түбәндәге мәгънә мөнәсәбәтләре була: а) исем сыйфатның билгеләнү объектын белдерә: *кешегә ягымлы, халыкка таныш, җырга оста;* ә) билгенең барлыкка килү вакытын белдерә: *яшьтән таныш, тумыштан сукыр;* б) билгенең барлыкка килү сәбәбен белдерә: *куркуыннан ап-ак;* в) билгенең булу урынын белдерә: *уртасыннан сынык, (юл) урманнан туры.*

**§ 60. Сыйфатның исемне бәйлек һәм бәйлек сүзләр аша ияртүе нәтиҗәсендә ясалган сүзтезмәләр.** Монда, бәйләүче чара булып, *белән, өчен, шикелле, кебек, сыман, төсле, чаклы, хәтле, тикле, кадәр, күрә* бәйлекләре һәм *караганда, буенча* бәйлек сүзләре катнаша. Исем сыйфатны төрле яктан ачыклый: а) билгенең кайсы яктан конкретлашкан булуын белдерә: *буе белән зур, күз карашы белән саф;* ә) билгенең тәэсир итү объектын белдерә: *күршем белән уртак;* б) билгене үзендәге шундый ук билгегә охшата: *Халыклар кебек тыйнак ул, даһилар кебек гади* (Х. Туфан); *Яфрак кебек ямь-яшел;* в) билгенең барлыкка

килү объектын белдерә: *тормыш өчен куркыныч, эш өчен яхшы, кешесенә күрә юмарт;* г) билгенең булу дәрәҗәсен (*биленә чаклы юеш*), билгене булдыручыны (*анасына кадәр усал*), билгене башка билге белән чагыштыруны (*ул сиңа караганда остарак*), билгенең чыганагын (*университет буенча таныш*) белдерә.

## РӘВЕШЛЕ СЫЙФАТ СҮЗТЕЗМӘЛӘР

**§ 61. Бу сүзтезмәләрнең үзенчәлекләре.** Сыйфатлар рәвешләрне күбрәк янәшә тору чарасы һәм лексик мәгънә аркылы ияртәләр. Рәвешләр сыйфаттан аңлашылган билгенең күләмен яки вакытын белдерәләр: *артык озын, бөтенләй яхшы, бихисап зур, бик ипле, бүген матур, һаман тирән, хәзер күңелле.*

*-ча/-чә*, *-дай/-дәй* кушымчалары ярдәмендә ясалган рәвешләр сыйфатка ияргәндә, сыйфаттан аңлашылган билгенең ияргүче кисәктән аңлашылган шундый ук билгегә тиңләштерелүе аңлашыла: *яшьләрчә саф, картларча нык, үзенчә хаклы, батырларча кыю, бәйрәмчә матур, тимердәй нык, ындыр табагыдай зур, уттай кызу, төлкедәй хәйләкәр, кылычтай үткен.*

## ФИГЫЛЬЛЕ СЫЙФАТ СҮЗТЕЗМӘЛӘР

**§ 62. Бу төр сүзтезмәләрнең үзенчәлеге.** Сыйфатка бары инфинитив һәм сыйфат фигыльләр генә ияр... Ияргүче инфинитив ияртүчедән аңлашылган билгенең булу максатын белдерә: *киярго уңай, йөрергә яхшы, күрергә үткен.* Сыйфат фигыль исә, сыйфатка юнәлеш килеше кушымчасы яки *күрә* бәйлеге ияреп, билгенең барлыкка килү сәбәбен белдерә: *эшләгәнгә күрә нык.*

## АЛМАШЛЫК СҮЗТЕЗМӘЛӘР

**§ 63. Алмашлык сүзтезмәләрнең үзенчәлекләре.** Алмашлык исемне һәм исем урынындагы башка сүзне үзенә чыгыш яки иялек килеше аша ияртә, һәм монда күп әйберләр яки затлар арасыннан аерым әйбер яки зат аерып алына: *дусларымнан тегесе, таныш-*

*ларымнан монысы, танышларымнан ул.* Моделе: И (*-нан/-нән*) – А (аерып алу).

## САН СҮЗТЕЗМӘЛӘР

**§ 64. Бу төр сүзтезмәләрнең үзенчәлекләре.** Сан исемне күптөрле чаралар ярдәмендә ияртә: а) чыгыш килешендәге исем санауның башлану урынын белдерә: *ахырдан алтынчы, теге баштан җиденче, уртадан бишенче;* ә) чыгыш яки иялек килешендәге исем күп әйберләрне, затларны, ә ияртүче сан шулар арасында аерым урын тотканнарның санын белдерә: *эшчеләрдән алтау, укучыларның бишесе;* б) *белән* бәйлеге ярдәмендә исем билгеле санга кушылган әйберне белдерә: *бу китап белән тугыз, укучы белән ун;* в) *өчен* бәйлеге белән килгән исем саналмыштан аңлашылган әйбернең булу максатын яки санны танучыны белдерә: *ә минем өчен биш* (*мин аны биш дип таныйм*).

## РӘВЕШ СҮЗТЕЗМӘЛӘР

**§ 65. Рәвеш сүзтезмәләрнең үзенчәлеге.** Рәвешләр рәвешләрне һәм исемнәрне ияртәләр. Рәвешләр рәвештән аңлашылган билгенең күләм-чама дәрәҗәсен (*шактый зур, бераз кыйбат, артык тупас, бөтенләй бушлай, шактый элек*), вакытын (*кичә көндезен, бүген иртән, былтыр көзен, иртәгә кичен*) белдерәләр.

Рәвешләр исемнәрне чыгыш килеше кушымчасы аша ияртәләр һәм билгеләрне чагыштыруны, объектны, урынны белдерәләр: *кошлардан да җитезрәк, поездлан тизрәк.*

## ХӘБӘРЛЕК СҮЗ СҮЗТЕЗМӘЛӘР

**§ 66. Бу төр сүзтезмәләрнең үзенчәлекләре.** Хәбәрлек сүзләрдән *кирәк, тиеш, мөмкин, ярый, бар, юк* кебек сүзләр башка сүзләрне да ияртеп килгәлиләр. Монда бәйләүче чара булып, кайбер килеш кушымчалары да, күп кенә бәйлек һәм бәйлек сүзләр дә катнаша. Иярүче сүзләр белән хәбәрлек сүз арасында төрле мәгънә

мөнәсәбәтләре була: *укытучы өчен кирәк, су кебек кирәк, эш буенча кирәк, сиңа мөмкин, Равилгә ярамый, миңа юк, Вилдә бар, сиңа миннән ни кирәк?*

## СҮЗТЕЗМӘЛӘРГӘ АНАЛИЗ

**§ 67. Сүзтезмәләрне җөмләдән аерып алу һәм анализлау алымнары.** Сүзтезмәләрне анализлаганда, нигездә, ике төрле кыенлык очрый: аларны хәбәрлекле тезмәдән (җөмләдән) аера белмәү һәм анализның тәртибен буташтыру.

Сүзтезмәне җөмләдән аеру кыенлыгы бигрәк тә сүзтезмәнең ияртүче кисәге хәбәр булып килгәндә туа. Мәсәлән, *Урман артыннан тулган ай калыкты* дигән җөмләдәге сүзләрнең үзара бәйләнешен өйрәнү өчен, андагы мөстәкыйль сүзләрне, парлап-парлап алып, түбәндәге тезмәләргә таркатырга була:

*ай калыкты;*
*тулган ай;*
*урман артыннан калыкты (калку).*

Бу тезмәләрдән беренчесе ия белән хәбәрдән тора, димәк, ул сүзтезмә булмый, җөмлә була. Икенчесе – сүзтезмә. Монысын ялгышмыйча әйтергә мөмкин. Ә менә өченче тезмәне гадәттә төгәл билгеләү кыен. Андый сүзтезмәләрне К. Насыйри һәм Җ. Вәлиди тулы сүзтезмәләргә, ягъни җөмләләргә кертеп йөрткәннәр. *Урман артыннан калыкты* сүзләре сүзтезмә була, ә җөмлә булмый, чөнки анда ия белән хәбәр бәйләнеше юк. Аның җөмләгә охшавы ияртүче сүзнең, хәбәр булып килеп, хәбәрлекле (затланышлы) форма алуында гына. Ә андый форманы *калыкты* сүзе *ай* сүзе белән бәйләнешкә кергәндә генә ала; *урман артыннан* сүзе белән бәйләнү өчен, *калыкты* сүзендәге форманың әһәмияте бөтенләй юк. Шуңа күрә аны *урман артыннан калку* дип алу методик яктан уңышлырак.

Гомумән, җөмләдән сүзтезмәләрне аерып алу ике сүз арасындагы бәйләнешне өйрәнү өчен эшләнә. Шуңа күрә аерып алынган ике сүзнең бәйләнешен белдерми торган башка кушымча һәм ярдәмлек сүзләрне сүзтезмәдән төшереп калдырып, ияртүче сүзне төп формада кую яхшы була. Мәсәлән: *Гәрчә сез күп тапкырлар сыналган развед-*

*чик булсагыз да, бүген сезгә тапшырыла торган эш гаять җаваплы булганлыктан, мин сезне тагын бер мәртәбә кисәтергә тиеш таптым* (Г. Әпсәләмов) мисалындагы сүзләрнең үзара бәйләнешен өйрәнү өчен, иң элек, ия белән хәбәр парлап-парлап аерып алына (*мин тиеш таптым, эш җаваплы, сез разведчик*), шуннан соң сүзтезмәләр аерыла: *кисәтергә тиеш табу* (*таптым* түгел, чөнки *табу* сүзе зат формасын *сез* сүзе белән бәйләнешкә кереп кенә ала, *кисәтергә* сүзе белән *тиеш табу* арасындагы бәйләнешне өйрәнү өчен аның кирәге юк, шуңа күрә төшеп кала); *сезне кисәтү, бер мәртәбә кисәтү* (*кисәтергә* түгел, чөнки инфинитив формасы *кисәтү* һәм *тиеш табу* сүзләрен бәйләүдә генә катнаша); *җаваплы булганлыктан кисәтү, тапшырыла торган эш, сезгә тапшырылу* (*тапшырыла торган* түгел, чөнки *-а/-ә + торган* формасы *тапшыру* сүзен *эш* сүзенә бәйләү өчен генә килгән, *тапшыру* һәм *сез* сүзләре арасындагы бәйләнешне белдерүдә катнашмый, шуңа төшеп кала); *бүген тапшыру, сыналган разведчик*; *күп тапкырлар сыналу* (*сыналган* түгел).

Шулай итеп югарыда китерелгән җөмләдән түбәндәге сүзтезмәләрне аерып чыгарып була: *кисәтергә тиеш табу, сезне кисәтү, бер мәртәбә кисәтү, җаваплы булганлыктан кисәтү, тапшырыла торган эш, сезгә тапшырылу, бүген тапшыру, сыналган разведчик, күп тапкырлар сыналу.*

Бу сүзтезмәләрне анализлау түбәндәгечә башкарыла.

*Кисәтергә тиеш табу* – монда фигыль фигыльне иярткән, ягъни бу – фигыльле фигыль сүзтезмә. Фигыль фигыльне инфинитив *-ергә* формасы ярдәмендә иярткән. Ияртүче фигыль (инфинитив) ияртүче фигыльдән аңлашылган процессның (тиеш табу процессының) объектын белдерә. Моделе: Ф (*-ырга/-ергә*) – Ф (объект).

*Сезне кисәтү* – монда фигыль алмашлыкны иярткән, ягъни бу – алмашлыклы фигыль сүзтезмә. Фигыль алмашлыкны төшем килеше формасы ярдәмендә иярткән. Ияртүче алмашлык ияртүче фигыльдән аңлашылган процессның (кисәтү процессының) объектын белдерә. Моделе: А (*-ны/-не*) – Ф (объект).

*Бер мәртәбә кисәтү* – монда фигыль санны иярткән, ягъни бу – санлы фигыль сүзтезмә. Сан фигыльгә *мәртәбә* дигән бәйлек сүз аша ияргән. Ияртүче сан ияртүче фигыльдән аңлашылган процессның күләм-дәрәҗәсен белдерә. Моделе: Сан – *мәртәбә* – Ф (күләм).

*Җаваплы булганлыктан кисәтү* – монда кисәтү фигыле *җаваплы булу* дигән ясалма фигыльне иярткән, димәк, бу да – фигыльле фигыль сүзтезмә. Фигыль фигыльне *-лыктан* формасы ярдәмендә иярткән. Иярүче кисәк иярүче кисәктән аңлашылган процессның сәбәбен белдерә. Моделе: Ф (*-лыктан/-лектән*) – Ф (сәбәп).

*Тапшырыла торган эш* – исем фигыльне иярткән, ягъни бу – фигыльле исем сүзтезмә. Фигыль исемгә *-ган* формасы һәм мәҗбүри янәшә тору аркылы иярген. Иярүче исем иярүче фигыльдән аңлашылган процессның объектын белдерә, киресенчә әйткәндә, иярүче фигыль иярүче исемнән аңлашылган предметны процесс ягыннан төгәлли. Моделе: Ф (*-а торган / -ә торгаэн*) – И (процесс ягыннан төгәлләү).

*Бүген тапшыру* – монда фигыль рәвешне иярткән, димәк, бу – рәвешле фигыль сүзтезмә. Конкрет бәйләүче чара булып, сүзләрнең лексик мәгънәләре генә катнашкан. Иярүче кисәк иярүче кисәктән аңлашылган процессның вакытын белдерә. Моделе: Р – Ф (вакыт).

## СҮЗТЕЗМӘЛӘРНЕҢ СЕМАНТИК ТӨРКЕМНӘРЕ

**§ 68. Гомуми мәгълүмат һәм семантик төркемнәр.** Сүзтезмәләрнең семантикасы – андагы сүзләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәте дигән сүз. Моңа кадәр без сүзтезмәләрне форма ягыннан төркемләдек һәм ул формаль төркемнәрнең семантикасын ачып бардык. Хәзер инде төркемләүнең нигезенә сүзтезмә семантикасы салына һәм һәрбер мәгънә мөнәсәбәтенең нинди формалар белән бирелүе күрсәтелә.

Мәгълүм булганча, җөмләнең логик-грамматик кисәкләре дә мәгънә ягыннан (семантикалары буенча) билгеләнәләр. Шуңа күрә сүзтезмәләрне мәгънәләре буенча төркемләү җөмләнең иярчен кисәкләрен өйрәнү өчен дә нигез хезмәтен үти.

Сүзтезмәләрнең семантик төркемнәре модельләргә салына, һәм, модель төзү өчен, бу китапның 31 нче параграфында бирелгән шартлы кыскартмалар алына.

Сүзтезмәдәге сүзләрне үзара бәйләүче чаралар схема-модельләрдә үзләре күрсәтеләләр. Сүзтезмәдә беренче урынны иярүче сүз, икенчесен – иярүче сүз алып тора.

| Сүзтезмә семантикасы | | Сүзтезмә модельләре | Мисаллар |
|---|---|---|---|
| гомуми | аерым | | |
| объект | туры | И (-ны/-не ) – Ф (күч)<br>И – Ф (күч)<br>И (-дан-дән) – Ф (күч)<br>Ф (-ырга/-ргә) – Ф<br>Ф (-ырга/-ргә) – дип – Ф<br>Ф (-ганны/-гәнне) – Ф | *җырны багышлау*<br>*хат язу*<br>*чәйдән авыз итү*<br>*эшләргә уйлау*<br>*эшләргә дип карар кылу*<br>*сөйләгәнне ишетү* |
| | кыек | И (-га/-гә) – Ф<br>И (-дан/-дән) – Ф<br>И (-да/-дә) – Ф<br>И – белән – Ф<br>И – аша, аркылы – Ф<br><br>И – саен – Ф<br>И(-га) – каршы – Ф<br>И(-га)– карата – Ф (сөйл.)<br>И – алдында – Ф<br>И – итеп – Ф<br>Ф (-ырга) – дип – Ф<br>И – хакындагы, турындагы – И<br>И – буенча – И<br>И (-га) – каршы – И<br>И (-дан/-дән, -тан/-тән) – С<br>И (-да/-дә) – С<br>И – өчен – С<br>И (-га) – күрә – С<br>И (-га) – карата – С<br>И (-га/-гә, -ка/-кә) – С | *укучыга әйтү*<br>*укучыдан сорау*<br>*игенчелектә җиңү*<br>*спорт белән шөгыльләнү*<br>*приказ аркылы уткәрү, почта аркылы җибәрү*<br>*кеше саен өләшү*<br>*машинага каршы йөгерү*<br>*кешегә карата әйтү*<br>*кеше алдында начар хис итү*<br>*бригадир итеп сайлау*<br>*укырга дип сүз бирү*<br>*белгеч турындагы карар*<br>*велосипед буенча ярыш*<br>*җавапсызлыкка каршы чара*<br>*аттан биек*<br>*сүздә дөрес*<br>*Мәрьям өчен авыр*<br>*кешесенә күрә юмарт*<br>*кызга карата тыйнак*<br>*халыкка таныш* |
| | корал | И – Ф (хәр)<br>И (-га/-гә) – Ф<br>И – белән – Ф<br>И (-тан/-тән) – Ф | *чаңгы шуу*<br>*канга буяу*<br>*машина белән эшләү*<br>*агачтан ясау* |
| | объект-сәбәп | И (-га/-гә) – Ф<br>И (-дан/-дән) – Ф<br>И – белән – Ф<br>И – өчен – Ф | *матурлыкка ис китү*<br>*ачлыктан үлү*<br>*батырлык белән канатлану*<br>*ярдәм өчен рәхмәт әйтү* |
| | объект-максат | И – белән – Ф<br>И – өчен – Ф<br>И (-га/-гә) – дип – Ф | *йомыш белән килү*<br>*икмәк өчен көрәшү*<br>*орлыкка дип чүпләү* |
| | объект-урын | И (-ны/-не) – Ф(хәр)<br>И – Ф(хәр) | *урманны чыгу*<br>*урам әйләнү* |

| Сүзтезмә семантикасы | | Сүзтезмә модельләре | Мисаллар |
|---|---|---|---|
| гомуми | аерым | | |
| объект | көтел-мәгән | И (-гача) – Ф<br>И (-га) – кадәр – Ф | *тышкы киемнәренәчә киенү*<br>*гаризага кадәр язу* |
| | ияртел-гән | И – белән – Ф | *орлык белән чәчү* |
| | булмый калган | И – урынына – Ф | *китап урынына алу* |
| | алдарак булган | И (-дан) – соң – Ф | *әтидән соң күрү* |
| | башкаручы сыйфатын-дагы | И – сыйфатында – Ф<br>И – буларак,булып – Ф | *механик сыйфатында килү*<br>*бригадир булып эшләү* |
| | объ. сыйфа-тындагы | И – итеп, буларак – Ф | *укытучы буларак хөрмәт итү* |
| | кем дигән | И – дип – Ф | *укытучы дип атау* |
| Башкаручы | башка-ручы | И (-га) – Ф<br><br>И (-дан) – Ф (йөк)<br>И (-га) – Ф (йөк)<br>И – тарафыннан – Ф(төш.) | *әтигә барырга (әти барырга тиеш)*<br>*кешедән эшләтү*<br>*балага эшләтү*<br>*әти тарафыннан җибәрелү* |
| | көтелмә-гән | И (-гача) – Ф<br>И (-га) – кадәр – Ф<br>И (-га) – чаклы – С | *балагача белә*<br>*күгәрченнәргә кадәр шатлана*<br>*баласына чаклы усал* |
| | ияргән | И – белән –Ф | *әти белән килү* |
| | үтәүче | И – өчен – Ф<br>И – урынга – Ф | *Габдулла өчен эшләү*<br>*укытучы урынына язу* |
| | алдарак булган | И (-дан) – соң – Ф | *әтидән соң килү* |
| | тоелган | И (-га) – С | *укытучыга матур* |
| күләм, дәрәҗә | вакытта | Сан + И – Ф<br>Сан + И(-га) – Ф(хәр.)<br>Сан + И (-да) – Ф<br>Сан + И (-лык) – Ф<br>И (-дан) – бирле – Ф<br>И – буе – Ф<br>Р – Ф<br>Ф (-ганчы) – Ф<br>Ф (-ганнан) – бирле – Ф<br>Ф (-ган) – саен – Ф | *ике ел хезмәт итү*<br>*бер төнгә кайту*<br>*өч көндә эшләү*<br>*өч көнлек эшләү*<br>*җәйдән бирле эшләү*<br>*ел буе уку*<br>*озак көтү*<br>*яктырганчы язу*<br>*килгәннән бирле йөрү*<br>*караган саен суыну* |
| | урында | Сан + И (-ны) – Ф (хәр.)<br>И (-дан) – Ф<br>И (-дан) + И (-га) – Ф<br>И (-га) – чаклы – Ф | *100 чакрымны үтү*<br>*муеннан чуму*<br>*буйдан-буйга сузылу*<br>*урманга кадәр бару* |

| Сүзтезмә семантикасы | | Сүзтезмә модельләре | Мисаллар |
|---|---|---|---|
| гомуми | аерым | | |
| күләм, дәрәҗә | урында | И (-дан) – И<br>Сан + И (-га) – С<br>И (-дан) – С<br>И – чаклы – С | *билдән су*<br>*биш метрга тирәнрәк*<br>*билдән юеш*<br>*биленә чаклы юеш* |
| | күләм – зурлык буенча | И (-нча) – Ф<br>И – чаклы, хәтле, тикле, кадәр– Ф<br>И (-га) – күрә – Ф<br>Р (С) – мәртәбәдә, дәрәҗәдә – Ф<br>Сан + И – И<br>$И^2$ – И<br>Сан + И (-лык) – И<br>Р – И<br>Р – С<br>Р – Р | *үз мөмкинлегенчә эшләү*<br>*дустым хәтле тырышу*<br>*эшенә күрә түләү*<br>*искиткеч дәрәҗәдә уңган*<br>*ике чиләк бәрәңге*<br>*вагон-вагон кеше*<br>*җиде еллык план*<br>*күп изгелекләр*<br>*шактый куе*<br>*бөтенләй бушлай* |
| | хак | Сан + И (-га) – Ф<br>Сан + И (-дан) – Ф | *биш тиенгә алу*<br>*ун сумнан бирү* |
| | сан | Сан – кат, мәртәбә, тапкыр – Г<br>$Сан^2$ – Ф<br>Сан – Ф<br>Сан (-лап) – Ф<br>Сан – И<br>Сан-Сан – И<br>Сан (-ларча) – И<br>Сан – төрле – И<br>Сан (-га) – якын, [(-дан) – артык] – И<br>Сан (-га) – Ф | *биш тапкыр килү*<br>*унар-унар килү*<br>*җидәү килү*<br>*җидәүләп килү*<br>*биш кеше*<br>*биш-алты кеше*<br>*уннарча сугышчылар*<br>*биш төрле кеше*<br>*утызга якын (утыздан артык) солдат*<br>*бишкә бүлү* |
| | тәртип | Сан – мәртәбә, тапкыр, кат – Ф<br>Сан – булып, итеп – Ф<br>Сан – И | *беренче кат куу*<br>*икенче булып язу*<br>*бишенче урын* |
| вакыт | кабатлану | Р – Ф | *тагын бару* |
| | периодик түгел | (вак) – И (-ны) – Ф (хәр.)<br>И – Ф<br>И (-га) – Ф<br>Сан + И (-дан) – Ф<br>Сан + И (-да) – Ф<br>И (-гача) – Ф<br>И (-ләй, ли) – Ф<br>И (-ын) – Ф | *узган елны кайту*<br>*шул вакыт күрү*<br>*обедка бушау*<br>*ике көннән кайту*<br>*30 нчы елда туу*<br>*китәр көнгәчә әйтмәү*<br>*җәйли печән чабу*<br>*кышын бару* |

<table>
<tr><th colspan="2">Сүзтезмә семантикасы</th><th rowspan="2">Сүзтезмә модельләре</th><th rowspan="2">Мисаллар</th></tr>
<tr><th>гомуми</th><th>аерым</th></tr>
<tr><td rowspan="2">вакыт</td><td>периодик түгел</td><td>И – белән – Ф<br>И (-га) – хәтле – Ф<br>И (-га) – таба – Ф<br>И (-га) – каршы – Ф<br>И (-дан) – соң – Ф<br>Сан + И – эчендә – Ф<br>Ф (-гач) – Ф<br>Ф (-гачтын) – Ф<br>Ф (-ганчы) – Ф<br>Ф(-у) – белән – Ф<br>Ф (-уга) – Ф<br>Ф (-ышлай) – Ф (хәр.)<br>Ф (-ганда) – Ф<br>Ф (-ганнан) – соң – Ф<br>Ф (-мастан) – Ф<br>Ф (-мае) – борын – Ф<br>И (-гы, дагы) – И<br>(вак.) – И (-дан) – С<br>Р – С<br>Р – Р</td><td>кич белән уку<br>пожарныйларга хәтле сүндерү<br>кышка таба кайту<br>кичкә каршы кайту<br>докладтан соң бару<br>ун көн эчендә картаю<br>кайткач күрү<br>баргачтын сөйләү<br>яктырганчы язу<br>кайту белән бару<br>яктыруга килеп җитү<br>барышлый кереп чыгу<br>сөйләгәндә тотлыгу<br>арыганнан соң кайту<br>килеп җитмәстән исәнләшү<br>тикшермәс борын әйтү<br>киләчәктәге дус<br>узган елдан билгеле<br>бүген матур<br>бүген иртән</td></tr>
<tr><td>периодик</td><td>И – саен – Ф</td><td>көн саен йөрү</td></tr>
<tr><td rowspan="3">урын</td><td>урын</td><td>И (-да) – Ф<br>И – буйлап – Ф<br>И – белән – Ф<br>И – аркылы (аша) – Ф<br>И – буенда – Ф<br>Р – Ф<br>И (-гы, -дагы) – И<br>И (-дан) – С<br>И (-дан) – Сан<br>И – И</td><td>университетта уку<br>яр буйлап бару<br>юл белән бару<br>авыл аша үтү<br>чишмә буенда йөрү<br>ерак утырту<br>бакчадагы агачлар<br>уртасыннан сынык<br>ахырдан алтынчы<br>югары оч Галәви</td></tr>
<tr><td>юнәлеше</td><td>И (-дан) – Ф (хәр.)<br>И (-гача) – Ф<br>И (-га) – таба – Ф<br>И – өстенә – Ф<br>И (-га) – Ф (хәр.)</td><td>өйдән чыгу<br>стенагача сузу<br>урманга таба китү<br>шәһәр өстенә килү<br>урманга бару</td></tr>
<tr><td>периодик</td><td>И – саен – Ф</td><td>урам саен ябыштыру</td></tr>
<tr><td>рәвеш</td><td>рәвеш</td><td>$И^2$ – Ф<br>И (-га) – Ф (хәр.)<br>И (-дан) – Ф<br>И (-да) – Ф</td><td>рәт-рәт тезелү<br>бөтен көчкә чабу<br>эшләпәдән йөрү<br>татар телендә сөйләү</td></tr>
</table>

| Сүзтезмә семантикасы | | Сүзтезмә модельләре | Мисаллар |
|---|---|---|---|
| гомуми | аерым | | |
| рәвеш | | И (-гыча) – Ф | *кичәгечә эшләү* |
| | | И (-дагыча) – Ф | *колхоздагыча эшләү* |
| | | И (-лап) – Ф | *минутлап санау* |
| | | И – белән – Ф | *тырышлык белән үзләштерү* |
| | | И (-га) – каршы – Ф | *кояшка каршы җемелдәү* |
| | | И – катыш – Ф | *ачу катыш сөйләү* |
| | | И (-ча) – килеш – Ф | *татарча килеш җибәрү* |
| | | И – буенча – Ф | *димләү буенча алу* |
| | | И – рәвештә – Ф | *шатлыклы рәвештә кайту* |
| | | И – итеп – Ф | *туган итеп ярату* |
| | | Сан – дип, итеп, сыман – Ф | *ике сыман хәтердә калдыру* |
| | | С – Г | *матур тегә* |
| | | Р – Г | *хөр яшәү* |
| | | $Р^2$ – Г | *кискен-кискен бәрелешү* |
| | | С (-дан, -га) – Ф | *турыга тегү* |
| | | Р (С) (-лай,-лап,-лата,-ча) – Ф | *яңача күрү* |
| | | Р (С) – дип, булып, итеп – Ф | *матур итеп уйлау* |
| | | Р (С) – көе (килеш, кебек, хәлдә, рәвештә) – Ф | *шат хәлдә йөрү* |
| | | Ф (-ып) – Ф | *мактап әйтү* |
| | | $Ф^2$ (а-и) – Ф | *җырлый-җырлый үтү* |
| | | Ф (-макчы) – Ф | *синнән күрмәкче эшләү* |
| | | Ф (-ган) – кебек – Ф | *сөйләгән кебек уку* |
| | | Ф (-дай, -ганча) – Ф | *ялгыштырмыйча сөйләү* |
| | | Ф (-гән) – көе – Ф | *утырган көйгә йоклау* |
| | | Ф (-ган) – дип, итеп, булып – Ф | *килгән итеп күрсәтү* |
| | | И – Ф (-мастан) – Ф | *сулыш алмастан күзәтү* |
| | | Ф (-ыр) – төсле – Ф | *йөрер төсле тою* |
| | | Ф (а-и) – кебек – Ф | *күрәм кебек хис итәм* |
| | | Ф (а-и) – дип – Ф | *укыйм дип йөрү* |
| | | И (-сыз) – Ф | *пычаксыз кисү* |
| | | И (-лы) – Ф | *мәгънәле генә карау* |
| | | И (-дан) – башка – Ф | *әтидән тыш килү* |
| чагыштыру, охшату | | И (-ча) – Ф | *татарча уку* |
| | | И (-дай) – Ф | *карлыгандай ялтырау* |
| | | И – буларак, булып – Ф | *җыр булып яңгырау* |
| | | И – формада – Ф | *китап формасында чыгару* |
| | | И – И (-ы) | *иген диңгезе* |
| | | И – И | *куян йөрәк* |
| | | И (-дәй) – И | *чәчкәдәй кызлар* |
| | | И (-ча) – И | *чуашча җыр* |
| | | И – кадәр, хәтле – И | *яфрак кадәр кар* |

| Сүзтезмә семантикасы | | Сүзтезмә модельләре | Мисаллар |
|---|---|---|---|
| гомуми | аерым | | |
| чагыштыру, охшату | | И – кебек, ише – И<br>И (-чә) – С<br>И (-дәй) – С<br>И – төсле, кебек – С<br>И(-га) – караганда – С<br>И (-дән) – Ф<br>И – кебек – Ф | *көрәк күк сакал*<br>*яшьләрчә саф*<br>*төлкедәй хәйләкәр*<br>*роман кебек күңелле*<br>*атка караганда яхшырак*<br>*кошлардан да тизрәк*<br>*аю кебек йөрү* |
| сәбәп | | И (-лык)тан – Ф<br>И – аркасында – Ф<br>Ф (-мәгәч) – Ф<br>Ф (-магачтын) – Ф<br>Ф (-ып) – И-Ф<br>Ф (-га, ганнан) – күрә – Ф<br>И (-дан) – С<br>Ф (-га) (с.ф.) – күрә – С<br>Ф (-лыктан) (с.ф.) – С | *шатлыктан йөгерү*<br>*авыру сәбәпле килмәү*<br>*белмәгәч әйтмәү*<br>*күрмәгәчтен әйтмәү*<br>*җырлап йокыны качыру*<br>*авырганга килмәү*<br>*яктылыктан кызыл*<br>*йөргәнгә күрә яхшы*<br>*белгәнлектән якын* |
| максат | | И (-га) – Ф (хәр)<br>Р – Ф<br>Ф (-у) – өчен – Ф<br>Ф (-рга) – Ф<br>Ф (-рга) – дип – Ф<br>Ф (-мак) – өчен – Ф<br>Ф (-макчы) – булып – Ф<br>Ф (-ыр) – өчен – Ф<br>И – өчен – И<br>Ф (-рга) – И<br>Ф (-рга) – С | *утынга бару*<br>*бушка йөрү*<br>*коткару өчен көрәшү*<br>*укырга бару*<br>*карарга дип бару*<br>*күрешмәк өчен килү*<br>*күрмәкче булып килү*<br>*белер өчен килү*<br>*революция өчен көрәш*<br>*сыенырга урын*<br>*кияргә уңай* |
| шарт | | Ф (-са) – Ф<br>Ф (-де) – исә – Ф<br>Ф (-ганда) – Ф<br>Ф (а-и) – икән – Ф | *күрсәм, әйтермен*<br>*килде исә, күренер*<br>*язганда аңлап була*<br>*уйлый икән эшли* |
| киресен башкару | | И – белән – Ф (-ма, -мый)<br>И (-га) – каршы – Ф<br><br>И (-га) – карамастан – Ф<br>Ф (-гач) – та – Ф<br>Ф (-ып) – та – Ф<br>Ф (-са) – да – Ф<br>Ф (-ута) – карамастан – Ф<br>Ф (-ганда) – да – Ф<br>Ф (-масын) – Ф<br>Ф (-ганчы) – Ф | *тавышы белән катнашмый*<br>*әтисенең теләгенә каршы*<br>*өйләнешү*<br>*явымга карамастан җыелу*<br>*карагач та күренмәү*<br>*әйтеп тә аңламау*<br>*күрсә дә әйтми*<br>*чакыруга карамастан килмәү*<br>*күргәндә дә әйтмәү*<br>*кайда күрмәсен, әйтә*<br>*тик йөргәнче укырлар* |

| Сүзтезмә семантикасы | | Сүзтезмә модельләре | Мисаллар |
|---|---|---|---|
| гомуми | аерым | | |
| каратылу | хуҗа милеккә | И (-ның) – И (-ы)<br>И – И (-ы) | *укучының китабы*<br>*командир машинасы* |
| | урын затка | И (-ның) – И (-ы) | *авылның егетләре* |
| | туган туганга | И (-ның) – И (-ы) | *малайның атасы* |
| | вакыт күренешкә | И (-ның) – И (-ы) | *көзнең яңгырлары* |
| | әйбернең максатына | И (-ның) – И (-ы) | *кошларның җиме* |
| | процессн. объектка | И (-ның) – И (-ы) | *корабның тукталуы* |
| | әйбернең үтәүчегә | И (-ның) – И (-ы)<br>И (-ның) – И (-ы) (ф) | *суның һөҗүме*<br>*Зиннәтнең кайтуы* |
| | сыйфат хуҗасына | И (-ның) – И (-ы) | *көннең кызуы* |
| | өлешнең бөтенгә | И (-ның) – И (-ы)<br>И (-ның) – И (-ы) | *кешенең күзе*<br>*өчнең берсе* |
| | әйбернең материалга | И (-ның) – И (-ы) | *чиләкнең калае* |
| мөнәсәбәт | үтәүченең процесска | И – И (-ы)<br>И – И (-ы) | *эзләү агенты*<br>*орудие тавышы* |
| | әйбернең процесска | И – И (-ы)<br>И – И (-ы) | *кимсетү сүзләре*<br>*ташкүмер өелүе* |
| | милләткә | И – И (-ы) | *рус укучысы* |
| | атамага | И – И (-ы) | *Идел елгасы* |
| | өлешнең бөтенгә | И – И (-ы) | *шомырт чәчәге* |
| | өлешнең урынга | И – И (-ы) | *көзге алды* |
| | өлешнең вакытка | И – И (-ы) | *көн урталары* |
| | әйбернең максатка | И – И (-ы) | *хатыннар бүлмәсе* |
| | әйбернең урынга | И – И (-ы) | *урам капкасы* |
| | әйбернең вакытка | И – И (-ы) | *кыш көне* |
| | әйбернең материалына | И – И (-ы) | *боз тавы* |
| | объектның үтәүчегә | И – И (-ы) | *су юлы, агач заводы* |
| ия булу - булмау | зат коралга ия | И (-лы, -сыз) – И | *күзлекле (күзлексез) кеше* |
| | зат сыйфатка ия | И (-лы, -сыз) – И<br>С + И(-лы, -сыз) – И | *акыллы (акылсыз) кеше*<br>*кара күзле малай* |

| Сүзтезмә семантикасы | | Сүзтезмә модельләре | Мисаллар |
|---|---|---|---|
| гомуми | аерым | | |
| ия булу-булмау | урын әйбергә ия | И(-лы,-сыз) – И | *урманлы (урмансыз) тау* |
| | вакыт әйбергә ия | И(-лы,-сыз) – И<br>И – И | *кояшлы (кояшсыз) көн*<br>*смотр көн* |
| | процесс әйбергә ия | И(-лы,-сыз) – И<br>И(-лы,-сыз) – И | *давыллы яңгыр*<br>*кайгысыз кеше* |
| | үтәүче процесс-ка ия | И (-лы) – И<br>И (-сыз) – И | *ашкынулы ритм*<br>*уйсыз кеше* |
| | объект процесс-ка ия | И (-лы) – И | *җигүле ат* |
| билгеле, үзенчәлек | материал буенча | И – И<br>И (-дан) – И<br>И (-дан) – гыйбарәт – И | *сатин күлмәк*<br>*татарлардан отряд*<br>*сөттән гыйбарәт елга* |
| | профес. буенча | И – И | *артист Искәндәр* |
| | исем буенча | И – И<br>И – дигән – И | *Җиһанша бабай*<br>*сандугач дигән кош* |
| | төре буенча | И – И<br>И (-дан) – И | *ир бала*<br>*дусларымнан Әхмәт* |
| | катышкан әйбер аркылы | И – аралаш, катыш – И | *төтен катыш бензин исе* |
| | төс буенча | С – И | *кызыл чәчәк* |
| | тәм буенча | С – И | *ачы катык* |
| | төрле үзенчәле-ге буенча | С – И | *һәвәскәр композитор* |
| | сәләт буенча | Ф (-лык)(с.ф.) – И | *ярдәм итәрлек чара* |
| процесс буенча | үзенчәл. билгесе | Ф (с.ф.) – И | *бирешми торган егет* |
| | объект билгесе | Ф (с.ф.) – И | *җырланасы җыр* |
| | урын билгесе | Ф (с.ф.) – И | *туган-үскән җир* |
| | вакыт билгесе | Ф (с.ф.) – И | *китәсе көн* |
| | корал билгесе | Ф (с.ф.) – И | *кисә торган пычкы* |

Шулай итеп, семантик төркемләү сүзтезмә кисәкләре арасында күптөрле мәгънә мөнәсәбәтләре булуын ачык күрсәтә. Гомуми мәгънә мөнәсәбәтләре – унбиш, ә аерымрак мәгънә мөнәсәбәтләре сиксәнгә якынлаша. Сүзтезмә кисәкләре арасында мәгънә мөнәсәбәтләренең характерын сүзләрне бәйләүче грамматик чаралар гына түгел, ә ияртүче яки иярүче кисәкнең мәгънәсе дә билгели.

Димәк, сүзтезмә кисәкләре арасында семантик мөнәсәбәтләрне лексик-грамматик мөнәсәбәтләр дип атау дөресрәк булыр.

## ҖӨМЛӘ КИСӘКЛӘРЕ

**§ 69. Җөмлә кисәкләре турында гомуми мәгълүмат**. Җөмлә төзелешен тикшерүдә, җөмләне кисәкләргә таркатып, аларның үзенчәлекләрен һәм үзара мөнәсәбәтләрен өйрәнү аеруча әһәмиятле. Хәзерге көндә җөмләләрне кисәкләргә логик-грамматик, структур-семантик, синтагматик һәм актуаль таркату кабул ителгән.

Логик-грамматик бүленешне, икенче төрле, традицион яисә грамматик бүленеш дип кенә дә атыйлар. Бу төр кисәкләр башта логикадагы субъект, предикат, объект, атрибут кисәкләренә туры китереп бүленгәннәр. Соңга таба саф логик принципка грамматика да кушылган, һәм атрибутның фигыльгә иярүчеләрен – хәл, исемгә иярүчеләрен аергыч дип икегә бүлгәннәр; ияртүчедән соң килә торган атрибутны аныклагыч дип аерып чыгарганнар; модаль мәгънә белдерүче кисәкләрне дә болар рәтенә куйганнар. Шулай итеп логик-грамматик кисәкләр буларак, ия, хәбәр, тәмамлык, аергыч, хәл, аныклагыч, модаль кисәкләр таныла башлаганнар.

Структур-семантик кисәкләргә бүлү синтаксис фәнендә бары XX йөзнең икенче яртысында гына ныклап танyла башлады, гасыр ахырында ул тюркологиядә, шул исәптән татар синтаксисы фәнендә дә, җентекле өйрәнелә. Структур-семантик кисәкләр буларак, шул ук логик-грамматик кисәкләр алына, ләкин аларга атамалар мәгънәдән (семантикадан) чыгып бирелә: предикат (нигездә хәбәргә туры килә), субъект (нигездә иягә туры килә), объект (тәмамлык), атрибут (аергыч), квалификатор (хәл). Бу бүленешне тикшергәндә, семантик

кисәкләрнең грамматик мәгънәләре генә түгел, лексик мәгънәләре дә исәпкә алына.

Синтагматик кисәкләргә бүлү җөмләнең, әйткәндә яисә укыганда, интонацион буыннарга бүленүен өйрәнүдән барлыкка килгән. Җөмләнең бер-берсеннән пауза белән аерылып тора торган кисәге синтагматик кисәк була.

Җөмләне аралашу чарасы буларак тикшергәндә, аның тыңлаучыга алдан таныш өлешен (темасын, сөйләмнең предметын), тыңлаучыга яңалык әйтә торган өлешен (сөйләм яңалыгын, темасын) аерып чыгаралар. Менә шул сөйләм предметын һәм сөйләм яңалыгын белдерүче сүзләрне актуаль кисәкләр дип атыйлар.

Җөмлә кисәкләренең үзенчәлеклерәк реальләшүе булган тиңдәш кисәкләр һәм аерымланган иярчен кисәкләр дә шушы ук бүлектә өйрәнелә.

## ЛОГИК-ГРАММАТИК КИСӘКЛӘР

**§ 70. Логик-грамматик кисәкләр турындагы өйрәтмәнең барлыкка килүе.** Синтагматик һәм актуаль кисәкләрдән аермалы буларак, логик-грамматик кисәкләрне «җөмлә кисәге» дип кенә атыйлар. Җөмләнең бу төр кисәкләргә (җөмлә кисәкләренә) бүленеше турындагы өйрәтмә барлыкка килгәнче, сүзләр бәйләнешен сүз төркемнәренә бәйләп тикшергәннәр, ягъни ул чорда синтаксис бары сүзтезмәләр белән генә эш иткән. Соңга таба логик юнәлеш өстенлек алуга бәйле рәвештә, грамматика әкренләп үзенә логик категорияләрне кабул итә башлаган, чөнки җөмләне логик категория булган хөкемләү (суждение) белән чагыштырып, аерым очракларда хәтта тәңгәлләштереп өйрәнгәннәр, димәк, хөкемләүнең борынгы философлар тарафыннан ук табылган кисәкләрен җөмләдән дә эзләргә тиеш булганнар. Ә җөмләне бары сүз төркемнәренә генә таркатканда, бу бүленешне (ягъни исемне, фигыльне, сыйфатны һәм башкаларны) хөкем кисәкләре (субъект, предикат, связь, объект, атрибут) белән туры китерү, бәйләү мөмкин булмаган. Шулай итеп, сөйләмне логик юнәлештә өйрәнү ихтыяҗыннан җөмләләрне кисәкләргә таркату барлыкка килгән. 1827 елда немец галиме Карл Беккер, хөкем кисәкләренә туры китереп, җөмләдә дүрт кисәк саный: субъект,

предикат, объект, атрибут. Җөмлә кисәкләрен болай бүлүне тиздән көнбатышта да, рус лингвистикасында да яклап чыгалар. XIX йөз уртасында А. Востоков үзенең «Русская грамматика» (СПб., 1848) дигән хезмәтендә шулай ук дүрт кисәк күрсәтә. Соңыннан рус тел белемендә биш кисәк (ия, хәбәр, аергыч, тәмамлык, хәл) турында сүз алып бара башлыйлар. Безнең чорда күп кенә рус лингвистлары бу биш кисәккә модаль кисәкләрне һәм аныклагычны өстиләр. Шулай итеп рус тел белемендә төрле чыгармалар һәм бәхәсләр, икеләнүләр белән ия (подлежащее), хәбәр (сказуемое), аергыч (определение), тәмамлык (дополнение), хәл (обстоятельство), аныклагыч (уточнение) һәм модаль (модальное яки сопутствующее) кисәкләрне күрсәтәләр. Ләкин бу бүленеш тә тулысы белән кабул ителмәгән. Бигрәк тә иярчен кисәкләрне төрләргә аеру күп бәхәс кузгатты. Кайбер телчеләр, мәсәлән, академик В.В.Виноградов иярчен кисәкләр турындагы элекке өйрәтмәнең тамырдан үзгәрергә тиешлеген әйтәләр. Б.А. Шапиро ул өйрәтмәнең фәнни грамматика принципларына җавап бирә алмавы турында яза.

Кайбер лингвистлар җөмләләрне кисәкләргә бүлүгә каршы чыгып, аларны грамматикалардан чыгарып ташларга тәкъдим итәләр. Мәсәлән, М.Н. Петерсон 1952 елда ук җөмлә кисәкләре турындагы өйрәтмә җөмләне хөкемләү белән тиңләүгә алып бара, шуңа күрә җөмлә кисәкләрен түгел, бәлки җөмләдә сүзләр бәйләнешен өйрәнергә кирәк дип язып чыкты. М.Н. Петерсон, бер яктан, җөмлә кисәкләренең традицион бүленешен тәнкыйтьләп дөрес эшли, ләкин, икенче яктан, җөмләләрнең кисәкләргә бүленешен инкяр итеп ашыгычлык күрсәтә. Чөнки җөмләне кисәкләргә бүлү тел һәм фикерләү, җөмлә һәм хөкемләү арасындагы мөнәсәбәтне тикшерү өчен генә түгел, бәлки барыннан да элек җөмлә модельләрен, калыпларын танып белү өчен кирәк. Э. Сепир әйтмешли, һәрбер төгәлләнгән җөмләнең нигезендә алдан әзер булган җөмлә өлгесе – моделе ята; бу модельләр, сөйләүчегә кирәк булганда, теләсә нинди конкрет җөмлә төзү өчен өлге булып торалар. Ул өлгеләр, сүзләр һәм формалар кебек үк, телдә аерым берәмлек буларак яшиләр [Сепир, 1934]. Алда әйтелгәнчә, синтаксис җөмләнең әнә шул модельләрен, өлгеләрен, аларның төзелешен өйрәнә. Ә моны уңышлы башкару өчен, җөмлә кисәкләрен тикшерергә кирәк була, чөнки җөмлә өлгеләрен,

модельләрен җөмлә кисәкләре төзи, ә сүз төркемнәре теге яки бу кисәк булып кына килергә мөмкин.

**§ 71. Татар телендә җөмлә кисәкләре.** Татар телендә җөмлә кисәкләрен өйрәнү һәм аларны төркемләү рус грамматикасы йогынтысында эшләнә. XIX йөздә үк инде баш һәм иярчен кисәкләрне аерып карыйлар. Башта җөмләне хөкемләүгә тиңләп, өч баш кисәк санийлар: ия (субъект), хөкем (предикат), бәйләгеч (связь). Аннары баш кисәкләрдән ия һәм хәбәр генә таныла башлый. Иярчен кисәкләрне башта ике дип кенә күрсәтәләр: аергыч (атрибут), тутыргыч (объект). Соңыннан аергыч, тәмамлык һәм хәлләрне саный башлыйлар. Г. Ибраһимов һәм Г.Нугайбәк иярчен кисәкләргә кереш һәм эндәш сүзләрне дә кертәләр, ләкин соңыннан эндәш һәм кереш сүзләр җөмлә кисәге итеп танылмый. Тик безнең чорда гына алар җөмләнең модаль кисәкләре дип санала башладылар.

Баш кисәкләргә – ия һәм хәбәр, иярчен кисәкләргә – аергыч, тәмамлык, хәл һәм аныклагыч, модаль кисәкләргә эндәш һәм кереш сүзләр керә. Сүзләр бәйләнешеннән чыгып караганда, модаль кисәкләр турыдан-туры сүзләр арасындагы бәйләнешне өйрәнү өчен хезмәт итмиләр, алар җөмлә өлгеләрен тулы ачыклауны гына тәэмин итәләр. Башка кисәкләр исә җөмлә өлгеләрен, модельләрен өйрәнү өчен дә, сүзләр бәйләнешен тикшерү өчен дә нигез булып торалар. Сүзләр бәйләнешенә мөнәсәбәттә караганда, хәбәрлекне генә белдерүче кисәкләр буларак, ия һәм хәбәр беренче дәрәҗәле кисәкләр булалар, ягъни алар сөйләм оештыруда беренче дәрәҗәдәге рольне уйныйлар. Үзара төгәлләүле мөнәсәбәткә кергән сүзләрнең ияртүчесе буларак, аергыч тәмамлык һәм хәл икенче дәрәҗәле кисәкләр булалар, чөнки сөйләм оештыруда икенче дәрәҗәдәге рольне уйныйлар. Аларның өчесен бергә гомуми исем белән «төгәлләгечләр» дип тә атарга мөмкин. Аныклаулы бәйләнештәге сүзләрнең ияртүчесе буларак, аныклагыч өченче дәрәҗәле кисәк була, чөнки бу бәйләнеш сөйләм оештыруда өченче дәрәҗәдәге рольне уйный.

Җөмләнең кисәкләргә логик-грамматик (традицион) бүленешен түбәндәге таблицада гомумиләштереп күрсәтергә мөмкин.




## БАШ КИСӘКЛӘР

**§ 72. Баш кисәкләр турында гомуми мәгълүмат.** 1814 елда ук инде, рус грамматикаларына ияреп, А. Троянский «Краткая татарская грамматика» дигән китабында өч баш кисәк саный: ия, хәбәр, бәйләгеч (связь). Болар хөкемнең өч кисәгенә – субъект, предикат, бәйләгечкә тәңгәлләштереп каралалар. А. Казимбәк та шул бүленешне үткәрә. Каюм Насыйридан башлап [Насыри, 1860] ике баш кисәкне: ияне һәм хәбәрне бүлеп чыгаралар. Тик профессор Г. Алпаров кына «Шәкли нигездә татар грамматикасы» (1926) хезмәтендә баш кисәк булып хәбәр генә танылырга тиеш дигән карашта тора. Ияне ул хәбәрнең баш тәмамлыгы дип кенә таный. Бу карашны дөрес дип булмый, чөнки хәбәр үзе – иягә ияреп килә торган кисәк.

Җөмләләрне ике составлы һәм бер составлы дигән төрләргә аерып өйрәнү тәртибе кергәч, баш кисәкләрне дә ике зур төркемгә бүлеп тикшерү кабул ителде: а) ике составлы җөмләләрдә баш кисәкләр: ия һәм хәбәр, ә) бер составлы җөмләләрдә баш кисәкләр; соңгысында да алар ике составлы җөмләләрдәге ияне һәм хәбәрне хәтерләтәләр, ләкин аларның иягә һәм хәбәргә тәңгәл килмәгән очраклары да күзәтелә, шуңа күрә бер составлы җөмләнең баш кисәкләре аерым алып карала.

Җөмлә төзелсен өчен, я ике сүзнең (иянең һәм хәбәрнең) хәбәрлекле мөнәсәбәткә керүе, я бер генә сүзнең (баш кисәкнең) хәбәр итү интонациясе белән әйтелүе кирәк. Беренче очракта – ике составлы җөмлә, икенче очракта бер составлы җөмлә барлыкка килә. Ике составлы җөмләләрдә баш кисәкләр **ия** һәм **хәбәр** дип өйрәнелә, бер составлы җөмләләрдә баш кисәк бары **баш кисәк** дип кенә атала.

## ИКЕ СОСТАВЛЫ ҖӨМЛӘЛӘРДӘ БАШ КИСӘКЛӘР

### ИЯ

**§ 73. Ия турында гомуми мәгълүмат.** Җөмләдә баш килештәге сүз белән бирелеп, хәбәрне үзенә ияртә торган грамматик бәйсез кисәк ия дип атала. Ияне өйрәнү – үзара хәбәрлекле мөнәсәбәткә кергән сүзләрнең ияртүчесен өйрәнү дигән сүз.

Җөмләдә ия турында ни дә булса әйтелә, ул җөмләнең бернинди кисәгенә дә грамматик буйсынмый, шуңа күрә аны бәйсез кисәк дип атыйлар. Иянең грамматик бәйсез булуы аның һәрвакыт баш килештәге сүз белән бирелүендә күренә. Баш килештәге сүз белән бирелеп кенә, ул хәбәрне үзенә буйсындыра, ягъни җөмләнең оештыручы үзәге була ала.

**§ 74. Иянең төп мәгънәләре.** Хәбәрнең кайсы сүзләр белән нинди формаларда бирелүенә карап, ия төрле мәгънәләрдә килә.

1. Хәбәр төп, кайтым яки уртаклык юнәлешендәге фигыльләр белән бирелгәндә, ия киң мәгънәдә үтәүчене (действующее лицо) белдерә. Мәсәлән: *Явыз ниятле к е ш е генә аштан баш тарта ул* (М. Гали). *Биектә-биектә күбәләк хәтле генә бер н ә р с ә күзенә чалынды аның* (И. Гази).

2. Хәбәр йөкләтү юнәлешендәге фигыль белән бирелсә, ия үтәүчене түгел, бәлки үтәргә кушучыны, йөкләүчене, ирек бирүчене яки эшнең үтәлүе өчен сәбәпчене белдерә. Мәсәлән: *Эшнең болай булуы аны бик ачындырды* (Г. Бәширов). *(Мин) янымдагы Ибрайдан, бертуктамый тегеләргә: «Тизрәк!» – дип кычкырта торам* (Г. Ибраһимов). *Кешеләр малайлардан яңгыр боткасы да пешертеп карадылар* (И. Гази).

3. Хәбәр төшем юнәлешендәге фигыль белән бирелсә, ия эшнең объектын белдерә. Мәсәлән: *Җигүле атлар да бүләк ителде* (Г. Ибраһимов). *Ап-ак тары боткасы ындыр табагыдай зур агач савытка сосылды* (Г. Ибраһимов).

4. Башка төрле хәбәр янында ия нинди дә булса бер үзенчәлеге хәбәр ителә торган әйберне, төшенчәне белдерә. Мәсәлән: *Ул бик туры карт* (Г. Ибраһимов). *Роман кебек күңелле син, юл!* (Х. Туфан). *Әбез – өчәү* (И. Гази). *Безнең Алмачуардан башка ике атыбыз бар* (Г. Ибраһимов). *Аның синнән башка да эше җитәрлек* (Г. Тукай). *Габдулла Нигъмәтҗан абзый өчен, шулай ук Әптелбәр өчен чиктән тыш шат һәм горурлы!* (Ә. Фәйзи). *Быел кар күп* (Ә. Фәйзи). *Ай да гел синең төсле* (җыр).

Шулай итеп, ия, үтәүчене генә түгел, башка мәгънәләрне дә белдерә. Үз чиратында үтәүче дә иядә генә бирелми. Ул тәмамлыкта (мәсәлән, бу *мәсьәлә минем тарафтан хәл ителде*), аерылмышта да (мәсәлән, *укыган кеше*) бирелергә мөмкин.

**§ 75. Иянең бирелеше һәм аның төрләре.** Ия, башлыча, исемнәр белән бирелә. Исем мәгънәсендә барлык башка төрле сүз төркемнәре дә җөмләдә ия булып килә алалар. Мисаллар: *Төн караңгы. Дөнья тын. Ләкин диңгез шаулый* (Г. Ибраһимов). *Алар аны урманчы белән уртаклап эшләделәр* (А. Шамов). *Анысын үзең карарсың инде* (Ш. Камал). *Күбебез моның сүзен куәтләде* (Г. Ибраһимов). *Болар һәммәсе шул атасына охшап туган Гыйлаҗи кулыннан ясалып килә* (Г. Ибраһимов). *Сөйләшү барып чыкмады* (Ф. Хөсни). *Бу өйнең башка өйләрдән әллә ни аермасы юк* (Ф. Хөсни). *Ашаган белми, тураган белә* (мәкаль). *Җылы сөяк сындырмый, салкын җанны тындырмый* (мәкаль). *Бүген – җомга көн* (Р. Вәлиев). *Тугыз өчкә тигез бүленә. Гайшә тик кул куярлык булып чыкты. Бу чаклысы да аның өчен зур шатлык иде* (Г. Ибраһимов).

*Җитәр инде ялкауланырга* (К. Тинчурин). *Мондый кайгылы уйлар уйлап маташырга миңа да килешми* (Г. Тукай). *Укымак – фикерләрне җирдән күккә җибәрмәк* (Г. Тукай). *Аһ-ваһлар калмады хәзер. «Барып» – рәвеш фигыль. «Һәм» – теркәгеч.*

Бер генә сүз белән бирелсә, ия гади ия дип йөртелә. Ия фразеологик сүзтезмә белән бирелсә, мондый ияләрне тезмә ия дип атыйлар. Мәсәлән: *«Язгы җилләр» – тарихи роман; Үги ана яфрагы юешрәк урында үсә.*

**ХӘБӘР**

**§ 76. Хәбәр турында гомуми мәгълүмат.** Җөмләнең ия турында хәбәр итә һәм аңа грамматик буйсына торган баш кисәге хәбәр дип атала.

Бирелүләренә һәм мәгънәләренә карап, татар әдәби телендә хәбәрләр ике төрле булалар: фигыль хәбәр һәм исем хәбәр.

Фигыль хәбәр фигыль белән бирелә һәм һәрвакыт процесс, динамика белдерә.

Исем хәбәр фигыльдән башка сүз төркемнәре белән бирелә һәм иядән аңлашылган әйбернең, төшенчәнең материалын, хезмәтен яки нинди дә булса бер билгесен хәбәр итә.

**Искәрмә:** «Исем хәбәрләр» дигән терминдагы «исем» сүзе фигыльдән башка сүзләрне җыеп атау өчен шартлы рәвештә алына.

Исем хәбәрләр дә, фигыль хәбәрләр дә гади, тезмә һәм кушма булалар. Бер сүз белән бирелгән хәбәр – гади, фразеологик яки бу очракта аерым кисәкләргә таркалмый торган синтаксик сүзтезмә белән бирелгән хәбәр тезмә хәбәр була. Боларда грамматик мәгънәләр кушымчалар һәм интонация ярдәмендә бирелә. Грамматик мәгънәләре ярдәмлек сүзләр белән бирелсә, гади хәбәр дә, тезмә хәбәр дә кушма төргә әйләнә. Димәк, кушма хәбәрләр гади яки тезмә хәбәрләргә нигезләнеп ясалалар.

Татар телендә исем хәбәрне ияга бәйләүче хәбәрлек кушымчалары бар: I зат өчен – *-мын*/*-мен*, *-ыбыз*/*-без*; II зат өчен – *-сыз*/*-сез*, *-сың*/*-сең*; III зат өчен – *-дыр*/*-дер*, *-тыр*/*-тер*. Болар, кушымчалар гына булганлыктан, исем хәбәрне гади итеп формалаштыралар. Хәзерге әдәби телдә алар гадәттә кулланылмыйлар. Хәбәрлек кушымчалары кушылып ясалган гади исем хәбәрләр, хәбәрлек кушымчалары төшеп

калгач та, гади булып калалар. Шуңа күрә татар телендә исем хәбәрләрнең гади төре дә бар. Рус телендә гади исем хәбәрләр булмый, анда исем хәбәр һәрчак кушма була. Чөнки тарихи яктан руста исем хәбәр янында *есмь-есть* ярдәмче сүзе йөргән. Ул ярдәмче сүз исем хәбәрне һәрвакыт кушма итеп формалаштырган. Ярдәмче сүз кулланылмаса да, хәзер рус телендә исем хәбәрләр бары кушма гына була дип карыйлар.

Хәбәрләрнең төрләрен, схематик рәвештә, түбәндәге таблицадан күреп була.




ФИГЫЛЬ ХӘБӘРЛӘР

## Гади фигыль хәбәрләр

**§ 77. Хикәя фигыльләр белән бирелгән гади фигыль хәбәрләр.** Мондый хәбәрләр җөмләдә күптөрле модаль мәгънәләрне белдерәләр.

1. Хәзерге заман хикәя фигыль белән бирелгән хәбәр түбәндәге мәгънәләргә төренгән процессны (эш яки хәлне) белдерә:

а) Сөйләү моменты белән туры килә торган процессны. Мәсәлән:

*Идел буе талларыннан*
*Суга яфрак к о е л а ...*
*Ярга килеп, сары көймә*
*Яфрак кебек с ы е н а ...* (Р. Мингалим).

ә) Сөйләү моментыннан соң үтәләчәк процессны. Мәсәлән: *Ун минуттан соң җыелышны а ч а б ы з .*

б) Сөйләү моментына кадәр булып үткән процессны. Мәсәлән: *Бервакытны б а р а м шулай урам буйлап, о ч р ы й бит миңа бер бүре. Мылтыгымны а л а м , бүре т е л г ә к и л ә* (халык иҗаты).

в) Сөйләү моментына мөнәсәбәте булмаган, ягъни һәрвакыт табигый рәвештә булып тора торган процессны. Мәсәлән:

*Тик бел, йөрәк: шырпы җилдә с ү н ә ,*
*Учак я н а җилдә катырак* (М. Фәйзуллина).

г) Сөйләү моменты белән мөнәсәбәте булмаган, ләкин үтәлүе икенче бер процессның үтәлүенә бәйле булган процессны. Мәсәлән: *Кышын карлы буран булса, язын яңгыр б у л а* (Һ. Такташ). *Икмәк кырда яңгыр астында калса ү р ә* («Ватаным Татарстан»).

2. Киләчәк заман хикәя фигыльләр белән бирелгән хәбәрләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр: а) сөйләү моментыннан соң үтәлергә тиеш булган процессны. Мәсәлән: *Мин, партизан, анда к а й т ы р м ы н* (Һ. Такташ); ә) һәрвакыт булып тора торган яки сөйләү моментына кадәр булган процессны. Мәсәлән: *Сакалы ак, һәм йөзеннән нур ч ы г а р , күз к а м а ш ы р , һәркем йөзенә б а г а р* (Г. Тукай).

3. Үткән заман хикәя фигыль белән бирелгән хәбәрнең төп мәгънәсе – сөйләү моментына кадәр башкарылган һәм үтәлүе сөйләүче тарафыннан күзәтелгән процессны белдерә. Мәсәлән: *Синең әтиең фашистларга каршы с у г ы ш т ы* (Д. Аппакова). *Хәйрулла абзый соңгы елларда үзенең олы улы Хафиз семьясында я ш ә д е* (С. Әдһәмова).

Аерым очракларда әдәби телдә һәм сөйләшләрдә бу төр хәбәр сөйләү моментыннан соң һичшиксез башкарылачак процессны да белдерә. Мәсәлән: *Шул вакытта уйла, шагыйрь! К и л д е Илһам, уйласаң* (Г. Тукай). *Җирне яхшылап с ө р син аны, энем. Менә аннан соң ашлыкны умырдың да а л д ы ң инде!* (Минзәлә сөйләше).

**§ 78. Боерык фигыльләр белән бирелгән хәбәрләр.** Бу төр хәбәрләр төрле модаль мәгънәләрне белдерәләр.

1. Боеруны, кушуны белдерә. Бу – боерык фигыльләр белән бирелгән хәбәрләрнең төп мәгънәсе. Мәсәлән: *Шул вакытта у й л а , шагыйрь!* (Г. Тукай).

2. Теләк мәгънәсен белдерә:

*Ташка тисә, таш э р е с е н ,*
*Һич с ү р е л м ә с е н йөрәк!* (С. Сөләйманова).

3. Җөмләнең төзелешенә һәм интонациясенә карап, күптөрле модаль мәгънәләр белдерә: сөйләүче процесска гаҗәпләнеп, ирония белән карый, процессның дәвам ителүен тели, тыңлаучыга процессның үтәлүеннән сакланырга куша һ.б. Мисаллар: *Ялы беткәч, бу егет белән бергә Казанга к и т м ә с е н м е !* (Ф. Хөсни). *Тизрәк барырга кирәк: тегеләр к и т м ә с е н н ә р ! Без кайтыйк, алар к а л с ы н н а р .*

4. I зат боерык фигыльнең берлеге белән бирелгән хәбәр сөйләүченең киңәш соравын, ниятләвен белдерә. Мәсәлән: *Мин эш эзләргә ч ы г ы й м , син миңа рөхсәт бир* (халык иҗаты). Шул ук фигыльнең күплеге белән бирелгән хәбәр процессны үтәргә яки үтәмәскә чакыруны белдерә: *А т л ы й к , дуслар, алга табан!* (Г. Тукай).

Үткән заманда кинәт кенә үтәлгән процессны да хәбәр итә ала. Мәсәлән: *Беткән баш беткән дидем дә, й ө г е р шул якка* (Г. Бәширов).

Шушы ук төр хәбәр кире җөмләне дә формалаштыра ала. Бу вакытта ул каршы кую мәгънәсен бирә. Мәсәлән:

*...Төн буена нинди каты җил и с м ә с е н,–*
*ни булса да, бары да бер аның өчен...* (Г. Тукай).

*Асылыңны яшереп*
*к ы л а н м а ни генә, –*
*буыннар хәтерендә*
*бары да чигелә!* (Р. Фәйзуллин).

**§ 79. *-ачак* һәм *-ган* формасындагы фигыльләр белән бирелгән гади фигыль хәбәрләр.** Бу төр хәбәрләрнең грамматик мәгънәләре түбәндәгечә.

1. Киләчәк заман хикәя фигыль белән бирелгән хәбәр сөйләү моментыннан соң һичшиксез башкарылачак процессны белдерә. Мәсәлән: *Җансыз гәүдәм шушы теләкләргә азык булып җирдә я т а ч а к* (Һ. Такташ).

2. Үткән заман хикәя фигыль белән бирелгән хәбәр нигездә түбәндәге мәгънәләрне белдерә.

а) Сөйләү моментына чаклы башкарылган процессның нәтиҗәсен сөйләү моментына китереп күрсәтә. Мәсәлән:

*Менә карагыз минем йөзләремә,*
*Анда нинди сүзләр с ы з ы л г а н .*
*Зур күзләрем эчкә кереп баткан,*
*Ак чәчләрем ничек т у з ы л г а н* (Һ. Такташ).

*Кайда баксаң, анда т у л г а н сәүдәгәр* (Г. Тукай).

ә) Сөйләү моментына чаклы үтәлгән, ләкин үтәлүе сөйләүче тарафыннан күзәтелмәгән процессны белдерә. Мәсәлән:

*Я ш ә г ә н бу халык,*
*заманнар к и ч е р г ә н .*
*Өмете кырык кат*
*я л г а н г а н, к и с е л г ә н* (К. Сибгатуллин).

Биредә сөйләүче, процессның башкарылуы турында төрле чыганаклардан белеп, башка кешедән ишетеп сөйли. Бу – II–III затларга караган җөмләләрдә шулай. I затка караган җөмләләрдә *-ган/-гән* формасы алган фигыль белән бирелгән хәбәр сөйләүченең процессны белештермичә, аның нәтиҗәсен уйламыйча башкаруын белдерә; сөйләүче процессның үзе тарафыннан үтәлгән булуына яки ул процессның көтелмәгән нәтиҗә бирүенә соңыннан гына, процесс үтәлгәч кенә төшенә: *К а г ы л г а н м ы н былбыл оясына Һәм б а с к а н м ы н кара еланга...* (Зөлфәт). *Һәр җинаятьченең үз фәлсәфәсе булуы турында ничек дөрес у й л а г а н м ы н* (Р. Вәлиев).

б) Үтәлгән вакыты сөйләүчегә ачык билгеле булмаган процессны белдерә. Мәсәлән: *Үткән заманда бер авылда б у л г а н бер карт, аның булган өч улы* (халык иҗаты). *А с р а г а н н а р бер кәҗә белән сарык* (Г. Тукай).

Бу төр хәбәрнең барлык очракларына да уртак булган абстрактграмматик мәгънәсе – сөйләүченең процесс барышына, агылышына игътибар итмәвен, бәлки инде башкарылган процессның нәтиҗәсен сөйләү моментына кайтарып күрсәтүен белдерү.

**§ 80. Шарт һәм теләк фигыльләр белән бирелгән хәбәрләр.** Бу төр хәбәрләр түбәндәге модаль мәгънәләрне белдерәләр:

1. Шарт фигыль шарт һәм кире җөмләнең хәбәре булып килә, һәм мондый хәбәр башка бер процессның үтәлү-үтәлмәвенә шарт булган яки булмаган процессны белдерә. Мәсәлән: *Кунак булып к и л м ә с ә м д ә , әйбәт каршы алдыгыз* (Ф. Хөсни). *Анда, фронтта, дошман туп*

*белән җ и м е р т с ә , монда юешлек дошманга ярдәм итә: стеналарны җимерә* (Ә. Фәйзи). *Төн уртасы а в ы ш с а , җил бераз туктар иде* (А. Шамов).

Сорау өлеше кулланылмаганда, сорау җөмләнең хәбәре дә шарт фигыль белән бирелә ала. Мондый хәбәр шикләнеп сорауны белдерә. Мәсәлән: *Ә алар авылга үзләре к и л с ә л ә р ?!* (И. Гази). *Шәкертләр бер айдан соң да ч ы г а р ы л м а с а л а р ?!* (Г. Ибраһимов).

2. *-кыры*/*-кере*, *-гыры*/*-гере* формасындагы фигыльләр белән бирелгән хәбәрләр теләкне белдерәләр. Мәсәлән: *Авызыңны корт ч а к - к ы р ы* (әйтем). *Тамагыңа таш к е р г е р е !* (Р. Батулла).

3. *-гай*/*-гәй* формасындагы фигыль дә хәбәр булып кулланыла. Мондый хәбәр процессның үтәлүеннән сөйләүченең саклануын белдерә. Мәсәлән: *Өйгә кеше к е р м ә г ә е* ; *Каш ясыйбыз дип, күз ч ы - г а р м а г а е к .*

**§ 81. Дәрәҗә формасындагы фигыльләр белән бирелгән гади фигыль хәбәрләр.** Бу төр хәбәрләр түбәндәге абстракт-грамматик мәгънәләргә төренгән процессларны белдерәләр.

а) Кабатлана-кабатлана үтәлә торган процессны. Мәсәлән: *Син безгә к и л г ә л ә . Бу китапны у к ы ш т ы р . Гали безгә к и л г ә л ә ш - т е р с е н , киногa б а р г а л а ш т ы р г а л а р б ы з .*

ә) Тулысынча башкарылмаган, бәлки өлешчә генә үтәлгән процессны. Мәсәлән: *Ул бераз й о к ы м с ы р а д ы . Гали к ө л е м с е р и . Тозы бераз ч ы г ы н к ы р а с ы н . Бу кыяфәте белән ул хирург-профессорга о х ш а н к ы р ы й* (К. Нәҗми).

**§ 82. Төрле юнәлештәге фигыльләр белән бирелгән гади фигыль хәбәрләр.** Мондый хәбәрләрне өйрәнү – татар әдәби телендәге биш төрле (төп (үтемле), уртаклык, йөкләтүле, кайтымлы һәм төшемле) әйләнмәләр белән танышу дигән сүз. Хәбәрнең билгеле бер юнәлештә булуы әйләнмәнең үзенчәлеген, ягъни ия һәм үтәүче, хәбәр һәм процесс, тәмамлык һәм объект арасындагы мөнәсәбәтләрнең ничек булуын билгели.

1. Төп юнәлештәге фигыльләр белән бирелгән хәбәрләр (үтемле әйләнмә). Мондый хәбәр җөмләнең иясеннән үтәүчене, ә җөмләнең тәмамлыгыннан объектны белдерүне таләп итә. Мәсәлән, *Халык танецлар башланганын көтте* (Ф. Әмирхан) дигән җөмләдә көтү процессын җөмләнең иясе (*халык*) башкара. Процессның объектын тә-

мамлык белдерә. Хәбәрне белдерүче фигыль күчемсез булса, үтәүче белән ия арасындагы мөнәсәбәт турында гына сөйләргә туры килә, чөнки күчемсез фигыль объект таләп итми.

2. Уртаклык юнәлешендәге фигыль белән бирелгән хәбәр (уртаклык әйләнмә). Мондый хәбәр күплектә булганда, эшне кара-каршы үтәүчеләр икесе дә ия булып киләләр. Мәсәлән: *Аннары Биктаһир карт белән Галиулла тагын сугыш турында с ө й л ә ш т е л ә р* (И. Гази).

Хәбәр берлектә килгәндә, эшнең инициаторы булган үтәүче ия булып, процессны ияреп кенә үтәүче җөмләнең тәмамлыгы булып формалаша. Мәсәлән: *Аннары Галиулла Биктаһир карт белән тагын сугыш турында с ө й л ә ш т е .*

Уртаклык юнәлешендәге күчемле фигыль белән бирелгән хәбәрнең тагын бер үзенчәлеге шунда: ул ярдәм итү, булышу мәгънәсен белдерә. Мәсәлән: *Ай да атлар с а к л а ш а* (Р. Корбан).

Монда төп үтәүче – тәмамлык булып, төп үтәүчегә ярдәм итүче ия булып формалаша.

3. Йөкләтү юнәлешендәге фигыль белән бирелгән хәбәр (йөкләтүле әйләнмә). Мондый хәбәр төрле мәгънә төсмерләрен бирә.

а) Процессны үтәргә турыдан-туры кушу, йөкләү мәгънәсен белдерә, бу вакыт процесс турыдан-туры кешеләргә караган була. Мәсәлән: *Гөләнвәр аңардан Фазылга хат я з д ы р д ы* (Ә. Фәйзи).

ә) Бер әйбернең процессны үтәргә сәбәпче булуын, ирек бирүен белдерә. Мәсәлән: *Бу кәгазь аңа, әйтерсең лә, канатлар ү с т е р - д е* (К. Нәҗми). *Куанычлары эчләренә сыймый, йөзләрен б а л к ы т а* (Г. Бәширов). *Әңгәмә аны бик к ы з ы к с ы н д ы р д ы* (Ә. Фәйзи).

Мондый әйләнмәдә процессны үтәүче – тәмамлыкта, үтәүчегә йөкләүче яки үтәргә сәбәпче, ирек бирүче булган зат (күренеш) иядә бирелә.

4. Кайтым килешендәге фигыль белән бирелгән хәбәр (кайтымлы әйләнмә). Мондый хәбәр үтәүченең дә, объектның да иядә бирелүен таләп итә, ягъни үтәүче бер үк вакытта объект та була. Мәсәлән: *Су буенда казлар т ө з ә т е н ә , Уйнап туйганнар да инештә* (Х. Әюп).

Аерым очракларда мондый әйләнмәдән үтәүченең процессны үз файдасына, үз алдына башкаруы да аңлашыла. Мәсәлән: *Рәҗәп абыйлардан чыккач, Габдулла шулай дип у й л а н д ы* (Ә. Фәйзи).

5. Төшем юнәлешендәге фигыль белән бирелгән хәбәр (төшемле әйләнмә). Мондый хәбәрле җөмләдә процесс объекты – ия булып,

процессны үтәүче тәмамлык булып формалаша. Мәсәлән: *Бу мәсьәлә җыелышка халык тарафыннан к у е л д ы .*

Җөмләдә үтәүче аерым сүз белән бирелмәскә дә мөмкин: ул фикер сөрешеннән аңлашыла, яки аның кем (нәрсә) булуына игътибар ителми. Мәсәлән: *Укучылар өчен дәреслекләр җәйдән әзерләнде.*

Җөмләдә үтәүче, түбәндәге формаларны алып, тәмамлык булып килә: а) *тарафыннан* сүзе белән, мәсәлән: *Бу мәсьәлә җыелышка студентлар тарафыннан куелды*; ә) *белән* бәйлеге ярдәмендә, мәсәлән: *Урам ташлары, агач коймалар, куе яфраклы яшел кипарислар чиста итеп яңгыр суы белән юылган иделәр* (М. Юныс); б) чыгыш килеше формасы аша, мәсәлән: *Яшь чагымда мин авыру дәрәҗәдә хыялый-сентиментальный бер кеше идем, юк кына нәрсәләрдән тәэсирләнәм, күңелем кузгала иде* (Ш. Камал); в) үтәүче аерым сүз белән бирелми, бәлки контексттан аңлашыла, мәсәлән: *Шушыңа охшашлы шигъри хәбәрләр бездә аз басылмыйлар* (С. Әдһәмова). *Бу тарихи карар халыкның көнкүреш дәрәҗәсен кискен күтәрүгә юнәлдерелгән* («Ватаным Татарстан»).

## Тезмә фигыль хәбәрләр

**§ 83. Тезмә фигыль хәбәрләрнең бирелеше.** Тезмә фигыль хәбәрләр бирелешләре буенча төп ике төргә аерылалар.

1. Кайбер исемнәрдән, сыйфатлардан, саннардан һәм, бигрәк тә алынма сүзләрдән *ит*, *бул*, *кил*, *кыл* сүзләре ярдәмендә ясалган фигыльләр белән бирелгән хәбәрләр. Монда ярдәмче фигыльләр грамматик мәгънә белдермиләр, бәлки ясагыч кушымчалар кебек үк, фигыль генә ясыйлар. Шуңа күрә мондый хәбәрләр кушма төргә кертелмиләр. Мәсәлән: *Юлыбыз һаман дәвам итә* (М. Гали). *Бәйрәм итә, үзенекен итә, өмет итә, зыян итә, вәгъдә итә, хис итә, мыскыл итә, тәкъдим итә, киңәш итә* һ.б.ш. ясалма фигыльләр тезмә хәбәр булып килә алалар. *Мут булсын, ут булсын, вафат булган, тәмам булган, һәлак булган, риза булган, насыйп булган, мәгълүм булган* сүзләре дә шул төр хәбәр була алалар.

2. Тезмә фигыль хәбәрләрнең икенче төре идиоматик (фразеологик) әйләнмәләр белән бирелә. Андый әйләнмәләрне хәзерге көндә сүзгә-сүз аңлау мөмкин түгел, аларның кайберләре образлы итеп әйтүдән башланып киткәннәр (мәсәлән: *колак салу, күз салу*),

ә кайберләре кешеләрнең борынгы уйлау ысулын чагылдыралар (мәсәлән: *күңелен табу, өмет өзү, уй йөртү*). Тарихи яктан мондый хәбәрләр төрлечә барлыкка килгәннәр.

1) Туры тәмамлык белән хәбәрнең бергә кушылуыннан. Мәсәлән: *Мин ни дип әйтсәм дә, аңар әһәмият бирми* (Ш. Камал). *Мин сезгә ул турыда сүз бирәм* (Д. Аппакова). *Анда бүген, канлы Европада, тәре үбеп антлар бирәләр* (Һ. Такташ). *Садретдинов дошман траншеяларыннан күзен алмады* (Г. Әпсәләмов). *Ул як-ягына күз салды* (Г. Бәширов).

2) Хәлләр яки кыек тәмамлыклар белән хәбәрнең мәгънә ягыннан бергә кушылуыннан. Мәсәлән: *Ә мин, Нәфисә апа ачуланмаса, киләсе елдан башка чыгам! Кышкы салкыннарда, беләсез, бу бик кыенга килә* (Г. Бәширов). *Аның матурлыгы мине таңга калдырды. Дүртенче көн инде Мәликә апа бөтенләй аяктан калды* (К. Нәҗми). *Кояшның соңгы нуры... күздән югалды* (Г. Бәширов). *Мөхәммәтгариф дөньядан үтте* (Ә. Фәйзи). *Агыйдел... хәтта чит-читләренә төнбоеклар үсүгә дә каршы килми* (М. Әмир). *Әптелбәр, уйнарга теләсә дә, бу тәкъдимне кире какты* (Ә. Фәйзи).

3) Ия һәм хәбәрнең мәгънә ягыннан бергә берегүеннән. Мәсәлән: *Казнадан бирәләр икән, анда икенче мәсьәлә, анда күз күрер* (Г. Бәширов). *Анасыннан «улым» сүзе дә ычкынгач, Хәлимнең эченә җылы керде* (И. Гази). *Моннан әллә ни эш чыкмады. Ярсыды халык, апакайларым, халыкның ачуы кабарды* (Г. Бәширов).

Соңгы очракта бер составлы җөмлә барлыкка килә.

Менә шундый хәбәрләрнең элек ике кисәк булып, хәзер бер кисәккә генә калуы, кешенең фикерләве үсүгә бәйләнешле рәвештә, грамматик категорияләрнең дә үсүен, үзгәрүен күрсәтә.

## Кушма фигыль хәбәрләр

### Сөйләүченең процесска мөнәсәбәтен (модаль мәгънә) белдерүче кушма фигыль хәбәрләр

**§ 84. Боеру, үтенүне белдерүче кушма фигыль хәбәрләр.** Бу төр хәбәрләр түбәндәгечә ясалалар:

1. *Күр* фигыле *-а*/*-и* формасын алган фигыль янында килә һәм кушма хәбәр ясый. Андый хәбәр ялынуны, процессның үтәлүеннән

сакланырга кушуны белдерә. Мәсәлән: *А ч у л а н а  к у р м ә мине бүген...* (М. Әгъләм).

2. *Бул* (*булма*) фигыле һәм киләчәк заман сыйфат фигыль белән ясалган хәбәр катгый боеруны белдерә. Мәсәлән: *Хәзер үк с а л а с ы б у л галошыңны!* (К. Тинчурин). *Яңадан к е р ә с е  б у л м а г ы з шул картларга!* (Г. Ибраһимов).

3. *Тиеш* модаль сүзе дә, инфинитив янында килеп, кушма хәбәр ясый, һәм ул хәбәр сөйләүченең боеруын, гомумән процессның башкарылырга яки башкарылмаска тиешлеген белдерә. Мәсәлән: *Мин музыка я з а р г а  т и е ш* (Р. Вәлиев).

**§ 85. Теләкне белдерүче кушма фигыль хәбәрләр.** Болар түбәндәгечә ясалалар:

1. *Иде* һәм III зат боерык фигыльләр белән ясалган хәбәр модаль мәгънә белдерә: сөйләүче процессның III зат тарафыннан үтәлүен тели. Мәсәлән: *Сап-сары алтыннар алар, шунда я н с ы н н а р  и д е, җөмлә гасыйлар үчен шулардан а л с ы н н а р  и д е* (Г. Тукай).

2. *-ырдай*/*-рдай* формасындагы фигыль, *бул* ярдәмлек фигыле белән бергә, чарасыз теләкне белдерә торган хәбәр ясый. Мәсәлән: *Йөгереп к и т ә р д ә й  б у л а м ла, кайтып җ и т ә р д ә й  б у л а м* (җыр). *Бик к и л е р д ә й  б у л ы р с ы ң – без булмабыз* (К. Тинчурин).

**§ 86. Ниятләүне белдерүче кушма фигыль хәбәрләр.** Бу төр хәбәрләрнең ясалышы түбәндәгечә:

1. *Ит* яки *әйт* ярдәмлек фигыле һәм инфинитив белән. Мәсәлән: *Мин, иптәш, тагы бер мәртәбә т а л п ы н ы п  к а р а р г а  и т ә м* (Г. Ибраһимов). *Ә язмыш аңа к а р ш ы  б а р ы р г а  ә й т ә* (И. Гази).

2. *Тор* ярдәмлек фигыле һәм инфинитив белән. Мәсәлән: *Ашамый-эчми кая ю г а л ы р г а  т о р а с ы ң, өлгерерсең әле* (Ә. Фәйзи). *Басыбрак тотмасаң, кәләпүшеңне а л ы п  к и т ә р г ә  т о р а* (И. Гази).

3. *Бул* ярдәмче фигыле һәм *-макчы*/*-мәкче* формасы алган фигыль белән. Мәсәлән: *Ике хәзрәт, ни өчендер, извозчик я л л а м а к ч ы  б у л а л а р* (Г. Тукай). *Музыка картларның да йокыларын качыра икән, әүзләре яшьләргә а ч у л а н м а к ч ы  б у л а л а р* (М. Гали).

4. *Бул* ярдәмче фигыленең категорик үткән заман (*булды*) формасы һәм инфинитив белән. Мәсәлән: *Таҗи шул яктан гына к ү з ә т е р г ә  б у л д ы* (Г. Гобәй). *Игенчелек кораллары турында бәхәс әллә ни*

*озын булмады: аларны җәмәгать файдасына б и р е р г ә  б у л д ы л а р* (И. Гази). *Мин артык түзә алмыйм, мин к и т ә р г ә  б у л д ы м* (Г. Гобәй).

**§ 87. Шартны белдерүче кушма фигыль хәбәрләр.** Бу төр хәбәрләр түбәндәгечә ясалалар:

1. *Исә* ярдәмлек фигыле үткән заман хикәя фигыль янында килеп. Мәсәлән: *Ул к и л д е  и с ә , киногa китәбез. Шул картинаны к а р а д ы м  и с ә , күңелем тула.*

2. *Иде* ярдәмлек фигыле, *-ыр*/*-ер* кушымчасын алган фигыль белән бергә, кушма хәбәр ясый, һәм ул хәбәр билгеле шарт булганда үтәлергә мөмкин булган процессны белдерә. Мәсәлән: *Иркәм иркәләр иде. Иркәм авылларда булса, к и л е п  к и т к ә л ә р  и д е* (җыр). *Дивизиядә радиостанция булса, без хәзер дошманга сулыш алырга да и р е к  б и р м ә с  и д е к* (Г. Бәширов).

**§ 88. Үкенүне белдерүче кушма фигыль хәбәрләр.** Мондый хәбәр үткән заман сыйфат фигыль янында *булса* фигыле килү юлы белән ясала. Мәсәлән: *Мин үзем барган булсам, барысы да хәл ителә иде.*

**§ 89. Иронияне белдерүче кушма фигыль хәбәрләр.** *Бул* ярдәмче фигыле, үткән заман сыйфат фигыль янында килеп, иронияне белдерә. Мондый хәбәрдә ирония ачуланып көлүдән башлап җиңелчә елмаеп әйтүгә кадәр йомшарырга мөмкин. Мәсәлән: *Җитмәсә тагы теге аксак кызы да «Үз энем! Җан энем!» – дип, Садрины, юри мине кәефсезләндерер өчен, сөйгән була иде* (Г. Тукай). *«Мин белӛмлек» дәгъвасын кыйлган була, салам сыйрак!* (Г. Тукай). *Һи, тел бистәсе, һи, ерык авыз! Телеңә салынып утырган буласың шунда!* (Г. Бәширов).

*Булат уйнап куган булды,*  
*Кочаклап алган булды,*  
*Фәйрүзәсе көлгән булды,*  
*Битен каплаган булды* (М. Җәлил).

**§ 90. Мөмкинлекне белдерүче кушма фигыль хәбәрләр.** Болар түбәндәгечә ясалалар:

1. *Ал* ярдәмче фигыле *-а*/*-и* формасындагы фигыль янында килеп. Мәсәлән: *Тавышым ерак еллар күкрәгендә я ң г ы р ы й  а л с ы н !* (Һ. Такташ). *Аның бу сүзләренә каршы, Сәлимә бернәрсә дә ә й т ә  а л м а д ы* (М. Гали).

2. *Бел* фигыле *-а/-и* формасындагы фигыль янында килеп. Мәсәлән: *Ул бит инде хәзер нинди сөйкемле итеп к ө л ә б е л ә* (Г. Гобәй). *Таҗи хәзер күп кенә эшләр э ш л и б е л ә* (Г. Гобәй).

**§ 91. Гаҗәпләнүне, икеләнүне белдерүче кушма фигыль хәбәрләр.** Болар түбәндәгечә ясалалар:

1. *Икән* ярдәмлек фигыле һәм *-ыр/-ер* формасындагы фигыль белән. Мәсәлән: *Алтмыш яшьлек картлар да шулкадәр хезмәт көне э ш л ә р л ә р и к ә н ! Ул да шулай каты итеп с ө я р и к ә н !*

2. Сорау кисәкчәсе алган фигыльләр янында *икән* ярдәмлек фигыле килү юлы белән. Мәсәлән: *Мин хәтта яхшылап белмим дә әле, әгәр дә мине җәзаласалар, минем батырлыгым җ и т ә р и д е м е и к ә н ?* (А.Әхмәт). *Әллә Фатыйма бакчаны бик а р з а н ы ч к ы н д ы р д ы м ы и к ә н ?* (И. Гази).

**§ 92. Ихтималны белдерүче кушма фигыль хәбәрләр.** Болар түбәндәгечә ясалалар:

1. *Торган* яки *торгандыр* фигыле *-а/-и* кушымчасын алган фигыль янында килеп. Мәсәлән: *Бәлки ул безгә биреләчәк машинаны үзе б е л ә т о р г а н д ы р . Бәлки мин аның белән йөрәгемә утырган юшкынны ю ы п т ө ш е р ә т о р г а н м ы н !* (Г. Бәширов).

2. *Бул* ярдәмче фигыле *булыр* формасында хәзерге заман хикәя фигыль янында килеп. Мәсәлән: *Эш ү с т е р ә б у л ы р , Хәдичә түти, басу җиле, җир сулышы шулай тиз ү с т е р ә б у л ы р* (Г. Бәширов).

3. *Булса кирәк* тезмәсе һәм *-а/-и* формасындагы фигыль белән. Мәсәлән: *Ул дәрес х ә з е р л и б у л с а к и р ә к . Ул арада боларны кайсыдыр к ү р е п а л д ы б у л с а к и р ә к* (Г. Бәширов).

Шундый ук мәгънәдә *кирәк* сүзе инфинитив белән дә килә һәм кушма хәбәр ясый. Мәсәлән: *Бүген мин сөйләшкән кеше язучы б у л ы р г а к и р ә к .*

**§ 93. Сынауны белдерүче кушма фигыль хәбәрләр.** Бу төр хәбәр *-ып/-п* формасын алган фигыль янында *кара* фигыле килү юлы белән генә ясала. Мәсәлән: *Ул иреннәрен к ы й м ы л д а т ы п к а р а д ы , ләкин бернәрсә дә әйтә алмады* (А. Шамов). *Артларыннан бер эскадрон кавалерия җ и б ә р е п к а р а д ы к , тота алмадылар* (Г. Гобәй).

**§ 94. Хикәяләүне белдерүче кушма фигыль хәбәрләр.** Монда сөйләүче процессны объектив рәвештә хәбәр итә, аңа үзенең эчке кичерешләрен дә, бернинди теләкләрен дә кушмый. Андый хәбәрләр

төрлечә ясалалар. Мәсәлән: *Ләкин крестьянның төп катламы бу хәлдән соң, үз эченә йомылып, мыштым гына йөрер булды* (Ә. Фәйзи). *Әни миңа, эш кушарга кирәк булмаса, сүз дә дәшмәс булды* (Г. Тукай).

Бу формадагы хәбәр белдергән процесс, гадәттә, субъектның һәрвакыттагы сыйфатына әйләнеп киткән була. Шундый ук процессны белдерүче хәбәр *-а/-и* формасын алган фигыль янында *торган бул* тезмәсе килү юлы белән дә ясала. Мәсәлән: *Малай үсә төшкәч, җәй көннәрендә алар, аталы-уллы, иртүк торып, бакчага алмагачлар карарга ч ы г а   т о р г а н   б у л д ы л а р* (И. Гази).

Аннан соң *бул* ярдәмче фигыле, башка формадагы фигыльләр янында килеп тә, хикәяләү мәгънәсен бирә ала. Мәсәлән: *Якуб ул шәһәр кешесе. Кырмыска оясына таяк тыгып бутар-бутар да к и т т е   б а р д ы   б у л ы р* (И. Гази). *Монысының нәрсәсе о ш а м ы й   б у л а   инде, янәсе, кайсы ягы килешми* (Г. Бәширов). *Хат язуның остасы булып китүе һәм олы кешеләрнең бу мәсьәләдә үзенә мохтаҗлыгы, әлбәттә, Габдулланың аз булса да г о р у р л ы г ы н   к и т е р м и   б у л м а д ы* (Ә. Фәйзи).

## Процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә үтәлүен белдерүче кушма фигыль хәбәрләр

**§ 95. Процессның башлану дәрәҗәсен белдерүче кушма фигыль хәбәрләр** түбәндәгечә ясалалар:

*Яз* фигыле *-а/-и* формасын алган фигыль янында килеп, кушма хәбәр ясый, һәм ул кушма хәбәр башланыр алдыннан туктап калган процессны белдерә. Мәсәлән: *Кеше алдында ярамаганны с ө й л и   я з д ы . Ай-яй җил көчле икән монда: йөгереп барганда, кәләпүшне а л ы п   к а л а   я з д ы !* (Г. Гобәй).

*Җибәр* фигыле, *-ып/-п* формасын алган фигыль белән килеп, процессның бик тиз башланып китүен белдерә. Мәсәлән: *Егет җ ы р л а п   җ и б ә р ә* (җыр). *Зәлия к ө л е п   җ и б ә р д е* (Р. Вәлиев).

*Маташ* фигыле дә инфинитив белән бергә кушма хәбәр ясый, һәм андый хәбәр процессның башлану алдында торуын белдерә. Мәсәлән: *Дошман атаканы к и р е   к а й т а р ы р г а   м а т а ш а* (С. Әдһәмова).

*Алып кит*, *алып биреп кит* конструкцияләре дә *-ып/-п* формасын алган фигыль белдергән процессның башлану дәрәҗәсен күрсәтәләр. Мәсәлән: *Әсма хәлен аңлатты, сәламәтлеген сагынды, авыруның*

*ни икәнен дә белмәгән яшьлеге турында с ө й л ә п   а л ы п   к и т т е* (Ә. Фәйзи).

*Башла* фигыле, -*а*/-*и* формасындагы фигыль белән килеп, кушма хәбәр ясый. Мондый хәбәр, гомумән, процессның башлануын гына хәбәр итә. Мәсәлән: *Бу турыга килеп җиткәч, тагын да дәртләнебрәк у й н ы й   б а ш л а д ы л а р* (М. Гали). *Тора-бара бу кыз туганнарын сагына, җ и р с и   б а ш л ы й* (халык иҗаты).

*Тотын*, *кереш* фигыльләре дә инфинитив белән бергә кушма хәбәр ясыйлар һәм процессның башлануын белдерәләр. Мәсәлән: *Тыштагы ай яктысы тагын аның йөрәк моңнарын т и б р ә т е р г ә   т о т ы н а* (Г. Бәширов).

Бу бүлекчәдә китерелгән хәбәрләр белдерә торган процесс тәмамланган булырга да мөмкин. Ләкин сөйләүче аңа игътибар итми, процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә башлануына гына басым ясый.

**§ 96. Процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә дәвам итүен белдерүче кушма фигыль хәбәрләр.** Мондый хәбәрләр түбәндәгечә ясалалар:

*ят* фигыле -*ып*/-*п* формасын алган фигыль белән бергә генә кушма хәбәр ясый, һәм ул процессның ике чик (башлану һәм тәмамлану) арасында салмак кына, үзгәрешсез дәвам итүен белдерә. Мәсәлән: *Урамда митинг я с а л ы п   я т а   иде* (М. Гали). *Бер тарафта балдан һәм сөттән гыйбарәт кәүсәр елгасы а г ы п   я т а* (Г. Тукай).

*Тор* фигыле, -*ып*/-*п* һәм -*а*/-*и* формасын алган фигыльләр янында килеп, кушма хәбәр ясый һәм процессның үзгәрешсез дәвам итеп торуын белдерә. Мәсәлән: *Көннәр бер-бер артлы у з а   т о р д ы* (Р. Вәлиев).

Бу төр хәбәрләр процессның башка бер процесс үтәлгән чорда башкарылуын да (мәсәлән, *Әминә апа язганда, Мортаза бабай ике кулына чыра тотып я к т ы р т ы п   т о р д ы* (Г. Гобәй); процессның вакытлыча үтәлүен дә белдерә (мәсәлән, *Мә, син менә бу карандаш белән я з а   т о р ; Гарифулла көрәген биреп т о р м а с   м и к ә н ?* (И. Гази).

*Торган иде* ярдәмлек фигыле, -*а*/-*и* формасындагы фигыль янында килеп, процессның кабатлана-кабатлана дәвам итүен белдерә. Мәсәлән: *Аның тирән сагышлы тавышы кичләрен караңгы авыл урамында еш и ш е т е л ә   т о р г а н   и д е* (М. Вәлиев).

*Кал* фигыле, *-а/-и* формасындагы фигыль янында килеп, процесснең дәвам итүен белдерә. Мәсәлән: *Газизә ялгыз гына утыра калды* (Ш. Камал). *Без чыгып киттек, ул шунда йөри калды.*

*Утыр* фигыле *-ып/-п*, сирәгрәк, *-а/-и* формасын алган фигыль белдергән процессның дәвамлылыгын күрсәтә. Мәсәлән: *Газизә апа яшенә буылып, чыга алмый утырды* (Ә. Фәйзи). *Син менә шул картиналарны карый утыр.*

*Бир* фигыле, *-а/-и* формасын алган фигыль белән килеп, процессның ике чик (башлану – тәмамлану) арасында үзгәрешсез дәвам итүен белдерә. Мәсәлән: *Як-юненә каранып, бара бирә Хәлим* (И. Гази).

*Бар* фигыле, *-ып/-п* һәм *-а/-и* формаларын алган фигыльләр янында килеп, процессның дәвамлылыгын белдерә. Мәсәлән: *Әллә без барган саен, «чыпчык» ераккарак оча бара* (Г. Тукай). *Бала күңелен тетрәткән ул фаҗиганең ярасы акрынлап төзәлә барды* (Г. Бәширов). *Ул сөйләгәннәрнең барысын да язып бардым.*

*Кил* фигыле, *-ып/-п* формасын алган фигыль белән бергә, процессның ике чик арасында үзгәрешсез дәвам итүен яки соңына якынлашып килүен белдерә. Мәсәлән: *Атасы Бикбулат килгәндә, Нәфисә яза торган хәбәрен очлап килә иде* (Г. Бәширов). *Яшелчәләр өлгереп киләләр.*

*Кил* фигыле, *-а/-и* формасын алган фигыль белән дә кушма хәбәр ясый, һәм андый хәбәр билгеле вакыт эчендә дәвам итә торган процессны белдерә. Мәсәлән: *Мин сезгә бу турыда ел буена искәртә килдем.*

*Төш* фигыле, *-а/-и* формасын алган фигыль белән бергә, кушма хәбәр ясый һәм ике чик арасында эзлекле рәвештә үсә барган процессны белдерә. Мәсәлән: *Морозка Хома Рябцев бакчасы янында атын туктата төште* (А. Шамов). *Күзләре дә икенче төрле карый башладылар, өс-башы да рәтләнә төште* (Г. Гобәй).

*Тот* фигыле, *-ып/-п* формасын алган фигыль белән бергә, процессның дәвамлы булуын белдерә. Мәсәлән: *Дару урынына гына салып тоттым. Чыгып китмәсен дип карап тоттым.*

*Маташ* фигыле, *-ып/-п* формасын алган фигыль янында килеп, процессның дәвамлы булуын белдерә. Мәсәлән: *Тыкрыкка сыенып утырган кечкенә мастерскойда картлар тырма һәм арба кебекләрне*

*төзәтеп маташалар* (Г. Бәширов). *Мәктәптә шигырьләр язып маташтым* (Р. Вәлиев).

**§ 97. Процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә тәмамлануын белдерүче кушма фигыль хәбәрләр.** Мондый кушма хәбәрләрнең төп өлеше бары *-ып*/*-п* формасын алган фигыль белән генә, ә ярдәмче өлеше түбәндәге фигыльләр белән бирелә:

*Кит, ут* фигыльләре процессның бик тиз тәмамлануын белдерә. Мәсәлән:

*Тавышыңда туган якның*
*Чишмәләре чыңлап китә,*
*Әнкәм көйләгән көйләрнең*
*Аһәңнәре чагылып үтә* (Р. Вәлиева).

*Ал* фигыле процессның бик кыска вакыт эчендә үтәлеп, бик тиз тәмамлануын белдерә. Мәсәлән: *Сөйләр алдыннан төрле якка карап алдылар* (М. Гали). *Мортаза бабай комиссарга астан гына карап алды* (Г. Гобәй).

*Төш* фигыле процессның кинәт кенә үтәлеп, тәмамланып куелуын күрсәтә. Мәсәлән: *Коралсызландырылган Мечик кинәт җебеп төште* (А. Шамов). *Талчыбыктай бөгелеп төшмәмен* (Ә.Исхак). *Бу хәбәрдән Фатыйма каушап төште* (И. Гази).

*Куй* фигыле процессның тиз үтәлеп, бик тиз тәмамлануын белдерә. Мәсәлән: *Еракта, бик еракта пароход кычкыртып куйды* (Г. Гобәй). *Без, үзебез дә сизмәстән, бер-беребезгә карап куйдык* (Ф. Яруллин).

*Кал* фигыле процессның соңына кадәр үтәлеп тәмамлануын белдерә. Мәсәлән: *Габдулланың уйлары шунда бүленеп калды* (Ә. Фәйзи). *Кәрван юл уртасында туктап калган* (К. Насыйри). *Кал* фигыле төп фигыль белдергән процессның башка процесс башланганчы тәмамлануын да тәгъбир итә. Мәсәлән: *Яңгырлар башланганчы, бәрәңгеләрне җыеп калдык.*

*Ташла* фигыле процессның ахырына кадәр үтәлеп, тәмамлануын тәгъбир итә. Мәсәлән: *Ярый, абый. Мин самоварда калган су белән керләрне чайкап ташлармын* (Һ. Такташ). *Ул барысын да сөйләп ташлады.*

*Ат* фигыле процессның бик тиз тәмамлануын белдерә. Мәсәлән: *Мин ул гаризаны кичә үк язып аттым. Ул артлы чананы кичә үк ясап аткан*. Бу форма әдәби телдә бик актив түгел.

**Процессның үтәлү дәрәҗәсен белдергән кушма хәбәрнең төзелешен һәм мәгънәсен якынча күрсәтүче таблица**

| Кушма хәбәрдәге дәрәҗә категориясе төрләре | Кушма хәбәрдәге төп фигыль формасы | | |
|---|---|---|---|
| | *-а/-и* формасындагы фигыль (*сөйли... әйтә...*) | *-ып/-п* формасындагы фигыль (*сөйләп... әйтеп...*) | инфинитив (*сөйләргә... әйтергә...*) |
| Процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә башлануын белдерү | яз, башла | җибәр, алып кит, алып биреп кит | маташ, тотын, кереш (башла) |
| Процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә дәвам итүен белдерү | тор, кал, утыр, бир, бар, кил, төш | ят, тор, утыр, бар, кил, тот, маташ | |
| Процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә тәмамлануын белдерү | | кил, ал (җибәр), үт, төш, куй, кал, ташла, ат, сал, бир, җит, җиткер, бет, бетер, чык, чыгар | |

*Сал* ярдәмче фигыле процессның тиз генә тәмамлануын белдерә. Мәсәлән: *Сүзгә бик үткен нәрсә икән, кистереп кенә салды* (Г. Бәширов). *Барлык белгәннәрен әйтеп салды*.

*Бир* фигыле процессның тәмамлануын белдерә. Мәсәлән: *Галия үзе әйтеп бирер* (Г. Гобәй). *Туганы аңа ничек итеп хакыйкать эшләвен сөйләп биргән* (халык иҗаты).

*Җит* фигыле процессның чигенә җитеп тәмамлануын белдерә. Мәсәлән: *Галиянең тагарактагы суы җылынып җитә* (Г. Гобәй). *Ит пешеп җитә. Стенаны агартып җиткердем*.

*Бетү* фигыле процессның чигенә җитүен белдерә. Мәсәлән: *Бабай картаеп беткән. Без «Мәрфугат» мәйданына килеп җиткәнче*

*й ө д ә п  б е т т е к* (Ш. Камал). *Мәктәп киштәсендә аунап яткан китапларның барысын да у к ы п  б е т е р д е  инде ул* (И. Гази).

*Чык* фигыле процессның дәвамлылыктан соң чигенә җитеп тәмамлануын белдерә. Мәсәлән: *Пика бүреге тирәли кулын й ө р т е п  ч ы к т ы* (А. Шамов). *Ике араны үткәнче минем баш берничә җирдән к ү б е п  ч ы к т ы* (Ш. Камал). *Таһир бөтен залны күзе белән с ө з е п  ч ы к т ы* (Ш. Камал). *Ул якларын инде аның Нәфисә үзе и с ә п л ә п  ч ы г а р а* (Г. Бәширов).

### Заман белдерүче кушма фигыль хәбәрләр

**§ 98. Бу төр хәбәрләрнең төп үзенчәлекләре.** Төрле заманны белдерүче кушма фигыль хәбәрләр *иде* һәм *бул* ярдәмлек фигыльләре ярдәмендә ясала.

1. Үткән заманда билгеле бер вакытта үтәлгән процессны белдерә торган хәбәрләр: а) процессның сөйләүче тарафыннан күзәтелгән булуын күрсәтәләр, мәсәлән: *Кояш аңа үзенең нурларын каршы яктан б ә р ә  и д е* (А. Шамов); ә) процессның сөйләүче тарафыннан күзәтелмәгән булуын күрсәтәләр, мәсәлән: *Шәмси бабай белән йон эрләүче Гайни карчык шау-шусыз гомерләрен ү т к ә р ә  б у л г а н н а р* (Г. Ибраһимов). *Ат Урманбаш авылының әле бер урамында, әле икенче тыкрыгында тузан туздырып чабып й ө р и  т о р г а н  б у л г а н* (Ф. Хөсни). *Габделгәрәй карчыкка авылга якын бер җирдә һәр ел ун таяк тары ч ә ч е п  б и р ә  б у л г а н* (Г. Ибраһимов). *Борынгы заманнарда авыл халкы... орлык белән бергә күкәй дә ч ә ч ә  б у л г а н н а р* (Г. Бәширов).

2. Булган процесстан да алдарак үтәлгән процессны (күптән үткән заманны белдерүче кушма хәбәрләр: а) процессның сөйләүче тарафыннан күзәтелүен күрсәтәләр, мәсәлән: *Шәрәфи абзый өйдәме? – дип, солдат к ы ч к ы р г а н  и д е* (Ш. Камал). *Бу вакытта фронтның алдынгы көчләре башка урынга к ү ч к ә н  и д е л ә р* (К. Нәҗми); ә) процессның сөйләүче тарафыннан күзәтелмәгән булуын күрсәтәләр, мәсәлән: *Бу юлы монахның теле аз-маз р ә т л ә н г ә н  б у л а* (К. Нәҗми).

3. Сөйләү моментыннан соң үтәләчәк процессны үткән заманга кайтарып күрсәтүче хәбәр түбәндәге мәгънәләрне белдерә: а) процессның үтәлергә тиешлеген сөйләүче турыдан-туры үзе белә, мәсәлән: *Ул*

*бүген каравылга үзе* *ч ы г а с ы и д е ( ч ы г а ч а к и д е ) . Син минем янга к и л ә ч ә к и д е ң бит;* ә) процессның үтәлергә тиешлеген сөйләүче төрле чыганаклардан гына белә, мәсәлән: *Докладны Әхмәт с ө й л и с е ( с ө й л ә я ч ә к ) б у л г а н .*

4. Сөйләү моментына кадәр башкарылган, ләкин тәмамлануына сөйләүче тарафыннан игътибар ителмәгән процессны белдерүче хәбәрләр. Мәсәлән: *Һәркөн төшкәчә дәрес укып, аннан соң балалар белән уенга ч ы г а р и д е* (К. Насыйри). *Аның улы Газиз дә нәкъ менә шулай: у к ы р и д е д ә, я з ы п к у я р и д е, у к ы р и д е д ә, кәгазенә с ы з ы п к у я р и д е* (Г. Бәширов).

Хәзерге әдәби телдә мондый кушма хәбәр, күбесенчә, шартлы теләкне белдерә, заман мәгънәсендә сирәгрәк кулланыла.

### Эзлекле яки параллель процессларны белдерүче кушма фигыль хәбәрләр

**§ 99. Бу төр хәбәрләрнең төп үзенчәлекләре.** Алда төрле абстракт-грамматик мәгънәләрне белдерүче кушма хәбәрләр тикшерелде. Анда грамматик мәгънәләрне, конкрет эчтәлеген югалтып, ярдәмлек фигыльләр урынында йөри торган фигыльләр белдерәләр. Шулар ук һәм башка бик күп фигыльләр, *-ып*/*-п* яки *-а*/*-и* формасын алган фигыльләр янында килеп, кушма хәбәр ясыйлар һәм шул ук вакытта үзләренең төп, конкрет эчтәлекләрен дә саклап киләләр. Мондый кушма хәбәрләрдә *-ып*/*-п* яки *-а*/*-и* формасын алган фигыль – үзенә аерым, ярдәмлек фигыль үзенә аерым бер процессны белдерә. Бу процесслар үзара я параллель, я эзлекле булалар. Мисаллар: *Менә тагын у з ы п к и т е п б а р а м ...* (И. Гыйләҗев). *Янәшәдә генә инеш ш а у л а п а г а* (Р. Вәлиев). *Җәяүле кеше юлның һәр адымына үзенең хәләл көчен т ү г ә б а р а* (М. Юныс). *С ө р ә н с а л ы п у з д ы киек казлар...* (Н.Гамбәр). *Искәндәр пианино янына к и л е п у т ы р д ы* (Р. Вәлиев).

## ИСЕМ ХӘБӘРЛӘР

### Гади исем хәбәрләр

**§ 100. Гади исем хәбәрләрнең бирелеше һәм мәгънәләре.** Гади исем хәбәрләр хәзерге заманга караган яки заманга мөнәсәбәте

булмаган җөмләләрдә генә булалар. Алар, фигыльдән башка төрле сүз төркемнәре белән бирелеп, төрле мәгънәләрне белдерәләр.

1. Исемнәр, алмашлыклар һәм исем урынында килгән башка сүзләр белән бирелгән гади хәбәрләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр: а) бер әйберне (затны) икенче әйбер (зат) аркылы аңлаталар, хәбәр итәләр: *Шуларның берсе – м и н , – диде егет* (А. Расих); ә) иядән аңлашылган әйбернең материалын белдерәләр: *Бу кровать – т и м е р . Теге өстәл – а г а ч* ; б) *-ныкы*/*-неке* формасын алган сүзләр белән бирелгән гади исем хәбәр бер әйбернең икенче әйбергә (затка) каравын белдерә, ягъни хәбәр белдергән әйбер ия белдергән әйбернең хуҗасы булып аңлашыла: *Калган көн иртәдән алып кичкә кадәр а н ы к ы* (Ә. Фәйзи). *Бу китап И с м ә г ы й л ь н е к е . Йөз чалымнары гына түгел, хәтта холкы да б а б а с ы н ы к ы, Ш а к и р а б ы е г ы з н ы к ы* (М. Хуҗин).

2. Сыйфатлар, рәвешләр, саннар һәм сыйфат урынында йөри торган башка сүзләр белән бирелгән хәбәр ия белдергән әйбернең (затның) сыйфатын, рәвешен, санын һәм башка күптөрле билгеләрен, үзенчәлекләрен белдерә. Мәсәлән: *Кәеф к ү т ә р е н к е* (Р. Вәлиев). *Чират буенча мин – а л т ы н ч ы . Акыллы дошман акылсыз дустан я х ш ы р а к* (мәкаль).

3. Чыгыш, юнәлеш һәм урын-вакыт килешендәге сүзләр белән бирелгән хәбәрләр иядән аңлашылган әйбернең материалын, нәрсә өчен булуын, күләмен-чамасын, урынын һәм төрле билгеләрен белдерә. Мәсәлән: *Аклы ситсы күлмәгемнең сәдәпләре а л т ы н н а н* (җыр). *Безнең план з у р д а н* (К. Тинчурин). *Беребез кояш ч ы г ы ш ы н д а , беребез б а е ш л а р ы н д а* (җыр).

**§ 101. Хәбәрлек сүзләр белән бирелгән гади исем хәбәрләр.** Гади хәбәрнең *бар*, *юк*, *кирәк*, *тиеш* кебек хәбәрлек сүзләр белән бирелгән төре дә бар. Бу төр хәбәрләр исем хәбәрдән дә, фигыль хәбәрдән дә аерылып, үзләренә башка төркем тәшкил итәләр. Мәгънәләре белән алар фигыль хәбәрләргә, зат (хәбәрлек) кушымчаларын алу-алмаулары белән исем хәбәрләргә якын торалар. Мәсәлән: *Рус Микитинның Казанда циркы б а р* (Г. Тукай). *Күктәге йолдызларда күптән җир йөзеннән юкка чыккан халыкларның эзләре бар* (М. Юныс). *Эше юкның ашы да юк* (мәкаль). *Мескен кешедә бер чакта да өмет ю к* (Р. Вәлиев). *Тышлык ясарга зәңгәр буяу к и р ә к* (К. Нәҗми).

## Тезмә исем хәбәрләр

**§ 102. Тезмә исем хәбәрләрнең бирелеше.** Тезмә исем хәбәрләр дә, гади исем хәбәрләр кебек үк, хәзерге заманга караган яки заманга мөнәсәбәте булмаган җөмләләрдә генә булалар.

1. Иярүче кисәге фигыльдән башка сүз булган фразеологик сүзтезмәләр белән бирелгән тезмә исем хәбәрләр. Мәсәлән: *Ә хәле аның җ и л к ә  к а ш ы р л ы к* (Ә. Еники).

2. Хәбәр булып килгәндә, бу контекстта аерым кисәкләргә таркалмый торган синтаксик сүзтезмәләр белән бирелгән тезмә исем хәбәрләр. Мәсәлән: *Өйрәләре сыек булса да, өйләре к а л а й  т ү б ә л е* (Г. Ибраһимов). *Безнең урам – з у р  у р а м* (җыр). *Казан – бик м а т у р  ш ә һ ә р . Синең атың – я х ш ы  а т . Карлыгач – бик җ и т е з  к ы з . Ул – ш ә һ ә р  к ы з ы* (Р. Вәлиев).

Тезмә исем хәбәрнең мәгънәләре гади исем хәбәр мәгънәләренә охшый.

## Кушма исем хәбәрләр

**§ 103. Кушма исем хәбәрнең төп мәгънәләре һәм бирелеше.**

1. Кушма исем хәбәрләр *иде*, *икән*, *бул* ярдәмче фигыльләре ярдәмендә формалашалар.

*Иде* тамырыннан булган ярдәмче фигыльләр үткән заманны белдерсәләр, *бул* ярдәмче фигыле үткән һәм киләчәк заманнар белән төрләнә һәм шул заманнарны белдерә ала. Мәсәлән: *Иртә белән көн т о м а н л ы  и д е* (Ш. Камал). *Хәят бу кич туганнарына ч а к ы р у л ы  и д е* (Ф. Әмирхан). *Кадыйр аның а в ы л д а ш ы  и д е* (Р. Вәлиев). *Һәр заманны монда хәлләр ш у л  и к ә н* (Г. Тукай). *Кичен бигрәк я м ь л е  б у л а . Кына гөл к ы з ы л  б у л а* (җыр). *Кичә сезгә килгән кеше м и н  б у л а м .*

Борынгы телдә *тор* ярдәмче фигыле белән дә кушма исем хәбәр ясалган. Мәсәлән: *Салчы – А м ә т  у г л ы  т о р ы р .*

Тора-бара *тор* ярдәмче фигыле кушымчага әйләнгән. Мәсәлән: *Кояш илә ай икесе ике кәнитилле к а л ф а к л а р д ы р* (Г. Тукай) (гади хәбәр).

Кайбер очракта *тор* ярдәмче фигыле хәзерге телдә дә кушма хәбәр ясый. Мәсәлән: *Икенче команда студентлардан тора.*

2. III зат алмашлыгы ярдәмендә ясалган кушма исем хәбәрләр. Мәсәлән: *Дөресен әйткәндә, халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул* (Г. Тукай). *Безнең егетләр батырлар алар*. Бу алмашлыклар I, II нче зат хәбәрлек күрсәткечләренә ияреп кулланылалар.

3. *Түгел* сүзе дә кушма исем хәбәр формалаштыра. Мәсәлән: *Мәктәп залында үсәләр гөлләр, әле ул кадәр биек түгелләр* (С. Баттал). *Тик эшегез болай булса... сезнең хәлләр шәптән түгел* (Г. Бәширов).

4. Төрле бәйлекләр ярдәмендә ясалган кушма исем хәбәрләр түбәндәгеләрне белдерәләр: а) ия белән хәбәр арасындагы сәбәпле һәм максатлы бәйләнешне: *Аның тырышуы халык өчен;* ә) бер предметны икенчесенә чагыштыруны: *Бу бөтенләй кибетчедәге үлчәү шикелледер* (Г. Тукай). *Сагынганда айга карыйм, Ай да гел синең төсле* (җыр). *Шул томанның эчләрендә минем дустым бар сыман* (җыр). *Бүген көн ут кебек*.

5. Татар телендә *бугай*, *ич*, *бит*, *шул*, *ләбаса*, *ахры*, *соң* һ.б.ш. кебек модаль сүзләр дә, фигыль яки исем янында килүләренә карап, кушма фигыль хәбәр яки кушма исем хәбәр ясыйлар, чөнки алар күбрәк хәбәр янында абстракт-грамматик мәгънә белдереп йөриләр. Мәсәлән: *Кичә безгә килгән кеше укытучы бугай. Ул укытучымы соң? Харис хәзер укытучы бит* (*ич, ахры, шул*).

### Ия белән хәбәр арасында бәйләнеш һәм аны белдерүче чаралар

**§ 104. Фигыль хәбәрнең ия белән ярашуы.** Фигыль хәбәр һәм ярдәмлек фигыль белән ясалган кушма исем хәбәр I һәм II затларга караган җөмләләрдә иягә затта да, санда да һәрвакыт яраша. Мәсәлән: *Мин тормышка тешем, тырнагым белән ябышачакмын* (Г. Бәширов). *Без инде моннан элек өч думаның өчесенә дә гакыллы кешеләр җибәреп карадык* (Г. Тукай). *Ашамый-эчми кая югалырга торасың инде син* (Ә. Фәйзи). *Хәзер без өчәү булдык* (халык иҗаты). *Шулай итеп без хәзер атлы, арбалы булдык* (Г. Ибраһимов). Күрсәтелгән төрдәге хәбәрләр I һәм I затларда һәрвакыт махсус кушымчалар алганлыктан, III заттагы хәбәр кушымчасыз да I, II затлардагы хәбәрләрдән аерылып тора. Димәк, III заттагы фигыль хәбәр (һәм кушма исем

хәбәр) дә ия белән затта һәрвакыт яраша, мәсәлән: *Алар кайттылар. Укучылар китте.*

Сирәк очракларда үткән һәм киләчәк заман сыйфат фигыльләр белән бирелгән хәбәрләр, I һәм II затларга караган җөмләләрдә дә, ия белән затта һәм санда ярашмаска мөмкин. Мәсәлән: *Мах биргән мин, мәсьәләне, стал быт, кабыргасы белән куймаган* (Г. Бәширов). *Бу картинаны без үзебез караячак. Сез юлны яхшы төзегез, юкса шуннан үзегез үк үтәчәк бит.*

**§ 105. Исем хәбәрнең ия белән ярашуы.** Ярдәмлек фигыльләре булмаган исем хәбәрләр, бигрәк тә гади һәм тезмә хәбәрләр, кагыйдә буларак, ия белән ярашмыйча киләләр: *Аның барлы-юклы бер чокыр сөте була, аны ни сиңа, ни миңа... ә без өчәү* (И. Гази). *«Таулар» авылында өч җил тегермәне бар. Аларның берсе Мәлик байныкы* (И. Гази).

Ләкин аерым басым ясап әйтергә кирәк булганда яки җөмләнең стилистик шомалыгы, матурлыгы таләп иткәндә, гади исем хәбәрләр дә ия белән затта һәм санда ярашып киләләр. Мондагы ярашу, башка төрле хәбәрләрдәге кебек үк, хәбәрлек кушымчалары ярдәмендә тормышка ашырыла. Мәсәлән: *Гүзәлсең син, матурсың син, матурсың, Матурларның матурыннан матурсың* (Г. Тукай). – *Казан ягымын, – ди иде* (Г. Ибраһимов). *Мин гашыйкмын, Шуны белмиләр!* (Х. Туфан).

I–II затларга караган җөмләләрдә хәбәрнең ия белән ярашуы ияне хәбәр янында кабатлап әйтү принцибына корылган. Андый җөмләләрдә ия һәрвакыт I–II зат алмашлыклары белән бирелгәнлектән, хәбәр янында һәрвакыт I–II зат алмашлыклары кабатланып килгән. Менә шул I–II зат алмашлыклары, хәбәр янында һәрвакыт әйтелгәнлектән, үз формаларын югалтып, кушымчага әйләнеп киткәннәр, һәм алар I–II затлардагы хәбәрләрне иягә яраштыру хезмәтен үтиләр. III затка караган җөмләләрдә ия булып теләсә нинди сүз килә, димәк, хәбәр янында да төрле сүз әйтелергә тиеш була. Шуңа күрә хәбәр янында кабатланып әйтелгән ия хәбәрлек кушымчасына әйләнә алмый, сүз килеш сакланып кала[1]. Хәзерге әдәби телдә дә өченче затка

[1] Шуның өчен III затта хәбәрлек кушымчасы башка юл белән – *торыр* фигыленең кыскаруыннан ясалган, ләкин хәзерге телдә ул кушымча да төшеп калган.

караган җөмләләрдә исем хәбәрнең ия белән ярашуы сирәк булса да ия булып килгән сүзнең хәбәр янында кабатланып әйтелүе аша белдерелә. Мәсәлән: *Безнең халык – шигырь вә җыр, бәетләр чыгарырга бик маил халык* (Г. Тукай). *Безнең урам – зур урам* (җыр). *Синең атың – яхшы ат.*

Кайбер очракта, исем хәбәр янында ия үзе түгел, бәлки ия керә торган ыру-төр төшенчәсен белдерүче сүз, бигрәк тә III зат алмашлыгы, кабатланып килергә мөмкин. Мәсәлән: *Дөресен әйткәндә, халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул* (Г. Тукай). *Карлыгач – бик тырыш кыз. Биктимер – бик юмарт карт.*

**§ 106. Хәбәрнең ия белән санда ярашуы.** III затка караган җөмләләрдәге хәбәрләрнең ия белән санда ярашуы тулы ярашу була алмый. Күп вакытта ия күплектә булса да, хәбәр берлектә бирелә. Мәсәлән: *Боз һәм кар эреде, Сулар йөгерде, Еглап елгалар, Яшьләр түгелде* (Г. Тукай). *Китә башлады инде бездән кошлар. Алар бездән ерак җирләрдә кышлар* (Г. Тукай). *Гади генә эштә үтә кышлары һәм җәйләре* (С. Баттал). Тик билгеле бер обстановкада, стиль таләбе буенча, хәбәр күплектә бирелгән иягә санда ярашып килергә мөмкин: *Язлар җитте, карлар эри башладылар, толыплылар толыпларын ташладылар* (Г. Тукай). *Күл өстендә үрдәкләр, казлар йөзеп йөриләр* (И. Гази). *Ике як бакчаның алмагачлары баш очында килеп тоташканнар* (И. Гази). *Кешеләр быелгы язны бик көтеп алдылар* (И. Гази).

Ия берлектә бирелгәндә исә, хәбәр дә гадәттә берлектә килә, ягъни ия белән хәбәр яраша. Ләкин монда да төрле чыгармалар була:

а) әгәр ия сан белдерүче сүзләр белән ачыкланган булса, ул грамматик яктан берлек санда булуга карамастан, хәбәр күплек санда бирелергә мөмкин. Мәсәлән: *Габдулла өйгә керү белән, өч олы кеше аның тирәсендә йөгереп дигәндәй йөрделәр* (Ә. Фәйзи). *Бу ике рисалә... берсе ачкыч вә икенчесе йозак кабиленнәндерләр* (Г. Тукай);

ә) *һәм* теркәгече яки *белән* бәйлеге ярдәмендә бәйләнгән тиңдәш ияләр берлек санда бирелүгә карамастан, хәбәр еш кына күплек санда килә. Мәсәлән: *Мәүлиха түти белән Әпипә берәмтекләп бодай чүплиләр* (Г. Бәширов). *Анда керфекләренә кадәр тузан кунган юка гәүдәле бер кыз белән башына колакчын бүрек кигән яшүсмер кыз бала, җырлый-җырлый, бодай тазарталар* (Г. Бәширов).

**§ 107. Хәбәрнең тиңдәш ияләр белән ярашуы.** Җыю мәгънәсендә, I һәм II зат алмашлыклары тиңдәш ия булып килгәндә, хәбәр – I зат белән; II һәм III зат алмашлыклары тиңдәш ия булып килгәндә, хәбәр – II зат белән; I һәм III зат алмашлыклары ия булып килгәндә, хәбәр I зат белән затта яраша; ияләр берлектә булуга карамастан, хәбәр күплектә килә. Мәсәлән: *Гали һәм мин утынга барабыз; Ул һәм мин узган елда шәһәрдә булдык. Син һәм ул иртәгә шәһәргә барырсыз.*

I һәм II яки II һәм III, яки I һәм III зат алмашлыклары белән бирелгән тиңдәш ияләр бер-берсенә бүлүче теркәгечләре ярдәмендә бәйләнгән булсалар, хәбәр үзенә якын урнашкан ия белән затта һәм санда яраша. Мәсәлән: *Син яки мин барырмын. Я мин, я син барырсың. Я сез, я алар барырлар. Я алар, я сез барырсыз. Я Гали, я син укырсың. Я син, я Гали укыр. Мин яки ул барыр. Гали яки мин барырмын.*

## БЕР СОСТАВЛЫ ҖӨМЛӘЛӘРДӘ БАШ КИСӘКЛӘР

**§ 108. Бер составлы җөмләнең баш кисәге турында гомуми мәгълүмат.** Югарыда әйтелгәнчә, җөмләнең барлык кисәкләре дә бер генә баш кисәк янында оешып бетсә, андый җөмлә бер составлы була. Бер составлы җөмләгә икенче состав өстәп булмый. Әгәр икенче составны контексттан алып өстәп булса, ул бер составлы булмый, ике составлы, ләкин ким җөмлә дип таныла.

Бер составлы җөмләләрне өйрәнү, аның хәтта семантикасын тикшерү дә андагы баш кисәкләрнең бирелешен һәм семантикасын анализлауга кайтып кала һәм, киресенчә, нәкъ менә баш кисәкләрне өйрәнү аркылы бер составлы җөмләнең үзенчәлекләре анализланып бетә.

Бер составлы җөмләләр, баш кисәкнең бирелүенә карап, өч төрле булалар: фигыль җөмлә, исем җөмлә һәм сүз җөмлә. Баш кисәге фигыль һәм процесс белдерүче башка сүзләр белән бирелсә, җөмлә бер составлы **фигыль җөмлә** дип йөртелә. Мондый җөмләләрдә баш кисәк булып килгән сүзләр җөмләнең хәбәрен хәтерләтәләр, ә ия булмый. Шуннан чыгып, аларны и я с е з  җ ө м л ә дигән термин белән

дә атап йөртәләр. Фигыль җөмләләр процессны хәбәр итәләр, ләкин процессны үтәүче билгесез була, я, билгеле булганда да, ул ия белән бирелми. Үтәүченең (процессны башкаручының) билгеле булу-булмавына карап, иясез җөмләләр билгеле үтәүчеле һәм билгесез үтәүчеле дигән төрләргә бүленәләр.

Бер составлы җөмләнең баш кисәге исем яки исемләшкән башка сүзләр белән бирелсә, **исем җөмлә** барлыкка килә. Биредә баш кисәк ияне хәтерләтә, ә хәбәр булмый, шуңа күрә боларны хәбәрсез җөмлә дип атарга була. Ләкин хәбәрсез сүзе термин буларак яраксыз: аның башка мәгънәләре дә бар. Бер составлы исем җөмләләрне, мәгънәләреннән чыгып, атау җөмлә дип исемләү гадәткә кергән.

Фигыль җөмлә (иясез җөмлә) дә, исем җөмлә (атау җөмлә) дә, иярчен кисәкләр кабул итеп, җәенкеләнә алалар. Шуннан чыгып бер составлы җөмләнең бу ике төрен гомуми тел гыйлемендә җәенкеләнә алучы бер составлы җөмлә дип атыйлар (распространяемые однокомпонентные предложения).

Сөйләмдә фикерне раслау яисә инкяр итү өчен, сөйләүченең башка кеше фикеренә мөнәсәбәтен белдерү өчен махсус җөмләләр була. Аларны җөмләнең бер кисәге дип тә санап булмый, алар башка кисәкләрне үзләренә ияртә дә алмыйлар (*әйе, юк, түгел, ярый*). Җөмләнең традицион кисәкләренә туры килеп бетми һәм башка кисәкләрне ияртеп җәенкеләнә алмый торган сүзләрдән торган җөмләләрне сүз җөмләләр дип атау гадәткә кергән. Ләкин сүз җөмләләр бер составлы җөмләләргә шартлы рәвештә генә каратылалар. Аларны ия составы дип тә, хәбәр составы дип тә, иярчен кисәк составы дип тә карап булмый. Димәк, сүз җөмләләр атау һәм иясез җөмләләрдән шактый гына аерылып торалар.

Сүз җөмләләрне рус тел гыйлемендә җәенкеләнә алмый торган бер составлы җөмлә дип тә атыйлар (нераспространяемые однокомпонентные предложения).

Шулай итеп бер составлы җөмләләр күп төрле булалар, аларны схематик рәвештә түбәндәге таблицадан күрергә мөмкин.




## ИЯСЕЗ ҖӨМЛӘ
## (фигыль җөмлә)

### Билгеле үтәүчеле җөмлә

**§ 109. Билгеле үтәүчеле җөмләнең гомуми үзенчәлекләре.** Баш кисәктән аңлашылган процессның үтәүчесе конкрет билгеле булган бер составлы җөмлә билгеле үтәүчеле җөмлә дип атала. Мондый җөмләдә баш кисәктән аңлашылган эшне үтәүче төрле чаралар белән бирелә.

а) Баш кисәкнең формасы белән. Мәсәлән: *Буяучыга да кереп чыгасым бар* (К. Нәҗми).

ә) Юнәлеш яки иялек килешендәге тәмамлык белән. Мәсәлән: *Һаҗәргә киң Идел елгасын көймә белән аша чыгарга туры килде* (Г. Ибраһимов).

б) Ике чара белән берьюлы – тәмамлык һәм баш кисәк формасы белән. Мәсәлән: *Бүген минем бер дә ялгыз каласым килми* (Г. Ибраһимов).

в) Аерым формадагы бер баш кисәкле җөмләләрнең бары сөйләүчегә генә, ягъни беренче затка гына караган булуы белән. Мәсәлән:

*Хәзер аңа чыбык белән сыптырасы иде!..* (И. Гази). *Шундый авыр минутларда аның янында булсаң иде!* (Ә. Фәйзи).

г) Конкрет үтәүче сүз сөрешеннән яки ситуациядән билгеле була. Мәсәлән: *Б а й б и ч ә н е ң жаны әрнүле иде. Мәгәр, кабаттан сүз кузгатып, авыруны борчыйсы килмәде* (Г. Ибраһимов) дигән мисалда соңгы җөмләнең конкрет үтәүчесе алдагы җөмләдә бирелгән (*Байбичә*). Аны алып, бер составлы җөмләләргә куйсак та, ул ия булып килеп үзенә бер үзәк төзи алмый, бәлки тәмамлык булып, иялек килеше кушымчасы аша баш кисәккә буйсына: *Байбичәнең, кабаттан сүз кузгатып, авыруны борчыйсы килмәде*. Икенче мисал: *Аның борчылган күңеле китапка омтылмады. Арылган да* (Г. Әпсәләмов). Алдагы җөмләдә *аның* кисәге белән бирелгән конкрет кеше турында сүз бара. *Арылган да* дигән бер составлы җөмләнең үтәүчесе дә – шул конкрет кеше була. Тагын бер мисал: *М и н ныгырга, чыныгырга тиешмен. Юкса тәҗрибәле көрәшчегә каршы чыгасы бар* дигән мисалдагы соңгы җөмләнең үтәүчесе алдагы җөмләдә бирелгән. Аны бер составлы җөмләнең баш кисәгенә кушымча итеп кертергә мөмкин: *Юкса тәҗрибәле көрәшчегә каршы ч ы г а с ы м бар.*

Татар әдәби телендә билгеле үтәүчеле җөмләнең баш кисәге төрле формаларда бирелә.

**§ 110. Баш кисәге бары инфинитив белән генә бирелгән бер составлы җөмлә (инфинитив җөмлә).** Монда – үтәүче, сирәк кенә булса да, юнәлеш килешендәге тәмамлык белән бирелә. Мәсәлән: *А ң а р тагын адвокат булырга!* (К. Тинчурин). *Әле генә күрсәтмә алып кайттым: иртәгә б е з г ә машина белән урманга барырга.*

Инфинитив җөмлә сөйләүчегә генә, ягъни I затка гына караганда, конкрет үтәүчеле була. Мәсәлән: *Өй кыегында кызыл күзле күгәрченнәр гөрли: ә й, ш у л а р н ы ң б е р с е н т о т а р г а !* (И. Гази). *Әллә күршеләрдән сорап карагамы?* (И. Гази).

Инфинитив җөмләнең конкрет үтәүчесе сүз барышыннан аңлашып торырга мөмкин. Мәсәлән: *Һәр икесе ике кулыннан тоталар да, әйдә, бөтен якты дөнья буенча сөйрәргә!* (Г. Тукай).

Бер составлы инфинитив җөмләләр, билгеле бер интонация белән әйтелгәндә, кайбер очракта сорау алмашлыклары һәм кисәкчәләре белән килеп, күптөрле мәгънәләрне белдерәләр. Менә аларның кайберләре:

а) көчле теләк. Мәсәлән: *Өй кыегында кызыл күзле күгәрченнәр гөрли. Әй, шуларның берсен тотарга!* (И. Гази).

ә) Карар кылу. Мәсәлән: *Үртәшергә булгач, үртәшергә! Нәфисә бу рольне кыш көне генә уйнавын юри әйтми калдырды* (Г. Бәширов). *Әллә ышна җирен урыргамы, әллә сабыр итеп торыргамы? – Әлбәттә урырга! – диде Якуб* (И. Гази). *Эшләр яхшыргач, моторлы көймә – су автомобиле нигә алмаска!* (М. Максуд).

б) Аптырау (туры мәгънәсендә яки ирония катыш). Мәсәлән: *Алар белән ничек эшләргә? Әллә ышна җирен урыргамы? Әллә сабыр итеп торыргамы?* (И. Гази).

в) Боеру, кушу, чакыру. Мәсәлән: *Ычкындырмаска, түзәргә, түзәргә!* (Р. Вәлиев).

**§ 111. Баш кисәге инфинитив һәм төрле ярдәмлек сүзләр белән бирелгән бер составлы җөмлә (инфинитив җөмлә).** Монда үтәүче күбрәк юнәлеш килешендәге тәмамлык белән бирелә, яки ул сүз сөрешеннән аңлашылып тора. Мәсәлән: *Шулай да бер тапкыр аңа Малик белән бик каты бәрелешергә туры килде* (И. Гази). *Мин сиңа яхшылык белән әйтәм. Инде тыңламыйсың икән, ул чагында, бигайбә, кода булып түгел, председатель булып сөйләшергә туры килер* (Г. Бәширов).

Бер составлы җөмләнең баш кисәге булып, инфинитив түбәндәге ярдәмлек сүзләр белән килә, һәм ул сүзләр инфинитив җөмләнең мәгънәсенә үзенчәлекле төсмер бирәләр.

1. Инфинитив белән *кирәк* сүзе баш кисәк булып килә һәм тиешлекне, кушуны, үтенүне, карар итүне белдерә. Мәсәлән: *Сиңа укыштыргаларга кирәк булыр* (Ә. Фәйзи). *Дошманның каршылыгын хәзер үк сындырырга кирәк* (Г. Бәширов). *Бу ятимлектән, һичшиксез, котылырга кирәк* (Ә. Еники). *Минә аны кода белән уйлашырга кирәк* (К. Тинчурин).

Г. Тукай әсәрендә *кирәк* сүзе урынына *тиеш* сүзен куллану да очрый. Мәсәлән: *Сиңа, кая булса да китеп, кәсеп эзләргә тиеш була* (Г. Тукай). *Кечкенә генә дошманга да зур дошманга хәзерләнгән кебек хәзерләнергә тиеш* (Г. Тукай).

Хәзерге әдәби телдә *тиеш* сүзе инфинитив белән бергә ике составлы җөмләнең хәбәре булып килә. Мәсәлән: *Син барырга тиеш.*

2. *Ярый, мөмкин, була* сүзләре инфинитив белән бергә килеп, бер составлы җөмләнең баш кисәге ясала: мондый җөмләдә мөмкинлек

яки мөмкин түгеллек мәгънәсе белдерелә. Мәсәлән: *Инде өйгә кайтырга мөмкин.*

*Бул* фигыле, III зат боерык формасын алып, юнәлеш килешендәге тәмамлык белән бирелгән үтәүченең гадәтенә кергән процессны белдерә. Мәсәлән: *Миңа ашарга булсын! (ди Гариф). Аңа көйләргә булсын!* (Г. Ибраһимов).

3. Инфинитив янында *иде* ярдәмлек фигыле килә. Бу юл белән ясалган бер составлы җөмлә, интонациянең төрле булуына карап, я теләкне, я үкенүне белдерә. Мәсәлән: *Күрергә иде үзен! Сиңа тавышланмаска иде! Безгә кичә үк барырга иде! Их, шул картинаны карарга иде!*

4. Инфинитив белән *туры килү*, *насыйп булу* яки *язу* сүзләре килеп, бер составлы җөмлә төзиләр һәм ихтыярдан тыш үтәлгән процессны белдерәләр. Мәсәлән: *Кайчагында белгәнеңне дә онытып торырга туры килә* (К. Нәҗми). *Ләкин Галкәй Хаҗиның бабасына барыбер тыныч яшәргә насыйп булмый* (К. Нәҗми). *Безнең өчен кайгырырга сиңа туры килмәс* (К. Тинчурин). *Аңа эш талымлап торырга туры килмәде* (И. Гази). *Я, мәгъзум, исән-сау йөреп кайт инде, шатлык белән күрешергә насыйп булсын!* (Г. Ибраһимов). *Безгә моннан китәргә язмагандыр инде!* (Ә. Фәйзи).

5. *Кал* фигыле, инфинитив белән бергә, үтәүченең ирегеннән тыш башкарылырга тиешле процессны белдерә. Мәсәлән: *Миңа җырларга гына калды инде.* Тиешле интонация белән әйткәндә, шушы ук конструкция иронияне дә белдерә.

6. *Юк* сүзе *әйтү* сүзенең инфинитивы белән килгәли. Бу юл белән ясалган бер составлы җөмлә нәрсәнең булса да гадәттән тыш булуын аңлата. Мәсәлән: *Юлларның начарлыгын әйтергә дә юк!* (Г. Ибраһимов). *Сафа байның гаиләсен әйтергә дә юк* (Г. Ибраһимов).

**§ 112. Баш кисәге сыйфат фигыль булган бер составлы җөмләләр.** Бер составлы җөмләләрдә баш кисәк булып *-сы*/*-се* яки *-ган*/*-гән*, *-кан*/*-кән* формасындагы сыйфат фигыльләр дә йөрергә мөмкин. Алар янында, гадәттә, төрле ярдәмлек сүзләр килә торган була.

Бу юл белән ясалган бер составлы җөмләдә үтәүче я иялек яки юнәлеш килешендәге тәмамлык белән, я баш кисәктәге тартым кушымчасы белән, я икесе белән дә берьюлы бирелә, яисә, җөмлә ким булганда, ул сүз сөрешеннән аңлашыла.

Баш кисәк булып килгән сыйфат фигыль янында, төрле мәгънәләрне белдереп, түбәндәге ярдәмлек сүзләр йөри:

1. *Иде* ярдәмлек фигыле теләкне белдерә. Мәсәлән: *Чынлап та, һич тә булмаса, күршеләрдән калышасы түгел иде!* (Ф. Хөсни). *Кырларыңда, илем, юлларыңда гизәсе дә гизәсе иде; җырга салып, җырдай тормышыңны үзеңә бүләк итәсе иде!* (Х. Туфан).

Мондый җөмләләрдә сыйфат фигыльне шарт фигыль белән дә алмаштырырга мөмкин. Ул да I затка караган җөмләләрдә, *иде* белән бергә, теләкне белдерә. Мәсәлән: *Их, туйганчы бер йокласаң иде!* (Г. Ибраһимов).

Мондый җөмләдә үтәүче юнәлеш килешендә бирелергә мөмкин. Үтәүче баш килештә бирелсә, җөмлә ике составлы була, һәм ул теләкне белдерми, бәлки киләчәктә буласы процессны гына хәбәр итә. Мәсәлән: *Ул безгә киләсе иде.*

2. Баш кисәк *-сы/-се* формасындагы фигыль һәм II зат берлек сандагы *кил* фигыле белән бирелә һәм үтәүченең теләген белдерә. Мәсәлән: *Күрәсем бик килде аны!* (Г. Ибраһимов). *Бүген минем гел чабасым, чаптырасым гына килә* (Г. Ибраһимов). *Акташның киң яланнарында, урманнарында йөрисе, элекке кебек чиләк-чиләк җиләкләр җыясы килә* (Г. Ибраһимов).

3. *Калган* (*калды*) фигыле үкенүне белдерүче бер составлы җөмләне ясауда катнаша. Мәсәлән: *Кичә докладка барасым калган! Минем үземә барасы калды.*

4. Баш кисәге *-сы/-се* формасын алган сыйфат фигыльгә *бар, юк, түгел, бул* сүзләренең берсе кушылып ясалган бер составлы җөмлә алда эшләнергә тиеш булган процессны белдерә (тиешлек мәгънәсен бирә). Мәсәлән: *Дошманны куасы бар* (Г. Бәширов). *Иртәгә эшкә чыгасы түгел. Төштән соң бодайны триерлап бетерәсе булыр* (Г. Бәширов). *Җитәр җире аның ерак әле, үтәсе бар озын елларны* (Х. Туфан). *Аларның ул яхшылыгын Якубның гомерендә дә онытасы юк* (И. Гази).

5. *-ган/-гән* формасындагы сыйфат фигыль, *бар* яки *юк* сүзләре белән килеп тә, бер составлы җөмләнең баш кисәген барлыкка китерә ала. Мондый җөмләдә процессның үтәлү вакыты билгеле бер моментка текәп әйтелми, бәлки процессның гомумән сөйләү моментына чаклы үтәлүе хәбәр ителә. Мәсәлән: *Аның андый төшләрне күп күргә-*

*не бар* (Г. Тукай). *Минем бу әсәрне укыганым юк. Синең ише кешеләрне күргәнем бар* (К. Тинчурин).

**Искәрмә:** Борынгы формаларны кулланып язган язучыларның әсәрләрендә -*мыш*/-*меш* формасындагы сыйфат фигыльнең бер составлы җөмләдә баш кисәк булып килүен очратырга мөмкин. Мондый җөмләдә үтәүчене тартым кушымчасы белдерә; җөмлә үзе гомумән үткән заманда булган эшне яки хәлне хәбәр итә. Мәсәлән: *Алмышым гомеремдә унбишләп хатын. Һәм Мәскәүдән дә маллар алмышым, сумына туксан тиеннән чәлмешем...* (Г. Тукай). Хәзер инде бу формалар кулланылмый.

**§ 113. Баш кисәге исем фигыль булган бер составлы җөмләләр.** Бер составлы җөмләдә баш кисәк булып -*у*/-*ү* һәм сирәгрәк -*ыш*/-*еш*/-*ш* формасындагы исем фигыльләр килә. Мондый бер составлы җөмләләрдә үтәүче, кагыйдә буларак, тартым кушымчасы аша бирелә, шулай ук иялек килешендәге тәмамлык белән дә күрсәтелгәли.

Баш кисәк булып исем фигыльләр үзләре генә яки *иде* ярдәмлек фигыле белән килә һәм дәвам итеп тора торган процессны белдерә. Мәсәлән: *Бодай тарттырырга килеш иде* (Г. Бәширов). *Картның диңгезгә беренче керүе икән!* (Г. Ибраһимов).

-*у*/-*ү* һәм -*ыш*/-*ш* формасындагы исем фигыльләр, чыгыш килеше формасын алып, *кит* фигыле белән бергә, бик тиз башланып, гадәттән тыш тизлек белән дәвам итә торган процессны белдерә. Мәсәлән: *Котырынып биештән китте* (Г. Бәширов). Ләкин бу формадагы җөмлә телдә бик сирәк кулланыла.

-*у*/-*ү* формасындагы исем фигыль *бар* сүзе белән дә бер составлы җөмләнең баш кисәге булып килә ала. Бу юл белән ясалган бер составлы җөмлә үтәлергә мөмкин булган процессны һәм сөйләүченең шуны искәртеп куюын белдерә. Мәсәлән: *Мин сине, малай актыгы! – дип йодрык селкүе бар* (И. Гази).

**§ 114. Баш кисәге төшем яки кайтым юнәлешендәге фигыль булган бер составлы җөмләләр.** Мондый җөмләләрдә баш кисәк булып төшем яки кайтым юнәлешендәге күчемсез фигыльнең III заты килә. Баш кисәктән аңлашылган процессны үтәүче, башкаручы гадәттә сөйләүче үзе (ягъни I зат) була. Мәсәлән: *Шәһәрдә бик озак йөрелде, арылды. Бер яткач, бик озак йокланган* (И. Гази). *Җитмәсә, бу аягы тагын! – Уңайсызрак төшелде, ахры* (И. Гази). *Яшьлек үтте, инде картаелды. Яшим хәзер читтә, ышыкта* (М. Җәлил). Ләкин

контекстттан аңлашылып торганда, баш кисәк белдергән процессны үтәүченең билгеле өченче зат булуы да мөмкин. Мәсәлән: *Ул бүген клубка бөтенләй бармаска булды. Арылган да*.

Шулай итеп баш кисәге төшем яки кайтым юнәлешендәге күчемсез фигыль булган бер составлы җөмләләрдә гадәттә үтәүче билгеле була. Ләкин процессны сөйләүче үзе яки башка бер конкрет кеше башкарса да, ул ихтыярдан тыш, ниндидер билгесез бер көчнең кушуы буенча башкарган булып аңлашыла. Шул үзенчәлегеннән чыгып, аны үтәүчесез җөмләләргә дә каратырга мөмкин. Шуның белән бергә бу төр бер составлы җөмләдә үтәүче гомумиләштерелергә дә мөмкин. Мәсәлән: *Актаныш авылына хәзер туры юлдан барыла?*

Төрле мәгънә белдерүгә сәләтле булуларына карамастан, үтәүчеләре күбрәк очракта билгеле булудан чыгып, баш кисәге төшем яки кайтым юнәлешендәге күчемсез фигыльләр булган бер составлы җөмләләрне билгеле үтәүчеле җөмләләргә кертү дөресрәк булыр. Фигыль юнәлешләрен тикшерүчеләр дә шундый ук караштa торалар [Зиннатуллина, 1969, с. 160].

## Билгесез үтәүчеле җөмлә

**§ 115. Билгесез үтәүчеле, гомуми үтәүчеле, үтәүчесез җөмләләр турында.** Баш кисәктән аңлашылган процессның үтәүчесе конкрет билгеле булмаса, бер составлы фигыль җөмлә билгесез үтәүчеле җөмлә дип атала. Мәсәлән: *Чәчмиләр, урмыйлар бу җирдә* (Ә. Фәйзи). *Ни чәчсәң, шуны урырсың* (мәкаль). *Бүген урамда яланөс йөрерлек түгел. Салкынайтып җибәрде.*

Рус телендәге неопределенно-личное, обобщенно-личное, безличное дигән җөмләләргә туры китереп, татар телендә дә билгесез үтәүчеле, гомуми үтәүчеле һәм үтәүчесез җөмләләрне аерып карарга мөмкин. Элегрәк ул шулай эшләнә иде дә [Зәкиев, 1966, б. 96–100). Дөресен әйткәндә, иясез җөмләләрнең билгеле үтәүчеле төрләреннән башкаларын андый өч төргә бүлү рус телендә дә, татар телендә дә бик якынча гына эшләнә һәм аның синтаксик төзелешне өйрәнү өчен әһәмияте дә артык зур түгел. Менә шуларны исәпкә алып, иясез җөмләләр, үтәүченең билгеле булу-булмавыннан чыгып, ике төргә – билгеле үтәүчеле һәм билгесез үтәүчеле дигән төрләргә генә бүленәләр.

Бу бүленешнең дә билгеле дәрәҗәдә якынча бүленеш булуын истән чыгармаска кирәк.

Билгесез үтәүчеле җөмләләрне конкрет анализлаганда, алардагы үтәүченең ничегрәк булуын (үтәүче гомумиләштерелгәнме, әллә бөтенләй булмаган кебек аңлашыламы һ.б.) конкрет мисалдан чыгып күзәтергә мөмкин.

**§ 116. Билгесез үтәүчеле җөмләнең баш кисәкләре.** Мондый бер составлы җөмләләрдә баш кисәк төрле формаларны алган фигыльләр белән бирелә.

1. III зат хикәя (кайчакта – шарт) фигыльнең күплеге белән. Мәсәлән: *Казнадан бирәләр икән, анда икенче мәсьәлә* (Г. Бәширов). *Фәхрине яраталар иде. Үз итеп, туган итеп, авыр йөккә төптән җигелеп өстерәүче итеп яраталар иде* (Г. Ибраһимов). *Беренче тапкыр уң яктан искәрмәстән китереп сукканнар... Икенче кат менә алгы яктан шул ук кендек белән бәргәннәр* (Г. Ибраһимов). *Бүген кич калага барып җитәргә, ди. Аннан иртәгә таңда ук каядыр еракка озатачаклар, ди* (Г. Ибраһимов). *Капкадан йөрергә мөмкин түгел, я икенче җирдән юл салалар, я аның башын алып ташлыйлар* (Г. Ибраһимов). *Чөнки җир шундый әйбәт: кайдан гына бирсәләр дә, үпкәләрлек түгел!* (И. Гази). *Бу эшегезне күрсәләр, рәхмәт әйтмәсләр* (Ә. Фәйзи).

**Искәрмә:** Бу төр җөмләләрдә үтәүче сөйләүче белән туры килергә мөмкин, ягъни сөйләүче үзе үтәгән процессны да III зат исеменнән хәбәр иткәли. Мәсәлән: *Күп телеңә салынып торма, карт дурман! Әйтәләр сиңа улың патша дошманы дип... тыңларга кирәк!* (К. Нәҗми). Ләкин мондый җөмләләрнең үтәүчесе күбрәк билгесез була, шуңа күрә алар билгесез үтәүчеле төргә каратылалар.

2. II зат берлек сандагы хикәя яки шарт фигыль белән: *Урамга да чыга алмыйсың, муеннан кар* (Г. Тукай). *Әйләнеп карарга да өлгермисең, картлык җилкәңә менеп тә атлана* (Г. Ибраһимов). *Башыңны югалтырсың монда!* (И. Гази). *Ни чәчсәң, шуны урырсың* (мәкаль). *Аны ничек ачуланасың!* (Ә. Фәйзи). *Эшеңне җиренә җиткереп эшләсәң, йөзең ак була* (Д. Аппакова).

3. I зат боерык фигыльнең күплеге, II зат боерык фигыльнең берлеге белән. Мәсәлән: *Кайда гына барма, анда шатлык, анда җыр! Бу кортлар бик усал булдылар, умарта янына гына бар, хәзер чагып алалар.*

4. Баш кисәге урын-вакыт килешендәге үткән заман сыйфат фигыль белән белдерелә. Мондый бер составлы җөмлә иярчен вакыт яки шарт җөмлә булып килә. Мәсәлән: *Д ө р е с е н  г е н ә  ә й т к ә н д ә, ул бит иген үстерү эшенә берниндидә яңалык кертмәде* (М. Әмир).

5. *-ып/-п*, *-мыйча/-мичә* һәм *-ма+-гач/-мә+-гәч* формаларындагы хәл фигыльләр, *бул* яки *ярый* ярдәмлек сүзләре белән бергә килеп, баш кисәк барлыкка китерәләр. Бу юл белән ясалган бер составлы җөмләнең бер төрләре – мөмкинлек, мөмкин түгеллекне, икенче төрлеләре процессны үтәмәскә яки үтәргә ярамауны белдерәләр. Мәсәлән: *Киң сахраларда салынган печән кибәннәрен табып булмый* (Г. Ибраһимов). *Дөньяны дер селкетеп йөрергә иде Биктаһирга... Ләкин бик дер селкетеп булмый шул инде* (И. Гази). *Мондый вакытта балаларның өстен карамыйча ярамый иде* (Г. Бәширов). *Җитәр иде инде! Үлек өстендә кычкырышмагач та ярар иде! – диде* (Г. Ибраһимов).

6. *-ырлык/-ерлек/-рлык/-рлек* формасы бер составлы җөмләнең баш кисәге булып килә ала һәм мөмкинлек-мөмкин түгеллекне белдерә. Мондый җөмләдә баш кисәктән аңлашылган процессны үтәүче теләсә кем булырга мөмкин. Шуңа күрә бу юл белән ясалган җөмлә билгесез үтәүчеле җөмләгә карый. Мәсәлән: *Устьеда халык күплектән, ары-бире үтеп йөрерлек түгел иде* (Ш. Мөхәммәдов). *Бөтенләй караңгы йорт эчендә берни дә аерырлык түгел* (И. Гази). *Бүген кояш шулкадәр эретә, күпер башындагы җыелган судан үтәрлек тә түгел* (К. Тинчурин). *Бүген урамда яланөс йөрерлек.*

7. *-малы/-мәле* формасындагы исем фигыль һәм хәзерге заман сыйфат фигыльнең кушма төре бер составлы җөмләнең баш кисәге булып килә һәм мөмкинлек яки мөмкин түгеллек мәгънәсен белдерә. Мәсәлән: *Күпме азапгануларның исәбенә дә чыга торган түгел* (Г. Бәширов). *Анда халык җыелган, янына да бармалы түгел.*

8. Табигать күренешләрен һәм эчке сиземләүләрне белдерүче фигыльләр белән. Мәсәлән: *Яктыра башлады. Салкынайтты. Салкынайтып җибәрде. Туңдыра. Калтырата башлады.* Табигать күренешләрен һәм төрле сиземләүләрне белдерә торган фигыльләрнең тарихи яктан ия белән хәбәр кушылуыннан ясалганнары да бер составлы җөмләнең баш кисәге булып йөриләр: *Тәнгә җ ы л ы  й ө г е р д е* (Р. Вәлиев); *таң ата, күңел болгана, көзән җыера, ак төшә, баш җитә, сару кайный* һ.б. Хәзер инде болар борынгы кешеләрнең уй-

лау, фикер йөртү дәрәҗәләрен генә күрсәтәләр, чөнки хәзерге телдә андый фигыльләрдә үтәүче һәм процесс аерым-аерым күз алдына килми. Кешенең абстракт уйлау сәләте үсү белән бергә, ул тезмәләр хәзер идиоматик тезмәгә әйләнгәннәр һәм бары процессны гына атыйлар. Мисаллар: *Эчне кату алды. Күзгә ак төште. Аякны к ө з ә н җ ы е р - д ы . Әгәр кысрыклый-нитә калсалар, бөтен отряд белән монда кыяк! ...Бездән җ и л л ә р и с ә р!* (А. Шамов). *Малайларның акрынлавына а ч у ы м к и л д е* (Г. Ибраһимов). *Анысына Мәүлиха түтинең б а ш ы д а җ и т ә т о р г а н т ү г е л* (Г. Бәширов).

## АТАУ ҖӨМЛӘЛӘР

**§ 117. Атау җөмләләрнең төп үзенчәлекләре.** Әйберләрнең, билгеләрнең яки төрле күренешләрнең исемнәрен атау юлы белән аларның булу-булмауларын хәбәр итә торган җөмләләр атау җөмлә (бер составлы исем җөмлә) дип аталалар. Алда өйрәнелгән бер составлы җөмләләрдән аермалы буларак, атау җөмләләрдә процесс бирелми, шуңа күрә монда үтәүче турында да сөйләп торырга туры килми. Атау җөмләнең баш кисәге исемнәр, алмашлыклар, саннар, сыйфатлар һәм исем урынындагы башка сүзләр белән бирелә. Атау җөмләләр күбрәк хәзерге заманда һәм, *иде* ярдәмлек фигылен алып, үткән заманда кулланылалар.

Атау җөмләләр текст эчендә мәгънәне тыгызрак итеп бирүдә зур роль уйныйлар һәм алар текст эчендә генә мәгънәви яктан ачылалар да.

1. Атау җөмләләр төрле табигать күренешләрен тасвирлыйлар. Мәсәлән: *Кыш. Буран. Салкын һава. Яфрак кадәрле кар төшә* (Г. Тукай). *Төн. Караңгы. Буран. Өермә. Кит, «Прометей», китче, кит әле; язасы бик килә бит әле!* (Х. Туфан).

*Көзге у р м а н .*
*Моңсу т ы н л ы к* (Н. Сафина).

*О, иртәнге сихри с ә г а т ь,*
*җирнең моңга т а л у ы !* (З. Мансуров).

Атау җөмләләрне бу мәгънәдә халык шагыйре Г. Тукай үз әсәрләрендә бик оста файдаланган, мәсәлән: «Җир йокысы»ннан берничә юл:

*Язның айлары,*
*Апрель, майлары.*
*Бик матур сызылып*
*Аткан таңнары.*

*Урман шаулавы,*
*Кошлар сайравы,*
*Күкләр күкрәве,*
*Яңгыр аннары.*

Мондый җөмләләр, үткән заманны тасвирлаганда, *иде* ярдәмлек фигыле белән киләләр. Мәсәлән: *Диңгезгә кергәнемнең икенче көне иде* (Г. Ибраһимов). *Җәй башлары иде* (М. Гафури). *Анда ачык вә якты кышкы төн иде* (Г. Ибраһимов). *Җилле, давыллы көннәрнең берсе иде* (Г. Ибраһимов). *Җәйнең аяз, матур кичләреннән берсе иде* (Г. Ибраһимов).

2. Атау җөмләләр төрле күренешләрне, кешенең килеш-килбәтен тасвирлауда киң кулланылалар. Бу үзенчәлеге аның сәхнә әсәрләрендә күбрәк күренә. Мәсәлән: *Иске мәдрәсәнең бер бүлмәсе. Акшарлары кубып, пычранып беткән диварлар. Уртада ишек. Ике якта тәрәзәләр... Ике тәрәзә уртасында һәм түрдә – ике башта икешәр-өчәр кешелек урыннар* (К. Тинчурин). *Өстендә оборкалы күлмәк, башында алсу сәрпинка яулык, муенында тәңкәләр, гәрәбәләр, кулында беләзекләр...* (Г. Ибраһимов). *Борынгы шәһәр. Биек-биек манаралар, тимер капкалар, имән ишекләр* (Ю. Сафиуллин).

3. Атау җөмләләр кайда булса да (яки кайчан булса да) нинди булса да бер хәлнең, билгенең яшәвен раслыйлар яки инкяр итәләр. Мәсәлән: *Миңа монда торырга оят. Инде бик вакыт, бабай* (Г. Гобәй). *Бүген бездә шатлык! Хәзер бик күңелле чак. Монда миңа бик салкын булып китте* (А. Шамов). *Безнең Таҗига бик күңелсез иде* (Г. Гобәй). *Тайга урманнарында бик куркыныч. Хәзер соң инде, караңгы да.*

4. Атау җөмләләр төрле хәлләрне кыска гына итеп санап чыгарга кирәк булганда еш кулланылалар. Мәсәлән: *Кичә. Шау-шу. Кыллы оркестр. Биюләр. Җырлар* (Һ. Такташ). *Фәхри унҗиде яшьтә Фон-Келлер дигән алпавытка ялчы булып керә. Анда дүрт ел. Аннан солдат. Ел ярым үтми, герман сугышы. Фронт. Карпаттан кичкәндә, Австриядә кала. Аннан дүрт кеше качалар. Икәве эләгә. Бу бер мари егете белән, яраланып, имгәнеп, Россиягә кайтып егыла. Дүрт ай Петербургта лазарет. Шуннан февраль революциясе. Аннан Октябрь. Аннан кызыл фронтлар. Аннан партия-совет эшләре* (Г. Ибраһимов).

Бер үк күренешнең кабатлануын белдергәндә атау җөмлә *тагын* сүзен алган була. Мәсәлән: *Тагын шул эчпошыргыч, озын, ямьсез, мәгънәсез көзге көннәр!* (Г. Ибраһимов). *Тагы имешләр, хәбәрләр, тагы дулкыннар, тагы йокысыз төннәр, өмет-газап эчендә үткәрелә торган авыр минутлар!* (Г. Ибраһимов).

5. Нәрсәгә булса да төбәп күрсәткәндә, атау җөмләләр *менә*, *әнә* кебек сүзләрне үз эчләренә алалар. Мәсәлән: *Анда киң урамга ике яклап тезелгән кечкенә авыл... Менә салам түбәле өйләр...* (Г. Ибраһимов). *Мәхмүдә түти, менә Гөлшатка газета, журналлар* (К. Тинчурин).

6. Зур тойгы белән әйтелеп, төрле модаль мәгънәләрне белдерә торган сүзләр дә атау җөмләләргә керәләр. Мәсәлән: *Скважинаны бораулап бетергәннән соң, мастер: «Нефть! Нефть» – дип контрага килеп керде. Алты! Алты! Алты гектар урылган. Тәрәзәдән карап торган апа: «Ул! Ул!» – дип йөгереп чыгып китте. Хат ташучы: «Сезгә хат бар», – дип килеп керде. Галимә аптырап: «Хат!» – диде. Ул хат алудан өмет өзгән иде инде. Ефимка, штабтан йөгереп килеп, капкага кычкырды: Тревога! Бөтенегез дә җыелу урынына!* (А. Шамов). *Янгын, янгын, янгын! Караул!* (К. Тинчурин). *И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!* (Г. Тукай).

Хәтер калган тон белән яки бик шатлыклы тон белән әйтелгән исемнәр яки көчле тойгы белән әйтелгән мөрәҗәгать, эндәш сүзләр дә атау җөмлә дип каралалар. Мәсәлән: *Нәфисә! (синең шуны эшләргә ничек кулың бара!); Гөлсем апа!? (Сине монда нинди җилләр ташлады?!).*

7. Ниндидер бер фикерне тыңлаучыга ачыграк җиткерү өчен, ул фикернең субъектын, темасын алдан атап кую гадәте бар. Мондый атау җөмләләр ниндидер предметның, күренешнең, проблеманың булуын, яшәвен гомумән хәбәр итәләр, соңыннан тезелеп киткән җөмләләр шул фикер субъекты (темасы) турында тагын да җентеклерәк мәгълүмат бирәләр. Бу төр атау җөмләләрне Ф. Сафиуллина күзаллауны белдерә торган җөмләләр дип тикшерә [Сафиуллина, 1974]. Мәсәлән: *Их, минем авылым!.. Шунда бит минем яшьлегемнең иң матур еллары үтте, шунда күңел бөреләнде. Кайткан чакларда мин аның матурлыгына һаман сокланам!* («Ватаным Татарстан»). *Әдәбиятның үткәне... Тәнкыйть ярдәмендә мин аның зурлыгын тоярга телим!* (С. Хәким). *Мохит вә табигать! Болар*

*һәркемнең хәятендә иң зур рольләрне үзләренә алалар* (Г. Ибраһимов). *К и л ә ч ә к ! . . Сугыш китергән иң авыр, иң газаплы бер заманда кешеләрнең бердәнбер юанычы, өмете, татлы хыялы иде ул!* (Ә. Еники). *У к а з . . . У к а з . . . У к а з . . . У к а з ! ! Беләмсең, аның өчен бу ни тора иде? Бу – аның өчен һәрнәрсә, һәрнәрсә, һәрнәрсә иде!* (Г. Ибраһимов). *М ә р ь я м . Менә кем кирәк, менә кемне юксына икән ул!* (Ә. Еники). *Т а м ч ы л а р, т а м ч ы л а р ! Кайсысы иң бәхетле дә, кайсысы җирдә яз ясауда иң мөһиме соң аның!?* (Р. Төхфәтуллин).

## СҮЗ ҖӨМЛӘЛӘР

**§ 118. Сүз җөмләләрнең төп үзенчәлекләре.** Башка сүзләрне ияртеп җәенкеләнә алмый торган сүзләр белән бирелгән җөмләләр сүз җөмләләр дип аталалар. Сүз җөмләләрне җөмләнең аерым бер кисәгенә тиңләп булмый, ягъни аны ия, хәбәр яки кайсы да булса бер иярчен кисәк дип атау мөмкин түгел. Сүз җөмләләр бары алда әйтелгән яки уйланган фикерне раслыйлар, я инкяр итәләр, алда әйтелгән фикер белән кушылуны-кушылмауны яки, гомумән, әйтелгән фикергә тыңлаучының бәясен һәм төрле тойгыларны белдерәләр. Диалогларда кулланыла торган бер генә сүзле җөмләләр, әгәр дә аларны җөмлә кисәге дип санау яки җәенкеләндерү мөмкинлеге булса, сүз җөмләләргә кермиләр.

Сүз җөмләләрне төзүче сүзләр телдә бик чикле. Алар – *әйе, шулай, әә, дөрес, ярар, яхшы, юк, түгел, шөбһәсез, нәкъ үзе, әлбәттә, табигый* сүзләре, шулай ук ымлыклар һәм төрле аваз ияртемнәре.

Төрле бәяләү сүзләреннән торган сүз җөмләләргә мисаллар: *Уңае килгәндә, безгә кереп чыккала. – Ә л б ә т т ә* (А. Шамов). *– Тынычрак чакларыңда йорт турында уйларга онытма. – Я р а р ! . – Әллә сез архитектура бүлеген тәмамладыгызмы? – Ю к . Төзелеш бүлеген* (Р. Вәлиев). *Ә ни өчен ул шулай? Бу турыда уйлап караганы бармы соң аның? Ю к б и т, ю к !* (Р. Төхфәтуллин). *Ә һ ә ! Эләктеңме, иблис токымы!* (Г. Ибраһимов). *Ул укытучымы? – Т ү г е л ;* С ә р б и җ а м а л . *Бәдбәхет! Дәҗҗал! Чык моннан бар! Вон!* (К. Тинчурин).

Ымлык һәм ымлык ролендәге сүзләрдән торган сүз җөмләләргә мисаллар: *Ул тәрәзә канатларын ачты. Ух! Иркен бушлык!* (Р. Төхфәтуллин). *Аһ! Бу нинди аерылу? Гомеремдә бер тапкыр күрәм!*

(Г. Тукай). Гыймай *(команда бирә). Атлар. Шунда кал! Гаскәр, алга! Һү-лә-лә-лә! Ура! Һәйт, вайт!* (Н.Исәнбәт). *Абау! Бу ни дигән сүз?* (Ю. Сафиуллин).

Төрле аваз ияртемнәреннән торган сүз җөмләләргә мисаллар: *Тфү, әйдә алай булса шобага салабыз!* (К. Нәҗми). *Хе-хе-хе! Шаяртасың, иптәш комиссар, хе-хе-хе!* (Г. Бәширов). *Кәҗә әйтә: «Микикки! Микики!»* (Г. Тукай). Б а р ы с ы . *Тс-с-с! Профессор!* (К. Тинчурин). *Чәбә! Тсс... Чәбә! – дип әйтәм түгелме мин сезгә... Тамакларыгызга таш кадалгыры!* (К. Нәҗми). *Пес, пес, пес!.. Пес, пес, пес! Песие тагын юк, ахры* (М. Фәйзи). *Нәгъләт! Нәгъләт! Сыер булса «һәш» дияр идең, сарык булса, «Төррә!» дип, эт булса, «Чәбә!» дип, кәҗә булса, «кәҗә ристан» дип кычкырыр идең!* (М. Әмир).

## ИЯРЧЕН КИСӘКЛӘР

**§ 119. Гомуми мәгълүмат.** Төгәлләүле һәм аныклаулы мөнәсәбәткә кергән сүзләрнең ияручесе иярчен кисәк дип йөртелә. Иярчен кисәк җөмләне һәрвакыт җәенке итеп формалаштыра. Ул ике составлы җөмләләрдә дә, бер составлы җөмләләрдә дә була.

Татар телендә иярчен кисәкләрне өйрәнү теге яки бу күләмдә XIX йөзнең беренче яртысыннан башлана. М. Иванов «Татарская грамматика» (Казан, 1842) дигән хезмәтендә иярчен кисәкләрне тәмамлык һәм аергыч дигән төрләргә бүлә. А. Казимбәк исә «Общая грамматика турецко-татарского языка» (1846) хезмәтендә иярчен кисәк төрләрен аерым терминнар белән атамый, бәлки аларны, ияртүче кисәккә бәйләнү юлларыннан чыгып, ике зур төркемгә бүлү белән чикләнә: ияртүче кисәккә янәшәлек юлы белән бәйләнгән кисәкләр (сочетание слов без управления) һәм ияртүчегә башкару юлы белән бәйләнгән кисәкләр (сочетание слов при управлении). XIX йөзнең икенче яртысында һәм XX йөзнең 20 нче елларына кадәр рус теле грамматикалары үрнәгендә язылган хезмәтләрдә иярчен кисәкләрне ике төркемгә туплап өйрәнү дәвам итә. Мәсәлән, К. Насыйри һәм А.Троянский, ияртүче кисәкнең мәгънәсен ачыклау характерыннан чыгып, иярчен кисәкләрне икегә: ачыклаучы кисәкләргә (определительное слово) һәм төгәлләүче, тәмамлаучы кисәкләргә (дополнительное слово) бүлеп өйрәнәләр. Бу караш Җ. Вәлидинең

«Татар теленең грамматикасы» (1919) китабында тагын да үстерелә. Җ. Вәлиди иң элек, сүзтезмәләрне өйрәнү тәртибендә, аергычларны тикшерә, аннан соң җөмлә эчендә тәмамлыкларга туктала һәм аларны төшем, күчем, юнәлеш, юлдаш, урын, вакыт, сәбәп, максат һәм рәвеш дигән төрләргә бүлә.

Г. Ибраһимов исә [Татар нәхүе, 1911] иярчен кисәкләрне икегә бүлеп тормый, турыдан-туры сигезгә бүлә: вакыт, урын, рәвеш, сәбәп, тәмамлык, аергыч, эндәш, кереш сүз.

Проф. Г. Алпаров [Шәкли нигездә татар грамматикасы, 1926] иярчен кисәкләрне ияртүче кисәкнең кайсы сүз төркеме булуыннан чыгып бүлә. Алпаровча, фигыльгә һәм ярдәмлеккә ияргән иярченнәр – тәмамлыклар, исемгә бәйләнгәннәре – аергычлар, сыйфатка бәйләнгәннәре ачыклаулар булалар.

Соңга таба рус грамматикалары тәэсирендә иярчен кисәкләрне өчкә генә бүлеп йөртә башлыйлар: эндәш һәм кереш сүзләрне иярчен кисәк составыннан чыгаралар, аергыч шул килеш кала, тәмамлыкларны икегә: тәмамлык һәм хәл дигән төрләргә аералар. Шулай итеп, төгәлләүле мөнәсәбәткә кергән сүзләрнең генә ияртүчесен алып, аны аергыч, тәмамлык һәм хәл дигән төрләргә бүлеп өйрәнә башлыйлар. Аныклаулы мөнәсәбәткә кергән сүзләрнең ияртүчесе аерым очракларда аергычка кертелеп өстәмә сүз исеме астында өйрәнелә, күп очракта бөтенләй өйрәнелми. Хәзерге көндә андый кисәк, аныклагыч исеме астында, дүртенче төр иярчен кисәк итеп тикшерелә.

Иярчен кисәкләрне болай төркемләү хәзерге көндә дөрес дип санала, шулай да тәмамлык белән хәл арасындагы аерманы табу күп очракта кыенлык тудыра. Мәсәлән: *Мин авылга киттем* һәм *Мин Шакирләргә киттем* җөмләләрендә *авылга* һәм *Шакирләргә* кисәкләре грамматик яктан бер төрле, бер формада һәм бер үк функцияне үтиләр: китү процессының юнәлеш урынын күрсәтәләр. Шуңа карамастан алар икесе ике төрле кисәк булып санала. Грамматикадан читтә тора торган принципка (кешене яки әйберне атауга)карап кына, *Шакирләргә* кисәге – тәмамлык, *авылга* кисәге урын хәле була дип әйтәләр. Иярчен кисәкләр бүленешендә мондый очраклар шактый күп, шуңа күрә алда китерелгән бүленеш бик шартлы булып кала: нинди дә булса бер генә принципка нигезләнми.

## АЕРГЫЧ

**§ 120. Гомуми мәгълүмат.** Җөмләнең предмет төшенчәсен атаучы кисәгенә ияреп, шул предметларның билгесен, санын һәм кемгә (нәрсәгә) каравын белдерүче кисәк аергыч була. Аергыч буйсынган кисәкне аерылмыш диләр. Аерылмыш күбрәк исемнәр һәм исемләшкән башка сүзләр белән бирелә. Аерылмыш җөмләнең теләсә нинди кисәге булырга мөмкин, димәк, аергыч җөмләнең теләсә кайсы кисәге янында була ала, һәм аерылмыш кайсы кисәк булып формалашса да, аергыч үзгәрешсез кала.

Без биредә аергычларны кайсы сүз төркемнәре белән бирелүенә карап төркемлибез. Һинд-Европа телләрендә аергычлар күбрәк сыйфатлар белән бирелсәләр, дөресрәге, аергыч булып килгән исем сыйфат формасын алса, төрки телләрдә исем, аергыч булып килгәндә дә, исем булып кала, күп очракта сыйфатка әйләнми. Шуңа күрә төрки телләрдә исемнәр белән бирелгән аергычлар күбрәк очрыйлар.

### Исем белән бирелгән аергычлар

**§ 121. Аерылмышка иялек килеше һәм тартым кушымчасы ярдәмендә ияргән аергыч.** Монда иялек килеше формасын – аергыч, тартым формасын аерылмыш ала.

Аергыч I–II зат алмашлыклары булганда, аерылмыш сөйләмә әдәби телдә тартым кушымчасын алмаска да мөмкин, мәсәлән: *минем китап, синең китап.* Ләкин язма әдәби телдә, кагыйдә буларак, тартым кушымчасын төшереп калдырмыйлар: *минем китабым, синең китабың* формасын кулланалар.

Аергыч өченче затка караган сүз белән бирелгәндә, аерылмыштан тартым формасы төшерелми. Тик тезмә әсәрләрдә генә чыгармалар булырга мөмкин, мәсәлән: *Бик матур бер айлы кичтә бу а в ы л н ы ң б е р  е г е т  киткән урманга утынга...* (Г. Тукай).

Аергыч түбәндәге очракларда иялек килеше кушымчасын ала:

а) күрсәтү алмашлыкларының берлеге яки зат алмашлыклары (III затның күплегеннән башкалары) белән бирелсә. Мәсәлән: *минем китабым, синең китабың, тегенең китабы, безнең китабыбыз, аның китабы* (ләкин *аларның китабы*, *тегеләрнең китабы* дип тә, *алар китабы* дип тә әйтеп була);

ә) аерылмыш белән янәшә килмәсә. Мәсәлән: *Гомерен бирде халык бәхете өчен д а л а л а р н ы ң мәгъруp лачыны* (С. Хәким). *Михаил да, Лиза шикелле үк, Х ә я т н ы ң кечкенәдән бергә уйнап үскән иптәше иде* (Ф. Әмирхан);

б) билгеле әйберләрне, кешеләрне атаучы сүзләр белән бирелсәләр, аергычлар күбесенчә иялек килешендә булалар. Мәсәлән: *Тәрәзәдән Габсаттар а б з ы й н ы ң хатыны карап тора* (И. Гази). *Б и ю ч е л ә р н е ң эзе дә юк* (Г. Ибраһимов).

Ләкин билгеле әйберләрне белдерүче сүзләр белән бирелгән аергычның иялек килешендә генә килүе хәзерге әдәби тел өчен мәҗбүри кагыйдә була алмый. Аерылмыш белән янәшә килгәндә, билгеле әйберне (затны) белдерүенә карамастан, аергыч билгесез килештә дә килә ала. Мисаллар: *Ә кичләрен балалары өчен Ш е к с п и р әсәрләрен, «Н и б е л у н г и» поэмаларын кат-кат укып чыгарга вакыт тапкан* (Г. Кутуй). *Эшләпәле радиоалгычтан Б е т х о в е н музыкасы агыла* (Р. Батулла). *Рәхимсез вакыт к ү з е м нурын, Ч ә ч л ә р е м карасын урлады* (Ш.Җиһангирова).

Иялек килешендәге сүз белән бирелгән аергыч, аерылмыш белән бергә, бер әйбернең (затның, төшенчәнең) икенче әйбергә (затка, төшенчәгә) караган булуын белдерә. Бу юл белән түбәндәге әйберләр бер-берсенә каратылалар: а) берсе икенчесенә ия булган әйберләр: *Петров ү з е н е ң аксагы (ат) белән урманга карата югалды* (Г. Ибраһимов); ә) әйбер һәм аның урыны: *А в ы л н ы ң байтак егетләре, эш бетәр-бетмәс, читкә кәсеп эзләп чыгып киттеләр* (Г. Ибраһимов); б) әйбер һәм аның вакыты: *Җ ә й н е ң туктаусыз хезмәте бик ардырды* (Г. Ибраһимов); в) үзара туган-тумачалык мөнәсәбәтендә торган затлар: *Бала сөючән К а м и л ә н е ң улы байда хезмәт итә* (Г. Ибраһимов); г) әйбер үзенең булу максатын белдергән әйбергә каратыла: *Т е р л е к л ә р н е ң дә азыгы бетү алдында тора* (И. Гази); д) процесс үзенең барлыкка китерүчесенә каратыла: *Бөя... с у н ы ң һөҗүменә каршы тора бирә* (Г. Ибраһимов); е) әйбер үзенең билгесенә каратыла: *Җ а н ы ң н ы ң ваклыгын сылтама заманга* (Р. Фәйзуллин); ё) бөтен үзенең өлешенә каратыла: *Төрле ф ә н н ә р н е ң нигезләрен үзләштерү су кебек кирәк* (К. Насыйри). *М а й н ы ң урталары булганга, кояш ерак, ләкин туры һәм матур карый* (Г. Ибраһимов).

**§ 122. Аерылмышка янәшә тору һәм тартым кушымчасы ярдәмендә ияргән аергыч.** Мондый аергыч, кагыйдә буларак, аерылмышка янәшә торып кына бәйләнә ала. Бу очракта да аергыч белән аерылмыш бер әйберне (затны, төшенчәне) икенче әйбергә (затка, төшенчәгә) каратып ачыклый, төгәлли, димәк, монда да бер әйбер икенче әйбергә каратыла.

Түбәндәге әйберләр бер-берсенә каратылалар: а) нинди дә булса бер әйбер билгеле әйбергә каратыла. Аергыч булып билгелелеге болай да – иялек килешен алмыйча да – аңлашылып торырлык әйберләрне белдерүче сүзләр: кеше исемнәре, ялгызлык исемнәр, дөньяда бер генә булган уникаль әйберләрне атаучы исемнәр һәм аергычлы исемнәр киләләр: *Рәхимовлар гаиләсе белән катышу Хәяткә беркадәр үзгәреш бирми кала алмады* (Ф. Әмирхан). *Без, яшь көчләр, чыныгабыз эштә, нурланабыз кояш нурында* (М. Җәлил); ә) конкрет әйбер гомумиләштерелгән әйбергә каратыла: *...Чын халык телен, чын халык рухын безгә тик халык җырларыннан гына табып була* (Г. Тукай); б) әйбер үзенә бәйле булган процесска каратыла: *Бу – җинаять эзләү агенты иде* (Г. Ибраһимов); в) зат нинди дә булса милләткә каратыла: *Рус укучысына мин беренче булып хат язачакмын* (Д. Аппакова); г) әйбер үзенең исеменә каратыла: *Перекоп шәһәренең теге ягында, буйдан-буйга, калку ныгытма сузылып китә* (Г. Бәширов); д) ыру төргә каратыла: *Тел белеме фәне, физика-математика фәннәре кебек үк, төгәл фәннәрдән санала*; е) өлеш бөтенгә каратыла: *Тибрәлеп яфрак өстендә уйный чык бөртекләре* (С. Хәким); ё) аергыч әйбернең ни өчен хезмәт итүен белдерә: *Беләгенә юл плащы салган Гали абзый үзе дә күренде* (Г. Әпсәләмов); ж) әйбер үзенең булу урынына яки вакытына каратыла: *Тау як көлтәсе бигрәк тә җанга тия* (Г. Ибраһимов). *Көз гөлләре чәчәк аткан саен, яз яңадан кайта күңелгә* (Р. Харис); җ) әйбер үзенең материалына каратыла: *Өй түбәләреннән боз бармаклары салынып төште* (И. Гази); з) объект үтәүчегә каратыла: *Ватан сугышы өчен ул ике улын корбан итте*; и) һәм башка төрле мөнәсәбәтләр: *Тыңлаучылар көлешеп куйды һәм сугыш чыкмавына иркенләп тын алды* (Ә. Фәйзи). *Карчыкның сәнәк фетнәсеннән калган күңел ярасы һичбер төзәлмәде* (Г. Ибраһимов).

**§ 123. Аерылмышка янәшә тору чарасы аша бәйләнгән аергыч.** Мондый аергыч, аерылмыш белән бергә, бер әйбернең (затның, төшенчәнең) икенче әйбер (зат, төшенчә) аркылы ачыклануын белдерә. Түбәндәге әйберләр берсе икенчесе белән ачыкланалар: а) әйбер үзенең материалы белән: *Вакыт җиткәч, с а т и н  күлмәк белән каты кунычлы х р о м  итек сатып алды* (А. Шамов); ә) зат үзенең профессиясе белән: *Чүкечләр тынып торган арада, аргы почмакта т и м е р ч е  Мостафаның карлыга төшкән тавышы яңгырады* (К. Нәҗми); б) әйбер үзенең төрен белдерүче исем белән: *Беренче кар төшәр алдыннан, бер и р  бала дөньяга килгәч, икесенең дә башлары күккә тиде* (И. Гази); в) сан белдерүче сүзләр белән ачыкланган әйбер икенче бер әйберне ачыклый – күләм-чамасын белдерә: *Башта б е р - и к е  ч а к р ы м  җирне барыбыз да тигез килдек* (Ф. Хөсни); г) кабатланган сүз белән бирелгән аергыч та аерылмыштан аңлашылган әйбернең күләм-чамасын белдерә: *Боларның кайсында м и ч - к ә - м и ч к ә  кымыз, кайсында т ә п ә н - т ә п ә н  май, к а п ч ы к - к а п ч ы к  корт була* (Г. Ибраһимов); д) әйбер үзенең вакыты яки урыны белән ачыклана: *Сәфәр у р а м  я к  тәрәзәдән баш тыкты да ут чыккан кебек акырып җибәрде* (Г. Ибраһимов). *Т у й  көнне алар безгә бергәләп килергә тиешләр иде* (К. Тинчурин); е) бер әйбер икенче әйбер белән чагыштырып ачыклана: *Ничә еллар буе бер е л а н  хатынны ашатып, тәрбияләп ятканмын икән* (Ә. Еники). *К ү ң е л  язы шаулап үтте аның т ә ң к ә  карлар яуган буранда* (Һ. Такташ). *Хатыны а л т ы н  кылгандай чәчләрен селкетеп куйды* (М. Максуд).

**§ 124. Аерылмышка чыгыш килеше кушымчасы аша ияргән аергыч.** Мондый аергыч түбәндәге мәгънәләрне белдерә: а) аерылмыштан аңлашылган әйбернең, затның нинди төрдән булуын: *К о ш - л а р д а н  чыпчык яисә сыерчыклар гына чыркылдашып үтәләр* (Ш. Камал). *Әйдә киттек! Минем яшь чагымда п е с и л ә р д ә н  дуслар күп иде* (Һ. Такташ); ә) аерылмыштан аңлашылган әйберләрнең нәрсәдән, кемнәрдән торуын: *...ак т и м е р д ә н  бүрке бар* (К. Насыйри); б) аерылмыштан аңлашылган әйбернең күләм-чамасын: *Урамга да чыга алмыйсың: м у е н н а н  кар* (Г. Тукай).

**§ 125. Аерылмышка төрле ярдәмлекләр аша ияргән аергыч.** Мондый аергычларның мәгънәләре төрлечә:

1. *Хәтле, чаклы, тикле, кадәр* бәйлекләре аша ияргән аергыч аерылмыштан аңлашылган әйберне үзеннән аңлашылган әйбергә күләм-чама ягыннан чагыштырып ачыклый. Мәсәлән: *Я ф р а к к а д ә р кар төшә* (Г. Тукай).

2. *Кебек, шикелле, сыман, төсле (күк, сынлы, ише)* бәйлекләре аша ияргән аергыч аерылмыштан аңлашылган әйберне үзеннән аңлашылган әйбергә төс, форма, эчке халәт якларыннан чагыштырып ачыклый. Мәсәлән: *Ике арада кечкенә и ш е к к е б е к капка да бар* (Г. Ибраһимов). *Ү г е з т ө с л е уллар үстереп, үзең һаман кеше эшендә* (М. Җәлил).

3. Процесс белдерүче исемгә *өчен* бәйлеге аша ияргән аергыч аерылмыштан аңлашылган процессның булу максатын белдерә. Мәсәлән: *Кешенең бөтен тарихы, Газинур, а з а т л ы к ө ч е н көрәш тарихы ул* (Г. Әпсәләмов).

4. *Турындагы*, *хакындагы* ярдәмлекләре аша ияргән аергыч аерылмыштан аңлашылган әйберне ачыклаучы объектны белдерә. Мәсәлән: *Нәгыймә Җиһан әбинең чәчәкләр белән к ү б ә л ә к л ә р т у р ы н д а - г ы сүзен хәтерли иде* (Г. Ибраһимов). *Бу аның я з м ы ш ы т у р ы н - д а г ы көй иде* (Р. Вәлиев).

5. *Дигән* сүзе аша ияргән аергыч аерылмыштан аңлашылган әйберне исеме ягыннан ачыклый. Мәсәлән: *С а н д у г а ч д и г ә н , ай, асыл кош гөлбакчада сайрый, ояда* (И.Башмаков). *Французлар килеп кергән М ә с к ә ү д и г ә н калага* (халык иҗаты).

6. Аергыч аерылмышка *гыйбарәт, катыш, аралаш, буенча, каршы, күрә* кебек ярдәмлекләр, *тулы* сүзе аша да иярә һәм аерылмышны төрле яктан ачыклый. Мәсәлән: *Бер тарафта балдан һәм с ө т т ә н г ы й б а р ә т кәүсәр елгасы агып ята* (Г. Тукай). *Баштанаяк өтеп ала т о м а н к а т ы ш таң суы* (З. Мансуров). *В е л о с и п е д б у е н ч а балалар ярышында беренчелекне яулап алды* (Р. Төхфәтуллин). *Матур булыр, бу к о р с а к л а р г а к а р ш ы чаралар корсак* (Г. Тукай). *Синең дә, Хәмит, ү з е ң ә к ү р ә эшең бар* (К. Тинчурин). *Ул үзенең, к и т а п т у л ы портфель күтәреп, беренче тапкыр мәктәпкә барганын күз алдына китерде* (Р. Вәлиев). *А в ы р л ы к л а р т у л ы бу тормышта Бер җиңеллек булсын, дисеңме...* (И. Юзиев).

## Сыйфатлар, рәвешләр, саннар, хәбәрлек сүзләр белән бирелгән аергычлар

**§ 126. Ясалма сыйфатлар һәм ясалма рәвешләр белән бирелгән аергычлар.** Алар исем һәм башка төркем сүзләр белән бирелгән аергычларга якын торалар. Чөнки сыйфат һәм рәвеш ясаучы күп кенә кушымчалар исемнәрне һәм башка сүзләрне исемгә бәйләү хезмәтен дә үтиләр. Исемнәрне исемгә шул кушымчалар ярдәмендә бәйләү процессында сыйфатлар һәм рәвешләр ясала, һәм алар синтаксиста аерылмышны төрле яклап ачыклаучы аергычлар булалар.

1. *-лы*/*-ле* кушымчалы сыйфат белән бирелгән аергыч түбәндәге мәгънәләрне белдерә: а) аерылмышта булган әйберне, мәсәлән: *...ак алъяпкычлы хатыннар күренде* (М. Әмир). *Күк атлы кеше узып та китте* (И. Гази); ә) аерылмышта булган эчке билгеләрне, мәсәлән: *Дөньяда күп кешеләр бардыр ки, үткен вә гакыллы кешеләрдән куркып, үз тирәләрендә күбрәк ахмакларны йөртәләр* (Г. Тукай). *Бу китапны ... мәхәббәтле бер хәлфәдән укыдым* (Ф. Әмирхан); б) исем фигыльдән ясалган сыйфатлар белән бирелгән аергыч аерылмыштан аңлашылган объектны яки үтәүчене ачыклый, мәсәлән: *Сызганулы беләкләр Мөнирәнең күз алдында торалар* (Ф. Хөсни). *Рәнҗү катыш әрнүле сүзләр ике арада бик кызып кителәр* (Г. Ибраһимов); в) аергыч аерылмышны ниндидер билгегә ия булган өлеше буларак ачыклый, мәсәлән: *Ике генә тәрәзәле өй күренде* (Г. Ибраһимов). *Ул абзарга керә дә кәкре мөгезле кәҗәне өстерәп алып чыга* (Г. Гобәй).

2. *-сыз*/*-сез* кушымчалы сыйфат белән бирелгән аергыч аерылмышны анда табылмаган үзенчәлек аркылы ачыклый. Мәсәлән: *Син яшәмә, файдасыз бер түмгәк булып тигез урында* (М. Җәлил). *Тамырсыз агач корый* (М. Юныс).

3. *-гы*/*-ге* кушымчалы сыйфат белән бирелгән аергыч әйберне шул әйбернең булу урыны, вакыты ягыннан ачыклый. Мәсәлән: *Җәйге төннең гадәтенчә төн бераз салкын икән* (Г. Тукай). *Башындагы яраларыннан кан бөркелә бинтлар үтәли* (Х. Туфан). *Күзге учакларда сәер моңсулык бар* (Зөлфәт).

4. *-дай*/*-дәй* кушымчалы рәвеш белән бирелгән аергыч аерылмышны үзеннән (аергычтан) аңлашылган әйбергә яки күренешкә тиңләп ачыклый. Мәсәлән: *Җырга салып, җырдай тормышыңны үзеңә*

*бүләк итәсе иде* (Х. Туфан). *Калтырый җир, т а у д а й танкларның дәһшәтләрен күрсә идегез*! (Ф. Кәрим).

5. Башка төрле ясалма рәвешләр һәм сыйфатлар белән бирелгән аергычлар да аерылмыштан аңлашылган әйберне төрле яклап ачыклыйлар. Мәсәлән: *Анда т а т а р ч а спектакль куела* (Г. Камал). *Ничә й ө з е л л ы к зур карт имәнне... Яманкүл чокыры өстенә аша ташлады* (Г. Ибраһимов).

**§ 127. Төп сыйфат һәм рәвешләр белән бирелгән аергычлар.** Мондый аергычлар аерылмышка янәшә тору чарасы аша ияреләр һәм аерылмыштан аңлашылган әйберне төрле яклап ачыклыйлар: а) төсен белдерәләр: *Мәйдан буш, к ы з ы л өй ялгыз калды* (Г. Ибраһимов); ә) урын, вакыт эчендәге яки гомумән күләм-чамасын белдерә: *К е ч - к е н ә генә дошманга да з у р дошманга хәзерләнгән кебек хәзерләнергә тиеш* (Г. Тукай). *Аның машинасына а в ы р танклар да юл биреп үтәләр* (Г. Бәширов). *Б е р а з җир сүзсез бардылар* (Ф. Хөсни). *Үз гомерендә бик к ү п изгелекләр эшләде Миргали Сабирга* (М. Әмир); б) формасын, рәвешен белдерә: *Т ү г ә р ә к күл буйларында кошлар сайрый камышта* (җыр). *Аның куәтле дулкыннары... т е к ә ярга һөҗүм итәләр* (Г. Ибраһимов); в) тәмен белдерә: *Ә ч е алма ашар идем, тияр дим тешләремә* (җыр); г) эчке характерын, үзенчәлеген белдерә: *Я к ы н дустым, сиңа миннән киңәш шул: кешеләргә сереңне сөйләмәс бул* (Г. Тукай). *У с а л җилләр моңа сугылу белән кинәт тыелганнар* (Ә. Фәйзи); д) эчке халәтне, эчке сыйфатны белдереп, күбрәк, алынма сыйфатлар белән бирелгән аергычлар йөриләр: *Т а - б и г ы й о б ъ е к т и в законнарны үз белдегең белән генә бозып булмый* («Ватаным Татарстан»). *Сезгәме соң г о м у м и эшләр артыннан йөрү!* (К. Тинчурин).

**§ 128. Саннар белән бирелгән аергычлар.** Мондый аергычлар аерылмышка янәшә тору чарасы аша бәйләнәләр һәм аерылмыштан аңлашылган әйбернең (затның) санын белдерәләр. *Отрядта и к е й ө з батыр бар* (Г. Ибраһимов). *Җ и д е н ч е яшемдә мине мәктәпкә бирделәр* (Ф. Әмирхан). *У н кешене аттылар, җ и д е л ә п кеше генә качып котыла алды* (Г. Ибраһимов).

Сан белән бирелгән аергыч аерылмышка *төрле*, *артык* сүзләре ярдәмендә дә ияргә мөмкин. Мәсәлән: *Бишесе б и ш т ө р л е характерда. У т ы з д а н а р т ы к солдат кул куйган.*

**§ 129. Хәбәрлек сүзләр белән бирелгән аергычлар.** Бу төр аергычлар, хәбәрлек сүзнең мәгънәсенә һәм бәйләүче чараларның төренә карап, аерылмыштан аңлашылган әйберне (затны, төшенчәне) төрле яктан ачыклыйлар. Мәсәлән: *Бәхеткә каршы, икмәкче көнде, итекчегә к и р ә г е к а д ә р икмәк бирде* (Г. Тукай). *Мин к и р ә к х ә т л е мал бирермен* (халык иҗаты). *И, калдыр әле ю к уйларны* (К. Тинчурин). *Дөнья кайнарга тора, шундый вакытта сез җыен ю к - б а р эш артыннан йөрисез* (Г. Ибраһимов).

### Фигыльләр белән бирелгән аергычлар

**§ 130. Сыйфат фигыль белән бирелгән аергычлар.** Алар түбәндәге мәгънәләрне белдерүче аерылмышны ачыклыйлар: а) аерылмыштан аңлашылган үтәүчене ачыклыйлар: *К ү р г ә н бер кеше сорап тора* (Г. Ибраһимов). *Ә й т е р сүзләр әйтелмичә калсын Ю г а л т ы ш к а н чакта гомерлеккә* (Зөлфәт); ә) аерылмыштан аңлашылган объектны ачыклый: *Җ ы р л а н а с ы җырымны иртәнге һава җилләрендә назладым, кояш нурларында җылыттым* (Г. Кутуй); б) процессның үтәлү урынын яки вакытын ачыклый: *К а й т ы р юл түбән таба иде* (Г. Ибраһимов). *Ат җ и б ә р ә ч ә к вакыт җиткән икән* (Ф. Хөсни); в) процессны үтәүдә катнашкан коралны ачыклый: *Азатка әтисе а т а т о р г а н мылтык бүләк иткән иде.*

**§ 131. Инфинитив белән бирелгән аергыч.** Бу төр аергыч аерылмыштан аңлашылган әйбернең (затның, төшенчәнең) булу максатын белдерә: *...кая булса да с ы е н ы р г а бер урын эзли башлый идем* (Г. Ибраһимов). *Сизенәм: егетләрнең у р н а ш ы р г а исәпләре юк түгел* (Ф. Хөсни). *К у р к ы р г а, ө р к е р г ә Җай бар ул һаман да* (Р. Фәйзуллин).

## ТӘМАМЛЫК

**§ 132. Гомуми мәгълүмат.** Җөмләнең процесс белдерүче сүз белән бирелгән теләсә кайсы кисәгенә ияреп, процессның (яки билгенең) объектын, үтәүчене яки нинди дә булса бер хәл кичерүче әйберне (затны) һ.б. мәгънәләрне белдерүче иярчен кисәк тәмамлык була.

Тәмамлык җөмләнең процесс белдерүче сүз белән бирелгән теләсә кайсы кисәгенә иярә ала, мәсәлән: 1) хәбәргә иярә: *Мин бу к и т а п н ы укыйм;* 2) иягә иярә: *С е з г ә баруым минем өчен бик зур шатлык*

*булды;* 3) хәл кисәгенә ияртү: *К и т а п н ы укымыйча гына сөйлисең;* 4) аергычка ияртү: *Б у й о р т н ы төзегән эшчеләр башка объектта эшлиләр;* 5) тәмамлыкка ияртү: *хәзер без и л е б е з н е индустрияләштерүдә зур уңышларга ирештек.*

Тәмамлыклар туры тәмамлык һәм кыек тәмамлык дигән төрләргә бүленәләр. Әгәр дә тәмамлык процесс турыдан-туры кагыла торган әйберне, төшенчәне белдерсә, андый тәмамлык туры тәмамлык дип йөртелә. Тәмамлык процесс турыдан-туры кагылмый торган әйберне, затны белдерсә, андый тәмамлыкны кыек тәмамлык диләр.

## Туры тәмамлыклар

**§ 133. Ияртүче кисәккә төшем килеше формасы аша бәйләнгән туры тәмамлыклар.** Түбәндәге шартларда туры тәмамлыклар ияртүче кисәккә төшем килеше формасы аша бәйләнәләр.

1. Туры тәмамлыкка аерым басым ясап әйтелсә яки тәмамлык сөйләүче өчен дә, тыңлаучы өчен дә алдан билгеле булган предметны (төшенчәне) белдерсә, ул төшем килеше формасын ала: *Кемдер пычрак аткач, искә төште күлдә акбүз а т н ы юганым…* (З. Мансуров). Мондый тәмалыкларны күбрәк күрсәтү, зат алмашлыклары һәм ялгызлык исемнәр ачыклап киләләр яки алар 1, II зат тартым кушымчасын алган булалар. Мисаллар: *Әнә т е г е г а р м о н ь н ы , ди, зинһар китереп бирегез, – ди* (Ф. Кәрим). *Син м и н е м к и т а п н ы укып чыктыңмы? Казан урамнарын ташлап китәм* (Һ. Такташ). *П а л ь т о ң н ы бик ошаттым.*

2. Ялгызлык исемнәр, кешене белдерүче сүзләр (апа, абый, кодагый, әни һ.б.ш.) белән бирелгән туры тәмамлыклар һәрвакыт төшем килешендә булалар. Мәсәлән: *Г а б д у л л а н ы чыбылдыклы бүлмәгә алып керделәр* (Ә. Фәйзи). *Мин ә н и е м н е бик сагындым.*

3. Алмашлыклар белән бирелгән туры тәмамлыклар һәрвакытта да төшем килеше формасында булалар. Мәсәлән: *С и н е көтеп, бик күп вакытыбыз үтте.*

4. Үзе ияргән кисәктән башка сүзләр белән аерылып торган туры тәмамлык та, кагыйдә буларак, төшем килеше формасын ала. Мәсәлән: *Б а р җ ы р ы м н ы илгә багышладым* (М. Җәлил).

5. Саналмышлары урынында килгән саннар белән бирелгән туры тәмамлыклар да һәрвакыт төшем килеше формасын ала. Мәсәлән:

*Сәгать суга с и г е з н е , чыгып киттек диңгезне...* (җыр). *Беләге юан б е р н е егар, белеме булган м е ң н е егар* (мәкаль).

6. Туры тәмамлыкны башка кисәк белән бутау куркынычы булганда, ул һәрвакытта да төшем килеше формасын ала. Мәсәлән: *Солдатлар алып кайткан вагон төзәтелеп ята* җөмләсендә *солдатлар* кисәген ия дип тә, тәмамлык дип тә карап була, әгәр *солдатлар* сүзе тәмамлык булса, аныклык өчен, аны төшем килешендә әйтергә кирәк була: *Солдатларны алып кайткан вагон төзәтелеп ята.*

**§ 134. Ияртүче кисәккә янәшә тору чарасы аша бәйләнгән туры тәмамлыклар.** Мондый тәмамлыклар, аерым форма алмау аркасында, ияртүче кисәккә, кагыйдә буларак, янәшә тору аркылы гына буйсына алалар. Мәсәлән, *Мин картина карадым* дип булса да, *Картина мин карадым* дип булмый.

1. Туры тәмамлык, тыңлаучы өчен алдан таныш булмаган объектны белдергәндә, билгесез килештәге сүз белән бирелә. Мәсәлән: *Әйтерсең, учитель к и т а п тоттырмады, к а н а т тагып җибәрде аңарга* (Ә. Фәйзи).

2. Билгесезлекне белдерүче *бер* сүзе белән килгән туры тәмамлык та билгесез килештәге сүз белән бирелә. Мәсәлән: *Тукта, мин сиңа б е р к и т а п күрсәтим әле* (Ә. Фәйзи).

3. Инфинитив белән бирелгән туры тәмамлыклар да ияртүче кисәккә билгесез килеш формасы аша, ягъни бары янәшә тору юлы белән генә бәйләнәләр. Бу вакытта туры тәмамлык предметны түгел, бәлки процесс төшенчәсен бирә, ә ияртүче кисәк уйлауга, боеруга бәйләнешле фигыльләр белән бирелә. Мәсәлән: *Ул үзенең рухын тутырган куәтле ялкынны аңа б е л д е р е р г ә теләмәде* (Г. Ибраһимов). *Укытучы к е р е р г ә кушты, җ ы р л а р г а өйрәтәм, диде.*

**§ 135. Ияртүче кисәккә чыгыш килеше һәм кайбер бәйлекләр аша бәйләнгән туры тәмамлыклар.** Мондый тәмамлыклар бик аз кулланылалар. Кулланылганда да, андагы чыгыш килеше формасын төшем килеше формасы белән бик җиңел алмаштырырга мөмкин була. Мәсәлән: *Ул аның я к а с ы н н а н эләктерде. Беренче пуля аның б а ш ы н н а н яралады. Тотып к у л ы м н а н , гомерем юлыннан минем белән бергә килдең син. Я, рәхим итегез, Гали абзый, үзегез яраткан к о й м а к т а н авыз итегез* (Г. Әпсәләмов). *Кырмыска аучының б о т ы н н а н бик каты тешләде* (Г. Тукай).

Чыгыш килеше кушымчасы туры тәмамлыкның ныклы формасы була алмый, чөнки чыгыш килешендәге кисәк бик җиңел урын хәленә әйләнә ала. Мәсәлән: *Ул аны к у л ы н н а н тотты. Ул аны я к а с ы н н а н тотты* җөмләләрендә *аны* сүзе – тәмамлык, *кулыннан, якасыннан* – урын хәле.

Туры объект *кадәр, чаклы* бәйлекләре янындагы туры тәмамлык белән дә бирелергә мөмкин. Мәсәлән: *Күңел бу якларның бер кул яссу Т у ф р а г ы н а к а д ә р сагынган* (Зөлфәт). *Авыл урамының яшел чирәмнәрен, койма буена үскән ә р е к м ә н н ә р е н ә, әрсез к ы ч ы т к а н н а р ы н а х ә т л е сагынганмын...* (Ф. Яруллин).

## Кыек тәмамлыклар

**§ 136. Үзенә процесс турыдан-туры кагылмаган объектны белдерүче кыек тәмамлыклар.** Болар түбәндәге формаларны алган сүзләр белән бирeләләр.

1. Юнәлеш килеше формасын алган сүз белән; бу вакытта ул фигыльләр, сыйфатлар, саннар, алмашлыклар, рәвешләр һәм кайбер модаль сүзләр белән бирелгән кисәкләргә ияртә. Мәсәлән: *Шул чибәрләр х ө р м ә т е н ә кычкырып җырлап җибәр* (җыр). *Бу – бик кадерле бүләк, безнең ү з е б е з г ә дә алтау гына. Синең бу эшең м а к т а у г а лаек. С и ң а монда ни бар? М и ң а монда ни булмас. Бу класс белән эшләү яшь к е ш е г ә бик авыр. Алар с ө й л ә г ә н г ә каршы килеп булмас. Эндәшә батыр утынчы: – С и ң а миннән ни кирәк?* (Г. Тукай). *К е ш е л ә р г ә ничек соң ул, ягымлымы?*

2. Чыгыш килеше формасын алган сүзләр белән. Мәсәлән: *Гөлләр җ ы л ы с ы н н а н мантый дөнья...* (Зөлфәт). *Сездән тиз генә китәргә у к ы т у ч ы д а н оялам.*

3. Урын-вакыт килешендәге сүзләр белән. Мәсәлән: *Урлап алган м а л д а бәрәкәт юк анда* (Р. Вәлиев).

4. *Белән* бәйлеге янында килгән сүзләр белән. Мәсәлән: *Т и л е б е л ә н тапма да, югалтма да* (мәкаль). *Кеше алга карап яшәргә, зур х ы я л л а р б е л ә н хыялланырга тиеш* (Р. Вәлиев).

5. *Өчен* бәйлеге янындагы сүз белән. Мәсәлән: *Аның күңел күгендәге кайсыдыр бер тәрәзәсе И с к ә н д ә р ө ч е н инде ябык иде* (Р. Вәлиев). *Үземне түгел, аларны кызганам мин, а л а р ө ч е н борчылам* (Р. Вәлиев).

6. *Аша*, *аркылы* ярдәмлекләре янындагы сүзләр белән. Мәсәлән: *Бодайның бер ишесен т р и е р  а р к ы л ы  уздырырга кушты* (Г. Бәширов). *Дөньяда күп нәрсә белдем син туган т е л  а р к ы л ы* (Г. Тукай).

7. *Саен* янындагы сүз белән, мәсәлән: *У к у ч ы  с а е н  икешәр дәфтәр өләшенде.*

8. *Каршы* сүзе белән. Мәсәлән: *Ул минем с ү з л ә р е м ә  к а р ш ы бер нәрсә дә әйтә алмады* (М. Гафури).

9. *Турында*, *хакта* ярдәмлек сүзләре янында килгән исемнәр, алмашлыклар белән. Мәсәлән: *Мин сезгә т у р г а й  х а к ы н д а  сөйлим* (М. Гафури). *Б ә х е т  т у р ы н д а  сөйләшү – бәхетсезләр эше* (Р. Вәлиев).

10. *Башка*, *тыш* ярдәмлекләре янындагы сүзләр белән бирелә. Мәсәлән: *Бөтен ч ы г ы ш л а р ы н н а н  т ы ш ,  сигез сум саф файда калды* (Г. Ибраһимов).

**§ 137. Үтәүчене яки нинди дә булса хәлне кичерүче затны (әйберне) белдерә торган кыек тәмамлыклар.** Мондый мәгънәдәге кыек тәмамлыклар җөмләнең фигыльләр һәм сыйфатлар белән бирелгән кисәкләренә ияреләр. Ияру төрле формалар аша булырга мөмкин, ягъни бу мәгънәдәге кыек тәмамлык төрле формаларда килә ала.

1) Юнәлеш килеше кушымчасын алган сүзләр белән бирелә. Бу очракта җөмлә бер составлы була. Мәсәлән: *М и ң а  эшләргә, яшәргә кирәк* (Р. Вәлиев).

Уртаклык юнәлешендәге фигыль белән бирелгән кисәккә ияргән кыек тәмамлык та, юнәлеш килеше формасында булып, төп үтәүчене белдерә: *Гали В ә л и г ә  утын ташышты. Мин с и ң а  хат языштым.*

2) Иялек килеше формасын алган сүзләр белән бирелә. Мәсәлән: *Г а л и н е ң  безгә киләсе бар әле.*

3) Эш башкаручыны белдерә торган кыек тәмамлык *кадәр, чаклы, тикле* бәйлекләре һәм юнәлеш килеш кушымчасын алган сүзләр белән бирелә. Мәсәлән: *К а з л а р г а  к а д ә р  каңгылдашалар* (И. Гази).

4) Чыгыш килешендәге сүзләр белән бирелергә мөмкин. Бу вакытта ияртүче кисәк йөкләтү юнәлешендәге фигыль белән бирелә. Мәсәлән: *Гөләнвәр а ң а р д а н . . .  хат яздырды* (Ә. Фәйзи).

5) *Тарафыннан* сүзе янында килгән исемнәр һәм алмашлыклар белән бирелә. Ияртүче кисәк төшем юнәлешендәге фигыль була. Мәсәлән: *Бу бина безнең э ш ч е л ә р  т а р а ф ы н н а н  салынган.*

6) *Белән* бәйлеге янында килгән сүз белән бирелә. Мондый кыек тәмамлык ике эш башкаручының берсен белдерә. Мәсәлән: *Әти белән килдем. Бабай белән дә сөйләштек.*

## ХӘЛЛӘР

**§ 138. Гомуми мәгълүмат.** Җөмләнең фигыль, сыйфат, рәвеш һәм процесс белдерүче башка сүзләр белән бирелгән кисәгенә ияреп, процессның яки билгенең билгесен, яисә процессның үтәлү рәвешен, вакытын, урынын, юнәлешен, максатын, сәбәбен, шартын, күләм-дәрәҗәсен белдерә торган кисәкләр хәл дип йөртеләләр.

Билгеләмәдән аңлашылганча, хәл, башлыча, түбәндәге сүзләр белән бирелгән кисәкләргә ияра: 1) фигыль белән бирелгән кисәккә (мәсәлән: *Без авылга кайтабыз*); 2) сыйфат белән бирелгән кисәккә (мәсәлән: *Әкияттәге төсле серле, җырдагы төсле моңлы, рәсемдәге төсле матур елга ул Агыйдел*); 3) рәвеш белән бирелгән кисәккә (мәсәлән: *Ул саф татарча сөйли. Әйберләрне бөтенләй бушлай бирдем. Урман эченнән бик якын*); 4) хәбәрлек сүзләр белән бирелгән кисәккә (мәсәлән: *Урманда бар, кырда юк, мунчада бар, өйдә юк.* – Н авазы).

Хәлләр мәгънә ягыннан түбәндәге төркемгә бүленәләр: урын хәле, вакыт хәле, рәвеш хәле, күләм хәле, сәбәп хәле, максат хәле, кире хәл һәм шарт хәле.

**§ 139. Урын хәле.** Процессның яки билгенең булу яки юнәлү урынын белдерә торган кисәк урын хәле дип атала.

1. Исемнәр һәм исем урынындагы сүзләр, башлыча, юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килеше формаларын алып, урын хәле булып киләләр. Алар процессның, билгенең урынын, кая таба, кайдан юнәлгән булуын белдерәләр. Мәсәлән: *Киткән урманга утынга* (Г. Тукай). *Ишектән юл кешесе килеп керде. Мин ахырдан алтынчы.*

2. Килеш формалары алган исемнәр белән бирелгән урын хәлләре процессның юнәлешен, урынын гомумән генә белдерсәләр, төрле ярдәмче сүзләр янында килгән исемнәр белән бирелгән урын хәлләре процессның урынын, юнәлешен конкрет билгелиләр. Мәсәлән: *Куян урман эчендә яши. Сочинениене дәфтәрләр арасына куйдым. Урманга таба очты. Авыл аша үтәргә туры*

*килде. Менә шушы юл белән бардык. Китә кошлар, китә урман өсләреннән...* (Зөлфәт). *Урам якка карый безнең тәрәз* (М.Әгъләм).

3. *Буйлап*, *буенча* сүзләре белән килгән исемнәр дә урын хәле була алалар. Мәсәлән: *Су буйлап отряд бара. Алар койма буйлап узалар.*

4. Кайбер исемнәр билгесез килештә дә урын хәле булып килә алалар, тик алар үз табигатьләре белән урын белдерүгә тартым булырга тиешләр. Мәсәлән: *Яшь чагында урамнар урый идек, авыл әйләнгән чаклар да булды. Тау мендем.*

5. Урын хәле рәвешләр белән бирелә. Мәсәлән: *Кояш бик югары күтәрелгән. Очар чагым булган биек-биекләрдә...* (Зөлфәт).

6. Иярчен урын җөмләне баш җөмләгә бәйләүче мөнәсәбәтле сүзләр (сорау һәм күрсәтү алмашлыклары) шулай ук урын хәле булалар. Мәсәлән: *Кайда берлек, шунда көч* (мәкаль). *Җил кайдан иссә, болыт та шуннан килә* (мәкаль). *Кая барсам, шунда көттерделәр* (Г.Рәхим).

**§ 140. Вакыт хәле.** Процессның үтәлү вакытын яки билгенең булу-булмау вакытын белдерә торган кисәк вакыт хәле дип атала.

1. Вакыт хәле түбәндәге формаларны алган исем яки исем урынындагы сүзләр белән бирелә: а) чыгыш килеше кушымчасын алган исемнәр белән: *Китабыңны өч сәгатьтән килеп алырсың. Без яшьтән үк таныштык;* ә) урын-вакыт килеше формасын алган сүзләр белән: *Газета шушы минутта ук чыгып җитәргә тиеш* (Д. Аппакова); б) төшем килеше формасын алган исемнәр белән: *Шушы төнне аны больницага алып киттеләр* (Һ. Такташ). *Г. Тукай 1886 елны туган;* в) билгесез килештәге сүзләр белән: *Тege вакыт әнисе килгән иде* (Г. Ибраһимов).

2. Вакыт хәле төрле бәйлекләр һәм ярдәмлекләр янында килгән сүзләр белән бирелә: *Иртә белән көн томанлы иде* (Ш. Камал). *Моннан соң биш-алты еллар читтә торырга туры килде. Ул арада боларны кайсыдыр күреп алды булса кирәк* (Г. Гобәй).

3. Вакыт хәле төрле фигыль формалары белән бирелә: а) *-у/-ү* формасындагы исем фигыль һәм юнәлеш килеше кушымчасы яки *белән* бәйлеге белән: *Кайту белән эшкә тотынды. Таҗи, йокыга китүгә, бик күп төшләр күреп алды* (Г. Гобәй). *Усал җилләр,*

*моңа сугылу белән, кинәт тыелганнар* (Ә. Фәйзи); ә) рәвеш фигыльләр белән: *Баргач, барысын да сөйләрмен*; б) юнәлеш, чыгыш һәм урын-вакыт килеше кушымчасы һәм кайбер ярдәмлек сүзләр белән килгән үткән заман сыйфат фигыльләр белән: *Мортаза бабай, бу хәбәрне ишеткәннән соң, башын түбәнрәк иеп йөри башлады* (Г. Гобәй).

4. Вакыт хәле вакыт рәвешләре белән бирелә: *Быел халык бик тырыша* (Г. Бәширов). *Я дөньяны үзгәртәм мин бүген, Я булмаса үзем үзгәрәм* (Р. Вәлиев). *Кайчагында белгәнеңне дә әйтмисең.*

5. Иярчен вакыт җөмләне баш җөмләгә бәйләүче мөнәсәбәтле сүзләр шулай ук вакыт хәле була алалар: *Кайчан кайтыр, шул вакыт килерсең. Йокысыннан кояш ничек уянды исә, җил шул вакыт җилбер-җилбер итеп исә* (Г. Тукай).

**§ 141. Рәвеш хәле.** Процессның ничек һәм ни рәвешле үтәлүен яисә нинди дә булса бер хәлнең яки билгенең билгесен, сыйфатын белдерә торган кисәк рәвеш хәле дип атала. Мәсәлән, рәвеш хәле процессның үтәлү рәвешен белдерә: *Мортаза бабай комиссарга астан гына карап алды* (Г. Гобәй); билгенең билгесен белдерә: *Төн кебек караңгы урман. Бер генә тавыш та ишетелми* (Р. Төхфәтуллин). *Сезнең кебек матур ярлар авылда ла түгел, илдә юк* (җыр).

Рәвеш хәлләре түбәндәге формаларны алган сүзләр һәм сүзтезмәләр белән бирелә.

1. Җөмләдә исемнәр яки исем урынында йөри торган сүзләр, рәвеш хәле булып килгәндә, түбәндәге формаларны алалар.

а) Чыгыш килеше формасын. Мәсәлән: *Ул атна буе спорт киеменнән йөрде.*

ә) Урын-вакыт килеше формасын ала. Мәсәлән: *Хәзер һәрбер күренешне фән нигезендә өйрәнергә кирәк.*

б) *Белән, кебек, төсле, сыман, күрә* һ.б. бәйлекләр һәм *каршы, булып, сыйфатында, буларак, итәрәк, дип, буенча* ярдәмлекләре белән килгән исемнәр (яки ияртүче кисәге шул исемнәрдән торган сүзтезмәләр) белән бирелә. Мәсәлән: *Өмет белән таңда уянасың...* (Р. Әхмәтҗан). *Җыр безгә су кебек, һава кебек кирәк. Йөзе дә яз кояшы кебек балкый иде* (Р. Вәлиев). *Ул да шул кешесенә күрә юмарт. Соңгы баржага агымга каршы йөзеп чыгарга туры килгән. Чәчләренә, җылы карлар булып, тал мамыгы*

*ява тын гына* (М. Галиев). *Фәхри, р е в и з о р с ы й ф а т ы н д а, безнең эшләрне тикшерергә килде* (Г. Ибраһимов). *Бу авылны З ә ң - г ә р Ч и ш м ә д и п атыйлар* (Г. Ибраһимов). *Ак каеннар, я ф р а к - я ф р а к и т е п , Җир-әнкәгә түли «алтын ясак»* (Р.Низами).

2. Рәвеш хәлләре сыйфатлар белән бирелә алалар. Мәсәлән: *Бик в а к ы т л ы төшкән икән* (И. Гази). *Газизә я л г ы з утыра калды* (Ш. Камал).

Сыйфатлар *итеп*, *көе*, *рәвештә*, *төсле*, *сыман* кебек ярдәмлек сүзләр белән дә җөмләдә рәвеш хәле булып килә алалар. Мәсәлән: *Ул бит хәзер нинди с ө й к е м л е и т е п көлә белә* (Г. Гобәй). *Зиннәт, шәмәхә төсле кульяулыгын чыгарып, й о м ш а к к ы н а и т е п , маңгаена, битләренә тидереп алды* (Г. Бәширов). *Барак тагын шулай ук ямьсез, кызганыч, б у ш к ө е тора* (Ш. Камал). *Мин моңа к и с к е н р ә в е ш т ә каршы киләм* (Д. Аппакова). *Р ә с е м д ә г е т ө с л е матур, җ ы р д а г ы т ө с л е моңлы... елга ул Агыйдел!* (М. Әмир).

3. Рәвеш хәле рәвешләр белән дә бирелә. Мәсәлән: *Юк, авыр булмас. Б е р ь ю л ы эшен бетерсәк* (Г. Бәширов). *Шундый чакта Хәдичәнең якты өметен к и н ә т к е н ә өзеп ташлау күңеленә ошамады* (Г. Бәширов). *Алар тагын килә калсалар, безне т е р е л ә й тотып ашарлар* (М. Гафури). *Шәмсетдин т и з г е н ә атлап чыгып та китте* (Г. Бәширов). *Төрле як т ө р л е ч ә сөйли* (М. Гафури). *Сез аны а к - ч а л а т а түләрсез. Умартачы к и н ә т к е н ә авырып китте* (Г. Бәширов). *Йөк а т ы д а й Тартып барам заман йөкләрен* (И. Юзиев).

4. Рәвеш хәле рәвеш фигыльләр яки ияртүче кисәге рәвеш фигыль булган сүзтезмәләр белән бирелә. Мәсәлән: *Аның нурлары эшкә баручыларны с ө е п каршы алды* (М. Гафури). *Еракта-еракта, з ә ң г ә р т а с м а д а й б у л ы п , су күренде* (И. Гази). *Кызу эш өстендә э ш к ә ч ы к м ы й ч а ятты бит* (Ә.Камал). *Е л ы й - е л ы й, с у г ы ш а - с у г ы ш а , җирдә Акыл күпме җавап эзләгән* (Р. Вәлиев).

5. Рәвеш хәле *төсле, кебек, сыман* бәйлекләре һәм *булып, итеп, дип* ярдәмлек сүзләре белән килгән сыйфат фигыльләр белән бирелә. Мәсәлән: *Искәндәр бик авыр имтихан т а п ш ы р г а н к е б е к җиңеләеп китте* (Р. Вәлиев). *Кешеләр, кулларын җәеп, б и е г ә н с ы - м а н йөрделәр* (И. Гази). *Гомерлеккә җ и т ә р и т е п сеңдер Гөл җылысын, гөлләр яктысын!* (Зөлфәт). *Аны укыган дип уйлыйлар, чөнки ул б е л г ә н б у л ы п күренә бит.*

6. Рәвеш хәле кайбер төр саннар белән бирелә. Мәсәлән: *Алар бүген бишәү килделәр, без исә б е р ә м л ә п кенә килдек.*

7. Рәвеш хәле кайбер төр алмашлыклар белән дә бирелә. Мәсәлән: *Рәҗәп абзыйлардан чыккач, Габдулла ш у л а й д и п уйланды* (Ә. Фәйзи). *Аңа ш у л а й тоела торгандыр. Туганы аңа н и ч е к и т е п хакыйкать эзләвен сөйләп бирде* (халык иҗаты).

8. Иярчен рәвеш җөмләне баш җөмләгә бәйләүче мөнәсәбәтле сүзләр (сорау һәм күрсәтү алмашлыклары) шулай ук рәвеш хәле булалар. Мәсәлән: *Кигән кием н и ч е к туза, яшь гомер ш у л а й уза* (җыр). *Н и ч е к эләкте, ш у л а й алып ташладык та кайтып киттек.*

**§ 142. Күләм хәле.** Процессның яки билгенең күләмен, дәрәҗәсен белдерә торган кисәк күләм хәле дип атала.

1. Күләм хәлләре процесс үтәлүнең яки дәвам итүнең вакыт ягыннан күләмен белдерәләр. Мондый хәлләр, күбрәк, вакыт белдерүче сүзләр белән биреләләр. Мәсәлән: *И к е с ә г а т ь инде яңгыр ява...* (Г. Гыйльманов). *К ө н е - т ө н е тырышып эшләгәнен ул әйтергә залга теләде* (Һ. Такташ). *Аннан соң и к е а й б у е н ч а аерылышып торырга туры килде* (М. Максуд). *Китапны б е р г е н ә к ө н г ә алды. И к е к ө н укыдык, тагын б е р а т н а укыйсы бар.*

2. Күләм хәлләре урын ягыннан процессның үтәлү, дәвам итү күләмен белдерәләр. Мәсәлән: *Оча алма! Алмагачы исә Тын йокыга иңгән тубыктан ук...* (Зөлфәт). *А й г а х ә т л е үрли учак* (Р. Корбан). *Б и л е н н ә н суга баткан килеш килгән. Т е з д ә н юеш килеш килдем.*

3. Процессның гомумән үтәлү күләмен, дәрәҗәсен белдерүче күләм хәлләре. Мәсәлән: *Орудиеләр тавышы һ а м а н якынлаша бара* (Г. Бәширов). *Дүртенче көн инде Мәликә апа б ө т е н л ә й аяктан калды* (К. Нәҗми). *Ашарларына инде т ә м а м бетте* (Г. Ибраһимов). *Мин синең белән б ө т е н л ә й сөйләшмәячәкмен* (Д. Аппакова). *Галиулла дөньяның әчесен-төчесен җ и т ә р л е к татыган кеше ул* (И. Гази).

4. Күләм хәлләре билгенең күләмен дә белдерәләр. Мәсәлән: *Биш ел үзе а р т ы к озын гомер түгел. Галиулла б ө т е н л ә й тозсыз аш пешергән. С а ф татарча сөйләргә кирәк. Ул – рухи яктан ш а к т ы й көчле кеше.*

5. Күләм хәлләре процесс объектының хакын белдерә. Мәсәлән: *Бу карандашларның бөтенесен* *ө ч  с у м г а* *алдык. Кыярларын* *ө ч ә р  с у м н а н  ( б е л ә н )* *биргәннәр, ә без* *д ү р т ә р д ә н* *алдык.*

6. Иярчен күләм җөмләне баш җөмләгә бәйләү хезмәтен үти торган мөнәсәбәтле сүзләр (күрсәтү һәм сорау алмашлыклары) дә күләм хәле булып киләләр. Мәсәлән: *Н и ч а к л ы* *тырышсаң,* *ш у л ч а к л ы* *күбрәк эшләнә. Бала* *н и ч а к л ы* *үссә,* *ш у л ч а к л ы* *аның мәшәкате дә арта.* *К ү п м е* *бара аласыз,* *ш у л к а д ә р* *яхшы.*

**§ 143. Максат хәле.** Процессның үтәлү-үтәлмәү, билгенең булу-булмау максатын белдерә торган кисәк максат хәле дип атала. Максат хәле түбәндәге сүзләр белән бирелә: 1) юнәлеш килешендәге исемнәр белән: *Киткән урманга* *у т ы н г а,* *ялгызы бер ат җигеп* (Г. Тукай). *С у г а* *барам. Алар* *җ и л ә к к ә* *киттеләр*; 2) инфинитив белән: *Чәй эчү ритуалын* *к а р а р г а* *күрше бүлмәләрдә яшәүче студентлар да җыелганнар* (М. Юныс). *Күзлисе идем мин энәмә ай нурын,* *Ч и г ә р г ә* *яулыкның матурдан-матурын* (Ф.Җамалетдинова); 3) *өчен* бәйлеге белән килгән исемнәр, алмашлыклар, кайбер фигыльләр белән: *Һаман көттем, ләкин эндәшмәдем,* *Д ә ш ә р  ө ч е н* *вакыт көттем мин* (Г.Рәхим); 4) *дип* сүзе белән килгән исемнәр һәм инфинитив белән: *О р л ы к к а  д и п* *чүпләгәнебез менә монысы була* (Г. Бәширов). *Күңелендәге сагышны* *б а с а р г а  д и п ,* *стенадагы скрипкасын кулына алды* (Ф. Яруллин). *Без монда* *к и н о  к а р а р г а  д и п* *килдек.*

**§ 144. Сәбәп хәле.** Процессның үтәлү-үтәлмәү яки билгенең булу-булмау сәбәбен белдерә торган кисәк сәбәп хәле дип атала.

1. *-лык/-лек* кушымчасы белән ясалган абстракт исемнәр, үткән заман сыйфат фигыльләр һәм исем фигыльләр, чыгыш килеше формасын алып, җөмләдә сәбәп хәле булып киләләр. Мәсәлән: *Ш у н л ы к т а н* *бүген дә кайнар бодай кабартмасы янында бер тәлинкә йомырка да урын алды* (Г. Бәширов). *Маймыл* *х у р л а н у д а н  һ ә м  к а й г ы с ы н н а н* *күзлекләрне таш өстенә атып бәрде* (Ә.Исхак). *Аның* *ә р н ү д ә н* *йокылары кача иде* (Г. Ибраһимов).

2. Юнәлеш килешендәге исемнәр һәм сыйфат фигыльләр сәбәп хәле булып килә алалар. Мәсәлән: *Кәҗә кычкырган* *т а в ы ш к а* *Таҗи торып чыга* (Г. Гобәй).

3. Сәбәп хәле *сәбәпле, аркасында, өчен, күрә* кебек ярдәмлекләр янында килгән сүзләр белән бирелә. Мәсәлән: *Озак* *й ө р ү  с ә б ә п-*

*л е , ул бүген бик арып кайтты. С о ң   к и л ү   а р к а с ы н д а урынсыз калдым.*

4. Сәбәп хәле *-гач/-гәч* формасындагы рәвеш фигыль белән дә бирелә ала. Мәсәлән: *А ң л а м а г а ч ,  сөйләмәдем* (Г. Ибраһимов).

**§ 145. Кире хәл.** Ияртүче кисәктән аңлашылган процессның киресе булачагын белдерә торган кисәк кире хәл дип атала.

1. Шарт фигыль, *-да/-дә* кисәкчәсен алып, җөмләдә кире хәл булып килә ала. Бу вакытта ияртүче фигыльдән һәм шарт фигыльдән аңлашылган процессны үтәүче бер үк зат булырга тиеш. Мәсәлән: *С о ң   я т с а м   д а, тиз генә йокыга китә алмадым* (Р. Вәлиев). *Галиулла, а в ы р с а   д а , эчтән тынды* (И. Гази).

2. Кире хәл *-ып/-п* формасындагы рәвеш фигыль белән бирелә. Рәвеш фигыль янында *да/дә* кисәкчәсе килә яки ул кисәкчәне куярга мөмкин була. Мәсәлән: *Ничә ел ш у ш ы н д а   т о р ы п, Алмаевның әле дә бу тирәдә булганы юк иде* (И. Гази). *Аның гаебе тагын да зур: ул бит к ү р е п   т ә  әйтмәгән. Әле без, инсаннар б у л а   т о р ы п   т а, кеше һәм гыйлемен мыегы белән киеменнән үлчибез* (Г. Тукай).

3. Кире хәл урын-вакыт килешен алган үткән заман сыйфат фигыльләр белән бирелергә мөмкин. Бу вакытта да кире хәлне формалаштыруда *да/дә* кисәкчәсе катнаша. Мәсәлән: *Син барысына да бер күзлектән карыйсың, ә беләсеңме, к ү р г ә н д ә   д ә   әйтми торган кешеләр була бит* (А. Шамов).

4. Кире хәл *карамастан* ярдәмлеге янында килгән төрле сүзләр белән бирелә. Мәсәлән: *Көннең к ы з у ы н а   д а   к а р а м а с т а н , халык җыены тагы да зурая төшкән иде. Ара-тирә яшенле я ң г ы р л а р г а   к а р а м а с т а н , һавалар берьюлы рәхәтләнеп, җылынып киттеләр* (Г. Ибраһимов).

5. Кире җөмләне баш җөмләгә бәйләүче мөнәсәбәтле сүз дә җөмләдә кире хәл булып килә. Мәсәлән: *Минем күзләрем ул хәтле җәете түгел, а л а й   д а күрәм* (Г. Бәширов). *Хәзер машиналар йөри-йөрүен, ш у л а й   д а  арырсың дип куркам. Яңгыр аз яуды, ш у ң а   к а р а м а с т а н  бездә уңыш зур булды.*

**§ 146. Шарт хәле.** Ияртүче кисәктән аңлашылган процессның үтәлү-үтәлмәвенә шарт булып тора торган процессны белдерә торган кисәк шарт хәле дип атала. Шарт хәле түбәндәге формаларда бирелә: а) үтәүчесе ияртүче фигыльнең үтәүчесе белән туры килгән шарт

фигыльләр белән: *Китсәм, кайта алмам инде* (җыр). *Барсам, алырмын*; ә) сорау кисәкчәсен алган хикәя фигыль белән: *Укыймы – сөйләп тә бирәм;* б) шарт хәле, ияртүче кисәккә *икән* бәйлек сүзе ярдәмендә иярә: *Барам икән, алып та кайтам.*

## АНЫКЛАГЫЧ

**§ 147. Гомуми мәгълүмат.** Ияртүче кисәктән соң килеп, аңа аныклык кертә торган кисәк аныклагыч дип атала. Аныклагычлар җөмләдә төрле сүз төркемнәре белән бирелгән төрле кисәкләрнең мәгънәләрен төгәлләп, аныклап киләләр. Башка иярчен кисәкләр, төгәлләүле (ачыклаулы) мөнәсәбәткә нигезләнеп, җөмлә оештыруда икенче дәрәҗәдәге урынны тотсалар, аныклагычлар, аныклаулы мөнәсәбәткә нигезләнеп, җөмлә оештыруда өченче дәрәҗәдәге рольне уйныйлар.

60 нчы елларга кадәр аныклагычлар аерым кисәк буларак өйрәнелмиләр, аларны телчеләр күп очракта бөтенләй күрмәгәннәр, яисә, кайсы кисәккә ияреп килүеннән чыгып, баш яки иярчен кисәкләрнең берсе итеп караганнар. Ә исем белән бирелгән аныклагычларны исә, аергычның бер төре итеп, өстәмә сүз термины астында тикшереп килделәр. Өстәмә сүз, үз чиратында, рус телендәге приложение белән тәңгәлләштерелде. Болай эшләү, һичшиксез, зур хата иде. Чөнки рус телендәге приложениеләр татар телендә бөтенләй юк, алар безнең телдә шул ук аергыч белән бирелә. Мәсәлән, рус телендәге *девочки-подростки, разведчики-саперы, канал Москва–Волга, старик-шахтер, полуторатонка, школа-интернат* кебек тезмәләрдәге приложениеләр татар телендә гадәти аергычлар белән биреләләр: *үсмер кызлар, сапер разведчиклар, Москва–Волга каналы, шахтер карт, бер ярым тонналы грузовик, интернат мәктәп.* Ә инде *плащ-палатка, инженер-механик, телефон-автомат* кебек приложениеле тезмәләр татар теленә шул килеш күчерелгәндә, алардагы ике сүзнең икесе ике кисәк итеп түгел, бәлки икесе дә тулы килеш бер кисәк, бер лексик берәмлек итеп танылa. Мәсәлән: *Безгә летчик-истребитель килде, үзе белән инженер-механикны да алган* дигән җөмләдә *истребитель* һәм *механик* сүзләре үзләре генә аерым кисәк итеп каралмыйлар, бәлки *летчик* һәм *инженер* сүзләре белән бергә бер берәмлек итеп танылалар.

Димәк, бу җөмләдә *летчик-истребитель* сүзе бер кисәк – ия, *инженер-механик* сүзе үзе бер кисәк – туры тәмамлык була.

Шулай итеп татар телендә приложениегә туры килә торган кисәкләр юк. Ә элекке грамматикаларда *Без, пионерлар, укуда алдынгы булырга тиешбез*; *Муса Җәлилне, Советлар Союзы Героен, искә алдык* кебек мисалларда өстәмә сүз дип йөртелә торган *пионерлар* һәм *Советлар Союзы Героен* кисәкләре чынлыкта өстәмә сүз түгелләр, чын мәгънәсендә аныклагычлар булалар, рус телендә дә андый кисәкләр приложениегә түгел, бәлки уточнениегә кертеләләр.

«Аныклагыч аерым бер кисәк була алмый, чөнки ул аныкланмыш белән бер үк сорауга җавап була, шулай булгач аның үзенә генә хас синтаксик функциясе юк» дигән фикер дә бар. Болай раслау үзенең нигезе белән үк ялгыш. Ул аныклагычны аныкланмышка түгел, бәлки аныкланмыш ияргән кисәккә каратудан килеп чыккан. Мәсәлән: *Без түбәннән, тормышның төбеннән, күтәрелдек* (Г. Ибраһимов) дигән җөмләдә *түбәннән* һәм *тормышның төбеннән* кисәкләрен икесен дә *күтәрелдек* кисәгенә каратып, аларга шуннан чыгып сорау куйсак, алар икесе дә *кайдан?* соравына җавап бирәләр һәм шуның өчен тиңдәш кисәкләр дип танылырга тиеш булырлар иде. Чынлыкта исә алар үзара тиңдәш түгелләр. Димәк, китерелгән мисалда аныклагыч та, аныкланмыш та бер үк сорауга җавап бирә дип әйтү ялгыш. Дөресе болай була: *түбәннән* кисәге турыдан-туры *күтәрелдек* кисәгенә буйсына һәм *кайдан?* соравына җавап була. *Тормышның төбеннән* кисәге исә, аныклагыч буларак, берьюлы ике кисәккә иярә: беренче чиратта аныкланмышка (ягъни *түбәннән* кисәгенә) һәм шуның аркылы – хәбәргә. Менә шуны истә тотып, *тормышның төбеннән* кисәгенә (аныклагычка) *түбәннән* кисәгеннән (аныкланмыштан) чыгып, *ягъни кайдан?* соравын куярга кирәк. Димәк, аныклагыч белән аныкланмыш икесе ике төрле сорауга җавап бирәләр, икесе ике төрле синтаксик функцияне үтиләр. Шулай булгач аныклагычның үзенә генә караган синтаксик функциясе бар һәм ул – җөмләнең аерым бер иярчен кисәге. Рус телендә дә аныклагычка туры килә торган уточнение дигән кисәк җөмләнең аерым бер иярчен кисәге итеп карала һәм югары уку йортлары дәреслегенә аерым иярчен кисәк итеп кертелә дә [Галкина-Федорук, Горшкова, Шанский, 1958, § 51, с 59; § 74, с. 88–89; § 76, с. 92–93]. Ләкин рус теленең мәктәп дәреслегендә уточнение

аерым алынмаган, аларның күбесе приложение янында каралганнар. Кайберләре башка кисәкләргә өстәмә рәвешендә генә бирелгәннәр. Приложение кисәге булганда, аның янында охшаш кисәкләрне карау мәктәп дәреслеге өчен җитә дип танылa. Ләкин хикмәт тә шунда: татар телендә аныклагычка азмы-күпме охшаган өстәмә сүз (приложение) дигән кисәк юк. Шуңа күрә рус телендә аерыммы-түгелме, аңа карамыйча, татар телендә аныклагычны аерым алып карарга туры килә.

Димәк, татар телендә аныклаулы мөнәсәбәткә кергән сүзләрнең иярүчесен аныклагыч дип аерым иярчен кисәк итеп алырга кирәк. Ул теләсә нинди сүз төркеме белән бирелгән теләсә нинди баш һәм иярчен кисәккә ияр. Аныклагыч алдыннан, аны аныкланмышка бәйләп, *ягъни, икенче төрле әйткәндә, башкача, шул исәптән, бигрәк тә, аеруча* яки *мәсәлән* сүзе килә яисә бу сүзләрнең берсен куеп карау мөмкинлеге була. Аныклагыч *ягъни* (*икенче төрле әйткәндә, башкача, шул исәптән, шул җөмләдән, бигрәк тә, аеруча* яки *мәсәлән*) сүзе белән килгән теләсә нинди сорауга җавап була: *ягъни кем? ягъни нишли? ягъни кайда? ягъни нинди? ягъни кемне?* һ.б.ш.

Кайсы сүз төркеме белән бирелүенә карап, аныклагычны ике төргә бүләләр: фигыльләр һәм фигыльдән башка сүзләр белән бирелгән аныклагычлар.

## Фигыльдән башка сүзләр белән бирелгән аныклагычлар

**§ 148. Гомуми төшенчә.** Бу төр аныклагычлар исемнәр, сыйфатлар, саннар, рәвешләр һәм алмашлыклар белән бирелгән кисәкләрне аныклыйлар. Алар фигыльләр белән бирелгән аныклагычларга караганда элегрәк тикшерелә башлаганнар, һәм шул вакытта ук инде аларга өстәмә сүз дигән исем бирелгән. Ләкин аларны аергычның бер төре дип карап ялгыш эшләгәннәр. Чөнки алар, күбрәк исем белән бирелгән кисәкләрне ачыклап килүләре белән аергычларга бераз якынлык күрсәтсәләр дә, алардан иң төп үзенчәлекләре белән бик нык аерылалар.

Аергычлардан аермалы буларак, бу төр аныклагыч: а) зат һәм күрсәтү алмашлыкларын аныклый; ә) үзе буйсынган кисәктән соң килә; б) аныкланмыш белән бергә, бер уртак кисәккә карый, шуның аркасында, кагыйдә буларак, аныкланмыш белән ярашып килә. Мәсәлән: *Батырлар үлеме белән һәлак булган пулеметчы энемә – М ә х м ү т к ә*

(Ә. Фәйзи). *Ул безнең белән без булып – б а л а л а р  б у л ы п  сөйләшә* (М. Гафури). *Ходай сулыш өргәч җан кергән бит Безгә – с ы н г а  – ү з л е  б а л ч ы к к а !* (Зөлфәт).

Ләкин аныкланмышка аерым басым ясалмаганда, ул аныклагыч белән ярашмаска да мөмкин. Мәсәлән: *Петров, үзенең юлдашы П а л а р у с о в к а* (*үзенең юлдашына – Паларусовка* түгел) *карап, урамның Иделгә чыга торган очына күрсәтте* (Г. Ибраһимов). *Һәйкәл күк торадыр Ак аю, үз иле К о т ы п н ы  күзәтеп* (Ә. Фәйзи) (*үз илен – Котыпны* түгел). *Биш ел буена барын-югын уртаклашкан дустым мин җ е б е г ә н н е* (*мине – җебегәнне* түгел) *ярдәменнән ташламас, янәсе* (М. Хуҗин).

Димәк, аныкланмышка бәйләнү ягыннан караганда, аныклагыч ике төрле: аныкланмышка ярашкан аныклагыч һәм аныкланмышка ярашмаган аныклагыч була. Ярашкан аныклагыч – аерымланып, ярашмаганы аерымланмыйча килә.

Мәгънә ягыннан да беренче төр аныклагычлар ике төрле булалар: мәгънә күләме аныкланмыш мәгънәсе белән бер үк булган аныклагыч, мәгънә күләме аныкланмыш мәгънәсеннән таррак булган аныклагыч.

**§ 149. Мәгънә күләме аныкланмыш мәгънәсе белән бер үк булган аныклагыч.** Мондый аныклагыч алдында *ягъни, икенче төрле әйткәндә* кебек сүзләр килә яки ул сүзләрне куеп карау мөмкинлеге була. Бу төр аныклагыч, аныкланмышка ярашмаска да, ярашырга да мөмкин.

1. Ярашмаган аныклагычларга мисаллар: *Аяклы тарих Я р м и  к а р т  т а , килеп, бераз утырып китте* (Г. Ибраһимов). *Ул якларын инде аның аларның башлыклары Н ә ф и с ә  үзе карый, үзе исәпләп чыгара* (Г. Бәширов). *Бәлки киявебез п р о ф е с с о р  белән миңа да Америкага китәргә туры килер* (К. Тинчурин).

2. Ярашкан аныклагычларга мисаллар: *Мин озаттым аны сугышка, Й ө р ә г е м н е ң  с ү н м ә с  к о я ш ы н* (М. Җәлил). *Шул арада, минем кайтканны ишетеп, күрше малайлар – б о р ы н г ы  д у с л а р да килделәр* (Г. Ибраһимов). *Укырга вакыт бик сирәк тисә дә, Садыйкта искедән калган бер дәрт – к и т а п  җ ы ю  д ә р т е  бик тирән иде* (Г. Ибраһимов). *Аның алдында кешеләр икегә – д у с к а , д о ш м а н г а  бүленәләр* (Г. Ибраһимов). *Бу вакыйга, я г ъ н и  (икенче*

*төрле әйткәндә) минем мәктәпкә беренче баруым, хәтеремдә мәңге сакланыр. Чөнки мин үземнең кем белән, ягъни нинди званиеле кеше белән, сөйләшкәнемне белми идем* (Г. Галиев). *Бармак белән каткан җирне казып булмый, әлифбасыз (алфавитсыз) язып булмый* (Г. Тукай).

**§ 150. Мәгънә күләме аныкланмыш мәгънәсеннән таррак булган аныклагычлар.** Бу төр аныклагыч белән аныкланмыш һәрвакыт ярашкан булалар һәм алар арасындагы бәйләнеш тезүле бәйләнешкә дә шактый якын була, ләкин монда ияртүле бәйләнеш ныграк сиземләнә. Мәсәлән: *Әйберләрне шул зур имән төбендә, күләгәдә, калдырдылар да текә ярдан, ава-егыла, зур кыенлык белән түбәнгә, Яманкүл төбенә, Фәхринең гәүдәсе табылган җиргә, төштеләр* (Г. Ибраһимов). *Садыйктан, аның Садыйккаеннан, кечкенә генә хат бар* (Г. Ибраһимов). *Казанда, Устьеда, иртәдән үк пароход пристаньнарында халык күплектән, ары-бире үтеп йөрерлек түгел иде* (Ш. Мөхәммәдев).

Мондый аныклагычның аныкланмышка бәйләнешен ныгытып, мәсәлән: *хәтта, бигрәк тә, шул исәптән, аеруча, шул җөмләдән* кебек сүзләр дә киләләр. Мисаллар: *Авыллар, бигрәк тә кара урман кебек ике тау арасында утырганнары, тагы бераз булса, бөтенләй кар астында калып югалыр мәртәбәгә якынлашканнар* (Г. Ибраһимов). *Ә кайберләре аларның, мәсәлән күмәче белән каймагы, иртәнге чәйгә үк өлгерергә тиеш* (Г.Минский). *Ул – сөйләүчеләрнең, аеруча председательнең, бер сүзен дә ычкындырмыйча ишетеп калырга тырыша иде* (А. Шамов). *Быел бөтен мәктәп, шул исәптән 7 класс укучылары, тулы өлгереш бирделәр.*

### Фигыльләр белән бирелгән аныклагычлар

**§ 151. Бу төр аныклагычларның үзенчәлекләре.** Икенче төр аныклагычлар фигыльләр белән бирелгән кисәкләрне аныклыйлар, шулай ук аерым очракларда башка сүз төркеме белән бирелгән хәбәрләрне дә аныкларга мөмкиннәр. Мәсәлән: *Моннан ике ел син яхшы идең: эшчегә кул бирергә оялмый идең* (Н. Островский) дигән мисалда икенче төр аныклагыч сыйфат белән бирелгән хәбәрне аныклый.

Икенче төр аныклагычлар аныкланмыш белән ярашкан булалар һәм һәрвакыт аерымланалар. Болар, беренче төр аныклагычлар кебек үк, мәгънә ягыннан икегә бүленәләр.

1. Мәгънә күләме аныкланмыш мәгънәсе белән бер үк булып аңлашылган аныклагыч *ягъни, икенче төрле әйткәндә* кебек сүзләр белән килә яки анда ул сүзләрне кую мөмкинлеге була. Мәсәлән: *Йөзе ап-ак, а к  д и г ә н д ә  д ә  ә л л ә  н и н д и  ү л е м  а г ы* (Г. Ибраһимов). *Кәҗә рәхмәт укый: с а к а л ы н  с е л к е т ә* (Г. Тукай). *Кызлар өй эчендә озак юанмадылар: б а к ч а г а  ч ы к т ы л а р* (Ф. Әмирхан). *Мин бер атуда ике куянны алмак булам: б и я н е  д ә  с а к л а р г а, б а л ы к  т а  т о т а р г а* (Г. Ибраһимов). *Үзе буйсынган сүздән ерак торган хәл аерымлана, я г ъ н и  (икенче төрле әйткәндә) а е р ы м  и н т о н а ц и я  һ ә м  п а у з а  б е л ә н  ә й т е л ә.*

2. Мәгънә күләме аныкланмыш мәгънәсеннән таррак булган аныклагыч *мәсәлән, хәтта, аеруча, бигрәк тә, шул исәптән* кебек сүзләр белән килә яки аныклагыч янына шул сүзләрнең берсен кую мөмкинлеге була. Мәсәлән: *Җәйгә чыккач, буш вакытын гел шунда чокчынып үткәрде: б а к ч а с ы н  т а ш т а н  а р ы н д ы р ы п, а л м а г а ч л а р н ы ң  т ө б е н  к а б а р т т ы, б о т а к л а р ы н  к и с т е, с у  с и п т е...* (И. Гази). *Ул, үзенең кайгысын басар өчен, нәрсәләр генә эшләмәде, ш у л  и с ә п т ә н  б и к  к ү п  к и т а п  т а  у к ы п  ч ы к т ы. Аның ашыкмыйча гына, б и г р ә к  т ә  х у җ а л а р ч а  җ е н т е к л ә п, эшләгәне әллә кайдан сизелеп тора иде.*

## МОДАЛЬ КИСӘКЛӘР

**§ 152. Гомуми мәгълүмат.** Сөйләүченең чынбарлыкка, тыңлаучыга, җөмлә эчтәлегенә, төзелешенә мөнәсәбәтен белдерә торган кисәкләр җөмләнең модаль кисәкләре дип аталалар. Боларга, традицион исемнәре белән атаганда, эндәш һәм кереш сүзләр керә. Элекке грамматикада аларны җөмлә кисәкләре түгел, чөнки җөмлә кисәкләренә грамматик юл белән (ярашу, башкарылу, янәшәлек юлларының берсе белән) бәйләнмиләр дип исбатлыйлар иде. Хәтта кереш һәм эндәш сүзләрне төшереп калдырсаң да, җөмлә үзгәрешсез кала дип сәбәп табалар иде. Болай эшләү гамәли яктан да, теоретик яктан да зур хата иде. Чөнки, беренчедән, кереш яки эндәш сүзне (шулай ук,

теләсә нинди иярчен кисәкне дә) төшереп калдырсаң, гомумән җөмләлек саклана. Мәсәлән: *Сабир, кил бире! – Кил бире! Алдынгы студентлар грамота белән бүләкләнделәр. – Студентлар бүләкләнделәр.* Ләкин баштагы җөмлә шул килеш сакланмый, бөтенләй икенче төрле җөмлә барлыкка килә. Сөйләмдәге реаль җөмләнең нинди генә элементын төшереп калдырсаң да, ул җөмлә бозыла, сакланмый, автор әйтергә теләгән фикерне бирә алмый. Аннан соң гомумән «төшереп калдыру» методы җөмләне грамматик яктан бербөтен итеп тануны юкка чыгара.

Икенчедән, сүзләр арасындагы грамматик бәйләнеш ярашу, башкарылу, янәшәлектән генә тормый, дөресрәге, грамматик бәйләнешне бу өч төргә генә бүлү чынбарлыкка туры килми. Чынлыкта сүзләрне бәйләүче чаралар бик күп: кушымчалар, бәйлекләр, бәйлек сүзләр, теркәгеч, теркәгеч сүзләр, интонациянең бик күп төрләре, сүз тәртибе, лексик мәгънә һ.б. Эндәш һәм кереш сүзләр күбрәк интонация (сирәгрәк кушымчалар) ярдәмендә гомумән җөмләгә яисә аның берәр кисәгенә грамматик буйсынып киләләр.

Шулай итеп эндәш һәм кереш сүзләр җөмләгә эчтәлек ягыннан да, форма ягыннан да органик бәйләнгән тулы хокуклы кисәкләр булалар, һәм аларны җөмләнең модаль кисәкләре исеме астында өйрәнәләр дә. Рус галимнәре Е.В. Кротевич һәм А.Г. Рудневлар да бу кисәкләрне җөмләнең аерым тулы хокуклы кисәкләре дип саныйлар.

## Эндәш сүз

**§ 153. Эндәш сүзләрнең үзенчәлекләре**. Сөйләм төбәлгән затны, әйберне белдерүче сүзләр эндәш сүзләр дип аталалар. Алар сөйләүченең тыңлаучыга яки гомумән табигать күренешләренә мөрәҗәгатен, мөнәсәбәтен белдерәләр. Эндәш сүзләр бик күптөрле стильләрдә (хатларда, лозунгларда, речьләрдә, матур әдәбиятта һ.б.) кулланыла. Ләкин аның иң күп кулланылган урыны – диалоглар. Эндәш сүзләр һәрвакыт икенче затка караган җөмләләрдә булалар. Эндәш сүзләр булып, төрле исемнәр киләләр.

1. Кеше исемнәре эндәш сүз булып килә. Мәсәлән: *Кучәрбай, сиңа ни булды? Нишләттеләр сине?* (М. Әмир).

2. Кеше исемнәре янында *апа, абый, әби, бабай, энем, сеңелем, туташ, ханым* кебек мөрәҗәгатьне, туган-тумачалыкны яки якынлыкны

белдерүче сүзләр килеп ясалган эндәш сүзләр дә телдә бик күп очрый. Мәсәлән: *Галиулла бабай, бу алмаларны сездә ничек атыйлар?*

3. Гомумән кешеләргә карата әйтелә торган сүзләр эндәш сүз булып киләләр. Мәсәлән: *Әсин, сөекле дускаем, миңа караганда да күбрәк күргәнсең икән* (М. Максуд). *И сабыйлар, эшләгез сез...* (Г. Тукай). *Син гөл идең, сеңлем, Һичбер кайчан Шиңмәс гөле ерак үткәннең* (Н. Гамбәр). *Аһ, яшьләр, бәгырьләрем, Яшерен сагынуларның, Яшерен сагышларның сез Белегез кадерләрен!* (Зөлфәт).

4. Кош-корт һәм хайваннарны атаучы сүзләр эндәш сүз булып киләләр. Монда ике очрак була: а) кош һәм кайбер хайваннарны атаучы сүзләр, кешеләргә карата иркәләү сүзләре буларак әйтелеп, эндәш сүз булып киләләр: *Әйтче, кошчыгым, сине кем җәберләде? Утырдым яшел вагонга, карыйм тәрәзәсеннән. Күбәләгем, түгәрәгем, асыл кошым, сандугачым, хатлар көтәмен синнән* (Ф. Кәрим). *Әй, чыпчык, кил бире, менә сиңа тагын бирәү* (А. Шамов). *Колынкаем, син барып йокла инде* (Г. Ибраһимов); ә) кош-корт, хайван, җәнлекләргә атап әйтелгән сүзләр дә эндәш сүзләр булалар: *Курыкмагыз, кошлар, күреп сез янызгызда мин барын!* (Г. Тукай). *И бүре, бүре! Син соры йонлы булсаң, мин ак сакаллымын!* (Г. Тукай).

5. Җансыз предметларны, төрле табигать күренешләрен атаучы сүзләр дә эндәш сүз булып килә алалар. Мәсәлән: *Ах, җырлар, җырлар, сез кеше йөрәген нәрсә генә эшләтмисез! Юлларымның башы синдә, урман!* (Һ. Такташ). *Син шаһит бул, кояш, язгы кояш, аккан каннарыма тезләнеп, мин ант итәм!* (Ф. Кәрим). *Сау бул инде, минем туып үскән илем; Сау булсыннар урман, басу, кырларым; Сау бул, даннар тоткан сабан туйларым!* (Т. Гыйззәт). *Синме бу, көз, мине уятучы?* (Зөлфәт).

Эндәш сүзләр, кагыйдә буларак, җөмләнең гомуми интонациясеннән аерып әйтеләләр. Җөмлә башында килгән эндәш сүз зуррак пауза белән, җөмләдән соң килгән эндәш сүз кыскарак пауза белән башка сүзләрдән аерылып тора. Җөмлә уртасында килгән эндәш сүз ике яктан пауза белән аерыла һәм җөмләнең гомуми интонациясен икегә бүлеп, үзе бер интонацион бөтен тәшкил итә.

Эндәш сүзләр, күбрәк, җөмлә белән бергә киләләр. Кайбер эндәш сүзләр җөмләләрдән тыш та килергә мөмкин. Андый эндәш сүзләр,

күбрәк, кеше исемнәрен үпкәләгән, хәтер калган, шатланган тонда әйтү аркылы ясалалар яки кешенең билгеле бер урында булу-булмавын белү өчен әйтелгән исемнәрдән торалар. Мәсәлән: *Әхмәт!* (нишләвең бу мәгънәсендә); *Сафия! – ди Зариф, Сафия тавыш бирми, Зариф тагын кабатлый: Сафия!* Бу вакытта эндәш сүзләр мөрәҗәгать (вокатив) җөмләгә якынаялар.

## Кереш сүзләр

**§ 154. Гомуми мәгълүмат.** Кереш сүзләр сөйләүченең сөйләм эчтәлегенә, төзелешенә һәм сөйләм обстановкасына мөнәсәбәтен белдерәләр.

Кереш сүзләр җөмләнең интонациясеннән бик нык аерылмыйлар. Аларны бүлеп торучы паузалар да бик аз була, ә җөмләнең аерым кисәгенә караган кереш сүзләр шул кисәктән бернинди пауза белән дә аерылмыйлар, алар бер синтагма басымы эчендә калалар. Мәсәлән, *Ул, бәлки, безгә килер* җөмләсендә *бәлки* кереш сүзе *безгә* кисәгенә карый һәм аннан пауза белән аерылмый, ләкин *бәлки* алдыннан аз гына пауза ясала. Димәк, кереш сүзләр интонацион яктан аерымланган ияргән кисәкләрдән һәм эндәш сүзләрдән аерылалар. Кереш сүз бер генә сүз белән дә һәм сүзләр тезмәсе белән дә бирелергә мөмкин. Соңгыларын кереш тезмәләр дип тә йөртәләр.

Кереш сүзләрне ике яклап төркемлиләр: нинди сүз белән бирелүенә һәм мәгънәсенә, ягъни җөмләгә нинди модаль мәгънә бирүенә карап.

**§ 155. Кереш сүзләрнең төрле сүз төркемнәре белән бирелүе.** Нинди сүз белән бирелүенә карап, кереш сүзләр ике төркемгә бүленәләр: а) теге яки бу сүз төркеменнән аерылып, башлыча кереш сүз булып йөрүгә күчкән һәм морфологиядә модаль сүзләр дип йөртелә торган сүзләр белән бирелгән кереш сүзләр һәм ә) кереш сүздән башка синтаксик функцияләрне үти алырлык сүзләр белән яки ияртүче кисәге шундый сүз булган сүзтезмәләр белән бирелгән кереш сүзләр. Беренче төр кереш сүзләр түбәндәге сүзләр белән биреләләр: *ниһаять, ахрысы, әлбәттә, янәсе, имеш, ихтимал, зинһар, ичмасам, гомумән, бәлки, каһәр, шайтан, ләгънәт, ягъни мәсәлән, валлаһи*. Мисаллар: *Поезд кузгалып гөрләп китте, без, ә л б ә т т ә , калдык* (Ш. Камал). *Гүя ул гимназист и м е ш , имтиханга хәзерләнә и м е ш* (Ш. Камал).

*Н и һ а я т ь , бер көнне Гаяз тантаналы итеп әйтте: менә хәзер инде сез чын бакчачылар!* (И. Гази). *Син бит инде, ә л б ә т т ә, я г ъ н и м ә с ә л ә н , йорт башы – ата урынындагы кеше бит* (Ш. Камал). *Бу эш барып чыкмас а х р ы с ы , хәерсез. Әйтче, з и н һ а р , кайдан шулкадәр хатлар аласың?* (Ф. Әмирхан). *Ләкин, ш ө к е р , бар күңелдә Кадерле яшереннәр...* (Зөлфәт). *Чынны саткан кемдер, б ә л к и, яла ягар, арттан кадар* (Р. Фәйзуллин).

Икенче төр кереш сүзләр, кайсы сүз төркеменнән булуларына карап (кереш тезмәләр, ияртүче кисәкнең кайсы сүз төркеменнән булуына карап), берничә төргә бүленәләр.

1. Исем белән яки ияртүче кисәге исем булган сүзтезмәләр белән бирелгән кереш сүзләр (*бәхеткә каршы, оятка каршы, нигездә* һ.б.): *Имәли бөтен җыелышның ямен бетерер кебек тоелды, ләкин, б ә х е т к ә  к а р ш ы , Имәли үзен бөтенләй көтелмәгәнчә тотты* (М. Әмир). *Мисаллар, н и г е з д ә , үз урыннарында калалар.*

2. Сыйфатлар белән бирелгән кереш сүзләр (*билгеле, табигый* һ.б.): *Т а б и г ы й , кергәндә – «исәнме»-«саумы», чыкканда – «сау бул, исән бул»* (Ш. Камал). *Б и л г е л е , бу кап-кара урманда һәр ерткыч та бар* (Г. Тукай).

3. Алмашлыклар белән бирелгән кереш сүзләр (*никтер, ни өчендер* һ.б.): *Һәм баса, н и к т е р , аяклар да кыек* (Г. Тукай). *Иптәш, н и ө ч е н д е р , элек ике кулы белән дә башындагы бүреген тотып карады* (Ш. Камал).

4. Саннар белән бирелгән кереш сүзләр (*беренчедән, икенчедән..., бердән* һ.б.ш.): *Б е р д ә н , атлар арыдылар, и к е н ч е д ә н , караңгы төште, ө ч е н ч е д ә н , яңгыр ява.*

5. Рәвешләр белән бирелгән кереш сүзләр (*минемчә, аныңча, үзеңчә, дөрес, белгәнчә* һ.б.): *М и н е м ч ә, җыелышны иртәгә ясарга кирәк. Д ө р е с , «Садун»да унлап татар бар иде* (Ш. Камал). *Чөнки Гайфулла абзый ул, б е л г ә н е м ч ә , йомшак табигатьле, сөйкемле кеше иде* (Ш. Камал). *Д ө р е с р ә г е , ул бер якны да якламады, ә шөбһәләнде генә* (И. Гази).

6. Фигыль белән бирелгән кереш сүзләр (*күрәсең, әйтик, алыйк, әйтергә кирәк, әйтергә мөмкин* һ.б.): *Ә син минем күңелдә аккош булып йөзәсең, тик күңелнең чиге юк, күңел – диңгез, к ү р ә с е ң !* (Ф. Кәрим).

**§ 156. Кереш сүзләрне мәгънә ягыннан төркемләү.**

1. Җөмләдә бирелгән фикернең сөйләүче тарафыннан дөрес дип, шикләнмәслек дип танылуын күрсәтүче кереш сүзләр (*чынлап та, әлбәттә, шөбһәсез, билгеле, бәхәссез, дөрес, шиксез, һичшиксез* һ.б.): *Соңгы сүзләрне ул, әлбәттә, әйтмәде, ә уйлап кына калды* (И. Гази). *Таң җиледәй мондый күз карашы Караш кына түгел, билгеле!* (Зөлфәт). *Дөрес, ул ишеткән иде, Идел буендагы алма бакчалары өшегән, дип сөйләгәннәр иде* (И. Гази). *Габделхак әфәнде, чынлап та, сез шулай җәберсенәсезмени?* (Ш. Камал).

2. Сөйләүченең фикерне шикләнебрәк, чама белән генә әйтүен белдерүче кереш сүзләр (*ахрысы, никтер, ни өчендер, бәлки, ихтимал, күрәсең, шәт* һ.б.): *Егет, бәлки, алтынчы ел сугышта йөри торгандыр, аңар әллә кавын ашап карарга да ярамыймы* (А. Шамов). *Ихтимал, ул бүген-иртәгә кайтып та җитәр.*

3. Үтенүне белдерүче кереш сүз (*зинһар*): *Кара аны, начар укып, зинһар, әтиеңнең йөзенә кызыллык китерәсе булма* (И. Гази).

4. Әйтелгән фикернең чыганагын белдерүче кереш сүзләр (*минемчә, синеңчә, аныңча, минем уемча* һ.б.): *Синеңчә, иген чәчүне ташла да, бөтен кырга алмагач утырт* (И. Гази). *Минемчә, Гаяз мәсьәләне бик урынлы һәм бик дөрес куя* (И. Гази).

5. Сөйләүченең җөмләдәге фикерне күптән билгеле, гадәттәге фикер итеп каравын белдерүче кереш сүзләр (*табигый, гадәттәгечә, кабул ителгәнчә, гадәт буенча, билгеле булганча* һ.б.): *Гадәттәгечә, төн бераз салкын була бирedә.*

6. Әйтелгән фикерләрнең үзара мөнәсәбәтен күрсәтүче кереш сүзләр. Бу группага керә торган кереш сүзләр җөмләнең теге яки бу өлешләрен аерып күрсәтү һәм ачыклау өчен, аларны бер-берсенә каршы кую өчен, чагыштырып карау өчен, җөмләнең аерым кисәкләрен бәйләү өчен, кайчандыр сөйләнгән фактны хәтергә төшерү өчен, йомгаклау, сүзне тәмамлау, әйтелгәннәрне гомумиләштерү өчен, хәбәр ителә торган фактларның тәртибен һәм аларның әһәмиятле булу дәрәҗәсен күрсәтү өчен хезмәт итәләр (*мисал өчен, ниһаять, өстәвенә, өлешчә, иң мөһиме, гомумән, шуның белән бергә, киресенчә, моңа каршы буларак, беренчедән, икенчедән, әйтик, фараз итик, бер яктан, икенче яктан* һ.б.): *Кыскасы, телеграфистларга борылырга да вакыт юк* (И. Гази). *Инде, әйтик, безнең бәхет басып, Май*

*җылы килде* (И. Гази). *Н и һ а я т ь , ата-бабалар белән эшне бетергәч, доктор Катяның үзенә күчте* (И. Гази). *Левинсон Метелицаны хәрәкәтләнми торган итеп, г о м у м ә н , аны яшәми торган итеп, һич тә күз алдына китерә алмый* (А. Шамов). *Б е р д ә н , күптәннән күңелемне биләп йөргән кызның безнең фикерләргә кушылып китүе; и к е н ч е д ә н, Гаязның – минем ышанычлы иптәшемнең – янымда булуы, ө ч е н ч е д ә н , бу волостьның иң зур кешесе Аязгуловның бик нык игътибар белән тыңлап торуы – мине батырайттылар* (М. Әмир). *Бу йортларга яңалык кирәк кадәр генә керә һәм искелекне тар-мар итми, к и р е с е н ч ә , аны кадерләп, түргә утыртып куя* (М. Юныс).

7. Тыңлаучыны җәлеп итә торган яки хәбәр ителгән фактка игътибар иттерә торган кереш сүзләр. Мондый кереш сүзләр үз мәгънәләре белән ымлыкларга да һәм эндәш сүзләргә дә якын торалар (*беләсең килсә, әйтсәм әйтим, кара әле, тыңла, гафу ит* һ.б.): *Т у к т а   ә л е , безнең хәл, сезнең хәл дигән булып, син нәрсә әйтмәкче буласың!* (Ш. Камал). *К а р а   и н д е , адәм баласына шулай ук әйтергә ярыймы соң инде?* (Ш. Камал). *Ә й т с ә м   ә й т и м , син белеп кал, чын атым Былтыр минем!* (Г. Тукай). *Көнем дисәм, ялгыш, әллә төн бу: Т у к т а , минме соң бу, әллә кем бу?* (М. Әгъләм).

8. Фикернең әйтелү ысулларына сөйләүченең мөнәсәбәтен белдерүче кереш сүзләр. Болар сөйләүченең сөйләм стиленә аерым сүзләр сайлавына карата булган мөнәсәбәтен белдерәләр (*турысын әйткәндә, боргаланмый әйткәндә, иң яхшысы, дөресрәге* һ.б.ш.): *Д ө р е с е н   г е н ә   ә й т к ә н д ә , аның үзенең дә мондый зур бакча утыртуда катнашканы юк иде* (И. Гази). *Р у с ч а   и т е п   ә й т к ә н д ә , аның үз исеме дә «учитель» булып чыга иде шул* (Ш. Камал).

**Искәрмә:** *Әйткәндә* формасындагы сүзләрнең җәенкеләнү юлы белән бирелгән тезмәләр кереш сүз белән бер составлы иярчен шарт җөмлә арасында торалар.

9. Сөйләүченең төрле тойгыларын белдерүче кереш сүзләр (*бәхетсезлеккә каршы, бәхеткә каршы, кызганычка каршы, имеш, янәсе, ичмасам, валлаһи* һ.б.): *Соңгы вакытта, б ә х е т с е з л е к к ә   к а р ш ы , ни рәтләп ат саткан кеше юк, ни рәтләп алучысы юк* (Ш. Камал). *Я н ә с е , Гыймади бакча утыртуга каршы түгел, ул бары Гаязның планына гына каршы; Я н ә с е , җилгә китәсе инде ул бакча; бәрәңгене, и ч м а с а , базга күмеп куясың да җаның тыныч* (И. Гази). *Ә л е г е*

*д ә   б а я г ы , шушы үзебезнең тау башы хакында...* (И. Гази). *Х ә е р , бер-ике чишмә кисәгенең җаны да бар бугай* (И. Гази). *Ну, в а л л а һ и , шушы малайларны!* (Г. Ибраһимов).

Сөйләүченең төрле тойгыларын белдереп, җөмләдә ымлыклар да киләләр һәм алар гомумән җөмләгә, сирәгрәк, аерым бер кисәгенә интонация ярдәмендә грамматик бәйләнәләр. Шуңа күрә аларны да кереш сүзләрнең аерым бер төре итеп карыйлар. *Ай-һай, ялгышмабызмы икән?!* (шикләнү, икеләнү). *Уф, арыдым. Их, нинди матур көн!* Аваз ияртемнәре, төрле кош, хайван тавышларына иярү белән ясалган ымлыклар мондый функцияне үти алмыйлар.

## СТРУКТУР ҺӘМ СЕМАНТИК КИСӘКЛӘР

**§ 157. Гомуми мәгълүмат**. Сөйләм берәмлекләреннән җөмлә иң катлаулысы санала. Мәсәлән, сүз төзелеше үтә күренүчән. Сүзтезмә төзелеше, кимендә ике мөстәкыйль сүзнең төзелешен эченә алган хәлдә, бу сүзләрнең үзара бәйләнеш чараларыннан һәм алар арасындагы гаҗәеп күп мәгънә мөнәсәбәтләреннән (семантик бәйләнешләреннән) тора. Җөмлә төзелеше исә күп сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең бергә оешуыннан ясала, шуңа күрә ул гаҗәеп катлаулы була. Бу төзелешне бүгенгә кадәр бер генә телдә дә тикшереп бер фикергә килә алмаганнар әле; тикшерү юллары да ачыкланып җитмәгән. Дөресрәге, җөмлә төзелешен тикшерүдә күптөрле юнәлешләр, алымнар барлыкка килгән, алар турында китапның кереш бүлегендә ачык әйтелде.

Җөмлә төзелешен тикшерүнең төренә карап, аның кисәкләргә бүленешен дә төрле юнәлештә башкаралар. Без югарыда җөмләнең күп телләрдә кабул ителгән логик-грамматик кисәкләргә бүленеше белән таныштык: ия, хәбәр, тәмамлык, аергыч, хәл, аныклагыч, эндәш сүз, кереш сүз. Бу кисәкләрне форма һәм эчтәлек ягыннан тикшереп чыктык. Ләкин һәрбер кисәкнең лексик мәгънәсенә кадәр төшмәдек. Мәсәлән, *Бала сөйли* җөмләсендә хәбәрнең мәгънәсе эш-хәрәкәтне белдерү дип чикләндек, аның лексик яктан әйтү-сөйләү мәгънәсе бар дип әйтеп тормадык. Сүздәге мондый **әйтү, уйлау, хәрәкәт, йөрү,**

**кайгыру, сөенү** һ.б. шундый мәгънәләрне лексика фәне өйрәнә. Традицион синтаксис аларга гадәттә кагылмый.

Барлык шундый лексик һәм грамматик мәгънәләрне бергә җыеп өйрәнүне семантик синтаксис башкара.

Семантик синтаксис традицион синтаксиста кабул ителгән ия, хәбәр, тәмамлык, аергыч, хәл, кереш сүз, эндәш сүз кебек кисәкләрне танымый, ул, беренчедән, аларны белдерүче сүз төркемнәре һәм аларның формалары белән, икенчедән, алар белдергән мәгънәләр (семантика) белән эш итә. Бу төр синтаксис иянең семантик ягын – субъект, хәбәрнең семантикасын – предикат, тәмамлыкның семантик ягын – объект, аергычныкын – атрибут, хәлнең семантик ягын ачыклагыч (квалификатор яки конкретизатор) тәшкил итә дип өйрәтә, һәм аларның лексик-синтаксик мәгънәләрен ача. Ләкин семантик синтаксисның хәзергә кадәр модаль кисәкләргә (кереш һәм эндәш сүзләргә), аныклагычларга чын-чыннан килеп җитә алганы юк әле. Җөмлә кисәкләре бөтен тулылыгы белән хәзергә грамматик синтаксиста өйрәнелә.

**§ 158. Структур кисәкләр турында.** Әле генә әйтелгәнчә, җөмләне структур дигән кисәкләргә бүлү ул синтаксисның морфологиягә төшеп эшләве дигән сүз. Традицион синтаксис та морфологик дәрәҗәгә төшеп эш итә, ләкин ул анда җөмлә кисәкләре аркылы төшә. Мәсәлән, *Бала мәктәпкә бара* җөмләсендә *Бала* – ия, ул баш килештәге исем белән бирелгән, хәрәкәттәге субъектны (үтәүчене) белдерә; *бара* – хәбәр, ул төп юнәлештәге хәзерге заман хикәя фигыль белән бирелгән, III зат, берлек санда, ия турында яңалык хәбәр итә һәм сөйләүченең хәбәр ителә торган күренешкә чагыштырмача битараф каравын (битараф модальлеген) белдерә; *мәктәпкә* – урын хәле, юнәлеш килешендәге исем белән бирелгән, субъектның юнәлү урынын атый. Шулай итеп бу җөмләдә ия, хәбәр, урын хәле бар дигәч, аларның форма ягы да һәм семантик ягы да әйтелә булып чыга.

Структур кисәкләрне билгеләгәндә исә, ия, хәбәр, тәмамлык, аергыч, хәл әйтелми, бары аларны белдергән морфологик категорияләр генә исәпкә алына. Әле генә китерелгән *Бала мәктәпкә бара* җөмләсендә түбәндәге структур кисәкләр күрсәтелә: *бала* – баш килештәге исем, *мәктәпкә* – юнәлеш килешендәге исем, *бара* – берлек сандагы, III заттагы хикәя фигыль, төп юнәлештә, хәрәкәт белдерә.

Күренә ки, структур кисәкләрне билгеләгәндә, аларның семантикалары әйтелми, ләкин җөмлә калыпларын (модельләрен) билгеләгәндә, аларның мәгънәләре семантик кисәкләр аркылы күрсәтеләләр.

Структур кисәкләр грамматик кисәкләрнең бары форма ягына туры киләләр, мәгънә ягы семантик кисәкләр буларак билгеләнәләр. Шуңа күрә структур кисәкләр һәрчак семантик кисәкләр белән бергә өйрәнеләләр.

Рус синтаксис фәнендә структур кисәкләрне, сүз төркемнәренең латинча атамаларыннан чыгып, бер-ике хәреф белән күрсәтәләр. Мәсәлән, *N* – исемне белдерү өчен кулланыла (латин. *nomen* – исем), әгәр исем баш килештә икән, аны $N_1$ дип күрсәтәләр, бу – исем баш килештә дигән сүз була, чөнки баш килеш килешләр системасында беренче урында тора. *Adj* – сыйфат (латин. *adjectivum*) *Vf* – затланышлы фигыль (латин. *verbum finitum*); $Vf_{3pl}$ – затланышлы фигыль III затта, күплектә (күплек – латин. *pluralis*) һ.б. *Урман шаулый* җөмләсенең структур кисәкләрен без, латинча атамалардан чыгып, түбәндәгечә язарга тиеш булабыз: $N_1$-*Vf* [Русская грамматика, 1982, с. 93].

Татар теленең русча язылган академик грамматикасында без структур кисәкләрне, русча атамаларыннан чыгып, кириллица хәрефләре белән күрсәткән идек: *С* – имя существительное, *Г* – глагол, *Пр*. – прилагательное, *М* – местоимение һ.б. Килешләрне, затларны сан белән түгел, ә кушымчаларның үзләрен язып бирдек [Татарская грамматика, 1995, с. 290].

Академик синтаксисны татарча язганда, структур кисәкләрне латинча да түгел, русча да түгел, ә татарча әйтелешләре буенча күрсәтергә кирәк таптык. Мәсәлән:

*И* – исем,

*С* – сыйфат,

*Сан* – сан,

*Ф* – фигыль,

*А* – алмашлык,

*Р* – рәвеш,

*Ым* – ымлык.

Хәбәрлек һәм модаль сүзләргә, ярдәмче фигыльләргә, бәйлекләр һәм бәйлек сүзләргә, теркәгечләргә шартлы билгеләр кулланылмый, алар үзләре языла.

Сүзләрне бәйләүче чаралар, юнәлеш кушымчалары, фигыль формалары шулай ук үзләре язылалар, сан белән дә, шартлы билгеләр белән дә бирелмиләр.

Кайбер сүз төркемнәренең төрләре, татарча атамаларыннан чыгып, шартлы билгеләр белән күрсәтеләләр:

*зА* – зат алмашлыгы, *кА* – күрсәтү алмашлыгы, *бА* – билгеләү алмашлыгы, *сА* – сорау алмашлыгы, *юА* – юклык алмашлыгы.

*С* – төп дәрәҗәдәге сыйфат, *чС* – чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфат (*җиңелрәк*), *аС* – артыклык дәрәҗәсендәге сыйфат (*коп-коры*), *кС* – кимлек дәрәҗәсендәге сыйфат (*кызгылт*).

*Сан* – төп сан (*биш*), *бСан* – бүлем саны (*бишәр*), *чСан* – чама саны (*бишләп*), *тСан* – тәртип саны (*бишенче*), *җСан* – җыю саны (*бишәү*).

*бР* – билге рәвеше, *хР* – хәл рәвеше.

Фигыльләрдәге төп категорияләрнең кушымчалары үзләре күрсәтелә, зат күрсәтергә кирәк булганда, 1, 2 яки 3 саннары кулланыла. *Ф-рга* – инфинитив, *Ф-н-ды* – кайтым юнәлешендәге үткән заман, III зат, берлектәге фигыль һ.б.

Структур кисәкләрне билгеләүне мисалларда күрсәтик:

*Рөстәм Ильяс белән сөйләште*
*И – И белән – Ф-ш-те*

*Бала мәктәпкә бара*
*И – И-кә – Ф-а*

*Галия иртүк торып юынды*
*И – Р – Ф-п – Ф-н-ды*

*Ул куркып урманга таба чапкан иде*
*зА – Ф-п – И-га таба – Ф-кан иде*

*Ул иртәгә эшкә чыгарга булган*
*зА – Р– И-кә – Ф-рга булган*

*Камил Шамилдән хат яздырып алды*
*И – И-дән – И – Ф-дыр-п алды*

Мондый анализ гамәлдә семантик кисәкләргә таркату белән берьюлы башкарыла һәм җөмләләрнең структур-семантик модельләрен билгеләү өчен хезмәт итә.

**§ 159. Семантик кисәкләр турында.** Югарыда әйтелгәнчә, семантик кисәкләр дип, грамматик кисәкләрнең бер өлеше – формадан (структурадан) тыш, бары мәгънәгә (семантикага) караган өлеше генә алына. Традицион синтаксиста бары грамматик мәгънәләргә игътибар ителсә, семантик синтаксиста бу семантик кисәкләрнең лексик мәгънәләре дә исәпкә алына.

Җөмләдә семантик кисәкләр дип, рус грамматикаларында **субъект, предикат** (яки предикативный признак), **объект, атрибут** таныла. Соңгы елларда исемнәр белдергән әйберләрне ачыклаучыларны **атрибут** дип, фигыль һәм сыйфатлар белдергән төшенчәләрне ачыклаучыларын **квалификатор** яисә **конкретизатор** дип атый башладылар. Күренә ки, семантик синтаксистагы бу семантик кисәкләр грамматик синтаксистагы ия, хәбәр, тәмамлык, аергыч, хәл дигән традицион кисәкләргә туры киләләр. Русчада да аларның традицион исемнәре – подлежащее, сказуемое, дополнение, определение, обстоятельство.

Традицион грамматик кисәкләрнең семантик кисәкләрдән аермасы шунда: ия, хәбәр, тәмамлык, аергыч, хәл дигән грамматик кисәкләрдә форма да (структура да) һәм эчтәлек тә (семантика да) исәпкә алына, ә семантик кисәкләрдә – бары семантика гына (мәгънә генә) тикшерелә. Шуңа күрә семантик кисәкләрнең исемнәре гомуми тел гыйлемендәгечә алына, татарчага тәрҗемә ителми. Бары квалификатор (яки конкретизатор) дигән терминны гына **ачыклагыч** дип алырга булдык.

Семантик кисәкләрне тикшерү җөмләнең семантик структурасын (төзелешен) ачу өчен дип эшләнә. Көнбатыш Европа халыклары телләрендә, аларга ияреп рус телендә дә җөмлә структурасын билгеләүгә бик зур әһәмият бирәләр. Җөмләнең семантик структурасы дип, андагы кисәкләрнең лексик һәм грамматик мәгънәләреннән оешкан гомуми абстракт мәгънәсенә әйтәләр. Җөмләнең һәрбер калыбына аерым абстракт мәгънә хас.

Җөмләдә семантик предикат һәм семантик субъект иң төп кисәкләр саналалар. Шушы хәлиткеч төркемгә объектны да кертү күп кенә телләрдә кабул ителгән. Атрибут (грамматик синтаксистагы аергыч һәм хәл) семантик кисәкләр арасында икенче дәрәҗәдә тора дип карау гадәткә кергән.

Семантик кисәкләр грамматик кисәкләрдән аерып карала, чөнки кайбер очракта бер үк җөмләдә алар бер-берсенә туры да килмиләр.

Мәсәлән, *Шалтыраталар* җөмләсендә бер генә грамматик кисәк бар: хәбәр, ягъни бер составлы җөмләнең бер баш кисәге. Семантик яктан караганда, монда ике кисәк санала: билгесез субъект һәм аның предикаты.

Гомуми тел гыйлемендә семантик кисәкләрне дә шартлы билгеләр белән күрсәтү кабул ителгән. Татар грамматикасында без аларны түбәндәге шартлы билгеләр белән күрсәтәбез.

*Пре.* – предикат, аның төрләре предикатны белдерүче сүзнең лексик мәгънәсеннән чыга: *хәрПре.* – хәрәкәт предикаты, *йөрПре.* – йөрү предикаты, *сизПре.* – сизү-тою предикаты, *аңлПре.* – аңлату-сөйләү предикаты һ.б.

*Суб.* – субъект. Болары да, предикатның лексик мәгънәсеннән чыгып, төрләргә бүленәләр: *хәрСуб.* – хәрәкәт субъекты, *сизСуб.* – сизү субъекты, *тоюСуб.* – тою субъекты, *аңлСуб.* – аңлату субъекты.

*Об.* – объект. Бу да, иярт үче фигыльнең лексик мәгънәсенә карап, төрләргә бүленә: *сизОб.* – сизү объекты, *хәрОб.* – хәрәкәт объекты һ.б.

*Ат* – атрибут һәм аның күп төрләре.

*Ач* – ачыклагыч, ягъни квалификатор яки конкретизатор.

Семантик синтаксиста семантик кисәкләрне менә шул шартлы билгеләр белән күрсәтеп, һәрбер җөмләне формула итеп язу кабул ителгән:

*Рөстәм Ильяс белән сөйләште*
*аңлСуб. – аңлОб. – аңлПре.*

*Бала мәктәпкә бара*
*йөрСуб. – юнАч. – йөрПре.*

*Галия иртүк торып юынды*
*хәрСуб. – вакАч. – хәрПре.*

*Ул, куркып, урманга таба чапкан иде*
*йөрСуб. – рәвАч. – юнАч. – йөрПре.*

*Ул иртәгә эшкә чыгарга булган*
*ниятСуб. – вакАч. – йөрОб. – ниятПре.*

*Камил Шамилдән хат яздырып алды*
*аңлСуб. – аңлОб. – төшОб. – аңлПре.*

Семантик кисәкләрне бу рәвешчә таркатып язу педагогик максатларда гына кулланыла. Ул гадәттә структур кисәкләр белән параллель алгебраик формулага охшатып языла һәм җөмләнең структур-семантик модельләрен билгеләү өчен кулланыла.

**§ 160. Предикат һәм аның төрләре.** Предикат, семантик кисәк буларак, һәрчак хәбәрлекне белдерә. Предикатны, икенче төрле, предикатив билге дип тә атыйлар.

Предикат башлыча субъект белән бергә килә, ягъни ул күбрәк субъектлы була: *Бала укый; Кояш чыкты; Улым – укытучы; Аңа укырга кирәк; Минем укыганым бар; Аңа бик авыр*. Предикатив билге субъектсыз да килергә, ягъни субъектның булуы бөтенләй күздә тотылмаска мөмкин: *Шалтыраталар; Караңгы; Салкын; Яшәп була; Янына бармалы түгел.*

Лексик-семантик мәгънәләреннән чыгып, предикатны башта ике зур төркемгә аералар: процесс белдерүче һәм процесс белдермәүчеләр.

Процесс белдерүче (процессуаль) предикатлар якынча түбәндәгеләр:

1) хәрәкәт предикаты: *Бала рәсем ясый; Мин хат язам; Эшче корыч коя; Әби чәч тарый;*

2) йөрү предикаты: *Бала өйгә кайта; Мин юлдан барам; Ат чаба; Әби урамда йөри;*

3) тою предикаты: *Ул ишетә; Мин аның матурлыгына таң калам; Аның яңа пароходка исе китә; Мин аны күптән чамаладым; Ул ис тоя;*

4) аңлату предикаты: *Бала дөресен әйтә; Әби әкият сөйли; Профессор лекция укый; Бала хат яза*;

5) хәл предикаты: *Мәсьәлә хәл ителде; Бала авырый; Бабай ял итә; Әни йоклый;*

6) тиешлек предикаты: *Ул барырга тиеш; Бала тыңларга тиеш*;

7) чамалау предикаты: *Ул килде булса кирәк; Хатны бәлки кызым язгандыр;*

8) мөмкинлек предикаты: *Сиңа язарга ярый; Аңа укырга мөмкин*;

Билгеле, лексик-грамматик мәгънәләр болар белән генә чикләнми. Фигыльнең күптөрле лексик һәм модаль мәгънәләреннән чыгып, процесс белдерүче предикатларның санын артыграк итәргә дә мөмкин. Без биредә аларның мәгънәви төрләрен табу юлларын гына күрсәттек.

Процесс белдермәүче предикатларның түбәндәге төрләрен якынча санарга мөмкин:

1) белгечлек предикаты: *Әти – укытучы; Әни – врач; Мин студент;*

2) материал предикаты: *Бүреге мехтан; Күлмәгем – сатин; Отряд – төрле милләттән;*

3) билге предикаты: *Кыз бик яшь; Егет бик уңган; Әби шактый ягымлы;*

4) хуҗа булу предикаты: *Китап әнинеке; Хат минеке; Китапханә шәһәрнеке;*

5) барлык-юклык предикаты: *Мин хәзер машиналы; Иптәшем фатирсыз; Акчам бар; Күршеләрем юк;*

6) төбәлү предикаты: *Бу хат сиңа; Тырышуым синең өчен;*

7) вакыт предикаты: *Кайтырга иртә әле; Барырга соң инде*;

8) урын предикаты: *Әти биредә; Балам хәзер Казанда;*

9) чагыштыру предикаты: *Ул да гел синең төсле; Улы хәзер әтисе чаклы;*

10) тәртип предикаты: *Мин бишенче; Әти алтынчы*;

11) күләм предикаты: *Әтинең хезмәте зур* һ.б.

Морфологик планда һәр сүз төркеменең лексик-семантик төркемчәләре ачыклана барган саен, предикатларның да семантик төрләре бик күп саналырга мөмкин.

**§ 161. Субъект һәм аның төрләре**. Субъект ул предикатив билгене йөртүче була. Субъект сөйләмдә предикаттан башка кулланыла алмый, алар икесе хәбәр итү үзәге төзиләр. Ләкин предикат субъекттан башка кулланылырга мөмкин.

Субъект кулланылганда, аның турында предикат сөйләүчегә нидер хәбәр итә, һәм ул күбрәк предикаттан аңлашылган процессны үтәүче булып килә. Шуннан чыгып, аны еш кына үтәүче белән тиңлиләр яисә үтәүчене субъект дип атыйлар. Болар икесе – ике төрле күренеш.

Чыннан да күп очракта субъект белән үтәүче бер-берсе белән туры киләләр. Мәсәлән, *Бала укый* җөмләсендә субъект та һәм уку процессын үтәүче дә – *бала*.

*Уенчык бала тарафыннан ясалды* җөмләсендә субъект – *уенчык*, ә үтәүче – *бала*. Биредә субъект үзенең төп мәгънәсендә килгән, предикат аның турында хәбәр итә; өстәмә мәгънәсе – процессның объектын

белдерү. Үтәүче (*бала*) тәмамлык белән бирелгән, аны үтәүче объект дип тә атыйлар.

Тагын бер мисал анализлыйк. *Марат уенчыкны энесеннән ясаттырды* җөмләсендә субъект – *Марат*, аның турында предикат тыңлаучыга хәбәр бирә, ләкин ул *ясау* процессын үтәүче түгел. Ул процессны *эне* үти, һәм аны белдерүче сүз, чыгыш килешен алып, үтәүче объект булып урын ала.

Үтәүче аерылмыш белән дә бирелә ала, ләкин аның аергычы (атрибуты) фигыль булырга тиеш: *укыган кеше* тезмәсендә атрибут – *укыган*, ул фигыль белән бирелгән, уку процессын үтәүче – *кеше* (аерылмыш).

Мисаллардан күренгәнчә, субъект белән үтәүчене бутарга ярамый. Үтәүчегә туры килә торган субъект – **актив субъект**, үтәүче белән туры килмәгәне **пассив субъект** дип атала. Үтәүчене гомуми тел гыйлемендә **агенс** дип йөртәләр.

Кайбер төр җөмләләрдә субъектны билгеләү һаман бәхәсле булып кала бирә. Мәсәлән, *Әнигә суык*; *Әтигә бик кыен*; *Балаларга күңелле* кебек бер составлы җөмләләрдә кайбер синтаксистлар *әнигә, әтигә, балаларга* кебек кисәкләрне субъект була дип раслыйлар һәм моны болай аңлаталар: суыкны әни тоя, кыенлыкны әти татый, күңеллелекне бала сизә. Димәк, диләр алар, китерелгән җөмләләрдә субъектлар – *әнигә, әтигә, балаларга*. Башка синтаксистлар болайрак фикер йөртәләр: бу бер составлы җөмләләрдә субъект – *суык, кыен, күңелле*, чөнки бу сүзләрне әйтү белән алар белдергән төшенчәләрнең булуы хәбәр ителә. Димәк, биредә *булу* төшенчәсе – предикат, ә *суык, кыен, күңелле* – чыннан да субъект. Ә *әнигә, әтигә, балаларга* кисәкләре – шушы билгеләрне татучы объектлар гына.

Соңгы карашны алга сөрүчеләрнең дөреслеге тагын шуның белән раслана, юнәлеш килешендәге сүз җөмләдә булмаганда, бер составлы җөмлә субъект һәм предикатка нәкъ шулай таркатыла. Мәсәлән, *Суык. Караңгы* җөмләләрендә субъектлар *суык* һәм *караңгы*, шул субъектларны атау, аларның хәзерге заманда барлыгын хәбәр итәләр, бу «барлык», «булучылык» төшенчәсе җөмләнең предикаты була.

Татарча җөмләләрдә, семантик кисәк буларак, субъект төрлечә бирелә: 1) ия аша: *Бала укый*; 2) хәбәр формасы белән: *язам, язабыз, язасыз, язасың, яза, язалар;* 3) субъекты бирелмәгән җөмләләрдә ул сүз сөрешеннән, җөмлә тибыннан чамалана: *Шалтыраталар; Ни чәчсәң,*

*шуны урырсың* (биредә тыңлаучыны кызыксындырмый торган гомумиләштерелгән субъект бар); 4) *-га кадәр/чаклы/-ча* формасын алган тәмамлык аша: *Баласына кадәр эшчән*; 5) *-га* формасындагы тәмамлык белән: *Галиуллага тыңларга туры килде* (И. Гази); 6) *-ның* формасындагы тәмамлык белән: *Аның андый төшләрне күп күргәне бар* (Г. Гобәй); 7) *белән* бәйлеге аша бәйләнгән ия һәм тәмамлык аркылы: *Илдус Рөстәм белән сөйләшә*; 8) *-га* аша бәйләнешкән ия һәм тәмамлык ярдәмендә: *Илдус Рөстәмгә су ташыша*.

Бу мисаллардан күренгәнчә, субъект, семантик категория буларак, ия белән дә тәңгәл килми икән.

Субъектның төрләренә килгәндә, аны гадәттә предикатка карап төркемлиләр. Кайсы предикатның субъекты булса, ул шундый ук исем белән атала. Процесс белдерүче предикат янында процесска бәйле (процессуаль) субъект килә; предикат процесс белдермәсә, субъект та процесска бәйләнешсез (непроцессуальный) субъект дип йөртелә.

Процессуаль һәм процессуаль булмаган субъектларның төрләре югарыдагы параграфта бирелгән процессуаль һәм процессуаль булмаган предикатлар төренә туры килә.

Процесска бәйле субъект, югарыда әйтелгәнчә, актив һәм пассив була. Төрки телләрдә болар белән янәшә йөкләтү һәм уртаклык субъектлары да күрсәтелә: *Бала укый* (актив субъект); *Китап укыла* (пассив субъект); *Бала яздыра* (йөкләтү субъекты); *Бала әтисенә утын ташыша* (уртаклык субъекты). Кайбер синтаксистлар *Бала юына* кебек җөмләләрдәге субъектны кайтым субъекты дип тә бүлеп чыгаралар.

**§ 162. Объект һәм аның төрләре**. Объект ул процесс турыдан-туры я читләтеп тәэсир иткән әйберне, затны атый. Мәсәлән, *Бала китап укый* җөмләсендә уку процессы турыдан-туры китапка төбәлгән, димәк, биредә объект – *китап*. *Әтигә сөйләдем* җөмләсендә сөйләү процессы читләтеп булса да *әтигә* тәэсир итә, димәк, *әтигә* – объект.

Объект җөмләнең семантик структурасында бик әһәмиятле урын тота. Предикат күчемле һәм йөкләтүле фигыльләр белән бирелгәндә, җөмлә объектсыз төзелә алмый: *Рөстәм хат язды*. Бу җөмлә ким булганда, ул *хат* сүзе белән бирелгән объекттан башка да реальләшә ала, ләкин *хат* (объект) алдагы җөмләләрдән аңлашылып торырга тиеш.

Тагын бер мисал. *Рөстәм апасыннан энесенә хат яздырды* җөмләсе *хат, апасыннан, энесенә* кебек объектлардан башка тулы булмый.

Аларның берсе бу җөмләдә бирелмәсә дә, контексттан аңлашылып торырга тиеш була.

Объект гадәттә тәмамлык белән бирелә. Ләкин кайбер лингвистлар пассив субъектны да объект дип танып, аны ия белән дә бирелә диләр. Мәсәлән, алар *Китап бала тарафыннан китерелде* җөмләсендә *китап* кисәген объект дип таныйлар, чөнки *китапны китерәләр*, диләр алар. Дөресендә, бу мисалдагы *китап* кисәге семантик субъект. Логик үтәүчене, белдерүче *бала тарафыннан* кисәге семантик яктан объект булып килгән, ә субъект түгел.

Логик объект буларак фигыль белән ачыкланган аергыч та килергә мөмкин: *укылган китап* тезмәсендә логик яктан *китап* уку процессының объектын белдерә, ләкин семантик яктан җөмләдә ул теләсә нинди семантик кисәк була ала.

Кайбер атау җөмләләрдә баш кисәк үзе логик объект була ала: *Су! Су! Су бирегез!* (А. Шамов). Гомуми семантикага карап, бу логик объект семантик объект итеп тә танылырга мөмкин.

Семантик кисәк буларак, объектның төрләре предикат төрләреннән чыгып билгеләнә. Предикатны белдерүче кисәк нинди лексик-грамматик мәгънәләргә ия булса, объект та (субъект кебек үк) шундый төрләргә бүленә. Аның төрләре төрки телләрдә 30 га якын санала. Мәсәлән, карачай-балкар телендәге структур-семантик кисәкләрне махсус тикшергән һәм шуның буенча монография чыгарган И.Х. Ахматов аларны түбәндәгечә санап бирә [Ахматов, 1983, с. 90–92]:

1) тәэсир итү объекты: *Аслан машинаны бозды;*

2) актив хәрәкәт объекты: *Вьетнам дошманнан саклана;*

3) бергәләп эшләү объекты: *Хәлил Фатыйма белән эшли;*

4) пассив хәрәкәт объекты: *Печән чабылган* (бездәге грамматикаларда бу пассив субъект дип санала);

5) сөйләү объекты: *Бабай әкият сөйли;*

6) адресат объекты: *Китап иясенә җибәрелде;*

7) алучы объект: *Энегә машина алдык;*

8) психологик я физиологик хәл объекты: *Мирзабәк абыйсын куандырды;*

9) чагыштыру объекты: *Һарун Хәсәннән зуррак;*

10) өлеш объекты: *Студентлар кабинеттагы китаплардан файдаланалар;*

11) материал объекты: *Тиредән тун тегәләр;*

12) сәбәп объекты: *Атасы улыннан куана;*

13) ышаныч объекты: *Без аңа ышанабыз;*

14) башлану объекты: *Сугыш уеннан башлана;*

15) тоткарлану объекты: *Су түбәдән үтми;*

16) урын объекты: *Аслан аттан егылды;*

17) сөйләм темасы объекты: *Аслан безнең дуслык турында җырлый;*

18) корал объекты: *Утынны балта белән яралар;*

19) тәэсир чарасы объекты: *Аны дару белән терелтәләр;*

20) атау объекты: *Аны Аслан атадылар;*

21) омтылу объекты: *Ул яктыга омтыла;*

22) мөнәсәбәт объекты: *Мин аны яратам;*

23) тою объекты: *Син аны ишетәсең;*

24) нәтиҗә объекты: *Аның анасы малай тапкан;*

25) гадәт объекты: *Син чалгыда остасың;*

26) сайлану объекты: *Сине депутатлыкка сайладылар;*

27) охшау объекты: *Ул сиңа охшаган;*

28) тутыру объекты: *Капчыкны он белән тутырдылар;*

29) йомышчы объекты: *Мин китапны бабайга синең аркылы җибәрдем,* һ.б.

Объектның И.Х. Ахматовтан алынган бу төрләрен без семантик синтаксиста гомумиләштерүнең әле җитешмәвен күрсәтү өчен китердек. Бу юл белән барсак, предикат булып килә торган һәр фигыльнең лексик мәгънәсе дә, грамматик мәгънәсе дә аерым төр объект төзи булып чыга, димәк, объект төрләренең дә иге-чиге булмаска мөмкин.

Без сүзтезмәләрне җентекләп өйрәнүдән объектның түбәндәге гомумиләштерелгән төрләре бар дип саныйбыз:

1) туры (процесс турыдан-туры төшкән) объект: *Җырны илгә багышладым*;

2) кыек (процесс турыдан-туры түгел, ә кыеклап төшкән) объект: *Әтигә әйттем;*

3) корал объекты: *Чаңгыда шудым;*

4) сәбәп объекты: *Матурлыкка исем китте; Ул ачлыктан үлде; Мин батырлык белән канатландым;*

5) максат объекты: *Йомыш белән килдем; Ул икмәк өчен көрәште;*

6) урын объекты: *Урманны чыктык;*

7) көтелмәгән объект: *Пальтосына кадәр салды; Гаризасына чаклы язып бирде;*

8) юлдашлык объекты: *Орлык белән бергә күкәй дә чәчә булганнар* (Г. Бәширов);

9) объект булып җитмәгән объект: *Китап урынына алдылар;*

10) алданрак булган объект: *Синнән соң күрдек;*

11) башкаручы сыйфатындагы объект: *Ул механик сыйфатында килде; Ул бригадир булып эшли; Аны укытучы буларак хөрмәт итәләр;*

12) башкаручы объект: *Бала тарафыннан язылды; Балага эшләтте; Әти белән килдек; Укытучы урынына яздым; Балага матур күренә.*

**§ 163. Атрибут һәм аның төрләре**. Җөмләнең грамматик кисәкләре рәтеннән аергычларны өйрәнгәндә күрдек: аергычның формадан тыш ягын, ягъни бары семантикасын атрибут дип атау гадәткә кергән. Шуның белән бергә әйтергә кирәк, хәлләрнең эчтәлеген дә башта атрибут термины белән атап йөрттеләр, хәзер исә академик грамматикаларда атрибут дип, бары предметның билгесен белдерүне генә атыйлар.

Атрибутларның төрләре, нигездә, аергычларның мәгънә төрләренә туры килә. Шуннан чыгып атрибутларны башта 5 эре төркемгә туплыйлар, алар эчендә кечерәк төркемнәр карала.

I. Иялек атрибутлары ияртүче сүздән (аерылмыштан) аңлашылган предметның иясен белдерәләр һәм һәрчак иялек килешендә торалар, аерылмыш тартым формасын ала. Мондый атрибутны ияртүче сүз (аерылмыш) белән бергә алып, тюркологиядә изафә III дип йөртәләр.

Бу төр атрибутлар иялекнең түбәндәге төсмерләрен белдерәләр:

1) милек иялеген (атрибут милеккә ия була): *укучының китабы;*

2) урын иялеген (атрибут урынны белдереп, шул урын нәрсәгәдер ия булып аңлашыла): *авылның егетләре;*

3) вакыт иялеген (атрибут вакыт белдерә, шул вакыт нәрсәгәдер ия булып аңлашыла): *көзнең яңгырлары;*

4) туганлык иялеген (бер туган икенчесенә ия итеп куела): *малайның атасы;*

5) максат иялеген (атрибут үзенә билгеләнгән әйбергә ия булып аңлашыла): *кошларның җиме*;

6) башкаручы иялеген (атрибут башкаручыны белдерә, һәм ул аерылмыштан аңлашылган процесска ия булып аңлашыла): *суның һөҗүме;*

7) сыйфат иялеген (атрибутның билгеле бер сыйфатка ия булуы аңлашыла): *көннең кызуы;*

8) өлешкә иялекне (атрибут бөтенне белдерә, шул бөтен үзенең бер өлешенә ия булып аңлашыла): *кешенең күзе;*

9) материалга иялекне (атрибут үзенең аерылмышында әйтелгән материалына ия булып аңлашыла): *чиләкнең калае.*

II. М ө н ә с ә б ә т  а т р и б у т л а р ы ияртүче сүздән (аерылмыштан) аңлашылган әйбергә билгеле бер мөнәсәбәт белдерәләр, икенче төрле әйткәндә, бер әйбер икенче әйбергә каратып ачыклана. Мондый атрибутлар күптөрле семантик төсмерләрне белдерәләр һәм аерылмыш белдергән күптөрле әйберләргә каратылалар (мөнәсәбәт белдерәләр):

1) процесс-атрибут үз башкаручысына каратыла: *эзләү агенты;*

2) процесс-атрибут үз коралына каратыла: *кимсетү сүзләре;*

3) милләт-атрибут затка каратыла: *рус укучысы, татар кешесе;*

4) исем-атрибут шул исемне йөртүчегә каратыла: *Идел елгасы;*

5) өлеш-атрибут бөтенгә каратыла: *шомырт чәчәге, арба тәгәрмәче;*

6) бөтен-атрибут урынга каратыла: *күзге алды, авыл тирәсе;*

7) бөтен-атрибут вакытка каратыла: *көн урталары;*

8) максат-атрибут үзенә билгеләнгән әйбергә каратыла: *хатыннар бүлмәсе;*

9) урын-атрибут шундагы әйбергә каратыла: *урам капкасы;*

10) вакыт-атрибут башка бер вакытка каратыла: *кыш көне;*

11) материал-атрибут шул материалдан торган әйбергә каратыла: *боз тавы;*

12) башкаручы-атрибут үз объектына каратыла: *су юлы;*

13) объект-атрибут башкаручыга каратыла: *агач заводы* һ.б.

III. Б а р л ы к / ю к л ы к  а т р и б у т л а р ы ияртүче кисәктән (аерылмыштан) аңлашылган әйберләрдә, затларда була яки булмый торган әйберләрне белдерәләр. Мондый атрибутлар һәрчак *-лы/-ле* я *-сыз/-сез* кушымчаларын алалар.

Бу төр атрибутлар:

1) әйбернең кемдәдер барлыгын/юклыгын белдерәләр: *күзлекле кеше, атлы юлчы, коралсыз сугышчы;*

2) сыйфатның кемдәдер барлыгын/юклыгын белдерәләр: *акыллы кеше, башсыз тавык;*

3) әйбернең билгеле бер урында барлыгын/юклыгын белдерәләр: *урманлы тау; чикләвекле урман, яфраксыз агач;*

4) әйбернең билгеле бер вакытта барлыгын/юклыгын белдерәләр: *кояшлы көн, айсыз төн;*

5) күренешнең билгеле бер күренештә барлыгын/юклыгын белдерәләр: *давыллы яңгыр; тузанлы җил, җилсез яңгыр* һ.б.

IV. Билге-сыйфат атрибутлары ияртүче кисәктән (аерылмыштан) аңлашылган әйбернең билге-сыйфатын төрле яклап белдерәләр:

1) материалын, составын: *сатин күлмәк, татарлардан отряд;*

2) профессиясен: *артист Искәндәр;*

3) исемен атыйлар: *Җиһанша карт;*

4) җенесен: *ир бала, кыз кардәш;*

5) төсен: *кызыл чәчәк;*

6) тәмен: *ачы катык;*

7) ысулын: *ярдәм итәрлек чара;*

8) башкарган эшен: *бирешми торган егет;*

9) башкарыласы эшен: *җырланасы җыр;*

10) урынны андагы процесс ачыклый: *туган-үскән җир;*

11) вакытны анда булган процесс ачыклый: *китәсе көн;*

12) коралны шуның белән башкарылучы процесс ачыклый: *кисә торган пычкы* һ.б.

V. Күләм-чама атрибутлары ияртүче кисәктән аңлашылган әйбернең күләмен, чамасын белдерәләр. Аларда мәгънә төсмерләре төрлечәрәк була:

1) күләмне белдерәләр: *билдән су, вагон-вагон кеше;*

2) санын белдерәләр: *ике чиләк, биш сум;*

3) хакын белдерәләр: *биш сумлык бүләк;*

4) тәртибен белдерәләр: *бишенче урын* һ.б.

Күренә ки, атрибутларның бу мәгънәләре грамматик синтаксиста аергычларның мәгънәләре буларак тәртипле итеп тикшереләләр. Се-

мантик кисәк буларак, шул ук мәгънәләрне без биредә семантик синтаксисның ни белән шөгыльләнүен күрсәтү өчен кабатлап күрсәттек. Шулай итеп безнең бу академик грамматикада грамматик синтаксис та, семантик синтаксис элементлары да урын алды.

**§ 164. Ачыклагыч һәм аның төрләре**. Ачыклагыч дигән терминны без конкретизатор (яисә квалификатор) дигән атама өчен кулланабыз. Семантик синтаксиста бик озак еллар боларны да атрибут дип кенә атадылар. Соңрак исемнәр янындагы атрибутларны гына атрибут дип атап, фигыльләр янындагы атрибутларны квалификатор яисә конкретизатор дип аерып алдылар. Димәк, семантик синтаксис әһелләре, грамматик синтаксистагыча, аергыч һәм хәлләрнең мәгънәләрен аерып карый башладылар.

Ачыклагычларны (конкретизаторларны) хәлләрнең мәгънә төркемнәренә туры китереп тикшерәләр, һәм аларда бик күп лексик-грамматик мәгънәләр күрсәтәләр. Без, күптөрле лексик-грамматик мәгънәләрне гомумиләштереп, тугыз төрле ачыклагыч санау ягында торабыз.

1. Күләм-чама ачыклагычлары процессны яки билгене тагын җиде яктан ачыклыйлар:

1) вакыт күләм-чамасын белдерәләр: *ике ел хезмәт итә, бер төнгә кайтты, җәйдән бирле эшләде, озак көтте;*

2) пространство күләм-чамасын белдерәләр: *100 чакрым үткән, биленә чаклы юеш; Урманга кадәр бардык;*

3) күләм-чаманы белдерәләр: *Эшенә күрә түләдек; Дустым хәтле тырыштым;*

4) хак күләм-чамасын белдерәләр: *биш тиенгә алдык;*

5) сан күләм-чамасын белдерәләр: *җидәүләп килдек, бишкә бүлделәр;*

6) тәртип күләм-чамасын белдерәләр: *бишенче булып алдык;*

7) кабатлау күләм-чамасын белдерәләр: *тагын килдек* һ.б.

2. Вакыт ачыклагычлары ияртүче кисәктән аңлашылган процессның үтәлү вакытын белдерәләр: *Узган ел кайткан иде.*

3. Урын ачыклагычы: *Университетта укыдым.*

4. Рәвеш ачыклагычлары: *Бөтен көченә чапты.*

5. Чагыштыру ачыклагычы: *Карлыгандай ялтырый; Карлыгандай кара.*

6. Сәбәп ачыклагычы: *Шатлыгыннан биеп алды.*

7. Максат ачыклагычы: *Утынга китте.*

8. Шарт ачыклагычы: *Күрсәм әйтермен.*

9. Кире шарт ачыклагычы: *Күрсә дә әйтми.*

Шулай итеп, семантик синтаксис семантик кисәкләр (предикат, субъект, объект, атрибут, ачыклагыч) дип грамматик кисәкләрнең (хәлнең, иянең, тәмамлыкның, аергычның һәм хәлнең) мәгънәләрен генә (семантикасын гына) аерып алып өйрәнә. Югарыда инде әйтелгәнчә, бу төр синтаксис аларны структур кисәкләр (грамматик кисәкләрнең формалары) белән янәшә куеп, җөмләләрнең структур-семантик модельләрен билгеләргә тырыша (242–245 § ларны карагыз).

## ТИҢДӘШ КИСӘКЛӘР

**§ 165. Гомуми мәгълүмат.** Нинди дә булса бер кисәккә караган һәм шул кисәккә карата бер үк мәгънә мөнәсәбәтендә торган кисәкләр тиңдәш кисәкләр дип аталалар. Тиңдәш кисәкләрнең кагыйдә итеп алырлык һәрвакыт була торган үзенчәлекләре шунда: алар арасында тезүче (җыючы, каршылык, бүлүче) теркәгечләр кулланыла яисә анда ул теркәгечләрне куярга мөмкин була.

Сөйләмдә грамматик кисәкләр дә, структур һәм семантик кисәкләр дә тиңдәшләнеп килә алалар. Ләкин артык кабатлаудан котылу максатыннан чыгып, без биредә бары грамматик кисәкләрнең тиңдәшлеген генә өйрәнәбез. Структур һәм семантик кисәкләрнең тиңдәшлеге мәсьәләсенә аерым тукталмыйбыз.

Татар телендә тиңдәш кисәкләр XIX йөздә үк өйрәнелә башлый. Каюм Насыйри тиңдәш кисәкләрне кушма кисәкләр дип атый. Г. Ибраһимов тиңдәш кисәкле җөмләләрне оешкан җөмләләр исеме астында тикшерә. Тиңдәш кисәкле җөмләләр берничә җөмләнең оешуы нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр дигән фикер әйтә. 1926 елда Г. Алпаров та бу фикерне куәтләп чыга. Аларча, мәсәлән, *Эшчеләр хөкүмәтне үз кулларына алдылар* һәм *Крестьяннар хөкүмәтне үз кулларына алдылар* җөмләләренең бергә оешуыннан *Эшчеләр һәм крестьяннар хөкүмәтне үз кулларына алдылар* дигән тиңдәш кисәкле җөмлә барлыкка килгән. Оешкан җөмлә теориясе «Гамәли тел сабаклары» дигән дәреслектә 20 нче елларда тагын да ныграк үсеш ала. Ләкин соңыннан бу теориянең дөреслеккә туры килмәве исбат ителә

һәм ул «тиңдәш кисәкләр» теориясе белән алмаштырыла. Бу теория буенча, тиңдәш кисәкләр сүзләр арасындагы тезүле бәйләнешне өйрәнү өчен кертелә.

**§ 166. Җөмлә кисәкләренең тиңдәш булуы өчен төп шарт.** Гадәттә, кисәкләр тиңдәш булсын өчен, алар арасында тезүле бәйләнеш булырга тиеш дип уйлыйлар. Бу билгеле дәрәҗәдә дөрес. Ләкин ул җөмлә кисәкләренең ни өчен тиңдәш булуын ачмый. Тиңдәш кисәкләр булу өчен, барыннан да элек ияртүле бәйләнешнең булуы шарт. Мәсәлән: *Ак, кызыл, ал чәчәкләргә бал корты куна* (Н. Баян) мисалында *ак, кызыл, ал* кисәкләре шуның өчен тиңдәшләнеп килгәннәр, чөнки аларның һәрберсе *чәчәкләр* сүзенә ияргән, буйсынган. Дөрес, кайбер ким җөмләләрдә, атамаларда тиңдәш кисәкләр үзләре генә дә киләләр: *Сугыш һәм Государственная Дума* (Г. Тукай); *Фатыйма һәм сандугач* (Г. Тукай); *Җыелышка кемнәр килгән? – Сафин, Хәкимов, Дәүләтшин.* Мондый очракларда ияртүле бәйләнеш китерелми, булуы аңлашылып кына тора. Мәсәлән: *Фатыйма белән сандугач турында шигырь* дип аңлашыла.

Шулай итеп җөмлә кисәкләре тиңдәш булсыннар өчен, барыннан да элек, ияртүле бәйләнешнең булуы кирәк.

**§ 167. Җөмләнең барлык кисәкләре дә тиңдәш була.**

1. Бер үк хәбәргә караган ияләр, бер үк иягә караган хәбәрләр һәм бер үк кисәккә караган туры тәмамлыклар һәрвакыт тиңдәш кисәкләр булалар. Мәсәлән: *Карлыгачлар, сандугачлар, тургайлар безнең якларга килделәр. Җәй көне эссе һавада мин суда коенам, йөзәм, чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм* (Г. Тукай). *Без дә аның кайсы як кешесе икәнен һәм нинди эштә булуын сораштык* (М. Гафури).

2. Бер үк кисәккә караган кыек тәмамлыклар, хәлләр һәм аергычлар һәрвакыт тиңдәш булмаска мөмкин. Тиңдәш булсыннар өчен, алар ияртүче кисәккә карата бер үк мәгънә мөнәсәбәтендә торырга тиешләр, икенче төрле әйткәндә, бер үк сорауга җавап бирергә тиешләр. Мәсәлән: *Нәфисә... өй эченең җыйнаклыгына һәм пөхтәлегенә кызыгып утырды* (Г. Бәширов). *Мин уйныйм урманда, болында, кырларда* (Г. Тукай). *Ул көннәрне ерак авыллардан, хуторлардан, станцияләрдән шәһәргә кешеләр төркеме агылып кына торды* (К. Нәҗми). *Алар басудан түгел, бәлки*

*у р м а н н а н кайтып киләләр иде. Эшкә һәр көн я а л т ы, я җ и д е, я с и г е з кеше килә.*

Бер үк кисәккә караган аергычлар, ияртүче кисәкне төрле яктан характерласалар да, сөйләүче аларны, үз карашы буенча бер төшенчәгә туплап, тиңдәш итеп китерергә мөмкин. Бу вакытта андый тиңдәшләр я теркәгечләр ярдәмендә бәйләнәләр, я алар арасына теркәгечләр куярга мөмкин була. Мәсәлән: *Диңгез өстен я м ь л е, с ы е к, к ы з г ы л т шәүләләр каплаган иде* (Ш. Камал).

Аныклагычлар һәм модаль кисәкләр дә тиңдәш булып килә алалар.

**§ 168. Тиңдәш кисәкләрне үзара теркәүче чаралар.** Төрле кисәкләрне үзара тиңдәш итеп тота торган иң әһәмиятле чара – аларның нинди дә булса бер уртак кисәккә иярүләре, ягъни ияртү бәйләнеше. Моннан башка, тиңдәш кисәкләрне бер-берсенә бәйләп һәм алар арасында төрле мөнәсәбәтләрне белдереп, теркәгеч чаралар да киләләр. Теркәгеч чаралар булып, санау һәм каршылык интонацияләре, җыючы, каршылык һәм бүлүче теркәгечләр һәм теркәгеч сүзләр киләләр.

1. Җыючы теркәгечләр түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр: а) *һәм, да/дә, та/тә* (XX йөз башларына кадәр булган әдәби телдә – *вә*) теркәгечләре һәм теркәгеч ролендә килгән *белән* сүзе, парлы тиңдәшләр арасында килеп, аларның җөмләдә тоткан урыннары тигез булуны күрсәтә: *Ө з е л ә д ә т ө ш ә тал яфрагы* (С.Гәрәева). *Капканы а ч ы п к е р д е д ә шаккатып т у к т а п к а л д ы* (Р. Вәлиев). *Хәсән аны т ө р л е в а к ы т л а р д а в ә т ө р л е х ә л л ә р д ә күрде* (Г. Ибраһимов). *Г а й ш ә б е л ә н Ш ә ң г ә р ә й икесе бер үк вакытта, нидер әйтмәкче булып, авызларын ачтылар* (Г. Ибраһимов); ә) *һәм* теркәгече, тиңдәшләрнең соңгысы алдында килгәндә, санап баруның тәмамланган булуын белдерә: *З ә й н ә п, Г а л и я һ ә м С а н и я бергә яшиләр;* б) *һәм, да/дә* теркәгечләре, һәрбер тиңдәш кисәк янында килеп, барлык тиңдәшләргә дә тигез дәрәҗәдә басым ясауны белдерәләр: *Казакъ далалары к и ң л е г е д ә , рус бәйрәмнәренең шашкын д ә р т е д ә , Грузия тауларының к а й т а в а з ы д а , татар моңнарының м о ң с у л ы г ы д а бар иде бу җырда* (Р. Вәлиев). *Күктә а й д а, й о л д ы з л а р д а юк* (Р. Вәлиев); в) *ни-ни* яки *нә-нә* теркәгече хәзерге әдәби телдә юклык формасы белән бәйләнгән тигез дәрәҗәле тиңдәшләрне бәйли: *Урман буш. Н и г ө м б ә, н и җ и л ә к,*

*н и  чәчәк* юк (Р. Вәлиев). *Н ә  б у с ы,  н ә  т е г е с е* «*ләм*»-«*мим*» *дип авыз да ачмады* (Г. Ибраһимов).

Г. Ибраһимов әсәрләрендә шул ук *нә-нә* теркәгече хәбәре барлык формада бирелгән җөмләләрдә дә очрый: *Ләкин ул н ә  сөйләде, н ә  хәбәр итте, н ә  күрешергә теләде* (Г. Ибраһимов). *Чөнки мулла н ә  юл бирерлек, н ә  дилбегә тотарлык, атны идарә кылырлык иде* (Г. Ибраһимов).

2. Каршылык теркәгечләре, гадәттә, парлы тиңдәшләр арасында киләләр һәм тиңдәш кисәкләрнең бер-берсенә каршы куелуын белдерәләр: *Л ә к и н  бер кеше бар: үзе бетерешкән, көчсез, чалгы да күтәрә алмый, л ә к и н  итекне бик матур тегә* (Г. Тукай). *Мин түгел, б ә л к и  син бу мәсьәләдә гаепле. Иптәшем, нидер әйтмәкче булып, миңа карады, т и к  бер сүз дә әйтә алмады* (Г. Бәширов). *Һаман көттем, л ә к и н  эндәшмәдем...* (Г. Рәхим).

3. Бүлүче теркәгечләр, реальлеге шикле булган тиңдәш кисәкләрне үзара бәйләп, түбәндәге мәгънәләрне бирәләр: а) *я, яки, яисә* теркәгечләре тиңдәш кисәкләрнең бер-берсен тигез дәрәҗәдә алмаштыра алуларын белдерәләр: *Инде кайтмас яшьлек Я  якында, Я  еракта учак кабыза* (Зөлфәт); ә) *әллә* теркәгече тиңдәш кисәкләрнең ачык билгеле булмаган төшенчәләрне, билгеләрне, процессларны белдерүен һәм тиңдәшләрнең бер-берсен тигез дәрәҗәдә алмаштыра алуларын күрсәтә: *Ә л л ә  күпкә, ә л л ә  бик озакка, ахры, мәңге оныта алмамын* (Һ. Такташ).

4. *Әле* теркәгече эзлекле күренешләрне белдерүче кисәкләрне тиңләштереп килә. Еш кына шул ук мәгънәдә *бер* саны кулланыла: *Ә л е  нурлар, ә л е  уклар ява Кояштан һәм усал телдәндер* (Ә. Баян). *Ә л е  көлешәләр, ә л е  җыр башлап җибәрәләр* (Р. Вәлиев). *Син б е р  шатланасың, б е р  газапланасың* (Ф. Яруллин). *Кулларын б е р  артына куйды, б е р  кесәсенә тыкты* (М. Галиев).

5. Сорау кушымчасы, һәрбер тиңдәш кисәк янында килеп, аларның сөйләүче өчен ачык билгеле булмаган төшенчәләрне, билгеләрне, процессларны белдерүен һәм ул тиңдәшләрнең бер-берсен тигез дәрәҗәдә алмаштыра алуларын белдерә: *Күбесе безгә ярты к о н ф е т м ы,  п р ә н н и к м е,  к а т к а н  к л и н д е р  к и с ә г е м е  ташлап китә* (Г. Ибраһимов). *Уенчак егетләрне я м а н  т ө ш м е,  к и л ә ч ә к н е  с и з е н ү м е  баскан* (Г. Ибраһимов). *Аркасы буйлап с у м ы,  т и р м е*

*ага* (М. Максуд). *Барлыгы утызмы, кырыкмы егет, шуның да берничәсе генә алынды* (Г. Ибраһимов).

6. Тиңдәш кисәкләрнең һәрберсенә дә ныграк басым ясауны белдереп, тиңдәш кисәкләрнең һәрберсенә уртак булган бер сүз кабатланып килә: *Шул көрәшләр, шул газаплар, шул каннар, шул каһарманлыклар эчендә кайнады* (Г. Ибраһимов). *Менә шул тойгы, менә шул сизенү, менә шул ышаныч Нәгыймнең авыр тормышында аның якты бәхетенең нигез ташы булып торды* (Г. Ибраһимов). *Өр-яңадан башларга, өр-яңадан чүлмәк ватарга, өр-яңадан көне буе су коенырга хәзер* (И. Гази). *Хәсән... бүлмә буенча йөрергә тотынды, ул да булмады тагы утырды, тагы торып йөренде, тагын утырды, ләкин файда чыкмады* (Ф. Әмирхан). *Һәр буразнасын, һәр үзәнен, һәр калкулыгын, һәр кишәрлеген беләм мин бу җирнең* (Р. Вәлиев).

7. Санау интонациясе җыючы теркәгечләр белән бергә йөри, алар булмаганда, тиңдәш кисәкләрне бәйләүче бердәнбер чара булып кала: *Чөнки ул бөтен авылның яланнарын, тауларын, чокырларын үзенең биш бармагы кебек белә* (Г. Ибраһимов).

8. Каршылык интонациясе каршылык теркәгечләре белән бергә йөри, алардан башка ул каршы куелган тиңдәшләрне бәйләүче әһәмиятле чарага әйләнә. Моннан башка тиңдәшләрнең үзара антоним (һәм барлыкта-юклыкта) булулары да бәйләүче чара була: *Яшәгәнмен бик күп, туймаганмын берни* (Зөлфәт). *Хәят җәһәт кенә үз бүлмәсеннән чыга башлаган иде дә, кире кайтты* (Ф. Әмирхан). *Талдин тартма ясадым, тар буласын белмәдем* (Г. Тукай).

**§ 169. Тиңдәш кисәкләрнең «ярашу» мәсьәләсе.** Кайвакыт иярчен кисәкләрнең үзара ярашулары турында язалар, ләкин сәбәбен ачыкламыйлар, шуңа күрә тиңдәш кисәкләр ярашуның үзенчәлеге дә ачылмый кала. Дөрес, күп очракта тиңдәш кисәкләр бер үк формада булалар, ләкин бу үзара ярашудан түгел, бәлки тиңдәш кисәкләрнең барысының да бер үк кисәккә карауларыннан килә. Мәсәлән: *Безнең бабаларыбыз җир өчен, икмәк өчен, ирек өчен көрәштеләр* (Г. Бәширов) дигән мисалда *икмәк өчен, ирек өчен* кисәкләре *өчен* бәйлеген *җир өчен* сүзенә карап, аңа ярашып алмаганнар, бәлки *җир өчен* кисәге белән бергә, бер үк кисәккә – *көрәштеләр* кисәгенә буйсынулары нәтиҗәсендә алганнар.

Тиңдәш кисәкләрнең бер үк форма алулары аларның һәрберсенә дә басым ясап әйткәндә була. Мәсәлән: *Егет тәнкыйть белән бик мавыга, төпченергә ярата, кешенең д ә р ә җ ә с е  б е л ә н  д ә, я ш е  б е л ә н  д ә хисаплашып тормый* (Ә. Еники).

Күп очракта тиңдәш кисәкләр бер үк форманы алмыйлар, ягъни бәйли торган чараны тиңдәш кисәкләрнең соңгысы гына ала. Моның бик зур стилистик әһәмияте бар. Чөнки үзеннән-үзе аңлашыла торган форманы кабатлап тормау, тавтология ясамау ким җөмлә барлыкка китерә: стильне матурлый. Мәсәлән: *Атнасына ике мәртәбә безне данлыклы а р т и с т л а р,  м у з ы к а н т л а р,  к о м п о з и т о р л а р  б е л ә н  очраштырып тордылар* (М. Юныс).

Тиңдәш булып хәбәрләр килсә, ярдәмче форма гадәттә соңгы хәбәр янында гына кабатлана. Мәсәлән: *Әлбәттә, кыз әдәпле дә, тәрбияле дә, уңган да, зирәк тә  б у л ы р г а  т и е ш* (Ә. Еники).

Тиңдәш булып иярчен кисәкләр килсә һәм һәрбер кисәккә аерым басым ясалмаса, кушымчалар яки ярдәмче чаралар шулай ук соңгы тиңдәш янында гына була, алдагыларында аны кабатлап торуның кирәге калмый. Мәсәлән: *Һәртөрле галстук һәм яулыкларны, җае белән генә алып, икенче кырыйга күчереп куйды* (Г. Бәширов). *Белән* бәйлеге теркәгеч урынына килеп, тиңдәшләрне теркәгәндә, тиңдәш кисәкләр бөтенләй «ярашмыйлар». Мәсәлән: *Аш пешерү эшендә булган Нәсимә белән Хәмидәдән һәм кичке каравыл тору эшендә катнашучы Мәдинә белән Гөлбанудан башка хатын-кызларның һәммәсе тары утарга билгеләнделәр* (Ш. Камал).

**§ 170. Тиңдәш кисәкләр янында гомумиләштерүче сүзләр.** Тиңдәш кисәкләрнең барысын бергә җыеп, гомумиләштереп әйтә торган кисәк гомумиләштерүче сүз дип атала. Гомумиләштерүче сүзләр тиңдәш кисәкләрне ияртүче сүзгә буйсыналар. Тиңдәш кисәкләр ияртүче сүзне кайсы яктан характерласалар, гомумиләштерүче сүз дә ияртүче кисәкне шул яктан характерлый. Гомумиләштерүче сүзләр, кагыйдә буларак, җыючы һәм бүлүче теркәгечләр белән бәйләнгән яки җыючы теркәгечләр белән бәйләнү мөмкинлеге булган тиңдәш кисәкләр янында булалар.

Гомумиләштерүче сүзләр булып, гадәттә, *һәммәсе дә, барысы да, бөтенесе, һичнәрсә, һичбере* кебек алмашлыклар һәм алмашлык урынындагы сүзләр йөриләр. Боларның баштагы өчесе раслаучы

җөмләләрдә, калган өчесе инкяр җөмләләрдә кулланылалар, һәм алар барысы да, гадәттә, тиңдәш кисәкләрдән соң куелалар. Мәсәлән: *Өздереп-өздереп сайраучы к о ш л а р , болын буйлап йөгерешүче ч ә ч ә к л ә р , койрык чәнчеп чабучы к о л ы н – һ ә м м ә с е - һ ә м м ә с е малайларның йөрәгенә олы шатлык булып берьюлы кереп тула* (Ф. Яруллин). *Д у с л а р, я к т а ш л а р, х а т л а р, ю а т у с ү з л ә р е – б а р ы с ы да ниндидер мәгънәсез нәрсә кебек тоела башлады* (Р. Вәлиев).

Тиңдәш кисәкләрдән аңлашылган әйберләр, процесслар, билгеләр керә торган ыру, төр төшенчәсен белдерүче сүзләр дә шул тиңдәш кисәкләрне гомумиләштереп киләләр. Бу типтагы гомумиләштерүче сүзләр, гадәттә, тиңдәш кисәкләрнең алдыннан килә. Мәсәлән: *Бездә бик күп а ш л ы к л а р – а р ы ш, б о д а й, с о л ы, к а р а б о - д а й һ ә м б а ш к а л а р игеләләр; Безгә с т у д е н т л а р – Г а л и, В ә л и, Р а в и л килделәр.* Бу очракта алда килгән гомумиләштерүче сүз аныкланмыш, ә тиңдәш кисәкләр аныклагыч ролен үтиләр.

Тиңдәш кисәкләрдән соң килсәләр, гомумиләштерүче сүзләр алдыннан гомумиләштерү буласын көттергән кебек зур гына пауза ясала. Тиңдәш кисәкләрдән алда килгән гомумиләштерүче сүзләрдән соң һәрвакытта да санап китү булачагын көттергән кебек (көттерү) пауза ясала. Тиңдәш кисәкләр алдында гомумиләштерүче сүз килмичә дә аның мәгънәсе аңлашылып торганда, тиңдәш кисәкләр алдыннан көттерү паузасы була. *Җыелышта катнашалар: Сәлимов, Таһиров* һ.б.

## СИНТАГМАТИК КИСӘКЛӘР

**§ 171. Гомуми мәгълүмат.** Сөйләм төзелешен дөрес аңлауда аның синтагмаларга бүленешен өйрәнү бик зур әһәмияткә ия.

Мәгънәнең нинди булуына карап, җөмлә бер-берсеннән паузалар яки башка ритмик-мелодик чаралар белән аерыла торган интонацион буыннарга – синтагмаларга бүленә. Мәсәлән: *Менә шул бабай | үләр алдыннан | үзенә чакырды да | миңа бер уч тутырып | орлыклар бирде* (Г. Ибраһимов). Сызыклар куйган урыннарга паузалар куеп әйтсәк, җөмлә бер мәгънәне аңлата, паузаларны башка урыннарда ясасак, ягъни синтагмаларга бүленешне үзгәртсәк, җөмләнең мәгънәсе бөтенләй үзгәрә, димәк, сүзләре һәм сүз тәртибе бер үк, ләкин синтагмаларга

бүленеше белән аерылып торган башка төрле җөмлә барлыкка килә: *Менә шул | бабай үләр алдыннан | үзенә чакырды да | миңа | бер үч тутырып | орлыклар бирде.* Монда инде бабай чакырмый, бәлки шул кеше бабай үләр алдыннан чакыра булып аңлашыла. Шулай итеп сөйләмдә мәгънә белдереп, сүзләр, формалар һәм сүз тәртибе генә түгел, бәлки җөмләнең синтагматик бүленеше дә килә. Шуңа күрә сөйләмнең синтагматик төзелешен өйрәнү теоретик һәм практик әһәмияткә ия. Татар телен башка милләт вәкилләренә өйрәткәндә, язганны сәнгатьле итеп укырга өйрәнгәндә һәм режиссерлык эшендә бу төр бүленешнең нигезен белү аеруча кирәк. Шуңа күрә башка халыкларда телнең синтагматик төзелешен, күбрәк, актерлар, сүз осталары һәм режиссерлар тикшергәннәр дә. Русларның танылган театр эшлеклесе К.С. Станиславский сөйләмне паузалар ярдәмендә дөрес итеп синтагмаларга бүлүнең мәгънәне бирү өчен генә түгел, бәлки эчке кичерешләрне төгәл бирү өчен әһәмиятле булуын таный [Слово, 1958].

**§ 172. Синтагма һәм аның өйрәнелү дәрәҗәсе.** Алда әйтелгәннәрдән аңлашылганча, синтагма ул – сөйләмнең бер-берсеннән паузалар һәм башка ритмомелодик чаралар белән аерыла торган мәгънәле кисәге. Бер синтагма белән икенчесе арасында пауза бик озак та һәм сизелер-сизелмәс күләмдә генә дә булырга, шулай ук синтагмалар сөйләм темпының, көченең, тонының кинәт үзгәрүе белән аерылырга мөмкин. Бер синтагма эченә кергән сүзләрнең барысы өчен дә бер генә фраза басымы була, сөйләм агышында аерым сүз басымы югалып кала. Шуңа күрә бер синтагмадагы сүзләр бергә кушылып әйтеләләр. Татар сөйләме сүзләргә түгел, бәлки синтагмаларга гына бүленә.

Сөйләмнең синтагматик бүленешен өйрәнү антик дөньяда ук башлана. Ораторлык теориясен һәм практикасын тикшерүче борынгы грек галимнәре синтагмаларга игътибар итәләр. Ләкин әле бу чорда синтагматик бүленеш турында эзлекле өйрәтмә барлыкка килми, синтагма, еш кына, сөйләм ритмы яки сулыш алу төркеме белән бутала.

Синтагма теориясенә нигез салучы булып акад. Л.В. Щерба санала. Ул үзенең «Фонетика французского языка» (М., 1953) дигән хезмәтендә синтагмага түбәндәге билгеләмәне бирә: «Это фонетическое единство, выражающее единое смысловое целое в процессе речи-мысли и могущее состоять как из одной ритмической группы, так и из целого ряда их, я называю синтагмой» (87 б.). Сөйләмнең

синтагмаларга бүленешен акад. В.В. Виноградов та өйрәнә, синтагма терминының күптөрле мәгънәдә кулланылуы, ләкин аны бары мәгънәле интонацион буын төшенчәсендә куллануның гына уңышлы булуы турында яза [Виноградов, О категории модальности..., 1950].

Татар телендә синтагмаларны аерым алып өйрәнү 1963 елда гына башлана [Зәкиев, 1963]. Аңа кадәр бары фраза басымы турында гына аерым фикерләр була. Татар сөйләменең синтагмаларга бүленешен эксперименталь юл белән Ш.Н. Асылгәрәев өйрәнә (кандидатлык диссертациясе).

**§ 173. Синтагма, сөйләм такты, сулыш төркеме һәм цезура.** Бездә тел һәм әдәбият белеме буенча язылган хезмәтләрдә еш кына синтагма югарыда әйтелгән күренешләр белән буташтырыла. Ә төгәл фәнни эштә боларны үзара бутау, берсен икенчесеннән аермау төрле аңлашылмаучылыклар китереп чыгара.

Кайчакта синтагманы сөйләм такты дип тә атыйлар, ләкин ул фәнни төшенчәләрне аермаудан килеп чыга. Сөйләм такты терминын бер басым белән әйтелә торган иҗекләр төркемен атау өчен кулланалар. Шуңа күрә мондый иҗекләр группасын синтагма дип атарга ярамый.

Сулыш төркеме ул бер сулыш алу тукталышыннан икенчесенә кадәр булган арада әйтелгән сүзләрдән тора. Кайбер очракта синтагма сулыш төркеме белән туры килергә мөмкин, ләкин күбрәк бер сулыш группасында берничә синтагма була. Ләкин киресенчә булырга, ягъни бер синтагмада берничә сулыш группасы килергә мөмкин түгел. Мәсәлән, нормаль сөйләгәндә, *Без | түбәннән | тормышның төбеннән | күтәрелдек*[1] (Г. Ибраһимов) җөмләсендә ике сулыш төркеме бар: *без түбәннән* һәм *тормышның төбеннән күтәрелдек*. Бу ике төркемнең икесе дә икешәр синтагмадан торалар. Тагын шуны әйтергә кирәк: сулыш төркемнең чиге синтагма чиге белән туры килә, ягъни сулыш төркеме тукталышы синтагманы урталай бүләргә тиеш түгел. Шулай булмаса, сөйләм нормаль яңгырамас иде.

Цезура термины урынына әдәбиятчылар еш кына синтагма термины кулланалар. Бу бөтенләй урынсыз. Чөнки цезура ул шигырь юлларының билгеле бер сандагы иҗекләргә бүленеше. Цезура аерым

---

[1] Вертикаль сызык (|) синтагматик кисәкләрне аера.

очракларда синтагма белән туры килергә мөмкин, ләкин цезура синтагманы кисәкләргә дә бүлә ала. Мәсәлән:

*Кичер мине,* || *илем,* || *синең бөек* ||
*Исмең белән* || *килеп* || *сугышка,* ||
*Данлы үлем* || *белән* || *күмәлмәдем* ||
*Бу тәнемне* || *соңгы* || *сулышта* || (М. Җәлил).

Бу мисалдагы *кичер мине, илем, бу тәнемне* синтагмалары аерым цезураларга туры киләләр. Ә *соңгы сулышта* синтагмасы – ике, *данлы үлем белән күмәлмәдем* синтагмасы – өч, *синең бөек исмең белән килеп сугышка* синтагмасы дүрт цезурадан тора. Цезура булып, мисалдан күренгәнчә, ярдәмлек сүзләр дә килә ала (*белән*), ләкин ярдәмлек сүз үзе генә бервакытта да синтагма төзи алмый.

**§ 174. Синтагма һәм сүзтезмә.** Сүзтезмә һәрвакыт ике яки аннан артык мөстәкыйль сүздән тора, ә синтагма булып бер генә мөстәкыйль сүз дә (үзе генә яки ярдәмче сүз белән бергә) килергә мөмкин. Сүзтезмә төзи торган сүзләр җөмләнең төрле урыннарында урнаша алалар, аларның янәшә килүләре мәҗбүри түгел, ә синтагмадагы сүзләр бары янәшә генә торырга тиешләр. Синтагма берничә сүзтезмәдән тора алган кебек үк, сүзтезмә дә синтагмаларга бүленә ала.

Сүзтезмә кисәкләре арасында һәрвакыт төгәлләүле (ачыклаулы) мөнәсәбәт кенә була, ә синтагмага кергән сүзләр арасында (әгәр ул берничә сүздән торса) төгәлләүле мөнәсәбәт тә, хәбәрлекле мөнәсәбәт тә булырга мөмкин. Сөйләмдә синтагма чиге белән сүзтезмә чиге туры килгән очраклар да була.

*Бездән унбиш чакрымда* | *Мәргәнташ дигән* | *биек бер тау бар* (Г. Ибраһимов). Бу мисалда өч синтагма, биш сүзтезмә бар (*бездән унбиш чакрымда, унбиш чакрымда бар, унбиш чакрым, Мәргәнташ дигән тау, биек бер тау*). Беренче синтагмада ике сүзтезмә – *бездән унбиш чакрымда – унбиш чакрымда, унбиш чакрым.* Икенче синтагмада бер сүзтезмә дә юк, чөнки ул бер генә мөстәкыйль сүздән тора. Өченче синтагманың бер өлеше генә сүзтезмә төзи: *биек бер тау. Тау бар* дигән өлеше җөмлә төзи. *Мәргәнташ дигән тау* сүзтезмәнең компонентлары ике синтагма эчендә урнашканнар.

Димәк, синтаксик төзелешне төгәл итеп күз алдына китерү өчен, сөйләмнең синтагмаларга һәм сүзтезмәләргә бүленеше арасындагы аерманы яхшы белергә кирәк.

**§ 175. Җөмлә кисәкләренең аерым синтагма төзи алмый торган очраклары.** Теге яки бу обстановкада, төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә, җөмләнең теләсә кайсы кисәге үзе генә яки үзенә ияргән башка сүзләр белән синтагма төзергә мөмкин. Ләкин төрле шартларда кайбер кисәкләр үзләре синтагма төзи алмыйлар, синтагма төзи торган башка кисәккә генә ияреп киләләр.

Җөмлә ия белән хәбәрдән генә торса һәм ияга яки хәбәргә аерым басым ясалмаса, алар аерым-аерым синтагма төзи алмыйлар, икесе бер синтагмага керәләр. Мәсәлән: *Җил чыкты, | болытлар таралдылар, | көн яктырып китте.*

Җәенке җөмләдә дә ия белән хәбәр янәшә торсалар һәм аларның берсенә дә аерым басым ясалмаса, ия үзенә, хәбәр үзенә аерым синтагма төземи, икесе бер синтагма хасил итәләр: *Безнең басулардан | мул уңыш алына.*

Төгәлләүле мөнәсәбәткә кергән сүзләрнең иярүчесе (төгәлләгеч – аергыч, тәмамлык, хәл), ияртүче белән янәшә торса, ул аерым синтагма төзи алмый, ияртүче сүз синтагмасы эчендә әйтелә. Мәсәлән: *Менә шул бабай | миңа, | бер уч тутырып, | орлыклар бирде* дигән җөмләдә *менә шул* аергычы, *бер уч* һәм *орлыклар* кисәкләре үзләре ияргән сүз белән янәшә торалар һәм шуңа күрә аерым синтагма төзи алмыйлар.

Аныклагыч аныкланмыш белән бер үк формада килмәсә, кагыйдә буларак, үзе генә аерым синтагма төзи алмый. Мәсәлән: *Аның кайгысын уртаклашты да, | сүзне өзмәстән, | Совет башлыгы Шәңгәрәйгә борылды* (Г. Ибраһимов). Монда *Щәңгәрәйгә* дигән аныклагыч үзе генә синтагма төземичә килгән. *Совет башлыгына – Шәңгәрәйгә борылды* дип, икесен бер формада куйганда, ул үзенә аерым синтагма төзегән булыр иде.

Модаль кисәк гомумән җөмләгә түгел, бәлки җөмләнең аерым бер кисәгенә караган булса, ул гадәттә шул кисәк белән бергә бер синтагма төзи: *Галимҗан, бәлки, безгә килер. Кунаклар | килеп беттеләр бугай.*

**Искәрмә**. Җөмләнең кисәкләре генә түгел, җыйнак синтетик иярчен җөмләләр дә, үзләре буйсынган сүз белән янәшә торсалар, ияртүче сүзнең синтагмасы эченә керәләр, аерым синтагма төземиләр: *Авылдашлар | кырдан | караңгы төшкәч кайттылар.*

**§ 176. Җөмлә кисәкләренең аерым синтагма төзи торган очраклары.** Түбәндәге очракларда җөмләнең кисәкләре үзләре синтагма төзи алалар.

Ия белән хәбәр бер-берсеннән ерак торсалар, алар аерым-аерым синтагма төзиләр: *Түбән очның күпере | бу ташуга түзә алмады.*

Әгәр җыйнак (ия белән хәбәрдән торган) җөмләдә иягә яисә хәбәргә аерым басым ясалса, ия үзенә, хәбәр үзенә аерым синтагма төзи. Ә иягә яисә хәбәргә аерым басым ясау җөмләләр каршы куелганда күбрәк була. Мәсәлән: *Марат яза, | ә Вәли | язмый.*

Хәбәр исем яки алмашлык белән бирелгәндә дә, җөмлә җыйнак булуга карамастан, ия һәм хәбәр аерым-аерым синтагма төзиләр: *Мин – комиссар. Кунагыгыз – мин.*

Төгәлләүче (конкретлаштыручы) кисәкләр (аергыч, тәмамлык, хәл) ияртүче сүздән ерак торсалар, үзләре аерым синтагма төзиләр. Мәсәлән: *Шул сүзләр белән | Якуб | ат өстеннән сикереп төште дә, | кайсыныңдыр көрәген алып, | үзе дә казый башлады* (И. Гази). Бу җөмләдә *шул сүзләр белән* һәм *кайсыныңдыр көрәген алып* кисәкләре үзләре бәйләнгән сүздән ерак торалар, шуңа күрә алар үзләре аерым синтагма төзегәннәр.

Аергыч, тәмамлык, хәлләр онытылып калганны өстәп кую тәртибендә, җөмләнең ахырында да әйтеләләр. Болар, өстәлмәләр буларак, гадәттә, ким җөмлә кебек аерым язылалар. Мондый өстәлмәләр шулай ук синтагма төзиләр. Мәсәлән: *Арыш исе килә. | Басу ягыннан* (Г. Минский). *Әйе, | кемнәр генә булмадык, | ниләр генә күрмәдек без. | Аянычын да, | көлкесен дә* (Ә. Еники). *Хәзер барысы да ачык. | Хәтта кирәгеннән артык* (Г. Афзал).

Анықланмыш белән бер үк формада килгән анықлагычлар, кагыйдә буларак, анықланмыш төзегән синтагма эченә кермиләр. Мәсәлән: *Аның алдында кешеләр икегә – | дуска, | дошманга | бүленәләр* (Г. Ибраһимов). Мондагы *дуска, дошманга* дигән анықлагыч *икегә* дигән анықланмышның синтагмасына кермәгән.

Модаль кисәкләр, кагыйдә буларак, аерым синтагма төзиләр. *Курыкмагыз, | кошлар, | күреп сез | янығызда мин барын* (Г. Тукай). *Минемчә, | җыелышны | иртәгә ясарга кирәк* (М. Әмир).

Кереш сүзләр (һәм кереш җөмләләр) гадәттә янәшә тора торган сүзләрнең синтагмасына кермиләр, үзләре аерым синтагма төзиләр.

Мәсәлән: *Мин* | *менә шушы куенымда* | (*ул* | *тун изүен чишеп җибәрде*) | *өшегән бәрәннәрне җылытып йөргән кеше* (Ә. Еники). *Язучы* | *безне борчырга тели,* | *ә без* | *(гаҗәп!)* | *тамчы да борчылмыйбыз* (И. Гази).

Тиңдәш кисәкләрнең ияртүче кисәк белән янәшә тора торганнарыннан башкалары аерым синтагмалар хасил итәләр. Мәсәлән: *Ашка тоз,* | *суган,* | *борыч,* | *кәбестә кирәк булыр.*

## АЕРЫМЛАНГАН ИЯРЧЕН КИСӘКЛӘР

**§ 177. Гомуми мәгълүмат.** Җөмләнең аерымланган иярчен кисәкләре турындагы өйрәтмәнең нигезендә ныклы фәнни принцип ятмый. Чөнки ул сөйләм төзелешен системалы өйрәнүдән түгел, бәлки тыныш билгеләре куюның традицион тәртибен акларга, шул тәртипне фәнни итеп күрсәтергә тырышудан барлыкка килгән. Хәзер дә әле аерымланган иярчен кисәкләрне тыныш билгеләре куела торган очракларга бәйләп карыйлар, һәм шуның аркасында теория белән практика арасында каршылык килеп чыга. Мәсәлән, теоретик билгеләмә түбәндәгечә бирелә: «Җөмләнең интонация һәм пауза белән аерып әйтелгән кисәге аерымланган иярчен кисәк дип атала, һәм андый кисәк башкаларыннан тыныш билгесе белән аерыла». Җөмләнең синтагмаларга бүленешен өйрәнгәндә күргәнчә, теләсә кайсы кисәк билгеле шартларда аерым интонация белән әйтелә, ягъни бер-берсеннән пауза белән аерылып тора ала. Ләкин тыныш билгеләрен кую, чынлабрак тикшереп караганда, аерым интонация һәм пауза белән әйтүгә нигезләнмәгән, бәлки традицион күнегүгә генә нигезләнгән, чөнки без аерым интонация һәм пауза белән әйтелгән кисәкләрнең барысын да түгел, бәлки кайберләрен генә (гадәттә хәлне һәм аныклагычны гына) язуда тыныш билгеләре белән аерабыз. Димәк, аерымланган иярчен кисәкләр җөмләнең синтагматик бүленешенә нигезләнгәннәр, алар синтагмаларның традицион рәвештә тыныш билгеләре белән аерыла торганнарын гына үз эченә алалар, тыныш билгесе белән аерылмый торган синтагмалар аерымланган иярчен кисәк дип саналмыйлар. Шулай итеп тыныш билгеләре куюның да һәм аерымланган иярчен кисәкләр теориясенең дә нигезендә тел төзелешен өйрәнүдән килеп чыккан фәнни принциплар түгел, бәлки синтагмаларның аерым очрак-

ларын гына күрүдән туган традицион принцип ята. Тыныш билгеләре кую принципларын синтагмалар теориясенә нигезләгәндә, ул, һичшиксез, фәннирәк һәм дөресрәк булыр иде, ләкин нык урнашкан традиция моңа ирек бирми.

Җөмлә кисәкләренең аерымланган очрагы, аерымланмаган очрагына караганда, мәгънә ягыннан әһәмиятлерәк була дип раслау да чынбарлыкка туры килми, чөнки теге яки бу кисәкнең роле, хәбәр итүдә булган әһәмияте, киресенчә, нәкъ менә аерымланмаган чагында, ягъни хәбәр белән янәшә килеп, логик басымны алганда арта. Мәсәлән: *Шамил лагерьга укуны тәмамлагач китте* дигән җөмлә *Шамил лагерьга кайчан китте?* дигән сорауга җавап бирә. Анда иң әһәмиятле сүз, ягъни тыңлаучы өчен яңа булган төшенчәне белдерә торган сүз, – *укуны тәмамлагач,* һәм ул логик басымны ала, димәк, аның мәгънә ягыннан булган роле дә шуның белән арта. Ә инде *Укуны тәмамлагач, Шамил кая китте?* дигән сорауга җавап бирергә уйласак, *Укуны тәмамлагач, Шамил лагерьга китте* дип әйтәбез. Монда инде *лагерьга* сүзенең мәгънә әһәмияте арта, һәм ул хәбәр янында килергә тиеш булганлыктан, *укуны тәмамлагач* кисәге ияртүче сүздән ераклаша һәм аерым синтагма төзи һәм аерымлана, алай да аның мәгънә әһәмияте артмый, бәлки, киресенчә *лагерьга* сүзенең әһәмиятенә караганда кимирәк төшә.

Шулай итеп аерымланганда теге яки бу кисәкнең мәгънә ягыннан булган роле артмый, бәлки бераз кими, ләкин ияртүче сүздән ераклашып, мөстәкыйльлеге бераз арта.

Синтагмаларга бүленешне бик ныклап тикшергәндә һәм тыныш билгеләрен дә шуңа нигезләгәндә, аерымланган иярчен кисәкләрне аерып алып өйрәнүнең кирәге дә калмас иде. Ләкин тыныш билгеләрен куюда традицион принциплар яшәгәндә, аерымланган иярчен кисәкләрне, ягъни тыныш билгеләре белән аерыла торган синтагмаларны, аерым алып өйрәнергә туры килә.

Шулай итеп аерымланган иярчен кисәкләр сөйләмнең аерым категориясен тәшкил итмиләр, алар – сөйләм категориясе булган синтагмаларның язуда тыныш билгеләре белән аерыла торганнары гына. Нинди синтагмалар язуда тыныш билгесе белән күрсәтеләләр соң? Моны инде, язу практикасыннан җыеп алып, истә калдырырга кирәк була.

## Аерымланган аергычлар

**§ 178. Аерымланган аергычларның үзенчәлекләре**. Аергычлар аерылмышларыннан ерак яки аннан соң килсәләр, аерым синтагма төзиләр: *Арткы урамдагы | яңа салынган мәктәп бинасының | зур тәрәзәләреннән төшкән яктылык | бөтен урамны балкыта.* Бу мисалда *арткы урамдагы* һәм *яңа салынган мәктәп бинасының* аергычлары үз аерылмышларыннан (*мәктәп* һәм *тәрәзәләреннән* кисәкләреннән) ерак торганлыктан, аерым синтагма төзиләр. Ләкин язуда тыныш билгеләре белән аерылмыйлар. Тыныш билгесе белән шигъри сөйләмдә инверсияләнеп килгән аергычлар гына аерымлана. Димәк, аерымланган аергычлар дип, без аерылмыштан соң килгән аергычларны гына атарга хаклыбыз. Мәсәлән: *Шул вакытта әллә кайдан чыга инсан, кулларына балта белән чүкеч тоткан* (Г. Тукай). *Бер җирдә юк камыш сабаклары, андагыдай шаулый торганнар* (Һ. Такташ). *Мин күп күрдем филдәй кешеләрне, киң күкрәкле, тимер бәдәнле.* (М. Җәлил). *Бер авыл бар, җырда аталмаган, тик җырымдай чыкмас күңелемнән* (шигырь). *Син китәсең, безне базга бикләп, хуш, иске ел, көмеш сакаллы* (М. Җәлил). *Исмең калсын, үзең үлсәң дә, тарихларда укып ятларлык!* (М. Җәлил). *Синең йортта аш юк, туярлык таракан* (Г. Тукай). Мондый аергычлар аерылмыштан өтер белән аерылалар.

Инверсияләнеп килгән аергычлар төп җөмләнең интонациясе эчендә булырга тиешләр, ягъни алар җөмлә тәмамланганчы әйтеләләр.

Инверсияләнгән аергыч тәмамланган җөмләдән соң, аерым җөмлә кебек, хәбәр итү интонациясе белән әйтелсә, ул өстәлмә дип танылa һәм язуда төп җөмләдән нокта, сорау яки өндәү билгесе белән аерыла. Мәсәлән: *Миңа да шундый чәй ясап керт әле, карчык. К а т ы с ы н, к а й н а р ы н* (Р. Ишморат). *Үзең үлсәң дә, исемең калсын. Т а р и х л а р д а у к ы п я т л а р л ы к.*

## Аерымланган тәмамлыклар

**§ 179. Аерымланган тәмамлыклар буламы?** Бу сорауга җавап биргәнче, тәмамлык үзе генә синтагма төзи аламы? дигән сорауны ачыклыйк. Без беләбез: үзе буйсынган сүздән ерак килгән тәмамлыклар үзләренә аерым синтагма төзи алалар. Мәсәлән: *Ул | укучылар-*

*ны* | *яңа әсәре белән* | *тагын бер таныштырды* (Г. Әпсәләмов). Бу мисалда *укучыларны* һәм *яңа әсәре белән* тәмамлыклары ияртүчедән (*таныштырды* кисәгеннән) ерак торып, үзләренә аерым синтагма төзегәннәр, ләкин язуда аерымланмаганнар, шуңа күрә мондый тәмамлыклар аерымланган тәмамлык булмыйлар.

Инверсияләнеп, җөмлә ахырында килгән һәм интонацион яктан җөмлә эчендә калган тәмамлыклар шулай ук аерым синтагма төзиләр, ләкин язуда аерымлану кыек тәмамлыкларда гына күзәтелә. Мәсәлән: *Җырлый-җырлый үттем Барабаны, Җырлый-җырлый үтәм Уралны* (Х. Туфан). Биредә инверсион туры тәмамлыклар *Уралны, Барабаны* аерым синтагма төзесәләр дә, язуда тыныш билгеләре белән аерымланмыйлар. Кыек тәмамлык бу очракта аерымлана: *Шәһәрдән кичә генә кайттык, әти белән. Ул бик яхшы поэма язган, мәхәббәт турында* (Ш. Усманов). *Мин сездән кияүгә китәргә җыенам, шәһәр егетенә...* (Х. Вахит).

Димәк, инверсион кыек тәмамлыклар җөмлә интонациясе эчендә калсалар, язуда тыныш билгеләре белән аерымланалар икән.

Тәмамлыклар инверсияләнеп җөмлә ахырына куелсалар һәм, җөмлә интонацион яктан тәмамлангач, аерым җөмлә интонациясе белән әйтелсәләр, алар өстәлмәләр булалар һәм төп җөмләдән җөмләләрне бер-берсеннән аера торган билгеләр белән аерылалар. Интонацион яктан аерым җөмлә итеп әйтелгәндә, югарыдагы аерымланган тәмамлыклар да өстәлмәгә әйләнергә мөмкин. Мәсәлән: *Шәһәрдән кичә генә кайттым мин.* | *Әти белән. Ул бик яхшы поэма язган.* | *Мәхәббәт турында. Мин үз командалыгым астындагы сүзләрне – солдатларны барларга булдым әле. Бөтенесен дә булмаса да, һич югы кайберләрен* (Ф. Хөсни).

## Аерымланган хәлләр

**§ 180. Гомуми мәгълүмат.** Үзләре буйсынган кисәктән ерак торган хәлләр үзләренә аерым синтагма төзиләр. Мәсәлән: *Безнең басу уртасында* | *төлке уйный торган җирләр бар* (җыр). *Гәлләм,* | *кулдан ычкынмакчы булып,* | *бик нык чабаланды* (Ф. Хөсни). Беренче җөмләдә – урын хәле, икенчесендә рәвеш хәле үзе буйсынган сүздән ерак килеп аерым синтагма төзегән. Ләкин язуда тыныш билгесе белән икенче җөмләдәге хәл генә аерылган, ягъни аерымланган. Күренә ки,

хәлләрнең тыныш билгеләре белән аерылуы да тел төзелешенә түгел, бәлки традициягә нигезләнгән. Гадәт буенча, синтагма төзегән теләсә нинди хәл түгел, аның да процесс белдерүче сүзләр белән бирелгәне һәм күбрәк җәенке булганы гына башка кисәкләрдән тыныш билгеләре белән аерыла.

Урын хәлләре процесс белдерүче сүз белән бирелми дип әйтерлек, шуңа күрә ул, аерым синтагма төзегәндә дә язуда тыныш билгесе белән аерымланмый.

**Искәрмә.** Өстәлмә булып килгән хәлләр шулай ук аерымланалар. Алар башка кисәкләрдән нокта, сорау яки өндәү билгесе белән аерылалар. *Ул күптән кайтты бит инде. Б ө т е н л ә й г ә. Аларның барысын да озатып бетерделәр. И р т ү к. Ш ә һ ә р г ә.*

**§ 181. Аерымланган рәвеш хәлләре.** Ияртүче кисәктән ерак булган рәвеш хәлләре һәрвакыт аерым интонацион бөтен – синтагма тәшкил итәләр. Синтагма төзи торган рәвеш хәлләре башка кисәкләрдән гадәттә өтер белән аерылып язылалар, ягъни аерымланалар. Бары бик җыйнак рәвеш хәлләренең генә өтер белән аерылуы мәҗбүри булмый: *Мортаза бабай | астан гына | комиссарга карап алды* (Г. Гобәй). Җәенке һәм фигыль белән бирелгән рәвеш хәлләрен аерымлау мәҗбүри санала. Мисаллар: *Урамның аргы башында, к а р а б о л ы т б у л ы п, халык җыелып тора* (Г. Ибраһимов). *Туташ, ә л л ә к а я к и т ә с е а д ә м к е б е к, тышкы киемнәренәчә киенде* (Ф. Әмирхан). *Ш а т, р ә х ә т, к ү ң е л л е х ә л д ә, йортка чыктым* (Г. Ибраһимов). *Бөтен зал, с у л ы ш а л м а с т а н, үлем тынлыгы эчендә аны тыңлый* (Г. Ибраһимов). *Алар, б и к һ ә в ә с к ә р б а л ы к ч ы л а р д а й, кармакларына чуалчанны өзек итеп эләктерәләр* (И. Гази).

Фигыльләр, бигрәк тә хәл фигыльләр, белән бирелгән рәвеш хәлләре иярүче кисәк (гадәттә, хәбәр) белән бергә эзлекле яки параллель процессларны белдерә алалар. Мондый рәвеш хәлләрен иярчен яки ярдәмче хәбәр дип атыйлар. Рус телендә аларны «дополнительное сказуемое» диләр. Хәбәр белән параллель яки эзлекле процессны белдергән рәвеш хәлләре аерым синтагма төзесәләр, һәрвакыт аерымланалар. Мәсәлән: *Хәзергә кадәр җиргә карап килгән Хәят, к ү т ә р е л е п, Михаилның йөзенә карады* (Ф. Әмирхан). *Аяклы тарих Надя, к ү з к ы р ы й л а р ы б е л ә н г е н ә е л м а е п, ияген селкетеп куйды* (И. Гази). *Ш у л с ү з л ә р н е ә й т е п, егет бабайның күзләренә*

*йотылды* (Г. Ибраһимов). *Хатыннар, б а ш л а р ы н   т ә р ә з ә д ә н   т ы г ы п , урамдагылардан сорадылар* (И. Гази). *Ярми карт та, к и - л е п, бераз утырып китте* (Г. Ибраһимов). Өтерне бу ярдәмче хәбәргә туры килә торган кисәкләрнең ике ягыннан да түгел, бәлки бер генә ягыннан – алардан соң гына куярга кирәк дип тәкъдим итүчеләр дә бар. Мәсәлән: *Аяклы тарих Ярми карт та к и л е п , бераз утырып китте* (Г. Ибраһимов).

Аерым басым ясап әйтелгәндә һәм җәенке булганда, ияртүче кисәк белән янәшә торган рәвеш хәлләре дә аерымланырга мөмкин. Мәсәлән: *Ләкин тәкъдим ителгән эш методлары ү з л ә р е н е ң   п р а к т и к   н ә т и җ ә л ә р е   б у е н ч а   канәгатьләндермәделәр* (Г. Ибраһимов). *Түбә калайлары у р ы н н а р ы н н а н   к у б а р г а   т е л ә п   шалтырыйлар* (Ф. Әмирхан). Ләкин бу соңгы очракта өтер кую мәҗбүри түгел.

**§ 182. Аерымланган күләм хәлләре.** Ияртүче кисәктән ерак торган күләм хәлләре аерым синтагма төзиләр. Аларның бигрәк тә җәенке булганнары, фигыльләр белән бирелгәннәре аерымланалар, ягъни язуда өтерләр белән аерылалар. Мәсәлән: *А в ы л г а   к а й т ы п   җ и т к ә н ч е , алар бер авыз сүз сөйләшмәделәр. У н б и ш   ч а к р ы м   ү т к ә н   с а е н , алар утырып ял иттеләр* (Г. Тукай). *Ул, б е р е н ч е   м ә р т ә б ә   б у л а р а к , көтелмәгән рәвештә, хөкүмәт каршысына җавапка алынды* (Г. Ибраһимов).

**§ 183. Аерымланган вакыт хәлләре.** Ияртүче кисәктән ерак торган вакыт хәлләре һәрвакыт аерым синтагма төзиләр. Ләкин кагыйдә буларак, төрле фигыль формалары белән бирелгән яки җәенке вакыт хәлләре генә язуда өтерләр белән аерылалар, ягъни аерымланалар. Мәсәлән: *Р ә җ ә п   а б з ы й л а р д а н   ч ы к к а ч , Габдулла шулай дип уйланды* (Ә. Фәйзи). *А л а р   б е л ә н   о ч р а ш у г а   к а д ә р , мин үзем дә алар турында бөтенләй башкача уйлый идем* (Д. Аппакова). *Мортаза бабай, б у   х ә б ә р н е   и ш е т к ә н н ә н   с о ң , башын түбәнрәк иеп йөри башлады* (Г. Гобәй).

**§ 184. Аерымланган максат хәлләре.** Ияртүче кисәктән ерак торган максат хәлләре һәрвакыт аерым синтагма төзиләр, ләкин язуда аларның күбесенчә *өчен* бәйлеге һәм *дип* сүзе янында килгәннәре яисә фигыльләр белән бирелгәннәре генә аерымлана. Мәсәлән: *Алар, к и ч - к е   а ш н ы   а ш а р г а   д и п , әлеге кечкенә өйгә таба киттеләр. Мин*

*ярама яптым ул яулыкны, басар өчен агышын канымның* (М. Җәлил).

**§ 185. Аерымланган сәбәп хәлләре.** Ияртүче кисәктән ерак тора торган сәбәп хәлләре аерым синтагма төзиләр һәм алар, һәрвакытта да дип әйтерлек, өтерләр белән аерылалар, ягъни аерымланалар. Мәсәлән: *Азатлыктан соң да, ярлылык сәбәпле мәктәп йөзе күрә алмады* (Г. Ибраһимов). *Рөхсәтсез кергәннәрнең кире чыгарылмаганын күргәч, халык берәм-берәм өйгә тулды* (Г. Ибраһимов). *Вакытлы ятып, вакытлы йоклап, вакытлы торганга күрә, ул бүген үзендә... бер көч сизә иде* (Ф. Әмирхан). *Кызлары, үкчәле туфлиләр киеп, берничә вершокка үсеп киткәннәр* (Ф. Хөсни).

**§ 186. Аерымланган кире хәлләр**. Ияртүче кисәктән ерак торган кире хәлләр аерым синтагма төзиләр һәм алар язуда күбесенчә аерымланалар да. Мәсәлән: *Анда, көннең кызуына карамастан, Фәхринең капкасы төбендә халык җыены тагы да зурая төшкән иде* (Г. Ибраһимов). *Хайваннар, симез, матур булсалар да, озак юл йөргәнгә, байтак талчыккан күренәләр* (И. Гази).

**§ 187. Аерымланган шарт хәлләре.** Шарт хәле, ияртүче кисәктән ерак торганда, аерым синтагма төзи һәм андый хәл язуда өтер белән аерыла, ягъни аерымлана. Мәсәлән: *Сары сандугачлар булсам, төшмәс идем һавадан* (М. Җәлил). *Эшлим икән, җиренә җиткереп куям.*

**Искәрмә**. Аныклагычлар һәм модаль кисәкләр, башлыча, аерымланып киләләр, шуңа күрә аларның аерымланганнарын аерым, аерымланмаганнарын аерым алып өйрәнүнең кирәге юк.

## АКТУАЛЬ КИСӘКЛӘР

**§ 188. Гомуми мәгълүмат**. Аралашу процессында, фикерне хәбәр итү өчен, сөйләүче җөмләләрдән файдалана. Җөмлә төзегәндә, ул бер төшенчәне атый һәм шул төшенчә турында нинди дә булса яңалык әйтә. Мәсәлән: *Быелгы кыш | карга юмарт булды* (Г. Ибраһимов). Биредә сөйләүче *быелгы кыш* төшенчәсен ала да аның турында *карга юмарт булды* дигән яңалыкны хәбәр итә.

Аның турында яңалык хәбәр итү өчен алынган төшенчә (һәм аны белдерүче сүзләр) с ө й л ә м  п р е д м е т ы дип атала. Сөйләм предметы сөйләүчегә дә, тыңлаучыга да, гадәттә, алдан таныш була: аның турында я алдагы җөмләләрдә сүз барган була, я ул тыңлаучыны да, сөйләүчене дә кызыксындырган уртак тема яисә аларга күренеп торган әйбер була. Шуннан чыгып, гомуми тел белемендә сөйләм предметын т е м а  һәм д а н н о е  терминнары белән дә атап йөртәләр. Хөкемләүнең (суждение) субъектына туры китереп, аны субъект дип атаучылар да бар.

Сөйләм предметын белдерүче кисәккә бервакытта да логик басым төшми. Югарыдагы мисалда сөйләм предметы – *быелгы кыш.*

Сөйләм предметы турында яңалык хәбәр итә торган сүзләр (һәм аның эчтәлеге) сөйләм яңалыгы дип атала. Гомуми тел белемендә сөйләм яңалыгын р е м а (рус телендә н о в о е) дигән термин белән дә билгелиләр, шулай ук аны, хөкемләүнең предикатына туры китереп, п р е д и к а т дип тә исемлиләр. Сөйләм яңалыгын белдерүче сүзләрнең иң әһәмиятлесенә һәрвакыт логик басым төшә. Югарыда китерелгән мисалда сөйләм яңалыгы – *карга юмарт булды*.

Сөйләм предметы һәм сөйләм яңалыгы җөмләнең актуаль кисәкләре дип йөртеләләр, чөнки аралашу процессында фикерне дөрес формалаштыру өчен, бу бүленешне һәм аның кисәкләрен белү зур әһәмияткә ия, ягъни аралашу моменты өчен әһәмиятле, актуаль.

Шулай итеп җөмлә, ничә сүздән торуына карамастан, ике актуаль кисәккә: сөйләм предметына һәм сөйләм яңалыгына бүленә.

Актуаль кисәкләрнең кайсына булса да һәрвакыт туры килә торган грамматик кисәкләр юк. Сөйләм предметына – теләсә кайсы грамматик кисәк, сөйләм яңалыгына шулай ук теләсә кайсы грамматик кисәк туры килергә мөмкин. Мәсәлән:

1. *Кояш | үзенең нурларын каршы яктан бәрә иде* (Г. Ибраһимов).
2. *Ишек алдында | эш тәмамланып килә иде инде* (Г.Минский).
3. *Көн ахырында | китаплар өелеп бетте* (Г.Минский).
4. *Арыган укучыларны | ашханәгә илттеләр.*

Сөйләм предметы – беренче җөмләдә иягә, икенчесендә – урын хәленә, өченчесендә – вакыт хәленә, дүртенчесендә тәмамлык группасына туры килә. Сөйләм яңалыгы исә беренче җөмләдә – тәмамлык, хәл һәм хәбәр белән, икенчесендә – ия һәм хәбәр белән, өченчесендә –

ия һәм хәбәр белән, дүртенчесендә урын хәле һәм хәбәр белән бирелгән.

Җөмләнең кисәкләрен фикер алышудагы әһәмиятләре буенча (мәгънә нагрузкалары буенча) ике төркемгә аеруны (ягъни, чех галиме В.Матезиус тарафыннан тәгъдим ителгән термин белән атаганда, җөмләнең актуаль бүленешен) беренче башлап грамматикада психологик юнәлешне яклаучылар кулланалар. Алар сөйләм предметын психологик ия, сөйләм яңалыгын психологик хәбәр дип атыйлар. Соңыннан инде рус тел белемендә актуаль бүленеш турында аерым хезмәтләр чыга [Распопов, 1961]. Татар тел белемендә исә җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше әле җитәрлек өйрәнелмәгән. Бу турыда сүз тәртибенә бәйле рәвештә кайбер фикерләр 1963 елда әйтелгәннәр [Закиев, 1963, с. 388–400], соңрак аларны киңрәк күләмдә Ф. Сафиуллина тикшерә [Сафиуллина, 1972, Учет актуального членения..., б. 22–42; Сафиуллина, 1972, Соотношение актуального..., б. 43–85].

Шулай итеп, җөмләне кисәкләргә өч төрле бүлү яшәп килә: грамматик (традицион), синтагматик һәм актуаль. Болардан беренчесе өйрәнелгән, калганнары, теоретик һәм практик әһәмиятләре бик зур булса да, бүгенге көнгә кадәр ныклап өйрәнелмәгәннәр әле.

**§ 189. Актуаль кисәкләрнең урыны**. Тыныч хикәяләү стилендә актуаль кисәкләрнең ике төрле урнашу очрагы бар. Беренче очрак. Хикәяләүне яки яңа фикерле абзацларны башлаганда һәм аерым алынган җөмләләрдә сөйләм предметы – алдан, сөйләм яңалыгы аннан соң урын ала. Бу тәртип, гадәттә, хәбәр сөйләм яңалыгын белдергәндә була һәм рус теле актуаль кисәкләре тәртибенә туры килә. Мәсәлән:

*Икенче көнне таңнан ук* | *Казбич килеп җитте* (На другой день рано утром | приехал Казбич).

*Дымовның* | *башы бик каты авырта иде* (У Дымова | сильно болела голова).

Икенче очрак. Контекст эчендәге җөмләләрдә хәбәр, алдан таныш булып, сөйләм предметын белдерүче сүзләр арасында калырга мөмкин. Димәк, бу очракта сөйләм яңалыгын хәбәрдән башка кисәкләр белдерәләр. Рус телендә бу очракта да актуаль кисәкләрнең тәртибе беренче һәм төп кагыйдәгә буйсына, ягъни сөйләм предметын белдерүче сүзләр (шул исәптән хәбәр) башта әйтелеп, соңыннан сөйләм яңалыгын белдерүче кисәкләр (хәбәрдән башкалары) килә. Мәсәлән:

*Лиза ждала его | целый день* (Гончаров). *Я возвращался в Кисловодск | в пять часов утра* (Лермонтов).

Татар телендә исә мондый тәртип дөрес булмый, чөнки анда хәбәр, актуаль кисәкнең кайсына туры килүенә карамастан, традиция буенча җөмләнең ахырында урнаша, сөйләм яңалыгын белдерүче кисәкләр хәбәр алдыннан янәшә куелалар һәм, гадәттәгечә, логик басымны алалар. Мәсәлән, югарыдагы русча җөмләләр актуаль кисәкләрнең татар теленә хас тәртибе буенча түбәндәгечә тәрҗемә ителергә тиешләр: *Лиза аны | көне буе | көтте. Мин Кисловодскига | иртәнге биштә | кайтып килә идем.* Бу җөмләләрдә сөйләм яңалыгын *көне буе* һәм *иртәнге биштә* кисәкләре белдерә һәм алар, сөйләм предметын ике өлешкә бүлеп, уртага кереп утырганнар. Димәк, икенче очракта актуаль кисәкләр өч җирдә урын алалар: беренче урында – сөйләм предметын белдерүче сүзләрнең хәбәрдән башкалары, икенче урында – сөйләм яңалыгы, өченче урында сөйләм предметын белдерүчеләрдән хәбәр килә.

Тагын бер мисал: *Мин монда | хикәямнең бер бүлеген төзәтеп чыктым. Калган бүлекләрен | кайткач | тәмамлаячакмын* (Г. Кутуй). Беренче җөмләдә актуаль кисәкләрнең тәртибе түбәндәгечә: сөйләм предметы – беренче урында, сөйләм яңалыгы – икенче урында, чөнки хәбәр сөйләм яңалыгын белдерүче сүзләр үзәгендә тора. Икенче җөмләдә актуаль кисәкләрнең тәртибе болай була: беренче урында – сөйләм предметын белдерүчеләрнең хәбәрдән башкалары, икенче урында – сөйләм яңалыгы, өченче урында – сөйләм предметының хәбәр белән бирелгән өлеше.

Җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленешен белү текст эчендәге мөстәкыйль җөмләләрнең мәгънәви эзлеклелеген өйрәнү өчен дә («Текст синтаксисы» бүлеген карагыз), тел белән практик эш иткәндә дә зур әһәмияткә ия.

**§ 190. Актуаль бүленеш һәм телне практик куллану.** Текст төзегәндә, аны редакцияләгәндә, тәрҗемә иткәндә, җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленешен истә тоту бик әһәмиятле. Моны белү бигрәк тә җөмләдә сүзләрне дөрес урнаштыру һәм, үзеннән-үзе аңлашыла торган артык сүзләрне төшереп калдырып, эчтәлекне мөмкин кадәр аз сүз белән бирә ала торган ким җөмләләр, җыйнак диалоглар төзү өчен кирәк.

Димәк, хәбәрнең сөйләм яңалыгын белдерү/белдермәвенә карап, актуаль кисәкләрнең җөмләдә урнашуы ике төрле була: 1) сөйләм предметына хәбәр керми һәм монда сөйләм предметы тулы килеш җөмлә башында урын ала; 2) сөйләм предметына хәбәр дә керә һәм мондый сөйләм предметының хәбәрдән башкалары – җөмлә башында, хәбәр – җөмлә ахырында, сөйләм яңалыгы болар арасында урын ала. Актуаль кисәкләрнең бу тәртибе сакланмаса, текст дөрес төзелмәгән була, кирәкле мәгънәне бирә алмый. Мәсәлән: *Бабайның бәхете икән: | ат терелде. Картка бөтен ике ел буенча хезмәт кылды. Аннан | кытлык килде. Бабай | ачлыктан шешенеп үлде. Ябыгып, тиресе сөягенә ябышып беткән Тимеркүкне | пот ярым алабута онына алмаштырдылар* (Г. Ибраһимов). Бу текстта хәбәр итүнең, фикер йөртүнең үз логикасы бар. Әгәр дә редакцияләү вакытында редактор яки автор актуаль кисәкләрне башкача урнаштырса, хәбәр итүнең логикасы бозыла, бөтенләй башкача логик эзлеклелек барлыкка килә. Мәсәлән, менә болай: *Бабайның бәхете икән: | ат терелде. Бөтен ике ел буенча | картка хезмәт кылды. Кытлык | аннан соң килде. Ачлыктан шешенеп, | бабай үлде. Пот ярым алабута онына | ябыгып, тиресе сөягенә ябышып беткән Тимеркүкне дә алмаштырдылар.*

Актуаль кисәкләрнең урынын дөрес билгеләү, рус теленнән татарчага тәрҗемә иткәндә, тагын да әһәмиятле. Хәбәре сөйләм яңалыгын белдергән җөмләне тәрҗемә иткәндә, русчада һәм татарчада актуаль кисәкләр тәртибе бер үк була. Мәсәлән: 1) *В половине девятого утра | выехали из города* (А. Чехов). Дөрес тәрҗемәсе: *Иртәнге тугызынчы яртыда | шәһәрдән чыгып киттек. Шәһәрдән | иртәнге тугызынчы яртыда чыгып киттек* – дөрес тәрҗемә түгел. 2) *Дымов... | тихо запел* (А. Чехов). Дөрес тәрҗемәсе: *Дымов | әкрен генә җырлап җибәрде. Әкрен генә | Дымов җырлап җибәрде* – дөрес тәрҗемә булмый.

Хәбәре сөйләм предметын белдергән җөмләне тәрҗемә иткәндә, актуаль кисәкләрнең урыны русча һәм татарчада бер төрле үк булмый: русчада хәбәр сөйләм предметын белдерүче башка сүзләр белән бергә җөмлә башында килә, җөмлә ахырында сөйләм яңалыгы урын ала. Татарчада исә традиция буенча хәбәр җөмлә ахырында куела, сөйләм яңалыгы аның алдыннан янәшә урнаша. Ягъни бу очракта русчада җөмлә ахырындагы сүз, татарчада хәбәр алдыннан янәшә

торырга тиеш. Югарыда искә алынган мәкаләсендә Ф. Сафиуллина дөрес һәм ялгыш тәрҗемәләргә түбәндәге мисалларны китерә. Дөрес тәрҗемәләр: *Анниныка провела ночь | беспокойно* (С.-Щедрин) – *Аннинька төнне | тынычсыз үткәрде. Первый побежал пить | Дымов* (А. Чехов) – *Эчәргә, беренче булып, | Дымов йөгерде. Он проснулся | от пристального взгляда* (К. Симонов) – *Ул | текәлеп караудан | уянып китте.*

Ялгыш тәрҗемә: *Коршуновы приехали | уже после того, как | жениха с невестой увезли в церковь* (М. Шолохов) – *Кияү белән кызны чиркәүгә алып киткәннән соң гына, | Коршуновлар килделәр.* (Булырга тиеш иде: *Коршуновлар | кияү белән кызны чиркәүгә алып киткәннән соң гына | килделәр*).

Актуаль кисәкләрнең урынын дөрес билгеләү сорауга җавап язганда һәм гомумән диалог төзегәндә дә бик әһәмиятле. Мәсәлән: *Кемнәр бу атнада гына ялдан кайттылар?* соравына телдән җавапны теләсә ничек төзеп була, тик сөйләм яңалыгына логик басымны гына куярга кирәк. *Без* сүзенә логик басым төшереп, *Без – бу атнада гына ялдан кайттык* дип әйтсәң дә, ялгыш булмый. Ә алай язарга ярамый, чөнки укучы кеше аның хәбәрдән алдагы сүзенә логик басымны куеп укый һәм җавап дөрес булмый. Ул *Сез бу атнада гына кайдан кайттыгыз?* дигән сорауга җавап булып чыга. Димәк, *Кемнәр бу атнада гына ялдан кайттылар?* соравына дөрес җавап болай язылырга тиеш: *Бу атнада гына ялдан без кайттык.* Диалогта булса, җавап бары *Без* сүзеннән генә тора. Димәк, диалог төзегәндә, җавап репликалары бары сөйләм яңалыгыннан гына торсалар, стиль тагын да яхшырак була.

## ҖӨМЛӘДӘ СҮЗ ТӘРТИБЕ

**§ 191. Сүз тәртибенең роле**. Сүзтезмәләрдә һәм җөмләләрдә сүзләрнең урнашу тәртибе зур роль уйный.

Сүз тәртибе сүзтезмәләрдә һәм җөмләләрдәге сүзләр арасында төрле мәгънә мөнәсәбәтләрен урнаштыруда катнаша. Мәсәлән, *Яулык кызыл* дигән тезмәдәге исем белән сыйфат арасында хәбәрлекле мөнәсәбәт урнашкан. Әгәр шундагы сүз тәртибе алмашынса, исем

белән сыйфат арасында төгәлләүле мөнәсәбәт барлыкка килер иде: *кызыл яулык*.

Сүз тәртибенең сүзләрне үзара бәйләү көче кушымчаларның бәйләү көченә тигез була. Мәсәлән: *Ана бала ярата* дигән җөмләдә *бала* белән *ярата* сүзләре арасындагы объектлык мөнәсәбәте сүзләрнең янәшә килүләре белән бирелә. Әгәр дә сүзләрнең тәртибен үзгәртеп, *бала* һәм *ярата* сүзләрен бер-берсеннән аерсак, ягъни *Бала ана ярата* дип әйтсәк, *бала* белән *ярата* сүзләре арасында объектлык мөнәсәбәте югала, хәбәрлекле мөнәсәбәт урнаша. Ул сүзләр арасындагы объектлык мөнәсәбәтен кире кайтару өчен, сүз тәртибен үзгәртеп тормыйча, *бала* сүзен төшем килешендә кую да җитә: *Баланы ана ярата*. Димәк, бу очракта сүз тәртибенең (һәм янәшә тору чарасының) биргән мөнәсәбәтен төшем килеше кире кайтара.

Тагын бер мисал. *Кичә булган студентлар җыелышы* тезмәсендә *студентлар* кисәге *җыелышы* сүзенә янәшә торып кына бәйләнә. Шул хәлендә аларны аерып, *студентлар кичә булган җыелышы* дип әйтеп булмый, чөнки *студентлар* сүзе белән *җыелышы* сүзләре арасында мәгънә мөнәсәбәте югала. Мәгънә мөнәсәбәтен кайтару өчен, иялек килешен куярга һәм *студентларның кичә булган җыелышы* дияргә була. Димәк, бу очракта да сүз тәртибенең бәйләү көче кушымчаның бәйләү көченә тигез була.

Сүз тәртибе җөмләнең синтагмаларга бүленеше белән дә тыгыз бәйләнгән. Мәсәлән: *Күләгәдә утырып, | әле яңа гына өлгергән бәрәңгеләрне ашыйсы килә* (Г. Ибраһимов) дигән мисалда *күләгәдә утырып* кисәге, үзе буйсынган сүздән ераграк килеп, аерым синтагма төзегән. Үзе буйсынган сүз белән янәшә торса, ул аерым синтагма төзи алмас иде: *Әле яңа гына өлгергән бәрәңгеләрне күләгәдә утырып ашыйсы килә*.

Сүз тәртибенең стилистик роле дә бик зур. Ул тойгыга бай булмаган һәм тойгыга бай булган сөйләмне төзүдә актив катнаша. Тойгыга артык бай булмаган сөйләмдә җөмләне тәмамлап куючы буларак хәбәр килә, һәм сүзләр арасында уңай тәртип була. Тойгыга бай булган сөйләмдә, бигрәк тә поэзиядә, сүз тәртибе гадәттәгедән кире була.

**§ 192. Төрле стильләрдә сүз тәртибен билгеләүче факторлар**. Сүз тәртибен өйрәнә башлаганда, аның төрле стильләрдә төрлечә булуына игътибар итмәгәннәр. Шуңа күрә кайбер телчеләр, язма сөй-

ләмне генә өйрәнеп, гомумән татар телендә сүз тәртибе шактый ныклы дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Икенчеләре, әйтмә сөйләмне өйрәнеп, татар телендә сүз тәртибе ирекле дип раслаганнар.

Чынлабрак тикшереп караганда, татар теленең төрле стильләрендә сүз тәртибе төрлечәрәк икән, чөнки сүзләрнең урнашуына төрле стильдә төрле факторлар тәэсир итә.

Әйтмә сөйләмдә, ягъни телдән сөйләп торганда, сүзләр шактый ирекле дә урнаша алалар, шулай да алар арасындагы бәйләнеш һәм мәгънә аңлашыла, чөнки бу очракта интонация бик зур ярдәм итә. Әйтмә сөйләм стиле үзе ике төрле була: гади сөйләм һәм әдәби сөйләм. Гади сөйләмдә сүзләр бик ирекле урнашалар, әдәби сөйләмдәге сүз тәртибенә исә язма әдәби тел тәэсир иткән була. Шуңа күрә анда сүзләрнең урнашу тәртибе артык ирекле булмый.

Язма сөйләмдә сүз тәртибенә интонация артык зур тәэсир итә алмый, ягъни без язуда интонацияне билгеләр белән күрсәтә алмыйбыз. Шуңа күрә язма сөйләмдә сүзләрнең гадәти, билгеле урыннары була. Язма сөйләм, сүз тәртибенең характеры ягыннан караганда, үзе ике төрле була: эмоциональ язма сөйләм һәм гадәти язма сөйләм. Эмоциональ язма сөйләмдә сүз тәртибе көчле тойгы тәэсире нәтиҗәсендә шактый үзенчәлекле була. Язма сөйләмнең шигъри төрендә исә сүз тәртибенә рифма һәм ритм да зур тәэсир ясый.

Гадәти язма сөйләмдә сүз тәртибе ныклы. Анда сүз тәртибен күптөрле факторлар билгели, шуларның иң сизелерлеге түбәндәгеләр: актуаль кисәкләрнең урыннары (мәгънә нагрузкалары), сүзләрне үзара бәйләүче чараларның бәйләү көче, электән килә торган традиция һ.б. Алга таба шушы факторлардан чыгып, һәрбер кисәкнең урыны караладак.

**§ 193. Сүзләрнең уңай тәртибе**. Бу мәсьәлә үзара ияртү бәйләнешендә тора торган сүзләргә генә карый. Үзара тезү юлы белән бәйләнгән сүзләргә, ягъни тиңдәш кисәкләргә карата уңай тәртип һәм кире тәртип терминнары кулланылмый.

Тыныч хикәяләү сүзләрнең уңай тәртибе булу белән характерлана. Уңай тәртип булганда, алар түбәндәгечә урнашалар: а) хәбәрлекле мөнәсәбәттәге кисәкләрнең ияртүчесе иярүчедән алда килә. Димәк, ия хәбәрдән алда куела; ә) төгәлләүле мөнәсәбәттәге кисәкләрнең, киресенчә, иярүчесе ияртүчедән алда куела, шуның өчен аергыч

аерылмыштан, тәмамлык һәм хәл ияртүче кисәктән алда куела; б) аныклагыч исә, бу иярчен кисәкләрдән аермалы буларак, аныкланмыштан соң куела. Җөмләдә сүз тәртибен ничек кенә үзгәртсәң дә, әгәр югарыдагы шартлар сакланса, анда уңай тәртип була. Мәсәлән: *Бу урынга узган ел Гайфи – Әхәтнең бабасы укучылар көче белән бакча утырткан; Узган ел бу урынга Гайфи – Әхәтнең бабасы укучылар көче белән бакча утырткан; Гайфи – Әхәтнең бабасы бу урынга узган ел укучылар көче белән бакча утырткан; Бу урынга укучылар көче белән Гайфи – Әхәтнең бабасы узган ел бакча утырткан; Укучылар көче белән бу урынга узган ел Гайфи – Әхәтнең бабасы бакча утырткан* һ.б. Бу җөмләләрнең берсендә дә сүзләрнең кире тәртибе юк, чөнки югарыдагы шартлар сакланган.

Сүзләрнең болай урыннарын алмаштыруга нәрсә тәэсир итә соң? Гадәти язма сөйләмдә сүзләрнең урнашу тәртибенә актуаль кисәкләрнең тәртибе бик нык тәэсир итә.

Алда әйтелгәнчә, рус телендәге гадәти сөйләмдә сөйләм предметын белдерүче сүзләр – беренче, сөйләм яңалыгын белдерүче сүзләр икенче (соңгы) урында урнашалар. Татар телендә исә бу тәртипкә хәбәрнең җөмләне тәмамлап куярга омтылуы да тәэсир итә. Шуңа күрә бездә актуаль кисәкләр ике төрле урнашалар.

1. Әгәр дә җөмләнең сөйләм предметын белдерүче өлешенә хәбәр кермәсә, сөйләм предметын белдерүче өлеш беренче урында килә. Мәсәлән: *Бүген нәрсә эшләдегез?* дигән сорауга җавап булып килә торган *Без бүген мастерскойда урындыклар ясадык* дигән җөмләдә *Без бүген* өлеше сөйләм предметын белдерә һәм беренче урында тора. *Мастерскойда урындыклар ясадык* өлеше тыңлаучыга яңалыкны хәбәр итә, димәк, ул яңалык өлеше була. Бу өлеш җөмләнең ахырына урнашкан.

2. Әгәр дә җөмләнең сөйләм предметын белдерүче өлешенә хәбәр дә керсә, бу вакытта сөйләм предметын белдерүче сүзләрнең хәбәрдән башкалары җөмләнең башында, ә хәбәр җөмләнең ахырында урнаша. Яңалык өлеше исә хәбәр алдыннан урын ала. Мәсәлән, *Бу китапны студентлар кайдан алдылар?* дигән сорауга җавап булып килә торган *Бу китапны студентлар китапханәдән алдылар* дигән җөмләдә сөйләм предметы (ягъни тыңлаучыга таныш булган өлеше) – *бу китапны студентлар алдылар* дигән өлеше – җөмләнең башында да,

ахырында да килә, ә яңалык өлеше *китапханәдән* хәбәр алдыннан куела. Рус телендә исә андый кисәк җөмлә ахырында куелыр иде: *Эту книгу студенты взяли из библиотеки*. Яңалык өлеше булып җөмләнең (хәбәрдән кала) башка кисәкләре килсә, алар да хәбәр алдыннан (ә рус телендә җөмлә ахырында) куелыр иде. Мәсәлән: *Бу китапны китапханәдән студентлар алдылар* 'Эту книгу из библиотеки взяли студенты'; *Студентлар китапханәдән бу китапны алдылар* 'Студенты взяли из библиотеки эту книгу'. Шулай итеп рус теленең гадәти язма сөйләмендә мәгънә нагрузкасы буенча сүз тәртибе болай була: сөйләм предметы – сөйләм яңалыгы; ә татар телендә ике төрле. I очракта: сөйләм предметы – сөйләм яңалыгы; 2 нче очракта: сөйләм предметы – сөйләм яңалыгы – сөйләм предметы (хәбәр).

Татар теле җөмләләрендәге туры тәртипнең тагын бер үзенчәлеге бар. Гадәти сөйләмдә хәбәр группасына караган кисәкләр ия группасына караган кисәкләр арасына керә алмыйлар. Бу яктан ия группасы ныклы бер төркем тәшкил итә. Хәбәр группасына караган сүзләр арасына исә ия группасы бик җиңел керә. Хәбәр группасына караган бер кисәк, сөйләм предметын белдереп, беренче урынга куелганда, ия группасы шул кисәк белән хәбәр арасында кала. Мәсәлән, *Әлеге эшкә быел гына диплом алган бик күп кешеләр кушылдылар* дигән мисалда ия группасы *быел гына диплом алган бик күп кешеләр* хәбәр группасына караган сүзләр арасына кергән, һәм бу – сүзләрнең уңай тәртибен бозмаган.

**§ 194. Сүзләрнең кире тәртибе**. Сүзләрнең кире тәртибе, ягъни инверсия, күбрәк телдән сөйләмдә һәм көчле тойгы белән әйтелгән җөмләләрдә була. Кире тәртип булганда, сүзләр түбәндәгечә урнашалар: а) үзара хәбәрлекле мөнәсәбәткә кергән сүзләрнең иярүчесе (хәбәр) алдан, ияртүчесе (ия) аннан соң килә; ә) үзара төгәлләүле мөнәсәбәткә кергән сүзләрнең ияртүчесе алдан, иярүчесе аннан соң килә, димәк, аергыч, тәмамлык һәм хәл ияртүче кисәкләрдән соң урнашалар.

Аныклагыч белән аныкланмыш арасында һәм модаль кисәкләрдә инверсия күренеше булмый. Әгәр дә аныклагыч һәм аныкланмышның урыннары алмашынса, алар урыннары белән генә түгел, функцияләре белән дә алмашыналар. Ягъни аныклагыч белән аныкланмыш кайсы урынга гына куелса да, алдан килгәне – аныкланмыш, соңыннан

килгәне аныклагыч итеп танылa. Мәсәлән, *Без язны – гөлләр патшасын зур түземсезлек белән көттек* дигән җөмләдә *гөлләр патшасын* дигән аныклагыч *язны* аныкланмышы алдыннан куелса да, инверсия барлыкка килми. (*Без гөлләр патшасын – язны зур түземсезлек белән көттек.*) Монда сүзләрнең урыннары алмашыну белән бергә, аларның функцияләре дә алмашына: *язны* сүзе – аныклагыч, *гөлләр патшасын* сүзе аныкланмыш итеп кабул ителә.

## ҖӨМЛӘ КИСӘКЛӘРЕНЕҢ УРЫНЫ

**§ 195. Хәбәрнең урыны.** Гадәти язма сөйләмдә хәбәр җөмләнең ахырында килә: *Көн бик кызу. Кояш кыздыра* (Г. Ибраһимов).

Тойгыга бай булган сөйләмдә хәбәр еш кына, яңалыкны белдерүче кисәк буларак, җөмлә алдына чыгарыла, чөнки тойгылы җөмләләрдә яңалык өлеше иң элек әйтелә торган була: *Рәхәт тә соң шушы олыларга тагылып йөрү!* (Г. Ибраһимов).

Сөйләмә әдәби телдә һәм гади сөйләмдә хәбәр теләсә нинди урында килергә мөмкин, чөнки бу очракта сүз тәртибе, җөмләне оештыручы буларак, зур роль уйнамый, бу рольне интонация башкара.

Шигъри сөйләмдә дә, тойгы, ритм һәм рифма таләпләре буенча, хәбәр теләсә кайсы урында килә ала.

**§ 196. Иянең урыны.** Гадәти язма сөйләмдә ия хәбәр алдындагы теләсә нинди урында килергә мөмкин. Әгәр дә сөйләм предметын белдерсә, (үзе генә яки үзенә ияргән кисәкләр белән бергә) ул җөмлә башында килә: *Баш врач аның янына килеп утырды* (А. Шамов). Әгәр дә ия яңалык белдерсә, ул логик басым ала һәм (үзе генә яки үзенә ияргән кисәкләр белән бергә) хәбәр алдыннан янәшә куела: *Шәйхетдинов исеменә бер хат килде. Хат эченнән открытка зурлыгында гына бер фоторәсем килеп чыкты* (А. Шамов). Ниһаять, әгәр дә ия турыдан-туры сөйләмнең предметын да, яңалыгын да белдермәсә, ул сөйләм предметын һәм яңалыгын белдерүче сүзләр арасына куела: *Кечкенә калай тартмадан Гөлзифа чәйнеккә чәй салып маташа иде* (Р. Төхфәтуллин).

Тойгылы сөйләмдә, шигъри әсәрләрдә һәм гади сөйләмдә ия җөмләнең теләсә кайсы урынында килә ала.

**§ 197. Аергычның урыны**. Гадәти язма сөйләмдә аергыч аерылмыштан алда куела. Аергыч белән аерылмыш арасына башка кисәкләр керә алмый, анда шул ук аерылмышка караган башка бер аергыч кына куелырга мөмкин. Димәк, аергыч үзенең аерылмышыннан читкә китә алмый, аерылмыш кайда булса, ул да шунда килә.

Бер үк аерылмышка караган тиңдәш булмаган аергычлар, бәйләүче чараларның көченә һәм үзләренең мәгънә йөкләнешләренә карап, төрле тәртиптә урнашалар. Тиңдәш булмаган аергычларның янәшә тору чарасы ярдәмендә ияргәннәре аерылмыш белән янәшә урнашалар, башкалары, бәйләүче чараларның ияртү көченә карап, аерылмышка төрле ераклыкта урын алалар. Ияртү көче зуррак булган чара ярдәмендә бәйләнгән аергыч аерылмыштанераграк та урнаша ала, ияртү көче азрак булган чара белән бәйләнгән аергыч аерылмышка якынрак торырга тиеш була. Күрсәтү алмашлыгы белән бирелгән аергыч төрле урыннарда килә ала, ул бары төп сыйфатлар һәм билгесез килештәге исемнәр белән бирелгән аергычлардан соң гына урнаша алмый.

Бер аерылмышка барлык төр аергычларның да берьюлы иярүе сирәк була. Бер үк аерылмышка караган күп аергычларның тәртибен түбәндәге мисалдан күзәтеп була: (1) *Безнең кырдагы* (2) *быел утыртылган* (3) *сирәк күзәнәкле* (4) *берьеллык* (5) *сары* (6) *«Лорх» бәрәңгесе бик зур уңыш бирде*. Биредә аерылмыш – *бәрәңге* сүзе. Аергычлары: 1) *безнең кырдагы*, ул аерылмыштан бик ерак урнашкан, чөнки *-дагы* дигән бәйләүче чараның бәйләү көче бик зур; 2) *быел утыртылган*, бу аергычта бәйләүче чара *-ган*, аның да бәйләү көче зур; 3) *сирәк күзәнәкле*, бу аергыч та аерылмыштан читтәрәк тора ала, чөнки анда *-ле* бәйләү чарасы бар; 4) *берьеллык* аергычы аерылмышка якынрак тора, аны шуннан да читкә этеп булмый, чөнки андагы *-лык* кушымчасының бәйләү көче азрак, ул күбрәк лексик мәгънә бирә; 5) *сары* аергычы төп сыйфат белән бирелгән, аның кайсы аерылмышка каравын лексик мәгънәдән генә белеп була, шуңа күрә ул аерылмыштан ерак китә алмый; 6) *«Лорх»* аергычы исем белән бирелгән һәм аерылмышка бары янәшә торып кына бәйләнә ала, чөнки башка чарасы юк. Тагын бер мисал: (1) *Безнең авылның* (2) *Гали батырдай* (3) *типсә тимер өзәрлек* (4) *баһадир егетләре*…

Аергычлар арасындагы бу тәртип мәгънә йөкләнеше таләбе буенча үзгәрергә дә мөмкин. Мәсәлән, сыйфат фигыль кушымчасы белән

бәйләнгән аергыч иялек килеше белән бәйләнгән аергычтан алда урнаша ала: *Күлнең кыйбла ягына утырган безнең авыл да... шәһәрдән ким түгел* (Г. Ибраһимов). Аерылмышка бер үк төрле чара ярдәмендә бәйләнгән аергычлар да мәгънә нагрузкалары буенча урнашалар, мәсәлән: *сары биек йорт – биек сары йорт.*

Тойгылы җөмләләрдә һәм гади сөйләмдә аергыч аерылмыштан соң да, аннан ераграк та килә ала:

*Син китәсең, безне базга бикләп,*
*Хуш, иске ел, – к ө м е ш  с а к а л л ы !* (М. Җәлил)

*Я, анда теге кыз, Салихова, ничек тора с е з н е ң ?* (А. Шамов)

**§ 198. Тәмамлык һәм хәлләрнең урыны**. Гадәти язма сөйләмдә тәмамлык һәм хәлләр ияртүче кисәктән алда киләләр, ләкин аларның ияртүче кисәк белән янәшә торулары мәҗбүри түгел, бары янәшә тору чарасы ярдәмендә ияргән тәмамлыклар һәм кайбер хәлләр генә ияртүче кисәк белән янәшә урнашырга тиеш булалар. Башка төрле тәмамлыклар һәм хәлләр, үзләренең коммуникатив нагрузкаларына карап, җөмләнең төрле урыннарында килә алалар. Әгәр тәмамлык һәм хәлләр сөйләмнең предметын белдерсәләр, алар җөмлә башында урнашалар: *Өй туенда уен-көлкенең чиге булмады* (Р. Вәлиев). Әгәр тәмамлык һәм хәлләр сөйләмнең яңалыгын белдерсәләр, алар хәбәрдән алда янәшә урнашалар: *Атасы пароходларны т а в ы ш л а р ы н н а н таный* (Г. Ибраһимов). *Аннары Биктаһир карт белән атасы тагын с у г ы ш  т у р ы н д а сөйләштеләр* (И. Гази). Әгәр дә тәмамлык һәм хәлләр сөйләмнең яңалыгын да, предметын да турыдан-туры белдермәсәләр, алар предмет һәм яңалык белдерүче кисәкләр арасында куелалар: *Кичләрен Х ә л и м н ә р  а в ы л ы н а  д а пароход тавышы ишетелә* (И. Гази).

Тойгылы җөмләләрдә һәм гади сөйләмдә тәмамлык һәм хәлләр җөмләнең теләсә кайсы урынында килергә мөмкиннәр: *Бер заман, кара болыт булып, казак килеп чыкты т а у  а р т ы н н а н* (халык иҗаты). *Чыгарасы иде бит моны б у  с а з л ы к т а н !* (И. Гази).

*Әкияттәге серле йомгак булып,*
*Җырым калды, сүтелеп юлымда,*
*Сез табарсыз, килеп шушы эздән,*
*Мине соңгы йөрәк җырымда* (М. Җәлил).

**§ 199. Аныклагычның урыны**. Аныклагыч үзенең аныкланмышыннан һәрвакыт соң килә. Гадәти язма сөйләмдә ул аныкланмыш белән янәшә тора. Бары тойгылы җөмләдә, поэзиядә һәм гади сөйләмдә аныклагыч үзенең аныкланмышыннан ерак торырга мөмкин: *Ул үзенең а х и р ә т е н каршы алды – җан д у с т ы н* (Х. Сарьян). *Без к е м б е л ә н сөйләштек, ягъни н и н д и з в а н и е л е к е ш е б е л ә н? Мин озаттым а н ы сугышка, й ө р ә г е м н е ң с ү н м ә с к о я ш ы н* (М. Җәлил).

**§ 200. Модаль кисәкләрнең урыны**. Хәбәрлек эчтәлеген тәшкил итә торган башка кисәкләрнең гадәти сөйләмдә ныклы урыннары бар. Ул урыннар, нигездә, актуаль кисәкләрнең урыннары белән, сүзләрнең үзара бәйләнеш төрләре һәм бәйләүче чараның көче белән билгеләнә.

Модаль кисәкләр хәбәрлекне түгел, модальлекне белдерүдә катнашалар һәм аларның урыннары да модальлекнең характерына карап билгеләнә.

Эндәш сүзләр сөйләүченең сөйләм төбәлгән затка (әйбергә) мөнәсәбәтен белдерәләр һәм алар гомумән җөмләгә карыйлар.

Тыңлаучының игътибарын җәлеп итәргә кирәк булса, эндәш сүзләр җөмлә башында әйтеләләр. Җөмлә башында әйтелгән эндәш сүздән соң тыңлаучы игътибарсыз калса, сөйләүче сөйләмне дәвам итмәскә тиеш. Мисаллар: *Иптәшләр! Иптәшләр! Тавышланмагыз, мин хәзер сезгә дөреслекне әйтәм!* (Г. Бәширов). *Адъютант иптәш, укып карагыз әле* (Ш. Усманов).

Тыңлаучы игътибарын җәлеп итү мәҗбүри булмаса, эндәш сүз бары тыңлаучыга илтифатлык билгесе генә булса, ул, гадәттә, җөмлә ахырында килә. Мондый эндәш сүз түбәнрәк тавыш белән әйтелә һәм ул, күбрәк, нәсерләрдә, хатирәләрдә, нечкә лиризм белән сугарылган әсәрләрдә кулланыла. Мәсәлән: *Синең белән бик күптәннән инде иркенләп сөйләшәсем килә, Назим!* (Э. Касыймов). *Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!* (Г. Кутуй).

Җөмлә уртасында килгән эндәш сүзләр дә күбрәк сөйләүченең тыңлаучыга илтифатлы мөнәсәбәттә торуын белдерәләр. Мәсәлән: *Сезнең миңа эшләгән яхшылыкларыгызны, Заһид Сафич, беркайчан да онытмам, рәхмәт сезгә!* (А. Расих).

Кереш сүзләр гомумән җөмләгә дә, аның бер кисәгенә дә карый алалар. Җөмлә кисәгенә караган кереш сүзләр шул кисәк янында

киләләр. Мәсәлән: *Ә хәзер аны, әйтерсең, алмаштырганнар* (Г. Әпсәләмов). – *Ә хәзер, әйтерсең, аны алмаштырганнар. Рәхәт тә соң, валлаһи, бу машина белән ашлык сугулар!* (Г. Ибраһимов). – *Машина белән ашлык сугулар рәхәт тә соң, валлаһи!*

Гомумән җөмләгә караган кереш сүзләр күбрәк җөмлә башында куелалар һәм бу очракта аларның мәгънәсе сөйләүчегә тагын да кирәгрәк булып тоела. Мәсәлән: *Хәер, дөньяда тоташмаган ярлар да бик күп бит әле!* (Ә. Баянов).

Гомумән җөмләгә караган кереш сүзләр ахырдан килгәндә, аларның мәгънә нагрузкалары кими кебек, хәтта ул интонацион яктан да хәбәргә кушылып китнәли. Мәсәлән: *Күңеле дә күтәренке иде бугай* (Г. Әпсәләмов). *Ул беренче булып тәмамлаган имеш!* (Ш. Камал). *Нокта Вәлинең авылга килгәненә ике генә көн булган янәсе!* (Ш. Камал).

**§ 201. Тиңдәш кисәкләрнең урыны.** Тиңдәш ияләр, аергычлар, тәмамлыклар һәм хәлләр, гадәттә, үзара урын сайламыйлар. Ә тиңдәш хәбәрләрнең үзара шактый билгеле урыннары була. Әгәр дә тиңдәш хәбәрләр параллель күренешләрне белдерсәләр, аларның гомумирәк эшне белдерә торганнары башта әйтелә, калганнары соңыннан килә: *Җәй көне эссе һавада мин суда коенам, йөзәм, чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм* (Г. Тукай).

Әгәр тиңдәш хәбәрләр эзлекле күренешләрне белдерсәләр, алар шул эзлеклелеккә карап урнашалар: *Зыятдин бабай ике кулын артка куйды, шактый вакыт арлы-бирле йөргәч, өйгә керде, су буена төшеп менде, мунчаны карап чыкты, лапастагы коралларны урыннарыннан алып яңадан тезде* (Р. Вәлиев).

## ӨСТӘЛМӘЛӘР

**§ 202. Сөйләмә телдәге сүз тәртибенең әдәби телгә үтеп керүе нәтиҗәсендә формалашкан күренеш буларак өстәлмәләр.** Җөмләнең берәр кисәген җөмлә ахырына чыгарып, өстәп әйтү – сөйләмә телдә гадәти күренеш. Әдәби телнең халык сөйләменә якынаюы процессында менә шундый ирекле тәртип әдәби телгә дә үтеп керә, ягъни әдәби телдә дә җөмләнең аерым кисәкләрен җөмлә ахырына калдырып, җөмләдән пауза белән аерып әйтәләр, язуда аны төп җөм-

ләдән нокта белән аералар. Шулай итеп өстәлмә дигән яңа синтаксик күренеш формалаша. Берничә мисал. *Киткән тәкъдирдә дә, халык сине сагынып искә алырлык итеп китәргә кирәк. Ә т и е ң к е б е к* (С. Шәкүров). *Эх, менә хәзер киң канатлы бөркет буласы иде дә югарыга күтәреләсе иде. К а н а т л а р н ы к и ң җ ә е п* (Г. Гобәй). Бу мисалларда, өстәлмәләр булып, *әтиең кебек, канатларны киң җәеп* сүзләре һәм тезмәләре килгәннәр.

Сөйләмә телдәге сүз тәртибенең әдәби телгә тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килгәнгә, өстәлмәләрне «сүз тәртибе» проблемаларына бәйләп өйрәнү кабул ителгән.

**§ 203. Өстәлмәнең мәгънә йөкләнеше һәм аның билгеләмәсе.** Җөмләнең аерым кисәкләрен җөмлә тышына чыгарып, аларны өстәлмә итеп формалаштырып, язучы аларның мәгънәләренә игътибарны тагын да ныграк җәлеп итә. Өстәлмәнең мәгънәсе җөмлә эчендә логик басым алган сүз мәгънәсеннән дә әһәмиятлерәк була. Чагыштыру өчен, югарыдагы параграфта китерелгән өстәлмәләрне җөмлә эченә кертеп, аңа логик басым төшә торган итеп, җөмләне үзгәртеп төзеп карыйк: *Киткән тәкъдирдә дә, халык сине сагынып искә алырлык итеп, ә т и е ң к е б е к итеп китәргә кирәк. Эх, менә хәзер киң канатлы бөркет буласы иде дә, к а н а т л а р н ы к и ң җ ә е п, югарыга күтәреләсе иде*. Югарыда телгә алынган өстәлмәләр бу җөмләләрдә гадәттәге кисәкләр булып киткәннәр һәм алар, хәбәр алдыннан куелып, логик басымны алалар, ягъни сөйләм яңалыгын белдерәләр. Мондагы *әтиең кебек*, *канатларны киң җәеп* рәвеш хәлләрен шул ук тезмәләрдән торган өстәлмәләр белән чагыштырып карасак, өстәлмәләрнең мәгънәсенә ныграк басым ясалганны күрәбез. Алар сөйләм яңалыгын тагын да ачыграк, ассызымлабрак белдерәләр.

Өстәлмәләр, аерым җөмлә кебек үк, алдагы җөмләдән зур пауза белән аерылалар. Алдагы җөмлә үзе тәмамланган җөмлә булып аңлашыла, интонацион яктан өстәлмә дә аерым бер җөмлә кебек әйтелә. Алар арасында аерым җөмләләр арасында була торган интонация ясалмаса, өстәлмә барлыкка килмичә, җөмлә кисәкләренең инверсиясе күзәтелә. Мәсәлән, югарыда китерелгән җөмләне интонацион яктан үзгәртеп карыйк: *Эх, менә хәзер киң канатлы бөркет буласы иде дә югары күтәреләсе иде, канатларны киң җәеп*. Биредә *канатларны киң җәеп* кисәге җөмләнең интонациясенә керә, үзе аерым җөмлә

интонациясе төземи, шуңа күрә ул өстәлмә була алмый, бары инверсион хәл итеп кенә таныла.

Шулай итеп, мәгънәсенә аерым игътибар юнәлтү өчен, җөмләнең кайсы да булса бер кисәген, ахырга чыгарып, аерым җөмлә интонациясе белән әйтү нәтиҗәсендә өстәлмә дигән синтаксик берәмлекләр барлыкка килә. Шулардан чыгып, аңа билгеләмәне түбәндәгечә бирергә мөмкин. Мәгънәсенә ныграк игътибар иттерү өчен, төп җөмлә ахырына чыгарылган һәм аерым җөмлә интонациясе белән әйтелгән сүз яки сүзтезмә өстәлмә дип атала.

Өстәлмә, бер яктан, аерым җөмләгә охшый, чөнки төп җөмлә янында торганда хәбәр итә, аерым интонацион бөтен төзи. Икенче яктан, ул җөмлә кисәгенә охшый, чөнки төп җөмләдән башка хәбәр итә алмый. Шул ук вакытта өстәлмә җөмләләрдән дә, җөмлә кисәкләреннән дә аерылып тора, тегесенә дә, монысына да керми, димәк, аерым синтаксик берәмлек буларак таныла. Синтаксис фәнендә өстәлмәләр темасы гади һәм кушма җөмлә темалары арасында тора.

**§ 204. Өстәлмәләрне өйрәнүнең кыскача тарихы.** Рус телендә өстәлмәләр «присоединительные конструкции» исеме астында бик җентекле өйрәнелгәннәр. Татар телендә өстәлмәләрне беренче булып К.Сабиров күрә. Ул аларны теркәгечләр белән башланган ким җөмләләр белән бергә ала, тиңдәш кисәкләргә якынайта һәм, рус телендәге «присоединительная связь» терминын тәрҗемә итеп, өстәлмә бәйләнеш дип атый [Сабиров, 1956, б. 44, 104–105].

Өстәлмәләрнең кайбер төрләрен без үзебезнең элекке китапларда ким җөмләләр рәтеннән карый идек: *Болар шунда бәйрәмнәрен үткәрә булганнар, агач төбендә корбаннар чалганнар. Е л г а  а л л а с ы н а  д а,  т а й г а  а л л а с ы н а  д а* [Зәкиев, 1958]. *Әни, безнең авылга әллә нинди кешеләр килде. П а р  а т  б е л ә н* (И. Гази) [Закиев, 1963].

Синтаксис фәнендә өстәлмәләрне аерым берәмлек итеп тануны алга сөрүче – Ф. Сафиуллина. Ул аларны өстәлмә конструкцияләр исеме астында бик җентекләп өйрәнә һәм төп үзенчәлекләрен билгеләп чыга [Сафиуллина, 1972, Татар әдәби телендә өстәлмә..., б. 61–76].

М.З. Зәкиев үзенең 1974 елда чыккан китабында, «өстәлмә» дигән термин кулланып, бу берәмлекләрне гомуми синтаксик тео-

риядән чыгып һәм тел үсеше процессын исәпкә алып бәяли. Өстәлмәләрнең ким җөмләләр, инверсион кисәкләр белән мөнәсәбәтен ачыклый.

**§ 205. Өстәлмәләр һәм ким җөмләләр.** Алдагы бүлекләрнең берсендә өйрәнгәнчә, ким җөмләләр диалогларда да һәм монологларда да еш очрыйлар. Диалоглардагы ким җөмләләр башка бернинди берәмлекләргә дә якын тормыйлар.

Монологлардагы, ягъни бер үк авторның сөйләмендәге, ким җөмләләр өстәлмәләргә бик якын торалар. Өстәвенә алар икесе дә алдагы җөмләләрдән, аерым җөмлә кебек, аерылып торалар, үзләре мөстәкыйль хәбәр итү интонациясе белән әйтеләләр. Өстәлмә һәм ким җөмләләрнең бер-берсенә охшауларын мисалларда карыйк. Мәсәлән: *Сак-сок дигән кошларның арасына тау үскән. Ут тавы* (Ш. Мөхәммәдев). *Барысы да шат, көләч. Бигрәк тә Соломон Моисеевич* (Н. Фәттах). *Безнең төзелеш газетасына әйбәт кенә бер хәбәр яз. Ярыш турында* (А. Расих). Биредәге *ут тавы, бигрәк тә Соломон Моисеевич, ярыш турында* сүзләре өстәлмәләр булалар, чөнки өстәлмә билгеләмәсенә тулы килеш туры киләләр һәм аларны, төп җөмләдән алынып ахырга чыгарылган дип уйлап, төп җөмлә эченә куеп карарга мөмкин. Мәсәлән: *Сак-Сок дигән кошларның арасына ут тавы үскән. Барысы да, бигрәк тә Соломон Моисеевич, шат, көләч. Безнең төзелеш газетасына ярыш турында әйбәт кенә бер хәбәр яз.*

Ким җөмлә исә, җөмлә дип танылгач, үзен генә алганда да, мөстәкыйль тора торган җөмләгә якын булырга тиеш: 1) аның составында хәбәрлекне белдерүче төп сүзләр ия-хәбәр яисә хәбәр булырга тиеш; 2) хәбәр кулланылмаганда, ким җөмлә составында, үзара бәйләнеп, бер сүзтезмә төземи торган, тиңдәш тә булмаган берничә кисәк булырга тиеш. Мәсәлән: *Гайшәнең күзләренә йокы кермәде. Самоварын сүндермичә, әнә кайта, менә кайта дип ирен көтте* (Г. Ибраһимов). *Манжет алган ун тиенгә, биш тиенгә – ак яка* (Г. Тукай). *Кем шул ялганны тараткан? Кем? Булдырган икән, ишкән ...* (А. Гыйләҗев).

Өстәлмә, җөмлә белән җөмлә кисәге арасында торганлыктан, үзе генә хәбәрлекне белдерерлек дәрәҗәдә булмаска тиеш, димәк, ул хәбәр белән бирелә алмый. Бу – бер. Икенчедән, өстәлмә, ниндидер бер

кисәкнең (хәбәрдән башка кисәкнең) төп җөмләдән чыгарылып аңа өстәлеп куелуыннан ясалгач, бер генә кисәктән торырга тиеш. Ләкин бу кисәк җәенке дә, тиңдәш тә була ала. Мисаллар: *Өйгә кергәч, чынлап җырлыйбыз әле, яме. Я ң а  а в ы л  к ө й л ә р е н* (Г. Әпсәләмов). *Политехник институтта укый. М ә с к ә ү д ә* (Г. Ибраһимов). *Сугыш дәвам итә... Г е р о й л а р с ы з,  р о м а н т и к а с ы з ...* (Ә. Баянов). *Халык алдында лекция укырга кирәк. М е д и ц и н а  т е м а с ы н а. К л у б т а* (Н. Фәттах). *Хурланмаслык та түгел шул: никадәр тырышып әзерләп-әзерләп тә кисәк кенә, җиңел генә синең өметеңне киссеннәр, имеш! Б е р н и н д и  с о р а у с ы з - н и с е з,  б е р н и н д и  с ө й л ә ш ү с е з !* (Н. Фәттах).

**§ 206. Өстәлмәләр һәм инверсион кисәкләр.** Боларның аерым төрләре арасында да шактый якынлык күзәтелә.

Инверсион кисәкләр (кире тәртиптә килгән кисәкләр), әгәр дә алар җөмлә ахырында торсалар, өстәлмәләргә бик якын булалар. Хәтта формаль яктан бер үк кисәк бер очракта инверсион кисәк булып, икенчесендә – өстәлмә булып саналырга мөмкин. Әгәр дә сөйләүче җөмләнең хәбәрдән башка бер кисәген ахырга чыгарып, аны сөйләмнең аерым бер яңалыгы итеп, әйтми икән, димәк, шул ук җөмләнең интонацион составына кертә икән, мондый кисәк инверсияләнеп килгән кисәк кенә була. Инверсион кисәк җөмлә тәмамлангач әйтелми, бәлки җөмлә тәмамланганчы әйтелә. Мондый инверсион кисәк күбрәк шигъри әсәрләрдә һәм гади сөйләмдә кулланыла. Мәсәлән: *Син китәсең безне базга бикләп, хуш, иске ел, к ө м е ш  с а к а л л ы !* (М. Җәлил). *Синең йортта аш юк, т у я р л ы к  т а р а к а н* (Г. Тукай). *Алар күңелдә мәңге сакланачаклар, ү л е м с е з  р а п с о д и я  б у л ы п !* (Ә. Баянов).

Бу мисалдагы инверсион кисәкләр сөйләм яңалыгын белдерсәләр, аерым җөмлә кебек, төп җөмләдән аерым әйтелергә тиешләр, ягъни алар алдагы җөмлә тәмамланганчы түгел, тәмамлангач әйтеләләр, һәм язуда алар арасына җөмлә арасында була торган тыныш билгеләре куела. Бу очракта алар өстәлмәләр дип танылырга тиеш булалар. Мәсәлән: *Син китәсең безне базга бикләп, хуш иске ел! К ө м е ш  с а к а л л ы ! Синең йортта аш юк. Т а р а к а н  т у я р л ы к  т а . Алар күңелдә мәңге сакланачаклар! Ү л е м с е з  р а п с о д и я  б у л ы п !*

Алдагы җөмләнең мәгънәсе инверсияләнеп килгән кисәктән башка тулы булмаса, мондый инверсион кисәкне бервакытта да өстәлмә итеп аерып булмый. Мәсәлән: *Җырлый-җырлый үттем Барабаны, Җырлый-җырлый үтәм Уралны* (Х. Туфан). *Барыбер күрсәң качарсың язны – гөлләр патшасын* (Г. Тукай). Биредә *Барабаны, Уралны, язны* сүзләре инверсияләнеп килгәннәр, ләкин алардан башка җөмлә тулыланып, тәмамланып куела алмый, шуңа күрә алар өстәлмә булып, аерым килә алмыйлар.

**§ 207. Өстәлмәләрнең кулланылышы һәм төрләре**. Бик борынгыдан килә торган классик әдәби телдә сөйләм яңалыгын белдерүчеләрдән бары хәбәр генә җөмлә ахырына куела. Мәсәлән, *Без кичә әти белән шәһәргә барып кайттык* дигән җөмләдә (әгәр дә ул *сез кичә нишләдегез?* дигән сорауга җавап булса) *әти белән шәһәргә барып кайттык* тезмәсе яңалыкны белдерә, аларның үзәгендә хәбәр тора, ул иң соңыннан килгән. Хәбәрдән башка кисәкләр, сөйләм яңалыгын белдерсәләр дә, җөмлә ахырына куела алмыйлар, чөнки классик әдәби телдә җөмләне хәбәр тәмамлап куярга тиеш. Мәсәлән, *Сез кичә әтиең белән кайда барып кайттыгыз?* соравына җавапта *шәһәргә* кисәге сөйләм яңалыгы була һәм ул барыбер җөмлә ахырына куела алмый, хәбәр алдыннан янәшә килә: *Без кичә әти белән ш ә һ ә р г ә барып кайттык.*

Гади сөйләмдә элек-электән үк инде сүз тәртибе ирекле: иң кирәкле сүзне – сөйләм яңалыгын, җөмлә эчендә әйтмичә, ахырга чыгару гадәте була. Бу гадәт сөйләмә телдә әле дә киң кулланыла. Мәсәлән: *Без кичә әти белән барып кайттык. Ш ә һ ә р г ә . – Без кичә шәһәргә барып кайттык. Ә т и б е л ә н . Мин кибеттән бик яхшы гармун алдым. К ө м е ш т е л л е .*

Сөйләмә телдәге бу тәртип башта шигъри әсәрләрдә генә урын ала, гадәти язма әдәби телгә кабул ителми. Милли тел барлыкка килгәндә һәм аның халык сөйләме хисабына баюы процессында, бу тәртип әкренләп язма телгә дә үтеп керә. Башта персонаж теленә, күнегелә төшкәч, автор текстларына да. Соңгы елларда халыкчан итеп, җанлы итеп язарга омтылу халык сөйләмендәге тәртипне әдәби телгә дә кертүнең бер сәбәбе булды. Бу – бер. Икенчедән, өстәлмәләр кулланып язу стильне табигый итә, кирәкле мәгънәне тагын да басым ясап әйтергә мөмкинлек бирә. Хәзерге көндә алар актив кулланыла торган барлык стильләрдә дә очрыйлар.

Өстәлмәләрнең төрләренә килгәндә, алар әле җентекләп өйрәнелмәгәннәр. Шулай да кайсы кисәк булуларыннан чыгып, аларны хәзергә түбәндәге төрләргә бүләргә мөмкин:

1. Өстәлмә ияләр: *Йолдызлар сүнә. Учак та* (Х. Туфан). *Эт тә баласын ташламый. Песи дә, бүре дә* (Н. Фәттах). *Барысы, барысы да матур һәм бик килешле. Хәтта биек үкчәле читеге дә* (А. Расих). *Күзләре нинди чибәр! – дип уйлый ул. Бөдрәләре дә!* (И. Гази).

Өстәлмә хәбәрләр булмый, булганнары да ким җөмләгә кереп бетәләр.

2. Өстәлмә аергыч һәм ия: *Тынлык каплаган иде җир өстен. Шомлы тынлык* (М. Юныс). *Бар яктан да сине нидер чолгап алган кебек, шулай ук монда үзенә бер төрле киңлек, иркенлек сизелә. Кырлар, басулар иркенлеге түгел, күңел иркенлеге* (Н. Фәттах). *Яңа салам исе борыннарны кытыклый. Юк, салам исе түгел, Агыйдел болыннарында без чабып җыйган яшь үлән исе* (Ә. Баянов). *Әтиләр урман кисә. Искәндәрнең әтисе белән минем әти* (М. Хуҗин).

3. Өстәлмә аергычлар: *Күк йөзендә болыт ертыклары арасыннан кәкре ай сыныгы күренгәләп куя. Тонык, ямьсез* (Э. Касыймов). *Куштирәк – бәләкәй авыл. Бер генә урамлы* (Н. Фәттах). *«Каенсар» дип атала ул йорт. Уналты катлы* (Р. Вәлиев).

4. Өстәлмә тәмамлыклар: *Алар югарыдан күбрәк күрәләр, күбрәк беләләр. Куркынычын да, киләчәк матурлыкны да* (Ә. Баянов). *Сугыш еллары туры килмәсә, институтын да бетергән булыр идек. Академиясен дә!* (Р. Вәлиев). *Сәйферанны безгә күтәреп алып кердек. Әни белән* (М. Хуҗин).

5. Өстәлмә хәлләр: *Сез үзегез үзегезгә суд ясарга тиешсез. Намуслы врачлар законы буенча* (Г. Әпсәләмов). *Безгә хирург кирәк. Тиз, бик тиз* (Г. Мөхәммәтшин). *Кич тагын килегез. Сәгать төгәл җидедә* (Н. Фәттах). *Безнең арада алыш-биреш тәмам! Бөтенләйгә! Мәңгегә!* (Н. Фәттах). *Бик сөенешеп күрештек без аның белән. Күптәнге танышлар кебек. Чын дуслар шикелле!* (М. Вәлиев). *Чәч дулкыннары кызның иңнәренә төшеп ятты. Нәкъ аның чәче кебек* (Р. Вәлиев).

6. Өстәлмә аныклагычлар: *Барыбер аның абыйсы Рәисне ярат-маска тиеш. А н ы ң  и ш е  ә л ә к ч е н е* (Р. Төхфәтуллин). *Минем хә-зер киявем бар. С а б а н т у й  б а т ы р ы* (Ю. Сафиуллин).

7. Өстәлмә кереш сүзләр: *Менә монысы чын хуҗаларча. Ч ы н - н а н  д а* (Г. Афзал). *Ату аяктан егарлык көче бар аның. И х л а с* (Г. Минский). *Хәмдия! Иртәгә эшкә чыгам! Директор шулай диде. В а л л а һ и  м е н ә !* («Казан утлары»). *Язу-сызу әйберләре китереп бирегез үзенә! З и н һ а р,  ә !* («Казан утлары»).

Мисаллардан күренгәнчә, өстәлмәләрнең мәгънәләренә басым ясауны арттырып, сөйләм яңалыгын белдерүләрен көчәйтеп, алар алдыннан *бигрәк тә, җитмәсә, аннары, өстәвенә, аеруча* кебек сүзләр килгәли: *Ә бездә ахмак сүзләр сөйлиләр. Б и г р ә к  т ә  я ш ь л ә р* (Г. Әпсәләмов). *Беренче укыганда, мәзәкләрнең кайберләре коры ша-яру... сыман күренергә мөмкин. А е р у ч а  к и я ү л ә р  т у р ы н д а - г ы л а р ы* (Г. Бәширов). *Бер дә ярамаган хәл булды бит бу? Җ и т - м ә с ә  к у н а к л а р  а л д ы н д а !* («Казан утлары»).

## ДЕТЕРМИНАНТЛАР

**§ 208. Гомуми мәгълүмат.** Җыйнак җөмләләрне җәенкеләндерүче иярчен кисәкләр баш кисәкнең берсенә – ияга яисә хәбәргә ияргән булалар, шуның белән бергә аларның берьюлы ияга дә, хәбәргә дә, ә бер составлы җөмләләрдә ия дип тә, хәбәр дип тә таныла алырлык хәбәрлекле үзәккә караганнары да була. Мәсәлән, *Олы язучы өчен туган телне белү генә аз* җөмләсендә *олы язучы өчен* кисәген без *аз* хәбәренә *өчен* бәйлеге ярдәмендә ияргүче тәмамлык итеп өйрәндек. Гомуми тел гыйлемендә һәм рус синтаксис фәнендә җөмлә башында килгән мондый иярчен кисәкне хәбәргә генә түгел, ә гомумән җөмләгә караган кисәк дип аерып алалар, һәм андый кисәкләрне детерминант дип аерым бер иярчен кисәк төре итеп өйрәнәләр.

Бер составлы җөмләләрдән дә бер мисал китерик. *Безнең Таҗига бик күңелсез иде* (Г. Гобәй) җөмләсендә *Безнең Таҗига* кисәге *күңелсез иде* дигән хәбәрлекле үзәккә ияргә, димәк, ул да җөмләне аерым кисәк аркылы түгел, ә гомумән җәенкеләндерә. Шуңа күрә бу җөмләдәге *Безнең Таҗига* кисәген, гомуми тел гыйлеменә яки рус синтаксисына иярсәк, детерминант дип танырга тиеш булабыз.

Рус академик синтаксисында детерминантка түбәндәгечә билгеләмә бирелә: «...җөмләнең аерым кисәгенә бәйләнмичә, гомумән җөмләгә караган җәенкеләндерүче кисәк детерминант дип атала» [Русская грамматика, 1982, с. 149].

**Детерминант** термины латинча *determinantis* сүзеннән алынган, татарча билгеләгеч мәгънәсен бирә.

Татар синтаксисы фәнендә «җөмләне җәенкеләндерүче теләсә нинди иярчен кисәк башка бер кисәккә иярү аркылы гына җөмлә эченә керә ала» дигән гомуми караш яшәп килә. Бары эндәш һәм кереш сүзләр генә аерым кисәккә буйсынмыйча җөмләгә гомумән карарга мөмкиннәр. Шуңа күрә татар синтаксисында детерминантларны аерым төр иярчен кисәк итеп бүлеп чыгару моңа кадәр кабул ителмәгән иде. Моны түбәндәгечә дә аңлатып була иде:

*Олы язучы өчен туган телне белү генә аз.* Гомуми лингвистикада һәм рус синтаксис фәнендә детерминант дип алынган *Олы язучы өчен* кисәге, җөмләнең гомуми эчтәлегенә караса да, гомумән җөмләгә түгел, ә аның бер кисәгенә – *аз* хәбәренә буйсына. *Безнең Таҗига бик күңелсез иде* җөмләсендә дә *Безнең Таҗига* кисәге җөмләнең гомуми эчтәлегенә карый, ләкин ул да аерым кисәккә – *күңелсез иде* баш кисәгенә буйсына. Мондый очраклар татар синтаксисының сүзтезмәләр бүлегендә дә, иярчен кисәкләр бүлегендә дә җентекләп өйрәнелделәр.

Детерминантлар, актуаль бүленеш күзлегеннән караганда, сөйләм предметына (темага) тәңгәл киләләр, җөмләнең калган өлеше сөйләм яңалыгын белдерә. Димәк, детерминант дип таныла торган кисәкләр (җөмләнең сөйләм предметы өлеше) мәгънә ягыннан җөмләне төзүче бер мәгънәви үзәк тә булып торалар (җөмлә актуаль яктан ике өлештән – сөйләм предметыннан һәм сөйләм яңалыгыннан тора).

Детерминантның сөйләм предметына туры килүен раслаучы тагын бер факт бар: аның төп билгеләреннән берсе – җөмлә башында әйтелүе [Русская грамматика, 1982, с. 149]. Сөйләм предметын белдерүче теләсә нинди кисәк җөмлә башында әйтелә. Димәк, детерминант чыннан да сөйләм предметын белдерүче кисәк була.

Җөмлә башында әйтелгән тәмамлык һәм хәл сөйләм предметын белдерсен өчен, ягъни детерминант булсын өчен, алар җөмләнең бер баш кисәгенә буйсынган булырга тиешләр; әгәр дә алар җөмләнең

башка бер иярчен кисәгенә буйсынсалар, аларны детерминант дип тә, сөйләм предметы дип тә әйтеп булмый. Мәсәлән, *Аны хөрмәтләп, җыелыш уткәрелде* җөмләсендә *Аны* тәмамлыгы детерминант та, сөйләм предметы да түгел, чөнки ул җөмләнең хәбәренә түгел, ә *хөрмәтләп* дигән хәлгә буйсынган. *Аны хөрмәтләп искә алдылар* җөмләсендә исә *Аны* тәмамлыгы – детерминант та, сөйләм яңалыгы да, чөнки ул баш кисәккә – хәбәргә буйсынган.

Җөмләнең баш кисәгенә (хәбәргә) буйсынган берничә кисәк берничә детерминант һәм бер сөйләм предметы булып килә ала: *Кырдан, беренче булып, атлар кайтты* (Г. Гобәй) җөмләсендә *кырдан* һәм *беренче булып* дигән ике детерминант бар, сөйләм предметын белдерүчеләр буларак, алар икесе бергә алыналар.

Детерминант белән сөйләм предметы арасында тагын шундый аерманы күрсәтеп була: сөйләм предметы булып ия һәм ия төркеме дә, тәмамлык һәм тәмамлык төркеме дә, хәл һәм хәл төркеме дә килә ала, ә детерминант дип җөмлә башында килгән тәмамлык һәм хәлләр генә санала ала, сөйләм предметын белдергән ия яки ия төркеме детерминант була алмый, чөнки ул җөмләне җәенкеләндерә торган кисәк түгел.

Шулай итеп безнең татар синтаксисында детерминантларны аерым төр җәенкеләндерүче кисәкләр дип бүлеп чыгаруның принципиаль зарурлыгы юк. Алар фактта «Сүзтезмәләр» бүлегендә дә, «Иярчен кисәкләр» бүлегендә дә, «Актуаль кисәкләр» бүлегендә дә өйрәнеләләр. Шулай да без биредә «Детерминантлар» дигән бер бүлекчә ачтык, чөнки гомуми лингвистикага яисә рус синтаксис фәненә ияреп, бездә дә аны аерым өйрәнергә тырышу булачак. Шуны күз алдында тотып, без биредә җөмлә башында килеп, сөйләм предметын белдерә торган хәл һәм тәмамлыкларны, детерминант исеме астында тагын бер күздән кичерергә булдык. Ләкин без аларга, сүз тәртибе белән бәйләнешле рәвештә, өстәлмәләрдән соң урын бирү дөресрәк булыр дигән нәтиҗәгә килдек.

**§ 209. Тәмамлыкларның детерминант булып килүләре.** Җөмлә башына чыгарып әйтелгән һәм сөйләм предметын белдерә торган тәмамлыклар детерминант дип карала алалар.

Болар икегә бүленәләр: объект белдерүчеләр һәм үтәүчене белдерүчеләр.

***1. Объект белдерүче детерминантлар.***

Төшем килешендәге сүз белән бирелгән туры тәмамлыклар еш кына җөмлә башында әйтелә һәм детерминант була алалар: *Габдулланы чыбылдыклы бүлмәгә алып керделәр* (Ә. Фәйзи). *Казан урамнарын ташлап китәм* (Һ. Такташ).

Ияртүче кисәккә янәшә тору чарасы һәм чыгыш килеше кушымчасы аша бәйләнгән туры тәмамлыклар детерминант булып бик сирәк киләләр: *Бер китап күрсәтим әле сиңа* (Ә. Фәйзи). *Үзегез яраткан коймактан авыз итегез, Гали абзый* (Г. Әпсәләмов).

Күтелмәгән туры объектны белдерүче тәмамлык гадәттә детерминант булып кулланыла, чөнки үзенең көтелмәгәнлек мәгънәсе белән ул җөмлә башында әйтелергә һәм сөйләм предметын белдерергә тиеш була: *Махносына кадәр бетерешеп кайтты* (Г. Бәширов). *Гаризасына чаклы язып китерде.*

Процесс турыдан-туры кагылмаган (ягъни кыек) объектны белдерүче тәмамлыклар бик еш сөйләм предметын белдерәләр һәм, җөмлә башында әйтелеп, детерминант булалар: *Үз эшчеләренә ул бик ягымлы мөнәсәбәттә булды* (М. Мәһдиев). *Тиле белән тапма да, югалтма да* (мәкаль). *Бөтен чыгымнарыннан тыш сигез сум саф файда калды* (Г. Ибраһимов).

***2. Үтәүчене белдерүче детерминантлар.***

Үтәүчене күбрәк ия белдерә, һәм ия дә сөйләм предметы булып җөмлә башында килә ала, ләкин аны детерминант төркеменә кертмиләр, чөнки ул җөмләне җәенкеләндерүче түгел, ә хәбәрлек төзүче. Без тәмамлыкларны өйрәнгәндә, махсус бер параграфта үтәүчене яки нинди дә булса бер хәлне кичерүче затны (әйберне) белдерә торган кисәкләрне аерым алып күрсәткән идек. Менә шундый тәмамлыклар еш кына детерминант булып килә алалар. Рус телендә, детерминант итеп, күбрәк шушы төр кисәкләр күрсәтелә.

Үтәүчене баш килештәге сүз белдерсә, ул ия була, һәм ул сөйләм предметы булып килгәндә дә детерминант саналмый дидек. Үтәүче булып башка формалардагы сүзләр килгәндә һәм ул кисәк сөйләм предметын белдергәндә, без үтәүчене белдерүче детерминант белән очрашабыз.

Үтәүчене яки нинди дә булса хәлне кичерүче затны (әйберне) белдерә торган детерминантлар түбәндәге формаларны кабул иткән булалар:

1) юнәлеш килеше кушымчасын: *М и ң а  монда озак торырга туры килмәде* (И. Гази). *Г а б д у л л а г а  бирәдә бик күңелсез иде* (Ә. Фәйзи). *Гали В ә л и г ә  утын ташышты;*

2) иялек килеше кушымчасын: *А н ы ң  бу эшкә бик исе китмәде. Г а л и н е ң  әле күп эшләр башкарасы бар;*

3) чыгыш килеше кушымчасын: *Гөләнвәр а ң а р д а н  Фазылга хат яздырып алды. А в ы л г а  к и л г ә н  о с т а л а р д а н  аны бик тиз төзәттереп алды. Б е з д ә н  бернинди каршылык юк;*

4) *тарафыннан* ярдәмче сүзен: *У к у ч ы л а р  т а р а ф ы н н а н бик матур стена газетасы чыгарылды*;

5) *кадәр, чаклы* бәйлекләрен: *К а з л а р г а  к а д ә р  каңгылдашалар* (И. Гази). *К ү г ә р ч е н н ә р г ә  ч а к л ы  гөрләшәләр;*

6) *белән* бәйлеген: *Ә т и  б е л ә н  шәһәргә килдек;*

7) *өчен* бәйлеген: *Г а з и н у р  ө ч е н  әйтеп бетергесез шатлык иде бу* (Г. Әпсәләмов) һ.б.

**§ 210. Хәлләрнең детерминант булып килүләре.** Аергычлардан аермалы буларак, хәлләр җөмләдә үз урыннарын үзләре сайлый алалар, димәк, алар, җөмлә башына да куелып, сөйләмнең предметын белдереп, детерминант булып килә алалар. Хәлләрнең барлык төрләре дә бу рольне башкарырга сәләтле.

Урын хәлләре детерминант булып килә алалар: *Б е з н е ң  а в ы л д а  ашлыкны кышын сугалар иде* (Г. Ибраһимов). *К о й м а  б у й л а п  алар бик тиз шуыштылар* (Г. Әпсәләмов).

Вакыт хәлләре дә еш кына детерминант ролен башкаралар: *И р т ә  б е л ә н  көн томанлы иде* (Ш. Камал). *Т е г е  в а к ы т  әнисе килгән иде* (Г. Ибраһимов); *Б ы е л  халык бик тырыша* (Г. Бәширов). *Б у  х ә л л ә р н е  и ш е т к ә ч , ул яңадан әйләнеп кайтмады* (А. Шамов).

Рәвеш хәлләре дә детерминант булып килә алалар: *Ш у л  у й л а р  б е л ә н  Таҗи чәй янынnан торып китте* (Г. Гобәй). *З ә ң г ә р  т а с м а д а й  б у л ы п, еракта су күренде* (И. Гази).

Күләм хәлләре дә детерминант булып килә ала: *М о н д а  к а д ә р  җәяү килдек. Д ү р т ә р  с у м н а н  барлык кыярларыңны алып бетерәм.*

Максат хәлләренең детерминант булып килүләре сирәгрәк очрый: *Р ө х с ә т  а л ы р г а, без ел саен Казанга киләбез. У к ы п  б е л е м  а л у  ө ч е н , мине мәдрәсәгә бирделәр* (Г. Гали).

Сәбәп хәлләре дә детерминант булып килә ала: *Соң килү аркасында, урынсыз калдым. Шатлыгыннан ул нишләргә белми иде. Озак йөрү сәбәпле, ул бүген бик арып кайтты.*

Кире хәлләр шулай ук детерминант була алалар: *Авырлыклар күрсә дә, ул сиздермәде* (А. Шамов). *Көннең кызуына карамастан, халык җыены тагын да зурая төшкән иде* (Г. Ибраһимов). *Ничә ел шунда торып, Алмаевның әле бу тирәдә булганы юк иде* (И. Гази).

Шарт хәлләре дә детерминант булып килә ала: *Китсәм, кайталмам инде* (җыр). *Барам икән, алып та кайтам.*

**Искәрмә**. Детерминант буларак, сөйләмдә синтетик иярчен җөмләләр дә еш кулланылалар: *Син килүнең файдасы зур булды. Син килүгә мин бик шат. Берничә айлар үткәч, аннан бер хәбәр килде. Эш күплеккә эчләре поша башлады* (Ә. Еники). *Теле ачылмасмы дип, хәл-әхвәлләрен җентекләп сораша* (Ә. Еники).

Шулай итеп детерминант дигән кисәкләрне татар синтаксисының төрле темаларында электән үк өйрәнеп килгәннәр. Бу академик синтаксиста без аларны аерым алып күрсәтүне дә кирәк таптык. Аңа татарча термин ясап тормадык. Киләчәктә детерминантларны махсус өйрәнүчеләр аның күп төрләрен ачарлар һәм аларга татарча термин да табарлар дип ышанабыз.

## ГАДИ ҖӨМЛӘ МОДЕЛЬЛӘРЕ

**§ 211. Гомуми мәгълүмат.** Синтаксис сөйләм төзелешен өйрәнә, ә сөйләмнең төп берәмлеге – җөмлә. Теге яки бу телдә сөйләшә белүченең хәтерендә сүзләр, сүзләрне үзара бәйләүче чаралар һәм җөмлә **модельләре** саклана. Һәр телнең үзенә хас җөмлә модельләре була. Җөмлә модельләрен татарча җөмлә **калыплары** дип тә атап була. Рус теле синтаксисында аларны җөмлә **схемалары** дип атыйлар. Татар академик грамматикасын русча язганда, без дә **җөмлә схемалары** дигән терминны кулланган идек. Татарча текстта **модель** сүзен кулланырга булдык, чөнки халыкара синтаксик хезмәтләрдә ул киң кулланыш тапкан. Бу хезмәттә, **модель** сүзе синонимы буларак, **калып** сүзе дә еш очрар.

Сөйләшергә, яки фикер әйтергә кирәк булганда, кеше мәгънәгә (семантикага) карап, кирәкле сүзләрне, аларны үзара бәйләүче чараларны автоматик искә төшерә һәм аларны, шул телгә хас җөмлә модельләренә салып, конкрет җөмлә төзи, аны кирәкле модальлек (чынбарлыкка мөнәсәбәт) белән сугарып тыңлаучыга әйтә. Сөйләүченең хәтерендә кала торган җөмлә модельләре (калыплары) ничә төрле, алар ниндиләр дигән сорауга синтаксистлар бик күптәннән җавап бирергә тырышканнар. Шул процесста җөмлә модельләрен билгеләүнең берничә юлы, алымы барлыкка килгән.

Төрле телләр синтаксисында иң күп кулланылган алым – җөмләләрнең модельләрен **логик-грамматик юл** белән билгеләргә тырышу.

Грамматика фәне шактый үскән телләрдә иң элек җыйнак җөмлә модельләрен билгеләргә, шуннан соң ул модельләрнең үзгәрешен (парадигмасын) һәм җәенкеләнү юлларын өйрәнергә кирәк дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Хәзер дә **җыйнак җөмлә** калыпларын **грамматик (күбрәк синтаксик) планда** танып белергә кирәк дигән фикер күп галимнәр тарафыннан алга сөрелә.

Инглиз теле һәм күп кенә рус теле синтаксистлары, җөмлә модельләрен билгеләгәндә, синтаксиста кабул ителгән категорияләргә (ия, хәбәр, тәмамлык, хәл, аергыч кебек кисәкләргә) игътибар итмәстән, турыдан-туры аларның формалары (структуралары) һәм эчтәлекләре (семантикалары) белән эш итүне алга сөрәләр. Шушы юлда алар җөмлә модельләрен билгеләүдә **структур-семантик** алым барлыкка китерделәр.

Биредә без җөмлә модельләрен, иң элек, грамматик кисәкләргә, аннан соң структур-семантик кисәкләргә нигезләп билгеләү үрнәкләрен бирәчәкбез.

Җөмләләрнең элекке синтаксис дәреслекләрендә аерым күрсәтелә торган төрләре (раслау һәм инкяр җөмләләр, хикәя, сорау, боеру, тойгылы җөмләләр, тулы һәм ким җөмләләр) гади җөмлә модельләренең грамматик яки стилистик парадигмаларына (төрләнешләренә) кереп бетәләр. Ләкин элекке традицияне бозмас өчен, бу төр җөмләләрне җентекләп күрсәтү өчен, без модельләр темасыннан соң «җөмлә төрләре» дигән бүлек тә ачтык.

## ГАДИ ҖӨМЛӘНЕҢ ГРАММАТИК МОДЕЛЬЛӘРЕ

**§ 212. Гомуми мәгълүмат.** Җөмләнең татар теленә хас һәм конкрет җөмләләр төзергә нигез булырлык модельләре, югарыда әйтелгәнчә, тел белүче хәтеренә тел өйрәнгәндә үк автоматик рәвештә сеңеп кала. Шул модельләргә (калыпларга) кирәкле сүзләрне тезеп, сөйләүче конкрет җөмләләр төзи, тиешле эчтәлекне хәбәр итә.

Җөмләнең грамматик модельләрен синтаксистлар аларның грамматик кисәкләренә таянып билгеләргә тырышалар, ягъни ия, хәбәр, тәмамлык, хәл, аергыч, аныклагычлар аркылы ачыклыйлар. Җыйнак җөмлә модельләрен билгеләгәндә, үзеннән-үзе аңлашыла, бары ия һәм хәбәр белән генә эш итәргә туры килә.

Мәгълүм булганча, грамматик (синтаксик) кисәкләр ике яктан – эчтәлек (семантика) һәм форма (структура) ягыннан характерланалар. Мәсәлән, **ия** дигәч, без һәрчак аның семантик яктан субъект белдерүен, ә структур яктан баш килештәге исем яки исемләшкән башка сүз белән бирелүен күз алдында тотабыз. Хәбәр исә семантик яктан предикатны белдерә, ягъни субъект турында яңалыкны хәбәр итә яисә шуны хәбәр итүдә төп рольне уйный, структур яктан аның хәбәрлек һәм модальлек белдерүче формалары бик күптөрле була.

Структур-семантик модельләрне өйрәнгәндә бу ике як аерым күрсәтелсә, грамматик модельләрдә структура (мәгънә) ягы да, семантика (эчтәлек) ягы да, эчтәлек һәм форма берлеге итеп, бергә алына.

Җөмләләрнең грамматик модельләрен билгеләү мәсьәләсе хәзерге синтаксис фәнендә хәл ителеп җитмәгән. Күпчелек галимнәр бары җыйнак җөмләләрнең генә модельләрен билгеләргә дә, җәенке җөмләләрдә модельләр билгеләү белән шөгыльләнмәскә кирәк, диләр. Чөнки җәенке җөмлә, иярчен кисәкләрне, ягъни җәенкеләндерүче кисәкләрне тикшергәндә тулысынча өйрәнелә, дип тә өстиләр.

Модельләрне структур-семантик яктан өйрәнүче синтаксистлар исә җәенке җөмләләрне дә модельләрдә күрсәтергә кирәк дигән карашта торалар. Аларча, *Бала укый* һәм *Бала китап укый* җөмләләре бер модельгә нигезләнмәгәннәр, алар төрле модельгә корылганнар.

Чынлыкта бу ике җөмлә бер үк модельгә (калыпка) нигезләнгән, аерма шунда гына: беренчесендә төшенчәләр гомумиләштереп би-

релгәннәр, икенчесендә *уку* процессы конкретлаштырылган. Ә конкретлаштыру юллары сүзтезмәләр бүлегендә җентекләп өйрәнелде.

Конкретлаштыру, икенче төрле, җөмләне җәенкеләндерү дигән сүз. Ә җәенкеләндерү юллары иярчен һәм модаль кисәкләрне тикшергәндә өйрәнелделәр.

Гомуми мәгълүмат буларак, тагын бер мәсьәләгә тукталыйк. Ул – модельләрне формулаларда (символик билгеләр аша языла торган схемаларда) күрсәтү. Структур-семантик кисәкләр турындагы бүлектә без бу юл белән таныштык. Анда һәр структур кисәкне һәм семантик кисәкне белдерүче символларны да күрсәттек. Искә төшерик:

исем – *И*,

сыйфат – *С*,

фигыль – *Ф*,

сан – *Сан*,

рәвеш – *Р*.

Калган сүз төркемнәреннән булган сүзләр символ белән (сүз төркеме исеме белән) күрсәтелмиләр, схемаларда үзләре язылалар.

Сүз формалары (кушымчалар) да формула-схемага үзләре язылалар.

Структур-семантик кисәкләр турындагы бүлектә тагын семантик кисәкләр символлары белән дә танышкан идек:

субъект – *Суб.*,

предикат – *Пре.*,

объект – *Об.*,

атрибут – *Ат.*,

ачыклагыч – *Ач.* (конкретизатор яки квалификатор),

үтәүче (агенс) – *Үт.*

Грамматик кисәкләргә нигезләп, җөмләнең модельләрен билгеләгәндә дә, аларны символлар аша формула итеп язу гадәте кабул ителгән. Аның өчен безгә җөмлә кисәкләренә дә символлар билгеләп чыгу кирәк:

ия – *Ия*,

хәбәр – *Хәб.*,

баш кисәк – *БК* (бер составлы җөмләдә ия дип тә, хәбәр дип тә тану кыен очрагы),

тәмамлык – *Тәм.*,

хәл – *Хәл*,
аергыч – *Аер*.,
аныклагыч – *Анык*.,
кереш сүз – *К.с.*,
эндәш сүз – *Э.с.*

**§ 213. Модельләрне билгеләгәндә нәрсәләр исәпкә алына?** Гадәттә биш төрле күрсәткеч исәпкә алына: 1) җөмлә иреклеме, әллә нычыганмы, 2) бер генә баш кисәклеме, ике баш кисәклеме, 3) үтәүче (агенс) ничек бирелә, 4) хәбәр формасы, 5) хәбәр лексик чикләнгән яки чикләнмәгән сүз белән биреләме? Болар җөмлә модельләрен билгеләү кабул ителгән һәр телдә исәпкә алыналар. Хәзер шул күрсәткечләргә аерым-аерым тукталыйк.

1. Татар синтаксисында фразеологик (ныгып калган) модельләр аерым алып тикшерүне көтә. Шуңа күрә аларның *Биештән китте* һәм *Ишетмәмешкә салына (салыша)* кебек модельләрен күрсәтү белән чикләнеп, без биредә ирекле модельләрне билгеләүгә игътибар бирәчәкбез.

2. Состав буенча билгеләү – модельләрне ике составлы һәм бер составлы төрләргә бүлү дигән сүз.

3. Үтәүче гомуми тел гыйлемендә агенс дип атала, һәм аның бирелешен, модельләрнең формуласын язганда, аерым күрсәтәләр. Мәсәлән, *Сиңа укырга* – бер составлы җөмлә. Моны баш кисәктән генә тора дип әйтү дә җитәр иде. Ләкин уку процессын үтәүче (агенс), ия булып килмәсә дә, модельнең үзенчәлеген төзүдә катнаша, шуңа күрә аны модельдә күрсәтергә туры килә: БК-*рга*.

4. Хәбәр формасын күрсәтү барлык телләрдә дә гадәткә кергән. Хәбәр формасына карап, модельләр төрләргә бүленә: а) хәбәре төрләнешле фигыль белән бирелгән модель, ә) хәбәре төрләнешсез фигыль белән бирелгән модель, б) хәбәре исем һәм исем урынындагы сүзләр белән бирелгән модель һ.б.

5. Хәбәр булып лексик яктан чикләнмәгән сүз төркеме килсә, модельдә сүз төркеменең исеме әйтелә. Мәсәлән, *Фатих – табиб* җөмләсенең моделен формулада болай язабыз: *Ия – Хәб*. И., чөнки бу модельдә *табиб* сүзе урынында мәгънәгә туры килә торган теләсә нинди исем килә ала, ягъни биредә лексик чикләнү юк. *Акча юк* яки *Эш кирәк* кебек җөмләләрдә хәбәрне беледерүче *юк* һәм *кирәк* сүзләрен

алмаштырырга башка андый сүзләр юк, андый сүз төркеме чикләнгән сүзләрдән генә тора. Шуңа күрә модель формуласында да бу төр лексик чикләнгән сүзләр үзләре язылалар: Ия – Хәб. *юк* һәм *Ия – Хәб. к и р ә к*.

Сүз-җөмлә калыпларында баш кисәкне белдерүче сүзләр лексик яктан тагын да ныграк чикләнгәннәр. Шуңа күрә монда да сүз төркеме исеме (ымлык, аваз ияртеме) түгел, ә сүз үзе күрсәтелә: *БК. – тфу!*; *БК – бах-бах* һ.б.

Җөмләнең грамматик моделе итеп, аның төп төре алына да, аның төрле заттагы, юнәлештәге, замандагы, наклонениедәге формалары шул модельнең төрләнеше (парадигмасы) итеп кенә бирелә. Димәк, теге яки бу төрләнеш (парадигма) системасына керә алмаган модельләр генә аерым төр модель итеп күрсәтелә. Хәзергә без татар җыйнак җөмләләренең 50 дән артык моделен саныйбыз. Татар грамматикасын җентекләп өйрәнү барышында ул модельләрнең кайберләре яңа ачылган парадигма системасына күчерелергә дә мөмкин. Шул рәвешчә төп модельләрнең санын киметү мөмкин булачак.

**§ 214. Хәбәре төрләнешле фигыль белән бирелгән ике составлы модель.** Моның формуласы: *Ия – Хәб. Ф*. Биредә *Ф* символы белән төрләнешле фигыль бирелә, төрләнешсез булганда *Ф* символы янына аның формасы – кушымчасы языла.

**Искәрмә:** Русча чыккан академик грамматикада без җөмләнең грамматик моделен, рус телендәге кебек, грамматик схема дип, ә аның символлар белән формула итеп язылышын модель дип атаган идек. Татарча язганда, без бераз үзгәреш кертергә кирәк таптык: җөмлә калыбын схема дип түгел, модель дип атадык, модельнең символлар аша кыскартып язылышын аның формуласы дип атадык.

Бу 1 н ч е *Ия – Хәб. Ф*. моделендә ия – баш килештәге исем яки исемләшкән башка сүз белән, ә хәбәр билгеле бер наклонениедәге төрләнешле фигыль белән бирелә. Гомуми хәбәрлек һәм модальлек белдерүдән тыш, бу модельнең семантикасы бар: фигыль белән бирелгән хәбәр субъектның хәрәкәтен, хәлен хәбәр итә.

Бу – сөйләмдә бик күптөрле парадигмаларда иң еш кулланыла торган модель. Мәсәлән, шушы ук модельгә нигезләнеп ясалган *Марат бизи* конкрет җөмләсе теләсә нинди юнәлеш (*Марат бизәнә*; *Марат бизәшә*; *Марат бизәтә*; *Марат бизәлә*), дәрәҗә (*Марат бизи*

*башлады; Марат бизәп чыкты; Марат бизәп ташлады; Марат бизи язды* һ.б.), заман (*Марат бизәде; Марат бизи иде, Марат бизәр; Марат бизиячәк; Марат бизәгән иде* һ.б.), раслау-инкяр (*Марат бизи/бизәми*) һәм наклонение формаларын алырга мөмкин.

Татар теле модальлек (сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерү) мәгънәләренә бик бай булганлыктан, анда модальлекне фигыль формаларында белдерә торган наклонение категориясе дә күптөрле. Башка телләрдә лексик чаралар белән бирелә торган модаль мәгънәләр дә төрки телләрдә фигыль формаларында (наклонениедә) чагылыш табалар.

Алар түбәндәгеләр:

1) хикәяләү модальлеге элекке грамматика китапларында – хикәя фигыль, гомуми лингвистикада – индикатив дип атала. Хәбәр ителә торган процесс билгеле бер заманга каратыла, ягъни бу наклонениенең заман парадигмасы бик бай, шуңа күрә аны реаль наклонение дип тә атыйлар; бу реаль наклонение барлык башка *ирреаль* (үтәлеше реаль хәбәр ителми торган) наклонениегә каршы куела;

2) шарт модальлеге (*-са* яки *-са иде*);

3) боеру (*яз, язсын, языйк, яза күр, языйм* – соңгысы теләк фигыль дип тә йөртелә);

4) теләк (*-рдай бул, -асы килә, -кыры, -сын иде, -са иде*);

5) шартлы теләк (сослагательное) (*-р* иде);

6) тиешлек (*-асы, -асы иде, -асы бул, -ачак иде, -ачак бул, -асы бар, -асы юк, -рга тиеш*);

7) икеләнү-шикләнү (*-уы бар, -магае, -а булыр, -а торгандыр, -са кирәк*);

8) ниятләү (*-макчы, -макчы бул, -рга бул, -рга ит, -рга тор, -асы ит*);

9) үти алырлык – алмаслык (*-рлык, -рлык бул, -малы, -малы түгел, -а ала, -ып була*);

10) юл кую (*-рга ярый, -рга була, -рга мөмкин*);

11) үкенү (*-асы калган, -асы булган, -рга булган*);

12) ирония (*-ган була*);

13) гаҗәпләнү (*-р икән! -мак кирәк!* ).

Фигыль формасы белән модальлек белдерүнең бу 13 төреннән бары башта саналган бише генә наклонение дип санала.

Бу 1 нче модель парадигмасына без менә шул биш төрле наклонение белән төрләнүне генә алдык. Калган сигезе аерым төр модель төзүче форма итеп алынды.

**§ 215. Хәбәре төрләнешсез фигыль белән бирелгән ике составлы модельләр.** Төрләнешсез фигыльләр күптөрле булганлыктан, мондый модельләр дә шактый санала.

2 нче модель: *Ия – Хәб. -асы*, гадәти ия янында *-асы* формасындагы фигыль хәбәр булып килә, семантикасы – процессның киләчәктә булырга тиешлеген хәбәр итү. Бу модельнең үз модаль парадигмасы бар: *Ул язасы түгел; Ул язасы иде; Ул язасы булган; Ул яздырасы түгел иде; Ул язасы булып чыккан* һ.б.

2 нче *а* моделе: *Ия – Хәб. -ган*. Ия тарафыннан үткәндә башкарылган эшне сөйләүче соңыннан гына, нәтиҗәсе буенча гына белгән: *Ул язган*. Бу төр җөмләне без мөстәкыйль модельгә кертмибез, чөнки ул 1 нче модельнең заман парадигмасына карый. Шулай да ул төрки телләр үзенчәлеге буларак (русчада аның мәгънәсе «оказывается» сүзе белән бирелә) синтаксиста аерым урын тота. Шул русчадагы «оказывается» сүзе белән бирелә торган мәгънәсе белән ул индикатив (реаль наклонение) системасыннан бераз читләшә дә. Аннан соң шуны да әйтергә кирәк: әгәр бу модельне парадигма эчендә генә калдырсак, татар теленең үзенчәлеге бераз игътибарсыз кала. Шуңа күрә *Ия – Хәб. -ган* моделен 2 нче модельнең *а* варианты итеп алырга булдык.

2 нче *ә* моделе: *Ия – Хәб. -ачак*. Семантикасы – киләчәктә процессның һичшиксез үтәләчәген хәбәр итү. Бу модель дә 1 нче модельнең заман парадигмасына керә, шуңа күрә ул мөстәкыйль модель санала алмый. Ләкин татар сөйләменең үзенчәлеген калкурак итеп күрсәтү өчен, без аны 2 нче модельнең *ә* варианты итеп күрсәтү зыян итмәс дидек.

3 нче модель: *Ия – Хәб. -а торгандыр*. Семантикасы – сөйләүче бәлки булыр дип уйлаган процессны хәбәр итү. *Ул яза торгандыр* моделендә хәбәр булып *-а торган* формасындагы сыйфат фигыль килә һәм бары *-дыр* кушымчасын һәм *иде* яки *бул* ярдәмче фигыльләрен алып кына.

*Иде* элементын алганда, ул 1 нче модельнең парадигмасына керә, *-дыр* кушымчасы һәм *бул* фигыле белән килгәндә, икесе ике

мөстәкыйль модель итеп карала, чөнки форма белән генә түгел, алар семантикалары белән дә аерылалар.

4 нче модель: *Ия – Хәб. -арлык.* Биредә хәбәр булып *-лык* кушымчасын алган *-ар* формасындагы сыйфат фигыль килә. 3 нче модельдә *-дыр* кушымчасын алган *-а торган* сыйфат фигыле бары хәбәр булып кына килсә, *-лык* кушымчасын алган *-ар* сыйфат фигыле хәбәр дә, аергыч та була ала: *Күрерлек күз – Күз күрерлек. Язарлык кеше – Ул язарлык*. Модельнең семантикасы – субъектның нәрсәдер эшләргә сәләтле булуын хәбәр итү. Бу модель, *иде* һәм *бул* ярдәмче фигыльләрен алып, төрле парадигмаларга керә ала: *Ул язарлык булды; Ул язарлык булсын; Ул язарлык булган иде* һ.б.

4 нче *а* моделе: *Ия – Хәб. -ар.* Гадәти ия янында *-ар* формалы хәбәр килә: *Ул язар.* Семантикасы – киләчәктә буласы эш турында бераз икеләнебрәк хәбәр итү. Бу модель хәзер 1 нче модельнең парадигмасына керә, ләкин аны без 4 нче модельнең бер төре итеп тә күрсәтәбез, чөнки *-ар* формасы сыйфат фигыльгә карый. Ә татар телендә барлык төр сыйфат фигыльләр дә, аергыч булу белән бергә, хәбәр ролендә дә килә алалар.

5 нче модель: *Ия – Хәб. -макчы.* Семантикасы – киләчәктә үтәлүе ниятләнгән процесс турында хәбәр итү. *Бала язмакчы.* Бу модельнең инкярлык белдерү варианты юк, ләкин *иде*, *ит*, *бул* һәм *түгел* сүзләре ярдәмендә ул теләсә нинди парадигмага (төрләнешкә) керә ала.

6 нчы модель: *Ия – Хәб. -у* (*-рга*). Гадәти ия янында хәбәр булып эш-хәл исемен атаучы *-у* фигыле (аерым очракларда *-рга* яки *-мак* инфинитивы) килә: *Теләк – уку; Гадәте – сайрау; Хезмәте – ял итү; Укымак – белмәк; Омтылышы – эшләргә; Планы – тазарырга; Нияте – кайтырга; Теләге – укырга* һ.б. Семантикасы – иядә бирелгән эш-хәлнең хәбәрдә бирелгән эш-хәлгә тиңлеген хәбәр итү.

7 нче модель: *Ия – Хәб. -мәгәе.* Хәбәрне белдерүче фигыль формасы өч аффикстан оешкан: *-ма* (инкяр формасы), *-гай* (теләкнең иске формасы), *-ы* (тартым кушымчасы). Семантикасы – процессның башкарылуы мөмкин дип, сөйләүче тыңлаучыны кисәтә: *Ул язмагае; Дошман сизмәгәе; Җыелыш башланмагае* һ.б. Бу искергән бер модель буларак үзе дә сирәк кулланыла, һәм аның парадигмалары да күзәтелми.

**§ 216. Хәбәре *тиеш*, *мөмкин*, *кирәк*, *ал* сүзләрен алган фигыльләр белән бирелгән ике составлы модельләр.**

8 нче модель: *Ия – Хәб. -рга тиеш*. Семантикасы – башкарылырга тиешле процесс турында хәбәр итү: *Ул язарга тиеш; Билге куелырга тиеш.* Бу модель төрле парадигмага *иде*, *бул*, *түгел* кебек сүзләр ярдәмендә керә.

9 нчы модель: *Ия – Хәб. -рга мөмкин*, башкарылуы мөмкин булган процесс турында хәбәр итә: *Юл ачылырга мөмкин; Әти кайтырга мөмкин* һ.б. Бу модельнең парадигмалары чикләнгән.

10 нчы модель: *Ия – Хәб. -са кирәк* сөйләүчегә үтәлүе ихтимал булып тоелган процесс турында хәбәр итә: *Ул язса кирәк; Әтисе күрмәсә кирәк* һ.б. Бу модель бик актив кулланылмый, ләкин *-рга* формасында *бул* фигыле килгәндә, ихтимал мәгънәсен белдерүче буларак, *булса кирәк* тезмәсе башка модельләрдә дә кулланыла: *Ул яза булса кирәк; Ул эшләргә тиеш булса кирәк* һ.б.

11 нче модель: *Ия – Хәб. -а ал* процессны үтәүченең башкара алуын/алмавын хәбәр итә: *Ул яза ала; Әтисе карый алмый; Бала җырлый ала* һ.б. Бу модель барлык төр парадигмаларга да керә ала.

**§ 217. Хәбәре *бул* янында килгән фигыль белән бирелгән ике составлы модельләр.** *Бул* ярдәмче фигыле татар җөмлә модельләрен һәм аларның парадигмаларын төзүдә иң актив роль уйный торган универсаль бер чара санала.

Хәбәре исем белән бирелгән модельләрне ул наклонение парадигмаларына кертә: 1) хикәяләү наклонениесенә (индикативка): *Ул инженер булыр; Ул инженер булды; Ул инженер булган; Ул инженер булган иде* һ.б.; 2) шарт наклонениесенә: *Ул инженер булса* (*булды исә*); 3) боеру наклонениесенә: *Ул инженер булсын;* 4) теләк наклонениесенә: *Мин инженер булса идем;* 5) шартлы теләк наклонениесенә: *Ул инженер булыр иде* (әгәр тиешле шарт булса).

Шуның белән бергә *бул* ярдәмче фигыле хәбәре исем булган башка төр модельләр дә ясый: *Ул инженер булса кирәк; Ул инженер була күрсен; Ул инженер булырга тиеш.*

Кыскасы, *бул* ярдәмче фигыле хәбәре исем белән бирелгән модельләрне теләсә нинди парадигмага катнаштыра ала.

*Бул* ярдәмче фигыле 11 төрле фигыль хәбәр ясауда катнаша ала: *яза, язар, язды, язган, яза торган, язасы, язачак, язмакчы, язарлык,*

*язарга (язу, язмак), язып. Язып* формасы белән ул бер составлы модель төзи.

Ике составлы модельләрнең бер төрләрендә *бул* фигыле, яңа модаль мәгънә барлыкка китереп, яңа модель төзи, икенчеләрендә яңа модаль мәгънә өстәми, төп модельне төрләндерә генә. Мәсәлән, *Ул язмакчы* моделе *бул* фигыле ярдәмендә түбәндәге парадигма төрләрен ала: индикатив: *Ул язмакчы була;* шарт: *Ул язмакчы булса;* боеру: *Ул язмакчы булсын;* теләк: *Ул язмакчы булсын иде;* шартлы теләк: *Ул язмакчы булыр иде.*

*Бул* ярдәмче фигыле ике төрле модельне бергә кушуда да катнаша ала. Мәсәлән, *Ул язмакчы булса кирәк* моделендә *Ул язмакчы* моделе дә бар; *Ул язмакчы булырга тели; Ул язмакчы була күрсен; Ул язмакчы булырга мөмкин* модельләре дә *Ул язмакчы* моделе белән кушылганнар.

*Бул* ярдәмче фигыле, җөмләгә яңа төр модальлек өстәмичә, аны бары танылган наклонениеләр белән генә төрләндерә икән, димәк, ул яңа модель ясамый, билгеле модельләрнең парадигмасын гына төзи; яңа мөстәкыйль модель төзесен өчен, ул җөмләгә яңа модаль мәгънә (грамматика фәнендә моңа кадәр наклонение дип танылмаган модаль мәгънә) өстәргә тиеш.

Алдан ук гомумиләштереп әйтеп куярга мөмкин: *бул* ярдәмче фигыле ун очракта яңа мөстәкыйль модель ясый, шуларның сигезе – ике составлы: 12 (*-а булыр*), 13 (*-ар булды*), 14 (*-ардай булды*), 15 (*-ды булыр*), 16 (*-ган була*), 17 (*-гандай була*), 18 (*-а торган булды*), 19 (*-рга булды*), икесе – бер составлы: 39 (*-рга була*), 40 (*-ып була*); ул тагын дүрт очракта модельне төрләндерә: 2 (*-асы – -асы бул*), 2 ә) (*-ачак – -ачак бул*), 4 (*-арлык – -арлык бул*), 5 (*-макчы – макчы бул*).

Хәзер *бул* сүзе белән ясалган ике составлы модельләрне тикшерүгә күчик.

12 нче модель: *Ия – Хәб. -а булыр: Ул яза булыр.* Семантикасы – үтәлүе сөйләүчегә ихтимал булып күренгән процессны хәбәр итү. Бу модельнең төрләнеше чикле, һәр төр үзенә генә хас мәгънә белдерә. Мәсәлән, *Ул яза булды* төрләнешендә субъектның процессны башкарырга тиешлеге турында сөйләүче һәм үтәүче бергәләп хәл иткәннәр булып аңлашыла.

13 нче модель: *Ия – Хәб. -ар булды: Ул язар булды.* Семантикасы – процессны үтәү агенсның гадәтенә кергән. Бу модель төрләре бик аз.

14 нче модель: *Ия – Хәб. -ардай бул: Ул язардай булды.* Семантикасы – агенс үтәргә дип көткән процессны хәбәр итү. Бу модельнең төрләнеше шактый бай.

15 нче модель: *Ия – Хәб. -ды булыр: Ул язды булыр.* Семантикасы – үтәлеше чамаланган процесс турында хәбәр итү. Хәбәр интенсивлык белдереп ике фигыльдән торса, *булыр* фигыле процессның үтәлешен киләчәккә карата: *Ул китте барды булыр.* Моның төрләнеше бик чикле.

16 нчы модель: *Ия – Хәб. -ган була: Ул язган була.* Семантикасы – сөйләүче процесс үтәлешенә ирония белән карый яки агенсның процессны башкаруында җитдилек җитми: *Ул язган була; Ул язган булды; Ул язган булыр.* Контекстына карап, бу модель процессның билгеле бер вакытка тәмамлануын да белдерә: *Син килгәнче, ул язган булыр; Без өлгергәнче, ул язган була.*

17 нче модель: *Ия – Хәб. -гандай бул: Ул язгандай була.* Семантикасы – агенс процессны ярты-йорты гына итеп, күз буяу өчен генә үти.

18 нче модель: *Ия – Хәб. -а торган бул: Ул яза торган булды.* Семантикасы – процессны үтәү агенсның гадәтенә әйләнгән.

19 нчы модель: *Ия – Хәб. -рга булды: Ул язарга булды; Ул язарга булган.* Семантикасы – башкарылуы агенс тарафыннан хәл ителгән процессны хәбәр итү.

Җыеп шуны әйтергә кирәк: телдәге барлык модаль мәгънәләр җентекләп өйрәнелгәч, бу параграфта саналган модельләрдәге модаль мәгънәләр дә модальлек системасына каратылсалар, әле генә саналган модельләрне 1 нче модельнең наклонение парадигмасына кертүләре мөмкин.

**§ 218. Хәбәре *ит* сүзен алган фигыльләр белән бирелгән ике составлы модельләр.** *Ит* фигыле үзенең төп мәгънәсендә һәм ярдәмче мәгънәләрдә кулланыла. Аның төп мәгънәсе – *бул* дигән көчемсез фигыльнең көчемле пары булу: *Ул инженер булды – Ул аны инженер итте*, ягъни нәрсәнедер үзгәртү, ясау. *Балтаны бритва кебек итте* дигәндә дә *итү* фигыле үзенең *үзгәртү, яңадан ясау* кебек төп мәгънәсендә килә.

Фигыльләр белән бергә килгәндә, *ит* фигыле бер генә очракта төп мәгънәне белдерә, *-а торган* формасы янында гына. Бу очракта да ул

*бул* күчемсез фигыленең күчемле пары булып кала: *Ул яза торган булды – Ул аны яза торган итте*.

Башка очракларда *ит* фигыле үзенең ярдәмче мәгънәсендә, ягъни ниятләү мәгънәсендә килә һәм дүрт төрле модель ясауда катнаша.

20 нче модель: *Ия – Хәб. -а торган ит* (яки -*малы ит*/ -*арлык ит*): *Ул аны яза торган итә* (*язмалы итә, язарлык итә*). Семантикасы – субъект тарафыннан башка бер зат (я әйбер) хәбәр ителгән процессны башкарырлык хәлгә китерелә. Юклык формасында кушымчалар үзгәрергә мөмкин: *Ул таякны сынмый торган итте*/ *сынмаслык итте*. Бу модель тулы парадигмалы булып кулланыла.

21 нче модель: *Ия – Хәб. -гандай ит: Ул язгандай итте.* Семантикасы – процессны күз буяу өчен генә үтәү.

22 нче модель: *Ия – Хәб. -асы ит: Ул язасы итте.* Семантикасы – агенс процессны үтәүне хәл иткән.

23 нче модель: *Ия – Хәб. -рга ит: Ул язарга итә.* Семантикасы – үтәлүе агенс тарафыннан хәл ителгән процесс турында хәбәр итү. Бу модельнең парадигмалары шактый чикле.

**§ 219. Хәбәре *кирәк, ярый, бар*/*юк* сүзләре белән бирелгән ике составлы модельләр.** Бу хәбәрлек сүзләр, бер яктан, исемнәргә, икенче яктан, фигыльләргә якын торалар.

24 нче модель: *Ия – Хәб. кирәк (кирәксә, кирәкмәс, кирәкте): Миңа син кирәк.* Семантикасы – ия аңлаткан предметның (затның) юнәлеш килешендәге тәмамлык белдергән затка (предметка) кирәклеге яки кирәк түгеллеге хәбәр ителә: *Аңа эш кирәк; Чүкечкә сап кирәк; Моңа буяу кирәк түгел; Аңа син кирәкмисең* һ.б.

25 нче модель: *Ия – Хәб. ярый: Миңа син дә ярый; Аңа син ярамыйсың.* Семантикасы – ия аңлаткан затның (әйбернең) юнәлеш килешендәге тәмамлык белдергән затка (әйбергә) яравын/ярамавын хәбәр итү.

26 нче модель: *Ия – Хәб. бар/юк: Намусы бар; Намусы юк; Белеме бар; Белеме юк.* Семантикасы – субъектның барлыгын/юклыгын хәбәр итү.

**§ 220. Исем хәбәрле ике составлы модельләр.** Фигыльдән башка сүзләр белән бирелсә, хәбәр исем хәбәр дип атала, һәм мондый хәбәрле ике составлы модельләр төрле парадигмаларга *иде*, *бул*, *ит* фигыльләре ярдәмендә керәләр.

27 нче модель: *Ия – Хәб. И: Энесе укытучы; Ул инженер; Җиңүчесе – ул.* Хәбәр булып, исем яки исем алмашлыгы килә. Семантикасы – субъектның предметлашкан предикатив билгесен хәбәр итү, ягъни предметларны, затларны үзара тиңләп аңлату.

28 нче модель: *Ия – Хәб. -ныкы: Каләм минеке; Деталь станокныкы.* Семантикасы – хәбәрдән аңлашылган затның (предметның) иядән аңлашылган предметка хуҗа булуын хәбәр итү.

29 нчы модель: *Ия – Хәб. -лы/-сыз: Болын печәнле; Марат – дәфтәрсез; Ул атлы; Рөстәм атсыз.* Семантикасы – хәбәрдән аңлашылган әйбернең иядән аңлашылган затта (әйбердә) табылуы/табылмавы. Бу модельдә хәбәр булып бары исемнәр генә килә.

30 нчы модель: *Ия – Хәб. Сан: Каравылчылар – бишәү; Инженерлар – ике; Марат унынчы; Алар утызлап; Тегеләр – күбәү; Дошман берничә.* Семантикасы – субъектның санын хәбәр итү.

31 нче модель: *Ия – Хәб. Р: Марат хәйләкәр; Кәеф күтәренке; Күлмәге яшел; Ул бөек; Әнисе шулай.* Семантикасы – субъектның төрле төсмерле рәвеше хәбәр ителә.

32 нче модель: *Ия -у (-рга, -мак) – Хәб. Р: Сөюе яшертен; Баруы әпен-төпен; Булдыруы озак; Туздыруы тиз; Тырышуың бушка; Кайтырга соң; Барырга иртә; Язмак авыр; Алырга уңай; Язарга озак* һ.б. Семантикасы – иядән аңлашылган процессның төрле төсмерле рәвешен хәбәр итү.

**§ 221. Субъекты ия булып формалашмаган бер составлы модель.** Бу модельдә субъект сөйләүче өчен көтелмәгән була һәм ул *-га кадәр* (*-га чаклы, -га тикле*) формасын алып формалаша. Хәбәр теләсә нинди формада килә ала.

33 нче модель: (*Суб. -га кадәр*) *БК: Күгәрченнәргә тикле үбешәләр* (Г. Бәширов); *Малаена чаклы тискәре; Балага кадәр аңларга тырыша; Атына кадәр ышанычлы; Энесенә хәтле артист.*

Бу модельгә нигезләнеп ясалган җөмләләр семантик яктан – ике составлы, форма ягыннан бер составлы саналалар.

**§ 222. Баш кисәге хәбәр дип таныла алмый торган бер составлы модельләр.**

34 нче модель: *БК -ган бар/юк: Барган бар; Укыганым юк; Күргәнем бар; Язганыбыз бар; Күргәнебез юк* һ.б. Семантикасы –

билгесез үткән заманда агенс тарафыннан үтәлгән/үтәлмәгән процессны хәбәр итү. Баш кисәк (БК) тартым формасын ала, ә агенс я тартым кушымчасында, я иялек килешендәге сүз белән бирелә: *Безнең язганыбыз юк; Эшчеләрнең күргәннәре бар.*

35 нче модель: *БК -асы бар/юк: Язасым бар; Күрәсең юк; Әтинең киләсе бар.* Семантикасы – агенс башкарырга тиеш яки тиеш түгел процесс турында хәбәр итү. Агенс үзе я тартым, я иялек килешендәге сүз белән бирелә.

36 нчы модель: *БК -уы бар: Маратның язуы бар; Минем укуым бар; Синең сөйләвең бар.* Семантикасы – агенс үтәргә мөмкин булган процесс турында хәбәр итү.

Бу модельдә *юк* сүзе кулланыла алмый, ягъни *күрүе бар* дип әйтеп булса да, *күрүе юк* дигән модель телдә урнашмаган. Фигыль формасы тартымсыз килсә генә *юк* сүзе хәбәр булып килә: *Бару юк*; *Язу юк*. Бу ике составлы модельгә керә. Аның *бар* белән килгән варианты да очрый: *Кайту бар, китү юк.*

37 нче модель: *БК -асы кил: Аның кайтасы килә; Ашыйсым килә; Язасылары килә.* Семантикасы – иялек килешендә яисә тартым формасында бирелгән агенсның процессны үтәргә теләген хәбәр итү.

38 нче модель: *БК -рга кирәк (-мак кирәк): Сиңа укырга кирәк; Күрмәскә кирәк; Эшләргә кирәк.* Семантикасы – сөйләүче процессны башкаруга агенсны үгетли.

Җөмләдә *ничек?* сорау алмашлыгы да килгәндә *БК -мак* формасын җиңел ала: *Анда ничек бармак кирәк!*

39 нчы модель: *БК -рга ярый (мөмкин, була,* сирәгрәк *-мак ярый): Аңа укырга ярый (мөмкин, була); Көләргә ярамый (мөмкин түгел, булмый).* Семантикасы – сөйләүче агенска нишләргәдер рөхсәт итә яисә аннан тыя.

*-мак ярый/ярамый* шулай ук тыю я рөхсәт итүне белдерә, ләкин искергән форма санала: *Сөймәк ярый; Ташламак ярамый.*

40 нчы модель: *БК -ып була* (*-мыйча булмый/ярамый*): *Язып була; Укымыйча ярамый; Укымыйча булмый.* Семантикасы – үтәлү/үтәлмәве мөмкин булган процесс турында хәбәр итү; агенс һәрчак гомумиләштерелгән була, я ул сөйләүчегә карый (сорау формасында торганда, тыңлаучыга карый: *Сөйләп буламы?*).

**§ 223. Баш кисәге төрле фигыльләр белән бирелеп, үтәүчесе читләтелгән бер составлы модельләр.** Үтәүче баш килештәге исем белән бирелгәндә, бу модель ике составлыга әйләнә.

41 нче модель: *(Үт. юк) БК төш. юн. Ф: Озак барылган; Күп йокланган; Әйбәт эшләнә; Аз торылган; Җырлана; Утырыла; Картаелды; Тиз кителде.* Семантикасы – сөйләүче ихтыярыннан тыш, үзеннән-үзе үтәлгән процессны хәбәр итү. Үтәүче юк.

42 нче модель: *(Үт. юк) БК III зат күпл. Ф (II зат берл. Ф): Чәчмиләр, урмыйлар бу җирдә (Ә. Фәйзи); Шаулашалар; Күрсәләр, күрсеннәр; Ни чәчсәң, шуны урырсың* (мәкаль); *Кайда карама, анда шатлык.* Семантикасы – агенссыз, я гомумиләштерелгән агенслы процесс турында хәбәр итеЛә.

43 нче модель: *(Үт. юк) БК -рлык (-малы түгел, -а торган түгел): Барырлык; Уйламаслык түгел; Хатны язарлык; Янына бармалы түгел; Янына бара торган түгел.* Семантикасы – гомумиләштерелгән агенс үтәрлек/үтәмәслек процесс турында хәбәр итү.

44 нче модель: *(Үт. юк) БК табигать күренеше яисә психологик Ф: Салкынайтты; Җебетә; Сагындыра; Ирендерә; Өшетә; Калтырата; Йөткертә.* Табигать күренешләре яисә эчке психологик халәт турында хәбәр итү. Фигыль күбрәк йөкләтү юнәлешендә килә.

Шушы ук модельгә электән ике составлы булып, хәзер рус теле аңы аркасында бер составлы булып аңлашыла торган калыплар да карый: *Күңел болгана; Таңнар ата; Өзелә үзәк; Күз тиде; Караңгылана (Көн караңгылана).*

**§ 224. Баш кисәге төрле фигыльләр, ә үтәүчесе юнәлеш яки иялек килешендәге сүз белән бирелгән бер составлы модельләр.**

45 нче модель: *(Үт. -га) БК -асы: Миңа эшкә чыгасы; Маратка иртәгә кайтасы.* Семантикасы – үтәүче эшләргә тиеш эш турында хәбәр итү.

46 нчы модель: *(Үт. -гә) БК -рга: Сиңа барырга; Маратка укырга; Аларга килмәскә; Сугышчыга курыкмаска.* Семантикасы – сөйләүченең үтәүчегә тапшырган эше турында хәбәр итү.

47 нче модель: *(Үт. -нең) БК -у (-ыш): Минем тегермәнгә барыш* (Г. Бәширов); *Хәзер минем ял итеп яту иде; Аның шәһәрдән*

*килеше иде.* Семантикасы – сөйләү вакытында үтәүче тарафыннан башкарылган эшне хәбәр итү.

**§ 225. Баш кисәге исемнәр белән бирелгән бер составлы модельләр.** Болар атау җөмлә дигән исемдә йөртеләләр.

48 нче модель: *БК. И: Кыш. Салкын һава; Яңгыр. Пычрак; Сәлам!; Их, Марат!* Семантикасы – әйбернең исемен хәбәр итү интонациясе белән әйтү аша аның барлыгын хәбәр итү.

49 нчы модель: *БК. С.: Караңгы; Салкын; Тыныч; Юеш; Тыгын; Кыен; Күңелсез; Куркыныч.* Семантикасы – сыйфатларны хәбәр итү интонациясе белән әйтеп, берәр хәл, билге турында хәбәр итү.

**§ 226. Җәенкеләнми торган баш кисәкле бер составлы модель.** Бу төр модельләр телдә бик чикле һәм аларның парадигмалары да модальлек һәм раслау/инкяр планында гына күзәтелә.

50 нче модель: *БК* җәенкеләнми. Баш кисәк булып, ымлыклар, аваз ияртемнәре һәм җавап сүзләре генә килә: *Әй, Алла! Ах! Уф! Тфү! Урра!*

*– Син чыгыш ясыйсыңмы? – дип сорады Гаяз.*

*– Әйе.*

*– Ә син?*

*– Юк.*

*– Ә Марат сөйләрме?*

*– Әлбәттә.*

Семантикасы – төрле тойгыларны, раслау һәм инкярны бер сүз белән белдерү.

**§ 227. Фразеологик модельләр.** Һәрбер телдә, ныгып калып, фразеологик берәмлеккә әйләнгән модельләр (калыплар) бар. Татар телендә алар өйрәнелмәгәннәр әле. Хәзергә бары ике төрле модельне күрсәтү белән чикләнергә туры килә.

51 нче модель: *Хәб. БК -штән (-үдән) китте: Котырынып биештән китте* (Г. Бәширов)*; Кунакка йөрешүдән китте.* Семантикасы – үтәлеп ята торган эш турында хәбәр итү.

52 нче модель: *Хәб. БК -мәмешкә салына: Ул күрмәмешкә салына; Аңламамышка салыналар.* Семантикасы – үтәүче эшләгән булып кыланган процесс турында хәбәр итү.

## § 228. Җыйнак җөмлә модельләрен бергә туплап күрсәтү.

| Модельләр | Мисаллар |
|---|---|
| I. Хәбәре төрләнешле фигыль белән бирелгән ике составлы модель | |
| 1. *Ия – Хәб. Ф.* | *Ул яза* |
| II. Хәбәре төрләнешсез фигыль белән бирелгән ике составлы модельләр | |
| 2. *Ия – Хәб. -асы* | *Хатны ул язасы* |
| 2а. *Ия – Хәб. -ган* | *Ул язган* |
| 2ә. *Ия – Хәб. -ачак* | *Ул язачак* |
| 3. *Ия – Хәб. -а торгандыр* | *Ул яза торгандыр* |
| 4. *Ия – Хәб. -арлык* | *Ул язарлык* |
| 4а. *Ия – Хәб. -ар* | *Ул язар* |
| 5. *Ия – Хәб. -макчы* | *Ул язмакчы* |
| 6. *Ия – Хәб. -у (-рга, -мак)* | *Теләге язу (язарга)* |
| 7. *Ия – Хәб. -магае* | *Ул язмагае* |
| III. Хәбәре *тиеш*, *мөмкин*, *кирәк*, *ал* сүзләрен алган фигыльләр белән бирелгән ике составлы модельләр | |
| 8. *Ия – Хәб. -рга тиеш* | *Ул язарга тиеш* |
| 9. *Ия – Хәб. -рга мөмкин* | *Ул язарга мөмкин* |
| 10. *Ия – Хәб. -са кирәк* | *Ул язса кирәк* |
| 11. *Ия – Хәб. -а ал* | *Ул яза ала* |
| IV. Хәбәре *бул* янында килгән фигыль белән бирелгән ике составлы модельләр | |
| 12. *Ия – Хәб. -а булыр* | *Ул яза булыр* |
| 13. *Ия – Хәб. -ар булды* | *Ул язар булды* |
| 14. *Ия – Хәб. -ардай булды* | *Ул язардай булды* |
| 15. *Ия – Хәб. -ды булыр* | *Ул язды булыр* |
| 16. *Ия – Хәб. -ган була* | *Ул язган була* |
| 17. *Ия – Хәб. -гандай бул* | *Ул язгандай була* |
| 18. *Ия – Хәб. -а торган булды* | *Ул яза торган булды* |
| 19. *Ия – Хәб. -рга булды* | *Ул язарга булды* |

| | |
|---|---|
| 2ә. *Ия – Хәб. -ачак бул* | *Ул язачак булды* |
| 2. *Ия – Хәб. -асы бул* | *Ул язасы булды* |
| 4. *Ия – Хәб. -арлык бул* | *Ул язарлык булды* |
| 5. *Ия – Хәб. -макчы бул* | *Ул язмакчы булды* |

V. Хәбәре *ит* сүзен алган фигыльләр белән бирелгән ике составлы модельләр

| | |
|---|---|
| 20. *Ия – Хәб. -а торган ит* | *Ул аны яза торган итте* |
| 21. *Ия – Хәб. -гандай ит* | *Ул язгандай итте* |
| 22. *Ия – Хәб. -асы ит* | *Ул язасы итте* |
| 23. *Ия – Хәб. -рга ит (тора)* | *Ул язарга итә (тора)* |

VI. Хәбәре *кирәк, ярый, бар/юк* сүзләре белән бирелгән ике составлы модельләр

| | |
|---|---|
| 24. *Ия – Хәб. кирәк* | *Ул кирәк* |
| 25. *Ия – Хәб. ярый* | *Ул ярый* |
| 26. *Ия – Хәб. бар/юк* | *Ул бар/юк* |

VII. Исем хәбәрле ике составлы модельләр

| | |
|---|---|
| 27. *Ия – Хәб. И.* | *Ул укучы* |
| 28. *Ия – Хәб. -ныкы* | *Ул бабасыныкы* |
| 29. *Ия – Хәб. -лы/-сыз* | *Ул дәфтәрсез* |
| 30. *Ия – Хәб. Сан* | *Ул бишенче* |
| 31. *Ия – Хәб. Р.* | *Яшәү күңелле* |
| 32. *Ия – -у (-рга, -мак) – Хәб. Р.* | *Туздыру тиз; Барырга ерак* |

VIII. Субъекты ия булып формалашмаган бер составлы модель

| | |
|---|---|
| 33. *(Суб. үт. -га кадәр) БК* | *Күгәрченнәргә кадәр үбешә* |

IX. Баш кисәге хәбәр дип таныла алмый торган бер составлы модельләр

| | |
|---|---|
| 34. *БК -ган бар/юк* | *Язганым бар/юк* |
| 35. *БК -асы бар/юк* | *Язасым бар/юк* |
| 36. *БК -уы бар* | *Язуы бар* |
| 37. *БК -асы кил* | *Язасым килә* |
| 38. *БК -рга кирәк (-мак кирәк)* | *Язарга кирәк* |

| | |
|---|---|
| 39. *БК -рга ярый (мөмкин була; -мак ярый)* | *Язарга ярый (мөмкин, була)* |
| 40. *БК -ып бул (-мыйча ярамый)* | *Язып була; Язмыйча ярамый* |

X. Баш кисәге төрле фигыльләр белән бирелеп, үтәүчесе читләтелгән бер составлы модельләр

| | |
|---|---|
| 41. *(Үт. юк) БК төш. юн. Ф* | *Йокланган* |
| 42. *(Үт. юк) БК 3 зат күпл. Ф (2 зат берл. Ф.)* | *Шаулыйлар; Ни чәчсәң, шуны урырсың* |
| 43. *(Үт. юк) БК -рлык (-малы түгел, -а торган түгел)* | *Барырлык; Уйламаслык түгел; Бармалы түгел* |
| *44. (Үт. юк) БК махсус Ф* | *Калтырата; Яктыра; Күңел болгана* |

XI. Баш кисәге төрле фигыльләр, ә үтәүчесе юнәлеш яки иялек килешендәге сүз белән бирелгән бер составлы модельләр

| | |
|---|---|
| 45. *(Үт. -га) БК -асы* | *Миңа эшкә чыгасы* |
| 46. *(Үт. -гә) БК -рга* | *Сиңа барырга* |
| 47. *(Үт. -нең) БК -у (-ыш)* | *Тегермәнгә барыш* |

XII. Баш кисәге исемнәр белән бирелгән бер составлы модельләр

| | |
|---|---|
| 48. *БК. И* | *Кыш. Салкын һава* |
| 49. *БК. С* | *Караңгы. Суык* |

XIII. Җәенкеләнми торган баш кисәкле бер составлы модель

| | |
|---|---|
| 50. *БК* җәенкеләнми | *Ах! Уф! Тсс! Әйе. Юк* |

XIV. Фразеологик модельләр

| | |
|---|---|
| 51. *(Хәб.) БК -ештән китте* | *Языштан китте* |
| 52. *(Хәб.) БК -мәмешкә салына* | *Күрмәмешкә салына* |

Шулай итеп татар телендә җыйнак җөмләнең 50 иректле (синтаксик) моделе бар. Болардан 32 се ике составлы, 18 е бер составлы модельләр. Фразеологик модельләр әле өйрәнелмәгәннәр. Хәзергә үрнәк өчен аның ике төре күрсәтелде.

Җәенке җөмләләрнең грамматик модельләре аерым алып тикшерелми, чөнки алар иярчен кисәкләрне өйрәнү тәртибендә тикшереләләр. Шуңа күрә аларның модельләрен формулаларда күрсәтү дә гамәлдә кабул ителмәгән. Ләкин махсус синтаксик тикшеренүләрдә формулаларга (схемаларга) әйләндереп язу очраштыргалый. Без биредә аның берничә үрнәген китерү белән генә чикләнәбез.

1. *Якын дустым шәһәрдән кайтты – Аер. С. – Ия. И. – Хәл. -дән – Хәб. Ф.*

2. *Якын дустым шәһәрдән китап алып кайтты – Аер. С. – Ия. И. – Хәл. -дән – Тәм. И. – Хәб. Ф.*

Җәенке җөмләләрне символлар белән формулалар итеп язу аларның структур-семантик модельләрен өйрәнгәндә киң кулланыла (242–245 § ларны карагыз).

Җыйнак җөмләнең әле генә күрсәтелгән модельләре (калыплары), сөйләмгә килеп керү өчен, төрле грамматик формаларны һәм стилистик төрләрне алалар. Алар синтаксис фәнендә модельләрнең грамматик формалары һәм стилистик реальләшүләре (кулланылышлары, төрләре) дип аерым алып өйрәнеләләр.

## ГАДИ ҖӨМЛӘ МОДЕЛЬЛӘРЕНЕҢ ГРАММАТИК ФОРМАЛАРЫ ҺӘМ ПАРАДИГМАЛАРЫ

**§ 229. Гомуми мәгълүмат. Иң элек формалар турында.** Сөйләмдә кулланылганда җөмлә модельләре үзара төрле мәгънә мөнәсәбәтләренә керәләр һәм, аларны белдерү өчен, төрле грамматик формаларны алалар, стилистик яктан үзгәрәләр.

Модельләрнең грамматик категорияләр буенча үзгәрешенә түбәндәге грамматик формалар керә: 1) раслау/инкярлык формалары; 2) хикәя, боеру, сорау, тойгы формалары; 3) синтаксик наклонение формалары; 4) синтаксик зат формалары; 5) синтаксик заман формалары; 6) күрелгәнлек һәм күрелмәгәнлек формалары; 7) синтаксик юнәлеш формалары; 8) синтаксик актуальлек формалары.

Синтаксик формалар ике төрле булалар: а) җөмләнең кайсы да булса бер кисәгенә (күбрәк хәбәргә) тагылып киләләр, ә) аерым кисәккә түгел, ә гомумән җөмләгә каратылалар; соңгысына җөмләнең интонациясе, сүз тәртибе һәм модаль лексик-синтаксик чаралар (кисәкчәләр,

ымлыклар, модаль сүзләр һәм модальлек белдерүче ярдәмче фигыльләр) карый.

Күп кенә телләрдә җөмлә формаларын вариантлы һәм вариантсыз дип бүлү гадәткә кергән. Татар синтаксисында да бу бүленешне үткәреп була. Теге яки бу конкрет грамматик мәгънәне белдерүче форма һәр очракта да үзе генә йөрсә, аның вариантлары булмаса, андый форманы вариантсыз форма дип атыйлар. Мәсәлән, татар телендә үткән һәм киләчәк заманнар берничә төрле, ләкин алар вариантлар түгел, чөнки мәгънәләре белән бер-берсеннән нык аерылалар: *Урман шаулады; Урман шаулый иде; Урман шаулаган; Урман шаулаган иде; Урман шаулар; Урман шаулаячак.*

Кайбер наклонение бездә вариантлы. Мәсәлән, боеру наклонениесенең *Син кил; Син килә күр* кебек вариантлары бар. Тиешлелек наклонениесенең *Ул язарга тиеш; Ул язачак иде; Ул язасы иде* кебек вариантлары күзәтелә.

**Хәзер парадигма турында.** Җөмләнең парадигмасы дип, билгеле бер гомуми мәгънә тирәсенә тупланган синтаксик формалар системасына әйтәләр. Мәсәлән, заман белдерү дигән гомуми мәгънә тирәсенә тупланган барлык заман формалары бер парадигма итеп каралалар. Әйтү максаты дигән гомуми мәгънә тирәсенә тупланган хикәя, боеру, сорау һәм тойгылы җөмләләр дә бер парадигма барлыкка китерәләр.

Татар теле җыйнак җөмләләрендә формалар түбәндәге парадигмаларга оешалар: 1) раслау/инкярлык, 2) әйтү максаты, 3) зат һәм сан, 4) наклонение, 5) заман, 6) күзәтелгәнлек/күзәтелмәгәнлек, 7) юнәлеш, 8) актуальлек.

Гади җөмләнең һәр моделендә шушы парадигмалар тикшерелергә тиеш. Ләкин татар телендә бу эш башкарылмаган әле; әгәр шулай эшләнсә, безнең телдәге кайбер мөстәкыйль модельләр башка бер модельнең теге яки бу парадигмасына кереп бетәргә дә мөмкин. Мәсәлән, җөмләнең наклонение парадигмасы эченә хәзергә берничә модель кертелгән. Наклонениеләрне тикшерү тәртипкә салынгач, һәрбер парадигманы аерым карау мөмкинлеге туачак.

Җөмлә парадигмалары аерым сүзнең морфологик парадигматикасына (төрләнешенә) нигезләнә. Җөмлә парадигмасын билгеләүче сүз хәбәр булып килә. Шуның белән бергә һәрбер парадигманың һәрбер формасы җөмлә төзелешенә дә тәэсир итә. Шуны истә тотып,

морфологиядәге сүз төркемнәре парадигмасы белән чикләнмичә, җөмлә схемаларының парадигмаларын да өйрәнергә туры килә. Бу һәрбер телдә шулай эшләнә.

Җөмләнең әйтү максаты буенча парадигмалары синтаксиста, җөмлә төрләре дип, күптән инде аерым алып тикшерелә (250–253 § ларны карагыз), актуальлек буенча төрләр дә актуаль кисәкләрне өйрәнү тәртибендә каралалар (188–190 § ларны карагыз). Җөмләнең раслау/инкяр төрләре дә, синтаксис логика фәненнән аерылып чыкканчы ук, раслау һәм инкяр хөкемләүгә (суждениегә) бәйле рәвештә аерым өйрәнелә башлаганнар. Традициягә ияреп, без дә раслау һәм инкяр җөмләләрне, җыйнак җөмлә парадигмалары эчендә түгел, ә «җөмлә төрләре» бүлегендә аерым алып тикшердек (247–249 § ларны карагыз).

Без биредә бу китапның башка бер урынында аерым алып яктыртылмаган парадигмаларга гына урын бирергә булдык.

**§ 230. Җөмлә модельләренең зат-сан формалары һәм аларның парадигмасы.** Зат-сан буенча парадигма төзи торган формалар, чаралар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) зат-сан кушымчалары: I зат: *-мын/-мен/-м, -быз/-без/-к;* II зат: -*сың/-сең/-ң, -сыз/-сез/-гыз/-гез;* III зат: зат күрсәткечен алмыйча гына башка затлардан аерылып тора, күплекне белдергәндә -*лар/-ләр* кушымчасы ала. Мисаллар: *Без язабыз/яздык; Сез язасыз/яздыгыз; Алар яза(лар)* һ.б.;

2) хәбәрлек кушымчалары (шул ук зат-сан кушымчалары, ләкин исем хәбәрләрдә кулланылганнары): I зат: *-мын/-мен, -быз/-без: Мин кешемен; Без кешебез/кешеләрбез;* II зат: *-сың/-сең, -сыз/-сез: Син кешесең; Сез кешесез/кешеләрсез;* III зат: я кушымчасыз, яисә -*дыр/-дер, -лардыр/-ләрдер* кушымчалары: *Ул кеше/кешедер; Алар – кеше/кешедер/кешеләрдер*. Хәзерге чорда -*дыр/-дер* формасы икеләнү модаль мәгънәсенә ныграк беркетелә бара;

3) тартым кушымчалары: I зат; *-ым/-ем/-м, -ыбыз/-ебез/-быз/-без: Язганым бар; Язганыбыз юк; Язасыбыз юк; Язасым бар;* II зат: *-ың/-ең/-ң, -ыгыз/-егез/-гыз/-гез: Язуың бар; Язуыгыз бар; Язасың бар; Язганың юк;* III зат: *-ы/-е/-сы/-се, -лары/-ләре: Язуы бар; Аларның язасылары юк* һ.б.;

4) ия-субъект яисә тәмамлык-үтәүче (агенс) җөмләдә: I зат алмашлыгы белән бирелә: *Мин язарга тиеш; Миңа язарга; Безгә язарга*

*кирәк; Безнең (Минем) укыйсыбыз (укыйсым) бар;* II зат алмашлыгы белән бирелә: *Син язарга тиеш; Сез язарга тиеш; Сез язмакчы; Синең язган бар; Сезгә язарга;* III зат кушымчасы, исем яисә исем мәгънәсендәге теләсә нинди сүз белән бирелә: *Ул язарга тиеш; Марат язарга тиеш; Укучылар (Алар) язарга тиеш(ләр); Маратның язасы бар; Маратка язарга; Аларга язарга кирәк* һ.б.

Зат буенча төрләнешне, русчадан алып, персональлек буенча парадигма дип тә атыйлар. Татар телендә парадигмага барлык төр модельләр дә буйсынып бетми. Мәсәлән, исем (атау) җөмләләрдә, үтәүчесез һәм гомумиләштерелгән үтәүчеле бер составлы җөмләләрдә, шулай ук сүз-җөмләләрдә зат-сан парадигмалары күзәтелми. Мәсәлән, *Язып була; Йокланган; Яктыра; Кыш. Салкын һава; Әйе; Дөрес; Уф! Бах-бах!*

Кайсы модельләрдә зат-сан парадигмасы ешрак күзәтелә соң? Хәзер шуларны мисалларда күрсәтик.

| Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|
| I зат | |
| *Мин язам* | *Без язабыз* |
| *Мин язарга тиеш(мен)* | *Без язарга тиеш(без)* |
| *Мин язмакчы(мын)* | *Без язмакчы(быз)* |
| *Мин беренче(мен)* | *Без беренче(без)* |
| *Минем язасы(м) килә* | *Безнең язасы(быз) килә* |
| *Минем укыган(ым) бар* | *Безнең укыган(ыбыз) бар* |
| *Миңа укырга ярый* | *Безгә укырга ярый* |
| *Мин кеше(мен)* | *Без кеше(без)(ләрбез)* |
| II зат | |
| *Син язасың* | *Сез язасыз* |
| *Син язарга тиеш(сең)* | *Сез язарга тиеш(сез)* |
| *Син язмакчы(сың)* | *Сез язмакчы(сыз)* |
| *Син беренче(сең)* | *Сез беренче(сез)* |
| *Синең язасы(ң) килә* | *Сезнең язасы(гыз) килә* |
| *Синең укыган(ың) бар* | *Сезнең укыган(ыгыз) бар* |
| *Сиңа укырга ярый* | *Сезгә укырга ярый* |
| *Син кеше(сең)* | *Сез кеше(сез)(ләрсез)* |

III зат

| | |
|---|---|
| *Ул яза* | *Алар яза(лар)* |
| *Ул язарга тиеш* | *Алар язарга тиеш(ләр)* |
| *Ул язмакчы* | *Алар язмакчы(лар)* |
| *Ул бишенче(дер)* | *Алар бишенче(ләрдер)* |
| *Аның язасы килә* | *Аларның язасы(лары) килә* |
| *Аның укыганы бар* | *Аларның укыганы(нары) бар* |
| *Аңа укырга ярый* | *Аларга укырга ярый* |
| *Ул кеше(дер)* | *Алар кеше(ләрдер)* |

**§ 231. Җөмлә модельләренең юнәлеш формалары һәм аларның парадигмасы.** Җөмлә модельләре, юнәлешләр буенча төрләнгәндә, структур яктан да шактый үзгәреш кичерәләр. Күчемсез фигыльнең төшем юнәлеше мөстәкыйль модель төзи: *Озак йөрелгән.* Җөмләләрнең юнәлеш буенча башка төрләре бер парадигма төзиләр.

Татар телендә биш юнәлеш санала: төп, төшем, кайтым, уртаклык һәм йөкләтү юнәлешләре. Җөмләләрнең юнәлеш буенча пардигмасын өйрәнгәндә, җыйнак җөмлә белән генә эш итү мөмкин түгел, чөнки юнәлеш формалары тәмамлык-объектсыз үз семантикаларын тулысынча ача алмыйлар.

1. Төп юнәлешкә нигезләнгән җөмләләр башкаларыннан нуль форма белән аерылып торалар. Башка юнәлеш мәгънәләрен билгеләгәндә, төп юнәлеш чыгыш ноктасы ролен уйный. Шуңа күрә төп юнәлеш семантикасын башка юнәлеш мәгънәләре булмау белән дә аңлаталар. Төп юнәлеш формасындагы җөмлә моделендә хәбәрдән аңлашылган процессны иядән яки тәмамлыктан аңлашылган үтәүче турыдан-туры үзе башкара: *Марат яза; Марат кеше булды; Маратның укыганы бар; Маратка укырга ярый; Маратка укырга.*

2. Төшем юнәлеше формасын алган җөмләдә субъект, объект, предикат, ия, тәмамлык һәм хәбәр дигән кисәкләрнең үзара мөнәсәбәтләре бик нык үзенчәлекле була. *Хат студентлар тарафыннан язылды* җөмләсендәге хәбәрдә төшем юнәлеше формасы булу иянең – объектны, тәмамлыкның – агенсны белдерүен таләп итә. Димәк, иядән аңлашылган әйбер (хат) җөмләнең субъекты булып килсә дә, ул агенс (үтәүче) була алмый, объект булып кала. *Җыелышта карар кабул ителде* җөмләсендә дә шул ук хәл, ләкин биредә агенс аерым кисәк

белән бирелмәгән, ул контексттан аңлашыла: *Карарны җыелышта катнашучылар кабул итә – Җыелышта карар кабул ителде.*

*Мондый шигырьнең язылганы юк иде әле* җөмләсендә агенс – билгесез, объект – *мондый шигырьнең.*

Төшем юнәлеше формасындагы җөмлә парадигма эчендә генә каралсын өчен, хәбәр төшем юнәлешендәге көчемле фигыль белән бирелергә тиеш.

3. Хәбәре кайтым юнәлешендәге фигыль белән бирелгән җөмләнең семантикасы – хәбәрдән аңлашылган процессны субъект үзе үти һәм үзе үк шул процессның объекты була: *Марат юына; Кош кагына; Ул сикеренә* һ.б. Бу семантика булсын өчен, кайтым юнәлеше формасы үзенең кайтым мәгънәсендә килергә тиеш.

4. Хәбәре уртаклык юнәлешендәге фигыль белән бирелгән җөмләнең семантикасы – үтәүчесе берничә булган процесс турында хәбәр итү. *Марат энисе белән хат язышып тора* җөмләсендә язу процессын Марат та, энисе дә үти, беренче үтәүче иядән, икенчесе тәмамлыктан аңлашыла. *Маратка энисе белән хат язышып торырга туры килде* моделендә ике үтәүче дә тәмамлык белән бирелгән. *Алар кул кысыштылар* җөмләсендә берничә үтәүче күплек санда килгән иядә бирелә.

Соңгы җөмләдә үтәүчеләр икәү генә түгел, күбрәк тә булырга мөмкин. *Кызлар көлешәләр; Халык йөгерешә* мисалларында күплектә бирелгән иядән үтәүчеләрнең күп булуы аңлашылып тора.

Җөмлә уртаклык формасында торганда, үтәүчеләр тигез дәрәҗәдә булмыйча, берсе төп үтәүче, икенчесе ярдәм итүче генә дә була ала: *Марат Ильяска рәсем ясашты; Наилә энисенә сыер савыша иде.* Бу җөмләләрдә төп үтәүче тәмамлык белән, ә ярдәм итүче ия белән бирелгән.

5. Хәбәре йөкләтү юнәлешендәге фигыль белән бирелгән җөмләнең семантикасы – туры объект таләп итүче көчемле процесс яисә үтәлүе агенска субъект тарафыннан йөкләтелгән процесс турында хәбәр итү. Мәсәлән, *Ул хәлне аңлатты* җөмләсендә йөкләтү юнәлеше формасы туры объект таләп итүче процесс турында хәбәр итә. *Марат Илдардан хат яздырды* җөмләсендә субъектның башка кешегә тапшырган эше турында хәбәр ителә. Эшне йөкләүче ия белән бирелә, ә эшне үтәүче (агенс) чыгыш килешендәге тәмамлыктан аңлашыла.

Кайбер модельләрдә йөкләүче дә тәмамлыкта бирелә: *Маратның Илдардан хат яздырганы бар.*

*Ит* ярдәмче фигылендәге *-т* йөкләтү формасы аны көчемсез *иде*, *бул* ярдәмче фигыльләренең көчемле пары итә. *Марат кеше иде – Марат аны кеше итте; Марат кеше булды – Маратны әтисе кеше итте.*

Татар телендә юнәлеш формалары күп кенә очракларда үзләренең юнәлеш семантикаларын югалтканнар, бары фигыльдән фигыль ясау ролен генә дә үтиләр. Шуңа күрә җөмләләрнең юнәлеш формасы белән төрләнүләрен парадигмага түгел, ә стилистик үзгәрешләргә кайтарып калдырырга мөмкин булыр иде. Ләкин шунысы бар: юнәлеш формалары җөмләнең синтаксик структурасына бик нык тәэсир итәләр. Димәк, аларны парадигматик үзгәрешләр рәтеннән карарга мөмкин.

Хәзер җөмләләрнең юнәлеш буенча парадигмаларын мисалларда бер урынга туплап күрсәтик.

1. *Марат чыршы бизи.*
2. *Чыршы Марат тарафыннан бизәлә.*
3. *Марат бизәнә.*
4. *Марат Илдарга чыршы бизәшә.*
5. *Марат Илдардан чыршы бизәтә.*

## Гади җөмләнең наклонение буенча формалары һәм парадигмалары

**§ 232. Гомуми мәгълүмат.** Наклонение ул фигыль формаларында бирелә торган модальлек. Ә модальлек – сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәте. Җөмләнең төп билгеләре: ул нәрсә булса да хәбәр итә (ягъни анда хәбәрлек була) һәм сөйләүче чынбарлыкка (тыңлаучыга, сөйләм эчтәлегенә, сөйләмнең формасына, сөйләү обстановкасына, үзенә) мөнәсәбәт белдерә (ягъни анда модальлек була). Шуңа күрә җөмләләрнең наклонение буенча формаларына һәм парадигмаларына җентекле рәвештә тукталу сорала.

Татар телендә наклонение, ягъни фигыль формалары белән модальлек белдерү җентекләп тикшерелмәгән, шуңа күрә аның татарча термины да юк, аның төрләре дә ачыкланмаган. Бары рус теле накло-

нениеләренә туры килгәннәре генә теге яки бу дәрәҗәдә ачыкланганнар. Русчага туры килми торганнары морфологиядә наклонение категориясенә дә кертелми калдырылган.

Гомуми тел гыйлемендә наклонениеләрне ике төргә аералар: а) реаль наклонение, моны синтаксик индикатив дип тә йөртәләр; ә) ирреаль наклонениеләр.

Синтаксик индикатив (үтәлүе реаль булган хикәяләү наклонениесе) формалары синтаксик заман һәм күзәтелгәнлек/күзәтелмәгәнлек формаларына аерылалар, шуңа карап индикативта җөмләләрнең ике төрле парадигма санала: а) заман буенча парадигма һәм ә) күзәтелгәнлек/күзәтелмәгәнлек буенча парадигма.

Синтаксик ирреаль (үтәлеше реаль булмаган) наклонениеләр татар телендә 12 санала, ләкин тюркологлар төзегән морфологиядә аларның бары 4 се чын наклонение дип табылган: боерык, шарт, теләк һәм шартлы теләк. Менә шуннан чыгып, җөмлә формалары дип без дә менә шул дүрт төрле ирреаль наклонениене алабыз. Башка ирреаль наклонение формаларын без хәзергә я мөстәкыйль модельләр итеп карадык (тиешлелек, шөбһәләнү, ниятләү, мөмкинлек, ризалык), я стилистик формаларга караттык (үкенү, ирония, гаҗәпләнү).

### Синтаксик индикатив формалары һәм парадигмалары

**§ 233. Җөмлә модельләренең заман формалары һәм аларның парадигмасы**. Җөмләнең заман буенча парадигмасын өйрәнү гадәттә **хәзерге заманнан** башлана. Ул сөйләү моменты белән туры килә торган яисә сөйләү моментына мөнәсәбәте булмаган (һәрчак үтәлеп тора торган) процессны формалаштыра. Стилистик яктан хәзерге заман формасы киләчәк һәм үткән заманны да белдерә ала.

Җөмләнең хәзерге заман формасы хәбәр булып килүче фигыльнең хәзерге заман формасы белән ясала, исем хәбәрләрдә хәзерге заман башка заман формалары булмау белән аерылып тора: *Марат яза; Теләгем – кайту; Китап студентныкы; Китап кирәк; Су юк; Марат укырлык; Ул каләмне язарлык итә; Маратның укыйсы килә; Яктыра; Төн; Караңгы; Буран.*

Индикативта заман билгеле була, һәм киресенчә, заман формалары башлыча индикативта була. Бик күп телләр өчен закон булган бу кагыйдәнең татарчада чыгармасы да бар. Мәсәлән, *Марат яза*

*ала* җөмләсе мөмкинлек наклонениесендә, ул төрле заман формасын алырга мөмкин: *Марат яза алачак; Марат яза алган иде* һ.б.

Хәзерге заман төсмере тагын башка төрле наклонениедәге модельләрдә дә күзәтелә: *Марат язарга тиеш; Миңа язарга мөмкин; Ул язардай була; Ул яза торган була; Миңа барасы; Аңа язарга кирәк; Аңа язарга ярый; Моны язып була*.

Гади җөмләнең **киләчәк заман** формасы түбәндәге чаралар белән бирелә:

а) хәбәр яки баш кисәкне белдергән фигыльнең киләчәк заман кушымчалары белән: *Марат язар; Марат язачак; Ул яза алачак;*

ә) *бул* һәм *ит* ярдәмче фигыльләре бик күптөрле модельләрдә кулланыла һәм, киләчәк заман кушымчасын алып, аларга киләчәк заман формасын бирә: *Марат инженер булачак/булыр; Ул укырга тиеш булачак; Сиңа укырга мөмкин булачак; Ул укырлык булачак; Китап минеке булыр; Аның укыйсы килер; Сиңа укырга кирәк булачак; Аның янына барырлык булыр; Китте-барды булыр; Әтисе Маратны инженер итәчәк; Ул аны укырлык итәчәк; Ул бу китапны минеке итәчәк;*

б) *-асы бар/юк* баш кисәге ярдәмендә: *Минем язасым бар; Аның язасы юк.*

Җөмләнең **үткән заман** формалары берничә төрле ясала.

1. Хәбәрне белдерүче фигыль һәм исем хәбәрләрдә *бул* ярдәмче фигыле *-ды* кушымчасын ала: *Ул язды; Ул яза торган булды; Ул инженер булды; Син беренче булдың; Буран булды*. Семантикасы – сөйләү моментына кадәр үтәлүен сөйләүче үзе күреп торган процессны, хәлне белдерү.

*Бул* ярдәмче фигыле төрле модаль мәгънә белдерүче модельләрдә дә килә ала һәм реаль булмаган (ирреаль) наклонениене реаль (индикатив) наклонениегә күчерә: *Ул язасы булды; Ул язган булды; Ул язачак булды; Ул яза торган булды; Ул язарлык булды; Ул язар булды; Ул язмакчы булды; Теләге – тикшерергә булды; Ул язарга тиеш булды; Ул яза булды; Ул язардай булды; Ул язгандай булды; Ул язарга булды; Акча кирәк булды; Аңа барырга кирәк булды; Миңа язарга булды; Язасы булды*.

2. Хәбәрне белдерүче фигыль һәм исем хәбәрдәге *бул* ярдәмче фигыле *-ган* кушымчасын ала: *Марат язган; Марат инженер булган; Марат орденлы булган; Китап Маратныкы булган; Ул чагында ка-*

*раңгы булган; Аңа китап кирәк булган* һ.б. Семантикасы – сөйләү моментына кадәр үтәлүен сөйләүче үзе күреп тормаган, эш нәтиҗәсеннән генә белгән процессны яки нинди дә булса бер хәлне хәбәр итү.

*Булган* ярдәмче фигыле, төрле модаль мәгънәле хәбәр янында килеп, эш-хәлне күзәтелмәгән үткән заманга кайтара: *Ул яза булган; Ул язар булган; Ул яза торган булган; Ул язган булган; Ул язачак булган; Ул язарлык булган; Ул язмакчы булган; Ул язарга булган; Аңа язарга булган; Ул язарга тиеш булган; Аңа язарга мөмкин булган; Ул язардай булган; Ул язгандай булган; Аңа язасы булган; Ул язасы булган.*

3. *БК -ган бар/юк* моделе дә җөмләнең синтаксик үткән заман индикатив формасын тәшкил итә: *Маратның язганы бар; Маратның язганы юк;* Җөмләнең бу формасы күзәтелгәнлек мәгънәсен дә бирә. Аны күзәтелмәгәнлек мәгънәсендә әйтергә кирәк булганда, *бар* сүзе – *булган*, *юк* сүзе *булмаган* сүзе белән алмаштырыла: *Маратның язганы бар – Маратның язганы булган; Маратның язганы юк – Маратның язганы булмаган*. Бу формалар парлы булып килсен өчен, агенслар (үтәүчеләр) икесендә дә иялек килеше формасында торырга тиешләр.

4. Җөмләнең үткән заман формасын ясаучы уникаль чара – *иде* ярдәмче фигыле. Ул теләсә нинди хәбәр янында кулланыла ала: *Марат яза иде; Марат язган иде; Марат яза торган иде; Марат язачак иде; Марат язар иде* (искергән)*; Ул язасы иде; Ул язарлык иде; Ул язмакчы иде; Ул язарга иде; Аңа язарга иде; Ул миңа кирәк иде; Бу миңа ярый иде; Өйдә кеше бар иде; Куркытуы бар иде; Ул инженер иде; Китап минеке иде; Төн иде; Укырга барыш иде; Янына бармалы түгел иде; Аның язганы бар иде; Аның язасы юк (бар) иде; Ул язгандай иткән иде; Ул язарга иткән иде; Язып була иде.*

Җөмләнең төрле модельләрен *бул* ярдәмче фигыле төрле парадигмаларга кертә ала, дигән идек. *Иде* ярдәмче фигыле *бул* ярдәмче фигыле янында да килә ала һәм җөмлә модельләрен төрле парадигмалардан икенче мәртәбә әйләндереп чыгара: *Ул язачак булган иде; Ул язмакчы булган иде; Ул инженер булган иде* һ.б. *Иде* ярдәмче фигыле *булган* фигылендәге күзәтелмәгәнлек төсмерен дә юкка чыгара: *иде* кулланылганда, процесс яки хәл күзәтелгәнлек төсмерен ала.

Җөмлә модельләре буенча күзәтеп чыгу шуны күрсәтә, *иде* кайбер модельләрдә бөтенләй кулланылмый диярлек. Мәсәлән, 3 нче модельдә (*Ия – Хәб. -а торгандыр*), 7 нче модельдә (*Ия – Хәб. -магае*);

10 нчы модельдә (*Ия – Хәб. -са кирәк*) *иде* фигыленең кулланылмавы норма буларак урнашкан. Бу аңлашыла да, чөнки -*магае* формасында *иде* фигыле кереп урнашып калган: -*магай+ие* (*иде*), ә калган икесе шикләнү мәгънәсен бирә, шуңа күрә күзәтелгәнлек мәгънәсен белдерүче *иде* фигыле анда килеп керә алмый.

Төрки телләр морфологиясен төзүчеләр *иде* ярдәмче фигылен бер очракта заман белдерүче дип саныйлар (*яза иде, язган иде, яза торган иде, язар иде*), башка очракларын заман белдерүгә каратмыйлар (*язасы иде; язмакчы иде, язарлык иде*). Димәк, *иде* ярдәмче фигыленең заман белдерүе өстәмә өйрәнүне таләп итә.

**Искәрмә**. *Иде* фигыле шарт һәм боерык (-*сә, -сен*) формасындагы фигыль белән кулланылганда заман белдерми, шартлы теләк дигән модаль мәгънә бирә: *Ул килсә иде; Ул килсен иде.*

**§ 234. Төрле җөмлә модельләренең заман формаларында килүләре.** Гомуми тел гыйлемендә заман формалары индикативта гына (хикәяләү наклонениясендә генә) кулланыла дигән караш урнашкан, чөнки һинд-европа телләрендә заманның төп мәгънәсе генә фигыль формаларында бирелә, аның төрле төсмерләре лексик юл белән аңлатыла. Төрки телләрдә исә, төп заман мәгънәләре дә, аның күптөрле төсмерләре дә фигыль формаларында бирелә ала. Ягъни заман төсмерләре төрле модаль мәгънәләргә төрелеп килә ала. Мәсәлән, ниятләү, теләк, мөмкинлек, чамалау кебек модаль мәгънәле модельләр дә заман формаларын алалар. Бу төр модальлектә (наклонениедә) сөйләүченең генә түгел, ә субъектның да, агенсның да чынбарлыкка мөнәсәбәте чагыла.

Без биредә заман формалары парадигмасын, үрнәк өчен, берничә модельдә бирү белән чикләнәбез һәм татарчада фигыль хәбәр эчендә бирелә торган мәгънәләрнең русчада лексик чаралар аркылы бирелүен күрсәтү өчен, мисалларның русча тәрҗемәләрен дә китерәбез.

### *1. Ия–Хәб. Ф.*

1) *Ул яза* ‘Он пишет’.

2) *Ул язар* ‘Он напишет’; *Ул язачак* ‘Он обязательно напишет’.

3) *Ул язды* ‘Он написал’; *Ул язган* ‘Он написал, оказывается’; *Ул яза иде* ‘Он написал было’; *Ул язган булган* ‘Он, оказывается, тогда писал’; *Ул язган иде* ‘Он написал было’; *Ул язган булган* ‘Он, оказыва-

ется, написал было’; *Ул язачак иде* ‘Он должен был писать’; *Ул язачак булган* ‘Он, оказывается, должен был писать’.

### *2. Ия–Хәб. -асы; 45. (Үт. -га) БК -асы.*

1) Бу модельләрнең тиешлелек модаль мәгънәсе хәзерге заманда ныграк чагыла: *Ул язасы* ‘Он должен писать’; *Аңа язасы* ‘Ему надо писать’.

2) *Ул язасы булыр/булачак* ‘Он должен будет писать’; *Аңа язасы булыр/булачак* ‘Ему надо будет писать’.

3) *Ул язасы иде* ‘Он должен был писать’; *Ул язасы булган* ‘Он, оказывается, должен был писать’.

### *3. Ия–Хәб. -арлык. 43. (Үт. -юк) БК -арлык.*

1) *Ул язарлык* ‘Он в состоянии писать’; *Янына барырлык* ‘Можно подойти’; *Янына бармалы (бара торган) түгел* ‘Невозможно подойти’.

2) *Ул язарлык булыр/булачак* ‘Он станет в состоянии писать’; *Янына барырлык булыр/булачак* ‘Можно будет подойти’. *Янына бармалы (бара торган) булмаячак* ‘Невозможно будет подойти’.

3) *Ул язарлык иде* ‘Он был в состоянии писать’; *Ул язарлык булган* ‘Он, оказывается, был в состоянии писать’; *Ул язарлык булды* ‘Он стал в состоянии писать’; *Янына бармалы түгел иде* (*бара торган түгел иде*) ‘Невозможно было подойти’; *Янына бармалы булмаган* (*бара торган булмаган*) ‘Оказывается, невозможно было подойти’.

### *4. Ия–Хәб. -макчы.*

1) *Ул язмакчы* ‘Он намерен писать’.

2) *Ул язмакчы булыр* ‘Он намерен будет писать’.

3) *Ул язмакчы иде* ‘Он намерен был писать’; *Ул язмакчы булган* ‘Он, оказывается, намерен был писать’.

### *5. Ия–Хәб. -кирәк.*

1) *Тынычлык кирәк* ‘Нужен мир’.

2) *Тынычлык кирәк булачак/булыр* ‘Нужен будет мир’.

3) *Тынычлык кирәк иде* (диал. *кирәкте*) ‘Нужен был мир’; *Тынычлык кирәк булган* ‘Оказывается, нужен был мир’; *Тынычлык кирәк булды* ‘Нужен был мир’.

***27. Ия–Хәб. И.***

1) *Ул эше* ‘Он рабочий’.

2) *Ул эше булачак/булыр* ‘Он будет рабочим’.

3) *Ул эше иде* ‘Он был рабочим’; *Ул эше булды* ‘Он стал рабочим’; *Ул эше булган* ‘Он был (стал), оказывается, рабочим’.

***34. БК -ган бар/юк.***

1) *Аның язганы бар* ‘Он когда-то писал’. Күренгәнчә, бу модельдә үткән заманда булган эш хәбәр ителә, ләкин аның нәтиҗәсе хәзерге заманда итеп күрсәтелә.

2) *Аның язганы булачак/булыр* (*бар* опускается) ‘У него еще будет случай сказать, что он писал’.

3) *Аның язганы бар иде* ‘Когда-то был случай, что он писал’.

***37. БК -асы кил.***

1) *Аның язасы килә* ‘Он хочет писать’.

2) *Аның язасы килер* ‘Он захочет писать’.

3) *Аның язасы килде* (*килгән, килә иде, килгән иде, киләчәк иде; килгән булган, килә булган, киләчәк булган* и т.д.) ‘Он хотел писать’.

Шул рәвешчә барлык грамматик модельләр буенча да заман формалары парадигмаларын төзеп чыгарга мөмкин.

**§ 235. Җөмлә модельләренең күзәтелгәнлек/күзәтелмәгәнлек формалары һәм аларның парадигмалары**. Күзәтелгәнлек/күзәтелмәгәнлек мәгънәсе татар телендә фигыль хәбәр формалары белән бирелсә, һинд-европа телләрендә ул лексик чара белән белдерелә, шуңа күрә ул телләрдә грамматик категория саналмый. Татарчада ул төгәл һәм нык шомарган грамматик категорияләр рәтенә керә.

Күзәтелгәнлек формасындагы җөмлә үтәлү/үтәлмәвен сөйләүче үзе күзәткән, күреп торган, яисә аны төп чыганактан – субъекттан я агенстан белгән эш-хәлне хәбәр итә: *Ул яза; Ул язачак; Ул язды; Ул инженер; Ул инженер иде.*

Күзәтелмәгәнлек формасындагы җөмлә үтәлү-үтәлмәвен сөйләүче үзе күзәтмәгән, күрмәгән, аны башкалардан ишетеп белгән эш-хәлне хәбәр итә: *Ул яза икән; Ул язачак икән; Ул инженер икән; Ул инженер булган* һ.б.

1. Күзәтелгәнлек/күзәтелмәгәнлек бигрәк тә үткән заманда ачык чагыла һәм тулы бер система тәшкил итә; күзәтелмәгәнлекнең төп күрсәткече булып бу очракта *булган* ярдәмче фигыле кулланыла.

| **Үткән заманның күзәтелгәнлек формалары:** | **Үткән заманның күзәтелмәгәнлек формалары:** |
| --- | --- |
| 1. *Ул язды* | *Ул язган* |
| *2. Ул инженер иде* | *Ул инженер булган* |
| *3. Ул беренче иде* | *Ул беренче булган* |
| *4. Ул яза иде* | *Ул яза булган* |
| *5. Ул язган иде* | *Ул язган булган* |
| *6. Ул яза торган иде* | *Ул яза торган булган* |
| *7. Ул язачак иде* | *Ул язачак булган* |
| *8. Ул язасы иде* | *Ул язасы булган* |
| *9. Ул язмакчы иде* | *Ул язмакчы булган* |
| *10. Ул язарлык иде* | *Ул язарлык булган* |
| *11. Аның язасы бар иде* | *Аның язасы булган* |
| *12. Аның язганы бар иде* | *Аның язганы булган* |
| *13. Аның язасы юк иде* | *Аның язганы булмаган* |
| *14. Аның язганы юк* | *Аның язганы булмаган* |
| *15. Ул язарга тиеш иде* | *Ул язарга тиеш булган* |
| *16. Аңа язарга кирәк иде* | *Аңа язарга кирәк булган* |
| *17. Аңа язарга ярый иде* | *Аңа язарга ярый булган* |
| *18. Аңа язарга мөмкин иде* | *Аңа язарга мөмкин булган* |
| *19. Ят кеше бар иде* | *Ят кеше булган* |
| *20. Өйдә ят кеше юк иде* | *Өйдә ят кеше булмаган* |
| *21. Ул язарга итә иде* | *Ул язарга итә булган* |
| *22. Ул язгандай итә иде* | *Ул язгандай итә булган* |
| *23. Ул аны яза торган итә иде* | *Ул аны яза торган итә булган* |
| *24. Ул язарлык була иде* | *Ул язарлык була булган* |
| *25. Ул язмакчы була иде* | *Ул язмакчы була булган* |
| *26. Ул беренче була иде* | *Ул беренче була булган* |
| *27. Ул беренче була торган иде* | *Ул беренче була торган булган* |
| *28. Ул врач булачак иде* | *Ул врач булачак булган* |
| *29. Ул врач буласы иде* | *Ул врач буласы булган* |
| *30. Ул өченче булмакчы иде* | *Ул өченче булмакчы булган* һ.б. |

2. Хәзерге һәм киләчәк заманнарда күзәтелмәгәнлек мәгънәсен *икән* ярдәмче фигыле белдерә. Ул шул ук *иде* фигыленнең тамырына -*ган* кушымчасы ялганып ясала: *и-де – и-кән*. Күзәтелмәгәнлек мәгънәсен белдерүче уникаль чара буларак, *икән* сүзе үткән замандагы күзәтелмәгәнлек формасына да өстәлеп килә ала һәм күзәтелмәгәнлек мәгънәсен тагын да көчәйтә: *Ул язган икән; Ул язмакчы булган икән; Ул язарлык булган икән.*

Хәзерге һәм киләчәк заманнарда *икән* күзәтелмәгәнлек белдерүче бердәнбер чара булып кулланыла. Хәзер бу формаларның парадигмасын күзәтик.

| Хәзерге һәм киләчәк заманда күзәтелгәнлек формалары: | Хәзерге һәм киләчәк заманда күзәтелмәгәнлек формалары: |
|---|---|
| *1. Ул яза* | *Ул яза икән* |
| *2. Ул инженер* | *Ул инженер икән* |
| *3. Ул минеке* | *Ул минеке икән* |
| *4. Иртәгә мин язасы* | *Иртәгә мин язасы икән* |
| *5. Ул язмакчы* | *Ул язмакчы икән* |
| *Ул язмакчы булачак* | *Ул язмакчы булачак икән* |
| *6. Ул язарлык* | *Ул язарлык икән* |
| *Ул язарлык булачак* | *Ул язарлык булачак икән* |
| *7. Аның язасы бар* | *Аның язасы бар икән* |
| *Аның язасы булачак* | *Аның язасы булачак икән* |
| *8. Аның язганы бар* | *Аның язганы бар икән* |
| *Аның язганы булачак* | *Аның язганы булачак икән* |
| *9. Аның язасы юк* | *Аның язасы юк икән* |
| *Аның язасы булмаячак* | *Аның язасы булмаячак икән* |
| *10. Аңа язарга мөмкин* | *Аңа язарга мөмкин икән* |
| *Аңа язарга мөмкин булачак* | *Аңа язарга мөмкин булачак икән* |
| *11. Өйдә кеше бар* | *Өйдә кеше бар икән* |
| *Өйдә кеше булачак* | *Өйдә кеше булачак икән* |

## Синтаксик ирреаль наклонение формалары һәм парадигмалары

**§ 236. Җөмлә модельләренең шартлы теләк, шарт, боерык, теләк наклонениесе формалары**. Бу төр наклонениеләр төрки морфологиясендә дә наклонение дип танылганнар, шуңа күрә аларны аерым карарга туры килә.

1. Шартлы теләк формасы дип, *-ар иде* үзе генә танылган, ләкин ул я шарт фигыль белән килә, яисә контекстта ниндидер шартның булуы аңлашыла.

Хәбәре фигыль белән бирелгән җөмләләрдә *-ар иде* формасы шул фигыль составында килә: *Ул язар иде* (берәр шарт үтәлсә); *Ул яза алыр иде; Бу сиңа ярар иде* һ.б.

Әгәр хәбәр *-ар иде* формасын алырлык хәлдә булмаса, хәбәргә *бул* ярдәмче фигыле өстәлә, һәм *-ар иде* формасын ул ала: *Ул язган булыр иде; Ул язарлык булыр иде; Ул язарга тиеш булыр иде; Аңа язарга кирәк булыр иде; (Укыса) ул инженер булыр иде; Аңа язасы булыр иде; (Кул төзәлсә,) язып булыр иде.*

Җөмләнең *Ия–Хәб. бар/юк* моделендә шартлы теләк белдергәндә, *бар/юк* сүзләре *бул* фигыле белән алмашына, һәм ул барлык/юклыкта килә: *Акча бар – Акча булыр иде; Акча юк – Акча булмас иде; Язганым бар – язганым булыр иде; Язганым юк – Язганым булмас иде; Язасым бар – Язасым булыр иде; Язасым юк – Язасым булмас иде.*

Җөмләнең кайбер модельләре: (7) *Ия–Хәб. -магае*, (10) *Ия–Хәб. -са кирәк*, (12) *Ия–Хәб. -а булыр*, (13) *Ия–Хәб. -ар булыр*, (36) *Ия–Хәб. -уы бар* шартлы теләк наклонениесе формасында кулланылмыйлар.

**Искәрмә**. Хәзерге әдәби телдә *-ар иде* (юклыкта *-мас иде*) шартлы теләк белдерүгә яраклашкан. Иске телдә ул тәмамланмаган үткән заман мәгънәсен дә белдерә, хәзер дә ул шул мәгънәдә кулланылгалый, ләкин норма буларак түгел, ә искечә сөйләү үрнәге буларак: *Ул укыр иде дә, язып куяр иде* (Г. Бәширов).

2. Шарт формасы, башка наклонение формаларыннан аермалы буларак, җөмләне тәмамлап куя алмый, һәрчак буйсынулы җөмлә барлыкка китерә.

Шарт мәгънәсен *-са, -ды исә* формалары белдерә, стилистик яктан *-деме, -а икән, -ганда* формалары да шарт мәгънәсендә кулланыла ала: *Ул язса, мин кайтырмын; Мин күрендем исә, ул ашарга сорый* (К. Тинчурин); *Сине күрдемме, әнием исемә төшә; Әгәр сорыйлар*

*икән, каршы килмәбез* (Г. Бәширов); *Яхшырак уйлаганда, бу мәсьәләне чишеп булыр иде.*

Шарт наклонениесе семантикасы – үтәлү-үтәлмәве башка бер эш-хәлнең булу-булмавы өчен шарт булып килгән процесс турында хәбәр итү. -*да* кисәкчәсе белән килгәндә, -*са*, кайчакта -*ганда* формалары кире шартны белдерәләр, ягъни алар билгеле бер шартның булуын хәбәр итәләр, ләкин тудырылган шарт нәтиҗә бирми, аның киресе эшләнә: *Ул язса да кайтмам; Күргәндә дә әйтми.*

Шарт формаларының үзләрендә заман белдерү күзәтелми, ләкин шарт формасындагы фигыльне буйсындырып килгән төп хикәя фигыльдә заман белдерү саклана.

Хәбәр затланышлы фигыльләр белән бирелгәндә, шарт формасын шул фигыльләр ала: *Укысам белермен; Укысаң белерсең* һ.б. Хәбәр затланышсыз фигыльләр я фигыльдән башка сүз төркемнәре белән бирелсә, шарт мәгънәсендә кулланылу өчен, ул *бул* ярдәмче фигылен ала: *Ул киләсе булса, мин әзерләнеп торырмын; Ул язарлык булса, язар иде; Ул инженер булса, болай ялгышмас иде.*

*Бар/юк* сүзе белән килгән грамматик модель шарт мәгънәсендә кулланылсын өчен, анда *бар/юк* сүзләре *булса/булмаса* сүзләре белән алмаштырыла: *Өйдә кеше бар – Өйдә кеше булса; Өйдә кеше юк – Өйдә кеше булмаса; Аның язганы бар – Аның язганы булса; Аның язганы юк – Аның язганы булмаса.*

3. Боерык формасындагы җөмләнең хәбәре боерык фигыль белән бирелә һәм ул боеруны, таләп итүне, үтенүне, теләкне, ризалыкны белдерә.

Боерык формасы заманга битараф, ләкин контексттан заман чамалана. Мәсәлән, киләчәк заман: *Күрсәң, әйтмә*; хәзерге заман: *Тукта!;* үткән заман: *Алырлар син.*

Җөмлә модельләрендә боерык формасын хәбәрнең боерык фигыль белән бирелүе тәшкил итә. Тел аңында боерык фигыльнең өч затта да килүе калыпка салынган: *яз, язсын, язый̆м, языгыз, язсыннар, язый̆к.* Тюркологиядә, кеше үз-үзенә боера алмый дигән сылтау белән, I затны аерып алалар да, аны теләк наклонениесе дип игълан итәләр. Ләкин бу боеру наклонениесенең зат-сан парадигмасын бозудан башка нәрсә түгел. Татарчада теләк белдерүнең үз формалары бар. Боерык формасы I затта да боерык булып саналырга тиеш.

Хәбәр фигыль белән бирелмәгәндә, җөмлә боерык формасын *бул* фигыле ярдәмендә ала: *Ул язучы булсын; Мин язучы булыйм; Син язучы бул* һ.б.

Боеруда бик күптөрле мәгънә төсмерләре бар, аларны белдереп, төрле кереш сүзләр, кисәкчәләр кулланыла: *-чы/-че, -сана/-сәнә, зинһар, -а күр* (*-а күрегез/күрим/күрик/күрсен/күрсеннәр*). Мисаллар: *Килче, күрешик; Язсана; Балам, аңа тия күрмә; Зинһар, якын килмәгез* (М. Гафури).

Катгый боеруны белдерү өчен *-асы бул/-асы булма* формасы беркетелгән: *Ул картларга кирәсе булма* (К. Тинчурин).

Инфинитив формасы да катгый боеруны белдерә ала: *Берсен дә качырмаска! Кача калса, штыкка алырга* (Г. Бәширов).

Боерык формасындагы җөмлә буйсынган хәлдә килгәндә кире шартны белдерә: *Кая гына бармасын, һәр җирдә шатлык* (К. Тинчурин).

4. Хәбәре теләк формасында бирелсә, җөмлә сөйләүченең төрле дәрәҗәдәге теләген белдерә. Теләк формасындагы җөмләдә заман парадигмасы булмаса да, ул үз мәгънәсе белән киләчәккә юнәлтелгән була.

Теләк белдергән җөмләнең хәбәре *-са иде, -са икән; -сын иде, -рга иде, -кыры/-кере* формаларын ала: *Ул язса иде; Ул язса икән; Ул язсын иде; Миңа аны күрергә иде*.

Игътибар итәргә кирәк: *иде* фигыле нигездә күзәтелгән үткән заман формаларын ясауда катнашса, аның теләк белдерү очраклары да бар икән. Алар дүртәү: 1) *-ар иде* шартлы теләкне белдерә: *Ул язар иде*. Башка телләр тәэсирендә бу шартлы теләкне без аерым наклонение (сослагательное наклонение) дип йөртәбез; 2) *-са иде* теләк наклонениесенең төп формасы дип санала: *Их, аны бер күрсәң иде!* (М. Гафури). Бу очракта *иде* сүзе *икән* сүзе белән җиңел алмаштырыла ала; 3) *иде* сүзе III зат боерык фигыль янында килгәндә дә теләк белдерә: *Язсын иде; Алар килсеннәр иде; Болыт килә йөзеп, Уртасына кырын ятып кына ак идең* (С.Гәрәева); 4) *иде* сүзе инфинитив янында заман белдерүдә катнаша: *Мин барырга идем; Миңа барырга иде*. Ләкин бу форманы алган җөмлә аерым очракларда, бигрәк тә тойгылы итеп әйтелгәндә, көчле теләкне дә белдерә: *Их барырга иде, күрергә иде үзен!* (И. Гази).

Хәбәре фигыльдән башка сүзләр белән бирелгән җөмләләрдә теләк формаларын *бул* ярдәмче фигыле ала: *Ул инженер булса иде; Ул язарлык булсын иде; Аңа, иң элек, кеше булырга иде* (Г. Ибраһимов).

Сөйләүченең генә түгел, агенсның (үтәүченең) теләген белдерергә кирәк булганда, җөмләнең хәбәре *-асы килә*, *-рдай бул* формасын алган фигыльләр белән дә бирелә: *Аның язасы килә; Аның язасы килде; Ул язардай булды; Бик килердәй булырсың, без булмабыз* (К. Тинчурин).

Татарчада көчле теләкнең тагын бер махсус формасы бар: *-кыры/-кере/-гыры/-гере*: *Тамагыңа таш кергере* (К. Тинчурин); *Шайтан алгыры! Каһәр суккыры; Алланың каһәре төшкере; Рәхмәт төшкере!* Бу форманы да теләк наклонениесе формасы итеп санарга кирәк.

**§ 237. Җөмлә модельләренең үзенчәлекле наклонение формалары һәм барлык төр наклонениеләр парадигмасы**. Югарыда бер телгә алган идек инде, төрки телләр морфологиясе һинд-европа телләре грамматикаларына ияреп язылган. Шуңа күрә күп кенә морфологик категорияләр һинд-европа телләре категорияләренә охшатырга тырышылган. Наклонениеләрдә дә шул ук хәл күзәтелә. Һинд-европа телләрендәге шартлы теләк (сослагательное), шарт, боерык һәм теләк наклонениеләренә туры килгәннәре генә төрки телләрдә дә чын наклонение төрләре дип танылган. Төрки телләр өчен үзенчәлекле булган наклонениеләр (модаль мәгънәне фигыль формасында белдерүләр) морфологиядә башлыча читләтеп үтелә. Синтаксиста җөмлә формаларын өйрәнгәндә, без аларны читтә калдыра алмыйбыз. Шуңа күрә төрки телләрдәге үзенчәлекле наклонение формалары белән таныштыру өчен, аерым параграф ачарга кирәк таптык.

Үзенчәлекле наклонение формаларының морфологиядә наклонение парадигмасына кертелмәвен истә тотып, үзенчәлекле модаль мәгънә белдерә торган формаларны без җөмләнең мөстәкыйль модельләре дип аерып күрсәттек. Җөмләләрнең үзенчәлекле наклонение формаларын санаганда, без ул модельләрне дә күрсәтеп барачакбыз.

Җөмлә модельләренең үзенчәлекле наклонение формаларына без түбәндәге модельләрне һәм формаларны кертәбез.

1. Тиешлелек наклонениесе: (2) *Ия–Хәб -асы*: *Ул язасы*; (45) *(Үт. -га) БК -асы: Аңа иртәгә эшкә чыгасы;* (35) *БК -асы бар/юк: Язасым бар; Язасым юк*.

Үткән заман формасы *-ачак иде, -ачак булган* шулай ук тиешлелек мәгънәсендә кулланыла: *Ул язачак иде; Ул язачак булган.*

Тиешлелекне белдерүче төп форманы без 8 нче модель итеп билгеләдек: (8) *Ия–Хәб.-рга тиеш: Ул язарга тиеш; Мин укырга тиешмен; Алар килергә тиеш.*

Хәбәре фигыльдән башка сүзләр белән бирелгәндә, тиешлелек формаларын алу өчен, *бул* ярдәмче фигыле килә: *Ул инженер булырга тиеш; Ул бишенче буласы иде* һ.б.

2. Шөбһәләнү наклонениесе мәгънәсен түбәндәге модельләр белдерә: (7) *Ия–Хәб.–магае: Ул язмагае;* (3) *Ия–Хәб. -а торгандыр: Ул яза торгандыр;* (10) *Ия–Хәб. -са кирәк: Ул язса кирәк;* бу модельнең *бул* ярдәмче фигыле белән кулланылган очрагы нормалашкан: *Ул яза булса кирәк;* (36) *БК -уы бар: Аның язуы бар*.

Исем хәбәрле җөмләләрдә шөбһәләнү мәгънәсе *бул* фигыле ярдәмендә формалаша: *Ул инженер булмагае; Аның инженер булуы бар; Ул инженер булса кирәк*.

3. Ниятләү модаль мәгънәсен түбәндәге модельләр белдерә: (5) *Ия–Хәб. -макчы: Ул язмакчы;* (19) *Ия–Хәб. -рга булды: Ул язарга булды;* (23) *Ия–Хәб. -рга ит (-рга тора): Ул язарга итә/язарга тора;* (22) *Ия–Хәб. -асы итә: Ул язасы итте.* Соңгы модель карар кылу мәгънәсен бирә.

Әйтергә кирәк, бу модельләрдә сөйләүче чынбарлыкка мөнәсәбәтен (ягъни модаль мәгънәне) субъект һәм үтәүче мөнәсәбәте аркылы белдерә. Биредә ниятләүче зат сөйләүче түгел, ә үтәүче (агенс).

Исем хәбәрле җөмләләрдә, ниятләү формаларын алу өчен, *бул* сүзе килә: *Ул инженер булмакчы*.

4. Мөмкинлек модаль мәгънәсенең дә үз формалары бар. Алар да хәзергә җөмләнең мөстәкыйль модельләре дип танылдылар: (4) *Ия–Хәб. -арлык: Ул язарлык;* (11) *Ия–Хәб. -а ал: Ул яза ала;* (40) *БК -ып була: Моны язып була;* (43) *(Үт. юк) БК -рлык (-малы түгел/-а торган түгел): Монда язарлык; Моны язарлык түгел; Биредә яза торган түгел.*

Исем хәбәрле җөмләләрдә, мөмкинлек формаларын алу өчен, *бул* сүзе килә: *Ул инженер булырлык; Ул инженер була ала; Монда инженер булырлык түгел; Монда беренче була торган түгел.*

5. Ризалык модаль мәгънәсе түбәндәге модельләр белән бирелә: (39) *БК -рга ярый/мөмкин/була: Сиңа язарга ярый/мөмкин/була;*

(9) *Ия–Хәб. -рга мөмкин: Сиңа язарга мөмкин;* 39 нчы модель варианты: *БК -мак ярый: Сөймәк ярый* (Г. Тукай).

Исем хәбәрле җөмләләрдә ризалык формасын *бул* сүзе ала: *Сиңа инженер булырга ярый.*

6. Үкенү модаль мәгънәсен белдерүче формалар: Мәсәлән, *БК -асы булган/калган/-рга булган: Язасым калган; Сиңа язасы булган; Сиңа язарга булган.*

Исем хәбәрле җөмләләрдә бу формаларны *бул* сүзе ала: *Инженер буласың калган; Инженер буласың булган.*

7. Контекст та ярдәмгә килгәндә, *-гән бул* формасын алган җөмлә ирония, кылану мәгънәсен белдерә ала: *Фәйрүзәсе көлгән булды, битен каплаган булды* (М. Җәлил); *Ул юри генә яраткан була иде* (К. Тинчурин).

Тиешле интонация белән әйтелгәндә, *-әр икән, -мак кирәк* формасын алган җөмлә гаҗәпләнү модаль мәгънәсен белдерә: *Ул да шулай матур итеп сөйләр икән!; Анда ничек бармак кирәк!*

Шулай итеп татар телендә җөмләләрнең модаль (наклонение) формалары шактый күп. Морфологиядә наклонение итеп танылмаган формаларны без мөстәкыйль модельләр рәтеннән карадык. Шул модельләрне дә наклонение формалары рәтеннән күрсәтсәк, аларның түбәндәге парадигмасын төзеп булыр иде.

| **Модаль мәгънәләр, ягъни наклонение исемнәре:** | **Мисаллар:** |
|---|---|
| 1. Хикәяләү | *Ул яза. Ул – инженер. Төн.* |
| 2. Шартлы теләк | *Ул язар иде. Ул инженер булыр иде.* |
| 3. Шарт | *Ул язса... Ул язды исә...* |
| | *Ул язса да... Ул яза икән...* |
| | *Ул инженер булса...* |
| 4. Боерык | *Син яз. Алар язсыннар. Без язйык.* |
| | *Сез яза күрегез. Сезгә язарга.* |
| 5. Теләк | *Ул язса иде/икән. Ул язсын иде.* |
| | *Аны күрергә иде. Ул инженер булса иде. Аның язасы килә. Бик килердәй булырсың. Рәхмәт төшкере!* |

| | |
|---|---|
| 6. Тиешлек | *Ул язасы. Аңа эшкә чыгасы. Язасым бар. Язарга тиеш. Ул инженер буласы иде.* |
| 7. Шөбһәләнү | *Ул язмагае. Ул яза торгандыр. Ул язса кирәк. Ул яза булса кирәк. Ул инженер булса кирәк. Ул инженер булмагае. Аның язуы бар.* |
| 8. Ниятләү | *Ул язмакчы. Ул язарга булды. Ул язарга итә. Ул язарга тора. Ул язасы итте. Ул инженер булмакчы. Ул инженер булырга итә.* |
| 9. Мөмкинлек | *Ул язарлык. Ул яза ала. Аны язып була. Монда язарлык. Монда яза торган түгел. Ул инженер була ала.* |
| 10. Ризалык | *Сиңа язарга ярый/мөмкин/була. Син язарга мөмкин. Сиңа язарга мөмкин. Сөймәк ярый. Сиңа инженер булырга ярый.* |
| 11. Үкенү | *Язасым калган. Язасы булган. Язарга булган. Инженер буласы калган.* |
| 12. Кылану, ирония | *Язган була.* |
| 13. Гаҗәпләнү | *Ул да шулай матур язар икән! Аны ничек укымак кирәк.* |

## ГАДИ ҖӨМЛӘ МОДЕЛЬЛӘРЕНЕҢ СТИЛИСТИК ФОРМАЛАРЫ

**§ 238. Гомуми мәгълүмат.** Югарыда әйтелгәнчә, җөмләнең татар теленә хас модельләре (калыплары) сөйләмдә төрле үзгәрешләр кичерәләр, ягъни сүзләр кебек үк төрләнәләр. Грамматик категорияләр буенча төрләнгәннәре грамматик формалар барлыкка китерәләр, һәм бу формалар грамматик категория буенча парадигмаларга берләшәләр.

Грамматик категорияләргә түгел, ә лексик берәмлекләрнең һәм контекстның үзенчәлекле кулланылышына нигезләнгән үзгәрешләрне җөмлә модельләренең стилистик үзгәрешләре дип атыйлар,

икенче төрле аларны стилистик формалар дип тә йөртәләр. Рус теле синтаксисында бу төр үзгәрешләрне «гади җөмләнең регуляр реальләшүе» (регулярные реализации простых предложений) дип атыйлар. Русча язылган академик синтаксиста без дә шул русча атаманы кулландык, чөнки русча укучыларга бер уртак атама булырга тиеш. Татарчада «гади җөмләнең регуляр реальләшүе» дигән атаманы кулланмаска булдык, чөнки җөмләләрнең стилистик кенә түгел, грамматик үзгәрешләре дә шул ук регуляр-даими реальләшүгә керә.

Җөмлә модельләре (калыплары) һәм аларның сөйләмдә төрләнеш-үзгәрешләре татар телендә хәзергә аерым алып өйрәнелмәгән. Алар турында беренче мәгълүматны без русча әзерләнгән татар синтаксисында бирдек.

Шуның белән бергә әйтергә кирәк, бу стилистик формалар традицион синтаксисның төрле темаларында да азмы-күпме өйрәнелгәннәр. Бу китапта да алар төрле темаларда яктыртылдылар.

Менә шуларны истә тоткан хәлдә, без биредә җөмлә модельләренең стилистик формаларын җентекләп түгел, ә кыскача гына гомуми мәгълүмат рәвешендә бирергә булдык.

Русча язылган академик синтаксиста бу формаларны без биш төркемгә туплап биргән идек: 1) гади җөмлә модельләренең модаль мәгънә белдерүче ярым мөстәкыйль фигыльләр ярдәмендә стилистик үзгәрешләре; 2) гади җөмлә модельләренең модаль мәгънә белдерүче модаль сүзләр һәм кисәкчәләр ярдәмендә стилистик үзгәрешләре; 3) гади җөмлә модельләренең дәрәҗә белдерүче ярым мөстәкыйль фигыльләр ярдәмендә стилистик үзгәрешләре; 4) гади җөмлә модельләренең параллель һәм эзлекле процессларны белдерүче ярым мөстәкыйль фигыльләр ярдәмендә стилистик үзгәрешләре; 5) гади җөмлә модельләренең сүзләрне төшереп калдырып ким кулланылуы нигезендә барлыкка килгән стилистик формалары.

Биредә бу төр стилистик формаларны өч төркемгә туплап бирергә булдык.

**§ 239. Гади җөмлә модельләренең модаль мәгънә белдерүче лексик чаралар ярдәмендә стилистик төрләнешләре**. Бу төр мәгънәләрне ярым мөстәкыйль фигыльләр, модаль сүзләр һәм кисәкчәләр белдерәләр, димәк, җөмләләрнең стилистик формаларын барлыкка китерәләр.

Сөйләүченең, үтәүченең һәм субъектның ниятләвен белдерә торган стилистик форма *ниятлә, уйла, тор, җыен, әйт* дигән ярым мөстәкыйль лексик чаралар ярдәмендә ясала: *Ул язарга ниятли; Ул язарга уйлый; Кәләпүшеңне алып китәргә тора* (И. Гази); *Ә язмыш аңа каршы барырга итә* (Г. Ибраһимов); *Ул бу эшендә калмаска җыена* һ.б.

Шөбһәләнү модаль мәгънәсен бирергә кирәк булганда, җөмләнең хәбәре *булса кирәк*, *булырга кирәк, бугай (бул+гай)* кебек ярым мөстәкыйль лексик берәмлекләр кулланыла: *Ул арада боларны кайсыдыр күреп алды булса кирәк* (Г. Бәширов); *Ул Казанда укый булырга кирәк; Ул аның кылычын алып киткән бугай.*

Мөмкинлек модаль мәгънәсен белдерергә кирәк булганда, җөмлә хәбәре *ал, бел* кебек ярым мөстәкыйль фигыльне ала, үзе *-а/-и* формасында килә: *Сәлимә бер нәрсә дә әйтә алмады* (М. Гафури); *Таҗи хәзер күп кенә эшләр эшли белә* (Г. Гобәй).

Сынап карау модаль мәгънәсен белдергәндә дә җөмлә үзенчәлекле стилистик формага керә: аның хәбәре составында *кара* фигыле килә, хәбәр үзе *-ып/-п* кушымчасын ала: *Ул иреннәрен кыймылдатып карады* (А. Шамов); *Артларыннан бер эскадрон кавалерия җибәреп карадык, тота алмадылар* (Г. Гобәй).

Ихтыярсызлык модаль мәгънәсен белдереп, җөмләдә ярым мөстәкыйль *яз, насыйп бул, туры кил* сүзләре килә: *Аңа кайтып күрергә насыйп булмаган* (Г. Гобәй); *Аңа монда эшләргә язмаган икән* (И. Гази); *Таҗига шуннан гына күзәтергә туры килде* (Г. Гобәй).

Җөмләдә битараф модальлек белдереп, ия һәм хәбәр бәйләнешен көчәйтүче ярым мөстәкыйль фигыльләр шулай ук стилистик форма тәшкил итәләр. Алар – *булып тора, булып санала, булып хисаплана, булып исәпләнә, булып күренә, булып тоела* фигыльләре: *Ул безнең чорның төп өйрәтмәсе булып тора; Килен бик уңган булып чыкты* (М. Әмир); *Хәйри безнең иң якын дустыбыз булып санала* (М. Максуд); *Ул миңа аеруча матур булып тоелды; Мин аларның бригадирлары булып исәпләнәм* (И. Гази).

Татар синтаксисында бу стилистик формаларның төрле модельләрдә кулланылыш үзенчәлекләре хәзергә әле өйрәнелмәгән.

Җөмлә модельләренең кисәкчәләр, модаль сүзләр, бәйләгеч сүзләр ярдәмендә ясалган стилистик формалары да еш очрый.

Ия–хәбәр бәйләнешен көчәйтеп, *дигән сүз, димәк* сүзләре килә, һәм хәбәр янында иянең кабатлануы да шушы ук функцияне үти: *Безнең урам – зур урам; Ул (кыз) – бик матур кыз; Ул укытучы ул; Мин киңәшче мин; Укырга, димәк, фикерне баетырга; Печән чабу, иптәшкәем, – ул мускулларны ныгыту дигән сүз.*

Ихтыяр белдерүче *әле, -чы/-че, -сана/-сәнә* кисәкчәләре боеру модаль мәгънәсенә үзенчәлекле төсмер бирәләр, җөмләләрнең стилистик формаларын төзиләр: *Кил әле, син дә бераз бармакларыңны селкет, и яшь егет! Килче, икәү уйныйк бераз кети-кети* (Г. Тукай); *Китерсәнә миңа бер йотым су!* (К. Нәҗми); *Кил әле, күбәләк, сөйләшик бергәләп* (Г. Тукай).

Тойгы белдерүче *бит, ич, лабаса/ләбаса, ла/лә, генә әле* кисәкчәләре дә җөмләләргә стилистик мәгънә өстиләр, стилистик форманы тәшкил итәләр: *Көннәр үтә ләбаса, ник бер утырып киңәшмәскә* (Г. Кутуй). *Бармыйм ла, чуртым да булмас* (К. Тинчурин); *Әйттем бит мин сиңа* һ.б.

Ихтималлык модаль мәгънәсен белдереп, *кебек, сыман, шикелле, төсле* бәйлекләре дә кулланыла. Бу очракта алар үзләренең бәйлек функцияләрен югалталар һәм җөмләнең хәбәре составында модаль мәгънә генә белдерәләр, кисәкчәләр кебек стилистик форма төзиләр: *Ул инженер кебек; Ул язган төсле иде; Ул язмакчы кебек; Ул язган шикелле; Ул карады сыман.* Бу функцияне *-дай* кушымчасы да башкара: *Ул карагандай итте.*

**§ 240. Гади җөмлә модельләренең дәрәҗәне, параллельлек һәм эзлеклелекне белдерүче ярым мөстәкыйль фигыльләр ярдәмендә стилистик төрләнешләре**. Бу төр фигыльләрнең хәбәр булып килүләрен без кушма фигыль хәбәрләр бүлегендә җентекләп өйрәнгән идек (95–97, 99 § ларны карагыз). Биредә җөмлә модельләренең стилистик формаларын тәртипле итеп күз алдына китерү өчен, шуларны гомумиләштереп искә төшерик.

1. Татар телендә процессның үтәлү дәрәҗәсен күрсәтеп сөйләшү гадәткә кергән, ләкин ул грамматик системага әйләнмәгән, шуңа күрә аның парадигмасын да күрсәтеп булмый. Кайбер мөстәкыйль фигыльләр, ярым мөстәкыйль позициядә *-ып/-п, -а/-и* яки *-рга* формасындагы башка фигыльләр янында килеп, процессның а) башланып китү; ә) башлану һәм тәмамлану арасында үтәлү; б) тәмамлану

дәрәҗәсен белдерәләр. Ярым мөстәкыйль фигыльләр теләсә нинди фигыльгә ияреп килә алмый, димәк, грамматик категория төзи алмый, шуңа күрә аларның кулланылышын стилистик күренеш буларак кына тикшерәләр.

Исем хәбәрләр янында бу ярым мөстәкыйль фигыльләр турыдан-туры түгел, ә *бул* фигыле аркылы кулланылалар.

Процессның башлану дәрәҗәсен белдерергә кирәк булганда, җөмлә хәбәрендәге төрле фигыль формалары янында түбәндәге ярым мөстәкыйль фигыльләр кулланыла:

а) *-а/-и* формасы янында *яз* һәм *башла* фигыльләре: *Ул егыла язды; Ул инженер була язды; Хәлим йөгерә башлады;* ә) *-ып/-п* формасы янында *җибәр, алып кит, алып биреп кит* фигыльләре: *Егет җырлап җибәрә; Әсма яшьлеге турында сөйләп алып китте* (Ә. Фәйзи); б) *-рга* формасы янында *маташ, тотын, кереш* фигыльләре: *Ул язарга маташа; Ул язарга тотынды/кереште* һ.б.

Процессның башлану һәм тәмамлану арасында үтәлү дәрәҗәсен белдерергә кирәк булганда, җөмлә хәбәрендә түбәндәге ярым мөстәкыйль фигыльләр кулланыла: а) *-ып/-п* формасы янында *ят, тор, бар, кил, маташ* фигыльләре: *Урамда митинг ясалып ята иде* (М. Гафури); *Әминә апа язганда, Мортаза бабай яктыртып торды* (Г. Гобәй); *Текстны рәттән тәрҗемә итеп барды* (Г. Хуҗи); *Ул язып маташа иде;* ә) *-а/-и* формасы янында *тор, утыр, бир, бар, кил, төш* фигыльләре: *Син килгәнче, мин яза тордым; Ул чыга алмый утырды* (Ә. Фәйзи); *Исе китмичә укый бирә* (М. Гафури); *Аның яралары әкренләп төзәлә барды* (А. Шамов); *Яшелчәләр өлгереп килә; Ул тагын да кыза төште* (И. Гази).

Процессның тәмамлану дәрәҗәсен белдерергә кирәк булганда, хәбәрдәге *-ып/-п* формасы янында *кит, ал, төш, ат, сал, кал, ташла, бир, җит, бет, бетер, чык, чыгар* ярым мөстәкыйль фигыльләр кулланыла: *Яшен ялтырап китте; Бу хәбәрдән Фатыйма каушап төште* (Ә. Фәйзи); *Ул астан гына карап куйды; Ул аны кичә үк әйтеп салды; Ул аны ачуланып ташлады; Ул бөтенләй арып беткән; Ул укып чыкты; Ул баш тирәли кулын йөртеп чыгарды* (И. Гази).

2. Татарчада бер процесс турында хәбәр иткәндә, аның белән параллель яки эзлекле үтәлергә тиешле процессны да әйтү гадәте бар. Моны хәбәрдә параллельлек/эзлеклелек белдерү күренеше диләр.

Бу да, грамматик категория кебек, бер система яки парадигма тәшкил итми, шуңа күрә стилистик күренешләр рәтенә керә.

Дәрәҗә белдергәндә, ярым мөстәкыйль фигыльләр, тулы формалы булып, тезмәне тәмамлап куялар, төп мәгънәне беренче фигыль белдерә. Эзлекле һәм параллель процесслар белдергәндә, гадәттә, беренче фигыль ярым мөстәкыйль мәгънәдә була, икенчесе төп мәгънәне белдерә: *Ат караучылар каравыл өенә килеп керделәр* (Ш. Камал). Бу мисалда *килү* һәм *керү* процесслары эзлекле үтәлә. *Хәлим үлчәүгә менеп басты* (И. Гази) мисалында *менү* һәм *басу* процесслары эзлекле үтәлә. *Таҗи Галияне куып китте* (Г. Гобәй) мисалында *куу* һәм *китү* процесслары эзлекле үтәлә. Менә шундый процессларны бер кушма фигыльдә бирү гади җөмлә модельләренең үзенчәлекле стилистик формаларын барлыкка китерә.

**§ 241. Гади җөмлә модельләренең тулылык/кимлеккә нигезләнгән стилистик төрләнеше**. Гади җөмлә модельләренең стилистик вариантларын төзүдә кимлек күренеше дә шактый зур роль уйный. Бу күренеш, традиция буенча, ким җөмлә дигән аерым тема астында тикшерелә (254–259 § ларны карагыз). Биредә җөмлә модельләренең кимлек күренешенә нигезләнгән стилистик формаларын гомумиләштереп күрсәтү күздә тотыла.

Контексттан аңлашылып тора торган сүзләр-кисәкләр гадәттә әйтелмиләр, шуның хисабына җөмлә ким була. Ким җөмләгә тулы җөмлә каршы куела. Җөмләнең тулы формалары хикәяләү башланганда, абзац башларында гына кулланыла. Тексттагы башка җөмләләр гадәттә ким формалы булалар. Ким җөмлә-сөйләмнең нормаль күренеше, мәгънә ягыннан ул ким булмый, тексттагы төрле чаралар ярдәмендә тулылана.

Ким формалы җөмләне мәгънә ягыннан контекст тулыландыра: *Галиулла лампасын уңайлап элеп куйды да, су челтерәмиме дип, бераз тыңлап торды. Юк, су тавышы ишетелми. Шуннан соң эшли дә башлады* (И. Гази).

– *Авылга кайтасы килмиме?*

– *Бик килә.*

– *Җибәр әле.*

– *Ярый. Мин риза* (Г. Хуҗи).

Бу мисаллардагы ким формаларның тулы парлары: *Шуннан соң Галиулла эшли дә башлады; Авылга кайтасым бик килә; Син мине*

*авылга җибәр әле. Мин сине авылга җибәрергә риза*. Бу тулы формалар сөйләмдә нормаль күренеш булып саналмыйлар.

Җөмләләрнең ким формалары барлыкка килүгә сәбәпче булып, контекст кына түгел, зат кушымчалары да килә: *Эшлибез* – тулы формасы: *Без эшлибез. Барасың юк – Синең барасың юк; Инженермын – Мин инженермын – Мин инженер.*

Шул җөмләнең үзеннән үк аңлашылып торганда, хәбәр кулланылмаска мөмкин. Бу да ким форма барлыкка китерә: *Бу йөзек алтыннан* – тулы формасы: *Бу йөзек алтыннан ясалган*; *Бу хат әтигә – Бу хат әтигә язылган; Мин сиңа теге мәсьәлә турында идем – Мин сиңа теге мәсьәлә турында килгән идем.*

Билгеле бер обстановкада еш кулланылып, кайбер җөмләләр фразеологик әйтелмә булып ныгып калалар: *Хәерле иртә* – тулы формасы: *Сезне хәерле иртә белән тәбрик итәм. Бәйрәм белән! Синең исәнлеккә!*

**Искәрмә.** Рус телендә җөмлә модельләренең (схемаларының) стилистик үзгәрешенә, төрләнешенә (регуляр реальләшүенә) хәбәрнең тулы җөмлә белән бирелү очраклары да каратыла: *Характер – ой-ой-ой!; «Так делают все» – не аргумент; Работник он – каких поискать*. Татарчада да мондый стилистик төзелешләр күзәтелә, ләкин алар синтетик кушма җөмләләрдә өйрәнеләләр. Мисаллар: *Әти әйткәннәр – безгә закон иде; Иң әһәмиятлесе: бу вакыйгадан соң җыелыш булды* һ.б.

## ГАДИ ҖӨМЛӘНЕҢ СТРУКТУР-СЕМАНТИК МОДЕЛЬЛӘРЕ

**§ 242. Гомуми мәгълүмат.** Гади җөмлә модельләрен өйрәнә башлаганда ук әйтелгән иде: җөмләнең теге яки бу телгә хас модельләрен ике төрле күрсәтү гадәткә кергән: грамматик кисәкләргә (ия, хәбәр, тәмамлык, аергыч һәм хәлгә) нигезләп һәм структур-семантик бүленешкә нигезләп. Татар теле җөмләләренең грамматик кисәкләргә нигезләп билгеләнгән модельләрен – грамматик модельләр дип, структур-семантик бүленешкә нигезләп билгеләнгән модельләрен структур-семантик модельләр дип атыйлар. Димәк, теге яки бу телгә хас модельләрне грамматик синтаксистлар бер төрле терминнарда күрсәтәләр, ә структур-семантик синтаксистлар үз терминнарына салып характерлыйлар. Ләкин тегеләре дә, болары да җөмләнең бирелү формасына да, семантикасына да аеруча игътибар итәләр.

Моны мисалларда күрсәтик. *Бала мәктәптә укый* җөмләсенең моделен, грамматик кисәкләргә таянып, болай күрсәтәләр: ГМ (грамматик модель) = *Ия – Хәл. -тә – Хәб. Ф.* Биредә ия табыла да, аның формасы билгеләнә: ул баш килештәге исем белән бирелгән; семантикасы ачыклана: ия *уку* процессын башкаручы, үтәүче (агенс).

Икенче чиратта бу җөмләдән хәбәр табыла, аның формасы билгеләнә: ул категорик үткән заман хикәя фигыль белән бирелгән; семантикасы ачыклана: ул ия белдергән зат үтәгән процесс турында хәбәр итә.

Аннан соң иярчен кисәкләр шулай тикшерелә. Бу җөмләдә бер иярчен кисәк бар, ул – *мәктәптә* дигән урын хәле. Формаль ягы: ул урын-вакыт килешендәге исем белән бирелгән, семантикасы – процессның үтәлү урынын белдерү.

Грамматик модельне язгач, традицион синтаксис җөмләне шул рәвешчә анализлау белән чикләнә, сүзләрнең лексик-семантик мәгънәләренә төшми.

Моның белән риза булмаган синтаксистлар җөмлә модельләрен билгеләүдә башка юл эзләделәр һәм аларны структур-семантик яктан бик җентекләп өйрәнүгә керештеләр.

Шул ук *Бала мәктәптә укый* җөмләсенә башта **структур (формаль) анализ** ясыйлар. Ул болай эшләнә.

Беренче позициядә (урында) баш килештәге исем килгән (*бала*), *И* символы белән языла; баш килештә булгач, кушымча юк. (Русчада аны $C_1$ дип күрсәтәләр, *С* – имя существительное, аста язылган 1 саны беренче килеш, ягъни именительный падеж була.)

Анализга алынган җөмләнең икенче позициясендә урын-вакыт килешендәге исем килгән, аны *И-тә* дигән символ белән күрсәтәләр; күренә ки, кушымча үзе языла. (Русчада аны $C_6$ рәвешендә язалар, 6 саны алтынчы килеш дигән сүз була.)

Өченче позициядә үткән заман хикәя фигыль, аны *Ф-ый* символы белән язалар. (Русчада фигыль формалары күрсәтелми.)

Менә шундый структур анализдан соң, бу модельнең символлар белән язылышы барлыкка килә: *Бала мәктәптә укый = И–И -тә – Ф -ый.*

Хәзер шул ук җөмләгә **семантик анализны** күрик. Беренче позициядә семантик субъект тора, ул уйлауга, баш белән эшләүгә кирә торган эш башкара, димәк, ул уйлау субъекты, аның символы – *уйл. Суб.*

Икенче позициядә процессны ачыклаучы сүз тора, аны гомуми лингвистикада да, тюркологиядә дә **квалификатор** яисә **конкретизатор** дип йөртәләр, без аны татарча **ачыклагыч** дип алдык, символы – *Ач*; ул урынны белдерә, димәк, символы – *ур. Ач.*

Өченче позициядә предикат тора, ул уйлауга, баш белән эшләүгә бәйләнгән процессны белдерә, шуннан чыгып аның символын *уйл. Пре.* дип күрсәтәбез.

Шулай итеп, *Бала мәктәптә укый* җөмләсенең семантик моделе символларда болай күрсәтелә: *уйл. Суб.–ур. Ач–уйл. Пре.*

*Бала мәктәптә укый* җөмләсенең гомуми структур-семантик моделе (ССМ) символларда тулысынча болай языла:

$$ССМ = \frac{И}{уйл.\ Суб.} - \frac{И\text{ -}тә}{ур.\ Ач} - \frac{Ф\text{ -}ый}{уйл.\ Пре.}$$

Структур-семантик модельләрне тикшергәндә, аларны символлар белән язуга бик җитди әһәмият бирәләр. Дөресрәге, структур-семантик модельләрне билгеләү аларны символларда дөрес итеп язу белән төгәлләнергә тиеш була.

Структур-семантик юнәлешне алга сөрүче синтаксистлар җөмлә модельләрен тикшерүне гадәттә түбәндәгечә катлауландырып баралар. Бер составлы җөмләләр гадәттә беренче чиратта каралалар һәм түбәндәге тәртиптә: 1) бер составлы җыйнак җөмләләр структур-семантик яктан өйрәнелеп тәмамлангач; 2) бер иярчен кисәге булган бер составлы җөмләләр тикшерелә, аннан соң; 3) ике яки икедән артык иярчен кисәге булган бер составлы җөмләләрнең структур-семантик модельләре җентекләп анализлана.

Икенче чиратта ике составлы җөмләләр карала һәм гадәттә түбәндәге тәртиптә: 1) ике составлы җыйнак җөмләләр структур-семантик модельләр буенча тикшереләләр; 2) шуннан соң хәбәре янында бер иярчен кисәге булган ике составлы җөмләләрнең структур-семантик модельләре ачыклана; 3) иясе янында бер иярчен кисәге булган ике составлы җөмләләр өйрәнелә; 4) бер детерминанты булган ике составлы җөмләләрнең модельләре ачыклана; 5) хәбәре янында ике яки икедән артык иярчен кисәге булган ике составлы җөмләләрнең структур-семантик модельләре языла; 6) иясе янында ике яки икедән

артык иярчен кисәге булган (ИЯ) ике составлы җөмләләр структур-семантик яктан анализлана; 7) хәбәре янында да, иясе янында да бер, ике яки икедән артык иярчен кисәкләре булган ике составлы җөмләләр тикшерелә.

Күренә ки, структур-семантик синтаксис әһелләре шушы юл белән барып теге яки бу сөйләмнең тулы бер картинасын язарга уйлыйлар. Ләкин бу күләмле һәм авыр эшнең бер генә телдә дә тулысынча үтәлгәне юк әле. Әгәр дә без биредә шушы тәртиптә төрле җөмләләрнең структур-семантик модельләрен тасвирларга уйласак, синтаксисның барлык традицион темаларыннан баш тартып, бөтен бер синтаксисны яңача язып чыгарга тиеш булыр идек. Без бу академик синтаксиста татар сөйләм төзелешен традицион-грамматик юл белән өйрәнсәк тә, яңа юнәлешләрне – бу очракта структур-семантик юнәлешне дә кыскача гына яктырту бурычын үтәргә булдык.

Без структур-семантик модельләр билгеләүне ике составлы җөмләләрдән башларга булдык, чөнки алар сөйләмдә күбрәк кулланылалар.

**§ 243. Ике составлы җыйнак җөмләнең структур-семантик модельләре**. Грамматик модельләрне тикшергәндә күрдек, ике составлы җыйнак җөмләнең 32 грамматик моделе (ГМ) саналды, 2 нченең – ике, 4 нченең бер вариантын да санасак, барлыгы 35 була. Грамматик модель бер төрле генә язылса, структур-семантик модель (ССМ) күптөрле язылуны сорый. Мәсәлән, *Бала йөгерә; Ул йөгерә* җөмләләрен генә алыйк. Алар – бер үк грамматик модельләр һәм бер төрле генә язылалар:

*ГМ=ИЯ–Хәб.Ф -ә.*

Шул ук ике җөмләнең структур-семантик моделе ике төрле языла.

*Бала йөгерә:*

$$ССМ = \frac{И}{Суб.йөр.} - \frac{Ф\ -ә}{Пре.йөр}$$

*Ул йөгерә:*

$$ССМ = \frac{зА}{Суб.йөр.} - \frac{Ф\ -ә}{Пре.йөр}$$

Шушы ук модельнең хәбәре башка лексик мәгънәле фигыльләр белән бирелсә, ул очракта да структур-семантик модель символлары үзгәрә, грамматик модель һаман бер төрле булып кала.

*Бала яза: ГМ=ИЯ–Хәб.Ф-а;*

$$\text{ССМ} = \frac{\text{И}}{\text{хәр.Суб.}} - \frac{\text{Ф -а}}{\text{хәр.Пре.}}$$

*Бала ишетә: ГМ=ИЯ–Хәб.Ф -а;*

$$\text{ССМ} = \frac{\text{И}}{\text{тою.Суб.}} - \frac{\text{Ф -ә}}{\text{тою.Пре.}}$$

*Бала сөйли: ГМ=ИЯ–Хәб.Ф -и;*

$$\text{ССМ} = \frac{\text{И}}{\text{аңл.Суб.}} - \frac{\text{Ф -и}}{\text{аңл.Пре.}} \text{ һ.б.}$$

Менә шушы күренешне исәпкә алганда, бер үк грамматик модель структур-семантик яктан күп вариантлы була. Аларның барысын да һәрбер модельдә күрсәтеп бару мөмкин түгел. Шуңа күрә биредә һәрбер грамматик модельнең бары берәр вариантын күрсәтү белән чикләнәбез.

Аңлату өчен югарыда китерелгән җөмләләр 1 нче модельгә карыйлар.

2. *Ул язасы: ГМ=ИЯ–Хәб.Ф.-асы;*

$$\text{ССМ} = \frac{\text{зА}}{\text{хәр.Суб.}} - \frac{\text{Ф -асы}}{\text{хәр.Пре.}}$$

2а. *Ул язган: ГМ=ИЯ–Хәб.Ф -ган;*

$$\text{ССМ} = \frac{\text{зА}}{\text{хәр.Суб.}} - \frac{\text{Ф -ган}}{\text{хәр.Пре.}}$$

2ә. *Ул барачак: ГМ=ИЯ–Хәб.Ф -ачак;*

$$\text{ССМ} = \frac{\text{зА}}{\text{йөр.Суб.}} - \frac{\text{Ф -ачак}}{\text{йөр.Пре.}}$$

3. *Ул яза торгандыр: ГМ=ИЯ–Хәб.Ф -а+торгандыр;*

$$ССМ = \frac{зА}{хәр.Суб.} - \frac{Ф\ \text{-а+торгандыр}}{хәр.Пре.}$$

4. *Ул язарлык: ГМ=ИЯ–Хәб.Ф -арлык;*

$$ССМ = \frac{зА}{хәр.Суб.} - \frac{Ф\ \text{-арлык}}{хәр.Пре.}$$

5. *Ул язмакчы: ГМ=ИЯ–Хәб.Ф -макчы;*

$$ССМ = \frac{зА}{хәр.Суб.} - \frac{Ф\ \text{-макчы}}{хәр.Пре.}$$

6. *Теләге язу (язарга): ГМ=ИЯ–Хәб.Ф -у (-рга);*

$$ССМ = \frac{И\text{-е}}{хәр.Суб.} - \frac{Ф\ \text{-у (-рга)}}{хәр.Пре.}$$

7. *Ул язмагае: ГМ=ИЯ–Хәб.Ф -магае;*

$$ССМ = \frac{зА}{хәр.Суб.} - \frac{Ф\ \text{-магае}}{хәр.Пре.}$$

Менә шул рәвешле ике составлы җыйнак җөмләләрнең барлык модельләре дә символлар белән язылалар.

**§ 244. Ике составлы җәенке җөмләнең структур-семантик модельләре.** Бу теманың керешендә әйтелгәнчә, җәенке җөмлә модельләрен язганда, барлык төр иярчен һәм модаль кисәкләр дә табыла, анализлана һәм анализ нәтиҗәсе схемаларда күрсәтелә. Әгәр дә бу эш тәртипле итеп эшләнсә, мондый анализ иярчен кисәкләрне генә түгел, сүзтезмәләрне өйрәнүне дә алмаштыра ала. Ләкин без биредә татар синтаксисын бу юнәлештә яңадан язу эшенә керешмибез, үрнәкләр күрсәтү белән чикләнәбез.

1. Ике составлы җөмләнең иясе янында бер иярчен кисәк килә, ул, гадәттә, аергыч була.

*Арыган бала йоклый: ГМ=А.Ф -ган–ИЯ–Хәб.Ф -ый;*

$$ССМ = \frac{\textit{СФ -ган}}{\textit{хәл.Аер.}} - \frac{\textit{И}}{\textit{хәл.Суб.}} - \frac{\textit{Ф -ый}}{\textit{хәл.Пре.}}$$

2. Ике составлы җөмләнең хәбәре янында бер иярчен кисәк килә һәм ул тәмамлык та, хәл дә, хәбәр исем белән бирелгәндә, хәтта аергыч та булырга мөмкин. Структур-семантик синтаксис белән шөгыльләнүчеләр аныклагычны гадәттә бөтенләй күрсәтмиләр.

Бу төр җәенке җөмләләрдә хәбәргә буйсынган иярчен кисәкләр бик күптөрле булалар. Структур-семантик модельләрдә аларны күрсәтеп бетерү дә бик авыр. Без биредә аларның берничә үрнәген генә тәкъдим итәбез.

*Бала китап укый: ГМ=ИЯ–Тәм.(-ны)–Хәб.Ф.-ый;*

$$ССМ = \frac{\textit{И}}{\textit{уйл.Суб.}} - \frac{\textit{И -ны}}{\textit{уйл.Об}} - \frac{\textit{Ф -ый}}{\textit{уйл.Пре.}}$$

*Бала мәктәпкә бара: ГМ=ИЯ–Хәл -кә–Хәб.Ф -а;*

$$ССМ = \frac{\textit{И}}{\textit{йөр.Суб.}} - \frac{\textit{И -кә}}{\textit{Ач.урын}} - \frac{\textit{Ф -ый}}{\textit{йөр.Пре.}}$$

*Фәрит – яхшы укучы: ГМ=ИЯ–Аер–Хәб. исем;*

$$ССМ = \frac{\textit{И}}{\textit{Суб.}} - \frac{\textit{С}}{\textit{Ат.}} - \frac{\textit{И}}{\textit{Пре.}}$$

3. Ике составлы җөмләнең хәбәренә дә, иясенә дә буйсынган берәр кисәк килә. Структур-семантик синтаксиста мондый җөмләләр гадәттә дүрт урынлы дип тикшерелә. Грамматик модельләр дә, структур-семантик модельләр дә җөмләдәге сүзләр тәртибе буенча языла.

*Тәртипле бала китап укый: ГМ=А–ИЯ–Тәм.(-ны)–Хәб.-ый;*

$$ССМ = \frac{\textit{С}}{\textit{Ат.}} - \frac{\textit{И}}{\textit{уйл.Суб}} - \frac{\textit{И(-ны)}}{\textit{уйл.Об.}} - \frac{\textit{Ф-ый}}{\textit{уйл.Пре.}}$$

4. Җөмләләрнең җәенкеләнүе, иягә яки хәбәргә берничәшәр иярчен кисәк ияру юлы белән генә түгел, иярчен кисәкләргә иярчен кисәкләр буйсынып килү нәтиҗәсендә дә еш күзәтелә. Ләкин структур-семантик синтаксиста мондый җөмләләрне анализлауның һәм аларның модельләрен символларда күрсәтүнең төгәл методикасы эшләнмәгән. Җөмләдә сүзләр нинди тәртиптә килсә, модель символларын язганда да шул ук тәртип саклана. Бу – сүзләр тәртибен күрсәтү өчен уңай булса да, кайсы сүзнең кайсы сүзгә буйсынуын ачыклау өчен шактый уңайсыз.

*Тәртипле һәм эшчән бала мәктәпкә кичекмичә килә:*
*ГМ=Аер.–Аер.–ИЯ–Хәл -кә–Хәл -мичә–Хәб.Ф -ә;*

$$\text{ССМ} = \frac{\text{С}}{\text{Ат.}} - \frac{\text{С}}{\text{Ат.}} - \frac{\text{И}}{\text{йөр.Суб.}} - \frac{\text{И-кә}}{\text{урын.Ач.}} - \frac{\text{Ф -мичә}}{\text{рәвешАч.}} - \frac{\text{Ф -ә}}{\text{йөр.Пре.}}$$

*Тәртипле балаерактагы мәктәпкә дә кичекмичә килә:*
*ГМ=Аер.–ИЯ–Аер.–Хәл -кә–Хәл -мичә–Хәб.Ф -гә;*

$$\text{ССМ} = \frac{\text{С}}{\text{Ат.}} - \frac{\text{И}}{\text{йөр.Суб.}} - \frac{\text{С -тагы}}{\text{Ат.}} - \frac{\text{И -кә}}{\text{урын. Ач.}} - \frac{\text{Ф -мичә}}{\text{рәвешАч.}} - \frac{\text{Ф -ә}}{\text{йөр.Пре.}}$$

Структур-семантик анализ ясаганда, һәрбер җөмләнең конкрет мәгънәсе-семантикасы билгеләнә. Бу очракта җөмлә яртылаш кабатланып әйтелә. Мәсәлән, *Тәртипле балаерактагы мәктәпкә дә кичекмичә килә* җөмләсенең семантикасы болайрак билгеләнә: биредә билгеле бер үзенчәлеккә ия булган затның билгеле бер үзенчәлекле урынга билгеле бер рәвешчә килүе хәбәр ителә.

**§ 245. Бер составлы җыйнак җөмләләрнең структур-семантик модельләре.** Җөмләләрнең иярчен кисәкләр ярдәмендә җәенкеләнүе ике составлы җөмләләрдә дә, бер составлы җөмләләрдә дә бер үк төрле була. Шуңа күрә без биредә структур-семантик яктан бары җыйнак бер составлы җөмләләрне генә тикшереп карыячакбыз.

Бер составлы җыйнак җөмләләрнең 18 моделе һәм схемалары күрсәтелә (33 нчедән башлап 50 гә кадәр). Алардан соңгысы (50 нчесе) сүз җөмләләрне тәшкил итә. Структур-семантик синтаксис аларны аерым алып тикшерми, аларның модельләрен символлар белән дә күр-

сәтми. Шуңа күрә без биредә бер составлы җыйнак җөмләләрнең бары 17 моделен генә символлар белән язып күрсәтәчәкбез.

33 нче модель. *Күгәрченнәргә кадәр үбешәләр: ГМ=(Үт.-га кадәр)БК;*

$$\textit{ССМ} = \frac{\textit{И -га кадәр}}{\textit{көтелмәгәнСуб.}} - \frac{\textit{Ф –ш -ә}}{\textit{хәр.Пре.}}$$

34 нче модель. *Барганым бар: ГМ=БК -ган бар/юк;*

$$\textit{ССМ} = \frac{\textit{Ф -ган бар/юк}}{\textit{(I зат Үт.) хәр.Пре.}}$$

35 нче модель. *Әйтәсең бар: ГМ=БК -асы бар/юк;*

$$\textit{ССМ} = \frac{\textit{Ф -асы бар/юк}}{\textit{(II зат Үт.) сөйл.Пре.}}$$

36 нчы модель. *Килүе бар: ГМ=БК -уы бар;*

$$\textit{ССМ} = \frac{\textit{Ф -уы бар}}{\textit{(III зат Үт.) йөр.Пре.}}$$

37 нче модель. *Барасым килә: ГМ=БК -асы кил;*

$$\textit{ССМ} = \frac{\textit{Ф -асы кил}}{\textit{(I зат Үт.) йөр.Пре.}}$$

38 нче модель. *Барырга кирәк: ГМ=БК -рга кирәк;*

$$\textit{ССМ} = \frac{\textit{Ф -рга кирәк}}{\textit{(Үт. контекстта) йөр.Пре.}}$$

39 нчы модель. *Килергә ярый (мөмкин, була):*

*ГМ=БК -рга ярый (мөмкин була);*

$$\textit{ССМ} = \frac{\textit{Ф -рга ярый (мөмкин, була)}}{\textit{(Үт. контекстта) йөр.Пре.}}$$

40 нчы модель. *Сөйләп була (-мичә ярамый/булмый):*

*ГМ=БК -әп була (-мичә ярамый/булмый);*

$$ССМ = \frac{\text{Ф -әп була (-мичә ярамый/булмый)}}{\text{(Үт. контекстта) сөйл.Пре.}}$$

41 нче модель. *Йокланган: ГМ=(агенс юк)БК төш.юн.Ф.;*

$$ССМ = \frac{\text{Ф төш.юн.}}{\text{(Үт. юк) хәл.Пре.}}$$

42 нче модель. *Шалтыраталар:*

*ГМ=(Агенс юк) БК III зат күплек (II зат берлек);*

$$ССМ = \frac{\text{Ф зат күплек}}{\text{(Үт. юк) хәр.Пре.}}$$

43 нче модель. *Барырлык түгел:*

*ГМ=(Үт. юк)БК -рлык түгел (-малы түгел);*

$$ССМ = \frac{\text{Ф -рлык түгел (-малы түгел)}}{\text{(Үт. юк) йөр.Пре.}}$$

44 нче модель. *Яктыра:*
*ГМ=(Үт. юк)БК табигать күренеше яисә психологик Ф;*

$$ССМ = \frac{\text{Ф табигать күренеше, психологик хәл}}{\text{(Үт. юк) таб.күр.Пре.}}$$

45 нче модель. *Миңа барасы:*

*ГМ=(Үт. -га) БК -асы;*

$$ССМ = \frac{\text{Ф -асы}}{\text{(Үт. -га) йөр.Пре.}}$$

46 модель. *Сиңа барырга:*

*ГМ=(Үт. -га)БК -рга;*

$$ССМ = \frac{\textit{Ф -рга}}{\textit{(Үт. -га) йөр.Пре.}}$$

47 нче модель. *Барыш иде/-у иде:*
*ГМ=(Үт. -нең) БК -ыш иде/-у иде;*

$$ССМ = \frac{\textit{Ф -ыш иде/-у иде}}{\textit{(Үт. -нең) йөр.Пре.}}$$

48 нче модель. *Кыш*:
*ГМ=БК.И;*

$$ССМ = \frac{\textit{И}}{\textit{булу Суб. (булу Пре.)}}$$

49 нчы модель. *Караңгы. Салкын:*
*ГМ=БК.С.;*

$$ССМ = \frac{\textit{С}}{\textit{булу Суб. (булу Пре.)}}$$

Инглиз һәм рус телләрендә җөмләләр структур-семантик модельләргә таркатылып, җентекле рәвештә өйрәнелгәннәр. Татар телендә бу эш башкарылмаган әле. Без биредә структур-семантик модельләр турында кыскача гына мәгълүмат бирергә тырыштык.

## ГАДИ ҖӨМЛӘ ТӨРЛӘРЕ

**§ 246. Гомуми мәгълүмат.** Гади җөмләнең калыпларын беренче синтаксис китапларында ук билгеләргә тырышканнар. Шул юнәлештә эшләгәндә, синтаксистлар җөмләнең күп кенә төрләре булуга игътибар иткәннәр. Гади һәм кушма, җыйнак һәм җәенке, бер составлы һәм ике

составлы, раслау һәм инкяр, хикәя, сорау, боеру һәм өндәү, ким һәм тулы дигән җөмлә төрләрен билгеләгәннәр, аларның үзенчәлекләрен шактый җентекләп өйрәнгәннәр.

Менә шул традициядән аерылып китмәс өчен, без бу калыпларны төрле темаларда тикшереп карадык, биредә аларның кайберләренә махсус тукталачакбыз. Модельләрдән аерылып торсын өчен, аларны традиция буенча җөмлә төрләре дип атадык.

Биредә җөмлә төрләренә кыскача характеристика бирергә булдык, кайсы төр кайда өйрәнелә, бу темада кайсылары карала, бу мәсьәләне дә читтә калдырып булмый.

Логика фәнендә танылган хөкемләүнең (суждениенең) ике төп төреннән чыгып, җөмләләрне раслау һәм инкяр дигән төрләргә бүлгәннәр. Боларны без шушы бүлектә җентеклерәк тикшерәчәкбез.

Җөмләнең иң кыска калыбын алып, аны җыйнак җөмлә дип атаганнар, иярчен кисәкләр дә өстәлгәнен җәенке җөмлә дигәннәр. Җыйнак җөмләләрнең грамматик калыпларын (модельләрен) аерым алып өйрәнү гадәткә кергән. Җәенке дигән калыплар иярчен һәм модаль кисәкләрне тикшерү барышында өйрәнелделәр.

Әйтүнең, хәбәр итүнең модаль максатына карап, җөмләләрне хикәя, сорау, боеру, тойгылы дигән төрләргә бүлү гадәткә кергән. Болары турында төп мәгълүмат шушы темада биреләчәк.

Җөмләдә баш кисәкнең бер генә яки ике булуыннан чыгып, аларны бер составлы һәм ике составлы дигән төрләргә бүлү кабул ителгән. Баш кисәкләрне җентекләп тикшерү барышында ике составлы җөмләләр белән дә, бер составлы җөмләләр белән дә без шактый җентекле таныштык.

Сөйләгәндә сүзләрне тавтологик кабатлап торудан котылырга, ягъни сүзләрне сак кына кулланырга омтылу гадәте бар. Үзеннән-үзе аңлашылган сүзләрне кулланмаска тырышу барышында, сөйләмнең ким җөмлә дигән төрләре барлыкка килә. Ким җөмләләр тулы дигән төрләргә каршы куеп өйрәнеләләр.

Шулай итеп без «Гади җөмлә төрләре» дигән бу бүлекчәдә раслау һәм инкяр җөмләләрне, аларның әйтү максаты буенча төрләрен, шулай ук ким һәм тулы җөмләләрне аерым алып өйрәнәбез.

## РАСЛАУ ҺӘМ ИНКЯР ҖӨМЛӘЛӘР

**§ 247. Раслау җөмләләр.** Раслау җөмләләр нәрсәне булса да раслыйлар. Күп вакытта алар юклыкны белдерүче формаларны алмыйлар. Раслау җөмләләр хикәя дә, сорау да, боеру да булалар. Мәсәлән: *Җырым белән дусны иркәләдем, җырым белән җиңдем дошманны* (М. Җәлил). *Төрле фәннәрнең нигезләрен укыту су кебек кирәк* (К. Насыйри). *Егетнең дә кызга дәрте бар* (Г. Ибраһимов). *И сабыйлар! Эшләгез сез: иң мөкатдәс нәрсә – эш* (Г. Тукай).

Раслау җөмләнең хәбәре аерым очракларда инкяр (юклык) формаларын да кабул итә ала. Раслауга аерым басым ясаганда, хәбәр ике инкяр формасын берьюлы ала. Мәсәлән: *Ике-өч бөртек җан иясенә ризык табылмый калмас, ничек тә көн күрербез әле* (К. Нәҗми). *Рәхимовлар гаиләсе белән катышу Хәяткә беркадәр үзгәреш бирми кала алмады* (Ф. Әмирхан). *Фронттан килүчеләрнең берсе генә дә орденсыз түгел* (М. Максуд). *Без биек йортлар күрергә күнекмәгәннәрдән түгел* (М. Юныс).

Аерым басым ясап, көчле тойгы белән әйткәндә, раслау җөмләнең хәбәре инкяр формасын алып, җөмләдә сорау күрсәткечләре килә. Мәсәлән: *Ниләр генә уйлап тапмыйлар да, ниләр генә эшләмиләр!* (Ф. Яруллин). *Җылы торак һәм икмәк, ихтирам һәм азатлык, йөрәк җылысы һәм инану – ниләр генә кирәкми адәм баласына!* (М. Юныс).

**§ 248. Инкяр җөмләләр.** Инкяр җөмләләр нәрсәне булса да инкяр итәләр һәм раслау җөмләләргә капма-каршы полюста торалар. Җөмләдә инкяр итү тулы һәм өлешчә булырга мөмкин. Шуңа карап, тулы инкяр җөмләләр һәм өлешчә инкяр җөмләләр билгеләнәләр.

**Тулы инкяр җөмләләрдә** хәбәр белдергән төшенчә инкяр ителә. Мондый җөмләгә түбәндәге үзенчәлекләр хас.

1. Хәбәрне белдергән сүздә юклык кушымчасы була. Мәсәлән: *Куркаклардан батырлар тумый* (Ф. Яруллин).

*Янсаң хөрлек*
*көрәшендә,*
*я кылычта*
*калсаң сынып, –*
*офтанма бер дә!*
(Р. Фәйзуллин).

Юклык кушымчасы фигыль хәбәрләр һәм ярдәмче фигыль аша ясалган исем хәбәрләрдә кулланыла.

2. Хәбәр составында *түгел* ярдәмлек сүзе килә. Мәсәлән: *Тәртипнең нинди булуы минем өчен барыбер түгел* (М. Максуд). *Тик чуклары ак түгел* (М. Җәлил). *Мин бит алай бик шәп биючеләрдән түгел* (Ф. Яруллин).

*Түгел* сүзе исем хәбәр яки кайбер сыйфат фигыльләр белән бирелгән хәбәр составында була.

3. Хәбәр составында *юк* сүзе була яки хәбәр үзе *юк* сүзе белән бирелә. Мәсәлән: *Егет анага бер булганга, солдат куркынычы юк иде* (Г. Ибраһимов). *Дошманым юк* (Р. Фәйзуллин).

*Юк* һәм *түгел* сүзләре үзләре генә дә диалогларда инкяр җөмлә төзи алалар.

4. Хәбәр составында -*сыз/-сез* кушымчасы килә. Мәсәлән: *Моңа кадәр тормышлары мәгънәсез иде* (Р. Төхфәтуллин). *Бу әйтелгәннәр булмаганда, безнең тормышыбыз күңелсез булачактыр* (Г. Тукай).

5. Югарыда күрсәтелгән формаларны алмаган җөмләләр дә, әгәр алар көчле ирония яки ачулану тойгысы белән әйтелсәләр, инкярны белдерә алалар. Мәсәлән: *Йокларсың анда!* (Р. Вәлиев).

Сорау алмашлыклары да булса, инкяр ныграк сиземләнә. Мәсәлән: *Ни өчен барыйм соң мин анда! Нәрсә үссен монда!* (И. Гази).

Хәбәрдән башка нинди дә булса бер кисәге белдергән төшенчә инкяр ителсә, аны **өлешчә инкяр җөмлә** дип атыйлар. Тулаем алганда, болар раслауны белдерәләр һәм шул яклары белән раслау җөмләләргә дә керәләр.

Татар әдәби телендә өлешчә инкяр җөмләләр ике төрле юл белән ясалалар.

Бер очракта инкяр күрсәткечләре турыдан-туры инкяр ителә торган кисәк янында киләләр. Мәсәлән: *Ләкин егет калу белән исергән иде, аркасына төшкән йодрыкларны юньләп т о й м ы й ч а , юлына омтылды* (Г. Ибраһимов). *Садретдинов, т ы н д а а л м ы й ч а , күзәтүендә дәвам итте* (Г. Әпсәләмов). *Куркыныч һәр заман и я л ә н м ә г ә н г ә генә була* (Г. Тукай). *Ал-гөл күбәләкләр үзләренең уеннары белән т у к т а у с ы з очыналар* (Г. Тукай). *Очучы меңләгән ат көчле самолет г а й р ә т е н г е н ә т ү г е л , аның кыюлыгын да үзенә буйсындыра* (М. Юныс).

Мисаллардан күренгәнчә, хәлләр шулай ук фигыль белән бирелгән аергыч һәм тәмамлыклар инкяр күрсәткечләрен турыдан-туры ала алалар. Җөмләнең иясе, фигыльдән башка сүзләр белән бирелгән тәмамлыгы, аергычы һәм хәле исә, кагыйдә буларак, каршы куела торган тиңдәшләре булганда гына, үз яннарына инкяр күрсәткечләрен ала алалар. Мәсәлән: *Йорт-җире түгел, аның каккан казыгы да булмаган* (Ә. Еники). *Түгәрәк юл уртасыннан таш килә. Таш түгел лә, бер киселгән баш килә* (Г. Тукай). *Хәзер мәсьәләнең киңлегенә түгел, бәлки тирәнлегенә игътибар итәргә кирәк. Ул туктады, ләкин гомергә түгел* (Г. Ибраһимов).

Икенче очракта инкяр күрсәткечләрен җөмләнең хәбәре ала, инкяр ителә торган кисәк исә логик басым алу белән чикләнә, һәм ул, кагыйдә буларак, хәбәр алдыннан янәшә куела. Мәсәлән: *Ильяс атасыннан бик з у р  б а й л ы к  б е л ә н калмаган иде* (Г. Тукай). *Зиннәт алай тиз генә б и р е ш ә  т о р г а н егет түгел* (Г. Бәширов).

Бер үк җөмләдә өлешчә һәм тулы инкяр итү берьюлы булырга мөмкин: *Мин Маратны гына түгел, бәлки Фазылны да белми идем.*

**§ 249. Раслау һәм инкяр җөмләләрне үзгәртеп төзүдә антонимнарның роле.** Мәгънәне төгәл бирү һәм стиль шомалыгын булдыру өчен, раслау җөмләне инкяр җөмләгә һәм киресенчә әйләндерүдә антонимнарның ролен аерым билгеләп үтәргә кирәк. Мәсәлән: *Быел яңгыр аз яуды. Игендә өмет зур түгел* (Г. Ибраһимов) дигән мисалдагы раслау җөмләне инкярга, инкярны раслауга әйләндерергә мөмкин: *Быел яңгыр күп яумады. Игендә өмет кечкенә.*

Антонимнарны кулланып раслау һәм инкяр җөмләләрне стилистик алмаштыру әле бездә ныклап өйрәнелмәгән. Шулай да әйтергә мөмкин: бу төр үзгәрүдә хәл булып килгән антонимнар аеруча зур роль уйныйлар.

Антонимнар ярдәмендә раслау җөмләне инкяр җөмләгә һәм киресенә әйләндергәндә, төп мәгънә үзгәрешсез кала, бары мәгънә төсмере үзгәрә, һәм стиль матурлыгы өчен әһәмиятле синонимик вариант ясала.

Тел белән эш иткәндә, редакцияләгәндә, тәрҗемә иткәндә, мондый үзгәртеп төзүләр еш ясалалар. Берничә мисал: *Шәһәрдән бик озак кайтылды – Шәһәрдән бик тиз кайтылмады. Спорт бәйрәме бик күңелле үтте – Спорт бәйрәме күңелсез үтмәде. Әдәбият кичәсе бик соң бетте – Әдәбият кичәсе бик иртә бетмәде.*

## ӘЙТҮ МАКСАТЫ БУЕНЧА ҖӨМЛӘ ТӨРЛӘРЕ

**§ 250. Хикәя җөмләләр.** Хикәя җөмлә чынбарлыкта булган күренешләр, әйберләр турында хәбәр итә. Аның эчтәлеге нәрсәне булса да раслау яки инкяр итүгә (хөкемләүгә) кайтып кала. Интонацион яктан хикәя җөмлә чагыштырмача тыныч тавыш, түбәнрәк тон белән тәмамлана. Шулай да анда тавышның күтәрелүе һәм төшүе кебек күренешләр да бар. Логик басым төшә торган сүзгә кадәр тавыш башта әкренләп күтәрелә, аннан соң әкренләп түбәнәя һәм тынычлап килеп туктала. Мәсәлән:

*Без* ↗ *аның белән* ↗ *зур* ↘ *каен* ↘ *төбендә* ↘ *утырабыз* (Г. Бәширов).

Логик басым төшә торган сүз җөмлә алдына чыгарылганда, хикәя җөмләдә тавышның күтәрелеп баручы өлеше булмыйча, төшеп баручы өлеше генә булырга мөмкин.

*Иртә* ↘ *белән* ↘ *кырау* ↘ *төшә.*

Интонациянең соңгы төре сөйләмә телдә очрый. Язуда, кагыйдә буларак, логик басым төшә торган сүз хәбәр алды позициясен алганлыктан, андый җөмләләрне әйткәндә, интонациянең һәм күтәрелү, һәм төшү өлешләре була.

Хикәя җөмлә тагын ия белән хәбәр арасында уңай тәртипнең саклануы, инверсиянең булмавы белән характерлана. Анда шулай ук тойгы белдерүче кисәкчәләр дә булмый. Хикәя җөмләләр сөйләмдә

бер-берсеннән шактый озын паузалар белән аерылалар. Мисаллар: *Киң Идел өстендә, нуры белән дөньяны балкытып, якты кояш күтәрелде* (Г. Ибраһимов). *Миңа кинәт әллә ничек моңсу булып китте* (Ф. Хөсни).

Татар әдәби телендә төрле кичерешләрне һәм ихтыяр актын хикәяләү формасында хәбәр итүче хикәя җөмләләр дә бар. Аларның хәбәрләре мөмкинлек/мөмкин түгеллек, ниятләү, шарт, ихтимал һәм сынау мәгънәсен белдерүче формалар ярдәмендә ясала. Мәсәлән: *Аның бу сүзләренә каршы Сәлимә бернәрсә дә әйтә алмады* (М. Гали). *Таҗи хәзер күп кенә эшләр эшли белә* (Г. Гобәй). *Ул дәрес хәзерли булса кирәк* (Г. Бәширов). *Балаларны, хатын-кызларны куркынычсыз урынга чыгарырга булдылар* (Ш. Камал). *Ике хәзрәт, ни өчендер,извозчик ялламакчы булалар* (Г. Тукай). *Ул иреннәрен кыймылдатып карады, ләкин бернәрсә дә әйтә алмады* (А. Шамов).

**§ 251. Сорау җөмләләр.** Нинди дә булса сорауны белдергән җөмлә сорау җөмлә дип атала. Сорауны сөйләүче күбрәк тыңлаучыга һәм үз-үзенә бирә. Мәсәлән:

– *Кораллар каян аласыз?* (К. Нәҗми).

*Әллә сыерга тими торыргамы? Яңаны җыеп алганга кадәр берәрсеннән көтәргә сорап торсаң ничек булыр?* (И. Гази).

Татар әдәби телендә сорау җөмләгә түбәндәге үзенчәлекләр хас.

1. Сорау җөмләдә *-мы/-ме* сорау кушымчасы була. Мәсәлән: *Габдулла әфәнде, бу сезме?* (Ә. Фәйзи). *Гафу итегез, сез Казаннан түгелме?* (Ф. Хөсни).

*-мы/-ме* кушымчасы, *ни* сорау алмашлыгына кушылып, *-мени* формасында йөри, һәм бу очракта сорау бераз йомшара; хәтта сөйләүче тыңлаучының җавабына мохтаҗ да булмый. Мәсәлән: *Менә Гөргерине генә алыйк инде. Баш китәрлек эш эшләмәдемени?.. Үзе өченме? Юк. Менә безнең кебек мисез тараканнар өчен!* (Ә. Фәйзи). *Әлифба булгач, барыбер түгелмени?* (М. Максуд).

Сорау кушымчасы белән килгән *икән, соң, әллә* сүзләре дә сорауны бераз йомшарталар: *Сандугачлар килгән безгә, китмәсләр микән көзгә?* (М. Җәлил). *Сәлимәне очратканың юкмы, кайтмадымы икән әле?* (Ф. Хөсни). *Әллә Якуб абзыйны пароходка озатасыңмы?* (И. Гази). *Әллә* сүзе булганда, сорау кушымчасы бөтенләй төшеп тә кала ала: *Сез бу эшкә ышанмыйсыз әллә?* (Ә. Фәйзи).

Татар әдәби телендә, хәбәрдән башка кисәкнең эчтәлеге соралуга карамастан, сорау кушымчасы хәбәр составында килә. Сорала торган кисәк логик басымны ала һәм язма телдә, кагыйдә буларак, хәбәр алдыннан янәшә куела. Мәсәлән: *Анасы аптырап калды: – Су кирәкме әллә?* (И. Гази). *Соң? Соң? Әллә безнекеләр килеп җитәләр диме?* (И. Гази.) *Укучылар лагерьдан кичә кайттылармы?*

**Искәрмә.** Аерым очракларда тиңдәш булып килгән кисәкләр, җөмләнең хәбәре булмасалар да, сорау кушымчаларын алгалыйлар. Тик бу очракта алар сорауны түгел, икеләнүне белдерәләр һәм сорау җөмлә булмыйлар. Мәсәлән: *Вакыты җиттеме, әллә болай хәлсезлектәнме, дүрт көн инде Мәликә апа бөтенләй аяктан калды* (К. Нәҗми). *Аркасы буйлап сумы, тирме ага* (И. Гази). *Болар бик күп түгел иде, – барлыгы утызмы, кырыкмы егет* (Г. Ибраһимов).

2. Сорау җөмләдә сорауны белдерә торган аерым сүзләр – сорау алмашлыклары, сорау рәвешләре киләләр. Алар җөмләнең теләсә нинди кисәге була алалар. Мәсәлән: *Кем язган аны шулай йөрәккә үткәреп* (К. Нәҗми). *Исемең ничек әле синең?* (К. Нәҗми). *Кайда күрешкән идек соң әле без?* (З. Нури). *Ни өчен аны күреп бетермәгәнбез, ә?* (А. Шамов).

3. Сорау җөмләгә һәрвакыт сорау интонациясе хас. Сорау интонациясе җөмләдә сорау кушымчалары, сорау сүзләре булганда да бик ачык сиземләнә. Ә сорау кушымчалары һәм сорау сүзләре булмаганда, сорау интонациясе сорау җөмләне формалаштыручы бердәнбер чара булып кала. Мәсәлән: *Белмисең? Өеңдә ни булганын күршеңнән сора, диләр бит* (Т. Гыйззәт).

*– Рөхсәт бирәләр дисез? – дип сорады, хәбәргә артык исе китми генә, Чердынцев* (Ә. Фәйзи). *Бәлки, бу вакыт эчендә без бераз үсеп киткәнбездер?* (Т. Гыйззәт).

Иярченле кушма җөмләдә сорау җөмлә формасында әйтелә торган баш җөмлә, гадәттә, үзеннән-үзе аңлашыла торган өлеш буларак төшереп калдырыла. Бу вакытта сорау иярчен шарт җөмләгә ябышып кала һәм ул бары сорау интонациясе белән генә белдерелә: *Әгәр безнең мөмкинлегебез булмаса?* (И. Гази). Төшеп калган баш җөмлә: *нәрсә эшләргә кушасыз? Әгәр җитмәгән орлыкны үзебездән җыеп салсак?* (Г. Бәширов). Соңгысында әйтелмәгән баш җөмлә: *Нәрсә әйтер идегез?*

Сорау интонациясе нәрсә белән үзенчәлекле соң? Сорау җөмләдә турыдан-туры сорала торган сүзгә логик басым төшә, һәм, бигрәк тә

аерым күрсәткечләре булмаганда, шул ук сүз сорау тоны белән, ягъни аның басым төшә торган иҗеге тагын да югарырак тонда сузыбрак әйтелә. Шул логик басым төшә торган сүзнең кайсы урында торуына карап, сорау җөмләдә төрле интонация булырга мөмкин:

кәнме?
кип-
су
1. Болында

*2. Кояш*
*шулай*
*уңдырганмы?*

*нигә*
*мине* *эзләттегез?*
3. *Сез*

Сорау җөмлә ике төрле була: чын сорау җөмлә, риторик сорау җөмлә.

Чын сорау җөмләләр турыдан-туры җавап таләп итәләр. Ул сорауга җавап бирелмәсә, сөйләмне дәвам итеп булмый. Мәсәлән: *Чын ихластан хезмәт итәргә сүз бирә аласыңмы?* (Г. Ибраһимов). *Бу сүзне кем әйтте сиңа?* (Һ. Такташ).

Риторик сорау җөмләләр җавап таләп итмиләр, тик үзләренең формалары белән генә сорау җөмләләргә кертеләләр. Сөйләүче риторик сорау белән нәрсәнедер раслый да, җавап көтеп тормыйча, сөйләмен дәвам итә. Мәсәлән: – *Сез барып җитә алдыгызмы?* – *Җитмәгән кая! Тик менә кеше дигәннең гомере ник болай кыска була икән? Әйләнеп карарга да өлгермисең, картлык җилкәңә менеп тә атлана* (И. Гази).

*Дөньяда күңелеңә ошамаган эш белән шөгыльләнүдән дә авыр җәза бармы икән?* (М. Юныс).

**§ 252. Боеру җөмләләр.** Боеру җөмлә сөйләүченең боеруын, үтенүен, чакыруын, киңәшен белдерә.

Татар әдәби телендә боеру җөмләгә түбәндәге үзенчәлекләр хас:

1. Боеру җөмләнең үзенә генә хас интонациясе була. Ул ачык итеп, сузмыйча, боеру тавышы белән югарырак тонда әйтелә. Башка төр җөмләләрдәге кебек үк, логик басым төшә торган сүз тагын да югарырак тон ала.

2. Боеру җөмләнең хәбәре боеруны белдерә торган формаларны ала, ягъни хәбәр түбәндәгечә бирелә:

а) II зат боерык фигыльнең берлеге һәм күплеге белән. Мәсәлән: *Артыкбикә йөзен алмыйча гына җавап бирде*:

*– Коткаруыгыз өчен рәхмәт, тик, зинһар, хәзергә мине калдырыгыз* (М. Әмир). *Тап! Тапмасаң, өстеңнән кәгазь бирәм* (Г. Ибраһимов). *Безнең чәйне эчсәң, утыр, түрдән уз* (К. Тинчурин).

ә) I зат боерык фигыльнең берлеге белән. Мәсәлән: *Тукта әле, мин уйлыйм әле, апа, – дидем мин* (Ф. Әмирхан).

Мондый җөмләләр киңәш сорауны, үтенүне, бераз теләкне белдерә торган булалар.

б) I нче зат боерык фигыльнең күплеге белән. Мәсәлән: *Мин дә көч, ярдәм бирермен, әйдә, иптәш, кузгалыйк. Шул агачны бергә-бергә ышбу арбага салыйк* (Г. Тукай).

*Күзне ачып якты күргән саен,*
*Кеше булыйк әле – куаныйк!* (Р. Харис).

в) III зат боерык фигыльләр белән. Мәсәлән: *Берсенә Җиһанша бабай барсын: ул бик туры карт, – диешеп, төрле яктан кычкырыштылар* (Г. Ибраһимов).

*Китсен бездән чыгып кәҗә белән сарык:*
*Ашап ята бушка гына алар азык* (Г. Тукай).

*Инде яшьләр хәзер яратсыннар,*
*Инде яшьләр хәзер сөйсеннәр* (Һ. Такташ).

г) Инфинитив белән. Мәсәлән: *Нык карагыз! Берсен дә качырмаска. Тегенди-мондый хәл булса, штыкка алырга. Но, үлмәсен дә* (Г. Бәширов).

Мондый җөмләләр катгый боеруны белдерәләр.

Инфинитив + *кирәк* һәм *иде* сүзләре белән килгәндә, җөмлә читләтебрәк боеруны яки үтенеч катыш боеруны, теләкне белдерә. Мәсәлән: *Сиңа шәһәрдән авылга күчәргә кирәк, юкса сәламәтлегең яхшы ук түгел* (Г. Хуҗи). *Дилбегәне үз кулыңа алырга иде* (И. Гази).

д) Үткән заман хикәя фигыльнең күплеге белән. Мәсәлән: *Киттек, иптәшләр, җыелышка. Тавыш бетте. Тавышны бетердек. Дәресне башладык.*

е) -*а*/-*ә* формасындагы фигыль янында *күр* (*күрегез*) ярдәмче фигыле килеп. Мәсәлән: *Төкле аягың белән генә килә күр* (Ә. Фәйзи). *Безне ташлама, вакыт булганда килә күр* (Г. Ибраһимов).

ж) Хәбәр киләчәк заман хикәя фигыльнең III зат күплеге (мәсәлән, *килерләр*) белән бирелә. Мондый хәбәрле җөмлә үтәлгән эшнең нәтиҗәсеннән чыгып киңәш бирүне аңлата. Мәсәлән: *Барысын бергә җыеп төрерләр син аның. Иртәрәк килерләр син. Шундый зурны күтәрмәсләр аны.*

3. Боеру җөмләдә *әйдә* (*әйдәгез, әйдәле*), *әле* кебек күрсәткечләр була. Алар боеруның төрле төсмерләрен бирәләр. Мәсәлән: *С а м а т . Әйдәгез, иптәшләр, түрдән узыгыз, чәйдән рәхим итегез* (К. Тинчурин). *Әйдәле, Акбай, өйрән син, арт аягың берлә тор* (Г. Тукай). *Әйдә югары, батыр очучы* (С. Баттал). *Бүген кич килеп чыгыгыз әле, чәй эчәрбез, дөнья хәлләрен сөйләшербез* (М. Максуд).

**§ 253. Тойгылы җөмләләр**. Көчле тойгы белән әйтелә торган җөмләне тойгылы җөмлә дип атыйлар[1]. Тойгы белдерүне ике төргә бүлеп йөртәләр: а) сөйләүченең эчке кичерешләрен, эчке халәтен (нәфрәт, ачу, күралмау, кәеф китү, шатлык, соклану, кайгы, сагыш, үкенү, ачыну, курку, ант һ.б.); ә) сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен (ышану, ышанмау, шикләнү, мыскыллап көлү, ирония, гаҗәпләнү, ризасызлык, хуплау, канәгать булу-булмау, кимсетү, карар итү, кызгану, иркәләү һ.б.) белдерү.

Тойгылы җөмләләр иң югары тонда ачык итеп әйтеләләр. Аларда тавыш бик кискен хәрәкәт итә: кинәт күтәрелү һәм кинәт төшүләр еш

[1] Тойгылы җөмләне өндәү җөмлә дип тә исемлиләр. Ләкин бу уңышлы термин түгел, чөнки өндәү сүзе күбрәк боеру мәгънәсен белдерә. Шул яктан караганда, өндәү билгесе дигән термин да уңышсыз. Ул билгене тойгы билгесе дип атау яхшырак булыр иде.

ясалалар. Биредә тойгы интонациясе – тойгыны белдерүче иң әһәмиятле чара. Мондый интонация белән әйткәндә, теләсә нинди хикәя, сорау һәм боеру җөмлә тойгылы җөмләгә әйләнә.

Тойгылы җөмләләрне, форма һәм эчтәлекләренә карап, дүрт төргә бүлеп йөртәләр: **тойгылы хикәя, тойгылы сорау, тойгылы боеру** һәм **бары тойгы гына белдерүче** җөмләләр.

**Тойгылы хикәя җөмлә** формасы белән генә хикәя җөмләгә охшый, ләкин нинди дә булса күренешне зур тойгы белән хәбәр итә. Мәсәлән: *Әгәр кем дә булса, сез кем, дип сораса: «Без сталинградчылар!» – дип горур җавап кайтарабыз* (Г. Кутуй). *Ах, таныш йортлар, тәмам күздән дә сез югалдыгыз!* (Г. Тукай).

**Тойгылы сорау җөмлә** формасы белән сорау җөмләгә охшый, ләкин төрле тойгыларны, кичерешләрне белдерү өчен кулланыла. Мәсәлән: *Кайгымыни бу!?* (И. Гази). *Их, бәгърем, Гайниям! Ничек онытыйм!? Сине онытырга мөмкинмени!?* (Г. Ибраһимов) *Әнә! Әнә!? Нигә сез аларны ишетмисез!? Нигә аларга таба сукмак сузмыйсыз!?* (К. Тинчурин).

**Тойгылы боеру җөмлә** формасы белән боеру җөмләгә охшый, ләкин боеру төрле тойгыларга, эчке кичерешләргә бай була. Мәсәлән: *Күп телеңә салышып торма, карт дурман! Әй, кадалып китсеннәр лә ул әшәке җаннар!* (Ә. Фәйзи). *Тукталмаска! Фараларны кабызып алга! – ди генерал* (Г. Кутуй).

*Ла, зинһар, -санә, -чы*(*-че*) кебек күрсәткечләр килгәндә, боеру җөмлә гадәттә тойгылы боеруга әйләнә. Мәсәлән: *Самовар куеп җибәрегез, зинһар!* (М. Әмир). *Әфәнделәр, мине дә серегезгә катыштырсагыз ла!* (Ф. Әмирхан). *Тыңлагызчы! Күрегезсанә! Әй-й, ямьсез уйларга бирелмикче!* (М. Хуҗин).

**Җөмләнең бары тойгы белдерү** өчен йөри торган формалары да бар. Аларда хәбәр *-сы/-се + иде, -са/-сә + иде, -са/-сә + -чы/-че* формалары белән килә. Мәсәлән: *Бөдрә талга килеп кунсаңчы!* (Ш. Мөдәррис). *Дөньяда зур кеше буласы иде!* (Г. Ибраһимов). *Их, туйганчы бер йокласаң иде!* (Г. Ибраһимов). *Сорашам гына ич, шунда да ачуланмасаң инде!* (Ф. Кәрим). *Их, Нәфисә, күрсәң иде син мондагы тормышны!* (Г. Бәширов).

Моннан башка көчле тойгы белән әйтелә торган сүзләр – әйберләрне, күренешләрне бәяләүче сүзләр буларак – хикәя, сорау, боеру

җөмләләргә охшамый торган тойгылы җөмлә төзиләр. Мәсәлән: *Татарча җыр!.. Егет өне катып тынып калды* (Ә. Еники). *Әюпов тирән көрсенеп куйды: – Курай! – диде ул. – Әйе, ниләр генә сөйләми ул курай!* (М. Әмир). *Харап, иптәшләр, харап!* (К. Тинчурин). *Ир бала! Ир бала!* (Ф. Әмир). *Тфү, мөртәт!* (Ш. Камал). *Ах сез, бунтарьлар! Шайтан балалары!* (Г. Ибраһимов). *Каһәр суккан дошман!* (М. Әмир). *Их, син, мыеклы сабый, салам торхан!* (Г. Бәширов). *Ах, җил баш, җил баш!* (Ә. Еники). *Янгын, янгын, янгын! Караул!* (К. Тинчурин). *Молодец! – диде Фәтхи. – Мәдинә бирешмәс ул!* (Ш. Камал).

Тойгылы җөмләдә, тойгыны көчәйтеп, еш кына түбәндәге чараларның берсе кулланыла:

а) Сорау алмашлыклары, рәвешләр, сорау кушымчалары. Мәсәлән: *Ух, нинди аяз, нинди тыныч, нинди гаҗәеп рәхәт!* (Ф. Әмирхан). *Туган җир, туган басулар... Никадәр якын, никадәр таныш аңа монда барнәрсә!* (И. Гази). *Ләкин үз күләгәңә үзең сокланып тора торган заманмы!?* (Ф. Хөсни). *Минем күзләрем, минем күңелем ялгышамы соң!* (Ф. Әмирхан).

ә) Ымлыклар. Мәсәлән: *Һай, гомер, гомер! Нинди канатлар үсте сиңа!* (Ә. Еники). *Их, Миңсылу апа! Юкка гына бармадың!* (Ш. Камал). *Аһ, беләм бит мин соңыннан ни буласын!* (Ә. Еники). *Абау, күтәрерлек тә түгел!* (И. Гази).

б) Җөмләдә *кара син аны, тукта, менә сиңа мә, кит аннан, ходаем, мур кыргыры, аллага шөкер, алла сакласын, валлаһи, җир йотсын* һәм башка шуның кебек тезмәләр һәм сүзләр килергә мөмкин. Мәсәлән: *Габсаттар абзый, бу хәлне күреп, канәгатьсезлек белән:*

*– Менә сиңа мә! Курорт!.. – дип мыгырданды. Гайшә: – Кара син аны! Төзек кенә торган икән ләбаса! – дип уйлады* (Г. Ибраһимов). *Сөйләүче: – Җир йотсын менә! Ялганламыйм! – диде дә тегеләргә кушылып үзе дә көлә башлады* (Ф. Әмирхан). *Рәхәт тә соң, валлаһи, бу машина белән ашлык сугулар!* (Г. Ибраһимов). *Кара син аны, биләмче! Көн буе сөрән сугып йөрүең җитмәгән!* (Г. Бәширов). *Хөснулла белән аралары ничек? – Шайтан белсен тагын!* (Ш. Камал). *Алланың каһәре суксын! Муеныгыз астыгызга килсен! Мәңге бәхиллегем юк!* (Г. Ибраһимов).

в) Кабатлаулар. Мәсәлән: *Юкса, мин, мин, үз иркем, үз саулыгым бар чагында, мондый хәлгә төшмәс идем!* (Г. Ибраһимов). *Әйе,*

*дөнья матур, чиксез матур!* (М. Әмир). *Кадерле, бик кадерле ул үткән гомер!* (Ә. Еники). *Белмим, белмим, валлаһи, бернәрсә дә белмим* (Г. Ибраһимов). *Указ... Указ... Указ!!! Беләмсең, аның өчен бу ни тора иде? Бу – аның өчен һәрнәрсә, һәрнәрсә, һәрнәрсә иде!* (Г. Ибраһимов).

г) Тойгыны көчәйтүдә инверсиянең роле бик зур була. Мәсәлән: *Рәхәт тә соң, валлаһи, бу машина белән ашлык сугулар!* (Г. Ибраһимов). *Әнә кайда икән ул!* (Г. Ибраһимов). *Роман кебек күңелле син, юл!* (Х. Туфан). *Шуннан соң башлана Мәрьям өчен авыр һәм борчулы көннәр!* (Г. Ибраһимов).

## КИМ ҖӨМЛӘЛӘР

**§ 254. Мәсьәләнең кыскача тарихы.** Ким җөмлә турында беренче мәгълүматлар XX йөзнең 10 нчы елларында язылган грамматикаларда очрый. Һ. Максуди кайбер кисәкләре әйтелмәгән җөмләләр турында сөйли һәм ким җөмләләрнең аерым очракларын мисалга китерә [Максуди, 1910]. 1911 елда («Татар нәхүе») Г. Ибраһимов ким җөмләләрне киңрәк күләмдә тикшерә [Ибраһимов, 1911]. Ул: «Җөмләнең кисәкләреннән берсе асылда бар булып та төшереп калдырылса, ул җөмләне ким җөмлә дип атыйлар», – дип яза, диалогларда очрый торган ким җөмләләрнең төрләрен күрсәтә. Җамал Вәлиди ким җөмләләрнең барлыкка килүен көчне экономияләү теориясе белән аңлата [Вәлиди, 1919].

1925 елда Г. Ибраһимов җитәкчелегендәге коллектив тарафыннан чыгарылган «Гамәли тел сабаклары» китабында ким җөмлә кыскартылма җөмлә (слитное предложение) теориясе белән аңлатыла. Ягъни авторлар ким җөмләне җөмләләрне кыскартуның бер юлы итеп карыйлар. Аларча, җөмләләрне ике төрле кыскартып була: 1) җиңел аңлашыла торган кисәкләрне төшереп калдыру юлы белән, 2) берничә җөмләне бергә оештыру юлы белән. Беренче очракта ким җөмлә барлыкка килә. Икенчесендә охшаш кисәкләре булган җөмләләр кыскартыла (*Мин язам + син язасың = Мин һәм син язабыз*) һәм тиңдәш кисәкле җөмләләр барлыкка килә.

1926 елда Г. Алпаров ким җөмләләрне шулай ук көчләрне экономияләү теориясе белән аңлата һәм ким җөмләне бары диалогларда гына таба.

1955–1956 елларда чыккан мәктәп дәреслекләрендә ким һәм тулы җөмләләрне бер һәм ике составлы җөмләләр белән бутап йөрттеләр. Моннан соң чыккан хезмәтләрдә дә ким җөмләләрнең ни өчен барлыкка килүе аңлатылмады. Тик 1958 елда гына аның кайбер үзенчәлекләре ачыклана башлады [Зәкиев, 1958]. Хәзерге чорда ким җөмләнең бары текст эчендә генә ачылып җитүе һәм текст категориясе булуы ачыкланды. Ул нәкъ шул планда өйрәнелергә тиеш тә.

**§ 255. Гомуми мәгълүмат.** Аралашу вакытында фикерне оештыруда сүзләр һәм формалар зур роль уйныйлар. Бу процесста шулай ук сөйләм оештыруның ярдәмче элементлары булган интонация дә, сүз тәртибе дә, җөмләнең синтагматик буыннарга бүленеше дә әһәмиятле. Болардан тыш сөйләм обстановкасы, контекст, мимика, жестлар һәм гадәти булмаган конструкцияләрне билгеле мәгънәдә куллануга күнегү дә мәгънә белдерүдә, димәк, сөйләм оештыруда катнаша. Менә шушы соңыннан саналган ярдәмче чаралар аралашу вакытында бер үк сүзләрне һәрбер җөмләдә кабатлап тормаска, фикерне җыйнак кына итеп әйтергә мөмкинлек бирәләр. Мәсәлән:

– *Әни, кайчан тереләсең инде син?*

– *Тиздән, улым, тиздән...* (К. Нәҗми) – дигән мисалдагы икенче җөмләдә иң кирәкле, ягъни сөйләм яңалыгын белдерә торган сүзләр генә кулланылган. *Терeләм, улым* сүзләрен әйтеп, кабатлап торуның кирәге юк, чөнки алар алдагы җөмләдә – контексттан аңлашылып торалар.

Әгәр перронда поезд көтеп торучыларның берсе «*Килә!*» дисә, нәрсәнең килүе сөйләм обстановкасыннан аңлашылып тора, шуңа күрә *поезд* сүзе әйтелми.

Магазинның кайда икәнен сораучыга сөйләүче «*Әнә!*» дип кулы белән, йөз хәрәкәте белән күрсәтә, монда мимика һәм ишарәнең ярдәме нәтиҗәсендә бик күп сүзләр кулланылмый.

Ниһаять, телдә бер үк мәгънәдә күп кулланыла торган стандартлашып киткән төзелмәләр әкренләп кыскара торган булалар, чөнки бер үк мәгънәдә һәм бер үк позициядә торган сүз үзеннән-үзе аңлашыла торган булып китә һәм әйтелми башлый. Мәсәлән: *Хәерле иртә белән тәбрик итәм! Яңа ел белән котлыйм!* кебек төзелмәләрдә *котлыйм* һәм *тәбрик итәм* кебек сүзләр болай да аңлашылып торалар, шуңа күрә аларны кулланмыйлар: *Хәерле иртә! Яңа ел белән!*

Шулай итеп сөйләмнең ярдәмче элементлары – контекст, обстановка, мимика һәм ишарә җөмләдә кайбер сүзләрне кулланмаска мөмкинлек биреп, ким җөмлә төзүдә катнашалар, безне тавтологик стильдән коткаралар.

Ким җөмләләр үзеннән-үзе аңлашылган сүзләр кулланылмаудан гына түгел, бәлки сүз формалары, бәйләүче чаралар кыскарудан да барлыкка киләләр. Мәсәлән: *Атнасына ике мәртәбә безне данлыклы артистлар, музыкантлар, композиторлар белән очраштырып тордылар* (М. Юныс) мисалында *белән* бәйлеген һәрбер тиңдәш кисәк янында кабатлап әйтү стиль ямьсезлеге тудырыр иде.

Менә шулардан чыгып, ким җөмләгә түбәндәге билгеләмәне биреп була. Контекст, обстановка, мимика һәм жестлардан аңлашыла торган кисәге яки сүз формасы кулланылмаган җөмлә ким җөмлә дип атала.

Мондый җөмләләрне шартлы рәвештә генә «ким» дип атыйлар. Мәгънә ягыннан алар һәрвакыт тулы, җитешле булалар. Шуңа күрә аны контексттан, обстановкадан чыгып, кайбер кисәкләрне тәҗрибә өчен генә өстәргә мөмкин. Кулланылмаган кисәкне өстәгәч, мәгънәгә артык зыян килмәсә дә, стиль бөтенләй бозыла, ямьсезләнә. Димәк, ким җөмлә сөйләмнең нindiдер бозылган формасы түгел, ул – сөйләмнең бик нормаль күренеше. Ул сөйләмдә тулы җөмләләргә караганда күбрәк кулланыла.

**§ 256. Тулы җөмләләр**. Тулы җөмлә төшенчәсеннән башка ким җөмләне өйрәнү мөмкин түгел. Тулы җөмләдә бер генә элемент та төшерелмәгән була һәм аңа үзеннән-үзе аңлашыла торган бернинди кисәк тә өстәп булмый. Ләкин тулы җөмләдәге фикерне аңлатканда, контекст та, обстановка да яки мимика һәм жестлар да катнашмый икән дип уйларга ярамый. Алар теләсә нинди җөмләгә ярдәмгә килә алалар. Ләкин тулы җөмләдә алар нинди дә булса бер сүзнең мәгънәсен бирмиләр, шуңа күрә теге яки бу сүз төшеп калмый.

Тулы җөмләләр бүлек, абзац башларында, яңа фикер башлап җибәргәндә күбрәк кулланылалар. Төрле билгеләмәләр, кагыйдәләр, карарлар, закон һәм указлар гадәттә тулы җөмләләр белән язылалар.

Тулы җөмләнең тагын бер билгесе шунда: әгәр ким җөмләгә, тәҗрибә өчен генә булса да, кулланылмаган кисәкне яки форманы өсти алсак, тулы җөмләгә андый кисәкне тәҗрибә өчен генә дә өстәп карап булмый.

Еш кына ким һәм тулы җөмләне бер һәм ике составлы җөмлә белән буташтыралар, хәлбуки алар арасында бик зур аерма бар. Ким җөмлә бер вакытта да тулы була алмый, ләкин бер составлы да, ике составлы да булырга мөмкин. Шулай ук бер составлы җөмлә ике составлы җөмләгә каршы куела, һәм ул ким дә, тулы да булырга мөмкин. Мәсәлән:

*– М. Мәһдиевнең «Бәхилләшү» әсәрен кем укыды?*

*– Мин укыдым. Ә сез үзегез укыдыгызмы?*

*– Мин дә укыдым. Узган ел укырга туры килде.*

Бу диалогта беренче җөмлә тулы һәм ике составлы; икенче, өченче, дүртенче җөмләләр ким һәм ике составлы; бишенче җөмлә шулай ук ким, ләкин бер составлы. Ә менә *Җәй урталары иде* (Г. Ибраһимов) дигән җөмлә бер составлы, ләкин тулы.

**§ 257. Ким җөмләләрнең кимлек сәбәбенә бәйле төрләре**. Кимлекнең, теге яки бу элементы кулланылмауның сәбәбе берничә төрле була, шуңа карап, ким җөмләне гадәттә өч төргә бүләләр:

Беренче төрдә кулланылмаган кисәкнең мәгънәсен контекст бирә, димәк, контекст теге яки бу кисәкнең кулланылмавына сәбәп була. Мәсәлән: *Галиулла лампасын уңайлап элеп куйды да, су челтерәмиме дип, бераз тыңлап торды. Юк, су тавышы ишетелми. Түшәмгә кәйлә белән суккалап карады: юк, түшәм дә ишелерлек түгел. Шуннан соң эшли дә башлады* (И. Гази).

Икенче төрдәге ким җөмләләрдә теге яки бу кисәкнең кулланылмавына обстановка сәбәпче була. Мәсәлән: *Кичкә таба авыл юлында бер малай күренде.*

*– Килә! Фирдәвес килә! Хәбәр алып килә!* (Г. Бәширов). Бу – «Намус» романыннан алынган өзек. Нәфисә бригадасы әгъзалары, үзләре эшкәрткән җирнең гектарыннан күпме уңыш алынуын белү өчен, авылдан кеше көтәләр. Менә шул обстановкада алардан берәү *«Килә!»* ди, һәм көтелгән кешенең килүе аңлашыла.

Мимика яки ишарә катнашу аркасында, кайбер кисәкләре әйтелмәгән җөмлә дә шушы төргә керә. Мәсәлән: *Каюм утырган килеш, бер аягын алгарак сузды да, кулы белән тезенә сугып:*

*– Менә күрәсеңме? – диде* (Ш. Камал).

*– Әни, карале, минем нәрсәм бар...*

Ул күкрәгенең сул ягына кадалган тасмага күрсәтте:

*– Менә, бөтен малайларга да бирделәр...* (И. Гази).

Сөйләшеп торганда, сөйләүченең сүзен бүлдерү нәтиҗәсендә дә ким җөмләләр барлыкка киләләр. Моңа да обстановка сәбәпче була. Мәсәлән:

*– Сине шәһәргә алма сатарга озатырбыз. Барырсың бит?*

*– Барырмын да... Мин бит әле бик кечкенә.*

*– Соң бит ул чакта син үскән буласың инде.*

*– Кем хәтле?*

*– Кем хәтле дип әйтим... Малик абзаңның зур улы хәтле. Аягыңда шыгырдавык итек, башыңда хәтфә каләпүш...*

*– Малик абзый малаеныкы кебекме, әти?* (И. Гази).

Өченче төр ким җөмләдә кайбер сүзләр бер үк позициядә күп кабатланганлыктан төшерелә. Мәсәлән: *Кайтуың белән! Хәерле иртә! Ишекне ачма, м и н – т ә р ә з ә а р к ы л ы , – дип пышылдады Гаяз* (М. Әмир).

**§ 258. Кайсы кисәкнең кулланылмавына карап ким җөмләләрнең төрләре**.

1. Иясе әйтелмәгән ким җөмләләр: *Атасы Акташта крестьян. Ярлы. Ләкин каты йөрәкле адәм. Шуның аркасында һәлак тә булды* (И. Гази). *Анасы изге күңелле иде. Кош-кортны бик сөючән иде. Аеруча карлыгач белән күгәрченнәрне бик кадерле иде* (Г. Ибраһимов).

2. Хәбәре әйтелмәгән ким җөмләләр:

*– Кайда эшлисең?*

*– Мәктәптә.*

*– Кайчан кайтасың?*

*– Сәгать алтыда.*

3. Кайсы да булса бер иярчен кисәге әйтелмәгән ким җөмләләр: *Начальник урыныннан кузгалды. Филимонов та торды* (М. Максуд). *Йөзүчеләрне бинокль белән күзәтеп утыручы бер абый әйтеп куйды: – Өчесе кире борылды* (М. Әмир).

4. Берничә кисәге берьюлы әйтелмәгән ким җөмләләр:

*– Кайчан кайттыгыз?*

*– Кичә.*

*– Зиннәт кайда?*

*– Урманда, эштә.*

*– Шакир абзый?*

*– Ул да шунда* (К. Тинчурин).

5. Ярдәмче сүзләре яки берәр аффиксы әйтелмәгән ким җөмләләр. Мәсәлән: *Җырлыйсы, бернәрсәне дә уйламыйча уйныйсы килә* (Ә. Еники). *Борчак, арыш, бодайларны җыеп бетердек.*

**§ 259. Ким җөмләләрнең кулланылышы.** Ким җөмлә, алда әйтелгәнчә, фикерне җыйнак итеп әйтүдә зур роль уйный һәм стильне матурлау чарасы да булып тора. Ул күбрәк диалогларда, сирәгрәк монологларда кулланыла.

Кара-каршы сөйләшкәндә, сорауларга җавап рәвешендә, бары сөйләм яңалыгын белдерә торган кисәкләр генә әйтелә, сөйләм предметын белдерүче кисәкләр, таныш булганлыктан, төшереп калдырылалар. Мәсәлән:

Б а т ы р х а н . *Йортыгыз зурмы?*

М и с б а х . *Кечкенә. Бик кечкенә. Йорт дип әйтерлеге дә юк.*

Аерым очракларда язучылар, сорауларны төшереп калдырып, бары җаваплардан гына да диалог төзиләр. Монда инде кимлек тагын да арта. Мәсәлән, К. Нәҗминен «Язгы җилләр» романыннан алынган түбәндәге өзектә Саимәнең ротмистр сорауларына биргән җаваплары гына китерелә.

*Ротмистрның бүтән сорауларына җавап биргәндә, тагын да корырак тавышка күчте ул:*

*– Саимә.*

*– Мастерскойда эшли.*

*– Бакча каравыллый.*

*– Бераз укый беләм, яза белмим.*

*– Хәсәннән дисезме? Юк, бер хат та килгәне юк.*

*– Бергә эшлибез. Мостафа абзый – кузнец, ә мин җилем кайнатам.*

*– Гәрәйне әйтәсезме? Шушы фатирда күргәләдем.*

*– Ә, юк... Гәрәй андый машина турында сөйләмәде.*

*– Бүтән бер кеше дә очратмадым...*

Монологик сөйләмдә ким җөмлә, еш кына, өстәлмәгә бик якын була (202–207 § ларны карагыз). Бер үк авторның алдагы җөмләсендә әйтелгән сүз соңгы җөмләләрдә кыскартылса, соңгы җөмлә ким була. Ләкин бер шарты бар: мондый ким җөмләнең эчтәлеге алдагы җөмләдән башка конкрет булмаса да, ул җөмлә дип танылгач, ким булса да, мөстәкыйль җөмләләргә шактый охшарга тиеш, ягъни анда

хәбәрлекне белдерүче төп кисәк – хәбәр булырга тиеш. Мәсәлән: *Анасы изге күңелле иде. Кош-кортны бик сөючән иде. Аеруча карлыгач белән күгәрченне бик кадерли иде* (Г. Ибраһимов). *Кечкенә-кечкенә китапларны да бик өстән генә карап үтте. Актарып тормады* (Г. Ибраһимов). *Прораб тәмәке төтене белән тулган бүлмәгә үтте. Мастер да керде* (М. Максуд).

Аерым очракларда монологик сөйләмдәге ким җөмлә хәбәрсез дә була ала, ләкин бу чагында аның составында алдагы җөмлә логикасыннан чыга торган, бер-берсенә буйсынмаган һәм тиңдәш тә булмаган берничә кисәк булырга тиеш. Мәсәлән: *Мескеннең зары бар, халыкның – заманы!* (К. Сибгат). *Манжет алган ун тиенгә, биш тиенгә – ак яка* (Г. Тукай). *Биш тиенгә – ак яка* ким җөмләсендә хәбәр әйтелмәгән булса да, анда үзара буйсынып бер группа төземи торган ике кисәк бар. Алар икесе дә аерым-аерым әйтелми калган хәбәргә буйсынганнар.

Ким җөмлә янәшә торган мөстәкыйль җөмләләрне һәм кушма җөмләдәге җөмләләрне үзара структур яктан оештыруда да зур роль уйный. Бер яки берничә җөмлә янәшәдәге башка җөмлә хисабына ким була һәм бу күренеш җөмләләрне структур яктан бергә оештыра. Мәсәлән: *Җыламасын дип, баланың кулына уенчыклар тоттырды* (Ф. Әмирхан). *Килеп сәлам биреп киткән булса, мин аңа рәхмәт кенә әйткән булыр идем* (Ә. Еники). *Нәгыймә арыганын онытты. Битен, кулын юды. Баласын яңадан карады. Инде төзәлеп килгән йөзеннән суырып-суырып үпте дә, зур бүлмәдәге көзге алдына барып, йөзен чибәрләде, чәчен төзәтте. Тагын баласы янына утырды. Тагын үпте дә:*

*– Әби, андый-мондый хәл булса, тиз генә миңа Хәсәнне җибәрерсең, – дип, хөкемгә китте* (Г. Ибраһимов).

## БЕР ЯРЫМ ХӘБӘРЛЕКЛЕ ҖӨМЛӘЛӘР

**§ 260. Гомуми мәгълүмат.** Бер ярым хәбәрлекле җөмлә мәсьәләләрен соңгы елларда гына, семиотика теориясенә нигезләнеп, семантик (тагын да тутырып әйткәндә, структур-семантик) синтаксистлар күтәреп чыктылар. Аларча, бер ярым хәбәрлекле җөмлә бер генә хәбәрлекле гади җөмлә белән ике яки икедән артык хәбәрлекле кушма җөмлә арасында тора. Шуңа күрә алар «Гади җөмлә синтакси-

сы» ахырында я «Кушма җөмлә синтаксисы» башында өйрәнелергә тиеш булалар. Бер ярым хәбәрлекле җөмләләр грамматик яктан гади җөмлә булып саналалар, шуңа күрә аларны «Гади җөмлә синтаксисы» бүлегендә өйрәнәләр дә.

Һәрбер мөстәкыйль җөмлә хәбәрлекнең (предикативлыкның) тулы булуы белән характерлана. Хәбәрлекнең эчтәлеге һәм формасы бар. Аның эчтәлеге – берәр хәл, эш турында хәбәр итү (гомуми лингвистикада моны **пропозиция** сүзе белән атыйлар), формасы – шул хәбәр итүне җөмләнең бер калыбына салып тиешле модаль интонация белән әйтү. Мондый хәбәрлек **тулы хәбәрлек** дип йөртелә, һәм ул мөстәкыйль гади җөмләләрдә була.

Тезмә кушма җөмләдә ике яки икедән артык тулы хәбәрлек була, ләкин аның бөтен яктан да тулысы соңгы җөмләдә күзәтелә. Тезмә кушма җөмләнең баштагыларында интонацион тулылык гадәттә җитешми, шулай да, анысы да тулы хәбәрлек санала.

Тулы хәбәрлектән тыш, тагын **иярчен хәбәрлек** тә күзәтелә, ул иярчен җөмләләрдә була. Аналитик иярчен җөмләләрдә иярчен хәбәрлек тулы хәбәрлеккә тартымлык күрсәтсә, синтетик иярчен җөмләләрдә ул ярым хәбәрлеккә якын тора.

**Ярым хәбәрлек** иярчен җөмлә төзи алмый, ул билгеле бер хәлне хәбәр итми, аны атау белән чикләнә һәм бу хәлне атап күрсәтү җөмлә калыбына төренми, я җөмлә кисәге белән, я морфологик-синтаксик чара белән, я конситуация белән (ягъни имплицит юл белән) бирелә. Ярым хәбәрлек тулы хәбәрлеге булган җөмләдә генә килә ала. Шуңа күрә ярым хәбәрлеге булган җөмләне бер ярым хәбәрлекле җөмлә дип атыйлар.

**§ 261. Тел чаралары белән бирелмәгән хәбәрлек ярым хәбәрлек дип таныла алмый.** Җөмләләрне семантик планда өйрәнүчеләр җөмләгә, аның төп хәбәрлеген үстерү юнәлешендә, төрле-төрле хәбәрлек уйлап чыгарып ябыштыра башладылар.

Мәсәлән, *Мин энемә китап бирдем* җөмләсендә төп ситуация – *мин бирдем*. Биредә хәбәрлек, эчтәлеге буенча, яңалык хәбәр итә, формасы буенча, ул татар теленә хас җөмлә моделе белән бирелгән, шуңа күрә ул тулы хәбәрлек санала. *Мин энемә китап бирдем* дип әйткәч, без тагын нindiдер ситуацияләр булганын уйлый алабыз: *Китап миннән энемә күчте* һәм *Энем китап алды*. Семантик синтаксис әһелләре

бу ике төрле ситуацияне дә *Мин энемә китап бирдем* ситуациясенә ияртергә, һәм мондый җөмләне күп хәбәрлекле дияргә өндиләр.

Ләкин шунысы бар: *Мин энемә китап бирдем* җөмләсендә югарыда әйтелгән ике ситуация (*Энем китап алды* һәм *Китап миннән энемә күчте* ситуацияләре) бернинди тел чарасы белән дә бирелмәгән, алар уйлап чыгарылган гына. Алай итеп уйлый башласак, без бу җөмләгә тагын берничә ситуация өсти алабыз: *Мин энемне хөрмәт итәм; Энем китапны үзе сатып ала алмый әле; Мин энемнең юмарт абыйсы* һ.б.

Үзеннән-үзе аңлашыла, төп ситуацияне үстерү юнәлешендә уйлап чыгарылган ситуацияләр төп җөмләдә бернинди тел чарасы белән дә бирелмәгәннәр, шуңа күрә аларны төп хәбәрлек янында өстәмә яисә ярым хәбәрлек дип танып булмый. *Мин энемә китап бирдем* җөмләсе бер тулы хәбәрлеккә ия, һәм ул гадәти бер хәбәрлекле гади җөмлә рәтенә керә.

Семиологик хезмәтләрдә очрый торган тагын бер җөмләнең семантик анализына тукталыйк: *Иван балта эшен белә.* Семантик планда бу җөмләдә ике хәбәрлек бар: *Иванның балтасы бар* һәм *Ул балта белән эшли белә.* Шулай уйлап чыгаруга китсә, монда тагын түбәндәге ситуацияләрне өстәргә мөмкин: *Иван үсә төште. Аңа балта бүләк иттеләр. Ул балта белән теләсә нинди әйберне ясый ала* һ.б. Төп ситуацияне үстерү юнәлешендә уйлап чыгарылган ситуацияләр төп җөмлә эчендә өстәмә хәбәрлек төземиләр, чөнки алар төп җөмләдә тел чаралары белән бирелмәгәннәр. Шуңа күрә *Мин энемә китап бирдем* һәм *Иван балта эшен белә* кебек җөмләләр бер тулы хәбәрлекле гадәти гади җөмлә булып калалар, кушма җөмлә дип тә, бер ярым хәбәрлекле җөмлә дип тә таныла алмыйлар.

**§ 262. Бер ярым хәбәрлекле җөмләләр турында гомуми мәгълүмат.** Семантик синтаксис вәкилләре уйлавынча, кайбер җөмләләрдә, төп тулы хәбәрлектән тыш, сөйләмнең кайбер элементлары ярдәмендә ярым хәбәрлек тә белдерелә. Ярым хәбәрлекне белдерүче чаралар булып кайбер кушымчалар, бәйлекләр, аерым очракларда җөмлә кисәкләре килә алалар. Мәсәлән, *Гали Вәлигә утын ташышты* җөмләсендә уртаклык юнәлеше кушымчасы *-ш-* һәм тәмамлыктагы *-гә* кушымчалары ярдәмендә тагын бер эш-хәлнең булуы аңлашыла: *Гали утын ташый* – төп хәбәрлек, *Вәли утын ташый* өстәмә, ярым хәбәрлек була. Бу ике эш-хәл арасында аерма шунда: беренчесендә эш-хәл хәбәр ителә һәм ул җөмлә моделе белән белдерелә; икенчесендә эш-

хәл (утын ташу) җөмлә моделе белән бирелми, ул атала гына, хәбәр итү юк. Шуңа күрә икенче эш-хәл ярым хәбәрлек кенә була. Димәк, беренче эш-хәлне хәбәр итү – аерым, тулы бер хәбәрлек була, икенче эш-хәлне *-ш-* һәм *-гә* кушымчалары ярдәмендә белдерү бары ярым хәбәрлек дип кенә танылa. Шулай итеп, *Гали Вәлигә утын ташышты* җөмләсе **бер ярым хәбәрлекле** җөмләләр рәтеннән санала.

Ярым хәбәрлек кайбер кисәкләр белән дә бирелә ала. Мәсәлән, *Абдулла Алиш – татар балалар язучысы фашист тоткынлыгында һәлак булды* җөмләсендә ия-хәбәр бәйләнеше белән бирелә торган тулы хәбәрлек янында *татар балалар язучысы* дигән аныклагыч ярдәмендә бирелә торган ярым хәбәрлек тә бар: *Абдулла Алиш – татар балалар язучысы.* Бу очракта ярым хәбәрлек өчен дә, тулы хәбәрлек өчен дә бер үк субъект килә, ягъни ярым хәбәрлекнең үз мөстәкыйль субъекты юк.

Бер ярым хәбәрлекле җөмләләрне ике төргә бүлеп өйрәнәләр: 1) ярым хәбәрлеге кушымчалар, бәйлекләр белән бирелгән гади җөмләләр; 2) ярым хәбәрлеге төрле кисәкләр белән бирелгән гади җөмләләр. Ярым хәбәрлекне белдерүче кисәкләрне ярым хәбәрлекле кисәк (полупредикативный член) дип тә йөртәләр.

**§ 263. Бер ярым хәбәрлекле җөмләләр асимметрик булалармы?** Эчтәлек белән форма үзара симметрияле булалар, ягъни нинди эчтәлек, шундый форма була.

Семиологик синтаксис юнәлешендә эшләүчеләр бу төр философик куелыш белән килешеп җитмиләр һәм бер ярым хәбәрлекле җөмләләрдә эчтәлек белән форма үзара асимметрик булалар, икенче төрле әйткәндә, эчтәлек белән форма симметрияле булмый дип расларга тырышалар.

Мәсәлән, В.В.Мартынов үзенең «Категории языка» (М., «Наука», 1982) дигән хезмәтендә бер ярым хәбәрлекле җөмләләрне бирелеш ягыннан (эксплицит яктан) – гади, ә форма белән бирелмәгән эчтәлек ягыннан (имплицит яктан) кушма булалар дип аңлата. Мәсәлән, *Иван аюны ашатты һәм эчерде* бирелеш ягыннан (ягъни формасы белән) гади, эчтәлеге белән (ул формаль бирелмәсә дә, ягъни имплицит яктан) кушма, чөнки монда *Иван аюны ашатты* һәм *Иван аюны эчертте* мәгънәләре салынган.

*Иван һәм Петр утын кистеләр* җөмләсе дә форма ягыннан гади, эчтәлеге ягыннан кушма, чөнки анда ике эш-хәл турында сүз бара: *Иван утын кисте* һәм *Петр утын кисте.*

*Хыяллану күңелле* җөмләсен дә В.В.Мартынов шул рәвешчә тикшерә. Бу – формаль яктан – гади, эчтәлеге буенча кушма, чөнки бирелдә а) *хыяллана белсәң*, ә) *күңелле* дигән ике эш-хәл хәбәр ителә, ди ул.

Гомумән, җөмләдә ия-хәбәрдән башка эш-хәлне (ситуацияне) белдерүче берәр сүз булса, андый җөмләне В.В. Мартынов һәм аның яклылар формаль яктан – гади, эчтәлеге белән кушма дип карыйлар. Эчтәлеге белән кушма булгач, андый җөмлә формасы (бирелеше) белән дә кушма (ягъни симметрияле) булырга тиеш иде, ләкин симметрияле булмаган, ягъни асимметрик булган, димәк, форма белән эчтәлек берлеге юк булып чыга. Семиотик юнәлеш вәкилләре синтаксис дигән фәнне бары форма өйрәнүче дип аңлаталар, ә ул форма белдергән мәгънәне семантика дигән башка фән өйрәнергә тиеш дип уйлыйлар. Традицион синтаксис исә сөйләм берәмлекләрен форма һәм эчтәлек ягыннан өйрәнә, һәм ул форма белән эчтәлекне симметрик күренешләр дип карый.

Бер ярым хәбәрлекле җөмләләр, алда әйтелгәнчә, гади җөмлә дип танылалар, анда төп хәбәрлек телгә хас булган бер модель белән бирелә, ә ярым хәбәрлек җөмлә моделе белән түгел, ә аның бер элементы булган кушымча, бәйлек яки берәр кисәк белән бирелә. Димәк, монда да билгеле бер эчтәлек үзенә хас форманы тапкан, эчтәлек белән форманың симметриясе сакланган.

## Ярым хәбәрлеге төрле кисәкләр аша бирелгән гади җөмләләр

**§ 264. Ярым хәбәрлек тиңдәш кисәкләр ярдәмендә бирелә.** Ярым хәбәрлекнең тиңдәш кисәкләрдә бирелүенә безнең галимнәр XX йөз башында ук игътибар иткәннәр. Г. Ибраһимов болайрак фикер йөрткән: җөмләдә тиңдәш кисәкләр берничә җөмләнең бергә оешуы нәтиҗәсендә барлыкка киләләр. Мәсәлән, *Илдус һәм Марат килде* җөмләсе *Илдус килде, Марат килде* дигән ике җөмләдән оешкан. Шуңа күрә тиңдәш кисәкле җөмләне Г. Ибраһимов **оешкан җөмлә** дип атый.

Тиңдәш хәбәрләр аша белдерелгән ярым хәбәрлек тулы хәбәрлеккә шактый якын тора, чөнки анда хәбәрлек һәм модальлек белдерү була. *Марат укыды һәм язып куйды* җөмләсендә мәгънә ягыннан *Марат укыды* һәм *Марат язып куйды* дигән ике хәбәрлек бар, аларның икесендә дә хәбәр итү һәм модальлек (сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсә-

бәте) бирелгән, ләкин, беренчедән, анда икесенә бер генә субъект бар, икенчедән, анда бирелү формасы ягыннан җөмләнең бер генә моделе күзәтелә. Шуңа күрә ул бер ярым хәбәрлекле гади җөмлә эчендә карала.

Тиңдәш хәбәрләр бик нык җәенкеләнеп, бер-берсеннән ераклашсалар, аларны чыннан да аерым җөмлә дип таныйлар. *Аннан соң бөтенләй тынсыз-өнсез калды ул, ләкин каршы сүз әйтә алмады* (Н. Фәттах). Бу җөмләдәге тиңдәш хәбәрләрне аерым җөмләләр итеп тануга алар арасында *ул* дигән иянең керүе дә сәбәп була.

Түбәндә китерелгән мисалда ике хәбәр бер-берсеннән *Волхов шаһит* дигән сүзләр белән аерылган, шуңа күрә ул хәбәрләр дә аерым-аерым җөмлә төзиләр:

*Юк, мин сине тузан бөртегедәй*
*Сансыз гомерем өчен сатмадым,*
*Волхов шаһит: изге сугыш антын*
*Соңгы чиккә керсез сакладым* (М. Җәлил).

Димәк, тиңдәш хәбәрләрнең аерым хәбәрлек төзү мөмкинлекләре бик зур. Шулай да бер генә җөмлә моделе, барлык хәбәрләргә бер генә субъект булганлыктан, тиңдәш хәбәрле гади җөмләне бер ярым хәбәрлекле төрләргә кертеп өйрәнәләр. Чыгарма буларак, аларның һәрберсе аерым хәбәрлек төзи дип раслау да күзәтелә.

Синтаксис фәнендә тиңдәш ияләрнең һәм тиңдәш тәмамлыкларның гади җөмләдә ярым хәбәрлек белдерүдә катнашуларын таныйлар. Һәм бу тиңдәш кисәкләр белән бирелгән ярым хәбәрлекне җөмләне берничәгә таркату юлы белән белергә мөмкин дип аңлаталар. *Әтием һәм әнием кушты: Әтием кушты – Әнием кушты. Энемә кәгазь һәм каләм бирдем: Энемә кәгазь бирдем – Энемә каләм бирдем. Әти миннән һәм энемнән сорады: Әти миннән сорады – Әти энемнән сорады.*

Хәлләр һәм аергычларның тиңдәшләнеп килүен ярым хәбәрлек белдерү дип танучылар күп түгел. Система булдыру өчен, без боларын да бер ярым хәбәрлекле гади җөмләләрдә өйрәнергә кирәк дип саныйбыз. *Ул тыныч кына һәм бик тиз килде: Ул тыныч кына килде – Ул бик тиз килде. Ак, кызыл чәчәкләр өздем: Ак чәчәкләр өздем – Кызыл чәчәкләр өздем.*

Кайбер синтаксистлар теләсә нинди җәенке җөмләдә мәгънә ягыннан икешәр, өчәр хәбәрлек саныйлар: *Урмандагы матур чәчәкләрне өздем: Урмандагы чәчәкләрне өздем – Урмандагы матур чәчәкләрне*

*өздем – Матур чәчәкләрне өздем.* Мондый җөмләләрне без бер ярым хәбәрлекле гади җөмләләргә кертү дөрес булмас дип санайбыз, чөнки формаль яктан җөмлә моделе бер, һәрбер кисәк ниндидер эш-хәлне хәбәр итми, атамый. Теге яки бу кисәк ярым хәбәрлек белдерсен өчен, ул билгеле бер таләпләргә җавап бирергә тиеш.

**§ 265. Ярым хәбәрлек исем фигыль һәм инфинитив белән бирелгән кисәкләр ярдәмендә белдерелә.** Бу төр җөмләләрдә исем фигыль һәм инфинитив төп җөмләнең хәбәре булып килми, иясе яисә кайсы да булса бер иярчен кисәк булып килә: *Синең килү миңа дәрт өстәде* җөмләсендә төп хәбәрлектән тыш тагын бер эш-хәл үтәлүе аңлашыла: *килү*. Бу кисәк эш-хәлне хәбәр итми, бары аны атый гына, һәм ул үз янындагы кисәк (*синең*) белән җөмлә моделе төземи, шуңа күрә ярым хәбәрлек белдерүче кисәк булып кала.

Ярым хәбәрлекле кисәк инфинитив белән бирелгәндә дә шундый ук хәл күзәтелә: *Ул кайтырга уйлаган иде.* Бу гади җөмләдә төп хәбәрлек – *ул уйлаган иде*, ярым хәбәрлек – *кайтырга*. Соңгысы җөмлә моделе төземәгән, шуңа күрә ярым хәбәрлек кенә белдерә дип санала.

Әгәр дә исем фигыль һәм инфинитив үз янындагы сүз белән җөмлә моделе төзесә (ягъни алар ия-хәбәр берлеге төзесәләр), алар ярым хәбәрлек түгел, ә бөтен хәбәрлек, ягъни синтетик иярчен җөмлә төзүчеләр буларак өйрәнеләләр: *Син килү миңа дәрт өстәде; Әти кайтырга биш көн калды*. Ләкин бу синтетик иярчен җөмләләрнең хәбәрлеге тулы булмый, андагы җөмлә моделе (ия-хәбәр бәйләнеше) булу аркасында гына аларны ярым хәбәрлек белдерүчеләргә түгел, ә иярчен хәбәрлек белдерүче синтетик иярчен җөмләләргә караталар.

Исем фигыль, ярым хәбәрлек белдергәндә, җөмләнең төрле кисәге булып килә ала:

а) ия булып килә ала: *Синең килү миңа дәрт өстәде;*

ә) тәмамлык булып килә ала: *Әтинең кайтуын түземсезлек белән көттек; Минем кайтуга исе китте; Минем кайтудан туйган; Минем кайту турында сөйли; Минем кайту белән горурлана; Кайтуыма барнәрсә әзер;*

б) хәл булып килә ала: *Бу эш минем кайтуым аркасында бозылды; Анасы ялсыз эшләүдән хәлсезләнеп тора* (А. Шамов); *Балалар кайту белән дәрес әзерләргә тотындылар; Ул, әтисен коткару өчен, барлык чараларны күрде;*

в) аергыч булып килә ала: *Синең килүнең файдасы күп булды.*

Инфинитив белән бирелгән ярым хәбәрлекле кисәк җөмләдә сирәгрәк кулланыла.

**§ 266. Ярым хәбәрлек сыйфат фигыльләр һәм хәл фигыльләр белән бирелгән кисәкләр ярдәмендә белдерелә.** Бу төр кисәкләр, үзләренә караган ияләре булса, җөмлә эчендә җөмлә моделе барлыкка китерәләр һәм синтетик иярчен җөмлә хәбәре дип танылалар. Шуңа күрә алар белдергән хәбәрлек ярым хәбәрлек дип түгел, ә иярчен хәбәрлек дип санала. Мәсәлән, *Син терелгәнне түземсезлек белән көттек* мисалында *терелгәнне* кисәге иярчен җөмлә хәбәре дип санала, чөнки аның үтәүчесен белдерүче кисәк (*син*) аның янында ия булып килгән, җөмлә моделе (ия-хәбәр бәйләнеше) ясалган. Бу кисәк ия булып килмәсә, *Синең терелгәнне* формасында бирелсә, *терелгәнне* кисәге иярчен хәбәрлек белдерми, бары ярым хәбәрлек белдерүче кисәк булып танылa.

Башка төр сыйфат фигыль белән бирелгән кисәкләр дә шулай ук: янында үзенә караган иясе булса, иярчен җөмлә хәбәре дип, үз иясе булмаса, ярым хәбәрлекле кисәк дип танылa. Мәсәлән, *Син киләсе юлдан күзем алмыйм* җөмләсендә *киләсе* кисәге – иярчен җөмлә хәбәре – *Синең киләсеңне белмәдем* җөмләсендә *киләсеңне* кисәге бары ярым хәбәрлекне генә белдерә. *Син салачак күпер проекты каралды* мисалында *салачак* – иярчен җөмлә хәбәре, ә *Төзеләчәк күпер юлны кыскартыр* мисалында *төзеләчәк* – ярым хәбәрлекле кисәк.

Сыйфат фигыльләр, ярым хәбәрлек белдергәндә, күптөрле функцияләрне үтиләр: *Укыганнан соң гына аңладым; Әйтелгән сүз – аткан ук; Эшләмәгән ашамый; Язар сүзем бик күп әле; Килгәндә арымадым* һ.б.

Хәл фигыльләр белән бирелгән кисәкләр дә, әгәр алар үз ияләре белән бергә җөмлә моделе хасил итсәләр, синтетик иярчен җөмлә хәбәре дип танылалар (*Әти кайткач барырбыз*), әгәр үз ияләре булмаса, ярым хәбәрлекле кисәк дип саналалар (*Кайткач сөйләрмен*). Мисаллар: *Кайтып җиткәнче җәфаландым; Эштән арып-талып кайтты; Хатны укымыйча түзә алмады.*

Хәл фигыль параллель һәм эзлекле процессларны белдерүче кушма фигыльләрдә дә катнаша, һәм анда да ул ярым хәбәрлекле кисәк

дип таныла ала: *Таҗи шул уйлар белән чәй янында торып китте* (Г. Гобәй) мисалында *торып китте* кисәге эзлекле процесслар белдерүче кушма фигыль белән бирелгән. Болар икесе дә төп бөтен хәбәрлек белдерүдә катнашалар, ләкин *торып* фигыле ярым хәбәрлек тә белдерә.

*Югары очтан күк ат чабып төшеп килә* (И. Гази) мисалында *чабып төшеп килә* хәбәре тулы килеш төп хәбәрлек белдерә, ләкин *чабып* һәм *төшеп* өлешләре дә ярым хәбәрлеккә ияләр.

**Искәрмә.** Шарт фигыль белән бирелгән кисәк тә, үз иясе булмаса, ярым хәбәрлек белдерә дияргә мөмкин: *Укысам белермен; Укысам да белмәдем.* Ләкин шарт фигыльнең затланышлы булуын исәпкә алсак, аны һәрчак синтетик иярчен кисәк хәбәрен белдерә дип танысак та ярый.

**§ 267. Ярым хәбәрлек *-лык/-лек*, *-гысыз/-гесез* кушымчаларын алган сүзләр һәм хәбәрлек сүзләр белән бирелгән кисәкләр ярдәмендә белдерелә.** *-лык* кушымчасы, төрле формадагы фигыльләргә, хәбәрлек сүзләргә, сыйфатларга, рәвешләргә ялганып, аларны сөйләмгә алып керә, һәм бу төр кисәкләр нигездә ярым хәбәрлек белдерәләр: *Ул үләрлек дәрәҗәдә ачыкты. Эшләмәслек булгач, ник сорадың? Озак йөргәнлектән, бик арыды. Билетның миңа кирәклеген оныткансың; Кәефемнең юклыгы авыр. Минем барлыгымны онытма; Кәефемнең начарлыгыннан булды бу. Акыллылыктан әле беркемнең дә зыян күргәне юк.*

Үзләренә аерым ия булганда, бу төр кисәкләр дә синтетик иярчен җөмлә хәбәре була алалар: *Мин барлыкны онытма. Ул юклыктан файдалан. Син эшләмәслек түгел бу* һ.б.

*-гысыз* кушымчасы фигыльләрнең архаик бер формасы дип йөртелә, ләкин ярым хәбәрлек белдергәндә, ул шактый актив кулланыла: *Ул әйтеп бетергесез шатлык кичерә иде* (Ә. Еники). *Монда гөлҗимеш җыеп бетергесез күп була торган иде* (Ә. Еники). *Күтәреп алгысыз йөк белән килгәнсез.* Бу төр җөмләләрдәге ярым хәбәрлек синтетик иярчен җөмлә хәбәренә дә тартымлык күрсәтә, чөнки семантик яктан мондый хәбәрлекнең субъекты гомумиләштерелгән һәм төп субъект белән туры килми.

Хәбәрлек сүзләр, ярым хәбәрлек белдереп, төрле кисәк булып киләләр: *Миңа кирәк китаплар синдә юк. Сиңа кирәкне белмәдем. Ул миңа кирәк чакта гына китеп барган. Миңа тиешле китап югалган* һ.б.

**§ 268. Ярым хәбәрлек аныклагычлар һәм өстәлмәләр белән бирелә.** Аныклагычлар үзе ияргән сүздән соң киләләр, шул сүзне аныклыйлар, аның турында үтеп барышлый гына хәбәр иткән кебек булалар. Мәсәлән, *Фронт командующие, армия генералы Еременко, үзенең бер мәкаләсендә Газинур Гафиятуллин турында язып чыкты* (Г. Әпсәләмов) дигән җөмләдә төп хәбәрлек *генерал язып чыкты* төзелмәсе белән бирелә, шул ук вакытта төп фикерне хәбәр итеп барышлый гына *фронт командующие – армия генералы Еременко* иде дигән хәбәрлек бирелә, ул хәтта җөмлә моделенә якын тора, тик төп җөмләдә аныклагыч белән бирелгән, ия-хәбәр төзелмәсе белән түгел. Шуңа күрә аны ярым хәбәрлек белдерүче кисәкләр рәтенә кертәләр.

Ияне генә түгел, башка кисәкләрне аныклап килгәндә дә, аныклагыч ярым хәбәрлеккә ия була: *Урман өскә авып тора, ягъни ындыр артында гына* (Ш.Рәкыйпов). *Биек тау башына, Илсөярнең әнисе күмелгән җиргә, күтәрелделәр* (Г. Гобәй). *Без, Идел буе халыклары, борын-борын заманнардан бирле күпмилләтле, зур тату бер гаилә булып яшибез* (Г. Бәширов). *Таякның юан башы класс җитәкчесенә – Хафизның үзенә төште* (Г. Әпсәләмов). *Ул Ульяновскида (элекке Сембер шәһәрендә) туган. Аның, ягъни шул кәкре аяклы малайның, сүзе туры иде* (М. Әмир).

Барлык төр кисәкләр дә җөмләдә өстәлмә булып килә алалар, ләкин алар аерым тулы хәбәрлек төземиләр, алдан килгән төп җөмләнең иярчен җөмләсе итеп тә саналмыйлар, семантик яктан ярым хәбәрлекле кисәк булып кына калалар.

Аергычның өстәмә булып килүе һәм ярым хәбәрлек белдерүе: *Мин күп күрдем филдәй кешеләрне, киң күкрәкле, тимер бәдәнле* (М. Җәлил). Биредә *мин күргән кешеләр киң күкрәкле, тимер бәдәнле иде* дигән ярым хәбәрлеге бар. *Куштирәк бәләкәй авыл. Бер генә урамлы* (Н. Фәттах).

Хәлнең өстәлмә булып килүе һәм ярым хәбәрлек белдерүе: *Кайттым, ләкин сагынып түгел, эш белән. Мин аны беләм һәм күптән. Эше бара, ләкин әкрен.*

Ия дә өстәлмә була ала, ярым хәбәрлек белдерә: *Мин дә, әни дә кайттык. Әти дә.*

Тәмамлыклар, өстәлмә булганда, ярым хәбәрлек белдерәләр: *Мин сине бик яратам. Энемне дә. Мин шәһәрдән кайттым. Әти белән.*

Кереш сүзләр дә өстәлмә була ала һәм ярым хәбәрлек белдерә: *Менә монысы чын хуҗаларча. Чыннан да* (Г. Ахунов). *Директор шулай диде. Валлаһи менә!* (М. Әмир).

## Ярым хәбәрлеге кушымчалар һәм бәйлекләр аша бирелгән гади җөмләләр

**§ 269. Ярым хәбәрлек төшем юнәлеше кушымчасы аша бирелә.** Төшем юнәлеше, беренче чиратта, күчемле фигыльләрдә ныклы чагылыш таба. *Бу рәсемнәрнең барысы да балалар кулы белән ясалган* мисалында тулы хәбәрлек – *рәсем ясалган*, *ясалган* хәбәрендәге төшем юнәлеше кушымчасы *-л-* семантик яктан тагын бер хәбәрлекнең булуын белдерә: *рәсемне балалар кулы ясаган.* Ләкин соңгы семантик хәбәрлек җөмлә моделе белән бирелмәгән, шуңа күрә аны ярым хәбәрлек төзүче дип таныйлар.

Төшем юнәлеше кушымчасы күчемле фигыль составында килгәндә, процессны үтәүче күп очракта аерым кисәк белән бирелә. Бу җөмләдә ул – *балалар кулы белән*. Димәк, *-л-* кушымчасы ярым хәбәрлекне белдергәндә, аңа аерым җөмлә кисәкләре дә ярдәмгә килә. Мондый кисәк төшем юнәлешендәге фигыль белән бирелгән кисәктән аңлашылган процессның үтәүчесе була, ләкин ул ия булып формалашмый, *белән, тарафыннан* ярдәмлек сүзләре янында килә торган тәмамлык була: *Йорт студентлар тарафыннан төзелде. Рәсем балалар кулы белән ясалган.*

Ярым хәбәрлек процессын үтәүче булып сөйләүче үзе аңлашылганда, ул җөмләдә аерым кисәк белән бирелмәскә дә мөмкин: *Соңгы җырым палач балтасына башны томкан килеш языла* (М. Җәлил).

Ярым хәбәрлекнең субъекты гомумиләштерелгән очракта да *-л-* кушымчасына өстәмә булып субъектны белдерүче сүз бирелми, чөнки аның кем булуы сөйләүче өчен дә, тыңлаучы өчен дә әһәмиятле түгел: *Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын* (М. Җәлил). Бу җөмләдә *мин онытылырмын* – тулы хәбәрлек, ә *кемнәрдер яки халык мине онытыр* ярым хәбәрлек.

Төшем юнәлешендәге кайбер фигыль хәбәр белдергән процессның объекты һәм субъекты бер үк була: *Баш әйләнеп китте һәм мин ишек яңагына килеп бәрелдем* (М. Әмир). Биредә *мин бәрелдем* тулы хәбәрлек, *мин* – объект. Семантик яктан ярым хәбәрлек – *мин үземне бәрдем.*

Хәбәр төшем юнәлешендәге күчемсез фигыль белән бирелгәндә, ярым хәбәрлек бөтенләй үтәүчесез була: *Шәһәрдә бик озак йөрелгән.* Бу җөмләдә йөрү процессын сөйләүче үзе ихтыярсыз үти, шуңа күрә сөйләүче үзен җөмләдә аерым сүз белән бирми, нәтиҗәдә җөмлә бер составлы була. Биредә ярым хәбәрлек – сөйләүчене йөрергә этәрү. Йөрергә этәрүче – ниндидер илаһи көч, билгесез, шуңа күрә ул җөмләдә бирелми.

**§ 270. Ярым хәбәрлек уртаклык юнәлеше кушымчасы аша бирелә.** Бу кушымча белән белдерелгән ярым хәбәрлектәге үтәүче гадәттә тәмамлык белән бирелә яисә үтәүчеләр тиңдәш ияләр белән биреләләр. *Марат Илдарга утын ташышты* җөмләсендә төп тулы хәбәрлек – *Марат ташышты*, ярым хәбәрлек – *Илдар ташыды*, ләкин бу төп үтәүче *Илдарга* дигән тәмамлык белән бирелгән. *Марат һәм Илдар хат языштылар* җөмләсендә *хат язу* процессын үтәүчеләр тигез дәрәҗәдә булгач, алар тиңдәш ияләр белән бирелгәннәр.

Хәбәре уртаклык юнәлешендәге фигыль белән бирелгән бер ярым хәбәрлекле гади җөмләләрдә уртаклык өч төрле мәгънә төсмере белән характерлана: 1) үтәүчеләр процессны тигез дәрәҗәдә башкаралар, 2) үтәүчеләрнең берсе процессны төп үтәүче була, икенчесе ярдәм итүче генә, 3) үтәүчеләрнең берсе – башлап йөрүче, икенчесе пассив була.

Процессны үтәүчеләр тигез булганда, алар я тиңдәш кисәкләр белән биреләләр, я иянең күплек санда булуыннан аңлашылалар: *Марат белән Илдар бик озак кочаклашып тордылар. Без бер-беребезгә карашып тордык. Илсөяр һәм этисе җитәкләшеп китеп бардылар* (Г. Гобәй).

Процессны төп үтәүче һәм ярдәмче үтәүче аерылып торганда, төп үтәүче – юнәлеш килешендәге тәмамлык белән, ә ярдәм итүче ия белән бирелә: *Илсөяр этисенә хат язышты. Мәрьям әнисенә су китереште.*

Үтәүчеләрнең берсе актив, икенчесе пассив булып аңлашылганда, актив үтәүче – ия булып, пассив үтәүче *белән* бәйлеге янындагы тәмамлык булып килә: *Мин Марат белән бик озак сөйләштем. Марат әнисе белән күреште.*

Бу төзелмәләрне формалаштыруда фигыльнең күчемле яки күчемсез булуы да зур роль уйный: күчемле фигыльләр янында уртаклык юнәлеше, башлыча, ярдәм итү мәгънәсен бирә (*Марат этисенә печән*

*әзерләште*), күчемсез фигыльләр янында үтәүчеләр күбрәк тигез дәрәҗәле булалар (*Галия белән Наилә көлешеп алдылар*).

**§ 271. Ярым хәбәрлек йөкләтү юнәлеше кушымчасы аша бирелә.** Мондый ярым хәбәрлекле җөмләләрдә йөкләүче үтәүчегә турыдан-туры йөкләргә, башка затлар аша йөкләргә мөмкин. Беренче очракта йөкләтү юнәлеше кушымчасы бер генә була: *Әтисе хатны улыннан яздырды;* икенче очракта йөкләтү юнәлеше кушымчасы ике (сирәгрәк – өч, дүрт) була: *Әтисе хатны әнисе аша улыннан яздыртты (яздырттырды).*

Тагын бер мисал. *Малай комиссия үтте* (йөкләтү юк); *Әтисе малаен комиссиядән үткәрде* (бер йөкләүче бар); *Әтисе үз ярдәмчесеннән малаен комиссиядән үткәртте* (*үткәрттерде*) (йөкләү ярдәмче аркылы башкарыла).

Йөкләү турыдан-туры бер зат тарафыннан башкарылса, җөмләдә ярым хәбәрлек бер генә була: *Әтисе улыннан яздырды.* Биредә *әтисе яздырды* – тулы хәбәрлек, ә *улы язды* – ярым хәбәрлек, чөнки ул җөмлә калыбы белән бирелмәгән, *улыннан яздырды* тезмәсе белән генә бирелгән.

Йөкләү башка бер зат аркылы башкарылганда, җөмләдә тулы хәбәрлек берәү, ә ярым хәбәрлек ике (хәтта өч) була: *Әтисе хатны әнисе аша улыннан яздыртты* җөмләсендә тулы хәбәрлек – *әтисе яздыртты*, ярым хәбәрлекләр: *әнисе яздырды, улы язды*, болары җөмләдә җөмлә моделе төземәгәннәр, шуңа күрә алар ярым хәбәрлек кенә барлыкка китергәннәр.

Бер ярым хәбәрлекле мондый гади җөмләләрдә йөкләүче – иядә, йөкләүдә арадашчы – *аша*, *аркылы* ярдәмлеге янында килгән кисәктә бирелә (*Әтисе хатны әнисе аркылы улыннан яздыртты*); үтәүче чыгыш килешендәге кисәк белән белдерелә: *Ул миннән белгәнемне сөйләтте.*

Үтәүче гомумиләштерелгән билгесез зат та булырга мөмкин, бу очракта ул җөмләдә бирелми: *Бал балчыкны ялата.* Биредә йөкләүче бар, ул – ия (*бал*), ә үтәүче теләсә кем була ала.

Күчемсез фигыльләр йөкләтү юнәлешендә килгәндә, ярым хәбәрлектәге төп үтәүче төшем килешендәге тәмамлык белән дә бирелә ала: *Асия баласын уйната.* Биредә тулы хәбәрлек – *Асия уйната*, ярым хәбәрлек – *бала уйный. Батырны яу тудыра* җөмләсендә тулы хәбәрлек – *яу тудыра*, ярым хәбәрлек – *батыр туа.*

**§ 272. Ярым хәбәрлек чагыштыру кушымчасы яки бәйлекләре аша бирелә.** *Марат Рөстәмнән акыллырак* җөмләсендә тулы хәбәрлек – *Марат акыллырак*, ярым хәбәрлек – *Рөстәм дә акыллы.* Соңгысы җөмлә калыбы белән бирелмәгән, чагыштыру кушымчасы һәм чыгыш килешендәге тәмамлык белән бирелгән, шуңа аларның семантик хәбәрлеге, формаль яктан ярым хәбәрлеккә туры килә. Ярым хәбәрлекнең субъекты чыгыш килешендәге тәмамлык белән бирелгән.

*Роман кебек күңелле син, юл!* (Х. Туфан) җөмләсендә тулы хәбәрлек – *син күңелле*, ярым хәбәрлек – *роман да күңелле*.

Ярым хәбәрлекнең субъекты *кебек* бәйлеге янындагы хәл белән бирелә.

Ярым хәбәрлекнең субъектын белдерүче хәл *кебек, шикелле, сыман, төсле, кадәр, чаклы* бәйлекләрен яки *-дай*, *-ча* кушымчасын алырга мөмкин. Мондый җөмләләрдәге ярым хәбәрлекне җөмләне үзгәртеп төзеп белеп була. Мисалларны күзәтик.

*Ул баладай беркатлы – Бала ничек беркатлы булса, ул да шулай беркатлы.*

*Ул берүзе ике кеше чаклы эшли – Ике кеше күпме эшләсә, ул берүзе шулчаклы эшли.*

*Мин синеңчә саныйм – Син ничек санасаң, мин дә шулай саныйм.*

*Мин синең шикелле тырышам – Син ничек тырышсаң, мин дә шулай тырышам.*

Чагыштыру формаларын алган кисәкләр хәбәрдән башка кисәккә карасалар, ярым хәбәрлек ачык сиземләнми, йомылып кала. *Таудай танкларның дәһшәтләрен күрсә идегез* (Ф. Кәрим) җөмләсендә тулы хәбәрлек – *сез күрсә идегез*, ярым хәбәрлек – *танклар тау кебек зур*, ләкин ул нык томаланган. Шуңа күрә мондый җөмләләрне бер ярым хәбәрлекле гади җөмләләр рәтеннән карамыйлар да.

**Искәрмә.** Бер ярым хәбәрлекле гади җөмләләрне бу китаптагыча төрләргә бүлеп өйрәнү шактый шартлы, чөнки ярым хәбәрлекне кушымчалар белән бергә төрле кисәкләр дә белдерәләр. Тагын шуны да истә тотарга кирәк: бер ярым хәбәрлекле җөмләләрдә ярым хәбәрлек бер генә түгел, берничә була ала. *Миңниса, ике тезен янәшә үк китереп, күлмәге белән каплый да кочаклап утыра* (Г. Бәширов) җөмләсендә тулы хәбәрлек – *Миңниса утыра*, ярым хәбәрлекләр: 1) *ике тезен янәшә үк китереп*, 2) *кочаклап*, 3) *каплый да* (монысы тулы хәбәрлеккә якын тора). Тагын мисал китерик: *Анасы, елмая-елмая, баласын киендерә башлады* (А. Шамов). Биредә тулы хәбәрлек – *анасы*

*киендерә*, ярым хәбәрлекләр: 1) *елмая-елмая*, 2) *баласы киенә. Мин улымны синең кадәр үк киендерә алмадым* (М. Әмир). Биредә тулы хәбәрлек – *мин киендерә алмадым*, ярым хәбәрлекләр: 1) *син киендергәнсең*, 2) *улым киенде.*

## ХӘБӘРЛЕК ҺӘМ МОДАЛЬЛЕК

**§ 273. Гомуми мәгълүмат.** Теләсә кайсы тел синтаксисында гади җөмлә төзелешен тикшерү төп урынны алып тора. Ә гади җөмләнең даими (инвариант) үзенчәлеге – хәбәрлек белән модальлек. Укучыны гади җөмлә белән таныштыра башлаганда ук, хәбәрлек һәм модальлек турында җитәрлек төшенчә бирелде, гади җөмләнең күп кенә категорияләре хәбәрлек һәм модальлеккә бәйле рәвештә аңлатылды. Гади җөмлә синтаксисын тәмамлаганда, җөмләнең бу даими билгеләренә тагын бер тукталу һәм шушы даими билгеләрне гомумиләштереп кую максатка туры килер дип уйлыйбыз.

Искә төшерик. Тел – аралашу коралы, ә сөйләм – аралашу ысулы, ягъни хәрәкәттәге тел. Аралашу бер-береңә яңалык хәбәр итү аркылы бара, яңалык хәбәр ителмәсә, сөйләмнең кирәге дә булмас иде. **Сөйләмнең яңалык хәбәр итәргә сәләтле булуын сөйләмнең хәбәрлеге (предикативность) диләр**.

Сөйләмдә яңалык сөйләүче тарафыннан хәбәр ителә, ә сөйләүче, хәбәр иткәндә, чынбарлыкка – сөйләм эчтәлегенә, сөйләм формасына, тыңлаучыга (укучыга), сөйләү обстановкасына, хәтта үз-үзенә нинди дә булса бер мөнәсәбәт белдерә. **Сөйләмнең чынбарлыкка сөйләүче мөнәсәбәтен белдерергә сәләтле булуын аның модальлеге диләр**.

Хәбәрлек һәм модальлек бары сөйләмдә генә бирелә ала, ягъни сөйләмнән башка хәбәрлек һәм модальлек юк, хәбәрлек һәм модальлектән башка сөйләм була алмый.

Сөйләмнең бу ике даими үзенчәлеген җөмлә генә белдерә ала, җөмлә кисәкләре дә, сүзтезмәләр дә белдерә алмый. Шуңа күрә бары җөмлә генә сөйләмнең төп берәмлеге була ала. Хәбәрлек һәм модальлек тә конкрет рәвештә җөмләләрдә өйрәнелә.

Җөмләне барлыкка китерүдә һәм аны куллануда катнашучы реаль чынбарлык түбәндәге элементлардан тора: 1) сөйләүче, 2) тыңлаучы, 3) җөмлә эчтәлеге (семантикасы), 4) җөмләнең эчтәлеген белдерүче формасы (җөмлә кисәкләре, сүзләрне үзара бәйләүче чаралар, интона-

циясе, сүз тәртибе һ.б.), 5) референт, ягъни җөмлә эчтәлегенең чынбарлыгы, предметы, 6) сөйләү өчен алынган төп төшенчә, ягъни субъект яисә сөйләм предметы, 7) субъект турында әйтелә, хәбәр ителә торган яңалык, ягъни предикат, 8) сөйләм обстановкасы. Җөмлә төзелгәндә һәм аны кулланганда, чынбарлыкның әле генә саналган элементлары үзара тыгыз мөнәсәбәттә торалар. Синтаксис фәне ул мөнәсәбәтләрнең барысын да җентекләп өйрәнергә тиеш. Гомуми тел гыйлемендә, инглиз, рус телләре синтаксисларында алар билгеле дәрәҗәдә өйрәнелгәннәр, ләкин татар синтаксисында чынбарлыкның бу элементларын тану гына бара әле, алар арасындагы мөнәсәбәтләргә игътибар итү дә татарның русча чыккан академик синтаксисында гына бераз урын алган. Хәбәрлек һәм модальлек мөнәсәбәтләрен сөйләүгә күчкәнче, биредә берничә әһәмиятле мөнәсәбәткә аңлатма бирү белән чикләнәбез.

1) Тыңлаучыга (укучыга) нәрсәдер әйтергә кирәк булганда, сөйләүче референтны (хәбәр ителәсе чынбарлыкны) күз алдына китерә, сөйләүченең миендә шул референт чагылыш таба һәм сөйләүченең фикеренә әйләнә, шул фикерне сөйләүче, тел формалары белән төреп, тыңлаучыга әйтә. Референт белән сөйләмнең (җөмләнең) эчтәлеге арасындагы мөнәсәбәтне гомуми тел гыйлемендә денотатив-коннотатив мөнәсәбәт, күбрәк репрезентатив мөнәсәбәт дип йөртәләр, һәм боларны тикшерү сөйләмнең эчтәлеге чынбарлыкны ни дәрәҗәдә чагылдыра дигән сорауга җавап бирү тәртибендә бара. Кайбер хезмәтләрдә менә шушы репрезентатив мөнәсәбәтне хәбәрлекле мөнәсәбәт була дип әйтү күзәтелә. Ләкин бу дөрес түгел. Репрезентатив мөнәсәбәт хәбәр итүдә (хәбәрлектә) төп рольләрнең берсен уйный, ләкин ул хәбәрлекле мөнәсәбәт түгел әле.

2) Хәбәр итү тыңлаучы өчен эшләнә, димәк, җөмләнең эчтәлеге белән тыңлаучы арасында да мөнәсәбәт урнаша. Бу мөнәсәбәт сөйләмнең эчтәлеге тыңлаучыга ни дәрәҗәдә аңлашыла дигән сорауга җавап бирү тәртибендә тикшерелә. Бу төр мөнәсәбәтне гомуми тел гыйлемендә прагматик мөнәсәбәт дип атыйлар. Бары менә шул прагматик мөнәсәбәтнең нормада булуы гына сөйләүче белән тыңлаучы арасында җөмләләр белән аңлашуны дәвам итүгә китерә. Димәк, хәбәрлекле мөнәсәбәт булсын өчен, прагматик мөнәсәбәт нормада булырга тиеш, ягъни җөмлә эчтәлеге тыңлаучыга мөмкин кадәр тулы барып җитәргә, аңлашылырга тиеш.

3) Хәбәрлекле мөнәсәбәт урнашсын өчен, җөмлә эчтәлеге белән формасы арасында да тиешле мөнәсәбәт сакланырга тиеш. Җөмлә эчтәлеге референтны тулырак бирсен, эчтәлек тыңлаучыга тулырак барып җитсен өчен, алынган эчтәлек үзенә хас формага төренгән булырга тиеш.

**§ 274. Хәбәрлекнең төп билгеләре.** Әле генә әйтелгән өч төрле мөнәсәбәт хәбәр итүнең (хәбәрлекнең) нигезендә ята. Хәбәрлек үзе – сөйләм субъекты (предметы) һәм предикаты арасындагы мөнәсәбәт, бәйләнеш. Берәр эш-хәл турында хәбәр итүне гомуми тел гыйлемендә пропозиция дип атыйлар, ул хәбәрлекнең эчтәлеген тәшкил итә, ә хәбәрлекнең формасы җөмләнең кайсы да булса бер моделе рәвешендә бирелә. Димәк, һәрбер грамматик күренеш кебек үк, хәбәрлек ике яклап карала: эчтәлек һәм форма якларыннан.

Сүз төшенчәләрне гомумиләштереп атый, сүзтезмә – конкретлаштырып атый. Сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең атау функциясен гомуми тел гыйлемендә номинатив функция яки номинативлык (атаулык) дип йөртәләр. Хәбәр итәргә кирәк булганда, менә шул төшенчәләрне атаучы сүзләр яки сүзтезмәләр үзара субъект-предикат буларак бәйләнешкә керәләр. Бу бәйләнеш ике составлы җөмләләрдә ия-хәбәр бәйләнеше буларак формалаша, ягъни субъект та, предикат та аерым сүзләр я сүзтезмәләр белән (эксплицит) бирелә, ә бер составлы җөмләләрдә субъект-предикат бәйләнеше имплицит бирелә, икенче төрле әйткәндә я субъект бирелми, бирелсә дә ия белән түгел, башка кисәк (тәмамлык) белән бирелә, я предикат аерым сүз яки сүзтезмә белән бирелми, бары сүз сөрешеннән яисә интонациядән генә аңлашыла.

Мәсәлән, *Бала укый* – җөмлә, ул атап кына калмый, хәбәр итә, чөнки ике сүз – субъект һәм предикатны белдерүче сүзләр хәбәрлекле мөнәсәбәткә кергәннәр, димәк, җөмлә моделе төзегәннәр. *Хатны язып була* җөмләсендә предикат кына сүзтезмә белән бирелгән, ләкин ул хәбәр итә, субъект бирелә алмый, чөнки ул теләсә кем булырга мөмкин, аның теләсә кем булуы татар телен белгән һәр кеше өчен ачык. Мондый очракта субъект-предикат мөнәсәбәтен, ягъни хәбәрлекле мөнәсәбәтне имплицит рәвештә бирелгән дип әйтәләр. *Кыш* сүзе, җөмлә интонациясе белән әйтелгәндә, шулай ук хәбәр итә, анда да хәбәрлекле мөнәсәбәт бар: кышның булуы хәбәр ителә, ягъни *кыш* – субъект, ә предикат аның булуын хәбәр итә торган хәбәр итү интонациясе.

Җөмләдә субъект-предикат мөнәсәбәте хәбәрлекле мөнәсәбәт дип атала, ә аның нәтиҗәсе – хәбәрлек була. Бары хәбәрлекле мөнәсәбәт кенә җөмлә оештыра ала.

Хәбәрлекле мөнәсәбәттән тыш җөмләдә төгәлләүле (конкретлаштыручы) һәм аныклаучы мөнәсәбәт тә күзәтелә. Соңгылары хәбәрлекле мөнәсәбәткә керә торган төшенчәләрне төгәлләү, аныклау хезмәтен башкаралар. Мәсәлән, *Минем бабам – әтиемнең әтисе – сугыштан яраланып кайтты* (М. Әмир). Бу җөмләдә гомумән бабай турында гына сүз бармый, ул төшенчә, иң элек, төгәлләнә (конкретлаштырыла): гомумән *бабай* түгел, ә *минем бабай*, һәм шунда ук аныкландырыла да: *әтиемнең әтисе* дип өстәлә. Предикат та *кайтты* дигән гомуми төшенчәдән генә тормый, ул *сугыштан* һәм *яраланып* сүзләре белән төгәлләнгән, конкретлаштырылган.

Хәбәрлекле мөнәсәбәт янында төгәлләүле яки аныклаулы мөнәсәбәт тә булса, җөмлә җәенкеләнә.

Мөстәкыйль җөмлә оештыра торган хәбәрлек **тулы хәбәрлек** яисә **мөстәкыйль хәбәрлек** дип атала. Моннан тыш җөмләдә тулы булмаган хәбәрлек тә һәм ярым хәбәрлек тә булырга мөмкин.

Тулы булмаган хәбәрлек кушма җөмләләрдә күзәтелә. Тезмә кушма җөмләләрдә соңгы җөмлә генә тулы хәбәрлекле була, алдагылары тулы булмаган хәбәрлеккә ия булалар, чөнки аларында хәбәр итүнең тәмамланмаганы сизелеп тора; иярченле кушма җөмләләрдәге иярчен җөмләләрдә хәбәрлекнең тулылыгы тагын да кимрәк була, шуңа күрә иярчен җөмләдәге хәбәрлекне иярчен хәбәрлек дип атау да очрый. Синтетик иярчен җөмләләрдәге хәбәрлек мәгънә ягыннан атауга (номинациягә) якын була, ләкин формаль яктан синтетик иярчен җөмләдә җөмлә моделе саклана, шуңа күрә ул иярчен кисәкләр рәтеннән түгел, ә иярчен җөмләләр рәтеннән санала.

Ярым хәбәрлек исә җөмлә төземи, ягъни ул җөмлә моделе белән бирелми, аерым кисәкләр һәм кушымчалар ярдәмендә генә бирелә. Ярым хәбәрлеге булган җөмләне бер ярым хәбәрлекле гади җөмлә дип таныйлар.

**§ 275. Модальлекнең төп билгеләре.** Сөйләмнең һәм җөмләнең икенче аерылгысыз билгесе – модальлек, ягъни сөйләүченең чынбарлыкка нинди дә булса бер төрле мөнәсәбәте. Чынбарлык нинди өлешләрдән тора дигән сорауга югарыда өлешчә җавап бирелгән иде.

Биредә аны тулыландырып саныйк. Чынбарлыкның өлешләре: 1 референт, 2) җөмлә эчтәлеге, 3) җөмлә формасы, 4) тыңлаучы, 5) сөйләм обстановкасы, 6) репрезентатив мөнәсәбәт, 7) прагматик мөнәсәбәт, 8) җөмлә эчтәлеге һәм формасы арасындагы мөнәсәбәт, 9) хәбәрлекле мөнәсәбәт. Сөйләүченең боларга булган төрле мөнәсәбәтен тел чаралары ярдәмендә белдерү җөмләнең модальлеге була.

Сөйләүченең чынбарлыкка булган гомуми мөнәсәбәтендә аның хәбәрлеккә төбәлгән мөнәсәбәте аерым урын тота. Сөйләүче хәбәр итүнең күп төрләрен билгели: тыныч хикәяләү рәвешендә хәбәр итүме, сорау, боеру формасындамы, әллә төрле кичерешләрне хәбәр итүме – боларның барысын да сөйләүче билгели, һәм чынбарлыкның башка өлешләренә булган мөнәсәбәтеннән чыгып билгели. Кайбер очракларда сөйләүче субъектның чынбарлыкка мөнәсәбәтен дә үз өстенә ала. Мәсәлән, *Маратның укыйсы килә* җөмләсендә субъектның (*Маратның*) теләге хәбәр ителә, ул теләкне субъектка сөйләүче йөкли.

Тел гыйлемендә модальлекне объектив һәм субъектив дигән төрләргә бүлү бар. Ләкин модальлекне сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәте дип аңлаганда, модальлек һәрчак субъектив булырга тиеш. Шуңа күрә модальлекне рациональ һәм эмоциональ дигән төрләргә бүлү дөресрәк булыр дип уйланыла. Сөйләүченең чынбарлыкка рациональ мөнәсәбәте – аның акылына нигезләнгән мөнәсәбәт, ә эмоциональ мөнәсәбәте – хисләренә нигезләнгән мөнәсәбәт.

Сөйләүченең чынбарлыкка эмоциональ (хис) мөнәсәбәте (эмоциональ модальлек) гадәттә тойгылы җөмләләрдә күзәтелә, ә рациональ (акыл) мөнәсәбәте (рациональ модальлек) хикәя, сорау, боерык җөмләләрдә була.

Төрле модаль мәгънәләрне җөмләдә күптөрле чаралар белдерә: интонация, сүз тәртибе (уңай һәм кире), наклонение формалары, модаль мәгънәле кушма фигыль хәбәрләр, модаль сүзләр, кереш сүзләр, ымлыклар, кисәкчәләр, ымлыклар, риторик сорау формалары, махсус синтаксик конструкцияләр, кабатлаулар, хәбәр составындагы хикәяләү, сорау, боеру, тойгы белдерүче башка чаралар.

«Гади җөмлә синтаксисы» бүлегендә модальлекне белдерүче бу төр чаралар үз урыннарында исәпкә алындылар, бары махсус синтаксик конструкцияләргә генә моңа кадәр урын бирелмәде.

Әйтергә кирәк: эмоциональ модальлекне белдерүче махсус синтактик конструкцияләр (төзелмәләр) татар синтаксисында җентекләп өйрәнелмәгән әле. Шулай да, башка телләрдәге кебек, татар телендә дә эмоциональ модальлекне белдерүгә хезмәт итә торган төзелмәләргә синтаксик фразеологизмнарны һәм кабатлауларны (редупликация очракларын) кертергә була.

**§ 276. Модальлекнең синтаксик фразеологизмнарда бирелеше.** Сүзләр бәйләнешенең хәзерге нормаларына сыймый торган сүзтезмәләр һәм җөмләләр синтаксик фразеологизм дип аталалар. Алар гадәттә тулы хәбәрлеккә ия булалар (нәрсә булса да хәбәр итәләр), ләкин үзенчәлекле эмоциональ модальлек белән характерланалар. Мәсәлән, *Җыелыш димәсәң, хәтере калыр* җөмләсендәге сүзләрнең грамматик бәйләнешләреннән чыгып, аны «хәрефкә-хәреф» аңласак, җөмлә *кемдер җыелышны җыелыш димәгән, шуңа күрә кемнеңдер аңа хәтере калган* дигәнне хәбәр итә дияр идек; ләкин татар телендә сөйләшүчегә ачык: җөмлә бары *Җыелыш начар үтте* дигәнне генә хәбәр итә. Моны гади генә хикәяләп хәбәр итми, ә көчле ирония белән хәбәр итә, ягъни хәбәрлеккә эмоциональ модальлек өсти.

Флектив телләр белән чагыштырганда, агглютинатив телләрдә нормадан читләшкән бәйләнешләр (синтаксик фразеологизмнар) сирәгәк очрый булса кирәк. Мәсәлән, рус телендә эмоциональ модальлек көчле булганда, синтаксик фразеологизмның бик күп төрләре күзәтелә, ә татар телендә алар сирәгрәк очрыйлар. Хәер, моның татар телендә синтаксик фразеологизмнарның әле өйрәнелмәгәнлек нәтиҗәсе булуы да мөмкин.

Хәзерге өйрәнелү дәрәҗәсеннән чыгып, татарчада түбәндәге синтаксик фразеологизмнарны күрсәтергә мөмкин:

1. Сөйләүче хәбәрлекне гадәти күренеш дип карый: *Өй өй инде*. Бу җөмләне 27 нче модельнең стилистик формасы дип әйтергә була. Биредә эмоциональ модальлек гадәтилек төсмерен көчәйтүгә кайтып кала.

2. Сөйләүче хәбәрлекнең югары дәрәҗәдә булуын әйтергә тели: *Менә, ичмасам, тавыш!* яки *Менә моны тавыш дияргә дә ярый!*

Биредә беренче җөмлә – 48 нче модельнең тойгылы варианты, икенчесе – кушма төзелешле. Соңгысының вариантлары: *Менә моны тавыш дисәң дә артык түгел! Менә моны тавыш дисәң дә харам түгел!*

3. Сөйләүче хәбәрлекне ирония белән әйтә, аның гадәтилектән дә түбән булуына басым ясый: *Бәйрәме бәйрәм түгел! Бәйрәм димәсәң хәтере калыр.*

4. Сөйләүче хәбәрлекне үзенең катгый карарына кушып әйтә: *Барырга булгач барырга! Барырга тек барырга!*

5. Сөйләүче бу хәбәрлекнең башкалардан өстенрәк булуына басым ясый: *Бәлешнең дә бәлеше!*

6. Сөйләүче күтелгәннең булуына шат: *Моны кем бүләк димәс!*

7. Сөйләүче гаҗәпләнеп хәбәр итә: *Нинди кешеләр алар!*

8. Сөйләүче кемнедер, нәрсәнедер гадәттән тыш хуплый я тискәре мөнәсәбәт белдерә: *Әй, син мошенник! Егет икәнсең! Әй, бу туган дигәннәре!*

9. Сөйләүче хәбәрлекнең вакытлы булмавына басым ясый: *Анда сөйләшү кайгысы түгел әле.*

10. Сөйләүче субъектның хәрәкәтен хупламый: *Дәшмичә торса ни була!*

11. Сөйләүче хәбәр ителгәнне дөрес дип, бердәнбер дип таба: *Бар шатлыгы – балалар! Балалар белән шатланудан башканы белми!*

12. Сөйләүче хәбәр ителгәнне мөмкин дип саный: *Моның турында уйларга була. Ял итәр җир табып була.*

13. Сөйләүче хәбәр ителгәнне әһәмиятсез дип таба: *Миңа соң нәрсә! Аңа соң нәрсә!? Исе китә миңа аның!*

14. Сөйләүче хәбәр ителгәнне дөрес дип таба: *Ул белмичә кем белсен! Өйгә кайтмыйча кая кайтасың! Моннан башка кайда ял итәсең! Эштән башка нәрсә турында сөйләшәсе!*

15. Кайбер сүзләрне кире мәгънәдә кулланудан сөйләүченең гаҗәпләнүе көчәя: *Кирәк бит шундый бәхетсезлеккә тап булырга! (Кирәк* сүзе кире мәгънәдә кулланылган*); Монда нәрсә генә юк! (Юк* сүзе *бар* мәгънәсен бирә*); Нәрсә бар соң монда! Ул ни өчен кайгырып торсын ди! Тишек авыз нәрсә сөйләмәс!*

Өстәп әйтергә кирәк: риторик сорау җөмләләр дә, сорауны түгел, ә икеләнүне, хиснең күплеген белдерүче формалар буларак, синтаксик фразеологизмнар рәтеннән каралалар: *Әллә күрше авылга барыргамы?! Шатлыкмыни бу!?*

**§ 277. Модальлекнең кабатлаулар ярдәмендә бирелеше.** Сүзләрне кабатлап куллануны гомуми тел гыйлемендә редупликация күре-

неше диләр. Татарчада бу күренешне өйрәнеп, Ф.Г. Галләмов махсус диссертация язган иде, шуңа карамастан бездә кабатлауларның сере ачылып җиткән дип әйтеп булмый әле.

Сүзләр үзгәрмичә дә, бераз үзгәрешләргә очрап та, бәйләүче чараларсыз да, бәйләүче чаралар белән дә кабатлана алалар. Кабатлауларны менә шул үзенчәлекләренә карап төркемләү кабул ителгән. Һәрбер төркемдә аларның модаль мәгънәләрен табарга тырышалар.

1. Сүзләр үзгәрешсез кабатланганда, алар арасында тезүле бәйләнеш интонацион чара белән генә белдерелә. Бу төр кабатлауны кулланып, сөйләүче билгенең, хәлнең артыклык дәрәҗәсендә булуына, гадәттән тыш булуына басым ясый: *Эре-эре күбәләкләр оча. Матур-матур балалар уйный. Биек-биек агачлар үсә. Йөзе таң нуры шикелле, алсу-алсу. Ул яза-яза арып бетте* (М. Максуд). *Мин бик-бик бәхетле* (А. Гыйлаҗев). *Ул өстән-өстән генә тикшереп чыкты.*

Кайбер төр фигыльләр, үзгәрмичә генә кабатланып, тәвәккәл шарт модаль мәгънәсен белдерә: *Әйткәч-әйткәч, рәхмәтне зуррак хөрмәт өчен әйтергә кирәк* (Т. Миңнуллин). *Баргач-баргач, алып та кайтырга кирәк иде* (Х. Сарьян). *Ташлагач-ташлагач, яңадан тартмаска иде* (Ә. Еники). *Булган-булган, дүрт өйле булсын* (әкият).

2. Үзгәрмичә кабатланган сүзләр арасында *да/дә/та/тә* теркәгечләре килсә, сөйләүче мәгънәне көчәйтә, аңа хис белән хәбәр итү төсмерен өсти: *Әрәмәсе дә әрәмәсе! Әй балан күп үзендә!* (М. Шабаев). *Өстәвенә көне-төне яңгыр да яңгыр!* (Х. Сарьян). *Ләкин кая гына барма, халык та халык!* (Ә. Еники).

Шушы юл белән фигыль кабатланса, мәгънәне хисси көчәйтүгә дәвамлыкның арту төсмере, ышанычлылык та өстәлә: *Сиңа түзмәсә, аңа түзми дә түзми инде ул!* (әкият). *Фрицларны тетрәткән дә тетрәткән инде бу Шүрәле!* («Чаян»). *Менә шулай тын гына утырырга да утырырга...* (Ә. Еники).

3. Үзгәрмичә кабатланган сүзләр арасында *ла/лә яки дек/тек* кисәкчәсе кабатланганда, сөйләүченең куаныч, сөенеч, соклануы белдерелә: *Сулары ла сулары, көймәдә барулары* (Н. Арсланов). *Әй, җиләге лә җиләге! Өзәсең дә аласың* (З. Нури). *Менә бу эшләпә дек эшләпә! – диләр* (Ә. Еники).

Кабатланган фигыльләр арасында *дек/тек* кисәкчәсе килгәндә, тәвәккәллек яки катгыйлык модаль мәгънәсе дә сиземләнә: *Мин үзем*

*барам тек барам!* (М. Гафури). *Гәрәй! Синең помошникка бераз эләкте... Эләкте тек эләкте* (Ш. Камал).

4. Кабатланган сүзнең икенчесе инкяр күрсәткечен алганда, сөйләүченең чынбарлыкка билгесезлек төсмерен бирүе күрсәтелә: *Кирәксә-кирәкмәсә, килә дә керә* (К. Тинчурин). *Караса-карамаса, янында булсын* (Ш. Камал). *Редактор исә, теләдеме-теләмәдеме, тәнкыйтьче дә була* (М. Максуд).

Шушы ук модаль мәгънәне бераз көчәйтеп, бу төр кабатлаулар янында *да... да* парлы теркәгече дә килә ала: *Имтихан тотып, бик арыдыңмы, Рокыя? – Арыдым да, арымадым да шунда* (Ф. Әмирхан). *Татарчага охшаган да охшамаган да бер тел белән мөнәҗәт әйтәләр* (Х. Сарьян).

Барлык-юклык фомасында кабатланган сүзләр янында бүлүче теркәгечләр килгәндә, билгесезлек мәгънәсе тагын да көчәя: *Я кайтырбыз, я кайтмабыз туып үскән илләргә* (җыр). *Бибисара түтинең бу сүзләрен әллә ишетте, әллә ишетмәде* (Г. Әпсәләмов).

*Ни... ни* парлы теркәгече, мондый кабатлаулар янында килеп, билгесезлекне битарафлыкка якынайта: *Монда утырдың ни, утырмадың ни* (Ф. Хөсни). *Син чакырганга карап, монда килдең ни, килмәдең ни!* (Ш. Камал).

Шарт фигыль барлык-юклыкта кабатланып, алар янында *да... да* теркәгече килсә, билгесезлек модаль мәгънәсе белдерелә: *Теләсәң теләмәсәң дә, йөрешергә туры килә* (М. Мәһдиев). *Да... да* теркәгече кулланылмаска да мөмкин: *Килешсә-килешмәсә, иң элек шул турыда сорашырмын* (Ф. Хөсни).

Юклык-барлык кабатлануы да күзәтелә, бу очракта ышанычлылык, катгыйлык модаль мәгънәсе сиземләнә: *Әллә безнекеләр килеп җитәләр, диме? – Җитәләр генә түгел, җиткәннәр инде* (Г. Ибраһимов). *Белү генә түгел, мин ул эшне белеп оныткан инде* (К. Тинчурин).

5. Кабатланган фигыльләр үзара шарт формасы белән бәйләнгән булса, шикләнеп әйтү, битарафлык модаль мәгънәсе сиземленә: *Моны үзе кичергән кеше генә аңласа аңлар* (Ә. Еники). *Без синең янга төшмибез, үлсәк үләбез, ләкин төшмибез* (А. Расих). *Килсә килә икән бәхет!* (А. Гыйлаҗев).

Шушы ук кабатлау, юклыкны алып, тагын кабатлана, ләкин дүртенче урынны *юк* сүзе ала, модаль мәгънә – битарафлык, билгесезлек:

*Барсам бардым, бармасам юк, – дип сөйләнә* (әкият). *Булса булыр, булмаса юк* (Х. Сарьян).

6. Кабатланган фигыльләр, кире шарт мөнәсәбәтендә торып, *-са да* формасы белән бәйләнсәләр, сөйләүче чынбарлыкка үзенең битарафлыгын, икеләнүен, шөбһәләнеп әйтүен белдерә: *Ни уйласа да уйлангандыр* (Э. Касыймов). *Кемне сөйсә дә сөйгән инде* (С. Хәким). *Дөнья булгач, ишетмәсәң дә ишетерсең* (Х. Сарьян).

Шушы кабатлау дүртле кабатлауга әйләнеп әйтелгәндә, ихтыярсызлык модаль мәгънәсе белдерелә: *Карчык ашаса да ашый, ашамаса да ашый* (әкият). *Барсам да бардым, бармасам да (бардым)* (Г. Әпсәләмов).

7. Кабатланган сүзләр арасында *дисәң, дигәч, булгач, калгач, икән* кебек сүзләр килсә, хәл кылу, катгыйлык, ис китү кебек тойгылар белдерелә: *Егет сүзе бер булыр, китәргә дигәч китәргә!* (М. Хәбибуллин). *Барырга булгач барырга инде* (С.Сабиров). *Булмый дигәч булмый* (Х. Сарьян). *Табарга калгач табыла инде ул* (М. Әмир). *Бармыйсың икән бармыйсың, көчлек эш түгел* (Ф. Хөсни). *Менә врач, ичмасам! Белә дисәң дә белә* (Ф. Шәфигуллин). *Буе дисәң буе, сыны дисәң сыны бар* (Ф. Шәфигуллин). *Карачкы дисәң карачкы түгел, кеше дисәң кеше түгел* (Н. Дәүли). *Чәчкеч белән икән чәчкеч белән* (М. Мәһдиев). *Туй булгач туй бит инде* (Х. Сарьян).

8. Кабатланган сүзләр ия-хәбәр мөнәсәбәтендә торганда, сөйләүче эш-хәлне ышаныч белән хәбәр итә: *Ә хатынының бәйләнүе бәйләнү! Аның бер урында чытырдавы чытырдау иде. Бал да – бал, бу да – бал, шикәр дә – шикәр, бу да – шикәр* (Ф. Шәфигуллин). *Җәннәт тә җәннәт, бу да җәннәт* (Г. Гобәй). *Абый бирешми, аның үз туксаны туксан* (М. Шабаев). *Ләкин аның үз хәле хәл иде* (А. Расих).

9. Кабатланган сүзнең берсе аергыч, икенчесе хәбәр булып формалашканда, чарасыз тәвәккәллек модаль мәгънәсе аңлашыла: *Беткән баш беткән! Мин тәвәккәлләргә булдым* (Г. Бәширов). *Я, ярар, булган эш булган, буявы сеңгән!* (М. Мәһдиев). *Үтәсе юл үтелгән, кире кайтып булмый* (Х. Сарьян).

10. Кабатланган сүзнең берсе (күбрәк беренчесе) III зат тартым һәм төшем килеше кушымчаларын ала, бу очракта билгесезлек, нәтиҗәсезлек модаль мәгънәсе төсмерләнә: *Атуын атканнар да ничек итеп белешергә белмичә аптырап торалар* (мәзәк). *Килүен килер инде*

*ул* (Ш. Маннур). *Сезнең белән сөйләшү файдасыз файдасызын, шулай да әйтим инде* (М. Максуд). *Юк, җәллим дигәч тә, ул кадәрле үк түгел түгелен* (Г. Мөхәммәтшин).

11. Кабатланган сүзнең берсе юнәлеш килеше формасын алганда, билгесезлек модаль мәгънәсе төсмерләнә: *Син болай әйбәт сикерә идең сикерүгә* (Ф. Хөсни). *Инеш суы чисталыкка чиста, ләкин кояшта җылынган*.

12. Кабатланган сүзнең беренчесе чыгыш килешендә торганда, артыклык дәрәҗәсенә якын модаль мәгънә аңлашыла: *Яңадан яңа өйләр тезелгән. Катыдан каты шикәрне тыныч кына ярып утыра иде. Усалдан усал этләр чыгып өрә*.

13. Кабатланган сүзнең беренчесе иялек килешендә килгәндә дә, артыклык дәрәҗәсе мәгънәсе аңлашыла: *Баһадирның баһадиры иде ул! Ул шаһлар шаһы булган ди! Гүзәлләрнең гүзәле иде ул!*

14. Кабатланган сүзләрнең беренчесе икенчесенә аергыч булып килсә, гаҗәпләнү модаль мәгънәсе аңлашыла: *Ат чаклы ат югалган!. Арыслан тикле арысланны кулга ияләштерәләр!* (М. Шәрифуллин).

15. Кабатлауларның беренчесе икенчесенә хәл булып килсә, катгыйлык, артыклык дәрәҗәсе модаль мәгънәләре сиземләнә: *Юк, очрамагач очрамый ул!* (Н. Фәттах). *Күргән саен күрәсе, сөйгән саен сөясе килеп тора. Наҗия булып Наҗия килде* (М. Хәбибуллин). *Тау булып тау картая* (Ә. Баян). *Ул киткән көе китеп барды* (Ә. Фәйзи). *Кайткан кайтыйм инде – кайтырга уйлагач кайтыйм инде* (Ф. Хөсни).

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк: синтаксик фразеологизмнарның үзләрен ачыклау, аларның һәм кабатлауларның модаль мәгънәләрен ачу буенча бездә махсус тикшеренүләр үткәрәсе бар әле.

# КУШМА ҖӨМЛӘ СИНТАКСИСЫ

**§ 278. Гомуми мәгълүмат.** Сөйләм төзелешен тулы итеп күз алдына китерү өчен, җөмләләрнең төрләрен, модельләрен, сүзләр бәйләнешен, аларның урнашу тәртипләрен белү генә җитми, бәлки җөмләләрнең, үзара бәйләнешкә кереп, сөйләм оештыруларын да өйрәнергә кирәк. Чөнки сөйләм бер җөмләдән генә тормый, бәлки бик күп җөмләләр кушылмасыннан ясала. Сөйләм барышында логик эзлеклелек булсын өчен, мөстәкыйль булмаган җөмләләр дә, мөстәкыйль җөмләләр дә, хәтта абзацлар да үзара бәйләнгән булырга тиешләр. Мөстәкыйль булмаган җөмләләр, үзара оешып, бер синтаксик бөтен – кушма җөмлә хасил итәләр. Мөстәкыйль җөмләләрнең һәм абзацларның үзара бәйләнешләрен өйрәнү өчен, сөйләм тоташ текст хәлендә алына.

Кайбер белгечләр гади җөмлә – гади уйны, кушма җөмлә катлаулы уйны белдерә дип раслыйлар. Бу чынбарлыкка һич тә туры килми, чөнки җәенке гади җөмләдә фикер, кушма җөмләдәге фикергә караганда, бик күпкә катлаулы булырга мөмкин. Гади һәм кушма җөмлә бер-берсеннән төзелешләре белән генә, ягъни структур яктан гына, аерылалар.

Кушма җөмлә, гади җөмлә кебек үк, бербөтен тәшкил итәргә тиеш. Әгәр дә шулай булмаса, ул мөстәкыйль җөмләләргә таркалыр иде. Бу бөтенлек анда мәгънәнең эчке бербөтенлеге, аерым өлешләренең структур яктан оешканлыгы һәм бер-берсенә грамматик яктан бәйләнгән булуы нәтиҗәсендә барлыкка килә.

Кушма җөмлә эчендәге аерым җөмләләр төзелешләре ягыннан мөстәкыйль гади җөмләләргә төрле дәрәҗәдә охшыйлар, ләкин алар кушма эчендә мөстәкыйль булмыйлар, мәгънә һәм интонацион яктан тәгәлләнмәгән булалар. Димәк, кушма җөмләне тәшкил итүче җөмләләр, бер-берсеннән аерылып, аерым мөстәкыйль җөмләләр төзи алмыйлар. Бу соңгы фикергә игътибарны тагын бер мәртәбә юнәлдерергә кирәк, чөнки тюркологиядә кушма эчендәге аерым җөмләләрне билгеләүгә

карата ялгыш фикер таралган: күп кенә тюркологлар төрки телләрдәге иярчен җөмләләрдән мөстәкыйльлек таләп итәләр, мөстәкыйльлек булмаса, иярчен җөмлә дә юк, шуңа күрә төрки телләрдә рус телендәге кебек иярченле кушма җөмлә булмый дип исбатларга тырышалар. Мондый тюркологлар рус телендәге иярчен җөмләләр мөстәкыйль була дип уйлыйлар. Ә нәкъ менә рус телендә аларның мөстәкыйль булмаска тиешлекләре исбатланганын исәпкә алмыйлар. Рус галиме Ф.Ф. Фортунатов кушма җөмләнең бары мөстәкыйль булмаган җөмләләрдән генә тора алуын XIX йөздә үк исбатлаган.

**§ 279. Кушма җөмләне семиотик билгеләү мәсьәләсе**. Семиология (башкача: семиотика) ул билге һәм билге системаларын өйрәнүче гомуми теория. Билге («знак», мәсәлән, сүз, сүзтезмә, җөмлә) ике өлешнең (синтактиканың һәм семантиканың) аерылгысыз берлеге итеп прагматик планда өйрәнелә. Синтактика – билгенең формасы, семантика – билгенең мәгънәсе, ә прагматика – билгенең тыңлаучыга, укучыга, билгене кулланучыга, өйрәнүчегә аңлашылу-аңлашылмавы.

Кушма җөмләләрне тикшергәндә, семиотиклар җөмләнең (билгенең) семантикасы дигән төшенчәгә беренче чиратта мәгънә төзү өчен алынган чынбарлыкны (денотатны, референтны, пропозицияне) кертәләр һәм аны синтаксис фәнендә ситуация дип атыйлар. Татар телендә аны гадәттә эш-хәл дип йөртәләр, шуның белән бергә русларга французчадан кергән ситуация сүзе дә кулланыла. Менә шул ситуация ике яки икедән артык булса, семиотиклар җөмләне кушма дип таныйлар. Алар һәрбер ситуациянең хәбәрлек (ия + хәбәр) мөнәсәбәтендәге сүзләр белән бирелүен таләп итмиләр. Ягъни кушма булу өчен бары ике яки икедән артык ситуация генә кирәк, җөмлә калыбы бер генә булса да ярый, диләр алар. Моны мисалларда күзәтик.

*Кояш күтәрелде, көн җылынды* җөмләсендә ике ситуация бар, икесе дә үзара хәбәрлекле мөнәсәбәткә кергән сүзләр белән бирелгән, ягъни ачыктан-ачык (эксплицит рәвештә) белдерелгән.

*Гали Вәлигә хат тапшырды* җөмләсендә бер ситуация җөмлә калыбы белән бирелгән (*Гали тапшырды*). Семиотиклар монда тагын ике ситуациянең булуын таныйлар: *Вәли хат алды; Хат Галидән Вәлигә күчте*. Бу соңгы ике ситуация җөмләдә җөмлә моделе белән (хәбәрлекле мөнәсәбәттәге сүзләр белән) бирелмәгәннәр, шулай да семиотиклар уенча, бу ситуацияләр дә яшерен (имплицит) рәвештә

белдерелгәннәр булып чыга. Шуннан чыгып семиотиклар *Гали Вәлигә хат тапшырды* җөмләсен кушма җөмлә дип таныйлар.

*Өшегәннән соң мин бик каты чирләдем* җөмләсе дә, семиотиклар фикеренчә, кушма була. Эксплицит рәвештә (ачыктан-ачык) биредә *мин чирләдем* дигән хәбәрлекле кушылма белән бер ситуация бирелгән; икенче ситуация *мин өшедем* мәгънәсеннән тора, монысы имплицит рәвештә (яшерен) бирелгән булып чыга.

*Марат һәм Рөстәм хат язышалар* җөмләсе дә семиотик яктан кушма була, чөнки биредә *Марат хат яза; Рөстәм хат яза* ситуацияләре бар, алар икесе дә яшерен бирелгәннәр, ягъни хәбәрлекле мөнәсәбәттәге сүзләр белән түгел, ә тиңдәш ияләрнең йөкләтү юнәлешендәге фигыль хәбәр белән бер хәбәрлекле мөнәсәбәткә керүе аркылы.

*Марат Рөстәмнән чокыр казытты* җөмләсендә бер ситуация ачыктан-ачык (эксплицит рәвештә) бирелгән: *Марат казытты*, икенче ситуация *Рөстәм казыды* дигәне имплицит (яшерен) рәвештә бирелгән. Бу төр җөмләләр дә кушма җөмләләр эчендә каралалар. Кайбер очракларда аларны бер ярым хәбәрлекле җөмләләр дип тә тикшерәләр.

*Марат портфель сатып алды һәм энесенә җибәрде* җөмләсе дә, семиотиклар фикеренчә, кушма була, чөнки биредә *Марат сатып алды* һәм *Марат җибәрде* ситуацияләре бар.

Хәбәре эзлекле яисә параллель процессларны белдерә торган фигыльләр белән бирелгән гади җөмләләрне дә семиотиклар кушма дип өйрәнәләр. Мәсәлән, *Хәлим шәһәргә барып кайтты* җөмләсендә алар *Хәлим шәһәргә барды* һәм *Хәлим шәһәрдән кайтты* ситуацияләре бар дип саныйлар. *Югары очтан күк ат чабып төшеп килә* (И. Гази) җөмләсендә, семиотикларча фикер йөрткәндә, түбәндәге ситуацияләрне аерып чыгарып була: *Ат чаба; Ат төшеп килә*. Бу ситуацияләрнең беренчесе яшерен (имплицит рәвештә), икенчесе ачыктан-ачык (эксплицит рәвештә) бирелгән. Семиотикларча уйлаганда, бу да кушма җөмлә була.

Шулай итеп семиотиклар грамматик кушма җөмләләрнең һәрберсен һәм грамматик яктан кушма булмаган күп кенә җөмләләрне (тиңдәш кисәкле, фигыль белән бирелгән иярчен кисәге булган, хәбәре йөкләтү, уртаклык юнәлешендәге фигыль белән бирелгән, икенче

ситуация өстәргә мөмкин булган гади җөмләләрне) кушма җөмлә дип таныйлар. Грамматик яктан гади булган җөмләләрне кушма дип таныганда, семиотиклар аларны «имплицит кушма» дип атыйлар.

Кайбер семиотиклар ике-өч ситуациясе булган гади җөмләләрне кушма җөмләгә кертмиләр, бер ярым хәбәрлекле җөмлә дип аерым тикшерәләр һәм аларны асимметрик җөмләләр дип атыйлар. Чөнки, аларча, бу төр җөмләләрдә ике-өч ситуациянең бары берсе җөмлә формасы белән бирелә, ә калганнары җөмлә формасы белән күрсәтелми, димәк, асимметрия (форма белән эчтәлекнең туры килмәве, симметрик булмавы) барлыкка килә.

Билгеле, җөмләләрне семиотик тикшерүне кире кагу дөрес түгел, мондый юл белән өйрәнү дә сөйләм үзенчәлекләрен ачарга ярдәм итә, һәм иң әһәмиятлесе: аны белү гомуми тел гыйлемендә соңгы елларда киң урын алган методлар белән танышырга ярдәм итә.

**§ 280. Кушма җөмләне грамматик билгеләү мәсьәләсе.** Грамматика, семиотика кебек үк, мәгънәгә (семантикага), формага (синтактикага) һәм аларның берлегенә таянып эш итә. Анда да җөмләнең тыңлаучыга аңлашылу дәрәҗәсенә (прагматикага) игътибар ителә. Кушма җөмләне билгеләгәндә, семиотикадан аермалы буларак, грамматика формага таләпчәнрәк якын килә. Кушма булсын өчен, җөмләдә ике-өч ситуация булу һәм аның ачыктан-ачык яисә яшерен һәм теләсә нинди форма белән бирелүе җитми, кушма җөмлә төзүче ситуацияләрнең һәрберсе хәбәрлекле мөнәсәбәттәге сүзләр белән (җөмлә нигезе белән) бирелергә тиешләр. Димәк, кушма дип табылган җөмлә берничә җөмләнең грамматик яктан бергә оешуыннан ясалган дип әйтерлек булырга тиеш. Кушма җөмлә, гади җөмлә кебек үк, бербөтен төзи, аерым җөмләләргә таркалып тормый; гади җөмләдән аермалы буларак, андагы ситуацияләр җөмлә оештыручы кисәкләр (җөмлә модельләре) белән биреләләр.

Кушма җөмлә эчендәге аерым җөмләләр мәгънә һәм форма ягыннан бер-берсенә керешкән, яраклашкан булалар, шуңа күрә кушма җөмлә эчендәге җөмләләр мөстәкыйль булмыйлар. Мөстәкыйльлек кушма эчендәге төрле җөмләдә төрле дәрәҗәдә була. Моны мисалларда күзәтик.

*Көннәр коры торды, икмәкләр вакытында җыелды* кушма җөмләсендә беренче җөмлә дә, икенчесе дә гади җөмләгә якын тора, ләкин

аларны тулы мөстәкыйль җөмләләр дип әйтеп булмый, чөнки алар бер-берсенә тыгыз мәгънә мөнәсәбәтендә торалар.

*Көннәр коры торганга, икмәкләр вакытында җыелды* дигән кушма җөмләдә беренче җөмләнең мөстәкыйльлеге шактый кимегән, аның хәбәре дә гади җөмлә хәбәреннән ераклашкан; икенче җөмләнең мөстәкыйльлеге зуррак, ләкин ул барыбер беренче җөмләсез фикерне тулы хәбәр итә алмый.

*Әтиләр даулаган тынычлыкны саклау – безнең изге бурычыбыз* дигән кушма җөмләдә *Әтиләр даулаган* җөмләсенең мөстәкыйльлеге бөтенләй сизелми, ул соңгы җөмләдән хәтта пауза белән дә аерылып тормый. Ләкин ул – җөмлә, чөнки ул ия-хәбәр бәйләнеше белән (хәбәрлекле мөнәсәбәттәге сүзләр белән) бирелгән. Соңыннан килгән җөмләнең мөстәкыйльлеге зур, ләкин анда мөстәкыйльлеген югалткан *Әтиләр даулаган* җөмләсеннән башка мәгънә тулы булмый.

Югарыда искә алынганча, кушма җөмлә эчендәге бер генә җөмлә дә мөстәкыйль була алмый. Мөстәкыйль булсалар, алар кушма җөмлә төземиләр, аерым-аерым мөстәкыйль гади җөмлә булып калалар. Башкача әйткәндә, кушма җөмлә эчендәге җөмләләрнең мөстәкыйль түгеллеге төрле дәрәҗәдә була һәм мөстәкыйльлек сизелеп тормаслык дәрәҗәдә аз булганда да, кушма җөмлә оеша. Мәсәлән, *Бу начар өйнең эчендә и к м ә г е  ю к  ярлы бар* (Г. Тукай) җөмләсендә *ярлы + бар* хәбәрлекле бәйләнеше чагыштырмача мөстәкыйль булса да, *икмәге + юк* хәбәрлекле бәйләнеше мөстәкыйльлеген бик аз саклаган. Шуңа карамастан Г. Тукайдан китерелгән җөмлә кушма була, чөнки *икмәге юк* семантик яктан аерым ситуацияне (эш-хәлне) белдерә һәм иң әһәмиятлесе: ул үзара хәбәрлекле мөнәсәбәткә кергән сүзләр (җөмлә калыбы) аркылы белдерелә. Димәк, грамматик яктан җөмләнең кушмалыгын билгеләгәндә, андагы җөмләләрнең мөстәкыйльлек дәрәҗәсе беренче роль уйнамый, кушма булса, аның эчендә хәбәрлекле мөнәсәбәткә кергән сүзләр төркеменең (җөмлә калыпларының) берничә булуы гына роль уйный.

**§ 281. Кушма җөмләне гади җөмләдән аеру юллары.** Күп кенә очракта кушма җөмләнең кушмалыгы бик ачык күренеп тора, кайбер синтаксик конструкцияләрнең кушмамы, гадиме икәнлеген аеру кыенлык тудыра. Шуңа күрә җөмләнең кушмалыгын күрсәтеп торган кайбер билгеләрен өйрәнү сорала.

1. Кушма җөмлә төзи торган аерым җөмләләрнең үзләренә генә караган субъектлары (S) һәм предикатлары (P) булырга тиеш. Мәсәлән, *Яңгыр туктады, без урамга чыктык*. Бу конструкция ике җөмләдән тора, һәм аларның үз субъектлары (*яңгыр* һәм *без*), үз предикатлары (*туктады* һәм *чыктык*) бар, аны шартлы билгеләр белән түбәндәгечә белдерәләр: [$S_1$–$P_1$], [$S_2$–$P_2$]. Биредәге ике җөмлә дә ике составлы. Кушма эчендәге җөмлә бер составлы булганда, аны шартлы билгеләр белән күрсәтүдә бераз аерма бар. Мәсәлән, *Көчле янгын башланды, янына бармалы түгел* синтаксик төзелмәсе бер ике составлы, бер бер составлы җөмләдән тора, боларның да үз субъектлары (*янгын* һәм гомумиләштерелгән теләсә нинди зат), үз предикатлары (*башланды* һәм *бармалы түгел*) бар. Бу җөмләнең кушмалыгы шартлы билгеләр белән болай күрсәтелә: [$S_1$–$P_1$], [$S_2$–$P_2$].

2. Җөмләләрнең субъектлары аерым сүз белән бирелмичә, предикатлар гына бирелеп, аларның субъектлары бер үк булмасалар да, җөмлә һичшиксез кушма санала. Мәсәлән, *Аңламагач таякладылар* (Г. Ибраһимов) җөмләсендә ике предикат бар һәм аларның субъектлары бер үк түгелләр, беренчесендә – контексттан аңлашыла торган конкрет зат, икенчесендә – билгесез затлар. Бу синтаксик төзелмә дә шартлы билгеләр белән бәхәссез кушма итеп языла: [$S_1$–$P_1$][$S_2$–$P_2$].

3. Кайбер синтаксик төзелмәләр субъектлары яки предикатлары бер үк булган, ләкин аерым-аерым бирелгән җөмләләрдән торырга мөмкин. Мондый төзелмәләр дә кушма җөмлә рәтеннән каралалар.

Мәсәлән, *Син ярлы идең, ләкин син яхшы идең* (Һ. Такташ) дигән кушма җөмләдә ике җөмлә бар, алардагы субъектлар – бер үк зат (*син*), ләкин алар аерым-аерым бирелгәннәр, шуңа күрә бу төр синтаксик төзелмә кушма җөмлә дип карала. Аны шартлы билгеләр белән болай күрсәтәләр: [$S_1$–$P_1$], ләкин [$S_1$–$P_2$].

Предикатлар бер үк булып, алар аерым-аерым бирелсәләр, җөмлә шулай ук кушма дип карала: *Әнисе әйтте, әтисе әйтте, әбисе әйтте, ә ул тыңламады*. Биредә *әйтте* предикаты һәр субъект янында кабатланып бирелгән, шуңа күрә алар аерым җөмлә төзүче предикатлар буларак кабул ителәләр. Шартлы билгеләр белән ул [$S_1$–$P_1$], [$S_2$–$P_1$], [$S_3$–$P_1$], ә [$S_4$–$P_2$] рәвешендә күрсәтелә һәм кушма җөмлә дип таныла.

4. Синтаксик төзелмәдәге бер үк субъект янында берничә тиңдәш булмаган, бер-берсенә буйсынган предикат килгәндә дә, ул кушма

җөмлә дип танылa. Мәсәлән, *Мин кат-кат укыдым, чөнки аңламаган идем* дигән төзелмәдә бер үк субъект янында ике предикат килгән (*укыдым, аңламаган идем*), ләкин аларны тиңдәш кисәкләр белән бирелгән дип булмый, чөнки алар бер-берсенә ияртү юлы белән бәйләнгәннәр, шуңа күрә икесе ике җөмләнең предикатлары дип каралалар. Димәк, бу җөмлә дә кушма буларак карала. Ул шартлы билгеләр белән болай языла: [$S_1$–$P_1$], чөнки [$S_1$–$P_2$].

Тагын мисаллар. *Мин йөгереп килдем, шулай да арымадым:* [$S_1$–$P_1$], *шулай да* [$S_1$–$P_2$];

*Мин йөгереп килдем, шуның аркасында арыдым:* [$S_1$–$P_1$], *шуның аркасында* [$S_1$–$P_2$];

*Мин йөгереп килдем, шуннан соң арыдым:* [$S_1$–$P_1$], *шуннан соң* [$S_1$–$P_2$];

*Бүген мин бик арыдым, гүя көне буе чабып йөрегәнмен*: [$S_1$–$P_1$], *гүя* [$S_1$–$P_2$] һ.б.

Кушма җөмлә белән гади җөмлә арасында тора торган синтаксик төзелмәләр дә була, болар рәтенә тиңдәш хәбәрле яки тиңдәш ияле җөмләләрне кертәләр.

Мәсәлән, *Кошлар килеп тә җиттеләр, ләкин көзгә тагын китәчәкләр* җөмләсендә *килеп җиттеләр*, *китәчәкләр* предикатлары (хәбәрләре) бар, алар тиңдәшләр, ләкин формалары буенча бик үк тиңдәш тә түгел, чөнки беренчесе үткән заман, икенчесе киләчәк заман формаларын алганнар. Шуңа күрә бу төзелмәне кушма дип тә, гади дип тә аңлатып була. Шулай да җөмләдәге тиңдәш кисәкләрне таныйбыз икән, бу җөмләне тиңдәш хәбәрле гади җөмлә дип әйтергә туры килә. Семиологик яктан ул, билгеле, кушма төргә кертелә, чөнки тиңдәшләнеп килгән кисәге булган җөмләне семиотиклар кушма җөмлә дип билгелиләр.

*Мин суда коенам, чәчрәтәм, уйныйм* җөмләсен дә без тиңдәш хәбәрле гади җөмлә рәтеннән карыйбыз. Семиотиклар аны кушма диярләр иде.

Рус телендә тиңдәш хәбәрләр арасына ия килеп кергәндә, ул хәбәрләрне аерым җөмлә итеп тикшерү очраклары күзәтелә. Мәсәлән, *Шел дождь, и перестал, и вновь пошел* (А. Пушкин) төзелмәсендә ия (*дождь*) тиңдәш хәбәрләр арасына килеп кергән, шуңа күрә ул хәбәрләр аерым җөмлә итеп каралалар, ә китерелгән синтаксик төзелмә

кушма дип танылa. Татар әдәби телендә иянең мондый тәртибе күзәтелми, ул бары гади сөйләмдә генә очрарга мөмкин: *Барып кайттык без, чаңгылар да алып кайттык*. Бу җөмләне чыгарма рәвештә генә кушма дип карарга мөмкин, ә система буларак ул тиңдәш хәбәрле гади җөмлә рәтенә кертелергә тиеш.

Җөмләдә өстәмә хәбәр рәвешендә килгән хәл кисәге булганда да, ул грамматик яктан гади дип танылырга тиеш. Мәсәлән, *Врач, авыруларны карап, кичен шәһәргә китеп барды* (М. Максуд) төзелмәсендә *авыруларны карап* дигән вакыт хәле бер үк вакытта өстәмә хәбәр хезмәтен дә үти, шуңа күрә бу төзелмәне кушма җөмлә итеп карарга тәкъдим итүчеләр дә бар. Ләкин, грамматикада система булдыру максатыннан чыгып, аны аерымланган иярчен кисәкле яки өстәмә хәбәрле гади җөмлә дип тану дөресрәк булыр.

**§ 282. Кушма җөмләләрне төрләргә бүлү мәсьәләсе**. Кушма җөмлә синтаксисының беренче бурычы мөстәкыйль булмаган җөмләләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләрен, һәм аларны белдерүче чараларны өйрәнү, ягъни мөстәкыйль булмаган җөмләләрнең кушма җөмлә эчендә үзара семантик һәм синтактик (формаль) бәйләнешләрен җентекләп тикшерү. Моның өчен гадәттә ике җөмләдән торган кушма җөмләләр алына, һәм аларны **гади кушма җөмлә** дип атау да очрый. Ләкин бу термин синтаксиста ныклап утырып җитмәгән. Мөстәкыйль булмаган җөмләләрнең үзара бәйләнешен тикшергәндә, мисал итеп өч-дүрт җөмләдән торган кушма җөмлә алынса да, аларның икесе арасындагы бәйләнешкә генә игътибар ителә. Шулай итеп тикшерү максатыннан чыгып, башта ике генә җөмләдән торган кушма җөмләләрне аерып алалар.

Кушма җөмлә синтаксисының икенче бурычы – өч-дүрт-биш, хәтта аннан да күбрәк җөмләдән торган кушма җөмләләрнең төзелешен өйрәнү. Моның өчен һәрчак икедән артык җөмләдән торган кушма җөмлә алына, һәм аларны **катлаулы кушма җөмлә** дип атыйлар. Димәк, кушма җөмләләрне иң башта гади кушма җөмлә (ике генә җөмләдән торган кушма җөмлә) һәм катлаулы кушма җөмлә (икедән артык җөмләдән торган кушма җөмлә) дигән төрләргә бүлү кабул ителгән.

Шушы урыннан башлап «Катлаулы кушма җөмлә» дигән бүлеккә кадәр ике генә җөмләдән торган гади кушма җөмләләр тикшереләчәк;

мисалга катлаулы кушма җөмлә китерелгәндә дә, андагы ике җөмләнең үзара бәйләнешләре өйрәнеләчәк.

Бәйләнеш төренә карап, кушма җөмләләр тагын **тезмә кушма җөмлә** һәм **иярченле кушма җөмлә** дигән төрләргә бүленәләр. Тезмә кушма җөмләдәге аерым җөмләләр үзара – **тезү юлы** белән, ә иярченле кушма җөмләләрдәге аерым җөмләләр **ияртү юлы** белән бәйләнәләр.

Җөмләләр арасында тезүле бәйләнешне санау һәм каршылык интонацияләре, тезүче теркәгечләр һәм теркәгеч сүзләр белдерә. Бу чаралар тезүче чаралар дип аталалар.

Җөмләләр арасындагы ияртүле бәйләнешне белдерүче, ягъни ияртүче, чаралар ике төргә бүленәләр: 1) ияреп килгән җөмләнең хәбәре формасын тәшкил итми торган чаралар; 2) ияреп килгән җөмләнең хәбәре формасын тәшкил итүче чаралар. Бу ике төрдәге ияртүче чара белән үзара бәйләнгән җөмләләрнең иярүчесе – **иярчен**, ияртүчесе – **баш җөмлә** дип атала.

Беренче төр ияртүче чаралар иярчен җөмләнең хәбәре составында тормаганлыктан, аерым җөмләләр тышкы яклары белән гади җөмләгә охшаган булалар, аларда мөстәкыйльлек шактый нык сизелә. Мәсәлән, *Көн матурланды, чөнки кояш чыкты* төзелмәсендә ике җөмләнең дә хәбәре гади җөмлә хәбәре кебек тулы формалы, чөнки бәйләүче чара ияртүче теркәгеч (*чөнки*) бер генә җөмләнең дә хәбәре составында килми, җөмләләр арасында аерым урын алып тора. Иярчен җөмләнең хәбәре составында тормый, аның бөтенлеген җуймый торган чараларга башлыча көттерү интонациясе (паузасы), ияртүче теркәгечләр һәм теркәгеч сүзләр, мөнәсәбәтле сүзләр керә. Боларны аналитик ияртүче (кыскартып, аналитик) чара дип йөртәләр. Мәсәлән, *Без беләбез: Мостафин үзенең бу исәбендә ялгышмады* (Ә. Еники). *Менә бер вакыт халык агыла башлады, әйтерсең бөтен дөнья монда җыелды* (Г. Ибраһимов). *Көннәр бик начар торды, шулай да язгы эшләр вакытында тәмамланды* (И. Гази). *Кигән кием ничек туза, яшь гомер шулай уза* (җыр).

Бу төр кушма җөмләләр һинд-европа (шул исәптән, рус) телләрендәге сложноподчиненные исеме белән йөртелә торган кушма җөмләләргә якын торалар. Татар синтаксисында аларны **аналитик**

**иярченле кушма җөмлә** дип атыйлар. Бу төр кушма җөмләләрнең кушмалыгын беркем дә шик астына алмый. 1992 һәм 1995 елларда русча дөнья күргән татар академик синтаксисында бу аналитик иярченле кушма җөмләләрне генә аерым алып сложноподчиненные предложения дип атадык. Бу китапта без ул **аналитик иярченле кушма җөмлә** дигән терминны, кыскартып, **аналитик кушма җөмлә** дип йөртергә тәкъдим итәбез.

Икенче төр ияртүче чаралар ияртүче җөмләнең хәбәре составында килә, шуңа күрә хәбәрнең гади җөмлә хәбәренә охшаган бөтенлеге җуела, иярчен җөмлә, иярчен кисәкләр кебек үк, баш җөмләгә керешеп киткәндәй була. Бу төр ияртүче чараларга шарт фигыль формасы, хәл фигыль, сыйфат фигыль формалары, килеш кушымчалары, рәвеш ясаучы дип йөртелгән кайбер кушымчалар, бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр керә. Бу төр ияртүче чараларны синтетик ияртүче (тагын да кыскартып синтетик) чара дип атыйлар. Мисаллар: *Теләсәң сөйләшербез* (М. Мәһдиев). *Син килгәч сөйләшербез. Әти әйткән сүз дөрес булып чыкты. Радио сөйләгәнне көн саен тыңлыйбыз. Барысын да укытучы өйрәткәнчә эшләделәр. Син килгәннән бирле, эшләр алга бара* һ.б.

Хәбәр формасын тәшкил итә торган чаралар төрки телләрдә тулы бер система тәшкил итәләр, һәм алар ярдәмендә ясалган кушма җөмләләр дә телдә актив кулланылалар. Рус һәм һинд-европа телләрендә бу төр җөмләләр чыгарма буларак кына очрыйлар, система тәшкил итмиләр, шуңа күрә алар кушма җөмлә эчендә бөтенләй каралмыйлар.

Татар синтаксисы фәнендә аерым җөмләләре хәбәр формасы (синтетик чара) аша бәйләнгән кушма җөмләләрне **синтетик иярченле кушма җөмлә** дип атыйлар, без аны, бераз кыскартып, **синтетик кушма җөмлә** дип атыйбыз. Русча басылган академик синтаксиста аларны, **сложноподчиненные** дигән җөмләләрдән аеру өчен, **сложноспаянное** дип атадык. Бу терминны, тюркология өчен, немец тел галиме В.Г. Адмони тәкъдим иткән иде [Адмони, 1982].

Бу параграфта сөйләнгәннәрне схематик рәвештә түбәндәгечә гомумиләштереп күрсәтергә мөмкин.




**Искәрмә 1**. Татар иярченле кушма җөмләләренең рус теле иярченле кушма җөмләләреннән аермасын калкурак күрсәтү өчен, төзелеше буенча рус телендәге **сложноподчиненные предложения**ләрне хәтерләткән татар аналитик кушма җөмләләрен – **иярченле кушма җөмлә** дип, ә рус телендә булмаган, татар теле (гомумән төрки телләр) өчен хас булган синтетик кушма җөмләләрне (русча сложноспаянное дип аталганнарын) **ябешкәкле** яки **берекмәле кушма җөмлә** дип аерып йөртү тәкъдиме дә бар иде. Бу тәкъдим буенча русча язылган татар синтаксисында спаянное предложение дип аталган синтетик иярчен җөмләне **ябешкәк** яки **берекмә җөмлә** дип атарга тиеш идек. Ләкин татар теленең югары уку йорты һәм мәктәпләр өчен язылган дәреслекләрендә **аналитик** һәм **синтетик** терминнары кереп урнашты, менә шул традициядән аерылмас өчен, югарыда китерелгән схемада иярченле кушма җөмлә икегә – аналитик кушма җөмләгә һәм синтетик кушма җөмләгә бүленә дип бирелде. Бәйләүче чараларга да тезүче һәм иярттүче чаралар дип исем кушылды. Ияртүче чаралар да ике исемдә: аналитик чаралар һәм синтетик чаралар дип алынды.

**Искәрмә 2**. Иярчен җөмләләр (синтетигы да, аналитигы да) баш җөмләнең кайсы да булса бер кисәге функциясен үти. Болардан җөмләнең модаль кисәге булган кереш сүз функциясендә килә торганын аерып алып, синтетик кушма һәм аналитик кушма җөмлә белән янәшә модаль кушма җөмлә дигән өченче төрне аерырга кирәк дигән тәкъдим дә бар. Шуңа карамастан бу китапта иярченле кушма җөмлә икегә генә бүлеп бирелде: аналитик кушма җөмлә һәм синтетик кушма җөмлә. Модаль кушма җөмлә аналитик кушма җөмлә эчендә карала.

**§ 283. Кушма җөмләләрне төрләргә бүлүнең кайбер үзенчәлекләре**. Без, рус телен дә өйрәнүчеләр буларак, татар теле кушма җөмләләрен төркемләүнең рус телендәге төркемләүдән аермасына да игътибар бирмичә үтә алмыйбыз.

Иң элек җөмләләр арасында **теркәгечсез бәйләнеш** турында әйтергә кирәк. Рус теленең 1980 елда чыккан академик синтаксисында аерым җөмләләре үзара теркәгечсез (бары интонация белән генә) бәйләнгән кушма төзелмәләр (конструкцияләр) кушма җөмлә эченә гомумән кертелмиләр. Димәк, рус телендә ике яки икедән артык җөмләдән торган синтаксик төзелмәләр башта ук икегә бүленәләр: 1) кушма җөмләләр (сложные предложения), боларда аерым җөмләләр үзара теркәгечләр ярдәмендә бәйләнәләр; 2) җөмләләрнең теркәгечсез бәйләнүе (бессоюзные соединения предложений), боларында аерым җөмләләр үзара теркәгечләрсез, ягъни бары интонация ярдәмендә генә бәйләнәләр. Рус синтаксисында интонация бәйләүче чара булып саналмый.

Һинд-европа телләре, димәк, рус теле өчен мондый бүленеш аңлашыла да, чөнки бу телләрдә теркәгечле бәйләнеш өстенлек ала, интонация ярдәмендә бәйләнеш чыгарма буларак кабул ителә. Төрки телләрдә исә, шул исәптән татар телендә дә сүзләрнең һәм җөмләләрнең интонация ярдәмендә, ягъни теркәгечләрсез, бәйләнеше – гадәти күренеш. Без, тюркологлар, тагын шуны истән чыгармыйбыз: интонация дә (санау, каршылык, көттерү паузалары), теркәгечләр кебек үк, реаль бәйләүче чаралардан санала. Шуңа күрә интонация ярдәмендә генә (теркәгечсез) бәйләнгән җөмләләрдән торган синтаксик төзелмәләрне без кушма җөмлә эчендә карыйбыз, аны кушма җөмлә тышына чыгаруны дөрес түгел дип табабыз. Димәк, татар синтаксисында берничә мөстәкыйль булмаган җөмләдән торган төзелмәләрнең барысын да кушма җөмлә эчендә карау кабул ителгән; аларны кушма җөмлә һәм теркәгечсез бәйләнгән җөмләләр дип икегә бүлү гадәте юк.

Икенчедән, рус телендә иярченле кушма (сложноподчиненные) җөмләләрне, предложения **нерасчлененной** структуры һәм предложения **расчлененной** структуры дип ике зур төркемгә аеру кабул ителгән.

Беренче төр кушма җөмләләрдә иярчен җөмлә баш җөмләдәге бер сүзне-кисәкне ачыклап килә. Мәсәлән, *Он подошел к тому окну, которое выходило в сад* төзелмәсендә икенче җөмлә беренче җөмләдәге

*к тому окну* кисәгенә карый, шуны ачыклап килә. *Не хотелось думать о том, что произошло вчера* төзелмәсендә икенче җөмлә баш җөмләдәге *о том* кисәген ачыклап килә. Менә шул рәвешчә иярчен җөмлә баш җөмләдән аерылып ук бетмәгән булып күренә, шуның өчен иярчен җөмлә н е р а с ч л е н е н н о е дип йөртелә.

Икенче төр кушма җөмләләрдә иярчен җөмлә баш җөмләдәге бер кисәкне генә ачыклап килми, баш җөмләне тулы килеш ачыклый, шуңа күрә ул баш җөмләдән аерылып җиткән булып тоела һәм русча р а с ч л е н е н н ы е структуры дигән төргә карый. Мәсәлән, *Когда я познакомился с Борисом Леонидовичем, он уже отрекся от музыки и всецело посвятил себя поэзии* (К. Чуковский); *Врубель жил просто, как все мы живем* (А. Блок). Бу мисаллардагы иярчен җөмләләр баш җөмләгә тулы килеш карый, аның аерым кисәген генә ачыкламый, дип аңлаталар рус синтаксистлары, шуңа күрә аларны расчлененное дигән төргә караталар.

Татар телендә иярчен җөмләләрне (димәк, иярченле кушма җөмләне дә) бу рәвешле ике төргә аеру кабул ителмәгән, чөнки нинди генә иярчен җөмлә дә баш җөмләнең билгеле бер кисәгенә карый; кайсы да булса бер кисәкне ачыклау аркылы гына баш җөмләгә буйсына. Мәсәлән, *Врубель без барыбыз да яшәгән кебек гади яшәде* төзелмәсендә *без барыбыз да яшәгән кебек* җөмләсе турыдан-туры *яшәде* кисәген ачыклый, һәм шул юл белән генә баш җөмләгә буйсына. Шуңа күрә татар синтаксисында иярченле кушма җөмләләрне нерасчлененное һәм расчлененное дип ике төргә аеру кабул ителмәгән, һәм бу төрләрнең шуңа күрә татарча терминнары да юк.

Ниһаять, кушма җөмләләрне төрләргә бүлүнең тагын бер үзенчәлеге шунда: еш кына, тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрне бер-берсеннән аеру шактый кыенлаша.

Мәсәлән, *Нуриасма кодагыеның бераз көнләшеп карап утыруын сизде һәм аңа тагын кыен булып китте* (Ф. Садриев) төзелмәсе формаль яктан тезмә кушма җөмлә дип таныла, ә семантик яктан биредәге җөмләләр арасында нәтиҗә-сәбәп мөнәсәбәте күзәтелә, алар арасына сәбәп мөнәсәбәтен белдерүче *шунлыктан* мөнәсәбәтле сүзе дә җиңел кереп утыра: *Нуриасма кодагыеның бераз көнләшеп карап утыруын сизде, һәм ш у н л ы к т а н аңа тагын кыен булып китте.* Бу җөмләдә тезүче чара (*һәм*) белән ияртүче чара (*шунлыктан*) бергә

кулланылганнар. Шуңа күрә бу төр җөмлә тезмә төргә дә, иярченле төргә дә карый.

*Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява* (Г. Тукай) төзелмәсендә дә тезүче (*дә-дә*) һәм ияртүче (-*еп*) чара параллель кулланылган. Семантикасы буенча ике җөмлә арасында ияртү, буйсыну мөнәсәбәте күзәтелми.

Җөмләләр арасында каре-каршылык мөнәсәбәте булганда да, синтаксик төзелмәне тезмә кушма җөмлә дип тә, кире җөмләле иярченле кушма җөмлә дип дә була: *Яңгыр күптән яуган, л ә к и н юллар пычрак* (Г. Әпсәләмов) төзелмәсе формаль яктан тезмә кушма җөмләгә каратыла, ә аның синонимы *Яңгыр күптән яуган, шулай да юллар пычрак* иярченле кушма җөмлә дип таныла. Ә семантик яктан болар бер үк җөмлә төрләре булалар.

Синтетик кушма җөмлә белән аналитик кушма җөмлә арасында торучы кушма төзелмәләр шактый очрый.

**§ 284. Җөмләләрнең үзара грамматик һәм структур бәйләнешенә карата**. Югарыдагы параграфларда күренгәнчә, җөмләләр арасындагы төрле мәгънә мөнсәбәтләрен белдерүче чаралар була, һәр чараның үзенә генә хас мәгънәсе бар. Билгеле бер мәгънә мөнәсәбәтенең үзенә хас чара белән белдерелүен җөмләләр арасындагы грамматик бәйләнеш дип атыйлар.

Инде искә алынганча, тезмә кушма җөмләдәге җөмләләр арасында тезүле бәйләнешне санау, каршылык интонацияләре, җыючы, каршы куючы һәм бүлүче теркәгечләр тормышка ашыра. Аналитик кушма җөмләдә аналитик иярчен һәм баш җөмләне бәйләүдә көттерү паузасы (интонациясе), ияртүче теркәгечләр, ияртүче теркәгеч сүзләр, мөнәсәбәтле сүзләр (ягъни аналитик чаралар) катнашалар. Синтетик кушма җөмләдә синтетик иярчен һәм баш җөмләләр үзара кушымчалар, бәйлекләр, бәйлек сүзләр (ягъни синтетик чаралар) ярдәмендә бәйләнәләр. Бу саналган бәйләүче чаралар грамматик чара булып танылсын өчен, һәр чараның үзенә генә хас семантикасы булырга тиеш.

Җөмләләр арасында төп өч төрле грамматик бәйләнеш була, шуңа карап кушма җөмләләр дә тезмә, иярченле (синтетик һәм аналитик) дигән төрләргә аерылалар. Мисаллар югарыда бирелделәр.

Үзара семантик яктан буйсынган җөмләләр арасында грамматик бәйләнештән тыш **структур бәйләнеш** тә күзәтелә, һәм бу төр бәй-

ләнеш тә җөмләләрнең үзара семантик буйсынуларын күрсәтә, шул буйсынуның чагылышы булып тора.

Җөмләләр үзара семантик мөнәсәбәттә торганлыктан, аларда уртак кисәк була, ул уртак кисәк, бер җөмләдә әйтелсә, башкасында кабатланмый, нәтиҗәдә бер җөмлә икенчесе хисабына ким булып формалаша. Бу – структур бәйләнешнең иң еш очрый торган төре. Моны мисалларда күзәтик.

*Монда үзеннән түбәннәр бар, үзе белән бер баскычта торганнар бар* (Ә. Еники). Бу мисалдагы ике җөмлә структур яктан икесенә дә *монда* дигән уртак кисәк булу белән бәйләнгән.

Күп кенә очракларда ике җөмлә өчен дә уртак төшенчәне белдерүче сүз уртак кисәк булып түгел, төрле кисәк булып килергә тиеш була. Мәсәлән, *Өйнең астына тирән итеп нигез салырбыз, юкса (өй) су китеп чери-фәлән итә башлый* (Г. Ибраһимов). Бу мисалдагы җөмләләрдә уртак сүз – *өй*, ул беренче җөмләдә иялек килешен алган, атрибут хезмәтен үти, икенчесендә ул субъектны (ияне) белдерергә тиеш иде, ләкин ул анда кулланылмаган. Беренче җөмлә хисабына икенчесе – ким. Бу да структур бәйләнешнең бер төре хисаплана.

Структур бәйләнешнең янә бер төре буларак, тагын шундый очракны күрсәтергә мөмкин: тиңдәш кисәкләрдәге кебек үк, тезү юлы белән бәйләнгән җөмләләр дә структур яктан оешсыннар өчен, аларның барысы да бер уртак кисәк белән ияртүле бәйләнештә торырга тиешләр. Мәсәлән, *Көне-төне кар ява, җил ыжгыра, туктаусыз буран уйный* (Г. Ибраһимов). Биредәге өч җөмлә үзара тезү юлы белән бәйләнгән, менә шул бәйләнеш һәрбер җөмләнең *көне-төне* кисәген ияртүе белән структур яктан ныгытыла. Без бу хәлне тиңдәш иярчен кисәкләрдә дә күргән идек: *Бакчада ак һәм кызыл чәчәкләр үсә* җөмләсендә *ак* һәм *кызыл* сүзләре арасындагы тезүле бәйләнеш тиңдәш кисәкләрнең *чәчәкләр* кисәгенә иярүләре белән структур ныгытыла (*ак чәчәкләр*, *кызыл чәчәкләр*).

Үзара бәйләнгән җөмләләрнең һәрчак уртак төшенчәләре була. Бу уртак төшенчә аерым сүз-кисәк белән бирелмичә калырга, контексттан аңлашылып торырга да мөмкин. Мәсәлән, *Кар сулары китеп бетте, җир кипте, киң кыр өстен куе яшел уҗым каплап алды* (И. Гази). Бу җөмләләрнең уртак төшенчәләре – ‘елның билгеле бер вакыты’, ул контексттан аңлашыла, һәм һәр җөмлә шул вакыт төшенчәсе белән

ияртүле бәйләнештә тора. Җөмләләр арасында мондый структур бәйләнеш шактый еш очрый.

Кушма җөмләләрнең гомуми үзенчәлекләре белән таныштыру тәмамланды. Хәзер шуны гына әйтәсе калды: кушма җөмләләрне конкрет өйрәнүне мөстәкыйльлекләре бик нык җуелган җөмләләр бәйләнешен анализлаудан башлыйбыз; иң ахырдан мөстәкыйльлеге ныграк сакланган җөмләләр бәйләнешен тасвирлаячакбыз. Шуны күздә тотып, иң элек синтетик кушма җөмләләр тикшерелә.

## ГАДИ КУШМА ҖӨМЛӘЛӘР

## ИЯРЧЕНЛЕ КУШМА ҖӨМЛӘЛӘР

### СИНТЕТИК КУШМА ҖӨМЛӘЛӘР

**§ 285. Гомуми мәгълүмат**. Иярчен җөмләсе баш җөмләгә синтетик чара ярдәмендә бәйләнгән һәм формасы белән гади җөмләгә охшамаган иярченле кушма җөмлә синтетик кушма җөмлә дип атала. Синтетик кушма җөмләдәге иярчен җөмлә синтетик иярчен җөмлә дип атала иде, хәзер бер күнегелгәч, аны синтетик җөмлә дип атау да җитә.

Синтетик бәйләүче чара – ул синтетик иярчен җөмләнең хәбәре формасын тәшкил итүче чара. Составында менә шундый чаралар (кушымчалар, бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр) килгәнлектән, иярчен җөмләнең хәбәре гади җөмлә хәбәре кебек тулы булмый. Мәсәлән, *Ул сизгәнне, мин белмәдем; Син укыган китапны озак эзләдек.* Мондый иярчен җөмләләр баш җөмләгә керешеп, синтезлашып киткән булалар. Менә шуңа күрә аларны синтетик җөмлә дип атыйлар (синтез – ‘кушылу’ сүзеннән).

1992 һәм 1995 елларда русча басылган татар синтаксисында бу төр җөмләләр сложноспаянные дип, ә андагы иярчен җөмлә спаянное дип аталган иде. Югарыда әйтелгәнчә, традициядән читкә китмәс өчен, бу татарча язылган синтаксис китабында аерым җөмләләре үзара синтетик чаралар белән бәйләнгән синтаксик төзелмәне тулы килеш **синтетик кушма җөмлә** дип, ә аның иярчен җөмләсен **синтетик җөмлә** дип атадык. Ул элекке дәреслекләрдә синтетик иярчен җөмлә дип йөртелә иде.

Инде югарыда әйтелгәнчә, төрки телләрдә бик зур система булып үскән синтетик кушма җөмләләр һинд-европа телләрендә, шул исәптән рус телендә система буларак кулланылмыйлар. Бу телләрдә бары аналитик кушма җөмләләр генә үсеш алган, ә төрки телләрдә болары да тулы бер системаны тәшкил итәләр.

Иярчен җөмләләрне өйрәнә башлаучы галимнәр иң элек менә шушы синтетик җөмләләрне күргәннәр һәм, иярчен кисәкләргә охшатып, аларны иярчен җөмләләр дип атаганнар. Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди һәм Г. Алпаров бары менә шушы без синтетик дип атаган җөмләләрне генә иярчен җөмлә дип тикшергәннәр. Бу галимнәр аналитик иярчен җөмләләрне башта күреп аера белмәгәннәр, кайберләрен тезмә кушма җөмлә эчендә карый торган булганнар.

М. Корбангалиев һәм Х. Габделбәдигъ тарафыннан 1919 елда чыгарылган «Ана теле нәхүе» дәреслегендә беренче мәртәбә синтетик иярчен җөмләләр белән аналитик иярчен җөмләләр бергә алынганнар, ике төре дә иярчен дип атала башлаган. Табигате, төзелеше белән тамырдан аерылып тора торган бу ике төр җөмләне, бергә алып, бер **иярчен** термины белән атау кайбер төрки телләрдә бүгенгә кадәр дәвам итә.

Бу хәл, татар теле кушма җөмләләрен рус телендәге кушма җөмләләр белән чагыштырып өйрәнгәндә, кыенлыклар тудыра. Шуңа күрә төрки телләргә рус теле үлчәве белән якын килүче тюркологлар, төрки телләрдә һинд-европа телләрендәге кебек иярчен җөмләләр юк дип язалар. Дөресендә, төрки телләрдә һинд-европа телләрендәге кебек иярчен җөмләләр дә бик төзек система тәшкил итәләр, аның өстенә әле төрки телләрдә һинд-европа телләрендә булмаган синтетик иярчен җөмләләр дә тулып ята, болары да тулы бер система төзиләр.

Синтетик җөмләләрне аналитик җөмләләрдән аеру омтылышы синтаксис белән шөгыльләнгән һәрбер тюркологта булган. Аны, русча язылган хезмәтләрдә, придаточные дигән җөмләләрдән аеру өчен, обороты с подлежащими, абсолютные обороты, трансформы, деепричастные обороты һ.б. төрле терминнар белән атап караганнар. Соңрак синтетические придаточные термины урнашты. 1982 елда немец теле профессоры В.Г. Адмони аны спаянные предложения дип атады, 1984 елдагы «Хәзерге татар әдәби теле синтаксисы һәм пунктуациясе» китабында М. Зәкиев бу терминны күтәреп алды (166 бит), ләкин әле

аны фәнгә кертеп җибәрергә ашыкмады. Бары 1992 һәм 1995 елгы академик синтаксис китабында гына ул *с п а я н н ы е* терминын татар теле фәненә тәкъдим итте. Моны төрки теле синтаксистлары тыныч кына кабул иттеләр; хәзер менә академик синтаксисның татарчасына без **синтетик иярчен җөмлә** атамасын, әз генә кыскартып, **синтетик җөмлә** атамасы дип тәкъдим итәбез.

**§ 286. Синтетик җөмләләрнең төп үзенчәлекләре**. Синтетик җөмләләр шарт фигыльләр, хәл фигыльләр, сыйфат фигыльләр һәм исем фигыльләр белән бирелгән ярым хәбәрлекле төзелмәләргә якын торалар: ярым хәбәрлекле төзелмәләрдә үзенә генә хас субъект-предикат (ия-хәбәр) бәйләнеше булмый, ә синтетик җөмләләрдә була. Мәсәлән, *Шәһәрдән кайткач, барысын да сөйләрмен* җөмләсендә *шәһәрдән кайткач* өлеше ярым хәбәрлекле төзелмә генә була, чөнки аның субъекты, төп субъект белән бер үк (*м и н шәһәрдән кайткач, м и н сөйләрмен*); шартлы билгеләр белән күрсәтелгән схемасы болай була: [$S_1$–$P_1$ кач], [$S_1$–$P_2$]. *С и н ш ә һ ә р д ә н к а й т к а ч, барысын да сөйләрмен* мисалында беренче өлеше – синтетик җөмлә, чөнки аның үзенә генә караган субъекты бар, һәм ул ия белән бирелгән. Схемасы: [$S_1$–$P_1$ кач], [$S_2$–$P_2$].

Аерым басым ясап әйтергә туры килгәндә, җөмләнең ике өлешендәге бер үк субъект кабатланып, ике ия белән бирелсә, ярым хәбәрлекле төзелмә синтетик җөмләгә (искечә әйтсәк, синтетик иярчен җөмләгә) әйләнә: *М и н шәһәрдән кайткач, м и н сөйләрмен.*

Ярым хәбәрлекле төзелмә бер составлы җөмлә моделенә туры килгәндә, аны синтетик җөмлә дип тә танырга була. Мәсәлән, *Б а р ы р г а т у р ы к и л с ә, үзем алып кайтырмын* төзелмәсендә беренче өлеш бер составлы җөмлә моделендә бирелгән, аның субъекты төп субъект белән туры килә, аны (*үзем* яки *мин* сүзен) беренче өлешкә куйганда да, ул – юнәлеш килешендәге тәмамлык, ә икенче өлештә ия булып килә: *Миңа барырга туры килсә, үзем алып кайтырмын.*

Синтетик җөмләнең үз субъекты булу гына җитми, ул субъектның ия белән бирелеше (я бирелү мөмкинлеге) дә кирәк. Әгәр субъект ия белән түгел, иялек килешендәге тәмамлык белән бирелсә, андый төзелмәне синтетик җөмлә дип түгел, ә ярым хәбәрлекле төзелмә дип кенә карап була. Моны ачык аңлау өчен, шундый төзелмәләрне каршы-каршы куеп күрсәтик.

| | Синтетик җөмләле төзелмәләр | Ярым хәбәрлекле төзелмәләр |
|---|---|---|
| 1. | *Син кайтканны мин белмәгән идем әле.* | *Синең кайтканны мин белмәгән идем әле.* |
| 2. | *Гаяз чыкмаганнан эшкә әллә ни зыян килмәде* (И. Гази). | *Гаязның чыкмаганыннан эшкә әллә ни зыян килмәде.* |
| 3. | *Син килүгә мин бик шат.* | *Синең килүгә мин бик шат.* |
| 4. | *Икмәк юклыктан зарлана иде* (Г. Ибраһимов). | *Икмәгенең юклыгыннан зарлана иде.* |

Шулай итеп синтетик җөмләләр ярым хәбәрлекле төзелмәләрдән ия-хәбәр бәйләнешендәге төзелмә булу белән аерылып торалар.

Синтетик җөмләләрнең тагын түбәндәге үзенчәлекләрен санап күрсәтергә мөмкин.

1. Синтетик җөмләләр баш җөмләгә үз хәбәрләре составында килә торган синтетик чаралар ярдәмендә бәйләнәләр.

2. Синтетик җөмләләр субъект-предикатлы (ия-хәбәрле) төзелмә булулары белән ярым хәбәрлекле әйләнмәләрдән аерылып торсалар да, алар күп кенә яклары белән ярым хәбәрлекле төзелмәләргә охшыйлар да, мәсәлән, алар аерымланып та, аерымланмыйча да килә алалар.

Синтетик җөмлә баш җөмләдәге ияртүче сүздән алда килеп, аның белән янәшә торса аерымланмый, ягъни ияртүче сүздән пауза белән аерылмый: *Авылдашлар эштән караңгы төшә башлагач кайттылар. Син кайтканны белмәгән идем әле мин. Мин дәрескә башым авыртканга күрә килмәдем. Мин тәрәзәләрне саф һава керсен өчен ачтым.*

Баш җөмләдәге ияртүче сүздән ерак торсалар, синтетик җөмләләр ярым хәбәрлекле төзелмәләр кебек үк аерымланалар, ягъни алардан соң пауза ясала: *Караңгы төшә башлагач, авылдашлар эштән кайттыла. Син кайтканны, мин ишетмәгән идем әле. Башым авыртканга күрә, мин дәрескә килмәдем. Саф һава керсен өчен, мин тәрәзәләрне ачтым.*

Синтетик җөмлә, инверсияләнеп баш җөмләдән соң килгәндә дә, ярым хәбәрлекле төзелмә кебек үк аерымлана: *Кап-кара урман бар*

*икән, һичбер инсан йөрмәгән* (М. Гафури). Чагыштырыгыз: *Һичбер инсан йөрмәгән урман бар икән.*

4. Синтетик җөмләләр баш җөмләгә хәбәр формасын тәшкил итә торган чаралар ярдәмендә буйсынганлыктан, аның хәбәре тулы (затланышлы) була алмый, шуңа күрә алар кушма җөмләне тәмамлап куя алмыйлар, бары җөмлә башында я уртасында гына килә алалар. Чыгарма бары шигъри сөйләмдә генә очрарга мөмкин.

**§ 287. Синтетик җөмләләрне баш җөмләгә иярткүче чаралар**. Синтетик җөмләләрне баш җөмләгә иярткүче чараларга шарт фигыль, хәл фигыль, сыйфат фигыль формалары, сүз бәйләүче кушымчалар, бәйлек һәм бәйлек сүзләр, шулай ук мәҗбүри янәшә тору һәм иярткүче сүздән пауза белән аерылмау керә. Бу чараларның барысын бергә синтетик чаралар дип атау гадәткә кергән. Хәзер шуларга җентекләбрәк тукталыйк.

1. Шарт фигыль формасы, башка чаралардан аермалы буларак, зат белән төрләнә, ләкин ул бервакытта да мөстәкыйль гади җөмләнең хәбәре була алмый, кушма җөмләне дә тәмамлап куя алмый. Шул яклары белән хәл фигыльләргә якын тора.

Шарт фигыльнең затланышлы булуын истә тотып, кайбер галимнәр аны һәрчак җөмлә хәбәре ролендә килә дип саныйлар. Ләкин система бозылмасын өчен, шарт фигыль, үзенә караган иясе булса, җөмлә хәбәре дип, ягъни синтетик җөмлә хәбәре дип таныла, үзенә караган иясе булмаса, ярым хәбәрлекле төзелмә рәтенә кертелә. *Укысам, аңлаган булыр идем* җөмләсендә *укысам* шарт фигыленең субъекты төп субъект (*мин*) белән бер үк, ул аерым ия белән дә бирелмәгән. Шуңа күрә бу очракта *укысам* кисәге ярым хәбәрлекле кисәк булып санала. *Бу китапны укысаң, мин килеп алыр идем* төзелмәсендә *укысаң* шарт фигыленең үзенә генә караган субъекты бар, ул *-саң* формасында бирелгән, һәм аның субъекты (*син*) җөмләдәге төп субъект (*мин*) белән бер үк түгел. Димәк, соңгы җөмләдә без синтетик җөмлә булуын таныйбыз.

2. Хәл фигыльләр дә, әле генә сөйләнгән шартлар булганда, синтетик җөмлә хәбәре була алалар; шарт фигыль формасыннан аермалы буларак, хәл фигыль формалары зат кушымчаларын алмыйлар. Шарт фигыль хәбәр булып килгәндә, ия белән хәбәр арасында ярашу (координация) булса, хәл фигыль белән бирелгәндә, ия-хәбәр координация-

се була алмый: *Син килмәгәч, мин борчылдым; Мин килмәгәч, ул бик борчылган* һ.б.

3. Синтетик җөмләне баш җөмләгә бәйләүче чараның иң үзенчәлекле төре – мәҗбүри янәшә тору һәм ияртүче сүздән пауза белән аерылмау, ягъни синтетик җөмлә хәбәренең баш җөмләдәге ияртүче сүз белән бер синтагма булып әйтелүе. Мәсәлән, *Бу начар өйнең эчендә икмәге юк ярлы бар* (Г. Тукай) төзелмәсендә *икмәге юк* синтетик җөмләсе баш җөмләдәге ияртүче *ярлы* сүзе белән мәҗбүри янәшә тора, *ярлы* сүзеннән пауза белән аерылмый, *икмәге юк ярлы* сүзләре бер синтагма төзиләр. Бу очракта янәшә тору чарасын мәҗбүри янәшә тору чарасы дип атыйлар, чөнки синтетик җөмлә белән ияртүче сүз арасына башка кисәк керә алмый.

Мәҗбүри янәшә тору чарасы ярдәмендә баш җөмләгә иярә торган җөмлә хәбәре булып күбрәк сыйфат фигыльләр, *бар*, *юк* сүзләре, кайбер рәвешләр һәм сыйфатлар килә: *Акчасы бар кеше ни эшләргә белә. Ул без язган хатны бик яратып укыган. Җире аз кешеләр батраклыкка яллана иделәр* (Г. Бәширов). *Әтисе бай малайлар мондый эшкә бармый иделәр* (Б. Рәхмәт).

Мондый синтетик җөмләләрдә ия һәм хәбәрнең ярашуы бары III затта гына күзәтелә.

Ияртүче сүз белән янәшә тору, ягъни аерымланмау, хәбәре шарт фигыль, хәл фигыль белән бирелгән синтетик җөмләләрдә дә күзәтелә, ләкин ул мәҗбүри янәшә тору дип саналмый, бары аерымланмау очрагы дип кенә таныла: *Мин бу хатны син килгәч укырмын – Син килгәч, мин бу хатны укырмын*. Димәк, мәҗбүри янәшә тору чарасы аергыч (атрибут) функциясен үтәүче синтетик җөмләләргә генә хас.

4. Аергыч функциясен үтәүче синтетик җөмләне ияртеп килә торган сүз үзеннән-үзе аңлашыла торган сүз буларак төшеп калырга да мөмкин. Бу очракта мәҗбүри янәшә тору һәм ияртүче кисәк белән бер синтагмада әйтелү чарасы да юкка чыга. Кушма җөмләдә синтетик җөмлә түгел, ә баш җөмлә кыскара, ләкин синтетик җөмлә баш җөмләнең кайсы да булса бер кисәге функциясен үтәүдән туктамый, димәк, синтетик кушма җөмлә саклана, тик синтетик җөмләнең генә функциясе үзгәрә. Бу үзгәрештән соң ияртүче булып башка чаралар килә.

Мисалда күзәтик: *Син әйткән сүз – миңа закон* (К. Нәҗми). Биредә мәҗбүри янәшә тору һәм ияртүче белән бер синтагмада әйтелү

ияртүче чара булып санала. Ияртүче сүз төшеп калса, җөмлә болай оеша: *С и н ә й т к ә н – миңа закон*. Биредә иярчен җөмлә ия функциясен үти, ә баш җөмлә, үзенең *сүз* дигән иясен югалтып, тагын да кыскара, җөмләлеген сакламый диярлек. Шуңа күрә бу җөмлә с у п е р с и н т е т и к кушма җөмлә дип таныла, ул гади җөмләгә бик якын тора.

Тагын бер мисалны анализлыйк: *С и н ә й т к ә н сүзне миңа тыңларга туры килде – С и н ә й т к ә н н е миңа тыңларга туры килде*. Бу җөмләдән ияртүче сүзнең төшеп калуы мәҗбүри янәшә тору чарасының төшем килеше чарасы белән алмашынуына китергән.

Менә шушындый суперсинтетик үзенчәлеген алып, хәбәре исем фигыль белән бирелгән синтетик җөмлә дә килә: *Б е р к е ш е а р т у аларга яңа көч бирде* (Г. Гобәй). *Б е р к е ш е а р т у г а алар сөенделәр генә. Б е р к е ш е а р т у д а н аларга файда булмады* һ.б.

5. Синтетик җөмләне баш җөмләгә ияртүче чара буларак килеш кушымчалары, кайбер рәвеш кушымчалары (*-ча/-чә, -дай/-дәй*) һәм *-лыктан* кушымчасы кулланыла: *Б а л а л а р ы ө й д ә ю к к а исе дә китмәде* (Б. Рәхим). *У л ө й р ә т к ә н ч ә эшли алмадык. Б а й л ы г ы ң б а р д а й кыланасың. К а й г ы с ы з у р л ы к т а н, башлары чатный* (М. Гафури).

6. Синтетик җөмләне баш җөмләгә бәйләүче чара булып, бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр йөри: *Ул килү белән, без кузгалып киттек. У л к и л ү г ә к а р а м а с т а н, без һаман кузгалмаган идек әле.*

Кайбер төрки телләрдә бәйлек һәм бәйлек сүзләрне, күрше сүздән аерым язылуын гына исәпкә алып, аналитик җөмләләрдәге бәйләгечләргә кертәләр. Ләкин бу дөрес түгел. Баш җөмләгә бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр белән бәйләнгән җөмләләр барлык үзенчәлекләре белән дә синтетик җөмләләр рәтенә карыйлар.

7. Синтетик җөмләне баш җөмләгә бәйләү, ияртү хезмәтен инфинитив формасы (*-ырга*/*-ергә*) да үти: *Ә т и к а й т ы р г а өч көн калды.*

### Синтетик җөмләләрне хәбәр булып килгән сүзгә карап төркемләү

**§ 288. Хәбәре исем фигыль белән бирелгән синтетик җөмләләр.** Бу төр җөмлә ярдәмендә төзелгән кушма җөмләләр гади җөмләгә шактый якын торалар; анда ия-хәбәр бәйләнешенең берничә булуы гына, бу төзелмәләрне кушма җөмлә дип танырга мөмкинлек бирә.

Хәзер каралачак синтетик җөмләләр, үзләренең төзелешләре буенча, гади җөмләнең 6 нчы моделенә (*Ия – Хәб.у*), нигезләнәләр (*Теләге – уку*).

Боларны, гадәттә, хәбәр формасына карап төркемлиләр.

1. Хәбәре баш килештәге сүз белән бирелсә, синтетик җөмләләр баш җөмләнең иясе булып киләләр: *С и н к и л ү миңа дәрт өстәде; С ө й г ә н у л ы с у г ы ш т а н к а й т м а у аны бөтенләй аяктан екты* (Г. Әпсәләмов). Мондый җөмләләрне суперсинтетик дип атарга да була, чөнки аларның баш җөмләгә ияреп, керешеп китүе бик көчле, ярым хәбәрлекле төзелмәгә дә алар бик җиңел әйләнәләр: *С и н е ң к и л ү е ң миңа дәрт өстәде; С ө й г ә н у л ы н ы ң с у г ы ш т а н к а й т м а в ы аны бөтенләй аяктан екты.* Мондый үзгәреш субъектның бер очракта баш килештәге, икенче очракта иялек килешендәге сүз белән бирелә алуына нигезләнгән: *син-синең; улы-улының*. Ләкин шуңа игътибар итәргә кирәк: баш килештә торганда, субъект билгесезлек төсмерен алса, иялек килешендәге сүз белән бирелгәндә, аңа билгелелек төсмере керә. Чагыштырыгыз: *С у г ы ш б а ш л а н у – аның барлык планнарын юкка чыгарды. С у г ы ш н ы ң б а ш л а н у ы аның барлык планнарын юкка чыгарды.*

Фигыльдән башка сүзләр белән бирелгәндә, хәбәр *булу* ярдәмче фигылен ала: *М и н с т у д е н т б у л у г ы н а гаилә бюджетына әллә ни зыян китермәде* (Х. Сарьян).

Бу төр синтетик җөмләләрне, билгеле, ярым хәбәрлекле төзелмәләр дип тикшереп тә булыр иде, ләкин синтаксиста система булдыру өчен, аларны ия-хәбәр бәйләнеше белән ясалган синтетик җөмлә дип карау дөресрәк булыр.

2. Хәбәре башка килеш кушымчаларын алганда, синтетик җөмлә белән баш җөмлә арасында төрле мөнәсәбәтләр урнаша.

Хәбәр иялек килешендә килсә, синтетик җөмлә баш җөмләнең атрибутын белдерә: *С и н к и л ү н е ң файдасы шул булды: печән вакытында җыелды* (Г. Ибраһимов). Хәбәрнең иялек килешен алуы иянең иялек килешендә килүен чикли: кирәкмәс кабатлау барлыкка китерә. Чыннан да, *синең килүең* диелсә, җөмлә стилистик яктан ямьсез яңгыры.

Хәбәр төшем килешендә килсә, җөмләләр арасында объектлык мөнәсәбәте барлыкка килә: *К ү к т ә к е ч к е н ә г е н ә б о л ы т к и с ә г е к ү р е н ү н е д ә зарыгып көтәсең* (Г. Галиев).

Хәбәрдәге юнәлеш килеше җөмләләр арасында вакыт яки объект мөнәсәбәте урнаштыра: *Еракларга киткән юл күренер, Таралуга бу гомерлек томан...* (Зөлфәт) – биредә вакыт мөнәсәбәте; *Син килүгә, мин бик шат* – биредә объект мөнәсәбәте.

**Искәрмә.** Диалектларда синтетик җөмлә хәбәре булып исем фигыльнең искергән *-еш/-еш* формасы да кулланыла һәм башлыча юнәлеш килешен ала: *Син кайтышка мин дә барып җитәрмен мунчага; Балалар кайтышка аш әзерлисе бар* (урта диал.). *Мәңге шулай әзерләнә җиһан Яңа җаннар җиргә килешкә ...* (Х. Әюп).

Хәбәр чыгыш килешендә килсә, синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең сәбәп-объектын белдерә: *Бер кеше артудан әллә ни булмас* (Ә. Еники). *Авыл язы кар эрүдән башлана* (М. Юныс).

Исем фигыль хәбәр булып килгәндә, аның составында урын-вакыт килеше кушымчасы бик сирәк кулланыла: *Бу четерекле эшкә син катнашуда файда юк*. Шул ук мәгънәдә чыгыш килеше кушымчасын куллану ешрак очрый: *...син катнашудан файда юк*.

Тагын шуны әйтергә кирәк: хәбәре төрле килештәге исем фигыльләр белән бирелгән синтетик җөмләләр ярым хәбәрлекле төзелмәләргә бик җиңел үзгәртеләләр. Аларның субъектларын белдерүче сүзләр баш килештә дә, иялек килешендә дә тора ала: *Син килүнең – синең килүнең, болыт кисәге күренүне – болыт кисәгенең күренүен, син килүгә – синең килүеңә, бер кеше артудан – бер кешенең артуыннан, син катнашуда – синең катнашуыңда* һ.б. Ләкин моннан бер чыгарма бар: синтетик җөмлә вакыт белдергәндә, субъект бары баш килештәге сүз белән генә бирелә ала: *Ат килеп туктауга, ул картлар белән татар телендә исәнләште* төзелмәсендәге синтетик җөмләне, *атның килеп туктавына* дип, ярым хәбәрлекле төзелмәгә әйләндереп булмый.

3. Хәбәре кайбер бәйлек һәм бәйлек сүзләрне алган исем фигыль белән бирелсә, синтетик җөмлә баш җөмләгә шулай ук төрле мөнәсәбәтләрдә тора ала.

Хәбәр составындагы *белән* бәйлеге җөмләләр арасында вакыт мөнәсәбәтен белдерә: *Бер-ике минут үтү белән, арадагы пәрдә югалды* (Г. Ибраһимов). *Сынау башлану белән, чыгып билет алдым* (М. Юныс). Ул кирелек мөнәсәбәтен дә белдерә ала: *Үзең ерак булу белән, син китмисең минем күңелдән* (җыр).

Ике җөмләне бәйләүче чара булып, *аркасында, сәбәпле* бәйлек сүзләре килә ала, алар җөмләләр арасында сәбәп мөнәсәбәте урнаштыралар: *Сугыш башлану аркасында, Карлыгач укырга китә алмый калды* (Г. Бәширов). *Ел коры килү сәбәпле, елгаларда су шактый кимеде* (С. Сабиров). Мондый җөмләләрнең субъектын иялек килешендәге сүз белән бирү нормадан чыгып бара: *сугышның башлануы аркасында...* дип әйтү сирәгәя.

*Карамастан* бәйлек сүзе килгәндә, синтетик җөмлә белән баш җөмлә арасында кире шарт мөнәсәбәте урнаша: *Алмалар җыелып бетүгә карамастан, бакча әле матур* (И. Гази).

Җентекләп тикшергәндә, хәбәре исем фигыль белән бирелгән синтетик җөмләне баш җөмләгә беркетеп башка бәйлек һәм сүзләр кулланыны да күзәтергә мөмкин.

**§ 289. Хәбәре *-асы, -а торган, -ыр/-мас* формаларындагы сыйфат фигыль белән бирелгән синтетик җөмләләр**. Бу төр җөмләләр ярым хәбәрлекле кисәкләргә якын булулары ягыннан икенче урынны алып торалар, ягъни алар да аерым очракларда ярым хәбәрлекле төзелмәгә әйләнә алалар: *Син укыган китап урынына куелмаган – Синең укыган китабың урынына куелмаган.*

Хәбәре сыйфат фигыльнең *-асы, -а торган, -ыр/-мас* формалары белән бирелгән синтетик җөмләләр гади җөмләнең 2 нче (*Ия – Хәб. -асы*), 4а (*Ия – Хәб. -ар*), 45 нче [*(үт-га) БК -асы*] модельләренә туры киләләр, бары хәбәре *-а Сос. 295 торган* формасындагы синтетик җөмләләр генә гади җөмләнең билгеле бер моделенә туры килми, ләкин 2а моделенә якын тора.

Синтетик җөмләләрнең хәбәре түбәндәге формалы сыйфат фигыльләр белән бирелергә мөмкин.

1. Хәбәре *-асы* формасындагы сыйфат фигыль белән бирелеп, ул башка бәйләүче чаралар алмаса, синтетик җөмлә баш җөмләнең атрибутын белдерә: *Без барасы юлларның ике чите гөлчәчәк* (җыр); *Мин аласы кыз кияүгә чыккан иде инде* (А. Шамов). *Мин эчәсе сулар изге, мин сулыйсы һава саф* (Л. Лерон).

Бу төр синтетик җөмләне ярым хәбәрлекле кисәккә әйләндерү бик җиңел: *Мин аласы кыз... – Минем аласы кыз (кызым)...*

Хәбәре *-асы* формасындагы синтетик җөмләгә, баш җөмләгә төшем килеше кушымчасы ярдәмендә бәйләнергә мөмкин: *Мин*

*к ү р ә с е н е сиңа күрү насыйп булмас* (Х. Сарьян). Биредә җөмләләр арасында объектлык мөнәсәбәте урнаша.

**Искәрмә.** Киләчәк заман сыйфат фигыль булып йөрүче *-әчәк* формасы синтетик җөмлә хәбәре булып кулланылмый дип әйтерлек, ул диалекталь сөйләмдә генә күзәтелә: *А л а р т ө з и я ч ә к тормыш бит бу*.

2. Хәбәре -*а торган* формасындагы синтетик җөмлә баш җөмләнең атрибутын белдерә: *Машинкада басу х а т ы н ы б а ш к а р а т о р г а н эш иде* (Г. Әпсәләмов). Бу төр җөмлә дә ярым хәбәрлекле төзелмәгә җиңел әйләнә: *...хатыны башкара торган... – Хатынының башкара торган эше.*

Шушы ук мәгънә *-еп торган* формасы белән белдерелә ала: *К ө н с а е н я ң а ф и к е р, я ң а б е л е м ө с т ә л е п т о р г а н омтылышлы студентлар тормышы ошый иде миңа* (М. Юныс).

3. Хәбәре -*ар/-мас* формасындагы сыйфат фигыль белән бирелгән синтетик җөмлә баш җөмләнең атрибутын белдерә: *Ике халык арасында у т ы с ү н м ә с дуслык урнашты* («Ватаным Татарстан»). Бу позициядә сыйфат фигыльнең формасы (*-мас*) гына кулланыла.

Хәбәр *-ар/-мас* формасындагы сыйфат фигыль белән бирелгәндә, ул төшем килеше кушымчасын алырга мөмкин. Бу очракта синтетик һәм баш җөмләләр арасында объектлык мөнәсәбәте урнаша: *Карт каушады, у л ы н и ә й т е р е н сизенде булса кирәк. Ул бу эшкә ү з е н е ң к ө ч е җ и т м ә с е н сизенә иде* (И. Гази).

Бәйләүче чара булып *-дай/-тай* кушымчасы килгәндә, синтетик җөмлә баш җөмләнең атрибуты вазифасын үти: *Дөньяда м и н э ш л ә м ә с т ә й эш юк* (Г. Ибраһимов); *С и н я р ы р д а й утын монда калмаган инде.*

Бәйләүче чара булып бик сирәк кенә чыгыш килеше кушымчасы килә ала, синтетик җөмлә объектны белдерә:

*Булса ялган, тик кәгазьләрдән ясалган бер чәчәк,*
*Билгеле, ү з ө с т е н ә я ң г ы р я в а р д а н к у р к а ч а к* (Г. Тукай).

Хәбәр -*мас* формасын алганда, бәйләүче чара булып, *борын* бәйлеге килсә, синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең вакытын белдерә: *Б а л а й о к л а м а с б о р ы н , эшкә тотынгансыз* (К. Тинчурин).

Диалектларда *өчен* бәйлеге дә ияртүче чара була ала, синтетик җөмлә максатны белдерә: *Әтәй, м и н к и я р ө ч е н, бишмәт алып куйган.*

Хәбәр *-мас* формасындагы сыйфат фигыль белән бирелгәндә, ияртүче чара булып, *дәрәҗәдә* бәйлек сүзе килергә мөмкин. Бу очракта синтетик җөмлә күләм-дәрәҗә белдерә: *Зәңгәр чишмәнең басуларында чәчәкләр а д ә м к ү з е к а р а п т у я а л м а с дәрәҗәдә куе төстә чибәр булып җитешәләр* (Г. Ибраһимов).

Хәбәр булып килгәндә, сыйфат фигыль барлык һәм юклык формаларында кабатлана ала, синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең вакытын белдерә: *Ул к и л е п җ и т ә р - җ и т м ә с, малайлар таудан төшеп тә киттеләр* (Б. Рәхмәт). *А л т ы а й т у л а р - т у л м а с, аны больницадан чыгардылар* (Р. Вәлиев).

**§ 290. Хәбәре *-ган* формасындагы сыйфат фигыль белән бирелгән синтетик җөмләләр**. Бу төр сыйфат фигыль синтетик җөмләнең хәбәре булып еш һәм төрле формаларда кулланыла, шуңа күрә, аны анализлау өчен, аерым параграф ачтык. Мондый хәбәрле синтетик җөмлә гади җөмләнең 2а (*Ия – Хәб. -ган*) моделенә нигезләнә.

Синтетик җөмләнең *-ган* формасындагы хәбәре түбәндәге бәйләүче чараларны алырга мөмкин.

1. *-ган* формасындагы хәбәр төрле килешләрдә тора, башка ярым ясагыч – ярым бәйләгеч кушымчаларны ала.

1) Хәбәре кушымча алмаса, синтетик җөмлә баш җөмләнең атрибуты хезмәтен үти: *Тузгытты җил к ү ң е л т ү р е н ә ү к Б ы л - б ы л ү р г ә н шигырь оясын* (Зөлфәт). *Җ ы р к у з г а т к а н моңны давыл үкерүе, диңгез котырынуы да җиңә алмый иде* (М. Юныс). *Т о т а ш м о ң т у л г а н йолдыз яктысы Шигырь язасы кәгазьгә төште* (Зөлфәт).

Хәбәре *-гән* формасындагы синтетик җөмлә баш җөмләнең субъекты булып килә ала: *Түбәннән моңа каршы и к е к а т л ы м а т у р п а р о х о д к и л г ә н е күренде* (И. Гази). Бу очракта *пароход килгәне* ярым хәбәрлекле кисәккә якын, чөнки анда иялек килеше (*пароходның*) булмаса да, тартым формасы (*килгәне*) катнаша. Ә менә *Ә т и ә й т к ә н н ә р безгә закон иде* мисалында ярым хәбәрлекле кисәккә якынлык зур түгел.

2) Хәбәр *-ның* кушымчасын алса, синтетик җөмлә атрибут белдерә: *И р е ң я р а т к а н н ы ң кадерен белеп кенә тор* (И. Гази). *Б ә д р и а б з ы й к и л г ә н н е ң икенче көнендә булды бу хәл* (Ә. Фәйзи).

3) Хәбәре юнәлеш килешен алса, синтетик җөмлә сәбәпне белдерә: *Бернинди дә уе булмаганга, бармаклары үзләреннән-үзләре гитара кылларын чирткәли башлады* (Ә. Гаффар).

Хәбәре юнәлеш килешен алса, синтетик җөмлә объект мәгънәсе белдерә ала: *Адәм баласы йөрәк теләгәнгә колак салып яшәргә тиеш* (М. Юныс).

4) -*ган* формасындагы хәбәр төшем килеше формасын алса, синтетик җөмлә баш җөмләнең объектын белдерә: *Хәзер Тимери Мәскәү белән Казан сөйләгәнне кырын ятып кына тыңлый* (Г. Бәширов).

5) -*ган* формасындагы хәбәр чыгыш килеше формасын алса, синтетик җөмлә баш җөмләнең сәбәп-объектын белдерә: *Гаяз чыкмаганнан, эшкә әллә ни зыян килмәде* (И. Гази).

6) Хәбәр -*ганда* формасында торганда, синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең вакытын белдерә: *Мин кергәндә, Гөлшат чәчен тарап утыра иде* (Ф. Яруллин). *Бәхет кошы иңеңә кунганда куарга ярамый* (Ф. Яруллин).

Шартын белдерә: *Бу әйтелгәннәр булмаганда, безнең тормышыбыз күңелсез булачактыр* (Г. Тукай).

7) Хәбәр -*ганда да* формасында торганда, синтетик җөмләдән көтелгән эш-хәлнең баш җөмләдә киресе хәбәр ителүен белдерә: *Якын дусты килгәндә дә, урыныннан кузгалмады. Игеннәр урылып беткәндә дә, ул кырдан кайтмады* (Г. Галиев).

8) хәбәр -*ганча, -гандай* формаларын алса, синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең рәвешен белдерә: *Бөтен көчкә уйнаган скрипканың барча кыллары берьюлы өзелгәндәй, тавышлар кинәт тынып калды* (Ф. Яруллин). *Икенче көнне Фидан аңа, берни булмагандай,ерактан ук сәлам бирде* (Р. Вәлиев).

**Искәрмә**. Иске татар әдәби телендә синтетик җөмләнең хәбәре булып -*дык/-дек* формасындагы фигыль еш кулланылган. Ул, төрле бәйләүче формаларны алып, җөмләләр арасында төрле мәгънә мөнәсәбәтләре урнаштырган: а) -*дыкча* (дәрәҗә-күләм мөнәсәбәте): *Шунда да исемең синең милләт яшәдекчә яшәр, милләт үсдекчә үсәр һәм милләт ашдыкча ашар* (Г. Тукай); ә) -*дыкта* (вакыт мөнәсәбәте): *Әмир Тимер Болгарны харап кылдыкта, Болгарда Бичура хан иде* (Мөслими); б) -*дыктан, -дыгымнан, -дыгыбыздан* (сәбәп мөнәсәбәте): *Бу көн төнлә генә кайттыгымнан, һәр нәрсә сагындырган* (Г. Ибраһимов);

*Калебем икенче җирдә улдыгыннан, сүзләрене юньле-башлы аңыша алмаенча, гадәтән төш күргән кебек утырдым* (Ф. Кәрими).

2. Хәбәре *-ган* формасындагы синтетик җөмлә баш җөмләгә бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр ярдәмендә дә бәйләнә.

1) *Саен* бәйлеге ярдәмендә бәйләнгәндә, синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең вакыт ягыннан күләмен белдерә: *Малайлар, кулга пычак эләккән саен, ул язулар өстендә эшлиләр булса кирәк* (Г. Ибраһимов). *Еллар үткән саен, тәҗрибә өстәлә* (М. Юныс).

2) *Күрә* яки *өчен* бәйлеге ярдәмендә бәйләнгәндә, синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең сәбәбен белдерә: *Ир балалары бер ул гына булганга күрә, аңа эш талымлап торырга туры килмәде* (И. Гази). *Кара төнне көндез кебек кылган өчен, урам буйлап халык йөри, кылып хозур* (Г. Тукай).

3) Хәбәре *-ган* формасында сыйфат фигыль белән бирелгән синтетик җөмлә баш җөмләгә *кебек, шикелле, сыман* яки *төсле* бәйлеге ярдәмендә бәйләнсә, алар арасында чагыштыру мөнәсәбәте урнаша: *Герләр бар нәрсәнең авырлыгын белер өчен хезмәт иткән шикелле, акчалар да бар нәрсәнең кыйммәтен белер өчен хезмәт итәләр* (Г. Тукай). *Аларны көтүдә сарык өелеп торган кебек тупладылар* (Н. Дәүли). *Кичкә Ташлыяр, әле генә дошман явы үтеп киткән төсле бушап, шыксызланып калган иде* (Р. Вәлиев).

4) Хәбәр составында *-ган кадәр* (*чаклы, хәтле*) формасы булганда, синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең күләмен белдерә: *Вера Карабышеваны сайлаучылары ул белгән кадәр беләләрме икән?* (Ә. Еники).

5) Хәбәре составында *-ганга кадәр* (*чаклы, хәтле*) кебек бәйләүче булса, синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең вакыты ягыннан, күләм-дәрәҗәсен белдерә: *Мин кайтканга кадәр, өй янында басып торган* (И. Гази). *Әтиең кайтканга чаклы сабыр ит* (А. Шамов).

*-ганга чаклы* формасы *-гангача* рәвешендә кыскарып килергә дә мөмкин: *Әтиең кайткангача сабыр ит.*

*-ганчыга кадәр* (*чаклы, хәтле*) варианты да шул ук мөнәсәбәтләрне белдерә: *Беренче кар төшкәнчегә кадәр, без җәй*

*буена күпме поливитамин ашый торган идек* (Ә. Еники). Бу форма *-ганчы/-гәнче* хәл фигыленең варианты буларак карала ала.

6) хәбәре *-ган* формасындагы сыйфат фигыль белән бирелгән синтетик җөмлә баш җөмләгә *бирле* бәйлеге ярдәмендә бәйләнгәндә, җөмләләр арасында вакыт күләме мөнәсәбәте урнаша: *Электростанция корганнан бирле, тормыш һаман яңара бара* (Ә. Еники). *Бирле* бәйлеге үз алдыннан чыгыш килешен таләп итә: *-нан бирле*.

7) Хәбәр составында *-ганнан соң* формасы килсә, синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең вакытын белдерә: *Көн кызуы сүрелгәннән соң, Тимери агай да капка төбенә чыга* (Г. Бәширов).

8) Хәбәр составында *-ган чакта* яки *-ган арада* формасы булса, синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең үтәлү вакытын белдерә: *Чүкечләр тынып торган арада, Мостафаның карлыга төшкән тавышы яңгырады* (К. Нәҗми). *Мин килгән чакта (вакытта), син өйдә юк идең.*

9) Бу төр хәбәр янында *җирдә* (*урында*) ярдәмлек (бәйлек) сүзе дә килә ала, бу очракта синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең урынын белдерә: *Ат аунаган җирдә төк кала* (мәкаль); *Самолёт үткән урында ак юл сызылып кала*.

10) *Тәкъдирдә* бәйлек сүзе җөмләләр арасында шарт мөнәсәбәте урнаштыра: *Барысын да белгән тәкъдирдә сөйләп булыр иде* (Б. Рәхмәт).

Хәбәре *-ган* формасындагы сыйфат фигыль белән бирелгән синтетик җөмләләр ярым хәбәрлекле кисәкләрдән шактый ерак торалар, аларны андый кисәкләргә үзгәртеп төзү стиль нормасын боза: *Син килгәнгә мин шат – Синең килгәнгә мин шат*. Соңгысы нормадан читләшә.

**§ 291. Хәбәре хәбәрлек сүзләр белән бирелгән синтетик җөмләләр**. Бу рольдә *бар, юк, кирәк, тиеш* хәбәрлек сүзләре кулланыла. Болар ярдәмендә ясалган синтетик җөмләләр гади җөмләләрнең 8 нче (*Ия – Хәб. -рга тиеш*), 24 нче (*Ия – Хәб. кирәк*), 26 нчы (*Ия – Хәб. бар/юк*) модельләренә нигезләнәләр.

1. *Тиеш* хәбәрлек сүзе гади җөмлә хәбәре булып та бик сирәк кулланыла: *Син миңа бер алма тиеш*. Инфинитив белән бергә активрак йөри: *Син миңа бер алма бирергә тиеш*.

Хәбәре *-рга тиеш* формасында килгәндә, синтетик җөмлә баш җөмләдәге ияртүче сүз белән мәҗбүри янәшә тора һәм аның атрибуты

була: *М и н к ү р е р г ә т и е ш кеше командировкага киткән булып чыкты* (А. Шамов).

*Тиеш* сүзе кайчакта *-ле* кушымчасын ала: *С ы е р л а р ы а ш а р - г а т и е ш л е печәнне күршеләренә бирергә мәҗбүр булдылар* (Х. Сарьян).

Диалекталь сөйләмдә *-ргә тиешкә күрә* формасы да күзәтелә: *У л к и л е р г ә т и е ш к ә к ү р ә, өйдә утырдык* (урта диал.).

2. Хәбәре *кирәк* сүзе белән бирелгән синтетик җөмлә баш җөмләдәге ияртүче сүзгә мәҗбүри янәшә тору чарасы аркылы бәйләнсә, ул баш җөмләнең атрибуты хезмәтен үти: *Бу юлы биржага а к ч а к и р ә к кешеләр генә җыелган иде* («Ватаным Татарстан»).

Мондый хәбәрле синтетик җөмлә баш җөмләгә *күрә* (*-кә күрә*) бәйлеге ярдәмендә бәйләнергә мөмкин, бу очракта ул баш җөмләдәге эш-хәлнең сәбәбен белдерә: *Улы, с п о р т к и е м н ә р е к и р ә к к ә к ү р ә , тиз генә өйгә кереп чыкты*.

Ияртүче чара булып, *чакта, вакытта* бәйлек сүзләре килсә, синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең вакытын белдерә: *Син кирәк чакта, син юк, мин кирәк вакытта, мин булмыйм*.

3. Синтетик җөмләнең хәбәре булып, хәбәрлек сүзләрдән *бар/юк* бик актив кулланыла.

1) Баш җөмләдәге ияртүче сүзгә мәҗбүри янәшә тору чарасы белән бәйләнгәндә, синтетик җөмлә баш җөмләнең атрибутын белдерә: *Бу ч и г е ю к озын мәңгелектә Бер генә кат яшибез ләса* (Х. Туфан). *Беркатлысы булу кызык д о ш м а н ы б а р бу дөньяның* (Р. Фәйзуллин).

2) Баш җөмләдәге ияртүче сүз, үзеннән-үзе аңлашылып торганда, төшереп калдырылырга да мөмкин. Бу очракта хәбәре *бар/юк* сүзе белән бирелгән синтетик җөмлә тулы булмаган баш җөмләнең иясе булып килә: *А я к л ы м а л ы б а р л а р (бар кешеләр), көннәр суыткач, малларын суялар* (Ә. Еники). *Бу ашханәгә х а т ы н ы ю к л а р гына килә дә инде* (Ә. Еники). *Э ш е ю г ы сөйләр, э ш е б а р ы тыңлап тормас*... (Х. Сарьян).

3) Үзеннән-үзе аңлашыла торган сүз төшеп калганда, *бар/юк* сүзе белән бирелгән хәбәр иялек килешен дә алырга мөмкин. Бу очракта да җөмләләр арасында атрибутлык мөнәсәбәте урнаша: *Э ш е ю к н ы ң ашы да юк* (мәкаль). *Д у с ы б а р н ы ң һушы бар* (мәкаль).

4) Ияртүче сүз төшеп калса, *бар/юк* хәбәре төшем килешендә дә килә ала. Бу очракта синтетик җөмлә объектны белдерә: *И т е г е ю к н ы монда санга сукмыйлар* (әкият). *К о р а л ы б а р л а р н ы – бер якка, коралсызларны икенче якка тезделәр* (Г. Әпсәләмов).

5) хәбәре *бар/юк* сүзе белән бирелгән синтетик җөмлә баш җөмләдәге ияртүче сүзгә юнәлеш яки чыгыш килеше кушымчасы ярдәмендә бәйләнсә, ул баш җөмләдәге эш-хәлнең сәбәбен белдерә: *А к ч а м б а р г а риза булып яшим* (әкият). *А л а р б а л а л а р ы ю к к а бик нык борчылалар иде* (Р. Төхфәтуллин). *Ул я х ш ы к и е м е ю к т а н җәфа чигә.*

6) хәбәре *бар/юк* сүзе белән бирелеп, урын-вакыт кушымчасын да алса, синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең үтәлү вакытын белдерә: *А к ы н б а р д а телең тый* (мәкаль). *Д у с л а р ю к т а чын дуслыкны мактыйм* (Р. Вәлиев).

7) Бәйләүче чара булып *күрә* (*-га күрә*) бәйлеге килсә, синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең сәбәбен белдерә: *Аны б е л е м е б а р г а к ү р ә хөрмәт итәләр.*

8) Бәйләүче чара булып *чакта, вакытта* бәйлек сүзләре килсә, синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең үтәлү вакытын белдерә: *Әйбәтрәк урынга билет аласың килсә, кассага м и н б а р ч а к т а кил* (Б. Рәхмәт).

9) Бәйләүче чара булып *җирдә* (*урында*) бәйлек сүзе килсә, синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең үтәлү урынын белдерә: *Т ә р т и п ю к җ и р д ә* (*у р ы н д а*) *эш тә бармый.*

Хәбәре *тиеш, кирәк, бар/юк* кебек сүзләр белән бирелгән синтетик җөмләләрне ярым хәбәрлекле төзелмәләргә әйләндереп булмый.

**§ 292. Хәбәре сыйфат яки рәвеш белән бирелгән синтетик җөмләләр.** Бу төр синтетик җөмләләр гади җөмләнең 31 нче (*Ия – Хәб. сыйф.*) һәм 32 нче (*Ия. ис. ф. – Хәб. рәв.*) модельләренә нигезләнәләр.

Бу очракта синтетик җөмләнең хәбәре төрле формаларда торырга мөмкин.

1. Хәбәре сыйфат яки рәвеш булган синтетик җөмлә баш җөмләдәге ияртүче сүзгә мәҗбүри янәшә тору чарасы белән бәйләнә һәм аның атрибутын белдерә, ягъни аергычы булып килә: *Т а в ы ш ы я г ы м л ы хатын-кыз, гаепле кеше сыман, бик тә борчылып сөйли* (Р. Вәли-

ев). *Җ и р е а з кешеләр батраклыкка яллана иделәр* (Г. Бәширов). *К ү з л ә р е м о ң л ы кеше бәхетен тиз җуя торган була* (Р. Вәлиев).

2. Үзеннән-үзе аңлашыла торган аерылмыш кулланылмаганда, сыйфат яки рәвеш белән бирелгән хәбәр иялек килешен дә алырга мөмкин; бу очракта да синтетик җөмлә атрибутны белдерә: *Б у е о з ы н н ы ң акылы да озын булмый шул* (Г. Әпсәләмов).

3. Аерылмыш кулланылмаганда, сыйфат яки рәвеш белән бирелгән хәбәр төшем килешен алганда, синтетик җөмлә баш җөмләнең объектын белдерә: *К и е м е м а т у р н ы бик тиз күреп алалар. Б у ы н ы с ы е к л а р н ы алмаска кирәк эшкә* (Р. Вәлиев).

4. Аерылмыш урынында килгәндә, синтетик җөмлә баш җөмләнең иясе булып та килә ала: *Биредә к ү ң е л е б у ш л а р хөкем итә* (Н. Дәүли).

5. Хәбәре сыйфат яки рәвеш булган синтетик җөмлә баш җөмләгә юнәлеш яки чыгыш килеше кушымчасы ярдәмендә бәйләнә ала һәм баш җөмләдәге эш-хәлнең сәбәбе булган объектны белдерә: *Әнисе у л ы н ы ң а к ч а с ы а з г а бик борчылып калды* (И. Туктар). *Ул б у е к ы с к а д а н артык газап чикмәде* (урта диал.).

6. Хәбәре сыйфат яки рәвеш булганда, синтетик җөмлә баш җөмләгә *күрә* бәйлеге ярдәмендә иярә һәм баш җөмләдәге эш-хәлнең сәбәбен белдерә: *Үрдәк оча, каз йөгерә, б о т ы о з ы н г а к ү р ә; «Тәрҗеман»ның эче поша, « И с л а х » к ы з ы л г а к ү р ә* (Г. Тукай).

7. Хәбәре сыйфат яки рәвеш белән бирелгән синтетик җөмлә баш җөмләгә *карамастан* бәйлек сүзе ярдәмендә бәйләнә һәм көтелгәннең киресе эшләнәчәген белдерә*: А к ч а с ы а з г а к а р а м а с т а н, кыйбатлы әйберләр алырга ярата.*

8. Әйбернең материалын белдерә торган исемнәр сыйфат мәгънәсендә синтетик җөмләнең хәбәре булып килә һәм синтетик җөмлә баш җөмләдәге аерылмыштан аңлашылган предметның материалын белдерә: *Егерменче елларның көзендә безне тагын а с т ы т а ш, ө с т е а г а ч зур бинага күчерделәр* (Ә. Еники).

Бу төр синтетик җөмләләрнең мөстәкыйльлеге ныграк сизелә, чөнки аларны ярым хәбәрлекле төзелмәләргә әйләндереп булмый.

**§ 293. Хәбәре** ***-лык/-лек*** **кушымчасы ярдәмендә ясалган сүзләр белән бирелгән синтетик җөмләләр.** Кайбер фигыльләрдән, хәбәрлек сүзләрдән, сыйфатлардан, рәвешләрдән *-лык* кушымчасы

абстракт төшенчәле сүз ясый, һәм бу сүз синтетик җөмләнең хәбәре булып килә ала.

1. *-ар/-мас* формасындагы фигыльгә *-лык/-лек* кушымчасы кушылып ясалган сүз хәбәр булып килгәндә, синтетик җөмлә ияртүче сүзгә мәҗбүри янәшә тору чарасы аша бәйләнә һәм шул сүздән аңлашылган предметның атрибутын белдерә: *Кирпеч араларында бармак сыярлык ярыклар бар* (Г. Әпсәләмов). *Хыял җитмәслек шәһәрләр, бакчага күмелеп утырган проспектлар, хан сарайларын көнләштерерлек театрлар, культура йортлары, спорт сарайлары турында көннәр буе да, төннәр буе да уйлады, хыялланып бетте ул* (Р. Вәлиев).

2. Хәбәрлек сүзләргә, сыйфатларга яки рәвешләргә *-лык/-лек* кушымчасы кушылып ясалган сүз хәбәр булып килгәндә, синтетик җөмлә гадәттә баш җөмләнең иясе булып килә: *Акча юклык теңкәгә тия* (К. Нәҗми); *Аны буе артык озынлык борчый. Җире азлык аны һаман артка тартты* (халык иҗаты). *Син барырга тиешлек тиз беленде.*

3. Хәбәре *-лыктан/-лектән* формасында булганда, синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең үтәлү-үтәлмәү сәбәбен белдерә: *Акча юклыктан җәфа чигәләр; Көне-төне укыганлыктан, аның башы авырта иде. Әнисе фермадан кайтып кермәгәнлектән, ул идәнен дә юды, бәрәңгесен дә әрчеде, ашын да пешерде...* (Ф Садриев).

4. Составында *-лык/-лек* кушымчасы булган хәбәр баш җөмләдәге ияртүче сүзгә төшем килеше кушымчасы аша бәйләнә; синтетик җөмлә баш җөмләнең объектын белдерә: *Без авылга талаучылар килгәнлекне ишетеп хәйран калдык* (М. Гафури). *Өйдә син барлыкны белми калганбыз. Машиналарга бензин кирәклекне тиз генә хәбәр итеп булмады* (А. Шамов).

5. Составында *-лык/-лек* кушымчасы булган хәбәр баш җөмләдәге ияртүче сүзгә юнәлеш килеше кушымчасы аша бәйләнә, синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәл үтәлешенә сәбәп булган объектны белдерә: *Вокзалда кеше күплеккә исләрем китте. Акча юклыкка кайгырма. Балалары кайтканлыкка шатланып туя алмый.*

6. Составында *-лык/-лек* кушымчасы булган хәбәр баш җөмләдәге ияртүче сүзгә урын-вакыт килеше формасы белән иярә, синтетик җөм-

лә кушма җөмләнең хәбәре функциясен үти: *Бөтен хикмәт икмәк юклыкта. Бөтен авырлык корал азлыкта* (И. Гази).

7. Составында *-лык/-лек* кушымчасы булган хәбәр ияртүче сүзгә иялек килеше формасы ярдәмендә иярә, синтетик җөмлә ияртүче сүздән аңлашылган предметның атрибутын белдерә: *Эш күплекнең бер авыр ягы бар* (Ә. Еники). *Дуслар юклыкның зыяны һәрчак тиеп тора.*

8. Составында *-лык/-лек* кушымчасы булган хәбәр ияртүче сүзгә *күрә* бәйлеге ярдәмендә бәйләнә, синтетик җөмлә баш җөмләдән аңлашылган эш-хәлнең сәбәбен белдерә: *Мөҗәһит, патроннар азлыкка күрә, шулай кычкырына иде* (М. Максуд). *Абруе төшкәнлеккә күрә, шулай кәефсез йөри.*

9. Составында *-арлык/-маслык* формасы булган хәбәр ияртүче сүзгә *кадәр*, *чаклы* яки *хәтле* бәйлеге аша бәйләнгәндә, синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең күләмен белдерә: *Алар бәрәңгене дә әнисе ачуланмаслык кадәр генә алдылар* (Б. Рәхмәт).

10. *-лык/-лек* кушымчасы ярдәмендә ясалган сүз белән бирелгән хәбәр ияртүче сүзгә *карамастан* бәйлек сүзе аша бәйләнгәндә, синтетик җөмлә көтелгән эшнең киресе үтәләчәген сиздерә: *Патроннар юклыкка карамастан, сугышчылар чигенергә җыенмыйлар иде* (Г. Әпсәләмов). *Дошман күплеккә карамастан, безнекеләр һөҗүмгә күчтеләр* (А. Шамов).

11. Составында *- лык/-лек* кушымчасы булган хәбәр баш җөмләдәге ияртүче сүзгә *турында* яки *хакында* бәйлек сүзе ярдәмендә буйсына; синтетик җөмлә баш җөмләдән аңлашылган эш-хәлнең объектын белдерә: *Бераз тынычлангач, ул баласы юклык турында сөйли башлады* (Г. Гобәй). *Акча кирәклек турында әнисенә берничә хат язды.*

12. Составында *-ырлык/-маслык* кушымчасы булган хәбәр баш җөмләдәге ияртүче сүзгә *дәрәҗәдә* (искер. *мәртәбәдә*) бәйлек сүзе ярдәмендә бәйләнә; синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең яки билгенең күләм-дәрәҗәсен белдерә: *Кеше туңып үләрлек дәрәҗәдә салкын иде* (М. Гафури). *Ун дисәтинә ашлыгы адәм ышанмаслык мәртәбәдә буйга ускән* (Г. Ибраһимов).

Бу төр синтетик җөмлә ярым хәбәрлекле төзелмәләргә якынлык күрсәтми.

**§ 294. Хәбәре инфинитив белән бирелгән синтетик җөмләләр.** Бу төр җөмлә, бер составлы булганда, гади җөмләнең 46 нчы [(*Үт. -га*) *БК -рга*] моделенә нигезләнә; ике составлысы аерым бер модельгә туры килми. Хәбәре инфинитив белән бирелгән җөмләләр ярым хәбәрлекле төзелмәләргә бик якын тормыйлар.

Хәбәре *-рга* формасын алган җөмлә баш җөмләгә шул *-рга* кушымчасы аша бәйләнә һәм баш җөмләдәге эш-хәлнең үтәлү вакытын-объектын белдерә: *Доклад башланырга ун минут вакыт калды. Аңа больницадан чыгарга тагын бер атна вакыт бар* (Г. Гобәй). *Әтисе кайтырга санаулы көннәр генә калды* (И. Гази).

Шунысы әһәмияткә ия: хәбәре инфинитив белән бирелгән синтетик җөмләләр телдә шактый актив кулланылалар, ләкин аларны баш җөмләгә башка бәйләүче чаралар ияртмиләр. Бу – *-рга* формасының үз бәйләү көче булуы турында сөйли.

**§ 295. Хәбәре хәл фигыльләр белән бирелгән синтетик җөмләләр.** Бу төр синтетик җөмләләр гади җөмләнең бик күп модельләренә нигезләнәләр. Хәбәр исем, сыйфат, сан, рәвеш яки хәбәрлек сүз белән бирелгәндә, хәбәр хәл фигыль формасы алсын өчен, аңа *бул* фигыле өстәлә: *Мин инженер булгач, әни шәһәргә күчеп килде; Мин инженер булганчы, әни шәһәргә күчеп килде; Мин инженер булмыйча, әни шәһәргә күчмәде.*

Хәл фигыльле төзелмәләрдә үз субъектлары бары ия белән генә бирелә, шуңа күрә үз субъекты булган хәл фигыль һәрчак синтетик җөмлә барлыкка китерә, ул ярым хәбәрлекле төзелмәгә әйләнә алмый.

Хәл фигыль формалары һәрчак бәйләүче хезмәтен үтиләр, ягъни исемнәрдә – килеш кушымчалары, ә фигыльләрдә хәл фигыль кушымчалары сүзләрне, җөмләләрне бәйләүче чаралар булып саналалар.

1. Хәбәре *-гач/-гәч/-кач/-кәч* кушымчасын алган һәм раслау формасында торган синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең вакытын белдерә: *Аш пешкәч, әни кунакларны табын янына чакырды* (М. Юныс).

Шуның белән бергә вакыт мәгънәсе еш кына сәбәп мөнәсәбәтенә дә күчә.

Хәбәр булып килә торган фигыль инкяр күрсәткечен алган булса, синтетик җөмлә белән баш җөмлә арасында бары сәбәп мөнәсәбәте генә урнаша: *Сүзне аңламагач таякладылар* (Г. Ибраһимов).

*С е з  к и л м ә г ә ч , без дә кайтып киттек* (Х. Сарьян). *Җ и р е ң б у л м а г а ч, сыер малы асрау кыенга төшә* (М. Хуҗин).

Раслау формасындагы хәбәр янында *та* кисәкчәсе килсә, синтетик җөмлә белән баш җөмлә арасында кире шарт мөнәсәбәте урнаша, ягъни синтетик җөмләне әйткәч көтелгән эшнең баш җөмләдә киресе эшләнә: *К о ч е г а р  к ү р е н г ә ч  т ә , машинистлар урыннарыннан кузгалмый тордылар* (Г. Ибраһимов). *Ә т и с е  ә й т к ә ч  т ә , малай мәктәпкә бармады.* Кире мөнәсәбәт урнашсын өчен, синтетик җөмләнең хәбәре раслау формасында, ә баш җөмләнең хәбәре инкяр формасында торырга тиешләр. Ике җөмләнең дә хәбәре раслау формасын алсалар, җөмләләр арасында кире шарт мөнәсәбәте түгел, ә ашыгыч вакыт мөнәсәбәте урнаша: *А т л а р  к и л е п  җ и т к ә ч  т ә , халык көрәш мәйданына ашыкты* (Г. Гобәй).

Баш җөмлә сорау формасында булса, инкяр формасындагы хәбәре *-гач/-гәч* хәл фигыле белән бирелгән синтетик җөмлә шарт мәгънәсендә кулланыла: *К о м а н д а  т у л ы  к и л е ш  җ и ң е п  ч ы к м а г а ч , ике кешенең алдынгы урын яулавыннан ни файда?* (Р. Төхфәтуллин). *Т е л н е  б е л м ә г ә ч , ничек аңлатасың?* (Ә. Еники).

Диалектларда *-гач* кушымчасына тагын чыгыш килеше кушымчасын да өстәү очраклары бар: *Безгә килерсең, б а л а л а р  к а й т к а ч ы н н а н ; Ул  и ш е т м ә г ә ч т е н , без дә кабатлап тормадык; Б а л а ң  м ә к т ә п т ә н  ч ы к к а ч т ы н , сиңа сүзе булмасмы соң? А т н а  с а е н  к а й т ы п  й ө р г ә ч т е н  д ә , балаңны сагынасың икән* (урта диал.). Мисаллардан күренгәнчә, *-гач* хәл фигыле белән бирелгән хәбәр составында чыгыш килеше формасы барлык төр мәгънәләрне дә белдерүдә катнаша. Бу формалар әдәби телдә персонаж телен үзенчәлекле итү өчен кулланылырга мөмкин.

2. Хәбәре *-ганчы/-гәнче/-канчы/-кәнче* формасындагы хәл фигыль белән бирелгән синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең үтәлү вакыты ягыннан күләм-чамасын белдерә: *Алар, ш ә м ә х ә  к ү к  ч и т е н д ә г е  т ү г ә р ә к  а й  э р е п  ю к к а  ч ы к к а н ч ы , шәһәр урамнары буйлап йөрделәр* (Р. Вәлиев). *Туй мәҗлесе т а ң  б е л е н ә  б а ш л а г а н ч ы  дәвам итте* (Р. Вәлиев).

Мондый синтетик җөмлә баш җөмләдән аңлашылган эш-хәлнең бары үтәлү вакытын гына белдерергә дә мөмкин: *Безнең семьяда ә т и  к а й т к а н ч ы  ашарга утыру гадәте юк иде* (М. Юныс).

Баш җөмләнең хәбәре *яхшы(рак), әйбәт(рәк), җиңел(рәк), тиз-(рәк)* кебек сүзләр белән бирелгәндә, хәбәре *-ганчы* хәл фигыле булган синтетик җөмлә каршы куеп чагыштыруны белдерә: *К ө н н ә р б у е җ а н к ө е г е б у л ы п й ө р г ә н ч е, тыныч кына эштә утыру әйбәтрәк* (Г. Бәширов). *С и н а к с а к а я г ы ң б е л ә н а н д а б а р ы п й ө р г ә н ч е, минем үземнең килү тизрәк булыр* (М. Хәсәнов).

*-ганчы* хәл фигыле юклык формасында кулланылмый.

3. Синтетик җөмләнең хәбәре еш кына *-ып/-мыйча* формасындагы хәл фигыль белән дә бирелә.

Хәбәре *-ып* хәл фигыле булганда, синтетик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең вакытын-шартын-сәбәбен белдерә: *К а й к ө н н ә р д ә т а ң а л д ы н д а к о я ш ч ы г ы ш ы я г ы а ч ы л ы п к и т е п, аязган да шикелле була* (А. Шамов). Бу җөмләләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтен белү өчен, *ачылып китеп* хәбәрен төрлечә үзгәртеп карарга мөмкин: *ачылып киткәч* дип булса, вакыт мөнәсәбәте аңлашыла, *ачылып китсә* дип булса, шарт, *ачылып киткәнлектән* дип булса, сәбәп мөнәсәбәте барлыгын тану дөрес була. Күренгәнчә, биредә хәбәрне өч формада да кулланып була. Шуңа күрә җөмләләр арасында вакыт-шарт-сәбәп мөнәсәбәте бар дип әйтергә туры килә.

Синтетик җөмлә белән баш җөмлә арасында шарт мөнәсәбәте булмыйча, вакыт-сәбәп мөнәсәбәте генә урнашырга мөмкин: *Ул арада сүз икенчегә китеп, алынганнарның кызганыч булуы хакында кайгырыша башладылар* (Г. Ибраһимов).

*-ып* хәл фигыле белән бирелгән хәбәр янында *та* кисәкчәсе килсә, синтетик һәм баш җөмләләр арасында кире шарт мөнәсәбәте урнаша: *С и н я р д ә м и т е п т ә, әллә ни алга китә алмадык* (А. Шамов). *Зыятдин карт ч а к ы р ы п т а чыкмады* (Р. Вәлиев).

Хәбәре *-ып* хәл фигыле белән бирелгән синтетик җөмләдәге эш-хәл баш җөмләдәге эш-хәл белән параллель яки эзлекле үтәлә. Бу очракта кушма җөмлә семантикасы белән тезмә кушма җөмләгә охшый: *Моның төн вә көнбатыш яклары киң вә тигез иген басуы булып, безнең нәкъ шул күлгә башы төшә торган җиребез бар* (Г. Ибраһимов).

Инкяр итүне белдергәндә, хәл фигыльдәге *-ып* формасы *-мыйча* (кыскарак варианты: *-мый/-ми*) формасы белән алмашына. Бу очракта синтетик җөмлә баш җөмләгә төрле мөнәсәбәттә тора:

а) вакыт мөнәсәбәтендә: *Улыбыз кайтмыйча, кунак җыймаска булдык* (И. Гази);

ә) шарт мөнәсәбәтендә: *Җир яшәрмәс, гөл ачылмас, төшми яңгыр тамчысы* (Г. Тукай). *Әйтми – беленми, ачмый – күренми* (мәкаль); *Җил басылмыйча җыеп булмас.*

б) *дә* кисәкчәсе килсә, кире шарт мөнәсәбәтендә: *Син ярдәм итмичә дә җитешербез дип торабыз* (К. Тинчурин).

**§ 296. Хәбәре шарт фигыль белән бирелгән синтетик җөмләләр**. Шарт фигыль төрки телләрнең үзенчәлекле күренеше санала. Бер яктан, ул хикәя фигыльләр кебек үк зат-сан белән төрләнә, икенче яктан, шарт фигыль, хикәя фигыльләрдән аермалы буларак, гади җөмлә хәбәре булып килә алмый, хәл фигыльләр кебек, синтетик җөмлә хәбәре я ярым хәбәрлекле кисәк булып кына килә ала. Затланышлы саналса да, шарт фигыль гади җөмләне дә, кушма җөмләне дә тәмамлап куя алмый, аның хәбәрлекле бөтенлеге юк.

Башка очраклардагы кебек үк, хәбәре фигыльдән башка сүзләр белән бирелгән җөмләләргә шарт мәгънәсендә кулланылырга туры килсә, алар башта *бул* фигылен алалар һәм шул фигыль шарт формасында килә: *Син инженер булсаң, әниең шатланыр иде.* Шарт формасын ала алмый торган фигыльләр дә, шарт мәгънәсен белдерү өчен, башта *бул* фигылен алалар: *Син кайтасы булсаң, эшләр җайланыр иде.*

Тагын шуны да истә тотарга кирәк: *-са* формасын фигыльләр генә түгел, кайбер хәбәрлек сүзләр дә ала: *Икмәк кирәксә, эшләп аласың. Җыелышта катнашырга ярас, сөйләр идем мин* (халык иҗаты).

Шарт фигыль формасы белән параллель *әгәр* һәм *гәрчә* теркәгечләре дә кулланыла: *Кошсыз тирәк булыр иде йөрәк, Сагынулар әгәр булмаса!* (Р. Харис). *Гәрчә ул килсә дә, без шатланмадык.* Биредә теркәгеч бар дип, кайбер синтаксистлар хәбәре шарт фигыль – затланышлы фигыль белән бирелгән синтетик җөмләне аналитик җөмлә итеп карарга тәкъдим итәләр. Бу караш белән килешү мөмкин түгел, чөнки *әгәр* һәм *гәрчә* теркәгечләре, алынма сүзләр буларак, *-сә* кушымчасына мәҗбүри булмаган (ягъни стилистик) өстәмә чара булып кына киләләр. Аларның кулланылышы мәҗбүри түгел, алардан башка да *-са* кушымчасы үз функциясен тулысынча үти ала:

*Син килсәң, без шатланыр идек; Ул килсә дә, без шатланмадык.* Димәк, мондый җөмләләрдә төп бәйләүче чара – шарт фигыль кушымчасы, ягъни синтетик чара, шуңа күрә хәбәре шарт фигыль белән бирелгән җөмлә синтетик җөмлә эчендә каралырга тиеш.

Хәбәре шарт фигыль белән бирелгән синтетик җөмлә баш җөмләдән аңлашылган эш-хәлнең шартын белдерә: *Б а ш ы ң  э ш л ә м ә с ә , аягың күп йөрер* (мәкаль).

Шарт фигыль белән бирелгән хәбәр янында *да* кисәкчәсе килсә, синтетик җөмлә көтелгән эш-хәлнең баш җөмләдә киресе үтәләчәген белдерә: *Ч о р л а р  н и н д и  г е н ә  б у л с а  д а , кеше һаман шул ук кеше булып кала икән* (М. Вәлиев). *К а р ш ы  а л ы р г а  а т  җ и г е п  к и л г ә н  б у л с а л а р  д а , җәяү кайтасым, сагынылган саф һаваны озаграк сулыйсым килде* (Ф. Яруллин). *Иманлы кеше, ү з е н ә  з ы я н  к и л е р д ә й  б у л с а  д а , яхшылык эшли* (М. Юныс). *С ә л ә т е  а л а й  з у р  б у л м а с а  д а, Өметгали ышанычлы студент иде* (М. Юныс).

Кире мәгънә белдерүче синтетик җөмлә булып, гади җөмләнең теләсә нинди моделе килә ала: *Ул  ө й л ә н ә с е  б у л с а  д а , эштән җибәрмәделәр* (Х. Сарьян). *У к ы р г а  с о ң  б у л с а  д а тырышты* (Ф. Хөсни). *Б о з  ө с л ә п  ч ы г а р л ы к  б у л с а  д а , алар язны көтеләр* (Ф. Хөсни) һ.б.

Аерым очракларда хәбәре шарт фигыль белән бирелгән синтетик җөмлә семантик яктан баш җөмләгә буйсынмыйча килергә мөмкин. Бу вакытта ике җөмлә арасында чагыштыру мөнәсәбәте генә урнаша. Ә мондый мөнәсәбәт тезмә кушма җөмләләргә хас. Мисаллар: *Юньле кеше баласы дип йөрсәм, синнән дә юньсез сүз чыгып куйды бит әле* (Г. Бәширов). *К а м ч ы  т ә н н е  г е н ә  а в ы р т т ы р с а , агулы сүз бәгырьгә тия* (М. Юныс). Шарт фигыль бу урында стилистик чарага якын, аны гадәти форма белән дә җиңел алмаштырып була: *Юньле кеше баласы дип йөргән идем… Камчы тәнне генә авырттыра…*

Шарт фигыль белән бирелгән хәбәрне шулай стилистик (грамматик мәгънәле – релевант итмичә) куллану аналитик иярчен җөмләләрдә дә күзәтелә: *Кигән кием ничек т у з с а , яшь гомер шулай уза – Кигән кием ничек т у з а , яшь гомер шулай уза* (җыр). Мондый җөмләләрдә шарт фигыль формасы җөмләләр арасында мәгънә мөнәсәбәтен белдерү өчен түгел, стилистик чара гына булып килгән.

Бу мисалда җөмләләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтен мөнәсәбәтле сүзләр белдерәләр.

**§ 297. Хәбәре III зат берлек сандагы боерык фигыль белән бирелгән синтетик җөмләләр.** Мондый форманы фигыль хәбәрләр – турыдан-туры, исем хәбәрләр *бул* фигыле ярдәмендә алалар.

Хәбәре -*сын* формасындагы фигыль белән бирелгән синтетик җөмлә, баш җөмләгә юнәлеш килеше кушымчасы ярдәмендә бәйләнсә, баш җөмләдән аңлашылган эш-хәлнең кыек объектын белдерә: *Борынгырак заманнарда авыл халкы, игеннәр ишелеп уңсын, бөртекләр авыр, салмак булсынга юрап, орлык белән бергә күкәй дә чәчә торган булганнар* (Г. Бәширов).

*Булсынга* формасындагы синтетик җөмләне ияртүче фигыль татар телендә күп түгел, шулар арасыннан активы – *юрау* фигыле.

Хәбәре -*сын* формасындагы фигыль белән бирелгән синтетик җөмлә баш җөмләгә *өчен* бәйлеге ярдәмендә иярсә, баш җөмләдән аңлашылган эш-хәлнең үтәлү максатын белдерә: *Әтиләре, абыйлары җиңеп кайтсын өчен, укучылар тырышып укыдылар, тырышып эшләделәр* (Б. Рәхмәт).

Хәбәре -*сын* формасындагы фигыль белән бирелгән синтетик җөмлә, баш җөмләгә *күрә (-га күрә)* бәйлеге аша бәйләнсә, шулай ук максат белдерә: *Бабай каравылга чыга алсынга күрә, аңа өстәмә паёк бирәләр иде* (А. Шамов).

**Искәрмә.** Хәбәре -*сын* формасындагы фигыль белән бирелгән җөмлә баш җөмләгә *дип* сүзе ярдәмендә дә буйсына: *Саф һава керсен дип, мин тәрәзәләрне ачтым*. Бу җөмлә дә синтетик җөмләләр рәтеннән каралырга тиеш иде, ләкин *дип* сүзе теләсә нинди модельдәге гади җөмләне баш җөмләгә бәйли, ияртә, ягъни ул чара ярдәмендә аналитик кушма җөмлә барлыкка килә. Шуңа күрә *дип* сүзе ярдәмендә баш җөмләгә бәйләнгән һәр җөмләне аналитик кушма җөмлә бүлегендә карау дөресрәк булыр дигән фикергә киленде. Синтетик кушма җөмлә бүлегендә менә шушы искәрмәне бирү белән чикләнү кирәк табылды.

**§ 298. *Күренә, тоела* кебек баш җөмләгә *кебек*, *сыман* яки *шикелле* бәйлеге аша ияргән синтетик җөмләләр**. Сүзне баш җөмләдән башлыйк. *Күренә, тоела* кебек сүзләр белән бирелгән баш җөмлә гади җөмләнең 41 нче [*БК. төш. юн. Ф*] моделенә туры килә. Бу төр баш җөмләгә *кебек*, *шикелле* яки *сыман* бәйлеге ярдәмендә теләсә нинди модельдәге җөмлә буйсынып килә ала. Мондый синтетик җөмләләр

баш җөмлә булып килгән *күренә, тоела* кебек хәбәрлекнең рәвешен белдерәләр: *Бу малайдан киләчәктә рәт чыгар кебек күренә* (Ф. Хөсни). *Кайтырсың шикелле тоела* (Х. Туфан). *Сиңа мин килмәмен сыман тоелган* һ.б.

Бу төр кушма җөмләләр синтетик кушма җөмлә белән аналитик кушма җөмлә арасында торалар: иярчен җөмлә гади җөмләнең теләсә нинди моделенә туры килә, аларда ия белән хәбәр гади җөмләдәге кебек үк ярашып килә, шуңа күрә аларны аналитик җөмлә дип танып була. Ә менә ияреп килгән җөмләне баш җөмләгә бәйләүче чара – бәйлекләр (*кебек*, *сыман* яки *шикелле*), шуңа күрә ияреп килгән җөмлә синтетик җөмлә эченә керә.

*Тоела, күренә* кебек фигыльләр, төп юнәлештә (*тоям, күрәм, хис итәм*) килгәндә дә, баш җөмлә хәбәре була алалар, ләкин бу очракта иярүче җөмләнең үз субъекты булмый; ләкин җөмлә булып формалаша: *Мин үземне әле эшли алырмын кебек хис итәм. Син үзеңне һәр эштә өстен чыгарсың кук тойдың; Мин сине килерсең кебек хис иттем* һ.б. Биредә ияреп килгән җөмлә хәбәре затланышлы фигыль белән бирелгән. Бу яктан ул аналитик җөмләгә якын, ләкин баш җөмләгә бәйлек ярдәмендә ияргән. Бу яктан синтетик җөмләгә якын.

**Искәрмә**. *Тоела, күренә, тоям, күрәм* кебек баш җөмләгә теләсә нинди модельгә туры килә торган җөмлә *дип* сүзе ярдәмендә дә бәйләнә ала: *Мин үземне һаман арымыйм дип хис итәм.* Югарыда әйтелгәнчә, *дип* аналитик чарага каратыла, шуңа күрә мондый җөмләләр аналитик кушма җөмлә эчендә каралалар.

Шулай итеп без синтетик кушма җөмләләрне хәбәр формасына карап төркемләүне аларның ярым хәбәрлекле төзелмәләргә якыннарыннан башладык, аналитик җөмләләргә якыннары белән тәмамлап куйдык.

## АНАЛИТИК КУШМА ҖӨМЛӘЛӘР

**§ 299. Гомуми мәгълүмат.** Иярчен җөмләсе баш җөмләгә аналитик чара ярдәмендә бәйләнгән һәм формасы белән гади җөмләгә охшаган иярченле кушма җөмлә аналитик кушма җөмлә дип атала. Аналитик кушма җөмләдәге иярчен җөмләне аналитик иярчен җөмлә дип атыйлар иде, аны хәзер, бераз җыйнакландырып, аналитик җөмлә дип атау тәкъдим ителә.

Аналитик кушма җөмләләр рус телендәге сложноподчиненные предложения дигән синтаксик төзелмәләргә туры киләләр. Ләкин татар телендәге аналитик кушма җөмләләрне беренче грамматикаларда аерып күрсәтә белмәделәр, бары синтетик кушма җөмләләр турында гына сүз алып бардылар. Ә синтетик кушма җөмләләр, инде әйтелгәнчә, рус телендә юк, анда бары аналитик кушма җөмләләр генә үсеп киткән. Менә шул русчадагы аналитик кушма (сложноподчиненные) җөмләләрне татарчада бары синтетик кушма җөмләләр белән чагыштырып, беренче телчеләр татар һәм төрки телләрдә кушма җөмләләр юк дигән нәтиҗәне чыгарганнар. Эш хәтта шуңа барып җиткән: кайбер галим-сәясәтчеләр «төрки телләрдә кушма җөмлә булмау – төркиләрнең катлаулы уйларны әйтә алмау нәтиҗәсе» дип расларга тырышканнар.

Төрки телләрдә аналитик кушма җөмләнең тулы бер системасы булу аларда кушма җөмлә юк дигән уйдырманы юкка чыгара.

Билгеләмәдән үк күренгәнчә, аналитик иярчен җөмлә баш җөмләгә аналитик чаралар ярдәмендә иярә. Аналитик бәйләүче чараларга көттерү паузасы (интонациясе), ияртүче теркәгечләр, ияртүче теркәгеч сүзләр, мөнәсәбәтле сүзләр һәм хәбәрнең бөтенлегенә зыян китерми торган кайбер кушымчалар һәм бәйлек сүзләр карыйлар. Аналитик чара бервакытта да аналитик җөмләнең хәбәре составында килми, шуңа күрә аналитик җөмлә формасы белән гади җөмләгә охшый, аның хәбәре тулы, затланышлы була. Мәсәлән, *Син кайчан кайтасың, мин шунда сөйләрмен* дигән аналитик кушма җөмләдә иярчен җөмлә баш җөмләгә *кайчан – шунда* парлы мөнәсәбәтле сүзе белән бәйләнгән, бу – аналитик чара, чөнки алар ике җөмләнең дә хәбәре составында тормыйлар, иярчен җөмләнең хәбәрен бөтен килеш калдыралар. Шуңа күрә *Син кайчан кайтасың* дигән иярчен җөмлә формаль яктан гади җөмләгә охшаган, анда ия һәм хәбәр үзара ярашып та килгәннәр, ул баш җөмләгә керешеп китмәгән, аннан аерылып тора, шуңа күрә аны аналитик җөмлә диләр (анализ ‘аеру’ сүзеннән). Әле генә китерелгән аналитик җөмлә үзенең синтетик парына бик җиңел әйләнә: *С и н к а й т к а ч сөйләрмен.* Биредә җөмләнең *Син кайткач* өлеше синтетик җөмлә була, чөнки ул бәйләүче чараны хәбәр составына керткән, хәбәр үзенең бөтенлеген җуйган, баш җөмләгә синтезлашып, керешеп киткән. Күренә ки, аналитик җөмлә синтетик җөмләдән бик нык аерылып тора.

Аналитик кушма җөмләләр аналитик һәм баш җөмләне үзара бәйли торган чаралар буенча төркемләнәләр, һәм бу төркемләү аналитик иярчен җөмләләрне төркемләү аркылы алып барыла. Башта аналитик җөмләләрнең синтетик җөмләләргә аз булса да якынлык күрсәткәннәре, соңга таба синтетик җөмләләрдән бик нык аерылып торганнары тикшерелә.

## АНАЛИТИК ҖӨМЛӘЛӘРНЕ БАШ ҖӨМЛӘГӘ ИЯРҮ ЧАРАЛАРЫ БУЕНЧА ТӨРКЕМЛӘҮ

### Баш җөмләгә хәбәр бөтенлеген бозмый торган кушымчалар аша ияргән аналитик җөмләләр

**§ 300. Бу төр җөмләләрнең төп үзенчәлекләре.** Хәбәр формасы аша баш җөмләгә ияру ул синтетик җөмләләргә хас күренеш. Ләкин биредә ияртүче чара, хәбәр формасын тәшкил итсә дә, аның бөтенлеген җуймый, иярчен җөмлә гади җөмләгә охшаган була, шуңа күрә бу төр иярчен җөмләне аналитик иярчен җөмлә дип танырга туры килә, ләкин аның синтетик җөмләгә якын ягын да күрсәтми мөмкин түгел.

Хәбәрнең бөтенлеген бозмыйча аның составында килә торган чараларга боеру наклонениесе кушымчасы һәм *-мы/-ме, -мыни/-мени* сорау кушымчалары (кисәкчәләре диярге дә була) килә: *Мин ничек кенә тырышмыйм, ул барыбер үзенекен итә* (К. Тинчурин). *Бу йорт, кайчан гына карама, гел буш тора* (Ә. Еники). *Ул каядыр китеп бардымы, өйдә тәртип бетә* (И. Гази). *Тоз суы сипкәннәрмени, инде җыелды халык!* (М. Гафури). *Өйдә, кич җиттеме, гел шул уку турында була иде сүз* (Р. Вәлиев).

Бу төр аналитик җөмләләрне баш җөмләгә ияртеп килүдә көттерү паузасына якын булган интонация дә ярдәмгә килә булса кирәк. Монысын, билгеле, эксперименталь юл белән тикшерү сорала.

Хәбәре баш җөмләгә боерык фигыль формасы аша бәйләнсә, аналитик җөмлә баш җөмләгә карата шарт яисә кире шарт мөнәсәбәтендә тора.

Баш һәм аналитик җөмләнең хәбәрләре икесе дә я раслау, я инкяр формасында торсалар, җөмләләр арасында шарт мөнәсәбәте урнаша: *Инде чана юлы гына төшсен, барып дәррәү эшләп алырбыз дип торалар иде* (Г. Ибраһимов). *Сибеп карасыннар, бирер әтисе үзләренә кирәкләрен* (И. Гази).

Аналитик һәм баш җөмлә хәбәрләренең берсе – раслау, икенчесе инкяр формасында торсалар, җөмләләр арасында кире шарт мөнәсәбәте урнаша: *Уянмый ул, бөтен кеше тавышлансын* (Г. Тукай). *Барлык дуслары ялынсыннар, ул барыбер хәрби хезмәттә калачак* (А. Шамов).

Бу төр кире аналитик җөмлә, инкяр формасын һәм сорау алмашлыгын алып, экспрессив сөйләмдә бик актив кулланыла: *Кайчан карама, шул чепи күз йөгереп килеп җиткән була* (А. Шамов). *Мин ничек кенә каршы төшмим, ул һаман шул йорт тирәсендә чуала* (Ә. Фәйзи). *Партизаннар ничек кенә тырышмасыннар, кыш үзенекен итте* (А. Шамов).

Хәбәре *-мы/-ме* сорау кисәкчәсен алса, аналитик җөмлә баш җөмләдәге ситуациянең шартын белдерә: *Бер нәрсә искә төшteme, чыгырдан чыгып китәбез* (Г. Бәширов). *Бераз буш вакыты булдымы, Айрат хат язарга утыра* (Ф. Яруллин). Сорау кисәкчәсен алган хәбәр, гадәттә, үткән заманда килә.

Хәбәре *-мыни/-мени* сорау кисәкчәсен (кушымчасын) алса, аналитик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең рәвешен белдерә: *Бөтенесен берьюлы кояш нурыннан әвәләп ясаганнармыни, көләчләр* (Ф. Хөсни). *Артымнан куып киләләрмени, йөгерәм дә йөгерәм икән* (Ә. Еники). Бу төр аналитик җөмләнең хәбәре гадәттә өченче зат күплектәге хәзерге заман фигыле белән бирелә, һәм җөмлә бер составлы, билгесез үтәүчеле була.

## Баш җөмләгә хәбәр бөтенлеген бозмый торган бәйлек-теркәгеч сүзләр аша ияргән аналитик җөмләләр

**§ 301. Бу төр җөмләләрнең төп үзенчәлекләре.** Иярчен җөмләнең хәбәр тулылыгына зыян китерми торган бәйлек-теркәгеч сүзләргә *исә, икән, дип, дигән* ярдәмлек сүзләре карый. Болар ике җөмлә арасында килүләре белән бәйлекләргә якын торалар, ә хәбәрнең тулылыгына зыян китермиләр, чөнки алар, бәйлекләрдән аермалы буларак, үзләре янындагы хәбәрнең билгеле бер формада килүен таләп итмиләр, шуңа күрә иярчен җөмләнең хәбәре гади җөмләдәге кебек тулы килеш сакланып кала. Менә шушы үзенчәлекләреннән чыгып, *исә, икән, дип, дигән* ярдәмлек сүзләрен бәйлек-теркәгеч сүзләр дип атарга мөмкин. Мисаллар күзәтик. *Мин килдем исә, син чыгып*

*китәсең* җөмләсендә *исә* сүзе ике җөмлә арасында тора, ике җөмлә арасында шарт мөнәсәбәте урнаштыра, шул ягы белән ул бәйлеккә охшаган. Ләкин бу *исә* сүзе үзеннән алда килгән җөмләнең гади җөмләгә охшаган бөтенлеген юкка чыгармый: *Мин килдем* тезмәсе аналитик җөмлә буларак кабул ителә.

*Мин барыбер укыйм диган фикер аның миенә бик нык сеңгән* төзелмәсендә *диган* сүзе җөмләләр арасында атрибутлык мөнәсәбәте урнаштыра, ләкин иярчен җөмлә хәбәренең бөтенлегенә зыян салмый. *Син киләсең дип, мин башыма да китермәгән идем* җөмләсендәге *дип* сүзе дә үзеннән алдагы җөмләнең аналитиклыгына зыян китерми.

*Без җиңәргә сүз куешканбыз икән, бу – буш сүз түгел* (Ә. Фәйзи) төзелмәсендә дә иярчен җөмлә аналитик килеш калган.

Бәйлек-теркәгеч сүзләрнең төрлесе билгеле бер шартларда да җөмләләр арасында төрле мәгънәләр урнаштыра.

1. *Исә, икән* сүзләре ярдәмендә бәйләнгән аналитик җөмлә баш җөмләдә бирелгән эш-хәлнең шартын белдерә: *Менә мин дә, буш вакытым чыкты исә, тәрәзә каршына киләм дә сәгатьләр буе шулай карап торам* (Р. Вәлиев). *Сез безгә вакытында килеп җитәсез икән, бернинди үпкәләү булмаячак* (Г. Гобәй).

Мондый кушма җөмләләргә, шарт мөнәсәбәтен көчәйтеп, *әгәр* теркәгече дә өстәлергә мөмкин: *Әгәр вакытында разведка ясалмаган икән, югалту да күбрәк була* (Г. Әпсәләмов). *Әгәр кергәнсең икән, тавышланма* (И. Гази). *Әгәр ул күренде исә, барып әйтербез.*

Искерәк әдәби телдә аналитик җөмләнең хәбәре *-мыш исә дә* формасын да алгалаган. *Дә* кисәкчәсе булу бу төр җөмләләр арасында кире шарт мөнәсәбәтен урнаштыра: *Җәйнең туктаусыз хезмәте бик ардырмыш исә дә, халыкның күңеле күтәренке, йөзе шат иде* (Г. Ибраһимов).

Бу уңай белән искә төшерик, бәйләүче чара *исә, икән* булганда, алар янында *да* кисәкчәсе килә алмый, *-мыш исә дә* формасы чыгарма буларак күзәтелә.

2. *Ди* фигыле теләсә нинди модельдәге җөмләне баш җөмләгә бәйләүче универсаль чара булып санала, бик күп формаларда кулланыла: *дип, дигәч, дигән, дигәннең, дигәнне, дигәнгә, дигәннән, дигәндә, ди-*

*гәндәй, дигән чакта, дигән вакытта, дигәнгә кадәр, дигәннән соң, дигән саен, дигән кебек, дигән сыман, дигән төсле, дию, дию аркасында, диюдән башка, диюгә карамастан, дияр, диярлек, диярлек кадәрле һ.б.*

Аналитик җөмләне баш җөмләгә бәйләп, *ди, дип, дигәч* формалары бик актив кулланыла.

*Дип* белән бәйләнгән аналитик җөмләләр баш җөмләдән аңлашылган ситуациянең төрле якларын ачыклыйлар:

– баш җөмләдәге эш-хәлнең объектын белдерәләр: *А й с ы л у б е л ә н Х ә с б и б и к т а т у б у л г а н н а р д ы р д и п уйлап алды* (Г. Бәширов). *Сез күптән килдегезме? – д и п сорады карт* (Ш. Камал).

Бу чара теләсә нинди туры сөйләмне автор сүзләренә (баш җөмләгә) бәйли һәм җөмләләр арасында объектлык мөнәсәбәте урнаштыра:

– баш җөмләдәге эш-хәлнең үтәлү рәвешен белдерәләр: *М и н а н ы к ү п т ә н б е л ә м д и п тавыш куптарды сатучы* (А. Шамов). *Монда алай и л х а к ы н а к у л с у з г а н д и п дау кубарырлык берни дә юк* (Ф. Хөсни);

– баш җөмләдәге эш-хәлнең үтәлү максатын белдерәләр: *Матур көндә чыгам кырга, а ч ы л м а с м ы к ү ң е л л ә р д и п* (Г. Тукай). *Т е л е а ч ы л м а с м ы д и п , хәл-әхвәлләрен җентекләп сораша* (Ә. Еники);

– баш җөмләдәге эш-хәлнең үтәлү сәбәбен белдерә: *Җ и р б е л ә н К ү к с у г ы ш а д и п , йөрәгем яргаланды* (Р. Харис). *Аның да бит фронттан кайткан әтисен, п л е н д а б у л г а н д и п , 1946 елда утыртып куйган булалар* (Р. Мөхәммәдиев).

*Дигәч* белән бәйләнгән аналитик җөмлә баш җөмләдән аңлашылган эш-хәлне төрле яклап ачыклый ала:

– сәбәп белдерә: *Ә т и е ң - ә н и е ң ш у ш ы й о м ы к ы й м а л а й г а к о я ш к е б е к к ы з ы б ы з н ы б и р м и б е з, д и г ә ч , мин сине урлап качтым* (М. Хуҗин);

– вакыт белдерә: *К ө н н ә р м а т у р л а н д ы д и г ә ч к е н ә , тагын коеп яңгыр яварга тотынды* (Г. Ибраһимов);

– кире мәгънә белдерә: *П а т ш а б у л д ы м д и г ә ч т ә , син бик борыныңны чөймә әле* (И. Гази).

3. *Дигән* сүзе һәм аның төрләнгән вариантлары аналитик җөмләне баш җөмләгә бәйләгәндә, җөмләләр арасында шулай ук күптөрле мәгънә мөнәсәбәтләре урнаша.

*Диган* сүзе аша бәйләнгәндә, аналитик җөмлә баш җөмләдәге ияртүче сүздән аңлашылган предметның атрибутын белдерә: *Без моны булдыра алмыйбыз диган фикер белән килешмим мин* (И. Гази). *Мин күрмәдем диган сүз белән котыла алмассың* (Ә. Фәйзи). *Моңлы кешеләрнең гомере кыска була диган сүз бар халыкта* (М. Вәлиев).

Югарыда әйтелгәнчә, *диган* бәйлек-теркәгеч сүзе кушымчалар ала һәм җөмләләр арасында төрле мөнәсәбәт урнаштыра:

– *диганнең* сүзе ярдәмендә бәйләнгән аналитик җөмлә баш җөмләдәге ияртүче сүзнең аергычы булып килә: *Мин белмим диганнең башы авыртмас* (Ә. Исхак).

– *диганне* сүзе җөмләләр арасында объектлык мөнәсәбәте урнаштыра: *Сөйләгез диганне көтеп торма* (А. Шамов);

– *дигангә* сүзе җөмләләр арасында сәбәп мөнәсәбәте урнаштыра: *Характерлары белән килешмәделәр дигангә исегез китмәсен...* (Ә. Еники);

– *диганнән* сүзе җөмләләр арасында сәбәп объекты мөнәсәбәте урнаштыра: *Сөйгәннән тел китми диганнән син әллә нәрсәләр уйлый күрмә* (Г. Ибраһимов);

– *дигандә* сүзе җөмләләр арасында вакыт мөнәсәбәте урнаштыра: *Кунак ашы – кара-каршы дигандә, авызыңны ачып торасың* (Ш. Усманов);

– *дигандәй* сүзе җөмләләр арасында чагыштыру-рәвеш мөнәсәбәте урнаштыра: *Ат азгыны тайга ияр диган-дәй, Фәхри дә, җитмәсә тагын, сакаллы башы белән шул ирен-нәреннән сөте кипмәгән малайны яклап тора* (Г. Ибраһимов). *Бер карт миңа кирәге нәкъ менә шушы булырга тиеш дигандәй, ишекне капыл гына тартып эчкә керде* (Ф. Хөсни).

*Диган* бәйлек-теркәгеч сүзе төрле бәйлек һәм бәйлек сүзләр белән бергәләп тә җөмләләрне бәйләүдә катнаша һәм җөмләләр арасында төрле мәгънә мөнәсәбәтләре урнаштыра:

– *диган чакта (диган вакытта)* ярдәмендә җөмләләр арасында вакыт мөнәсәбәте урнаша: *Аучы күгәрченне аулыйм диган чакта гына, кырмыска аучының ботыннан бик каты итеп тешләде* (Г. Тукай);

– *дигәннән соң, дигәнгә кадәр (чаклы)* формалары аналитик җөмлә белән баш җөмлә арасында шулай ук вакыт мөнәсәбәте урнаштыра: *Бер елдан кайтабыз дигәннән соң да, инде күпме гомер үтте* (Г. Кашшаф). *Башладык дигәнгә чаклы, берегез дә атмый* (А. Шамов);

– *дигән саен* формасы белән бәйләнгәндә, җөмләләр арасында күләм-чама мөнәсәбәте урнаша: *Тиле, тиле дигән саен, тигәнәк буе сикерә* (мәкаль);

– *дигән кебек (сыман, төсле)* формасы җөмләләр арасында рәвеш (процессның үтәлү рәвеше) мөнәсәбәте урнаштыра: *Моны күрүгә, качмасын дигән кебек, Шәрәфи шул якка ташланды* (Г. Ибраһимов);

– *дигәнгә күрә (дигән өчен)* формасындагы аналитик чара, аналитик һәм баш җөмләләр арасында сәбәп мөнәсәбәте урнаштыра: *Партизаннар үч алыр әле дигән өчен, икенче мәртәбә җавапка тарталар* (Г. Кутуй).

4. Аналитик җөмләне баш җөмләгә буйсындырып килү вазифасын *дию* (исем фигыль формасы), *дияр, диярлек* формалары да башкара. Болар әле тагын башка бәйләүче чараларны да кабул итә алалар, җөмләләр арасында төрле мәгънә мөнәсәбәте урнаштыралар:

– *дию* бәйлек сүзе ике җөмлә арасында хәбәрлекле мөнәсәбәт урнаштыруда катнаша: *Син минем бәгърем дию генә җитми* (халык иҗаты);

– *дию аркасында* сүзе җөмләләр арасында сәбәп мөнәсәбәте урнаштыра: *Анын исемлеккә керми калуы без барыбер килмәячәкбез дию е аркасында булды;*

– *диюгә карамастан* сүзе белән бәйләнгәндә иярчен һәм баш җөмләләр арасында кирелек мәгънәсе урнаша, ягъни иярчен җөмләне әйткәч, баш җөмләдә көтелгәннең киресе буласы аңлашыла: *Урын бөтенләй юк диюгә карамастан, ике машина җибәргән* (М. Максуд);

– *диюдән башка* сүзе ярдәмендә бәйләнгәндә, иярчен җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең чыгарма объектын белдерә: *«Үтәлде!» диюдән башка сүз әйтә алмады* (А. Әхмәт);

– *диярлек кадәр* сүзе җөмләләр арасында күләм-чама мөнәсәбәте урнаштыра: *Һәммәбез дә килгән бушка китмәде диярлек кадәрле балыклар тоттык* (Г. Ибраһимов);

– *дияр* сүзе җөмләләр арасында атрибутлык (аергыч-аерылмыш) мөнәсәбәте урнаштыра: *Б е з  и н д е  к а р т а й д ы к  д и я р  чаклар җитте* (А. Шамов).

## Баш җөмләгә ияртүче теркәгеч яки теркәгеч сүз аша ияргән аналитик җөмләләр

**§ 302. Бу төр җөмләләрнең төп үзенчәлекләре.** Ияртүче теркәгеч яки теркәгеч сүзләр баш җөмләгә, гади җөмләнең теләсә кайсы моделенә туры килә алырлык, аналитик иярчен җөмләләрне бәйлиләр. Һәрбер теркәгеч һәм теркәгеч сүз җөмләләр арасында үзенә генә хас мәгънә мөнәсәбәте урнаштыра, бары *ки* теркәгеченең генә үзенә хас мәгънәсе юк, ягъни ул җөмләләр арасында күптөрле мәгънә мөнәсәбәтләре булганда килә ала. Шуңа күрә *ки* теркәгече, грамматик чара булудан бигрәк, стилистик чарага тартым. Шулай да аны грамматик чаралар рәтеннән ияртүче теркәгеч дип йөртү гадәткә кергән.

Ияртүче теркәгеч сүзләр *(хәтта, хәер, юкса, бигрәк тә, аннан да бигрәк, әйтерсең, башкача, башкача әйткәндә, ул да түгел),* теркәгечләрдән аермалы буларак, үзләренең теркәгечкә хас булмаган мәгънәләрен дә белдерәләр, җөмләләрне үзара бәйләгәндә, теркәгеч сүз булып, алар арасында төрле мәгънә мөнәсәбәтләре урнаштыруда да катнашалар.

1. Ияртүче теркәгечләр аналитик җөмләне баш җөмләгә ияртकәндә, алар арасында күптөрле мәгънә мөнәсәбәтләре күзәтелә.

1) Төрле стильләрдә иң еш кулланыла торган ияртүче теркәгеч – *чөнки*, ул һәрчак аналитик җөмлә составында килә һәм җөмләләр арасында сәбәп мөнәсәбәте урнаштыра: *Ә шагыйрьнең юк һәм булмас ярдәмчесе-мазары, ч ө н к и  ш а г ы й р ь,  я р а л м ы ш т а н,  – х а л ы к  у р ы н б а с а р ы !* (Р. Харис).

*Чөнки* теркәгече баш җөмләдәге *шуның өчен, шуңа күрә* кебек мөнәсәбәтле сүз белән бергәләп тә кулланыла һәм сәбәп мөнәсәбәтен белдерә: *Көмештән шуның өчен акча ясадылар, ч ө н к и  к ө м е ш  – ы ш а н ы ч л ы,  б ә һ а л е  т о в а р* (Г. Тукай).

2) *Гүя* теркәгече, аналитик җөмләне баш җөмләгә бәйләп, гадәттә язма әдәби телдә кулланыла, ул да аналитик җөмлә составында килә һәм баш җөмләдән аңлашылган эш-хәлнең үтәлү рәвешен чагыштыру

юлы белән белдерә: *Урыныннан кузгала алмый, гүя аны нидер тота* (Г. Ибраһимов).

3) *Ки* теркәгече язма әдәби телдә дә, диалектларда да кулланыла, ул җөмләләр арасында үзенә генә хас бер мәгънә урнаштырмый, төрле мәгънә мөнәсәбәтләре белән бергә килә ала. Шул ягы белән ул стилистик чарага якын, һәм мәгънәгә зыян китермичә аны җөмләдән алып ташлап та була, тик бу очракта стилистик төсмер генә үзгәрә. *Ки* теркәгече, ярдәмче чара буларак, башка бәйләүче чаралар (мөнәсәбәтле сүзләр, *гүя* теркәгече) белән параллель кулланыла ала, һәрчак баш җөмлә составында килә.

а) *Ки* теркәгече, ияртүче чара булып, көттерү паузасы белән бергә кулланыла, аналитик җөмлә баш җөмләнең иясе функциясен башкара: *Шул вакытта минем исемә төште ки, минем сурәтләр төшергән бер кечкенәрәк китабым бар иде* (Г. Тукай).

ә) *Ки* теркәгече, ияртүче чара булып, көттерү паузасы белән бергә килә, бу юл белән бәйләнгән аналитик җөмлә баш җөмләдән аңлашылган эш-хәлнең объектын белдерә: *Мин ышанам ки, сез, Миңнулла агай, ачу сакламассыз* (И. Гази).

б) Җөмләләр арасында башка мөнәсәбәтләр булганда да *ки* теркәгече кулланылырга мөмкин: *Башка халыкта ничектер, бездә бер ел үтми ки, анда бер-бер төрле яңа көй чыкмасын* (Г. Тукай). Биредә җөмләләр арасында вакыт мөнәсәбәте сизелә.

в) Диалектларда *ки* теркәгече җөмләләр арасында бөтенләй көтелмәгән мәгънәләрне белдерә: *Йырак качтың ки, эзләмим* (урта диалект). Биредә сәбәп мөнәсәбәте бар. *Йел булмады ки, бик йылы* (урта диалект). Биредә сәбәп мөнәсәбәте дә, шарт мөнәсәбәте дә сиземләнә.

*Ки* теркәгече иске әдәби телдә һәм хәзерге әдәби тел оешкан чорда бик еш кулланылган, хәзер исә аның кулланылышы сирәгәя бара.

4) *Ягъни* теркәгече белән килгән аналитик җөмлә һәрчак баш җөмләдән соң килә һәм баш җөмләгә карата аныклагыч җөмлә санала, сөйләүче өчен, баш җөмләнең дә, аналитик җөмләнең дә әһәмияте бер үк дәрәҗәдә була: *Быел бик күп хәрби хезмәткәрләр демобилизовать ителделәр, ягъни хөкүмәтебез аларны тыныч хезмәткә кайтарды* («Ватаным Татарстан»).

2. Ияртүче теркәгеч сүзләр аналитик җөмләне баш җөмләгә ияргәндә, алар арасында төрле мәгънә мөнәсәбәтләре күзәтелә. *Юкса, җитмәсә, әйтерсең, ул да түгел, әйтәм (лә)* теркәгеч сүзләре иярчен җөмлә белән баш җөмлә арасында төгәлләүле мөнәсәбәтнең төрле төсмерләрен, ә *димәк, аеруча, бигрәк тә, аннан да бигрәк, башкача (әйткәндә)* теркәгеч сүзләре аныклаулы мөнәсәбәт урнаштыралар.

Беренче төр теркәгеч сүзләр белән бәйләнгәндә, аналитик җөмләне синтетик төргә үзгәртү мөмкинлеге була. Икенче төр ярдәмендә бәйләнгәндә, бу мөмкинлек күзәтелми. Мәсәлән: *Хәлим, дәресләрен хәзерләп бетереп, урамга чыкты, у л  д а  т ү г е л күрше малайлары да кырдан кайтып җиттеләр* (И. Гази) – синтетик синонимы: *Хәлим, дәресләрен хәзерләп бетереп, урамга ч ы г у г а , күрше малайлары да кырдан кайтып җиттеләр.*

1) *Юкса* теркәгеч сүзе *югыйсә* формасын да ала, кайчакта *булмаса* сүзе белән дә алмаштырыла. *Юкса (югыйсә, булмаса)* теркәгеч сүзе баш җөмлә составында килә, аналитик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең шартын белдерә: *С и н  к и л,  ю к с а  ямьсезлек чыгар. Юкса* теркәгеч сүзе *юк* сүзеннән ясалган, шуңа күрә аналитик җөмләдәге эш-хәл раслау аспектында торса, ул инкяр буларак шарт була һәм киресенчә. Мәсәлән, *С и н  к и л,  ю к с а  ямьсезлек чыгар* җөмләсендә *юкса* теркәгеч сүзен төшерсәк, ул *Син килмәсәң, ямьсезлек чыгар* формасында формалаша, ягъни раслау аспектындагы *кил* инкяр формасын ала, һәм киресенчә: *С и н  к и л м ә ,  юкса ямьсезлек чыгар – С и н  к и л с ә ң , ямьсезлек чыгар. Сиңа, кая булса да китеп, кәсеп э з л ә р г ә  тиеш була, ю г ы й с ә  сезнең семьягыз әллә нинди чуалчыкларга очрасыдыр* (Г. Тукай) – *...кәсеп  э з л ә м ә с ә г е з,...*

Диалектларда *юкса* сүзе урынына *ату* алынмасы кулланыла: *Ярый әле, эләктердем, ату егылып төшә иде* (урта диалект).

2) *Җитмәсә* теркәгеч сүзе, баш җөмлә составында килеп, аңа аналитик җөмләне ияртә, ә аналитик җөмлә баш җөмләдән аңлашылган эш-хәлнең үтәлү-үтәлмәү шартын белдерә: *Ул иртән китә дә, көн буе көтү көтеп, кичен безнең янга кайта, җ и т м ә с ә  т а г ы н  к а л г а н  б ә л е ш л ә р,  с и м е з  и т л ә р  а ш а в ы н  с ө й л ә п,  б е з н е ң  й ө р ә к н е  я н д ы р а* (М. Гафури).

3) *Әйтерсең (әйтерсең лә)* теркәгеч сүзе, аналитик җөмлә составында торып, аны баш җөмләгә ияртә. Бу очракта иярчен җөмлә баш

җөмләдәге эш-хәлнең үтәлү рәвешен чагыштыру тәртибендә белдерә: *Менә бервакыт халык агыла, халык агыла башлады, әйтерсең инде бөтен дөнья монда җыелды* (Г. Ибраһимов).

4) *Ул да түгел* теркәгеч сүзе баш җөмлә составында тора һәм аңа вакыт белдерүче аналитик җөмләне ияртә, төгәлрәк әйткәндә, баш җөмләдәге эш иярчен җөмләдәгесе үтәлү белән үк башкарыла: *Галиулла белән Хәлим тиз генә юлдан чыктылар, ул да түгел, әллә никадәр тузан туздырып, күк атлы кеше узып та китте* (И. Гази).

5) *Хәер* теркәгеч сүзе белән килгән баш җөмлә кушма төзелмә ахырында тора, ә башта килгән аналитик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең кире шартын белдерә: *Карты җавап бирмәде, хәер Зифа карчык аның җавабын көтми дә иде* (А. Шамов).

6) *Әйтәм (әйтәм лә)* теркәгеч сүзе баш җөмлә составында килә, баш җөмлә кушма төзелмәнең башында әйтелә, соңыннан сәбәпне белдерүче аналитик иярчен җөмлә килә: *Әйтәм лә бүлмә нурланып китте, Нурия килгән икән* (К. Тинчурин). Бу җөмләләр бәйләнешендә *икән* сүзе дә билгеле дәрәҗәдә роль уйный.

7) *Хәтта* бәйлеге иярчен җөмлә составында тора, ул җөмлә кушма төзелмә ахырында килә, һәм аналитик җөмлә баш җөмләдән аңлашылган эш-хәлнең күләм-чамасын белдерә: *Бик көчле яңгыр явып үтте, хәтта җыелган суда казлар йөзеп йөрде.*

8) *Башкача (әйткәндә), икенче төрле әйткәндә* теркәгеч сүзе, иярчен җөмлә белән бергә килеп, кушма төзелмәнең ахырында тора һәм башта килгән баш җөмләдәге фикерне төгәлләп, башка сүзләр белән җөпләп куя: *Мостафин бу урыннан очып төште, башкача әйткәндә аны яңадан сайламадылар* (Ә. Еники).

9) *Бигрәк тә, аннан да бигрәк, аеруча* теркәгеч сүзләре дә ахырдан әйтелә торган аналитик җөмлә составында булалар һәм баш җөмләдәге бер төшенчәгә басым ясап аныклыйлар: *Картина безгә бик ошады, аеруча укучылар яратып карадылар.*

10) *Һәрхәлдә* теркәгеч сүзе дә ахырдан әйтелә торган аналитик җөмлә составында була, һәм шул аналитик җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлне аныклый: *Хәлим баржада тоз бушатучы егеттән күп нәрсәләргә өйрәнде, һәрхәлдә ул акларның кем икәнлекләренә ачык төшенде* (И. Гази).

11) *Димәк* теркәгеч сүзе ахырдан килә торган аналитик җөмлә составында була һәм аналитик җөмлә баш җөмләдән аңлашылган мәгънәне гомумиләштереп әйтү юлы белән аныклый: *Бикмулла Ватан сугышының башыннан алып ахырына кадәр фронтта булган, димәк, ул яшь солдат янына чакырып алырга иң лаек кеше иде* (Ә. Еники).

*Димәк* теркәгеч сүзе текстта мөстәкыйль җөмләләрне бәйләүдә дә актив кулланыла.

## Баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр аша ияргән аналитик җөмләләр

**§ 303. Аналитик җөмләне баш җөмләгә иярткүче мөнәсәбәтле сүзләр**. Аналитик кушма җөмләләр бик еш мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә төзеләләр, шуңа күрә бу урында мөнәсәбәтле сүзләр белән танышып үтү максатка ярашлы булыр дип уйлыйм.

Мөнәсәбәтле сүзләр – җөмләләрне үзара бәйләүче алмашлыклар, сирәк кенә булса да, алмаштыру сәләте булган башка сүзләр. Мәсәлән, *Мин шуны гына беләм: ел елга охшамый* (Г. Тукай) җөмләсендә мөнәсәбәтле сүз – *шуны,* ул – күрсәтү алмашлыгы, баш җөмләдә торып, иярчен аналитик җөмләне баш җөмләгә бәйләп килә. *Шуны* мөнәсәбәтле сүзе баш җөмләдә тәмамлык булып килгән, аның ярдәмендә баш җөмләгә ияргән җөмлә дә тәмамлык җөмлә була.

*Кем эшләми, шул ашамый* (мәкаль) җөмләсендә ике җөмлә *кем – шул* дигән парлы мөнәсәбәтле сүз ярдәмендә бер-берсенә ияреп килгәннәр; күрсәтү алмашлыгыннан торган өлеше – *шул,* ул баш җөмләдә тора, баш җөмләдә ия ролен үти, аның ярдәмендә баш җөмләгә ияргән иярчен җөмлә дә иярчен ия җөмлә була. Мөнәсәбәтле сүзнең сорау алмашлыгы белән бирелгәне – *кем,* ул иярчен җөмлә эчендә тора.

Тагын бер җөмлә анализлыйк. *Утыр аулакка, кайда һич кеше юк* (Г. Тукай). Бу җөмләдә мөнәсәбәтле сүз – *кайда,* ул – сорау алмашлыгы, иярчен җөмлә эчендә килгән һәм аны баш җөмләгә бәйли, үзе бер үк вакытта иярчен җөмләнең урын хәле дә булып килгән, ә иярчен җөмлә үзе *аулак* сүзенең аергычы хезмәтен үти.

Сорау алмашлыкларының ялгызы гына мөнәсәбәтле сүз булып килүләре төрки телләргә хас түгел, алар төрки телләрдә һинд-европа

төркеменә карый торган фарсы һәм рус телләре йогынтысында кулланылалар.

Мөнәсәбәтле сүзләрнең теркәгечләрдән яки бәйлекләрдән аермасы шунда: алар бер үк вакытта җөмләләрне бәйләү хезмәтен дә үтиләр һәм җөмләнең аерым кисәге булып та киләләр. Мөнәсәбәтле сүзләр җөмләләрне һәрвакыт ияртүле юл белән бәйлиләр; алар бервакытта да тезмә кушма җөмләләрдә булмыйлар, чөнки мөнәсәбәтле сүз һәрвакыт җөмләнең теге яки бу кисәге булып килә, һәм аның ярдәмендә бәйләнгән җөмлә дә баш җөмләнең мөнәсәбәтле сүз белән белдерелгән теге яки бу кисәге функциясен үти.

Кайбер галимнәр мөнәсәбәтле сүзләр аша бәйләнеш төрки телләргә хас түгел дигән караштa торалар. Ләкин бу дөрес түгел. Телдә алмашлыклар кайчан барлыкка килеп, кайчан җөмләләрне алмаштыра башласалар, җөмләләрнең мөнәсәбәтле сүзләр (алмашлыклар) аша бәйләнеше дә шул вакыттан башланган. Мөнәсәбәтле сүзләрнең җөмләләрне үзара бәйләве Орхон-Енисей язмаларында ук очрый: *Körüg saby anlaγ: Toγuz oγuz budun üzä qaγan olurty...* (VIII йөздә язылган), хәзерге телгә үзгәртелгәне: *Күреп-күзәтүченең сүзе шундый: тогуз огуз халкы эчендә каган (хан) утырды.*

Төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә, мөнәсәбәтле сүзләр телне кулланучылар тарафыннан бик нык шомартылган система тәшкил итәләр. Чөнки алар бик борынгы чорда ук актив кулланылганнар, хәзерге төрки телендә тагын да күбрәк очрыйлар... Ләкин мөнәсәбәтле сүзләр һәм аларның җөмләләрне үзара бәйләүләре галимнәр тарафыннан танып беленеп җитмәгән. Төрки грамматикаларын беренче язучылар һинд-европа (шул исәптән рус) телләре грамматикаларыннан файдаланганнар, шуңа күрә мөнәсәбәтле сүзләрнең һинд-европа телләрендәгеләргә туры килә торганнары гына танылган. Мәсәлән, җөмләләрне үзара бәйләүче чаралар итеп, төрек телендә бары *bunun icin, onun üzerine,* башкорт телендә *шуга, шуга күрә, шуга ла, шуның өсөн, шунлыктан, шул аркала, шулай булгас, шуның һөзөмтәһендә* кебекләр генә танылган. Әгәр бу телләрнең мөнәсәбәтле сүзләрен система буларак махсус өйрәнсәләр, аларның бик нык үскән, билгеле бер калыпка салынган системасын табачаклар.

Татар телендә мөнәсәбәтле сүзләрнең озак кулланудан шомарган системасы табылган дип әйтергә мөмкин, хәзер шуны тасвирлыйк.

Татар телендә мөнәсәбәтле сүзләр ялгызак һәм парлы булалар.

Ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр үзләре төп һәм алынма дигән төрләргә бүленәләр.

Төп ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр булып, күрсәтү алмашлыклары яки шуңа нигезләнеп ясалган башка сүзләр киләләр, шулай ук күрсәтү мәгънәсен белдерә торган гомуми мәгънәле сүзләр дә төп ялгызак мөнәсәбәтле сүз була алалар.

Алмашлык яки алмашлыктан ясалган башка сүз, мөнәсәбәтле сүз булып килсә, җөмләләрне алмаштыра, мөнәсәбәтле сүз булып килмәсә, аерым сүзләрне генә алмаштыра. Мәсәлән: *Минем күзләрем ул кадәр җете түгел түгелен, алай да күрәм* (Г. Бәширов) дигән мисалда *алай да* сүзе – мөнәсәбәтле сүз, ул алдагы җөмләне алмаштырып килгән. *Алай да* сүзе урынына иярчен җөмләнең үзен куеп әйтергә мөмкин: *Минем күзләрем ул кадәр җете булмасалар да күрәм.*

Ә менә *Бүген стадионга бардым, анда спорт бәйрәме иде* дигән мисалда *анда* алмашлыгы мөнәсәбәтле сүз булып килмәгән, ул тулы җөмләне түгел, бәлки *стадион* сүзен генә алмаштыра, шуңа күрә *анда* алмашлыгы урынына җөмләне түгел, бәлки *стадион* сүзен генә куеп әйтеп була: *Бүген стадионга бардым, стадионда спорт бәйрәме иде.*

Димәк, җөмләләрнең мөнәсәбәтле сүз ярдәмендә бәйләнеше түбәндәгечә була: мөнәсәбәтле сүз, үзе бер җөмлә составында торып, икенче бер җөмләне тулы килеш алмаштыра, ягъни бер җөмләдәге мөнәсәбәтле сүзнең конкрет эчтәлеген икенче бер җөмлә белдерә.

Төп ялгызак мөнәсәбәтле сүз һәрвакыт баш җөмлә составында килә, һәм ул җөмләдә кайсы кисәк булса, аның эчтәлеген конкретлаштыручы җөмлә дә шул кисәкнең исеме белән атала. Мәсәлән, төп ялгызак мөнәсәбәтле сүз җөмләдә ия икән, аның эчтәлеген конкретлаштыра торган иярчен җөмлә дә ия җөмлә була: *Хәзер безгә шул калды: атланырга тизрәк атларга* (Г. Тукай).

Төп ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр булып, *шул, ул, бу* алмашлыклары бик күптөрле формаларда килә.

| | | |
|---|---|---|
| *шул* | *ул* | *бу* |
| *шунысы* | *анысы* | *монысы* |
| *шуны* | *аны* | *моны* |
| *шунысын* | *анысын* | *монысын* |
| *шуңа* | *аңа* | *моңа* |
| *шунысына* | *анысына* | *монысына* |
| *шуннан* | *аннан* | *моннан* |
| *шунысыннан* | *анысыннан* | *монысыннан* |
| *шунда* | *анда* | *монда* |
| *шунысында* | *анысында* | *мондый* |
| *шундый* | *алай* | *болай* |
| *шунлыктан* | *андый* | *моның өчен* |
| *шулай да* | *алай да* | *монысы өчен* |
| *шуңа күрә* | *аның өчен* | *моңа хәтле* |
| *шуның өчен* | *анысы өчен* | *моңа чаклы* |
| *шулхәтле* | *аңа хәтле* | *моның белән* |
| *шуңа хәтле* | *аңа кадәр* | *моннан соң* |
| *шуның белән* | *аннан соң* | *моннан бирле* |
| *шуннан соң* | *аннары* | – |
| *шуннан бирле* | *ул чакта* | *бу чакта* |
| *шулчакта* | *ул вакыт* | *бу вакытта* |
| *шул вакытта* | *андый вакытта* | *мондый вакытта* |
| *шуңа карамастан* | *аңа карамастан* | *моңа карамастан* |
| *шул сәбәпле* | *ул турыда* | *моның аркасында* |
| *шуның аркасында* | *ул хакта* | *бу хакта* |
| *шул рәвешчә* | *алай булса да* | *бу турыда* |
| *шул формада* | *алай булгач* | *болай булгач* |
| *шулай булгач* | *алай булса* | *болай булса* |
| *шулай булса да* | *алайса* | – |
| һ.б. | һ.б. | һ.б. |

Төп ялгызак мөнәсәбәтле сүз булып, *менә* сүзе белән килгән сорау алмашлыгы да йөререгә мөмкин. Ул да бик күптөрле формаларны ала: *менә нәрсә, менә ни, менә нәрсәгә, менә нәрсәдән, менә ни өчен, менә ни сәбәпле, менә нәрсәгә күрә, менә нәрсә аркасында, менә нәрсә турында, менә нәрсә хакында* һ.б.

Болардан тыш *барысы, бары, бөтенесе, бернәрсә* кебек сүзләр дә, җөмләләрне алмаштырып, мөнәсәбәтле сүз булып йөри алалар.

А л ы н м а  я л г ы з а к мөнәсәбәтле сүзләр булып, сорау алмашлыклары һәм аларга нигезләнеп ясалган башка сүзләр кулланыла. Мәсәлән: *кайсы, кайсысы кем, кайсыдыр ки, кемгә, кемнән, кем белән, кем өчен, ни өчен* һ.б. *Аз шул бездә байлар, к а й с ы с ы  к е м фәрештәдән канат каермас* (Г. Тукай). *Без черек йөкләрне өстән ташлыйбыз, к а й с ы л а р безне үлемдәй каплаган* (Һ. Такташ). *Утыр аулакка, к а й д а һич кеше юк* (Г. Тукай).

*Вә уйларсыз, н и ч е к шагыйрь яраткан.*
*Н и ч е к янган, синең өчен җан аткан* (Г. Тукай).

*Нигә мин тормадым бер читтә ялгыз,*
*Н и ч е к күктә яна бер данә йолдыз* (Г. Тукай).

*Ул менә шунда ята.*
*Ул, ул – кеше!*
*К а й с ы н гасырлар тудырды,*
*Минутлар үтерде* (Һ. Такташ).

А л ы н м а дигән термин монда алмашлыкларга түгел, бәлки аларның кулланылышына карый. Чыннан да, сорау алмашлыклары, мөнәсәбәтле сүз булып, һинд-европа телләре (башта фарсы, аннан соң рус телләре) тәэсирендә йөриләр дип уйланыла. Алынма ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр күбрәк гади сөйләмдә һәм поэзия стилендә кулланылалар, гадәти язма сөйләмдә алар норма булып кабул ителмәгәннәр. Ләкин сөйләм теле һәм поэзия стиле тәэсирендә алар гомуми әдәби кулланылышка әкренләп керә баралар. Алынма ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр, төп мөнәсәбәтле сүзләрдән аермалы буларак, һәрвакыт иярчен җөмлә составында киләләр һәм тулы җөмләгә түгел, бәлки андагы берәр сүзгә генә ишарә итәләр. Аларның функцияләре дә иярчен җөмләнең функциясен билгеләү өчен ярдәм итми.

П а р л ы  м ө н ә с ә б ә т л е  с ү з л ә р ике өлештән торалар: баш җөмлә составында күрсәтү алмашлыклары һәм алардан ясалган башка сүзләр иярчен җөмләне алмаштырып киләләр, ә иярчен җөмлә составында сорау алмашлыклары була.

Парлы мөнәсәбәтле сүзләрнең күрсәтү алмашлыгы белән бирелгән өлеше җөмләдә кайсы функцияне үтәсә, аның мәгънәсен ачыклаучы иярчен җөмлә дә шул ук функцияне үти. Сорау алмашлыгы белән би-

релгән өлешенең ул яктан бернинди дә әһәмияте юк. Мәсәлән, *Кем беренчелекне ала, шуны мактап язалар* дигән мисалда мөнәсәбәтле сүзләр: *кем – шуны. Шуны* дигәне баш җөмлә составында тәмамлык функциясен үти, һәм иярчен җөмлә дә иярчен тәмамлык җөмлә була. *Кем* дигәне ия булып килгән, ләкин аңа карап иярчен җөмлә ия түгел.

**Парлы мөнәсәбәтле сүзләрнең активлары**

| Иярчен җөмләдә | Баш җөмләдә | Иярчен җөмләдә | Баш җөмләдә |
|---|---|---|---|
| *кем* | *шул* | *кайсы* | *шул* |
| *кем* | *ул* | *кайсы* | *шуны* |
| *ни* | *ул* | *кайсы* | *шунда* |
| *кемнең* | *шул* | *кайдагы* | *шундагы* |
| *кемне* | *шул* | *кайдагы* | *шул* |
| *кемнән* | *шул* | *ни* | *шул* |
| *кемдә* | *шул* | *күпме* | *шулкадәр* |
| *кемгә* | *шул* | *күпме* | *бөтенесе* |
| *кем* | *шуның* | *күпме* | *барысы* |
| *кем* | *шуны* | *кайда* | *шунда* |
| *кем* | *шуңа* | *кайдан* | *шуннан* |
| *кем* | *шуннан* | *никадәр* | *шулкадәр* |
| *кем* | *шунда* | *ничаклы* | *шулчаклы* |
| *кемнең* | *шуның* | *күпме* | *шулкадәрле* |
| *кемнең* | *шунда* | *кая* | *шунда* |
| *кемнең* | *шуннан* | *кайсы* | *шундагы* |
| *кемне* | *шуны* | *нинди* | *шуңа карап* |
| *кемне* | *шуңа* | *күпме* | *шул дәрәҗәдә* |
| *кемне* | *шуның* | *ничек* | *шулай* |
| *кемне* | *шуннан* | *ничек* | *шул рәвешле* |
| *кемне* | *шунда* | *нинди* | *шулай* |
| *кемнән* | *шуннан* | *ни* | *һәммәсен* |
| *кемнән* | *шуны* | *кайвакыт* | *шулвакыт* |
| *кемнән* | *шунда* | *кай урын* | *шул урын* |
| *кемгә* | *шуңа* | *кем өчен* | *шуның өчен* |
| *кемгә* | *шуның* | *кем* | *аның* |
| *кемгә* | *шунда* | *кемдә* | *анда* |
| *кайсы* | *шуннан* | *кемдәге* | *андагы* |

Бу графаларда парлы мөнәсәбәтле сүзләрнең аз өлеше генә күрсәтелгән. Парлы мөнәсәбәтле сүздә сорау алмашлыгы, теләсә нинди формадагы күрсәтү алмашлыгы белән бергә, теләсә нинди формада килә ала, һәм, киресенчә, күрсәтү алмашлыгы, теләсә нинди формадагы сорау алмашлыгы белән килеп, теләсә нинди формада була ала. Моның өстенә парлы мөнәсәбәтле сүзнең баш җөмләдә килә торган өлеше (*шул*) урынында *ул*, *бу* алмашлыклары да булырга мөмкин.

Җөмләләрне үзара бәйләүче мөнәсәбәтле сүзләргә ияреп, кайчакта шарт фигыль формасы да кулланылырга мөмкин: *Нәфисә кайда булса, Зиннәт тә шунда булырга тырышты* (Г. Бәширов). Бу җөмләдә *кайда – шунда* мөнәсәбәтле сүзе белән *булса* хәбәрендә *-са* кушымчасы да килгән. Җөмләләр арасындагы урын мөнәсәбәте мөнәсәбәтле сүзләр белән белдерелгән, *-са* формасы биредә шарт мөнәсәбәтен бирми, ул стилистик чара итеп кенә кабул ителә һәм бик җиңел хикәя фигыль формасына алмаштырыла ала: *Нәфисә кайда була, Зиннәт тә шунда булырга тырышты.*

Мөнәсәбәтле сүзләр булып, нигездә, алмашлык һәм алмашлыкка якын башка сүзләр дә килә, ләкин аларның нигезе алмашлык булганлыктан, мөнәсәбәтле сүзләрне алмашлык белән генә мөнәсәбәттә өйрәнү гадәткә кергән.

**§ 304. Татар телендәге мөнәсәбәтле сүзләрнең рус телендәге мөнәсәбәтле сүзләр белән охшаш һәм аермалы яклары.** Бер үк вакытта рус телен дә белүчеләр буларак һәм рус грамматикаларыннан файдаланучылар буларак, без бу темадан да хәбәрдар булырга тиешбез. Бу – бер. Икенчедән, кайбер тюркологлар мөнәсәбәтле сүзләрне куллану төрки телләрдә фарсы яки рус теле йогынтысында башланган дигән ялгыш караштa торалар һәм, мөнәсәбәтле сүзләрне өйрәнгәндә, аларның рус теле мөнәсәбәтле сүзләренә туры килү очракларына гына игътибар итәләр.

Бу өйрәнелә торган күренеш буенча, төрки һәм һинд-европа телләренең охшашлыгы шунда күренә: ике төркем телдә дә парлы мөнәсәбәтле сүзләр (соотносительные пары местоименно-относительных слов) принципта бер үк төрле төзеләләр һәм бер үк төрле кулланылалар. Мәсәлән, *кайда – шунда* ‘там – где’; *кайдан – шуннан* ‘оттуда – откуда’; *кем – шул* ‘тот – кто’; *кайсы – шул* ‘тот – который’; *кем турында – шул* ‘о ком – тот’; *кем белән – шул* ‘с кем – тот’; һ.б. *Җил*

*кайдан исә, болыт та шуннан килә* (мәкаль) 'Тучи идут оттуда, откуда ветер дует'; *Кем эшләми, шул ашамый* (мәкаль) 'Кто не работает, тот не ест'.

Ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр куллануда татар һәм рус телләре шактый үзенчәлекләләр.

Төрки телләрдә, аналитик җөмләләрне баш җөмләләргә бәйләп, күрсәтү алмашлыгына нигезләнгән ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр күбрәк кулланыла, ә сорау алмашлыгына нигезләнгән ялгызак мөнәсәбәтле сүз чыгарма буларак күзәтелә.

Һинд-европа телләрендә исә киресенчә, система буларак сорау алмашлыгына нигезләнгән ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр (относительные слова) кулланыла, ә күрсәтү алмашлыгына нигезләнгән ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр сирәгрәк очрыйлар. Шуңа күрәдер күрсәтү алмашлыгына нигезләнгән мөнәсәбәтле сүз рус грамматикаларында мөнәсәбәтле сүз дип саналмый. Алар бары сорау алмашлыгына нигезләнгән парлары белән генә мөнәсәбәтле сүз (соотносительные слова) дип йөртеләләр.

Моны мисалда күзәтик. *Несмотря на то, что он живет далеко, он никогда не опаздывает 'Ул ерак тора, шуңа карамастан бер вакытта да соңга калмый'.* Бу җөмләдә *несмотря на то* күрсәтү алмашлыгына нигезләнгән һәм аның янында *что* сорау алмашлыгы бар, шуңа күрә биредәге русча җөмләдә парлы мөнәсәбәтле сүз (соотносительное слово) бар. *Несмотря на то, что* парлы мөнәсәбәтле сүзеннән *что* дигән сорау алмашлыгын төшереп калдырсаң, күрсәтү өлеше генә рус телендә мөнәсәбәтле сүз дип танылмый.

Мәсәлән, *Он живет далеко, несмотря на это он никогда не опаздывает 'Ул ерак тора, шуңа карамастан бер вакытта да соңга калмый'.* Бу очракта *несмотря на это* бәйләүче чара дип, мөнәсәбәтле сүз дип танылмый. Юкса аның ярдәмендә төзелгән җөмлә дә, беренче очрактагы кебек үк, татарчага аналитик кушма җөмлә белән тәрҗемә ителә. Шуңа күрә без раслый алабыз *«несмотря на то, что»* да, *«немотря на это»* да җөмләләр арасында бер үк төрле мәгънә мөнәсәбәте урнаштыра. Мөнәсәбәтле сүзләрнең татар һәм рус телләрендә кулланылу үзенчәлекләрен таблицада күрсәтергә мөмкин.

Татар телендә дә, рус телендә дә күрсәтү алмашлыгына нигезләнгән мөнәсәбәтле сүз (үзе генә булса да, парлы булса да) һәрчак баш

җөмлә составында тора, сорау алмашлыгына нигезләнгәне – һәрчак иярчен җөмлә эчендә килә.

Мөнәсәбәтле сүзләр бер җөмләдә торып, башка җөмләне алмаштыралар яки бер җөмләдә торып икенче җөмләдәге бер сүзгә буйсыналар, аңа күрсәтеп торалар. Мәсәлән, *Кайда берлек, шунда көч* (мәкаль) ‘Где единство, там сила’ җөмләсендә *шунда* (*там*) беренче җөмләне алмаштыра, икенче җөмләдә аның урынбасары (*заместитель*) булып килә; *кайда* (*где*) икенче җөмләнең булуын күрсәтеп тора. Менә бу күрсәтү-алмаштыру (отсылочно-заместительная) үзенчәлеге булудан чыгып, мөнәсәбәтле сүзләрне (относительные, соотносительные слова) белән бәйләнешне гомуми тел гыйлемендә анафорик бәйләнеш (анафорическая связь) дип атыйлар.

| Телләр | Парлы мөнәсәбәтле сүзләр (*тот – который* ‘кайсы – шул’*)* | Сорау алмашлыгына нигезләнгән ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр (*который* ‘кайсы’) | Күрсәтү алмашлыгына нигезләнгән ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр (*тот* ‘шул’) |
|---|---|---|---|
| 1. Татарчада | система буларак кулланыла | русчага ияреп, бик сирәк кулланыла | бик еш һәм система буларак |
| 2. Русчада | система буларак кулланыла | бик еш һәм система буларак | кулланыла, ләкин мөнәсәбәтле сүз дип саналмый |

Һинд-европа телләрендә, шул исәптән рус телендә, мөнәсәбәтле сүзләрдә сорау алмашлыгы төп рольне уйный, аннан башка гомумән мөнәсәбәтле сүз юк дип карала.

Мөнәсәбәтле сүз булып килгән сорау алмашлыгы, үзе генә кулланылып, баш җөмләдәге кайсы да булса бер сүзгә карый, аңа ориентация тота: *Комната, в которую вступил Иван Иванович, была совершенно темна* (Н. Гоголь). Татарча бу төзелеш чыгарма буларак кына очрый: *Ул – кеше, кайсын гасырлар тудырды, минутлар үтерде* (Һ. Такташ). Бу төр бәйләнешне рус грамматикалары **ориентированная анафорическая** связь дип атыйлар.

Әгәр дә сорау алмашлыгы, мөнәсәбәтле сүз булып, күрсәтү алмашлыгы белән бергә килсә, ул икенче җөмләдәге аерым сүз белән әйбергә, затка яки ситуациягә түгел, ә андагы үзенең күрсәтү парына

гына мөнәсәбәттә тора: *Т о т,  к т о  играет словами, не всегда играет чувствами* (М. Лермонтов) *К е м  сүз уйната, у л  һәрчак йөрәк кылларын тибрәтә алмый*. Мондый җөмләдә аерым сүзгә күрсәтү, аерым сүзгә ориентация юк. Шуңа күрә рус грамматикалары бу төр анафорик бәйләнешне **неориентированная анафорическая связь** дип атыйлар.

Тел үзенчәлекләреннән чыгып эш иткәндә, татар теле мөнәсәбәтле сүзләре аша бәйләнеш, нигездә, шушы неориентированная связь дигән төргә карый.

Татар синтаксисында бу терминнарны һәм мондый бүленешләрне без кабул итмәдек, чөнки татар телендәге мөнәсәбәтле сүзләрдә күрсәтү алмашлыгы төп рольне уйный, ул сорау алмашлыгыннан башка да мөнәсәбәтле сүз булып килә ала.

**§ 305. Баш җөмләгә төп ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр аша ияргән аналитик җөмләләр.** Төп ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр, югарыда әйтелгәнчә, күрсәтү алмашлыкларына нигезләнәләр, бу рольдә күрсәтү алмашлыклары бик күптөрле бәйләүче һәм ярым бәйләүче чараларны алып кулланылалар: *шул, шунысы, шунда, шул турыда, ул, ул турыда, аңа карамастан* һ.б. *Менә* дигән күрсәтү сүзе белән бергә сорау алмашлыклары да күрсәтү мәгънәсендә килә ала һәм төп ялгызак мөнәсәбәтле сүз ролен башкара: *менә нәрсә, менә нәрсәгә, менә ни өчен, менә ничек, менә кайчан* һ.б. сорау алмашлыгы янында күрсәтү мәгънәсендә *бер* сүзе дә килергә мөмкин: *бер нәрсәгә, бер нәрсә турында* һ.б.

Баш җөмләгә төп ялгызак мөнәсәбәтле сүз белән бәйләнгән аналитик җөмлә белән баш җөмлә арасында күптөрле мәгънә мөнәсәбәтләре урнаша, бу төр аналитик җөмләләрне дә менә шул мәгънә мөнәсәбәтләренә карап төркемлиләр. Мәгънә мөнәсәбәтен иярчен җөмләнең баш җөмләгә карата кайсы кисәк функциясен башкаруы белән ачыклыйлар. Мәсәлән, аналитик җөмлә баш җөмлә белән сәбәп мөнәсәбәтендә торса, аналитик җөмлә баш җөмләнең сәбәп хәле функциясен үти һәм ул аналитик сәбәп җөмлә дип атала.

Бу төр бәйләнеш булганда аналитик җөмләнең мәгънә төрен (функциональ төрен) билгеләү бик җиңел, чөнки монда төгәл һәм мәҗбүри система урнашкан. Ул система шуннан гыйбарәт: күрсәтү алмашлыгына нигезләнгән ялгызак мөнәсәбәтле сүз һәрчак баш җөмлә составында тора, һәм ул баш җөмләдә кайсы кисәк булып килсә,

иярчен аналитик җөмлә дә шул кисәккә туры килә, шул кисәк исеме белән атала. Мәсәлән, *Мин шуны гына беләм: ел елга охшамый* төзелмәсендә мөнәсәбәтле сүз – *шуны,* ул беренче җөмләдә килгән, димәк, беренче җөмлә баш җөмлә була. *Шуны* мөнәсәбәтле сүзе – җөмләдә тәмамлык, димәк, аналитик иярчен җөмлә дә аналитик тәмамлык җөмлә дип таныла.

1. Ия булып килгән төп ялгызак мөнәсәбәтле сүз баш килештә генә килә, ул бары тартым кушымчасын гына алырга мөмкин. Ия булып килгән мөнәсәбәтле сүз ярдәмендә ияргән җөмлә бары аналитик ия җөмлә генә була ала. Димәк, бу очракта җөмләләр арасында хәбәрлекле мөнәсәбәт урнаша.

Ия булып, түбәндәге төп ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр килә.

1) *Шул, шунысы. Хәзер безгә ш у л  к а л д ы : атланырга тизрәк атларга* (Г. Тукай). *Тагын ш у н ы с ы кызык: бу хәлдән соң управляющийны күрәсем килү көчәеп китте* (Ә. Еники).

2) *Бу* һәм *монысы: Нәкъ шулчакта елга үрендәге берничә кеше ашыгып кулларын күтәрәләр, м о н ы с ы – боз кузгалу турында сигнал* (Ә. Еники). *Чыннан да начар булмас иде б у : ак бүрәнәдән чибәр генә өй, яңа капка, яңа койма* (Ә. Еники).

Ия булып килгән алмашлык тартым формасын үзе яисә аның янындагы башка бәйләүче алырга мөмкин: *Гайшә тик кул куярлык булып чыкты, б у  ч а к л ы с ы да аның өчен зур шатлык иде* (Г. Ибраһимов).

3) *Бер нәрсә: Ләкин б е р  н ә р с ә калды: мин сездән мәсьәләләрне ачык һәм кискен куярга өйрәндем* (Г. Ибраһимов).

4) *Минә нәрсә: Мине м е н ә  н ә р с ә һәрчак борчып тора: улыбыз университетка керә алырмы?* (М. Мәһдиев).

2. Хәбәр булып килгән төп ялгызак мөнәсәбәтле сүз төрле формаларны ала һәм, баш җөмлә составында килеп, аңа аналитик хәбәр җөмләне бәйли. Димәк, җөмләләр арасында шулай ук хәбәрлекле мөнәсәбәт урнаша.

Хәбәр булып, күбрәк, түбәндәге ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр килә.

1) *Шул: Дөресе ш у л : яз яшенен һаман Үземә гел кардәш күрдем мин* (Зөлфәт).

2) *Шул булды, шул иде, шул икән: Тагын аның өчен иң куркынычлысы ш у л  и д е : халык күзеннән әкренләп төшә баруын, бер язучы*

*әйтмешли, аркасы белән тоеп йөри иде* (Ә. Еники). *Һәр заманны монда хәлләр ш у л  и к ә н : һәркем үз эше белән мәшгуль икән* (Г. Тукай). *Минем бөтен анархистлыгым ш у л  б у л д ы : мин анархизм турындагы китапларны яратып укый идем* (Г. Ибраһимов).

3) *Шунда: Кешенең кеше булуының чын мәгънәсе ш у н д а : ул башкаларны хөрмәт итәргә тиеш.*

4) *Шундый* (*шул + дай = шулдай = шундый*): *Идарәнең карары ш у н д ы й : бүгенгесе көннән башлап, син ындыр бригадиры буласың* (Г. Бәширов).

5) *Шулай, болай* (*шул + лай, бу + лай*): *Аның нәтиҗәсе ш у л а й и к ә н : барысы да безнең файдага булган* (А. Әхмәт).

6) *Шуңа, шуннан: Алдан килүче булса, бүләк ш у ң а* (Ә. Еники).

3. Аергыч булып килгән төп ялгызак мөнәсәбәтле сүз баш җөмлә составында тора һәм аңа аналитик аергыч җөмләне бәйли.

Аергыч булып, күбрәк, түбәндәге ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр килә.

1) *Шул, бер, күп*: *Иптәшләр, минем б е р тәкъдим бар: әйдәгез, бергәләп театрга барыйк* (К. Тинчурин). *Дөньяда к ү п кешеләр бар ки, үткен вә гакыллы кешеләрдән куркып, үз тирәләрендә күбрәк ахмакларны йөртәләр* (Г. Тукай).

2) *Шундый: Ул сиңа ш у н д ы й итекләр тегеп бирер ки, кешегә күрсәтү бөтенләй оят булыр* (Г. Тукай). *Дөнья кайнарга тора, ш у н д ы й вакытта сез әллә кайда җыен юк-бар эш артыннан йөрисез* (Г. Ибраһимов).

4. Тәмамлык булып килгән ялгызак мөнәсәбәтле сүз баш җөмлә составында тора һәм аңа аналитик тәмамлык җөмләне бәйли.

Тәмамлык булып, күбрәк, түбәндәге ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр йөри.

1) *Шуны, моны: Бик күп еллардан соң гына мин ш у н ы белдем: Рафис поездга билет ала алмаган икән* (М. Маликова). *Бу бер ай эчендә Мостафин күпме уйлар башыннан кичерде, м о н ы беркем дә әйтә алмас* (Ә. Еники).

2) *Шуңа: Хәзер бар да бетте, менә ш у ң а карап, тактиканы яңартырга кирәк.*

3) *Шуңардан, шуннан: Монда тик аның куәтле шаулавы гына килә, ш у ң а р д а н йөрәккә бераз шом төшә* (Г. Ибраһимов).

4) *Шул турыда, ул турыда, бу турыда: Быел безнең команда җиңү яулады, менә ш у л  т у р ы д а  сөйләргә ярыйдыр бит.*

5) *Шунда: Аның характеры ш у н д а  бик ачык күренде: икенче көнне үк үзе сөйләгәннең киресен эшләде* (Ф. Хөсни).

5. Хәл булып килгән ялгызак мөнәсәбәтле сүз баш җөмлә составында тора һәм төрле мәгънә төсмерендәге аналитик хәл җөмләләрне бәйли.

1) *Шундый, шулай, шулкадәр* (*хәтле*) баш җөмләдә фигыль, сыйфат яки рәвеш белән бирелгән кисәккә ияреп, иярчен җөмлә белән баш җөмлә арасында күләм-чама мөнәсәбәтен урнаштыра. Иярчен җөмлә баш җөмләгә карата аналитик күләм җөмлә булып формалаша: *Ш у н д ы й  якын үтте ки, үләндәге салкын чык тамчылары аның өстенә сибелеп калды* (И. Гази). *Күзгә төртсәң күренми, ш у л а й  караңгы* (Г. Ибраһимов). *Бу вакытта Ләйлә ш у л к а д ә р  матур иде ки, аңа бөтен кешенең исе китә иде* (И. Гази). *Ул ш у л ч а к л ы  көчәйде: бер сәгать эчендә янына бармалы булмады* (К. Тинчурин).

Күләм-чама мәгънәсен көчәйтеп, иярчен җөмлә алдыннан *хәтта* кисәкчәсе дә килә ала: *Әмма ул иптәш кызының тавышы белән ш у н д ы й  парга килә, хәтта Мәүлиха белән Әпипәгә аларның берәве генә җырлыйдыр күк ишетелә иде* (Г. Бәширов).

2) *Шунлыктан, шуңа күрә, шуның аркасында, шул сәбәпле, шуның өчен, шуңа* аналитик сәбәп җөмләне баш җөмләгә бәйли: *Мәскәүнең киң урамнары бик еш кына тар иде, ш у ң а  к ү р ә  көтелмәгән очрашулар бар иде* (Р. Харис). *Шулай да кешеләргә тулысынча ышанып бетми, ш у л  с ә б ә п л е  ихласлык та җитми* (Ф. Сафин). *Сатлыкҗанны таный алмадым һәм күрсәттем җепнең очын мин – Вөҗдан газабының ялкынын йотып янам ш у н ы ң  ө ч е н  мин* (Р. Харис). *Безгә бит гомер бер генә бирелә, ш у ң а  без бик күп хыялларыбызны тормышка ашырып бетерә алмыйбыз* (Р. Мөхәммәдиев). *Сүзләр моңа комачаулар иде, ш у ң а  к ү р ә  дәшмәделәр, бары тик булдыра алганча елмайдылар* (Ф. Садриев).

3) *Шуннан бирле, шуннан соң, шуннан ары, аннары, шуңа чаклы, шуңа кадәр, шуңа хәтле, шулчаклы* яки *шул вакытта* иярчен вакыт җөмләне баш җөмләгә бәйли: *Иң элек авылга атлылар килеп төште, ш у н н а н  с о ң  чехлар килеп керделәр* (К. Нәҗми). *Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән, а н н а р ы  төннәр буе әбкәм хикәят*

*сөйләгән* (Г. Тукай). *Кайбер хәлләрдә кешеләрнең бер-берсеннән ераграк торулары хәерлерәк ич, шулчакта алар бер-берсе турында әйбәтрәк уйлаучан булалар* (Ә. Еники).

4) *Шунда* ялгызак мөнәсәбәтле сүзе белән бәйләнгән җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең вакытын да, урынын да белдерә ала: *Мәңге буран булмас, бер аязыр, шунда халык игенен дә сугар, кызын да бирер, киленен дә ярәшер* (Г. Ибраһимов). *Уйсу җиргә су җыела, шунда казлар коена* (җыр).

5) *Шундый итеп, шул рәвешчә, шулай итеп* ялгызак мөнәсәбәтле сүзләре аналитик рәвеш җөмләне баш җөмләгә бәйлиләр: *Ул шундый итеп ясасын: атлап керергә кыймый торырлык булсын* (К. Тинчурин). *Баланы шул рәвешчә сынарга кирәк: ул синең караганыңны сизмәсен* (Г. Тукай). *Икенче елга тагын чәчәрсең, шулай итеп бакчаң чәчәккә тулар* (Г. Ибраһимов). *Афанасий атакай болай уйлады: Шәкүр, әлбәттә, төнлә киләчәк иде ат урларга* (Н. Акмал).

6) *Шулай да, алай да, шуңа карамастан, шулай булса да* ялгызак мөнәсәбәтле сүзләре аналитик кире җөмләне баш җөмләгә бәйлиләр, ягъни бу чаралар ярдәмендә бәйләнгән иярчен җөмләләрдән көтелгән эш-хәлнең баш җөмләдә киресе үтәлә*: Минем күзләрем ул хәтле җете түгел, алай да күрәм* (Г. Бәширов). *Әллә ни күп сөйләшергә хәле юк иде, шулай да авыру күршесе турында кызыксынмый булдыра алмады* (Ф. Яруллин). *Ишек ачык иде, шуңа карамастан ул бик озак шакып торды* (Ә. Фәйзи). *Балыкка йөрү – минем кечкенәдән гадәткә кергән эшем, шулай булса да бу юлы мин анда бармаска карар бирдем* (Г. Ибраһимов).

7) *Шуның белән* ялгызак мөнәсәбәтле сүзе ярдәмендә бәйләнгән җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең сәбәп булып килә торган объектын белдерә. Мондый иярчен җөмлә сәбәп җөмләгә дә, тәмамлык җөмләгә дә каратылырга мөмкин: *Прокурор Степановның башына ниндидер уй килде, шуның белән бераз җиңеләйде* (Г. Ибраһимов).

8) *Алай булса, шулай булса, алайса* ялгызак мөнәсәбәтле сүзләре баш җөмләгә, нигездә, шарт җөмләләрне бәйлиләр: *Сез безнең фикергә колак салмыйсыз, алай булса бу фикер алышуга безнең килү дә кирәк түгел* (М. Максуд).

**§ 306. Баш җөмләгә парлы мөнәсәбәтле сүзләр аша ияргән аналитик җөмләләр.** Югарыда әйтелгәнчә, парлы мөнәсәбәтле сүзләр

ярдәмендә ясала торган кушма җөмләләр – төрки телләрнең үз үзенчәлекләре, алар бик борынгы чорда ук, алмашлыклар белән бер чорда ук формалашканнар. Төрки-татар әдәби телендә дә алар борынгы текстларда ук еш очрыйлар. Мәсәлән, XI йөздә Мәхмүт Кашгари язмаларында ук алар гадәти төзелмәләр кебек кулланылганнар: *Аучы н е ч ә әл белсә, адыг ә н ч ә йол белер – Аучы н и ч ә юл белсә, аю да ш у л ч а к л ы юл белер.* VI гасырда Мөхәммәдьяр болай яза: *К е м яманлык кыйлса, у л табкай җәза.*

Парлы мөнәсәбәтле сүзнең баш җөмлә составында килә торган күрсәтү өлеше булып, *шул, ул, бу* күрсәтү алмашлыкларының бик күптөрле формалары йөри, ә һәрчак иярчен җөмләдә килә торган сорау өлеше булып, *кем, ни* алмашлыгының бик күп формалары һәм *кайсы, кайда, ничек* сорау алмашлыклары, *күпме* сорау рәвеше йөри.

Парлы мөнәсәбәтле сүзләр янында стилистик чара булып *-са* кушымчасы һәм *ки* теркәгече дә килә ала, ләкин болары җөмләләр арасында мәгънә мөнәсәбәтен белдерүдә катнашмыйлар.

Бу юл белән ясалган кушма җөмләләрдә, кагыйдә буларак, иярчен җөмлә – башта, баш җөмлә ахырдан килә. Җөмләләрнең кире тәртибе гади сөйләмдә яки поэзиядә генә күзәтелә: *Бәхетле ш у л баладыр, к а й с ы дәресенә күңел бирсә* (Г. Тукай).

Парлы мөнәсәбәтле сүзнең күрсәтү алмашлыгына нигезләнгән өлеше баш җөмләнең кайсы кисәге булып килсә, иярчен җөмлә дә шул кисәкнең исеме белән атала.

1. Парлы мөнәсәбәтле сүзнең күрсәтү алмашлыгына нигезләнгән өлеше баш җөмләнең иясе булып килсә, аналитик иярчен җөмлә ия җөмлә була, димәк, җөмләләр арасында хәбәрлекле мөнәсәбәт урнаша. Баш җөмләдә ия булып, *шул, ул* кебек сүзләр килә, иярчен җөмләдә сорау алмашлыгына нигезләнгән өлеш төрле формаларны алырга мөмкин. Мисаллар: *К е м н е ң күңеле көр, у л һәрвакыт көләч* (А. Шамов). *К е м намус белән хезмәт итә, ш у л һәрвакыт зур хөрмәткә ия була* (Г. Бәширов). *К а й с ы ил башлый ала, ш у л башлап җибәрергә тиеш* (И. Гази). *К е м н ә р моңлы, ш у л а р гына Хәлемне белсә белер* (Г. Зәйнашева).

2. Иярчен җөмлә баш җөмләдә хәбәр булып килгән мөнәсәбәтле сүзнең эчтәлеген конкретлаштырып килсә, ул аналитик хәбәр җөмлә дип таныла. Хәбәр җөмлә составында парлы мөнәсәбәтле сүзнең

сорау өлеше төрле формаларны ала, бу очракта баш җөмләдә хәбәр булып килә торган күрсәтү алмашлыгы да төрле формада килергә мөмкин. Мисаллар: *К е м чәчүдә беренчелекне ала, бүләк ш у ң а* («Ватаным Татарстан»). *К ү п м е булса сездә көч һәм ялкын, ш у л к а д ә р - л е җирдә хаккыгыз* (М. Җәлил). *Болында үлән н и х ә т л е , анда кеше ш у л х ә т л е* (Г. Бәширов). *Анасы н и ч е к , баласы да ш у н д ы й* (Г. Әпсәләмов).

3. Иярчен җөмлә баш җөмләдә аергыч булып килгән мөнәсәбәтле сүзнең конкрет эчтәлеген хәбәр итсә, ул аналитик аергыч җөмлә дип атала. Димәк, җөмләләр арасында атрибутлык мөнәсәбәте урнаша: *Н и н д и эш уңай булса, ш у л эшне эшлидер* (Г. Тукай). *К е м ки туган-үскән җирендә файдалы кешеләрдән саналмаса, а н ы ң күңелендә һәрвакыт чит җирләр сөекле булыр* (Г. Тукай). *К а й с ы урыннан юл салырга кирәк, ш у н д а г ы урманны кисеп, җирен тазартып бетерегез* («Ватаным Татарстан»).

Парлы мөнәсәбәтле сүзнең күрсәтү өлешенең аерылмышы кулланылмаганда, ул мөнәсәбәтле сүз җөмләнең башка кисәгенә әйләнә, кушма җөмләдәге җөмләләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәте дә үзгәрә. Мәсәлән, *К а й с ы беренчелекне ала, ш у л төркемне мактап язу гадәте бар* төзелмәсендә *шул* аергычына *төркемне* сүзе аерылмыш булып килгән. Ул төшеп калып аергыч аерылмыш урынында килү татар теле өчен бик табигый: *К а й с ы (төркем) беренчелекне ала, ш у н ы (аны) мактап язу гадәте бар.* Биредә *шул* мөнәсәбәтле сүзе, *шуны* формасын алып, тәмамлык булып формалашты, димәк, аның ярдәмендә ияргән җөмлә дә аналитик тәмамлык җөмләгә әйләнде.

4. Парлы мөнәсәбәтле сүзнең күрсәтү алмашлыгына нигезләнгән өлеше баш җөмләнең тәмамлыгы булып килсә, аналитик иярчен җөмлә тәмамлык җөмлә дип атала. Бу очракта мөнәсәбәтле сүзнең ике өлеше дә күптөрле формаларны алырга мөмкин.

Түбәндәге парлы мөнәсәбәтле сүзләр тәмамлык җөмләне баш җөмләгә бәйлиләр.

1) *Ни – шуны, нинди – анысын, нәрсә – һәммәсен: Ул н и куша, ш у н ы эшли* (Г. Ибраһимов). *Н и н д и уеннар башлап ташлаганбыздыр, а н ы с ы н ачык хәтерли алмыйм* (Г. Ибраһимов). *Хәзинәдә н и-н ә р с ә бар, һ ә м м ә с е н чыгарып салдылар* (Г. Ибраһимов).

2) *Кем – шуңа, ни – шуңа: К е м сораса, ш у ң а сатарга тора* (Г. Ибраһимов). *Н и теләсә, ш у ң а ирек куйдылар* (И. Гази).

3) *Кем – шуларда, кемнән – шулардан һ.б.: Бу эштә к е м катнашкан, ш у л а р д а ул тирән эз калдырган* (И. Туктар). *Элек сез к е м н ә н алган булсагыз, без дә хәзер ш у ң а р д а н сорарга уйлап торабыз* (Г. Ибраһимов).

4) *Кемнең ки – аның каршында: К е м н е ң к и күңеле дуслык, сөешү кеби хисләрдән буш яратылган булса, а н ы ң к а р ш ы н д а бөтен халык дошмандыр* (Г. Тукай).

5) *Нинди – шуңа карата: Кичә тәрбия эшләре буенча н и н д и мәсьәлә тикшерелде, бүген ш у ң а к а р а т а конкрет тәкъдимнәр керә башлады* («Ватаным Татарстан»).

6) *Кемнәр – шулар турында: Авылга к е м н ә р килгән булса, а л а р т у р ы н д а төрлечә сүзләр таралды* (М. Гафури).

7) *Ни – шуның белән: Н и туры килсә, ш у н ы ң б е л ә н тәнеңне кара яндырганчы кыйнап ташлый* (Г. Ибраһимов).

5. Парлы мөнәсәбәтле сүзнең күрсәтү алмашлыгына нигезләнгән өлеше баш җөмләнең күптөрле мәгънәдәге хәл кисәге булып килсә, аналитик иярчен җөмлә хәл җөмләнең билгеле бер төре булып формалаша.

Бу очракта күбрәк түбәндәге парлы мөнәсәбәтле сүзләр килә.

1) *Кайда – шунда, кайдан – шуннан* мөнәсәбәтле сүзләре җөмләләр арасында пространство мөнәсәбәтен урнаштыралар, иярчен җөмлә урын җөмлә дип атала: *К а й д а кирәк тапсалар, ш у н д а хезмәт итте* (И. Гази). *Җил к а й д а н исә, болыт та ш у н н а н килә* (мәкаль).

2) *Кайчан – шунда, кайчан – шул вакытта, ничек – шулвакыт* мөнәсәбәтле сүзләре аналитик вакыт җөмләне баш җөмләгә бәйлиләр: *К а й ч а н кирәк тапсалар, ш у н д а хезмәт итте* (И. Гази). *Йокысыннан кояш н и ч е к уянды исә, җил ш у л в а к ы т җилбер-җилбер итеп исә* (Г. Тукай).

Игътибар итәргә кирәк: иярчен вакыт яки иярчен урын җөмләне билгеләүдә парлы мөнәсәбәтле сүзнең сорау өлеше дә роль уйный. *К а й д а кирәк тапсалар, ш у н д а хезмәт итә* җөмләсендә *Кайда кирәк тапсалар* өлеше баш җөмләгә *шунда* аркылы бәйләнгән, ул – урын җөмлә, чөнки аның составында *кайда* дигән сорау мөнәсәбәтле сүзе бар. Ә *К а й ч а н кирәк тапсалар, ш у н д а хезмәт итә* төзел-

мәсендә баш җөмләдә шул ук *шунда* мөнәсәбәтле сүзе тора, иярчен җөмләдә *кайчан* сорау өлеше вакыт белдергәнлектән, иярчен җөмлә вакыт җөмлә була.

3) *Ничек – шулай* мөнәсәбәтле сүзләре рәвеш иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйли: *Н и ч е к таләп ителгән булса, ш у л а й эшләделәр* (И. Гази). *Кигән кием н и ч е к туза, яшь гомер ш у л а й уза* (җыр). *Заман н и ч е к булса, бүрегеңне ш у л а й ки* (мәкаль).

4) *Нихәтле – шулхәтле, нихәтле – шул дәрәҗәдә, күпме – шул дәрәҗәдә, никадәр – шулкадәр* һ.б. шундый мөнәсәбәтле сүзләр җөмләләр арасында күләм-чама мөнәсәбәтен урнаштыралар. Иярчен җөмлә күләм җөмлә булып санала. Мисаллар: *Ул к ү п м е тырыша, ш у л д ә р ә җ ә д ә яхшырак чыга. Ораторның сүзе н и ч а к л ы кискен чыкса, халыкның алкышы да ш у л д ә р ә җ ә д ә көчле була* (Г. Ибраһимов). *Күрәсең, талант н и к а д ә р зуррак булса, аны кабул итеп, аңлап бетерүгә дә ш у л к а д ә р үк кыендыр инде* (М. Вәлиев). *Иптәшләреңә к ү п м е яхшылык күрсәтә алсаң, алар сиңа ш у л - к а д ә р ихтирам кайтарып бирәләр* (М. Юныс).

Әле сөйләгәннәрдән күренгәнчә, иярчен сәбәп, максат, кире һәм шарт җөмләләр баш җөмләгә парлы мөнәсәбәтле сүз белән бәйләнмиләр, бу төр җөмләләрне баш җөмләгә күбрәк ялгызак мөнәсәбәтле сүз ияртә.

**§ 307. Баш җөмләгә алынма ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр аша ияргән аналитик җөмләләр.** Югарыда әйтелгәнчә, алынма ялгызак мөнәсәбәтле сүз булып, иярчен җөмлә составында күрсәтү алмашлыклары килә: *кем, кемдә, кемнең, кайсы, кайсысы, кем, ни, кайсыдыр ки, кайсыларын, кайда* һ.б. Бу сорау алмашлыклары үзләре алынма түгел, бәлки аларның мөнәсәбәтле сүз булып актив кулланылулары алынма, ягъни алар һинд-европа телләреннән фарсы һәм рус телләре йогынтысында җөмләләр арасында бәйләүче чара – мөнәсәбәтле сүз буларак актив кулланыла башлаганнар.

Бу төр мөнәсәбәтле сүзләрнең русча һәм фарсыча кулланылышы керүгә татар теленең үзендә сорау алмашлыкларының парлы кулланылышы да тәэсир иткәндер, чөнки парлы мөнәсәбәтле сүзнең күрсәтү өлеше еш кына төшеп тә кала. Аларның сирәк-мирәк кулланылышы төрки телләрнең үз җирлегендә туган булырга мөмкин. Мәсәлән, *Кем сөйләргә тели, сөйләсен* төзелмәсе – төрки тел өчен табигый төзелмә:

– *Кем сөйләргә тели?* дип сорау бирелә,

– *Сөйләсен,* дип җавап бирелә, яки *Кем сөйләргә тели, шул сөйләсен* дип әйтеп була.

Сорау алмашлыгы белән бәйләнгән иярчен җөмләләр борынгы рун текстларында аерым өйрәнелеп билгеләнмәгәннәр, ләкин XI йөздә язылган әсәрләрдә алар табылалар. Мәсәлән, Йосыф Баласагунлының «Котадгу белек» («Бәхетле булу белеме») әсәрендә: *Н ә ч ә эр бәдүсә, баш аґруґ бәдүр 'Н и к а д ә р ир булып җитешә, башы да (шулкадәр) авыртыр'.* Мәхмүт Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» («Төрки сүзләр җыелмасы») китабында шундый мисал табып була: *Качан көрсә аны түрк, будун анґа аниң айдачи. – 'К а й ч а н күрсә аны түрк, (шулчак) халыкка болай дияр'.*

VI йөздә Мөхәммәдъяр әсәрләрендә дә әле бу төзелмәләр төрки телгә хас рәвештә ясала: *Бәс н и килсә башка, телдин килер.* Хәзерге әдәби телдә бу төр төзелмәләр еш очрый:

*Вә уйларсыз, н и ч е к шагыйрь яраткан,*
*Н и ч е к янган, синең өчен җан аткан* (Г. Тукай).

*Н ә р с ә ачылыр ул томан артында, миңа билгесез* (Ә. Еники). *Диләфрүз элек бу зур дөньяда япа-ялгыз н и ч е к яши алгандыр, хәзер һич башына сыярлык түгел кебек* (Г. Әпсәләмов).

Әле генә китерелгән мисалларда сорау алмашлыгы я әле сорау бирүдән аерылмаган, я парлы мөнәсәбәтле сүзнең күрсәтү өлеше төшеп калу нәтиҗәсе булып тора. Мәсәлән, *Бәс ни килсә башка, (шул) телдин килер. Н ә р с ә ачылыр ул томан артында, миңа (шул) билгесез* һ.б.

Чын алынма мөнәсәбәтле сүзнең кулланылышы төрки телләрдәге менә шушы төзелмәләргә нигезләнеп, фарсы һәм рус телләреннән алынган дип расларга безгә түбәндәге фактлар хокук бирә: *Аз шул бездә байлар, к а й с ы с ы к е м фәрештәдән канат каермас* (Г. Тукай). *Утыр аулакка, к а й д а һич кеше юк* (Г. Тукай). *Без черек йөкләрне өстән ташлыйбыз, к а й с ы л а р безне үлемдәй каплаган* (Һ. Такташ).

*Ул менә шунда ята.*
*Ул, ул – кеше,*
*К а й с ы н гасырлар тудырды,*
*Минутлар үтерде* (Һ. Такташ).

Бу төр төзелмәләр рус теле тәэсирендә диалектларда еш очрыйлар: *Бар, алып чык атны, к а й с ы н  кичә Әхмәт җиккән иде. Син укырга тырыш, к а й ч а н  өйдә һичкем юк* (урта диалект).

Бу төр мөнәсәбәтле сүзләр иярчен җөмлә составында торалар һәм баш җөмләдәге нинди дә булса бер сүзгә каратып әйтеләләр, шул сүзгә ориентация тоталар (русча «ориентированные» дигән төргә керәләр).

Сорау алмашлыгыннан гына торган ялгызак мөнәсәбәтле сүзне хәзерге әдәби нормаларга кертмәскә тырышалар, чөнки ул рус теле йогынтысы булып аңлашыла. Ул бары поэзия стилендә генә үзен иркен хис итә.

Алынма ялгызак мөнәсәбәтле сүз белән килгән иярчен җөмлә гадәттә кушма төзелмәнең башында килә, ахырында килү татар теле өчен норма түгел.

Алынма ялгызак мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән кушма төзелмәнең баш җөмләсенә күп очракта мәгънәгә зыян китермичә күрсәтү алмашлыгына нигезләнгән мөнәсәбәтле сүзне өстәп була дигән идек. Бу өстәлгән мөнәсәбәтле сүз иярчен һәм баш җөмләләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтен табарга да ярдәм итә. Баш җөмләгә өстәлгән мөнәсәбәтле сүз кайсы кисәк булып килсә, иярчен җөмлә дә шул кисәк исеме белән атала, иярчен һәм баш җөмләләр арасында мәгънә мөнәсәбәте дә шул кисәкнеке кебек үк була. Мәсәлән, *Ул – кеше, к а й с ы н  гасырлар тудырды* төзелмәсенең баш өлешен *Ул шундый кеше* дип әйтеп була. *Ул ш у н д ы й  кеше, к а й с ы н  гасырлар тудырды.* Баш җөмләдәге *шундый* мөнәсәбәтле сүзе аергыч булып килгән, димәк, иярчен җөмлә дә аергыч иярчен җөмлә була: җөмләләр арасында атрибутлык мөнәсәбәте урнаша.

## Баш җөмләгә интонацион чаралар аша ияргән аналитик җөмләләр

**§ 308. Интонацион бәйләүче чаралар һәм аларның семантикасы мәсьәләсе.** Җөмләләрнең әйтелгән авазлар (сегмент фонемалар) ярдәмендә ясалган кушымчалар, бәйлекләр, бәйлек сүзләр, теркәгечләр, теркәгеч сүзләр, мөнәсәбәтле сүзләр аша икенче бер җөмләгә бәйләнешен карауны төгәлләгәч, җөмләләрнең үзара интонацион чаралар (суперсегмент фонемалар: просодемалар) аша иярүен өйрәнү башлана.

Җөмләләр арасында тезүле бәйләнештә санау яки каршылык интонацияләре урын алса, ияртүле бәйләнешне күтәрү интонациясе (күтәрү паузасы) белдерә: алдагы җөмлә мәгънәне тулысынча ачып салмый, аны әйткәч, тагын нидер әйтелергә тиеш кебек күтәрү паузасы ясала, шуннан соң әйтеләсе мәгънәне тутырып тагын бер җөмлә әйтелә. Мәсәлән, *Ш у л в а к ы т күрәм: лампам эчендә май кими* (Г. Тукай) төзелмәсендәге *Шулвакыт күрәм* җөмләсе әйтелгәч, мәгънә тулы түгеллеген сиздереп, күтәрү паузасы ясала, аннан соң мәгънәне тулыландырып, *лампам эчендә май кими* дип әйтелә. *Мин ш у н ы гына беләм: ел елга охшамый* (Г. Тукай) төзелмәсендә җөмләләр *шуны* дигән ялгызак мөнәсәбәтле сүз ярдәмендә бәйләнәләр, шул ук сүз җөмләнең төрен дә билгели: *шуны* – тәмамлык, димәк, аның төгәл эчтәлеген хәбәр итә торган икенче җөмлә дә тәмамлык җөмлә була. Бу төзелмәдә *шуны* дигән бәйләүче чара белән бергә тагын бер ияртүче чара бар, ул – күтәрү паузасы. *Мин шуны гына беләм* дип әйткәч, мәгънә тулысынча хәбәр ителми, әле әйтеләсе әйтелеп бетмәгәнне сиздереп, күтәрү паузасы ясала, шуннан соң мәгънәне хәбәр итеп тәмамлаучы җөмлә әйтелә.

Шулай итеп җөмләләрне үзара бәйләүче өч төрле интонацион чара бар икәнен белдек: тезмә кушма җөмләдә – **санау** һәм **каршылык паузалары** (интонацияләре дип тә әйтелә), иярченле кушма җөмләләрдә – **күтәрү паузасы** (күтәрү интонациясе).

Җөмләләр арасында ияртүле мәгънә мөнәсәбәтен белдерүче **дүртенче төр интонацион чара** да бар: ул – кереш җөмләләрне баш җөмләгә ияртүче чара. Эксперименталь булмаган күзәтүләр шуны күрсәтә: кереш сүз (модаль кисәк) фунуциясен үти торган аналитик иярчен җөмлә (кереш җөмлә) баш җөмләдән пауза белән аерыла, җөмлә интонациясеннән түбәнрәк тонда тавышны төшеребрәк, тизрәк әйтелә. Бу интонацияне хәзергә **кереш интонациясе** дип атарга була.

Кереш интонация ярдәмендә баш җөмләгә чын кереш җөмләләр һәм мәгънәне, вазгыятьне үтешли генә аныклап килә торган җөмләләр иярә: *Аларны бит, г а ф у и т е г е з , һавадан ясап булмый* (М. Максуд). *Һәм (б у л а б и т т о р м ы ш т а ш у н д ы й м о г җ и з а - л а р ) аксап-туксап Воропаев килеп керде* (М. Максуд). *Хәлил агай йотлыгып-йотлыгып – җ а н ы ә р н е п б у л ы р – шуларны хикәя кылды* (Ш. Камал). *Тегесе эшнең мондый борылыш алырга торуыннан*

*бик үк риза булмыйча (к а й с ы б ы з н ы ң  х а т ы н ы  а л а й  т ү г е л ), мәгънәле генә бер карап куйды* (Ф. Хөсни).

Интонацион чаралардан тагын көттерү паузасына әйләнеп кайтыйк. Бу чара җөмләләр арасында мәгънә бәйләнеше булуны гомумән хәбәр итә, ләкин нинди конкрет мәгънә мөнәсәбәте икәнлеген тәгаенләп әйтми. Җөмләләр арасындагы төгәл мәгънә мөнәсәбәтен төзелмә башында килгән баш җөмлә эчендәге ялгызак мөнәсәбәтле сүз, я өстәп куярга мөмкин булган мөнәсәбәтле сүз, я җөмләләрнең үзара семантик һәм структур бәйләнешләре белдерә.

Җөмләләр үзара көттерү паузасы белән бәйләнгәндә, алар арасындагы мәгънә мөнәсәбәтен ачыклау өчен, аларны структур яктан үзгәртеп карау алымы кулланыла. Боларны мисалларда күзәтик.

*Кайгы, миннән тизрәк кит инде: синең көнең бетте бит инде* (М. Җәлил) синтаксик төзелмәсендә җөмләләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтен ачыклау өчен, мәгънәдән чыгып, алар арасына *чөнки* теркәгечен куеп карап була: *Кайгы, миннән тизрәк кит инде, ч ө н к и синең көнең бетте бит инде.*

*Нәфисәнең йөзеннән борчылу күләгәсе узды: оятлы булмабызмы икән?* дигән синтаксик төзелмәдәге җөмләләр арасында ияртүле бәйләнеш барлыгы сизелеп тора, моны җөмләләрнең семантикалары әйтеп тора, һәм ул ияртү бәйләнеше көттерү паузасы аша бирелгән. Ләкин нинди конкрет мәгънә мөнәсәбәте, моны мәгънәдән һәм структурадан сиземләп була. Шушы сиземләүне дөресләү өчен, синтаксик төзелмәгә җөмләләрне бәйләүче мөнәсәбәтле сүз өстәргә мөмкин: *Нәфисәнең йөзеннән ш у н д ы й борчылу күләгәсе узды: оятлы булмабызмы икән?* Биредә *шундый* мөнәсәбәтле сүзе баш җөмләдә аергыч булып килгән, димәк, иярчен җөмлә аергыч җөмлә була: җөмләләр арасында атрибутлык мөнәсәбәте урнашкан.

*Мин күп вакыт күрәм: биек пулатларга менү җиңел түгел* (Г. Тукай) – *Мин күп вакыт шуны күрәм: биек пулатларга менү җиңел түгел.* Биредә *шуны* мөнәсәбәтле сүзе өстәлде, ә ул баш җөмләдә тәмамлык булып килгән, димәк, иярчен аналитик җөмлә тәмамлык җөмлә була: җөмләләр арасында объектлык мөнәсәбәте урнашкан.

*Хәл ителде: Павел иртәгә китә – Ш у л хәл ителде: Павел иртәгә китә* төзелмәсендә *шул* мөнәсәбәтле сүзе өстәлде, ул баш җөмләдә ия

булып килгән, димәк, иярчен аналитик җөмлә дә ия җөмлә була, җөмләләр арасында хәбәрлекле мөнәсәбәт урнаша.

*Әйтергә теләгән сүзем: кешеләр стандарт түгелләр* (Ф. Хөсни). *Әйтергә теләгән сүзем шул: кешеләр стандарт түгелләр.* Биредә өстәлгән мөнәсәбәтле сүз – *шул,* ул баш җөмләнең хәбәре булып килә, димәк, иярчен аналитик җөмлә дә иярчен хәбәр җөмлә була.

Көттерү паузасы аша үзара бәйләнгән җөмләләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтен билгеләүнең төрки телләргә генә хас юлы – аналитик кушма җөмләне мәгънәсе белән туры килә торган синтетик кушма яки гади җөмләгә әйләндерү.

*Мин күп вакыт күрәм: биек пулатларга менү җиңел түгел – Мин күп вакыт биек пулатларга менү җиңел түгеллекне күрәм.*

*Хәл ителде: Павел иртәгә китә – Павелның иртәгә китүе хәл ителде.*

Тагын бер әһәмиятле күренешне истә тотарга кирәк: интонацион чара ярдәмендә бер-берсенә ияргән җөмләләр арасында төгәл мәгънә мөнәсәбәтен билгеләүдә контекст та билгеле дәрәҗәдә роль уйный.

Мәсәлән, *Түләп бетерсеннәр: хәл итәрбез* (И. Гази) төзелмәсен контекстка карап, *Түләп бетерсәләр хәл итәрбез* мәгънәсендә дә, *Түләп бетергәч хәл итәрбез* мәгънәсендә дә аңларга мөмкин.

**§ 309. Баш җөмләгә көттерү паузасы аша ияргән аналитик җөмләнең функциональ үзенчәлекләре.** Бу төр җөмләләр ике зур төркемгә аерылалар. Беренче төркемдә аналитик иярчен җөмлә баш җөмләнең я берәр баш кисәге, я иярчен кисәге функциясендә килә, икенче төркемгә керә торган төзелмәләрдә аналитик иярчен җөмлә баш җөмләнең кереш сүзе (модаль кисәге) функциясен үти.

1. Баш җөмләгә интонацион чара (көттерү паузасы) аша ияргән аналитик җөмлә баш җөмләнең түбәндәге баш һәм иярчен кисәкләре функциясендә килә ала.

1) Көттерү паузасы белән баш җөмләгә ияргән аналитик җөмлә баш җөмләгә карата ия функциясен дә, хәбәр функциясен дә үти ала, андый аналитик җөмлә белән баш җөмлә арасында хәбәрлекле мөнәсәбәт урнаша: *Безгә ачык: бары көч һәм корал айкап ташлый коллык тәхетен* (М. Җәлил) – *Безгә шул ачык:... Шул* баш җөмләнең иясе булып килә, димәк, аналитик җөмлә дә ия җөмлә була.

*Иң әһәмиятлесе: ул китаплар укырга вакыт тапты* (Ә. Фәйзи) – *Иң әһәмиятлесе ш у л : ... Шул* – баш җөмләнең хәбәре, аның ярдәмендә баш җөмләгә ияргән җөмлә дә хәбәр җөмлә була.

*Гадәтем: ялгыз кешеләрне кытыклап үтерәм* (Г. Тукай) – *Гадәтем ш у л :... Шул* – хәбәр, иярчен җөмлә дә – хәбәр җөмлә.

2) Көттерү паузасы белән баш җөмләгә ияргән аналитик җөмлә, баш җөмләдәге ияртүче кисәкнең атрибутын белдереп, аергыч җөмлә булып формалаша: *Мин шарт куям: рөхсәтнең чигеннән чыгылмасын* (Г. Ибраһимов) – *Мин ш у н д ы й шарт куям:...* Мәгънәгә зыян китермичә өстәлгән *шундый* мөнәсәбәтле сүзе баш җөмләдәге *шарт* кисәгенең аергычы булып санала, димәк, аналитик иярчен җөмлә дә – аергыч җөмлә була, баш һәм аналитик җөмләләр арасында атрибутлык мөнәсәбәте урнаша. Моны тагын җөмләне башкача үзгәртеп тә белеп була: *Мин р ө х с ә т н е ң ч и г е н н ә н ч ы г ы л м а с ы н д и г ә н шарт куям.*

*Урядникка югарыдан әмер килгән: Сәхип өстеннән күз-колак булырга* (Г. Ибраһимов) – *Урядникка югарыдан ш у н д ы й әмер килгән:... – Урядникка югарыдан С ә х и п ө с т е н н ә н к ү з - к о л а к б у л ы р г а дигән әмер килгән.*

*Ниһаять, Мостафин ныклы карарга килде: кыз белән чынлап сөйләшеп карарга* (Ә. Еники) – *Ниһаять, Мостафин ш у н д ы й ныклы карарга килде... – Ниһаять, Мостафин к ы з б е л ә н ч ы н л а п с ө й л ә ш е п к а р а р г а дигән карарга килде.*

3) Көттерү паузасы аша баш җөмләгә ияргән аналитик җөмлә баш җөмләдән аңлашылган эш-хәлнең объектын белдерә, үзе иярчен тәмамлык җөмлә булып формалаша: *Һәм без беләбез: Мостафин үзенең исәбендә ялгышмады* (Ә. Еники) – *Һәм без ш у н ы беләбез:... – Һәм без М о с т а ф и н ү з е н е ң и с ә б е н д ә я л г ы ш м а в ы н беләбез. Күрәм: озын гына буйлы берәү, җил-җил атлап, каршыга килә* (М. Вәлиев) – *Ш у н ы күрәм:... – Озын гына буйлы берәү, җил-җил атлап, каршыга килгәнне күрәм.*

*Ышан, илем: шушы ант сугарды йөрәгемнең соңгы тибешен* (М. Җәлил) – *Ш у ң а ышан, илем: ...* Бирелә *шуңа* – кыек тәмамлык, иярчен җөмлә дә тәмамлык җөмлә була.

4) Көттерү паузасы аша баш җөмләгә ияргән аналитик җөмлә баш җөмләдән аңлашылган эш-хәлнең сәбәбен белдерә, димәк, җөмләләр

арасында сәбәп мөнәсәбәте урнаша: *Кызганмыйча күңелем чыдый алмый: бигрәк моңлы карый күзләрең* (Г. Тукай) – *Кызганмыйча күңелем чыдый алмый, ч ө н к и бигрәк моңлы карый күзләрең – Күзләрең бигрәк моңлы караганга, кызганмыйча күңелем чыдый алмый. Әмма ул боларга игътибар да итмәде: аның уйлары башкада иде* (Р. Мирхәйдәров) – *Әмма ул боларга игътибар да итмәде, ч ө н к и аның уйлары башкада иде – Аның уйлары башкада булганга, ул боларга игътибар да итмәде.*

Иярчен сәбәп җөмлә, интонацион чара белән бәйләнгәндә, синтаксик төзелмәнең ахырында гына тормый, беренче урынны да алырга мөмкин: *Һәммә нәрсә яхшы бара: оештыручы канәгать – Һәммә нәрсә яхшы бара, ш у ң а к ү р ә оештыручы канәгать – Һәммә нәрсә яхшы барганлыктан, оештыручы канәгать.*

Бу җөмләләрне аналитик нәтиҗә җөмләле кушма җөмлә дип танырга да була. Билгеле ки, сәбәп белән нәтиҗә һәрчак бергә йөри: бер җөмлә сәбәпне белдерсә, икенчесе нәтиҗәне белдерә. Шуңа күрә *Һәммә нәрсә яхшы бара: оештыручы канәгать* төзелмәсендә беренчесе – сәбәп, ә икенчесе нәтиҗә була.

5) Күтәрү паузасы аша баш җөмләгә ияргән аналитик җөмлә баш җөмләдән аңлашылган эш-хәлне аныклап килергә мөмкин, андый аналитик җөмләне аныклагыч иярчен җөмлә дип атарга була: *Һава торышы әйбәт: давыл да, томан һәм яшенле яңгыр да юк* (М. Юныс). Бу җөмләләр арасында мәгънә мөнәсәбәтен ачыклау өчен, аларны үзгәртеп корып карарга мөмкин; үзгәрткәндә, мәгънәгә зыян килмәскә тиеш. *Һава торышы әйбәт, я г ъ н и давыл да, томан һәм яшенле яңгыр да юк. Ягъни* теркәгече ярдәмендә аныклагыч җөмләләр генә баш җөмләгә иярә.

*Карчык, әлбәттә, җиңелде: әңгәмәнең ахыры кызны озату чараларын кайгырту белән тәмам булды* (Г. Ибраһимов). – *Карчык, әлбәттә, җиңелде, я г ъ н и әңгәмәнең ахыры кызны озату чараларын кайгырту белән тәмам булды.*

Бу әле генә китерелгән төзелмәләрдә баш һәм иярчен җөмләләр тигез мәгънә күләмле, шуңа күрә алар арасында *ягъни* теркәгечен куеп була.

Ахырдан килә торган иярчен җөмлә баш җөмләнең бер кисәген генә аныклый икән, ул чагында алар арасына *ягъни* теркәгечен куеп

карап булмый: *Бик вакытлы төшкән икән: атасы капчыклар арасыннан үзенекен эзләп тапкан* (И. Гази). Биредә соңгы җөмлә беренче җөмләдәге *вакытлы* кисәген генә аныклаган, шуңа җөмләләр арасына *ягъни* теркәгече куела алмый.

*Ике бөртек чәч: берсе кара, берсе ак* (Г. Ибраһимов). Биредә дә *ягъни* теркәгечен куеп карап булмый.

Аныклагыч җөмләләр кушма төзелмәнең ахырында киләләр.

6) Интонацион чаралар ярдәмендә баш җөмләгә кереш җөмләләр (модаль җөмләләр) дә иярәләр. Биредә интонацион чара – көттерү паузасы түгел, ә кереш интонациясе, ягъни кереш җөмләнең баш җөмләдән пауза белән аерылуы, әһәмияте төп җөмләнекеннән кимрәк икәнен сиздереп, түбәнрәк тавыш белән тизрәк әйтелүе.

Аналитик кушма җөмлә эчендәге аналитик кереш җөмләләр нигездә ике төргә бүленәләр: 1) сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен (модаль мәгънә) белдерү өчен генә килгәннәре; 2) сөйләп барганда, ниндидер бер кисәкне аныклап килә һәм шул юл белән сөйләүченең сөйләм эчтәлегенә мөнәсәбәтен (модаль мәгънә) белдерүчеләре. Бу бүленеш, билгеле, шартлы бүленеш. Кереш җөмләләрнең баш җөмлә белән булган мәгънә мөнәсәбәтен санап, төркемләп чыгу мөмкин булмаган эш булып күренә, чөнки һәр кереш җөмләнең үзенә генә хас мәгънә үзенчәлеге була.

Мисаллар: *Минем гомерем – укучылар күрерләр – шактый ямьсез, шактый караңгы, шуның белән бергә бик кызык кына үткән булганга, яза башлагач, исемдә калганнарның һәммәсен язасым килде* (Г. Тукай). *Быелгы яз, картлар әйтмешли, бик иртә уянды* (Ш. Камал). *Бар да тынып калдылар, ә Кәримә йомшак, ягымлы тавыш белән гадәттәгечә каушабрак (шунлыктан, ахрысы, аның сүзен бүлмичә тыңларга өйрәнгәннәр иде) сөйләргә кереште* (Ә. Еники). Биредә кереш җөмлә *шунлыктан* сәбәп мөнәсәбәтле сүзе белән баш җөмләне үзенә буйсындыра. Бу – грамматик яктан шулай. Ләкин нәкъ менә шул грамматик яктан баш җөмлә язучы тарафыннан аныклаучы кереш иярчен җөмлә итеп бирелгән, шуңа күрә язуда ул җәяләр эченә алынган.

*Солдатлар (алар өчәү иде) Пьерга әһәмият бирмичә ашыйлар иде* (А. Шамов).

Кереш һәм аныклагыч җөмләләр татар телендә хәзергә кадәр махсус өйрәнелмәгәннәр, шул уңайдан әйтергә кирәк, интонацион чаралар да үзләренең эксперименталь юл белән өйрәнелүләрен көтәләр.

## ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘЛӘРНЕ ФУНКЦИОНАЛЬ ТӨРКЕМЛӘҮ ҺӘМ АЛАРНЫ ҮЗГӘРТЕП ТӨЗҮ

**§ 310. Җөмләнең функциональ төрләре һәм трансформацион синтаксис турында гомуми мәгълүмат.** Иярчен җөмләләрне без әле генә, бәйләүче чараларның үзенчәлегенә карап, синтетик һәм аналитик дигән төрләргә бүлеп өйрәндек. Һәрберсе үз эчендә тагын хәбәрнең бирелеше, андагы ияртүче чаралар буенча төркемләнделәр. Иярчен җөмләләрне (димәк, иярченле кушма җөмләләрне дә) тагын мәгънәләренә карап, ягъни функциональ яктан төркемләү дә традициягә кергән, һәм бу функциональ төркемләү дә татар телендәге иярченле кушма җөмләләрнең үзенчәлекләрен тулырак ачарга ярдәм итә.

Функциональ төркемләү – иярчен җөмлә баш җөмләнең кайсы да булса бер кисәге функциясен үти, – дигән караштан чыгып эш итә. Гади (яки баш) җөмләдә нинди кисәкләр булса, кушма җөмләдә дә шундый ук иярчен җөмләләр була. Бары эндәш сүзләргә туры килә торган җөмләләр генә булмый. Функциональ яктан түбәндәге иярчен җөмләләрне күрсәтәләр: ия, хәбәр, аергыч, тәмамлык, хәл, аныклагыч һәм кереш җөмләләр. Хәл җөмләләр үзләре күптөрле булалар. Иярчен җөмләләрнең функциональ төрләрен схематик рәвештә түбәндәгечә күрсәтеп була.




Иярчен җөмләләрнең функциональ төрләре синонимнарга бик бай. Бер функциональ төр эчендә бер үк җөмләне күптөрле синоним-

нарга үзгәртергә мөмкин. Менә шуның өчен иярчен җөмләнең функциональ төрләрен һәм иярченле кушма җөмләләрне үзгәртеп төзүне (иярчен җөмләләр трансформациясен) бер темада карарга туры килә.

Без бу татар синтаксисын грамматик синтаксис дип атадык. Грамматик синтаксистан тыш семантик синтаксис, структур синтаксис, структур-семантик синтаксис, коммуникатив синтаксис, тарихи синтаксис, чагыштырмалы-тарихи синтаксис, контрастив синтаксис дигән лингвистик тармаклар белән дә таныштык.

Бу урында трансформацион синтаксис тармагы турында да төп мәгълүматны бирергә кирәк. Бу төр синтаксис тел гыйлемендә гомумирәк юнәлеш саналган трансформацион лингвистиканың бер бүлеге санала. Билгеле бер семантиканы телдә төрлечә бирү мөмкинлеген, ягъни аның синонимнар байлыгын өйрәнгәндә, бер синтаксик төзелмәне аның шул ук мәгънәдәге башка синонимик парына әйләндерү юлы белән сөйләм төзелеше байлыгын ачу трансформацион синтаксисның төп бурычы санала. Бу синтаксис стилистик синтаксис буларак үстерелә. Трансформацион синтаксис бер төр сөйләм берәмлеген аның синонимик парына әйләндерү (трансформацияләү) алымы белән эш итә.

Безнең бу синтаксис трансформацион синтаксис булмаса да, без кайбер темаларны ныграк аңлау өчен үзгәртеп кору алымын (трансформацион методны) сирәк кенә булса да куллангаладык инде. Иярченле кушма җөмлә темасында аны системалы кулланырга кирәк дип уйлыйбыз, шуның өчен биредә укучыны трансформацион синтаксис белән дә гомумән генә таныштырырга булдык.

Трансформацион синтаксис мәгънәгә зыян китермичә бер-берсенә үзгәртелә ала торган синтаксик берәмлекләрнең (трансформантларның) төп (базовый) берәмлеген билгели, башкаларын шул төп берәмлекнең синонимик парлары дип саный.

Иярченле кушма җөмләләрне үзгәртеп төзү белән шөгыльләнгәндә, төп берәмлек итеп, җөмләләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтен төгәл күрсәткән кушма җөмлә алына, бу гадәттә төп ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр белән килгән җөмлә була. Мәсәлән, *К е м  эш ярата, а н ы  хөрмәт итәләр* (Г. Бәширов). Бу иярченле кушма җөмләдә аерым җөмләләрне үзара бәйләүче чара – *кем – аны* мөнәсәбәтле сүзе, монда бер дә ялгышмыйча баш җөмләне, иярчен җөмләне һәм

иярчен җөмләнең функциональ төрен билгеләп була. Моның өчен парлы мөнәсәбәтле сүзнең күрсәтү өлешенә игътибар итү җитә. *Аны* мөнәсәбәтле сүзе баш җөмләдә килә, һәм *аны* җөмләдә кайсы кисәк булса, ул мөнәсәбәтле сүзнең конкрет эчтәлеген хәбәр итүче иярчен җөмлә дә шул кисәк исеме белән атала. Биредә *аны* – тәмамлык, димәк, аның ярдәмендә бәйләнгән иярчен җөмлә дә тәмамлык җөмлә була. Шулай итеп бу җөмлә синонимик парларның төп берәмлегә дип танылa. Аның синтетик пары *Эш яратканны хөрмәт итәләр* формасында бирелә. Бу да иярченле синтетик кушма җөмлә. Бу очракта аналитик җөмлә белән синтетик җөмлә синоним булып килделәр.

Күп кенә очракларда аналитик җөмләгә синонимик пар булып, синтетик җөмлә генә түгел, синтетик ярым хәбәрлекле төзелмә дә килә. Мәсәлән, *Хәлим ни сораса, шуны алып бирергә тырыштылар* (И. Гази). Бу аналитик кушма җөмләгә синоним булып *Хәлим сораганны һәммәсен алып бирергә тырыштылар* синтетик кушма җөмлә килә; аңа тагын синоним булып, ярым хәбәрлекле гади җөмлә дә килергә мөмкин: *Хәлимнең барлык сораганнарын алып бирергә тырыштылар.* Бу җөмләдә *Хәлимнең* иялек килешендәге аергыч була, югарыдагыларында ул *Хәлим* формасында бирелгән ия иде.

Иярченле кушма җөмләләрне үзгәртеп төзүне (аларның трансформацияләрен) без иярчен җөмләләрнең функциональ төрләренә бәйләп карарга булдык.

Хәзер иярченле кушма җөмләләрне үзгәртеп төзүнең кайбер гомуми мәсьәләләренә тукталыйк.

**§ 311. Иярченле кушма җөмләләрне үзгәртеп төзү.** Тел белән практик эш иткәндә: үз язганнарыңны яки башка кеше текстын редакцияләгәндә, икенче бер телдән ана теленә тәрҗемә иткәндә, стиль матур булсын, эчтәлек тизрәк, җиңелрәк аңлашылсын өчен, төп мәгънәгә зыян китермичә, бер төр синтетик җөмләне икенче төр синтетик төзелмәгә, бер төр аналитик җөмләне аның башка бер төренә, яисә аналитик төрне синтетик төргә, синтетик төрне аналитик җөмләгә үзгәртеп төзергә мөмкин. Тел белән оста эш итүче шагыйрьләр, язучылар, тәрҗемәчеләр, журналистлар һәм редакторлар үз практикаларында аналитик һәм синтетик төзелешнең мондый синонимлыгыннан бик уңышлы файдаланалар. Бу – татар синтаксик төзелешенең грамматик һәм стилистик мөмкинлекләре зур булуы турында сөйли.

Бер төр синтетик җөмләне икенче төр синтетик җөмләгә әйләндергәндә, җөмләләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәте үзгәрешсез калырга, бары аларны бәйләүче чара гына алмаштырылырга тиеш. Мәсәлән, *Су өсте тыныч булганга, ай, бик шома алтын багана булып, Агыйдел төбенә сузыла* дигән мисалдагы җөмләләр арасында сәбәп мөнәсәбәте, ул синтетик юл белән бирелгән. Бу синтетик кушма җөмләне башка төр синтетик җөмләгә әйләндергәндә дә, шул сәбәп мөнәсәбәте сакланырга тиеш, бары бәйләүче чара булган юнәлеш килеше кушымчасы гына сәбәп белдерүче башка синтетик чара белән алмаштырыла: *Су өсте тыныч булганга (булганлыктан, булу аркасында, булу сәбәпле, булганга күрә), ай, бик шома алтын багана булып, Агыйдел төбенә сузылган.* Тагын бер мисал: *Атасы Бикбулат килгәндә (килгән чакта, килгән вакытта), Нәфисә яза торган хәбәрен очлап килә иде* (Г. Бәширов).

Аналитик кушма җөмләне аның аналитик парына күчергәндә дә, аналитик бәйләүче чаралар гына үзгәрергә тиеш. Мәсәлән: *Безгә алар белән танышырга туры килмәде: (чөнки) без анда өч-дүрт көн генә тордык* (Ш. Камал) – *Без анда өч-дүрт көн генә тордык, шунлыктан (шуңа күрә, шул сәбәпле, шуның аркасында) безгә алар белән танышырга туры килмәде.*

Стилистик яктан иң әһәмиятлесе – аналитик җөмләне синтетик төргә һәм киресенчә үзгәртеп төзү һәм аларның үзара синонимлыгыннан уңышлы файдалана белү. Алда әйтелгәнчә, төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә, аналитик җөмләләрнең кушма яки гади җөмлә формасындагы синтетик параллельләре, синтетик төрләрнең аналитик парлары бар. Синтетик төрләр фикерне бик җыйнак итеп формалаштырсалар, аналитик төрләр фикерне өлешләргә аерып бүлеп-бүлеп бирәләр. Шуңа күрә гадирәк, җыйнаграк фикерләрне биргәндә, синтетик төзелмәләр күбрәк кулланыла, бик катлаулы фикерләрне синтетик төрләр белән ачык итеп бирү бик кыен була, шуңа күрә бу очракта аналитик төрләрне файдалану уңышлы. Мәсәлән, *Бу конструкциянең өстенлеге двигательнең әйләнү тизлеге җил көченә бәйле булмауда* дигән синтетик төзелешле гади җөмлә «Ватаным Татарстан» газетасындагы бер тәрҗемә мәкаләдә бирелгән. Тәрҗемәче рус телендәге аналитик төрне, нәкъ татарча булсын дип, синтетик төргә әйләндереп тәрҗемә иткән. Биредә тәрҗемәче «Татар теленә бары синтетик

төрләр генә хас, аңа аналитик төрләр ят» дигән фикердән чыгып эш иткән булса кирәк. Билгеле булганча, аналитик төрләр татар телендә соңыннан гына әллә кайдан читтән китереп кертелмәгәннәр, бәлки алар телдә иң башта ук булганнар. Шуңа күрә китерелгән җөмләне аналитик итеп биргәндә дә, ул чын татарча булыр һәм фикер тагын да ачыграк әйтелер иде: *Бу конструкциянең өстенлеге шунда: двигательнең әйләнү тизлеге җил көченә бәйле түгел.*

**§ 312. Аналитик кушма җөмләне синтетик төзелмәгә әйләндерү**. Аналитик җөмләне синтетик төргә әйләндереп төзегәндә, кушма җөмлә дә, ярым хәбәрлекле гади җөмлә дә барлыкка килергә мөмкин. Мәсәлән, *Кем эшләми, шул ашамый* җөмләсен синтетикка әйләндергәндә, гади синтетик төр барлыкка килә: *Эшләмәгән ашамый. Минем күзләрем ул кадәр җете түгел түгелен, алай да күрәм* (Г. Бәширов) дигән җөмләне синтетик төргә үзгәрткәч, кушма җөмлә саклана, ул гади җөмләгә әйләнми: *Минем күзләрем ул кадәр җете булмасалар да күрәм.*

Теләсә нинди аналитик кушма җөмләне мәгънәсе белән туры килә торган синтетик төргә әйләндереп була. Бу вакытта да җөмләләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәте үзгәрешсез сакланырга тиеш, ләкин җөмлә структурасы бөтенләй үзгәрә. Мәсәлән: *Шуны да әйтергә кирәк: режим бөтен гаиләдә дә бертөрле була алмый* дигән мисалдагы җөмләләр арасында объектлык мөнәсәбәте бар, ягъни иярчен җөмлә тәмамлык функциясен үти. Аны синтетик төргә әйләндергәч, иярчен җөмлә җөмләлеген югалтса да, ул тәмамлык функциясен югалтмаска тиеш: *Режимның бөтен гаиләдә дә бертөрле була алмавын әйтергә кирәк.*

Аналитик төрне синтетик төргә әйләндергәндә, мөнәсәбәтле сүзләрнең иярчен җөмләләрне алмаштыру үзенчәлегеннән файдалану уңайлы.

Мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә төзелгән аналитик кушма җөмләне синтетик төргә әйләндерү өчен, күрсәтү алмашлыгыннан торган мөнәсәбәтле сүз урынына иярчен җөмлә үзе куела. Бу алмаштыруны эшләгәндә, мөнәсәбәтле сүз составында булган бәйләүче чара (кушымча, бәйлек яки бәйлек сүз) иярчен җөмләнең хәбәре янына куела. Мәсәлән, *Сугышчылар ярләрен төзәттеләр, ш у н н а н  с о ң Дубов рудниктан килгән хатны кычкырып укыды* (А. Шамов) мисалында

мөнәсәбәтле сүз – *шуннан соң*, аның составында *-нан соң* бәйләүче формасы бар. Бу җөмләне синтетикка әйләндерү өчен, *шуннан соң* мөнәсәбәтле сүзе урынына иярчен җөмлә үзе куела һәм аның хәбәре *-нан соң* формасын ала: *Сугышчылар иярләрен төзәткәннән соң, Дубов рудниктан килгән хатны кычкырып укыды*. Стиль матурлыгы таләпләреннән чыгып, -*нан соң* формасын соңыннан вакыт белдерүче башка чаралар белән алмаштырырга мөмкин (*төзәткәч, төзәтү белән, төзәтүгә*).

Мөнәсәбәтле сүзләр парлы булсалар, синтетик төргә әйләндергәндә, сорау алмашлыгыннан торган мөнәсәбәтле сүз ташлап калдырыла, ә күрсәтү алмашлыгыннан торган өлеше иярчен җөмлә белән алмаштырыла. Мәсәлән: *Җил кайдан исә, болыт та шуннан килә* (мәкаль) – *Болыт та җил искән яктан килә. Кем ки туган-үскән җирендә файдалы кешеләрдән саналмаса, аның күңелендә һәрвакыт чит җирләр сөекле булыр* (Г. Тукай) – *Туган-үскән җирендә файдалы кешеләрдән саналмаган кешенең күңелендә һәрвакыт чит җирләр сөекле булыр.*

Аналитик төзелмәдә мөнәсәбәтле сүзләр булмаса, ул синтетик төргә турыдан-туры әйләндерелә, турыдан-туры әйләндерү кыен булганда, иң элек, аналитик җөмләгә мөнәсәбәтле сүз куеп карала, шуннан соң инде мөнәсәбәтле сүз иярчен җөмлә белән алмаштырыла. Мәсәлән, *Без аның белән бик озак көрәшә алмадык, чөнки кызу эш өсте иде* дигән аналитик җөмләне синтетик төргә турыдан-туры әйләндерергә мөмкин: *Кызу эш өсте булганлыктан, без аның белән бик озак көрәшә алмадык.* Шул ук җөмләне иң элек мөнәсәбәтле сүз белән үзгәртеп төзергә (*Кызу эш өсте иде, ш у н л ы к т а н без аның белән бик озак көрәшә алмадык*), шуннан соң мөнәсәбәтле сүзне (*шунлыктан*) иярчен җөмлә белән алмаштырып куярга мөмкин: *Кызу эш өсте булганлыктан, без аның белән бик озак көрәшә алмадык.*

Тагын бер мисал: *Безгә ачык: бары көч һәм корал айкап ташлый коллык тәхетен* (М. Җәлил) дигән аналитик җөмлә күтәрү паузасы ярдәмендә төзелгән, анда иң элек мөнәсәбәтле сүз куеп карарга кирәк: *Безгә ш у н ы с ы ачык...* Монда *шунысы* мөнәсәбәтле сүзен алып, аның урынына иярчен җөмләнең үзен куйсак, синтетик төзелмәле гади җөмлә барлыкка килер: *Безгә бары көч һәм коралның гына коллык тәхетен айкап ташлавы ачык.*

*Ләкин күңелем сизәдер ки, мин бу эшкә ярамыйм* (Г. Тукай) мисалында да иң элек мөнәсәбәтле сүз куеп карарга кирәк: *Ләкин күңелем ш у н ы  сизә...* Шуннан соң мөнәсәбәтле сүз урынына иярчен җөмләне генә китереп куярга була: *Ләкин күңелем үземнең бу эшкә ярамавымны сизә.*

**§ 313. Синтетик төзелмәләрне аналитик кушма җөмләләргә әйләндерү.** Аналитик төзелмәләрне синтетик төзелмәләргә үзгәртеп төзү юллары яхшы үзләштерелсә, синтетик төрләрне аналитик җөмләләргә үзгәртү бик җиңел башкарыла. Бу очракта да мөнәсәбәтле сүзләрдән файдаланырга туры килә. Иң элек җөмләнең синтетик төзелешле өлеше мөстәкыйль гади җөмлә кебек итеп үзгәртеп төзелә, шуннан соң аны тулы килеш алмаштырырлык итеп, баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүз куела, һәм синтетик төрдә нинди бәйләүче чара булса, мөнәсәбәтле сүз дә шул ук форманы ала. Мәсәлән: *Сугыш башлану аркасында, Карлыгач укырга китә алмый калды* (Г. Бәширов) дигән синтетик төрне аналитик итеп үзгәртү өчен, иң элек *Сугыш башланды* формасында гади җөмлә төзергә кирәк. Шуннан соң аны алмаштыру өчен, баш җөмлә составына мөнәсәбәтле сүз куябыз, һәм мөнәсәбәтле сүз *аркасында* дигән бәйлек сүзне алырга тиеш: *Сугыш башланды, ш у н ы ң  а р к а с ы н д а  Карлыгач укырга китә алмый калды.* Шушы аналитик төзелмәгә нигезләп, стиль таләпләре буенча, башка аналитик төрләрне ясарга була: *Сугыш башланды, шуның аркасында (шул сәбәпле, шуңа күрә, шунлыктан), Карлыгач укырга китә алмый калды.*

*Җиңүнең үзеннән-үзе генә килмәвен Газинур соңгы сугышларда аеруча яхшы күрде* (Г. Әпсәләмов) формасындагы гади җөмләләрне дә аналитик төзелешле кушма җөмләләргә шул ук юл белән үзгәртеп була: *Җиңү үзеннән-үзе генә килми, Газинур соңгы сугышларда м о н ы  аеруча яхшы күрде* яки *Газинур соңгы сугышларда ш у н ы  аеруча яхшы күрде: җиңү үзеннән-үзе генә килми.*

Аналитик төр ялгызак мөнәсәбәтле сүз белән уңышсыз чыкса, аны парлы мөнәсәбәтле сүз белән ясарга кирәк. Мәсәлән, *Җир яхшы ашланган урында икмәк мул уңыш бирә* дигән синтетик төзелмәне *Җир яхшы ашлана, ш у л  у р ы н д а  икмәк мул уңыш бирә* формасында аналитик төзелмәгә әйләндереп булмый, аңа парлы мөнәсәбәтле сүз кирәк: *К а й д а  җир яхшы ашлана, ш у н д а  (шул урында) икмәк мул*

*уңыш бирә.* Тагын мисаллар: *Аның йөрәге куркыныч булган җирләргә ташланырга ашкына торган булды – К а й д а куркыныч, аның йөрәге ш у н д а ташланырга ашкына торган булды – Кайда куркыныч, аның йөрәге шунда ташланырга ашкына торган булды* (Г. Ибраһимов). *Тау итәгеннән, көмеш тасма сузылган төсле, кечкенәрәк елга агып ята – Көмеш тасма н и ч е к сузылса, кечкенәрәк елга да тау итәгеннән ш у л а й агып ята. Сабыр иткән морадына җиткән* (мәкаль) – *К е м сабыр итә, ш у л морадына җитә. Эш күрсәткәнне ил онытмас* (мәкаль) – *К е м эш күрсәтә, а н ы ил онытмый.*

**§ 314. Иярчен ия җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү.** Иярчен ия җөмлә баш җөмләнең иясе урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән иянең конкрет эчтәлеген тәшкил итә. Мәсәлән, *Сизелә: у т т е я ш ь в а к ы т л а р* (Г. Тукай) дигән кушма җөмләдә баш җөмләнең (*Сизелә* нең) иясе булып икенче җөмлә килә, һәм шуңа күрә ул иярчен ия җөмлә була. *К е м намус белән хезмәт итә, ш у л зур хөрмәткә ия була* дигән кушма җөмләнең баш җөмләсендә ия *шул* мөнәсәбәтле сүзе белән бирелгән, аның эчтәлеге ачык түгел, аны ачыклап, ягъни кемнең зур хөрмәткә ия булуын белдереп, аерым җөмлә килә. Мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән иянең конкрет эчтәлеген тәшкил иткәнлектән, беренче җөмлә иярчен ия җөмлә була.

Иярчен ия җөмләнең аналитик төре баш җөмләгә түбәндәге чаралар ярдәмендә бәйләнә.

1. Ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр (*шул, шунысы, бу, бу чаклысы, менә нәрсә, бер нәрсә*) ярдәмендә. Мәсәлән: *Хәзер безгә ш у л калды: атланырга тизрәк атларга* (Г. Тукай). *Тагын ш у н ы с ы кызык: бу хәлдән соң управляющийны күрәсем килү көчәеп китте* (Ә. Еники). *Нәкъ шулчакта елга үрендәге берничә кеше ашыгып кулларын күтәрделәр, м о н ы с ы – боз кузгалу турында сигнал* (Ә. Еники). *Гайшә тик кул куярлык булып чыкты, б у ч а к л ы с ы да аның өчен зур шатлык иде* (Г. Ибраһимов). *Ләкин бер н ә р с ә (менә нәрсә) калды: мин сездән мәсьәләләрне ачык һәм кискен куярга өйрәндем* (Г. Ибраһимов).

2. Парлы мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә: иярчен җөмлә составында сорау алмашлыгыннан торган мөнәсәбәтле сүз теләсә нинди формада һәм теләсә нинди функциядә килә ала, ә баш җөмлә составында күрсәтү алмашлыгыннан торган мөнәсәбәтле сүз баш килеш формасында ия булып кына килә. Мәсәлән: *К е м н е ң икмәге мул, халкы бер*

*җан, бер тәндәй оешкан, шул җиңеп чыга сугышта* (Г. Бәширов). *Кемгә әйтсәң, шул барыр* (И. Гази). *Кайсы ил башлый ала, шул башлап җибәрергә тиеш* (И. Гази). *Ул ни дисә, шул булыр* (И. Гази). *Кемгә кадерле яктылык, ирек, саклар ул аны күкрәк киереп* (Г. Камал).

3. Көттерү паузасы ярдәмендә. Ялгызак мөнәсәбәтле сүзе булган баш җөмлә алдан килсә, аннан соң да көттерү паузасы ясала, һәм ул язуда ике нокта белән белдерелә. Мөнәсәбәтле сүз булмаса, бердәнбер бәйләүче чара булып, көттерү паузасы үзе генә кала. Мәсәлән: *Безгә ачык: бары көч һәм корал айкап ташлый коллык тәхетен* (М. Җәлил). *Хәл ителде: Павел иртәгә китә* (М. Максуд).

4. *Ки* теркәгече ярдәмендә. Билгеле булганча, *ки* теркәгече грамматик чара булудан бигрәк, стилистик чара булып тора, чөнки аның билгеле бер грамматик мәгънәсе юк, ул теләсә нинди мәгънә мөнәсәбәте янында тора ала. Тыныш билгеләре куюга тәэсир иткәнлектән, аны һәрбер иярчен җөмлә янында искә алырга туры килә. Көттерү паузасы янында *ки* теркәгече килсә, ике нокта түгел, бәлки өтер генә куела. Мәсәлән: *Беленә ки, атны төн буена чаптырып газаплаучы шушы шүрәле икән* (Г. Тукай). *Билгеле ки, мәкальләр иҗтимагый тормыштан башка туа алмый* (Н.Исәнбәт).

5. *Ди* бәйлек-теркәгеч сүзенең исем фигыль формасы *дию* ярдәмендә: *Син минем бәгърем дию генә җитми. Әти киләчәк дию әле берни дә аңлатмый* (М. Хәсәнов). Бу төр аналитик җөмләләр *дию* сүзенең тәмамлыгы булып киләләр, ә *дию* бәйлек сүзе үзе – ия, шуңа күрә бу очрак иярчен ия җөмлә эчендә карала. Бу җөмләне үзгәртеп төзү шактый үзенчәлекле: *Әти киләчәк дию генә җитми – Әти киләчәк дисең, монда ул гына җитми.*

6. Иярчен ия җөмләнең аналитик һәм синтетик төрләр арасында тора торганнары да бар. Мәсәлән: *К. Насыйриның китаплары басылып чыгу реакцион көчләрне аңа каршы куя* (М. Гайнуллин). *Беләге юан берне егар, белеме күп меңне егар* (мәкаль). *Энесе туу Габдулланың бу өйдә гомумән кадерен киметте* (Ә. Фәйзи). *Анда ул, анда ул утларның Тукайлар яшьлектә якканы* (С. Хәким). Шушы ук төргә тагын хәбәре -*са* яки -*ганда* формасын алган ия җөмләләр дә керә. Мәсәлән: *Шушы өянкеләр башындагы карга ояларын актарып төшсәң, шәп*

*булыр иде булуын* (И. Гази). *Бу китапны укып чыкканда, әйбәт булыр иде.*

Соңгы җөмләләрнең хәбәрен *актарып төшү*, *укып чыгу* формасында куеп әйтеп була. Бу төр җөмләләр аналитикка якын, чөнки алар аерымланмыйча килә алмыйлар; синтетикка якын, чөнки иярчен җөмләнең хәбәре затланышлы түгел, ия булып килү өчен, исем фигыль формасын алган. Аларны чын аналитик һәм чын синтетик төрләргә дә әйләндереп булмый.

Хәзер түбәндәге таблицада иярчен ия җөмләнең аналитик, синтетик җөмлә һәм ярым хәбәрлекле синтетик синонимнарын күзәтик.

| № | Бәйләүче чаралар һәм төзелмәнең атамасы | Синонимнарга үзгәртеп төзү мисаллары |
|---|---|---|
| 1. | 1) *шунысы*.<br>Аналитик җөмлә.<br>2) интонация<br>Аналитик җөмлә.<br>3) *-ү* һәм җөмлә тәртибе.<br>Синтетик-аналитик җөмлә.<br>4) *-үе* һәм җөмлә тәртибе.<br>Ярым хәбәрлекле кисәк. | *Шунысы хәл ителде: Павел иртәгә китә.*<br>*Хәл ителде: Павел иртәгә китә.*<br><br>*Павел китү хәл ителде.*<br><br>*Павелның китүе хәл ителде.* |
| 2. | 1) *шул*.<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *-гәне*, җөмлә урыны.<br>Синтетик җөмлә.<br>3) *-гәне*, җөмлә урыны.<br>Ярым хәбәрлекле кисәк. | *Ерактан пароход килә, шул күренә.*<br>*Ерактан пароход килгәне күренә*<br>*Ерактан пароходның килгәне күренә.* |
| 3. | 1) *кем – шул*.<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *-гән*, җөмлә урыны.<br>Ярым хәбәрлекле кисәк. | *Кем тырыша, шул таба.*<br><br>*Тырышкан таба.* |
| 4. | 1) *кемнең – шул*.<br>Аналитик җөмлә.<br>2) җөмлә тәртибе, III зат кушымчасы<br>Синтетик җөмлә. | *Кемнең гаиләсе юк, шул барыр.*<br>*Гаиләсе юклар барыр.* |

| | | |
|---|---|---|
| 5. | 1) *-лык,* җөмлә тәртибе.<br>Синтетик җөмлә.<br>2) *шул.*<br>Аналитик җөмлә.<br>3) *-лыгы,* җөмлә тәртибе.<br>Ярым хәбәрлекле кисәк. | *Аны а к ч а ю к л ы к борчый.*<br><br>*Аны ш у л борчый: акчасы юк.*<br><br>*Аны а к ч а с ы н ы ң ю к л ы г ы борчый.* |
| 6. | 1) *дию.*<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *ул.*<br>Аналитик җөмлә. | *Әни әйтер д и ю генә җитми.*<br><br>*Әни әйтер дисең, ул гына җитми.* |
| 7. | 1) интонация.<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *шул*<br>Аналитик җөмлә.<br>3) *-лек.*<br>Синтетик җөмлә.<br>4) *-леге.*<br>Ярым хәбәрлекле кисәк. | *Соңыннан беленде: э т и б а р ы р г а т и е ш.*<br>*Соңыннан ш у л беленде: эти барырга тиеш.*<br>*Соңыннан эти б а р ы р г а т и е ш л е к беленде.*<br>*Соңыннан этинең б а р ы р г а т и е ш л е г е беленде.* |

**§ 315. Иярчен хәбәр җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү.** Иярчен хәбәр җөмлә күбрәк баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән хәбәрне ачыклый, аның конкрет эчтәлеген тәшкил итә. Сирәк очракларда гына мөнәсәбәтле сүз кулланылмыйча, хәбәр җөмлә баш җөмләнең хәбәре урынында турыдан-туры килергә мөмкин.

Иярчен хәбәр җөмлә бары аналитик кына була һәм баш җөмләгә түбәндәге чаралар ярдәмендә бәйләнә.

1. Ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр (*шул, шул икән, шул булды, шул иде, шунда, шундый, шулай, болай, шуңа, шуннан иде*) ярдәмендә. Ялгызак мөнәсәбәтле сүз һәрвакыт баш җөмләдә хәбәр булып килә. Мәсәлән: *Әйтәсем килгәне ш у л : без элек хайван чутында яшәдек* (Г. Бәширов). *Эш ш у н д а : хәзер безгә аңардан да аяусызрак булырга* кирәк (Г. Бәширов). *Тагын аның өчен иң куркынычлысы ш у л и д е : халык күзеннән әкренләп төшә баруын, бер язучы әйтмешли, аркасы белән тоеп йөри иде* (Ә. Еники). *Һәр заманны монда хәлләр ш у л и к ә н : һәркем үз хәле белән мәшгуль икән* (Г. Тукай). *Минем бөтен анархистлыгым ш у л б у л д ы : мин анархизм турындагы китапларны яратып укый*

*идем* (Г. Ибраһимов). *Кешенең кеше булуының чын мәгънәсе шунда: ул башкаларны хөрмәт итәргә тиеш. Идарәнең карары ш у н д ы й : бүгенгесе көннән башлап син ындыр бригадиры буласың* (Г. Бәширов). *Минем уемча эш б о л а й : сине моңа өйрәтүчеләр Каюм абзый белән Әхмәт булырга кирәк* (Ш. Камал). *Алдан килүче булса, бүләк ш у ң а* («Казан утлары»). *Карчыкның сәнәк фетнәсеннән калган күңел ярасы һич төзәлмәде, Мәрьямбикә әйткәч, совхозга барырга теләмәве дә ш у н н а н  и д е* (Г. Ибраһимов).

2. Парлы мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә. Иярчен җөмләдә төрле формадагы сорау алмашлыклары, ә баш җөмләдә, төрле формада булса да, хәбәр функциясендәге күрсәтү алмашлыклары килә. Мәсәлән: *К е м  чәчүдә беренчелекне ала, бүләк ш у ң а* («Ватаным Татарстан»). *К ү п м е  булса сездә көч һәм ялкын, ш у л к а д ә р л е  җирдә хаккыгыз* (М. Җәлил). *Болында үлән н и х ә т л е , анда кеше ш у л х ә т л е* (Г. Бәширов).

3. Мөнәсәбәтле сүз кулланылмаганда, көттерү паузасы бердәнбер бәйләүче чара булып кала. Мәсәлән: *Гадәтем: ялгыз кешеләрне кытыклап үтерәм* (Г. Тукай). *Әйтергә теләгән сүзем: кешеләр стандарт түгелләр* (Ф. Хөсни).

4. Мөнәсәбәтле сүзләр янында *ки* теркәгече дә килә. Мәсәлән: *Бу ике гыйлемне укып белмәктән максат ш у л д ы р  к и , сөйләшкәндә вә язганда, телне хатадан сакламактыр* (К. Насыйри).

Соңгы елларда *ки* теркәгечен куллану сизелерлек дәрәҗәдә кими бара.

Иярчен хәбәр җөмләле кушма төзелмәне аның төрле синонимнарына үзгәртеп төзү мөмкинлеге бай түгел, шулай да бераз бар. Шуларны таблицада күзәтик.

| № | Бәйләүче чаралар һәм төзелмәнең атамасы | Синонимнарга үзгәртеп төзү мисаллары |
|---|---|---|
| 1. | 1) *шунда.*<br>Аналитик җөмлә.<br>2) (*-да*)<br>Ярым хәбәрлекле кисәк.<br>3) *шунда ки.*<br>Аналитик җөмлә. | *Эш  ш у н д а : иртәгә соң була.*<br><br>*Эш  ш у н д а  ки, иртәгә соң була.*<br><br>*Эш иртәгә соң булуда.* |

| | | |
|---|---|---|
| 2. | 1) *кем – шуңа, күпме – шул кадәрле* һ.б.<br>Аналитик җөмлә.<br>2) (*-гә, хәтле*).<br>Ярым хәбәрлекле кисәк. | *Кем алдан килә, бүләк шуңа. Болында үлән нихәтле, анда кеше шулхәтле.*<br>*Бүләк алдан килүчегә. Анда кеше болындагы үлән хәтле.* |
| 3. | 1) *шул, шул икән, шул булды, шул иде, шуннан иде.*<br>Аналитик җөмлә.<br>2) көттерү паузасы.<br>Аналитик җөмлә. | *Минем тәкъдим шул: сез аны сакларга тиеш.*<br><br>*Минем тәкъдим: сез аны сакларга тиеш.* |
| 4. | 1) *шундый, шулай.*<br>Аналитик җөмлә.<br>2) интонация.<br>Ярым хәбәрлекле кисәк. | *Сезнең эшегез шундый: машинадан кирпеч бушатасыз.*<br>*Сезнең эшегез – машинадан кирпеч бушату.* |

**§ 316. Иярчен тәмамлык җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү.** Иярчен җөмләләрнең туры тәмамлыкка туры килгәннәре дә, кыек тәмамлык сорауларына җавап биргәннәре дә бер исем белән тәмамлык җөмлә дип атала. Иярчен тәмамлык җөмлә я баш җөмләнең тәмамлыгы урынында килә, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән тәмамлыкны ачыклый, аның конкрет эчтәлеген тәшкил итә. Тәмамлык җөмләнең аналитик төрләре дә, синтетик төрләре дә бар.

Аналитик иярчен тәмамлык җөмләләр баш җөмләгә түбәндәге чаралар ярдәмендә бәйләнәләр:

1. Ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр (*шуны, моны, шунысын, шуңа, шуннан, шуңардан, шунда, шуның белән, шуның турында, шул хакта* һ.б.) ярдәмендә. Мәсәлән: *Мин шуны гына беләм: ел елга охшамый* (Г. Тукай). *Прокурор Степановның башына ниндидер уй килде, шуның белән бераз җиңеләйде* (Г. Ибраһимов). *Зур бурычлар тора алгы көндә, шул турыда язып ташлыймын* (Һ. Такташ). *Сездән бер генә нәрсә телим: тизрәк юлда булыгыз* (Х. Сарьян).

2. Парлы мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә. Иярчен җөмлә составында төрле формадагы һәм төрле функциядәге сорау алмашлыклары, ә баш җөмләдә тәмамлык функциясендәге күрсәтү алмашлыклары килә. Мәсәлән: *Ул ни куша, шуны эшли* (Г. Ибраһимов). *Кем со-*

*раса, шуңа сатарга тора* (Г. Ибраһимов). *Элек сез кемнән алган булсагыз, без дә шуңардан сорарга уйлап торабыз* (Г. Ибраһимов). *Кемнең ки күңеле дуслык, сөешү кеби хисләрдән буш яратылган булса, аның каршында бөтен халык дошмандыр* (Г. Тукай). *Хәлимнн сораса, шуны алып бирергә тырыштылар* (И. Гази).

3. Көттерү паузасы ярдәмендә. Ялгызак мөнәсәбәтле сүз белән килгән баш җөмлә алдан килсә, аннан соң да көттерү паузасы ясала, шулай ук көттерү паузасы үзе генә дә килергә мөмкин. Мәсәлән: *Галиулла шунда ук сизеп алды: десятник аны су юлы өстендәге ташландык забойны рәтләргә җибәрмәкче икән* (И. Гази). *Яулык шаһит: сине һәм илемне йөрәк каным белән сакладым* (М. Җәлил). *Һәм без беләбез: Мостафин үзенең бу исәбендә ялгышмады* (Ә. Еники).

4. Югарыдагы чаралар янында *ки* теркәгече дә килергә мөмкин. Мәсәлән: *Без беләбез ки, тынычлык сугышны җиңәр. Безнең мәктәп шуңа иреште ки, укучылар начар билгеләре алмый башладылар.*

5. *Дип, дигәнне, дигәннән, дигәнгә* сүзләре ярдәмендә. Мәсәлән: *Кем уйлаган, шушы шаярулар синдә кәсеп булып калыр дип* (Һ. Такташ). *Син шулай ачык һәм матур язасың дип, һич тә күз алдына китермәгән идем. Безгә дә килегез дигәнне ишетмәссең аңардан* (Х. Сарьян). *Мин сине хөрмәт итәм дигәннән әллә нинди нәтиҗә чыгара күрмәгез. Мин сине белмим дигәнгә аптырадым да калдым.*

Синтетик иярчен тәмамлык җөмлә баш җөмләгә хәбәр составындагы чаралар ярдәмендә бәйләнә.

1. Төшем килеше кушымчасы ярдәмендә: *Куктә кечкенә генә болыт кисәге күренүне дә зарыгып көтәсең* (Г. Гали). *Мин кабыздым җырда ялкын итеп, йөрәгем һәм хаклык кушканны* (М. Җәлил).

2. Юнәлеш килеше кушымчасы ярдәмендә: *Сез җырлаганга сокланабыз.*

Иярчен тәмамлык җөмләле кушма төзелмәне аның төрле синонимнарына үзгәртеп төзү мөмкинлеге шактый күп. Шуларны таблицадан күзәтик.

| № | Бәйләүче чаралар һәм төзелмәнең атамасы | Синонимнарга үзгәртеп төзү мисаллары |
|---|---|---|
| 1. | 1) *шуны, шунысын.*<br>Аналитик җөмлә.<br>2) көттерү паузасы.<br>Аналитик җөмлә.<br>3) *-ны, -уны.*<br>Синтетик җөмлә.<br>4) *-ын, -уын, -(мас)ын.*<br>Ярым хәбәрлекле кисәк. | *Мин шуны гына беләм: ел елга охшамый* (Г. Тукай).<br>*Мин беләм: ел елга охшамый.*<br>*Мин ел елга охшамауны (охшамаганны) гына беләм.*<br><br>*Мин елның елга охшамавын (охшамаганын, охшамасын) беләм.* |
| 2. | 1) *шуңа,шуннан, шуңардан, шул хакта, шунда, шуның белән* һ.б.<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *көттерү паузасы.*<br>Аналитик җөмлә.<br><br>3) *-га, белән, турында* һ.б.<br>Синтетик җөмлә.<br><br><br><br>4) *-уына, -уы белән, -уы турында* һ.б.<br>Ярым хәбәрлекле кисәк. | *Мин шуңа бик гаҗәпләндем: ул кайтмаган; Ул шуның белән мактана: әтисе чаңгы алган.*<br><br>*Мин бик гаҗәпләндем: ул кайтмаган; Ул мактана: әтисе чаңгы алган.*<br>*Ул кайтмаганга, мин бик гаҗәпләндем; Ул әтисе чаңгы алу белән мактана; Әтисе кайту турында сөйли.*<br>*Аның кайтмавына мин бик гаҗәпләндем; Ул әтисенең чаңгы алуы белән мактана; Әтисенең кайтуы турында сөйли.* |
| 3. | 1) *ни – шуны, кемнән – шуны* һ.б.<br>Аналитик җөмлә.<br>2) мөнәсәбәтле сүздәге формалар хәбәр составына күчә.<br>Синтетик җөмлә.<br>3) шул ук формалар.<br>Ярым хәбәрлекле кисәк. | *Хәлим ни сораса, шуны алып бирергә тырыштылар.*<br><br>*Хәлим сораганны алып бирергә тырыштылар.*<br><br><br><br>*Хәлимнең сораганын алып бирергә тырыштылар.* |

| | | |
|---|---|---|
| 4. | 1) *шуңа.* Тәмамлык-сәбәп җөмлә.<br>2) *-ка.*<br>Синтетик җөмлә.<br>3) *-лыг-ына.*<br>Ярым хәбәрлекле кисәк. | *Акчасы юк, шуңа бик борчыла.*<br><br>*Акчасы юкка (азлыкка) бик борчыла.*<br>*Акчасының юклыгына (азлыгына) бик борчыла.* |
| 5. | 1) *кем – шуны, кем – шуңа, кем – шуннан* һ.б.<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *-ны, -гә.*<br>Ярым хәбәрлекле кисәк. | *Кем качып кайта, шуны кире җибәрегез; Кем дөресен әйтә, аңа үпкәләп булмый.*<br>*Качып кайтканны кире җибәрегез; Дөресен әйткәнгә үпкәләп булмый.* |

*Дип, дигәнне* кебек сүзләр белән формалашкан тәмамлык җөмләне башка синонимик парга үзгәртеп төзү гадәте юк: *Кит дигәнне ишетмисеңме? Син килерсең дип уйламадым.*

**§ 317. Иярчен аергыч җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү.** Иярчен аергыч җөмлә я баш җөмләнең аергычы урынында килә, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән аергычны ачыклый. Аергыч җөмләнең аналитик төрләре дә, синтетик төрләре дә була.

Аналитик аергыч җөмлә баш җөмләгә түбәндәге чаралар ярдәмендә бәйләнә.

1. Ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр (*шул, шундый, шуның, аның*) ярдәмендә. Мәсәлән: *Була шундый вакытлар: ул үзенең гаҗәеп тавышы белән кем беләндер көлә-көлә сөйләшә башлый* (Г. Ибраһимов). *Герасимов монда шул моментны әрнеп йөрәгенә алды: ораторның сүзе ничаклы кискен чыкса, халыкның алкышы шул дәрәҗәдә көчле була* (Г. Ибраһимов).

Шигъри әсәрләрдә иярчен җөмлә составында килә һәм сорау алмашлыгы белән бирелә торган (ягъни алынма ялгызак) мөнәсәбәтле сүзләр дә аергыч җөмләне баш җөмләгә бәйләргә мөмкин. Мәсәлән: *Без черек йөкләрне өстән ташлыйбыз, кайсылар безне үлемдәй каплаган* (Һ. Такташ).

2. Парлы мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә. Иярчен җөмләдә сорау алмашлыкларыннан торган мөнәсәбәтле сүзләр төрле функцияләрдә килә алсалар да, баш җөмләдәге күрсәтү алмашлыгы белән бирелгән

мөнәсәбәтле сүз бары аергыч булып кына килә. Мәсәлән: *Кем ки туган-үскән җирендә файдалы кешеләрдән саналмаса, аның күңелендә һәрвакыт чит җирләр сөекле булыр* (Г. Тукай). *Бәхетле шул баладыр, кайсы дәресенә күңел бирсә* (Г. Тукай). *Нинди эш уңай булса, шул эшне эшлидер* (Г. Тукай).

3. Көттерү паузасы ярдәмендә. Мәсәлән: *Ләкин бер кеше бар: үзе бетерешкән, көчсез, чалгы да күтәрә алмый, ләкин итекне бик матур тегә* (Г. Тукай). *Җиткерәбез без аңар бер бик матур шатлык хәбәр: алдагы көзгә арыш, һич шөбһәсез, булыр чибәр* (Г. Тукай).

4. Югарыдагы чаралар янында *ки* теркәче дә килергә мөмкин. Мәсәлән: *Ул сиңа шундый итекләр тегеп бирер ки, кешегә күрсәтү бөтенләй оят булыр* (Г. Тукай). *Шундый байлар бар ки, аларның үлеме генә бер файдага ярыйдыр* (Г. Тукай).

Синтетик аергыч җөмләләр баш җөмләгә янәшә тору чарасы ярдәмендә бәйләнәләр, ягъни алар баш җөмләдәге ияртүче кисәк белән мәҗбүри рәвештә янәшә торырга тиеш булалар. Хәтта иярчен җөмләнең хәбәре булып сыйфат фигыльләр килгәндә дә, ул ияртүче кисәктән аерылып китә алмый. Мәсәлән: *Син гамьсез йөргән бу җирне батыр уллар үткәннәр* (Ш. Галиев). *Җире аз кешеләр батраклыкка яллана иделәр* (Г. Бәширов). *Без барасы юлларның ике чите гөлчәчәк* (җыр). *Син килергә тиеш юлны күзәтәм.*

Аергыч җөмләле кушма җөмләләр дә үзләренең төрле синонимнарына үзгәртелә алалар.

| № | Бәйләүче чаралар һәм төзелмәнең атамасы | Синонимнарга үзгәртеп төзү мисаллары |
|---|---|---|
| 1. | 1) *шул, шундый, шуның, аның* һ.б.<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *-ган, -асы, -ар/-мас, -арлык, -ардай, -лы/-сыз, юк/бар, аз, күп, кирәк, тиеш*<br>Синтетик җөмлә.<br>3) шулар ук.<br>Ярым хәбәрлекле кисәк | *Шундый чор килде: һәркем тулы хокуклы.*<br><br><br>*Һәркем тулы хокуклы булган чор килде*<br><br><br><br>*Һәркемнең тулы хокуклы булган чоры килде* |

| | | |
|---|---|---|
| 2. | 1) *кайсы – шул, кем – аның*. Аналитик җөмлә.<br>2) *-ган.*<br>Ярым хәбәрлекле кисәк. | *К а й с ы мәктәп беренчелекне ала, ш у л мәктәпне мактап язалар.*<br>*Б е р е н ч е л е к н е а л г а н мәктәпне мактап язалар.* |
| 3. | 1) *шундый.*<br>Аналитик җөмлә.<br><br>2) *-ган.*<br>Синтетик җөмлә. | *Ш у н д ы й байлар бар ки, аларның үлеме генә бер файдага ярыйдыр* (Г. Тукай).<br>*Ү л е м е г е н ә б е р ф а й д а г а я р ы й т о р г а н байлар бар.* |
| 4. | 1) *кайсы, кайсысы ки.*<br>Аналитик җөмлә.<br><br>2) *кайсы – шундый.*<br>Аналитик җөмлә.<br><br>3) янәшә тору.<br>Ярым хәбәрлекле кисәк. | *Без черек йөкләрне өстән ташлыйбыз, к а й с ы л а р ы безне үлемдәй каплаган* (Һ. Такташ).<br>*Без ш у н д ы й черек йөкләрне өстән ташлыйбыз, к а й с ы л а р ы безне үлемдәй каплаган.*<br>*Б е з н е ү л е м д ә й к а п л а г а н черек йөкләрне өстән ташлыйбыз.* |
| 5. | 1) *бер.*<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *шундый бер.*<br>Аналитик җөмлә.<br>3) янәшә тору.<br>Ярым хәбәрлекле кисәк. | *Б е р оста бар: итекне бик матур тегә.*<br>*Ш у н д ы й б е р оста бар: итекне бик матур тегә.*<br>*И т е к н е б и к м а т у р т е г ә т о р г а н оста бар* |
| 6. | 1) *кемнең – шуның.*<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *-ның.*<br>Синтетик җөмлә. | *К е м н е ң эше юк, а н ы ң ашы да юк* (мәкаль).<br>*Э ш е ю к н ы ң ашы да юк* |

*Дигән* сүзе белән белән килгән аергыч җөмләле кушма төзелмә синонимик парларга үзгәртелә алмый: *Башына о ч р а ш м а б ы з и н д е д и г ә н уй килде.*

**§ 318. Иярчен вакыт җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү.** Иярчен вакыт җөмлә баш җөмләдәге эш яки хәлнең вакытын белдерә. Ул я турыдан-туры баш җөмләнең вакыт хәле урынында килә, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән вакыт хәлен ачыклый, аның конкрет эчтәлеген тәшкил итә. Вакыт белдерү ягыннан иярчен вакыт

җөмлә баш җөмлә белән өч төрле мәгънә мөнәсәбәтендә тора: а) иярчен җөмләдәге эш баш җөмләдәге эш белән бер үк вакытта үтәлә: *Без мәктәпкә барганда (барган чакта, барган вакытта), бик көчле яңгыр яуды; Без мәктәпкә бара идек, шул вакытта (шунда, шулчакта) бик көчле яңгыр яуды;* ә) иярчен җөмләдәге эш баш җөмләдәге эштән соң үтәлә: *Без мәктәпкә барганчы (барганга хәтле, барганга чаклы), бик көчле яңгыр яуды; Без мәктәпкә бардык, аңа кадәр (аңарчы, аңа чаклы) бик көчле яңгыр явып үткән иде;* б) иярчен җөмләдәге эш баш җөмләдәге эштән алда үтәлә: *Без мәктәпкә баргач (барганнан соң, баруга, бару белән), бик көчле яңгыр яуды; Без мәктәпкә барып кердек, шуннан соң (шунда ук, ул да түгел) бик көчле яңгыр ява башлады.*

Иярчен вакыт җөмләнең аналитик төрләре дә, синтетик төрләре дә бар.

Аналитик вакыт җөмлә баш җөмләгә түбәндәге чаралар ярдәмендә бәйләнә:

1. Ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр *(шунда, шуннан бирле, шуннан соң, аннары, шуңа чаклы, шуңа кадәр, шулчакта, шундый вакытта)* ярдәмендә. Мәсәлән: *Мәңге буран булмас, бер аязыр, ш у н д а халык игенен дә сугар, кызын да бирер, киленен дә ярәшер* (Г. Ибраһимов). *Дөнья кайнарга тора, ш у л ч а к т а сез әллә кайда җыен юк-бар эш артыннан йөрисез* (Г. Ибраһимов). *Икесе дә арбадан төштеләр, ш у н н а н с о ң әтисе бодайларның ике төрлесеннән дә берәр башак өзеп алды* (Дәрдемәнд).

2. Парлы мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә. Парлы булып, иярчен җөмләдә вакыт белдерүче сорау алмашлыклары, ә баш җөмләдә вакыт хәле функциясен үтәүче күрсәтү алмашлыгы йөри. Мәсәлән: *К а й ч а н кирәк тапсалар, ш у н д а хезмәт итә* (Г. Ибраһимов). *Ул к а й ч а н килергә куша, Илсөяр нәкъ ш у л в а к ы т к а килеп җитә* (Г. Гобәй).

3. *Ул да түгел* теркәгеч сүзе ярдәмендә. *Галиулла белән Хәлим тиз генә юлдан чыктылар, у л д а т ү г е л , әллә никадәр тузан туздырып, күк атлы кеше узып китте* (И. Гази). Иярчен җөмләдә вакытны белдермәгән сорау алмашлыгы килүгә Г. Тукайда бер мисал бар: *Йокысыннан кояш н и ч е к уянды исә, җил ш у л в а к ы т җилбер-җилбер итеп исә.* Ләкин монда *ничек* сүзе вакыт мәгънәсендә килә. Хәзерге әдәби телдә мондый очракта *кайчан* алмашлыгы кулланыла.

Синтетик вакыт җөмлә баш җөмләгә түбәндәге чаралар ярдәмендә бәйләнә:

1. Төрле фигыль формалары (*-гач, -ганчы, җитәрәк, туктар-туктамас*) ярдәмендә. Мәсәлән: *А р б а я л к а у г ы н а ш ы г ы р д а п к у з г а л ы п к и т к ә ч , мин кармакларым янына килдем* (Ә. Еники). *С е к р е т а р ь у р ы н к ү р с ә т е п ө л г е р г ә н ч е , ул инде аның каршындагы урындыкка килеп утырган иде* (Ф. Хөсни). *Каракүз, т р а к т о р к и л е п т у к т а р - т у к т а м а с , тагылма вагонның ишегенә ябышты* (И.Салахов). *Т р а н ш е я г а б а р ы п җ и т ә р ә к , дошман бик каты ут ачты* (Г. Әпсәләмов).

2. Төрле формадагы хәбәрләр составында урын-вакыт яки юнәлеш килеше кушымчасы да килергә мөмкин. Мәсәлән: *А т к и л е п т у к т а у г а , ул картлар белән татар телендә исәнләште* (Г. Ибраһимов). *И р т ә н М о х т а р й о к ы с ы н н а н у я н г а н д а , Фәйзи инде торган, юынган, чәй эчәргә әзерләнеп маташа иде* (Ш. Камал).

3. Төрле формадагы хәбәрләр янында бәйлекләр яки бәйлек сүзләр *(белән, бирле, соң, арада, чакта, вакытта, борын)* килә ала. Мәсәлән: *Б е р - и к е м и н у т ү т ү б е л ә н, арадагы пәрдә югалды* (Г. Ибраһимов). *Э л е к т р о с т а н ц и я э ш л и б а ш л а г а н н а н б и р л е , тормыш һаман яхшыра бара* (Ә. Еники). *Б е р е н ч е к а р т ө ш ә р а л д ы н н а н , алар алмаларын агачта килеш Маликка саттылар* (И. Гази). *Ч ү к е ч л ә р т ы н ы п т о р г а н а р а д а , аргы почмакта тимерче Мостафаның карлыга төшкән тавышы яңгырады* (К. Нәҗми). *Б о л а р ш у л а й с ө й л ә н е п т о р г а н ч а к т а , арткы тыкрыктан Гайшә килеп чыкты* (Г. Ибраһимов).

Вакыт җөмләләрнең гадәттә үзләренең аналитик һәм синтетик төрләре арасында гына синонимлык күзәтелә.

| № | Бәйләүче чаралар һәм төзелмәнең атамасы | Синонимнарга үзгәртеп төзү мисаллары |
|---|---|---|
| 1. | 1) *шунда, шул чакта, кайчан – шул чакта* һ.б. Аналитик җөмлә.<br>2) *-ганда, -ган чакта* һ.б. Синтетик җөмлә. | *Без мәктәпкә бара идек, ш у л ч а к т а көчле яңгыр яуды.*<br><br>*Б е з м ә к т ә п к ә б а р г а н д а , көчле яңгыр яуды.* |

| | | |
|---|---|---|
| 2. | 1) *шуңа чаклы, кайчан – аңа кадәр* һ.б.<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *-ганчы, -ганга хәтле, -әр, -мәс, -әрәк* һ.б.<br>Синтетик җөмлә. | *Без мәктәпкә бардык, аңа чаклы көчле яңгыр явып үткән иде*<br><br>*Без мәктәпкә барганчы, көчле яңгыр явып үтте;*<br>*Без мәктәпкә барып җитәр-җитмәс, көчле яңгыр явып үтте.* |
| 3. | 1) *аннары, шуннан соң, кайчан – шуннан соң* һ.б.<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *-гач, -ганнан соң, -у белән, -уга.*<br>Синтетик җөмлә. | *Без мәктәпкә барып кердек, шуннан соң көчле яңгыр яуды.*<br><br>*Без мәктәпкә баргач, көчле яңгыр яуды.* |
| 4. | 1) *ул да түгел, нәкъ шул чакта.*<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *-үгә, -ар – -мас.*<br>Синтетик җөмлә. | *Балалар тынычландылар, ул да түгел (нәкъ шул чакта) укытучы керде.*<br>*Балалар тынычланып җитәр-җитмәс (җитүгә) укытучы керде.* |

**§ 319. Иярчен урын җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү.** Иярчен урын җөмлә баш җөмләдән аңлашылган эш яки хәлнең урынын белдерә. Ул я турыдан-туры баш җөмләнең урын хәле функциясендә килә, яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән урын хәлен ачыклый, аның конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

Урын җөмләнең аналитик төрләре дә, синтетик төрләре дә бар.

Аналитик урын җөмлә баш җөмләгә парлы мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән: *Җил кайдан исә, болыт та шуннан килә* (мәкаль). *Кайда эләксәм, шунда сезнең нәсел кирәгемне бирде бирүен* (Һ. Такташ). *Нәфисә кайда булса, Зиннәт тә шунда булырга тырышты* (Г. Бәширов). *Сезнең эшегез, кай якка барсаң, шунда борыла* (Ә. Еники).

Мисаллардан күренгәнчә, парлы мөнәсәбәтле сүзнең баш җөмләдәгесе дә иярчен җөмләдәгесе дә урын хәле функциясендә генә килә.

Сирәк кенә очракларда урын җөмлә ялгызак мөнәсәбәтле сүз ярдәмендә төзелә ала. Мәсәлән: *Уйсу җиргә су җыела, шунда казлар коена* (җыр).

Синтетик иярчен урын җөмлә баш җөмләгә *урында, җирдә, якта, яктан* кебек бәйлек сүзләр ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән: *Без тизрәк ямь-яшел кырлар җәелгән урынга китик. Болыт та җил искән яктан килә. Ат аунаган җирдә төк кала* (мәкаль).

Бик күп еллар буе татар телендә иярчен урын җөмләләрнең синтетик төрләре юк дигән фикер хөкем сөрде, шуның аркасында ул төр җөмлә грамматика китапларыннан да чыгарып ташланган иде. Моның сәбәбе шунда: *урында, якта, җирдә, яктан* кебек сүзләр белән килгән синтетик урын җөмләләр синтетик аергыч җөмләләргә бик якын торалар, һәм алар шуңа күрә синтетик аергыч җөмләләр рәтеннән каралдылар. Мәсәлән: *Болыт җил искән яктан килә* дигән мисалдан *җил искән* өлешен генә алсак, ул – *яктан* сүзенә аергыч булып килә. Ә *яктан* сүзен ике җөмләне үзара бәйләүче чара дип карасак, *җил искән яктан* җөмләсе иярчен урын җөмлә була. Бу төр синтетик җөмләләрне аналитик төргә әйләндергәндә дә, аналитик урын җөмләле кушма җөмлә барлыкка килә. Мәсәлән: *Болыт та җил искән яктан килә – Җил кайдан иссә, болыт та шуннан килә;* Шуңа күрә *җирдә, якта* яки *урында* сүзләре белән килгән синтетик җөмләләрне урын җөмлә дип тану грамматик яктан да, стилистик яктан да дөресрәк була. Шуның белән бергә андый очракларда монысы урын, монысы аергыч җөмлә дип кисеп куярга ярамый. Чөнки шул ук *җирдә* сүзе конкрет җир, туфрак мәгънәсен бирерлек булса, аның белән килгән синтетик төзелмәне аергыч җөмлә дип тә, урын җөмлә дип тә карарга мөмкин була. Мәсәлән: *Ашлама тиешенчә кертелгән җирдә икмәк мул уңыш бирә* дигән мисалдагы синтетик төзелмәне урын җөмлә дип тә, аергыч җөмлә дип тә танып була, чөнки мондагы *җирдә* сүзен бәйләгеч дип тә, конкрет мәгънәсендә килгән сүз дип тә карарга мөмкин. Ул төзелмәне аналитик төргә дә я урын, я аергыч җөмләле кушма җөмлә итеп үзгәртергә мөмкин була. Мәсәлән: *Кайда ашлама тиешенчә кертелә, шунда икмәк мул уңыш бирә* (иярчен урын җөмләле кушма җөмлә). *Җирдә* сүзен конкрет туфрак мәгънәсендә аңлап, шуңа басым ясарга кирәк булса, түбәндәге төзелмә

барлыкка килә: *К а й с ы җ и р г ә (кайда) ашлама тиешенчә кертелә, ш у л җ и р д ә икмәк мул уңыш бирә* (иярчен аергыч җөмләле кушма җөмлә).

Монда тагын бер нәрсәне истә тотарга кирәк: әгәр дә *җирдә*, *якта* яки *урында* сүзләре урынында конкрет мәгънәле сүз килеп, синтетик җөмләне аналитик төргә әйләндергәндә, аергыч җөмлә барлыкка килсә, андый синтетик җөмләне аергыч җөмлә дип танырга кирәк була. Мәсәлән: *Яшьләрне тәрбияләүгә җитәрлек игътибар бирелмәгән гаиләдә өлкәннәрне хөрмәтләү түбән дәрәҗәдә була – К а й д а (кайсы гаиләдә) яшьләрне тәрбияләүгә җитәрлек игътибар бирелми, ш у л г а и л ә д ә өлкәннәрне хөрмәтләү түбән дәрәҗәдә була.*

Урын җөмләләрнең аналитик һәм синтетик парлары була, алар шулай ук ярым хәбәрлекле кисәкләргә дә синоним була алалар.

| № | Бәйләүче чаралар һәм төзелмәнең атамасы | Синонимнарга үзгәртеп төзү мисаллары |
|---|---|---|
| 1. | 1) *кайда – шунда.*<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *җирдә, урында.*<br>Синтетик җөмлә. | *К а й д а ат ауйный, ш у н д а төк кала.*<br>*А т а у н а г а н җ и р д ә төк кала.* |
| 2. | 1) *шунда.*<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *җирдә.*<br>Синтетик җөмлә. | *Уйсу җиргә су җыела, ш у н д а казлар коена.*<br>*Су җыелган җирдә казлар коена.* |
| 3. | 1) *кайдан – шуннан.*<br>Аналитик җөмлә. | *Җил к а й д а н исә, болыт та ш у н н а н килә.* |
| | 2) *яктан, урыннан, җирдән.*<br>Синтетик җөмлә. | *Болыт та җ и л и с к ә н я к т а н килә.* |

**§ 320. Иярчен рәвеш җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү.** Иярчен рәвеш җөмлә баш җөмләдә бирелгән процессның үтәлү рәвешен белдерә. Ул я турыдан-туры баш җөмләнең рәвеш хәле урынында килә, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән рәвеш хәлен ачыклый, аның конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

Иярчен рәвеш җөмлә баш җөмләдә бирелгән эшнең үтәлү рәвешен күп очракта башка бер эшнең үтәлү рәвешенә чагыштырып белдерә, шунлыктан чагыштырма җөмләләрне аерым алып өйрәнүнең кирәге калмый, алар рәвеш җөмләгә кереп бетәләр.

Иярчен рәвеш җөмләнең аналитик төрләре дә, синтетик төрләре дә еш очрый.

Аналитик рәвеш җөмлә баш җөмләгә түбәндәге чаралар ярдәмендә бәйләнә.

1. Ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр *(шундый итеп, шулай, алай, шул рәвешчә, шул формада)* ярдәмендә. Мәсәлән: *Ул ш у н д ы й и т е п ясасын: атлап керергә кыймый торырлык булсын* (халык иҗаты). *Баланы ш у л р ә в е ш ч ә сынарга кирәк: ул аны үзе сизмәсен. Сугышчы гранатаны ш у н д ы й и т е п ыргытты: ул нәкъ немец орудиесе янында гына ярылды* (Г. Әпсәләмов). *Яшь бала бит, нәрсә белсен, биш тиенгә ат ала, н ә к ъ ш у л а й безнең Шәһит тәҗвит язып шөһрәт ала* (Г. Тукай).

2. Парлы мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә. Иярчен җөмләдә сорау алмашлыкларыннан торган мөнәсәбәтле сүз күбрәк рәвеш хәле функциясен үти, баш җөмләдә күрсәтү алмашлыгыннан торган мөнәсәбәтле сүз мәҗбүри рәвештә рәвеш хәле урынында гына килә. Мәсәлән: *Кигән кием н и ч е к туза, яшь гомер ш у л а й уза* (җыр). *Н и ч е к таләп ителгән булса, ш у л а й эшләделәр* (Г. Ибраһимов). *Уйнавың н и ч е к , мин ш у л а й биим* (З. Нури). *Заманы н и ч е к булса, бүрегеңне ш у л а й ки* (мәкаль).

3. *Гүя* теркәгече, *әйтерсең, диярсең* кебек теркәгеч сүзләр ярдәмендә. Мәсәлән: *Менә бервакыт халык агыла башлады, ә й т е р с е ң инде бөтен дөнья монда җыелды* (Г. Ибраһимов). *Паровоз авыр гына уфылдый, г ү я җан иясе хәл җыя* (А. Шамов). *Тирә-юнь кар белән капланган, ә й т е р с е ң л ә җир ак юрган ябынган* (Г. Әпсәләмов). *Болын бүген тыныч, хуш исле, ислемай сипкәннәр д и я р с е ң* (Г. Әпсәләмов). *Таш булып таш башын сузды судан, Ташның да бар г ү я йөрәге* (М. Җәлил).

4. -*мыни*/-*мени* сорау кушымчалары да рәвеш җөмләләрне төзүдә катнаша. Мәсәлән: *Болын бүген хуш исле, ислемай с и п к ә н н ә р м е н и ! Сиңа гына хокук б и р е л г ә н м е н и , бертуктамый сөйләп торасың.* Бу төр иярчен җөмләнең хәбәре составында

рәвешне белдерә торган кушымча килсә дә, ул иярчен җөмләнең бөтенлеген җуймый. Шуңа күрә бу төр иярчен җөмләләр дә аналитик төргә якын торалар.

5. *дип* бәйлек сүзе ярдәмендә. Мәсәлән: *Халык белми эшләмәс дип, мин дә үсәргә тотындым* (Ф. Әмирхан).

Синтетик рәвеш җөмлә баш җөмләгә түбәндәге чаралар ярдәмендә бәйләнә:

1. *Хәлдә, килеш, көенчә, шикелле, төсле, кебек* бәйлекләре һәм *итеп* бәйлек сүзе ярдәмендә. Мәсәлән: *Шатлыктан йөрәгем типкән килеш, мин сөенче алырга йөгердем. Сәгать суккан тавыш уйларга уңайсызламаган кебек, Аязгуловның өзлексез сөйләп торуы да миңа Артыкбикә турында уйларга уңайсызламады* (М. Әмир). *Ә үзләре, чебен балга сарышкан кебек, һаман Якубка сарылалар* (И. Гази). *Герләр бар нәрсәнең авырлыгын белер өчен хезмәт иткән шикелле, акчалар да барнәрсәнең кыйммәтен белер өчен хезмәт итәләр* (Г. Тукай). *Хатыңны мин таныррлык итеп язарга тырыш.* 2. Рәвеш ясаучы -*ча*/-*чә*, -*дай*/-*дәй* кушымчалары ярдәмендә. Мәсәлән: *Каядыр еракта, башы йолдызларга тигән зур таш таулар бер-берсе өстенә җимерелеп ватылгандай, каты тавышлар белән күк күкри башлады* (Г. Ибраһимов).

3. Хәл фигыль кушымчалары ярдәмендә. Мәсәлән: *Тегермән канатлары җил тимичә әйләнмәделәр. Бик каты күк күкрәп, яңгыр яуды.*

Аналитик иярчен рәвеш җөмләне синтетик төргә әйләндергәндә, кушма җөмлә дә, гади җөмлә дә барлыкка килә. Мәсәлән: *Абыйлары ничек күрсәткән булса, укучы шулай язып куйды – Укучы абыйлары күрсәткәнчә язып куйды* (кушма җөмлә); *Мин аны шулай итеп утыртырмын: бер ике елдан эре-эре алмалар бирә башлар. – Мин аны бер ике елдан эре-эре алмалар бирерлек итеп утыртырмын* (гади җөмлә).

Иярчен рәвеш җөмләле кушма җөмлә синонимнарга шактый бай, аны таблицада күзәтик.

| № | Бәйләүче чаралар һәм төзелмәнең атамасы | Синонимнарга үзгәртеп төзү мисаллары |
|---|---|---|
| 1. | 1) *шундый итеп, шулай, алай, шул рәвешчә* һ.б.<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *-лек итеп.*<br>Синтетик җөмлә. | *Баланы шул рәвешле сынарга кирәк: ул аны үзе сизмәсен.*<br><br>*Баланы үзе сизмәслек итеп сынарга кирәк.* |
| 2. | 1) *ничек – шулай.*<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *әйтерсең, гүя, -мени.*<br>Аналитик җөмлә.<br>3) *-ган кебек.*<br>Синтетик җөмлә. | *Кигән кием ничек туза, яшь гомер шулай уза* (Җыр).<br>*Яшь гомер тиз уза, әйтерсең (гүя) кигән кием туза.*<br>*Яшь гомер кигән кием тузган кебек уза.* |
| 3. | 1) *ничек – шулай.*<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *-канчә, -дай (итеп).*<br>Синтетик җөмлә. | *Әти ничек кушты, без шулай эшләдек.*<br>*Без әти кушканча эшләдек;*<br>*Без әти кушкандай итеп эшләдек.* |
| 4. | 1) *шулай.*<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *-ырлык (итеп).*<br>Синтетик җөмлә. | *Хатыңны шулай яз: мин танырлык булсын.*<br>*Хатыңны мин танырлык итеп яз.* |

**§ 321. Иярчен күләм җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү.** Иярчен күләм җөмлә баш җөмләдәге процессның яки билгенең күләмчамасын, дәрәҗәсен белдерә. Ул я турыдан-туры баш җөмләнең күләм хәле функциясендә килә, яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән күләм хәлен ачыклый, аның конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

Иярчен күләм җөмләнең аналитик төрләре дә, синтетик төрләре дә була.

Аналитик күләм җөмлә баш җөмләгә түбәндәге чаралар ярдәмендә бәйләнә:

1. Ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр (*шундый, шул дәрәҗәдә, шулхәтле, шулай, алай*) ярдәмендә. Мисаллар: *Күзгә төртсәң дә күренми, шулай караңгы* (Г. Ибраһимов). *Бүген кояш шулкадәр эретә: күпер башындагы җыелган судан үтәрлек түгел* (К. Тинчурин).

*Бу ызгышлар ш у л х ә т л е туйдырдылар: әллә кая баш алып китәргә риза булыр идем* (К. Тинчурин).

2. Парлы мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә. Парлы мөнәсәбәтле сүзнең иярчен җөмләдәгесе дә, баш җөмләдәгесе дә күләм хәле функциясендә килә: *Н и х ә т л е күп укыса, матурлыгы ш у л д ә р ә җ ә д ә арта гына барыр* (К. Тинчурин). *Н и х ә т л е тиз булса, ш у л х ә т л е яхшы* (Ш. Камал). *Н и к а д ә р ялкынлырак булса, ш у л к а д ә р тиз янып та бетә* (мәкаль). *К ү п м е металл ватыклары тапшырыла, мактау сүзләре ш у л д ә р ә җ ә д ә көчлерәк була* («Ватаным Татарстан»).

3. Мөнәсәбәтле сүзләр белән бергә *ки* теркәгече дә кулланылырга мөмкин. Мәсәлән: *Бу вакытта Ләйлә ш у л к а д ә р матур иде к и , аңа бөтен кешенең исе китә иде* (И. Гази). *Киң басулары ш у н д ы й бәрәкәтлеләр к и, кара туфраклары ярты дөньяны туйдырырлык нигъмәтләр бирәләр* (Г. Ибраһимов). *Ш у н д ы й якын үтте к и , үләндәге салкын чык тамчылары аның өстенә сибелеп калды* (И. Гази). *Ш у н д ы й күңелле, моңлы чыгардылар к и , күтәренке көйгә җырланган бу җырлар йөрәкләрне ашкындырдылар* (Г. Ибраһимов).

Синтетик күләм җөмлә баш җөмләгә *кадәр, хәтле, саен* бәйлекләре яки *дәрәҗәдә* бәйлек сүзе, *-ганчы/-гәнче*, *-ырлык/-ерлык* кушымчалары аша бәйләнә. Мәсәлән: *Зәңгәр чишмәнең бакчаларында чәчәкләр а д ә м к ү з е к а р а п т у я а л м а с д ә р ә җ ә д ә чибәр булып җитешәләр* (Г. Ибраһимов). *Һәммәбез к и л г ә н б у ш к а к и т м ә д е д и я р л е к к а д ә р л е балыклар тоттык* (Г. Ибраһимов). *Вера Карбышеваны сайлаучылары у л б е л г ә н к а д ә р беләләр микән?* (Ә. Еники). *Әти кайтканчы, бездә торып тор* (Б. Рәхмәт). *Без башкарып чыгарлык эшне генә йөклиләр.*

Күләм җөмләле кушма җөмләнең синонимнарын таблицадан күзәтик.

| № | Бәйләүче чаралар һәм төзелмәнең атамасы | Синонимнарга үзгәртеп төзү мисаллары |
|---|---|---|
| 1. | 1) *шундый, шул дәрәҗәдә, шулхәтле, шулай, алай.* Аналитик җөмлә.<br>2) *-мәслек дәрәҗәдә.* Синтетик җөмлә. | *Күзгә төртсәң дә күренми, ш у л а й караңгы*; *Ш у н д ы й нык борчылган, карарга куркыныч.*<br>*Күзгә төртсәң дә күренмәслек дәрәҗәдә караңгы* |

| | | |
|---|---|---|
| 2. | 1) *нихәтле – шул дәрәҗәдә, никадәр – шулкадәр, күпме – шул дәрәҗәдә.*<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *-ган саен, -ган дәрәҗәдә.*<br>Синтетик җөмлә. | *Нихәтле күп укыса, матурлыгы шул дәрәҗәдә арта барыр.*<br><br><br>*Матурлыгы укыган саен арта барыр.* |
| 3. | 1) *шулкадәр.*<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *-рлык дәрәҗәдә, -маслык дәрәҗәдә.*<br>Синтетик җөмлә. | *Һәммәбез шулкадәр балык тоттык: килгән бушка китмәде.*<br>*Һәммәбез килгән бушка китмәде диярлек дәрәҗәдә балык тоттык* |
| 4. | 1) *шундый.*<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *-мәслек дәрәҗәдә.*<br>Ярым хәбәрлекле кисәк. | *Самолёт шундый биек оча: гади күзгә бөтенләй күренми.*<br>*Самолёт гади күзгә күренмәслек дәрәҗәдә биек оча.* |

**§ 322. Иярчен сәбәп җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү.** Иярчен сәбәп җөмлә баш җөмләдән аңлашылган эш яки хәлнең сәбәбен белдерә. Ул я турыдан-туры баш җөмләнең сәбәп хәле функциясендә килә, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән сәбәп хәлен ачыклый, аның конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

Иярчен сәбәп җөмлә сәбәпне белдерсә, баш җөмлә, кагыйдә буларак, шул сәбәпнең нәтиҗәсен күрсәтә. Мәсәлән: *Монда эш кайный, шуңа күрә күңелле* (М. Гафури) дигән җөмләдә беренче җөмлә – иярчен сәбәп җөмлә, икенчесе – баш җөмлә, ул сәбәп җөмләдән аңлашылган эшнең нәтиҗәсен белдерә. Шулай итеп сәбәп белән нәтиҗә икесе бергә киләләр, һәм шуңа күрә иярчен нәтиҗә җөмләне аерым алып үтүнең кирәге калмый.

Иярчен сәбәп җөмләнең аналитик төрләре дә, синтетик төрләре дә бар.

Аналитик сәбәп җөмлә баш җөмләгә түбәндәге чаралар ярдәмендә бәйләнә.

1. Ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр (*шуңа, шунлыктан, шуңа күрә, шуның аркасында, шул сәбәпле*) ярдәмендә. Мәсәлән: *Ул елны көз бик коры килде, шуңа күрә кыр эшләре дә тиз бетте* (Г. Галиев).

*Хәйбулла аның чын ихластан сөйләгәнен сизенә, шунлыктан аның сүзләре һәм үзе Хәйбуллага бик якын тоелды* (Ш. Камал).

2. *Чөнки* теркәгече ярдәмендә. Мәсәлән: *Фәхри атасыннан бер казык та алмый чыкты, чөнки юк иде* (Г. Ибраһимов).

3. Нәтиҗәне белдерә торган *димәк* сүзе, гадәттә, синтаксик бөтеннәр эчендәге мөстәкыйль җөмләләр һәм җөмлә группалары арасында йөри. Шуның белән бергә ул сүз ике генә җөмлә арасындагы нәтиҗә-сәбәп бәйләнешен күрсәтү өчен дә кулланыла. Соңгы очракта аны иярчен сәбәп җөмләне баш җөмләгә бәйләүче чара дип тә карап була. Мәсәлән: *Бикмулла Ватан сугышының башыннан алып ахырына кадәр фронтта булган, димәк, ул яшь солдат янына чакырып алырга иң лаеклы кеше иде* (Ә. Еники). Мондый кушма җөмләләрдә соңгысы – нәтиҗәне, алдагысы сәбәпне белдерә. Шул ук вакытта соңгы җөмлә беренчесен бераз ачыклап та килә.

4. Көттерү паузасы ярдәмендә. Мәсәлән: *Артык сүз озайтырга вакыт юк иде: Фәтхи уракчылар янына барырга ашыга* (Ш. Камал). *Гаҗиз калды доктор: авыру кызга бер дару да файда бирмәде* (М. Җәлил).

Үзара көттерү паузасы белән бәйләнеп, сәбәп белдерә торган өлеше башта, баш җөмлә (ягъни нәтиҗә белдерә торган өлеше) соңыннан килсә, мондый кушма җөмләне иярчен нәтиҗә җөмләле кушма җөмлә дип тә атыйлар. Мәсәлән: *Быел яңгыр аз яуды: игендә өмет зур түгел* (Г. Ибраһимов). Бу төзелмәдә беренче җөмлә – сәбәпне, икенчесе нәтиҗәне белдерә. Димәк, әгәр беренчесен иярчен сәбәп җөмлә дип алсак, икенчесен – нәтиҗә белдерә торганын, баш җөмлә дип танырга туры килә; әгәр дә инде икенче җөмләне иярчен нәтиҗә җөмлә дип танысак, беренчесен – сәбәп белдерә торганын, баш җөмлә дип танырга тиеш булабыз. Бер үк кушма җөмләне ике урында өйрәнү булмасын өчен, иярчен нәтиҗә җөмләне аерым алып карамаска туры килә. Шулай итеп баш җөмләгә көттерү паузасы ярдәмендә бәйләнгән иярчен сәбәп җөмлә баш җөмләдән алда да, аннан соң да килергә мөмкин.

5. Башка чаралар белән *ки* теркәгече дә килергә мөмкин. Мәсәлән: *Мин сиңа хат язарга ашыгам ки, Газизә сеңелем миндә инде* (Г. Тукай).

Синтетик сәбәп җөмлә баш җөмләгә түбәндәге чаралар ярдәмендә бәйләнә:

1. *Күрә* бәйлеге яки *сәбәпле, аркасында* бәйлек сүзләре ярдәмендә. Мәсәлән: *Ир балалары бер ул гына булганга күрә, аңа*

*эш талымлап торырга туры килмәде* (И. Гази). *Сугыш башлану аркасында, Карлыгач укырга китә алмый калды* (Г. Бәширов).

2. Юнәлеш яки чыгыш килеше кушымчасы, яисә *-ып, -гач* хәл фигыль формалары ярдәмендә. Мәсәлән: *Бүген майның урталары булганга, кояш ерак, ләкин туры һәм матур карый* (Г. Ибраһимов). *Егет атага бер булганга, солдат куркынычы юк иде* (Г. Ибраһимов). *Минем бар курыккан нәрсәм пароходтан калу булганга, күтәргә разый булмадым* (Г. Тукай). *Минем атым юаш булганлыктан, бер малайга җигеп бирәбез* (Һ. Такташ). *Следователь мондый позиция тоткач, мин үзем генә аны боза алмыйм* (Г. Ибраһимов). *Сүзне аңламагач таякладылар* (Г. Ибраһимов). *Күлнең аргы башында булдыгыбыздан, авылга кайту өчен, бер чакрым озынлыгындагы күл буе белән барып, теге куркыныч камышны үтү лазем иде* (Г. Ибраһимов). *Бу көн төнлә генә кайттыгымнан, һәрнәрсә бик сагындырган* (Г. Ибраһимов).

*-гач* формасы, сәбәптән башка, вакытны да күрсәтә, ләкин юклыктагы фигыль янында килгәндә, ул һәрвакытта да сәбәпне белдерә.

Һәрбер аналитик сәбәп җөмләне синтетикка, һәм синтетикны аналитикның теләсә нинди төренә әйләндереп була. Бу – сәбәп җөмләләрнең үзара синонимнарга бик бай булуы турында сөйли. Шуларны таблицада күзәтик.

| № | Бәйләүче чаралар һәм төзелмәнең атамасы | Синонимнарга үзгәртеп төзү мисаллары |
|---|---|---|
| 1. | 1) *шуңа, шунлыктан, шуңа күрә, шуның аркасында, шул сәбәпле.*<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *чөнки.*<br>Аналитик җөмлә.<br>3) көттерү паузасы.<br>Аналитик җөмлә.<br>4) *-гач, -ганнан, -ганга, -ганга күрә, -у аркасында, -ганлыктан, -у сәбәпле.*<br>Синтетик җөмлә. | *Монда эш кайный, шуңа (шунлыктан, шуңа күрә, шул сәбәпле, шуның аркасында) күңелле.*<br>*Монда күңелле, чөнки эш кайный.*<br>*Монда күңелле: эш кайный.*<br><br>*Монда эш кайнаганга күрә (кайнаганга, кайнаганлыктан, кайнау аркасында, кайнагач, кайнаганнан, кайнау сәбәпле) күңелле* |

**§ 323. Иярчен максат җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү.** Иярчен максат җөмлә баш җөмләдәге эш-хәлнең максатын белдерә. Ул я турыдан-туры баш җөмләнең максат хәле функциясендә килә, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән максат хәлен ачыклый, аның конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

Иярчен максат җөмләнең синтетик төрләре дә, аналитик төрләре дә бар.

Аналитик максат җөмлә баш җөмләгә *шуның өчен, моның өчен* кебек ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр, *дип* бәйлек сүзе ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән: *Өй якты һәм җылы булырга тиеш, м о н ы ң  ө ч е н аны бөтен гигиена таләпләренә җавап бирерлек итеп төзиләр* (Д. Аппакова). *Икмәкләр мул уңыш бирсен, ш у н ы ң  ө ч е н вакытында кар тоту оештырылды* («Ватаным Татарстан»). *Матур көндә чыгам кырга, а ч ы л м а с м ы  к ү ң е л л ә р  д и п* (Г. Тукай). *Алмагачка яулык элдем, с а н д у г а ч л а р  к у н с ы н  д и п* (җыр). *Бер барганда, э ш л ә р е  б е т с е н  д и п, әнкәй уракларны кертеп бирде* (Г. Ибраһимов).

Синтетик максат җөмлә баш җөмләгә *өчен* бәйлеге ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән: *К ы з  у я н м а с ы н  ө ч е н, һәркем аяк очы белән генә басып йөри иде* (Г. Кутуй). Иярчен максат җөмләләрнең дә аналитик төрләре синтетик төрләр белән синоним була алалар. Шуннан файдаланып, аларның төрле очракта төрлесен кулланырга, ә редакцияләү процессында берсен икенчесенә үзгәртергә мөмкин.

| № | Бәйләүче чаралар һәм төзелмәнең атамасы | Синонимнарга үзгәртеп төзү мисаллары |
|---|---|---|
| 1. | 1) *шуның өчен, моның өчен.*<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *-сен дип.*<br>Аналитик җөмлә.<br>3) көттерү паузасы.<br>Аналитик җөмлә.<br>4) *-сен өчен, -сенгә.*<br>Синтетик җөмлә. | *Саф һава керсен, шуның өчен тәрәзәләрне ачам.*<br><br>*Саф һава керсен дип, тәрәзәләрне ачам.*<br>*Тәрәзәләрне ачам: саф һава керсен.*<br>*Саф һава керсен өчен (керсенгә), тәрәзәләрне ачам.* |

**§ 324. Иярчен шарт җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү.** Иярчен шарт җөмлә баш җөмләдәге эшнең үтәлү-үтәлмәвенә шарт бул-

ган процессны белдерә. Ул я турыдан-туры баш җөмләнең шарт хәле функциясен үти, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән шарт хәлен ачыклый, аның конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

Иярчен шарт җөмләнең аналитик төрләре дә, синтетик төрләре дә була.

Аналитик шарт җөмлә баш җөмләгә түбәндәге чаралар ярдәмендә бәйләнә.

1. Ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр (*шулай булса, шулай итсә, алайса, ул чагында* һ.б.) ярдәмендә. Мәсәлән: *Безгә осталар килеп өйне сипләячәкләр икән, шулай итсәләр кышны җылы өйдә үткәрер идек* (Г. Ибраһимов). *Шушы гомергә кадәр кузгалмагансыз, алайса (алай булгач, алай булса, алай итсәгез) барыгыз, кире кайтыгыз* (К. Тинчурин). *Газинур бәлки әйләнеп тә кайтмас, шулай булса Миңнурыйга бик авыр булачак* (Г. Әпсәләмов). *Күрсәтмисең, ул чагында бир миңа бер сарыгыңны* (халык иҗаты).

2. Сорау кушымчасы, *икән, исә* кисәкчәләре, яки *-сын (барсын)* формалары ярдәмендә. Мәсәлән: *Күкрәгемдә минем шигырь уты сауммы, күтәрәм мин, карт булсам да, авыр тауны* (Г. Тукай). *Шәкерт мәҗлесләре башландымы, Баязит анда беренче каһарман* (Г. Ибраһимов). *Буш вакыт булдымы, Иделгә балыкка китәләр* (Г. Ибраһимов). *Укыта алмыйсың икән, башыңнан колак кактың* (Н.Исәнбәт). *Инде чана юлы гына төшсен, барып дәррәү эшләп алырбыз дип торалар иде* (Г. Ибраһимов).

Мондый җөмләләр үзара шарт мөнәсәбәтендә булсалар да, бәйләүче чараларның чын бәйләүчеләргә кермәүләре аркасында, алар тезмә кушма җөмләләргә дә шактый якын торалар.

Синтетик шарт җөмлә баш җөмләгә *-са* яки *-ганда* формасы ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән: *Әгәр дә җирдә яктылык та, җылылык та булмаса, тормыш та булмас иде* (Г. Тукай). *Ныклабрак уйлап караганда, ул, чыннан да, гаепле түгел иде* (Г. Ибраһимов).

Мисалдан күренгәнчә, *-са* кушымчасы белән бергә *әгәр* теркәгече дә килә ала, ләкин ул җөмләне аналитик итә алмый, чөнки *әгәр* мәҗбүри чара түгел: ул килергә дә, килмәскә дә мөмкин. Ә *-са* формасы – төп чара, аны ташлап калдырып булмый.

Шарт җөмләле кушма җөмләләрнең төрле чаралар ярдәмендә ясалганнары үзара синоним булып торалар. Моны таблицадан күзәтик.

| № | Бәйләүче чаралар һәм төзелмәнең атамасы | Синонимнарга үзгәртеп төзү мисаллары |
|---|---|---|
| 1. | 1) *шулай булса, шулай итсә, алайса, ул чагында.*<br>Аналитик җөмлә.<br><br>2) *-мый икән, -дымы, -ды исә.*<br>Аналитик җөмлә.<br><br>3) *-са.*<br>Синтетик җөмлә. | *Газинур бәлки әйләнеп тә кайтмас, шулай булса Миңнурыйга бик авыр булачак* (Г. Әпсәләмов).<br>*Газинур әйләнеп кайтмадымы (-мый икән, кайтмады исә), Миңнурыйга бик авыр булачак.*<br>*Газинур әйләнеп кайтмаса, Миңнурыйга бик авыр булачак.* |
| 2. | 1) *юкса (+ -ма).*<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *-са.*<br>Ярым хәбәрлекле кисәк. | *Укымадым, юкса белер идем.*<br><br>*Укысам белер идем.* |

**§ 325. Иярчен кире җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү.** Иярчен кире җөмлә көтелгән эш яки хәлнең баш җөмләдә киресе булачагын белдерә. Ул я турыдан-туры баш җөмләнең кире хәле урынында килә, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән кире хәлне ачыклый, аның конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

Иярчен кире җөмләнең аналитик төрләре дә, синтетик төрләре дә бар.

Аналитик кире җөмлә баш җөмләгә ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр (*шулай булса да, шулай да, алай да, шуңа карамастан*) ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән: *Көннәр бик начар торды, шулай да язгы эшләр вакытында тәмамланды* (М. Галиев). *Машинаны йөртү бик кыен, шулай булса да син бу эшкә көннән-көн ияләнә барасың* (Г. Тукай). *Патрон белән снаряд юклык безгә зур гына кыенлык ясый, шуңа карамастан сугышчыларның күңелләре күтәренке* (Ш. Усманов).

Бу төр җөмләләр стилистик яктан каршы куючы теркәгечләр (*ләкин, әмма*) белән килгән кушма җөмләләргә бик якын торалар, ләкин грамматик яктан *ләкин, әмма* белән килгәннәре – тезмә кушма җөмләгә, ә мөнәсәбәтле сүз белән килгәннәре иярченле кушма җөм-

ләгә керәләр: *Монда көннәр бик тиз үтәләр, ш у л а й д а ( л ә к и н ) мин үз әсәремнең ике бүлеген язып тәмамладым инде* (М. Җәлил).

Синтетик кире җөмлә баш җөмләгә түбәндәге чаралар ярдәмендә бәйләнә:

1. Шарт фигыль кушымчасы, *да/дә* кисәкчәсе белән бергә килеп, кире җөмләне бәйли. Боларга өстәлеп *гәрчә* теркәгече дә килгәли. Мәсәлән: *Д у л к ы н н и ч а к л ы к а т ы б у л с а д а , ул сезнең биек тау итәгендәге урыныгызга килеп җитә алмаячак* (Г. Ибраһимов). *Ч а к ы р с а м д а , кошчык, син бу йортка үзең теләп очып килмәссең* (М. Җәлил). *А л а р д а т ө р л е к и е м, т ө р л е к ы я ф ә т б у л с а д а , болар көязлектә һәммәсе уртак иде* (Г. Ибраһимов). *Я ш е җ и т м е ш к ә җ и т с ә д ә , әле гәүдә таза, йөреше ныклы* (Г. Ибраһимов). *С ы й л а р с ы е б ы з б у л м а с а д а , сыйпамага телебез бар* (мәкаль). *Тышта кунып булмый бит, б у л с а д а г ә р ч ә й ө з а к* (М. Җәлил).

2. *-ып/-п+та/тә, -кач/-гач+та, -кәч/-гәч+тә, -у белән, -сын/-сен* формалары ярдәмендә. Мәсәлән: *Б ө т е н д ө н ь я м и ң а к а р ш ы б у л ы п т а , син минем яктан булсаң, без җиңәрбез дим* (Г. Ибраһимов). *С и н ү з е ң к а р а г а ч т а , мин берни дә күрмәгән бит* (К. Тинчурин). *С и н у к у б е л ә н , – мин укымаган бит. Уянмый ул, б ө т е н к е ш е т а в ы ш л а н с ы н* (Г. Тукай).

3. *Карамастан* бәйлек сүзе ярдәмендә. Мәсәлән: *Я з җ и т к ә н б у л у г а к а р а м а с т а н , иртәнге суыкта аяк асты коп-коры* (И. Гази). *К а т ы я ң г ы р я в у г а к а р а м а с т а н , тузан басылмаган иде.*

Иярчен кире җөмләләрнең дә үзара синонимлыгыннан бик оста файдаланырга мөмкин: алар бер төрдән икенче төргә бик җиңел үзгәртелә алалар. Шуларны таблицада күзәтик.

| № | Бәйләүче чаралар һәм төзелмәнең атамасы | Синонимнарга үзгәртеп төзү мисаллары |
|---|---|---|
| 1. | 1) *шулай да, алай да, шулай булса да, шуңа карамастан.*<br>Аналитик җөмлә.<br>2) *-са да, -уга карамастан.*<br>Синтетик җөмлә. | *Каты яңгыр яуды, ш у ң а к а р а м а с т а н ( ш у л а й д а , а л а й д а , ш у л а й б у л с а д а ) тузан басылмады.*<br>*К а т ы я ң г ы р я в у г а к а р а м а с т а н (яуса да), тузан басылмады.* |

| | | |
|---|---|---|
| 2. | 1) *-сын/-масын/-ма/ -мыйм/-магыз/-мыйк.* Аналитик җөмлә.<br>2) *шулай да* һ.б. Аналитик җөмлә. | *Уянмый ул, бөтен кеше тавышлансын* (Г. Тукай).<br>*Бөтен кеше тавышлансын, шулай да уянмый ул.* |
| | 3) *-са да, -ып та, -гач та, -гачтын да, -у га карамастан.* Синтетик җөмлә. | *Бөтен кеше тавышланса да (тавышлангач та, -ып та, -гачтын да) уянмый ул* |
| 3. | 1) *шулай да.* Аналитик җөмлә.<br>2) *-сә дә.* Ярым хәбәрлекле кисәк. | *Беләм, шулай да әйтмим.*<br>*Белсәм дә әйтмим.* |

Иярчен кире җөмләле кушма җөмлә *ләкин* яки *әмма* теркәгече белән килә торган тезмә кушма җөмләгә якын тора: *Көн инде төшкә авышкан, шулай да (ләкин) печән җыючылар кузгалмаган иде әле.*

**§ 326. Иярчен аныклагыч җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү.** Иярчен аныклагыч җөмлә баш җөмләдән аңлашылган берәр төшенчәне, фикерне өстәмә аныклап килә. Ул баш җөмләдәге аныкланмышка карата һәрчак аналитик була, ягъни алар үзара аналитик чаралар ярдәмендә бәйләнәләр. Ләкин аныклагыч җөмлә аныкланмышка гына түгел, аныкланмышны иярткән сүзгә дә буйсына, аңа буйсындыручы чара аныклагыч җөмләнең хәбәре составында килгәндә, аныклагыч җөмлә синтетик төргә дә тартымлык күрсәтә. Мәсәлән: *Сәгать уникеләрдә, кешеләр йокларга ятып беткәч, ул тагын эшкә утырды. Иртән, әниләр эшкә китү белән, мин сезгә керермен.* Аныклагыч җөмлә гомумән җөмләне яисә аның хәбәрен аныкласа, ахырдан килә, җөмләдәге башка кисәкләрне аныкласа, турыдан-туры шул кисәктән соң җөмлә уртасында әйтелә.

Иярчен аныклагыч җөмлә баш җөмләгә аныклагыч кебек үк, иң күп очракта *ягъни* теркәгече ярдәмендә иярә. Ул чара үзе килмәсә, аныклагыч җөмлә алдына аны куеп карау мөмкинлеге булырга тиеш. Мәсәлән: *Каникуллар башлангач, укулар тәмамлангач, безнең отряд авылыбызның тарихи урыннарын өйрәнәчәк.* Бу мисалдагы *укулар тәмамлангач* җөмләсе алдында *ягъни* теркәгечен куеп карап

була, димәк, ул алдагы җөмләгә карата аныклагыч буларак килгән, шуңа күрә аныклагыч җөмлә була.

Аныклагычлардагы кебек үк, аныклагыч җөмлә алдыннан, *ягъни* теркәгеченнән тыш, *башкача әйткәндә, икенче төрле әйткәндә, бигрәк тә, аеруча, һәрхәлдә* кебек аныклаучы теркәгеч сүзләр дә килә алалар. Мәсәлән: *Мостафин бу урыннан очып төште, б а ш к а ч а  ә й т к ә н д ә , аны яңадан сайламадылар* (Ә. Еники). *Картина безгә бик ошады, а е р у ч а  укучылар яратып карадылар. Хәлим баржада тоз бушатучы егеттән күп нәрсәләргә өйрәнде, һ ә р х ә л д ә  ул акларның кем икәнлекләренә төшенде* (И. Гази).

Иярчен аныклагыч җөмләнең *ягъни, башкача, икенче төрле (әйткәндә)* сүзләре ярдәмендә баш җөмләгә ияргәннәренең теркәгечсез аналитик парлары гына була. Баш җөмләгә *бигрәк тә, аеруча, һәрхәлдә* сүзләре белән бәйләнгәннәренең синонимнары күзәтелми.

| № | Бәйләүче чаралар һәм төзелмәнең атамасы | Синонимнарга үзгәртеп төзү мисаллары |
|---|---|---|
| 1. | 1) *ягъни, башкача, икенче төрле (әйткәндә).* Теркәгечле аналитик җөмлә.<br>2) көттерү паузасы. Теркәгечсез аналитик җөмлә. | *Мостафин бу урыннан очып төште, я г ъ н и  ( и к е н ч е  т ө р л е  ә й т к ә н д ә )  аны яңадан сайламадылар* (Ә. Еники).<br>*Мостафин бу урыннан очып төште: аны яңадан сайламадылар.* |

**§ 327. Иярчен кереш җөмләләр.** Бу төр җөмләләрнең синонимнарын күрсәтү кыен, алар өстәмә өйрәнүне таләп итәләр. Шуңа күрә болар стилистик яктан үзгәрүгә бирелмиләр дип әйтергә нигез бар.

Без җөмлә кисәкләрен санаганда, аларга баш кисәкләр, иярчен кисәкләр һәм модаль кисәкләрне керткән идек. Баш һәм иярчен кисәкләргә туры килә торган иярчен җөмләләрне без инде өйрәндек. Болардан тыш җөмлә эчендә модаль кисәкләргә якын булган җөмләләр дә еш очрыйлар. Дөрес, модаль кисәкләрдән эндәш сүз җөмлә белән бирелә алмый, ә кереш сүз урынында җөмләләр килә ала. Кереш җөмлә гомумән җөмләнең я аның кайсы да булса бер кисәгенең эчтәлегенә сөйләүченең мөнәсәбәтен белдерә. Мәсәлән: *Аның миңа сузган кулына (й о м ш а к  һ ә м  б и к  җ ы л ы  и д е  у л  к у л ) тотынып аякка бастым* (Ф. Хөсни). *Юк, д ө р е с е н  ә й т и м , серең турында*

*минем берни дә ишеткәнем юк* (Г. Әпсәләмов). Беренче мисалда кереш җөмлә тәмамлыкка, икенчесендә гомумән җөмләгә караган. Сөйләүче кереш җөмлә белән я җөмләнең, я аның кисәгенең эчтәлеген кайсы яктандыр өстәмә рәвештә аныкларга, комментарий бирергә кирәк дип таба һәм төп җөмләнең табигый агылышын, интонациясен өзеп, өстәмә мәгълүмат бирергә ашыга. Шуңа күрә кереш җөмләләр беркадәр тизләтелгән темп белән түбәнрәк тонда әйтеләләр.

Кереш җөмләләрне бары модаль мәгънә белдерү өчен генә килә дип әйтү дөрес булмас иде. Бер үк вакытта алар я җөмләнең, я аның кисәгенең эчтәлеген аныклап, төгәлләп тә киләләр, ләкин бу гадәти төгәлләүле мөнәсәбәт тә, аныклаулы мөнәсәбәт тә булмый. Кереш җөмлә фикернең гомуми агылышына кермәгән бер билгене өстәп әйтеп кую өчен килә, шул яктан ул сөйләүченең сөйләмгә карашын белдерә.

Бу юлларны язучы автор үзенең 1958 елда чыккан кулланмасында кереш җөмләләрне аерым алып тикшергән иде, ләкин 1966 елдагы кулланмада ул аларны аныклагыч җөмләләрнең бер төре буларак карады. Ләкин соңгы тикшеренүләр шуны күрсәтте: аныклагыч җөмләләр һәм кереш җөмләләр бер-берсеннән төп билгеләре белән – бәйләнеш төрләре белән аерылалар: аныклагыч җөмлә аныклагычларга хас булган бәйләүче чаралар ярдәмендә ияргә, кереш җөмләләр исә, кереш сүзләр кебек үк, төп җөмләгә керешү интонациясе белән генә бәйләнәләр, ягъни төп җөмләнең гомуми интонацион системасы эчендә калып, үзләре тизләтелгән темп белән, түбәнрәк тонда әйтеләләр.

Менә шуларны исәпкә алып, синтаксис буенча кулланманың 1974 елгы басмасында без кереш җөмләләрне аерым алу дөресрәк булыр дип таптык. Аларны модаль җөмләләр дип атарга мөмкин булыр иде, ләкин модаль кисәкләргә кереш сүз белән бергә эндәш сүз дә керә, ә эндәш сүзгә туры килә торган җөмләләр булмый. Алар бары кереш сүзгә генә билгеле дәрәҗәдә туры киләләр, шуңа күрә аларның атамасын да кереш җөмлә дип калдыру дөресрәк була. Бу – бер. Икенче яктан, кереш җөмләләр үзләренең әйтелешләре буенча, башка бер җөмләнең интонацион агышын бүлдереп, аңа килеп кергән (керешкән) җөмләләр булып аңлашылалар. Бу яктан да кереш дигән термин бу төр берәмлекләрнең характерына туры килә.

Кереш җөмләләр татар телендә җентекләп өйрәнелмәгәннәр әле, шуңа күрә аларның мәгънә һәм төзелеш ягыннан төрләре билгелән-

мәгән. Шулай да моңа кадәр тикшерелгәннәрдән чыгып, кереш җөмләләрне, шартлы рәвештә, ике төргә аерырга мөмкин. Беренче төргә – төп җөмләгә гомумән карый торган кереш җөмләләр, икенчесенә – җөмләдәге берәр кисәкнең эчтәлегенә караган кереш җөмләләр керә.

Җөмләнең гомуми эчтәлегенә караган кереш җөмләләргә мисаллар: *Аларны бит, гафу итегез, һавадан ясап булмый* (М. Максуд). *Һәм – була бит тормышта шундый могҗизалар – аксап-туксап, Воропаев килеп керде* (М. Максуд). *Минем гомерем – укучылар күрерләр – шактый ямьсез, шактый караңгы, шуның белән бергә кызык кына үткән булганга, яза башлагач, исемдә калганнарның һәммәсен язасым килде* (Г. Тукай). *Агроном әйтмешли, быел уңыш бик бай булачак.* Соңгы мисалдагы кереш җөмлә, төп җөмлә башында торса, гомумән җөмләгә карый, җөмлә уртасында торса, үзеннән соң килгән кисәккә каратыла. Мәсәлән: *Быелгы яз, картлар әйтмешли, бик иртә уянды* (Ш. Камал).

Җөмләнең аерым кисәкләренә караган кереш җөмләләргә мисаллар: *Бар да тынып калдылар, ә Кәримә йомшак, ягымлы тавыш белән гадәттәгечә каушабрак (шунлыктан, ахрысы, аның сүзен бүлмичә тыңларга өйрәнгәннәр иде) сөйләргә керешәте* (Ә. Еники). *Хәлил агай, йотылып-йотылып – җаны әрнеп булыр – шуларны хикәя кылды* (Ш. Камал). *Тегесе эшнең мондый борылыш алырга торуыннан бик үк риза булмыйча (кайсыбызның хатыны алай түгел!) мәгънәле генә бер карап куйды* (Ф. Хөсни). *Егетнең яраларын бәйләделәр, пиджагының ян кесәсеннән бераз акча, документлар (исеме Павел Мечик иде) һәм бер төргәк хатлар чыкты* (А. Шамов). *Повар исә, – үз музыкасы белән дан казанырга һич тә җыенмаган иде булса кирәк, – гармонен кесәсенә тыкты да, балаларга карап ишарәләр ясады* (М. Максуд). *Солдатлар (алар өчәү иде) Пьерга әһәмият бирмичә ашыйлар иде* (А. Шамов). *Ярсыган Шалдыба (Морозка аны бурсык тиресеннән тегелгән очлы бүрегеннән һәм кара атыннан таныды) кулындагы камчысы белән як-ягына селтәнә, ләкин кешеләрне туктата алмый* (А. Шамов). *Бер минуттан соң, бәлки, бер сәгатьтән соңдыр – вакыт йөрәкне әрнетеп үтә иде – Мечик партизаннарның артканын сизде* (А. Шамов).

## ТЕЗМӘ КУШМА ҖӨМЛӘЛӘР

**§ 328. Гомуми мәгълүмат.** Аерым җөмләләре үзара тезү юлы белән бәйләнгән кушма җөмлә тезмә кушма җөмлә дип атала. Иярченле кушма җөмләләрдән аермалы буларак, тезмә кушма җөмлә төзүче җөмләләр бер-берсенә буйсынмыйлар, үзара тигез хокукта булалар, чагыштырмача мөстәкыйльлек саклыйлар. Ләкин аларның мөстәкыйльлек дәрәҗәсе аерым гади җөмлә мөстәкыйльлегенә җитмәскә тиеш, алай булса тезмә кушма җөмлә аерым мөстәкыйль гади җөмләләргә таркалыр иде.

Янәшә тора торган теләсә нинди җөмләләр, бергә кушылып, тезмә кушма җөмлә төзи алмыйлар. Тезмә кушма җөмләдәге җөмләләр арасында тезүле бәйләнеш булырга, ягъни алар үзара төрле мәгънә мөнәсәбәтендә торырга һәм бу мөнәсәбәтләр грамматик чаралар (санау һәм каршылык интонацияләре яки тезүче теркәгечләр һәм теркәгеч сүзләр) белән белдерелгән булырга тиеш.

Сүзләр арасындагы тезүле бәйләнеш кебек үк, җөмләләрдәге тезүле бәйләнеш тә турыдан-туры ияртүле бәйләнеш булуына бәйләнгән. Мәсәлән, түбәндәге җөмләләр арасында тезүле бәйләнеш бер үк сүзнең һәрбер җөмләгә буйсынуы (ияртелүе) нәтиҗәсендә барлыкка килгән:




Тезмә кушма җөмлә гадәттә, билгеле, бер вакытны, урынны, нинди дә булса бер уртак объектны тасвирлаганда яки нәрсәнең булса да сәбәбен, шартын санаганда, яисә күренешләрне үзара каршы куйганда ясала, һәм уртак кисәк җөмләдә бирелергә дә, бирелмәскә дә мөмкин.

Тел белемендә тезмә кушма җөмләләр иярченле кушма җөмләләргә караганда иртәрәк формалашкан дигән караш бар. Бу карашны

түбәндәге дәлилләр белән исбатлыйлар. Беренчедән, сөйләмә әдәби телдә һәм гомумән сөйләү телендә тезмә кушма җөмләләр күбрәк очрыйлар. Хәтта мәгънә ягыннан бер-берсенә ияреpгә тиеш булган җөмләләр дә сөйләү телендә тезмә формада әйтеләләр. Мәсәлән, авыз иҗатыннан: *Агыйделдән көймә килә, көймә килә, эзе юк, хаты килә, сүзе килә, сөйләшергә үзе юк* (җыр).

Монда алты гади җөмлә бар. Аларның кайберләрен үзара иярченле кушма җөмлә итеп формалаштырырга мөмкин булса да, анда бары тезүле юл белән генә бәйләнеш бар. Икенчедән, тезмә кушма җөмләләрнең элегрәк барлыкка килүен тагын шуның белән раслыйлар: тезмә кушма җөмләдәге аерым җөмләләр, бернинди сүз формасы алмыйча, бер-берсенә бәйләнәләр, ә иярченле кушма җөмләдә аерым җөмләләр, күбрәк, сүз формасы аша бәйләнәләр. Тел белемендә, билгеле булганча, сүз формалары тел үсешендә соңрак баскычны тәшкил итәләр. Димәк, бары сүз формасы ясалгач кына, яисә сүз формалары (кушымчалар) ясалу процессында гына иярченле кушма җөмләләр барлыкка килгәннәр. Аларга кадәр җөмләләр сөйләмдә бер-берсенә тезмә юл белән генә бәйләнгәннәр.

**§ 329. Аерым җөмләләре үзара җыючы теркәгечләр аша бәйләнгән тезмә кушма җөмләләр.**

1. *Һәм* теркәгече җөмләләр арасында түбәндәге мәгънә мөнәсәбәтләре урнаштыра: а) җөмләләр эзлекле күренешләрне белдерәләр: *Болытлар таралдылар, һәм көн матурланды. Гафиятнең иске ачуы кабынып китте, һәм ул, йөрәген тыя алмыйча, бөтенесен берьюлы әйтте дә салды* (И. Гази); ә) җөмләләр параллель күренешләрне белдерәләр: *Каты җил исә, һәм яңгыр үзенең тамчыларын, ачу белән, тәрәзәгә китереп бәрә* (Ә. Фәйзи); б) соңгы җөмлә алдагы җөмләне мәгънә ягыннан тутырып яки аның нәтиҗәсен белдереп килә: *Кешенең иң кадерле нәрсәсе тормыш, һәм ул аңа бары бер генә мәртәбә бирелә* (Н. Островский). *Кайдадыр, еракта, кемдер курай уйный, һәм аның моңнары бөтен Агыйдел буйларына тарала* (М. Әмир).

2. *Вә* теркәгече егерменче елларга кадәр язылган әдәби әсәрләрдә очрый, шуннан соң язылган әдәби телдә ул кулланылмый. Мисаллар: *Рәхимовларның залында кыйммәтле рояль тора, вә ул рояльдә Хәят берничә төрле көйләрне матур гына итеп уйный да белә иде* (Ф. Әмирхан).

3. *Да/дә*, *та/тә* теркәгече җөмләләр арасындагы түбәндәге мәгънә мөнәсәбәтләрен урнаштыра: а) җөмләләр эзлекле күренешләрне белдерәләр: *Болытлар таралдылар да, ялтырап кояш чыкты. Теге Шакир Рамазановлар ягы җиңеп китте дә, Фәхрине егып салдылар* (Г. Ибраһимов); ә) җөмләләр бер үк вакытта булган күренешләрне белдерәләр: *Күп сөйләшкән бәндә кешене дә бутый, үзе дә бутала ул* (Р. Вәлиев); б) соңгы җөмлә беренче җөмләне мәгънә ягыннан тутырып, яки аның нәтиҗәсен белдереп килә: *Шулчак өстәл өстенә җәйгән ашъяулыкны кулы белән ялгыш тартып җибәрде дә чокыр идәнгә төшеп чәлпәрәмә килде* (М. Хуҗин). *Менә, ниһаять, кояшлы яңгыр явып үтте дә ул гөлнең барлык чәчәкләре берьюлы ачылып киттеләр* (Ф. Яруллин). *Быел игеннәребез уңар да көзге байлык мул булыр* (М. Хуҗин); в) җөмләләрнең эчтәлеге бер-берсенә охшатыла, чагыштырыла: *Гомрем минем моңлы бер җыр иде, үлемем дә яңгырар җыр булып* (М. Җәлил); г) күренешләр капма-каршы куела: *Минем дә бер чәчкәм бар да, Җаным күбәләк түгел* (Х. Туфан).

4. *Ни-ни* теркәгече күренешләрнең инкярын тезеп күрсәтә: *Ни җыелыш булмады, ни кино күрсәтмәделәр.*

**Искәрмә:** *Шулай ук, шуның өстенә* мөнәсәбәтле сүзләре параллель күренешләрне яки үзара чагыштырылган күренешләрне белдерә торган җөмләләрне теркиләр: *Күзгә төртсәң күренмәслек караңгы, аның өстенә яңгыр ява. Сорауларга урын юк, шиккә урын юк, шулай ук хәзергә әле вәгъдәләргә дә урын юк* (Ф. Хөсни).

**§ 330. Аерым җөмләләре үзара бүлүче теркәгечләр аша бәйләнгән тезмә кушма җөмләләр.**

1. *Янә, яисә, я* теркәгечләре, башлыча, булырга мөмкин булган процессларның, күренешләрнең берәвенең генә үтәлүен белдерә. Ләкин ике яки күп күренешләр арасында кайсысы үтәлә, сөйләүче аны аермачык белми: *Йортны, туган җирне я тартып алалар, яисә кеше аны үзе ташлап китә* (М. Юныс).

2. *Әле – әле* теркәгече күренешләрнең алмашынып, чиратлашып торуларын белдерә: *Әле яңгыр ява, әле кар ява.*

3. *Әллә – әллә* теркәгече сөйләүче шикләнә торган күренешләрне тезеп күрсәтә. *Әллә хат тәэсир итте, әллә Габделхак шулай тиз аңлады: ике атна эчендә ул Маһруйны үз янына алдырды* (Г. Гобәй).

**Искәрмә:** Сорау кисәкчәләре ярдәмендә теркәлгән җөмләләр дә үзара бүлгәләү мөнәсәбәтендә булалар: *Кеше күңелен калдырудан курыктымы,*

*вакытында акыл кердеме – никадәр сорасалар да, җавап бирергә ашыкмады; Почтаның кайтыр вакыты җиттеме, кунаклар килә башладылармы – басу капкасы ягыннан арба тавышлары ишетелә башлады.*

**§ 331. Аерым җөмләләре үзара каршылык теркәгечләре аша бәйләнгән тезмә кушма җөмләләр.**

1. *Ә* теркәгече белән бәйләнгән җөмләләр бер-берсенә каршы куелган яки бер-берсе белән чагыштырылган күренешләрне белдерәләр. Мәсәлән: *Яз аена кердек, ә көннәр һаман салкын. Айга күптән инде мең яшь тулган, ә ай аны үзе оныткан* (Һ. Такташ). *Ялган бик тиз килде, Ә дөреслек озак көттерде* (Г. Рәхим); *Сынау еллары артта калды, ә сыналу һаман дәвам итә* (М. Юныс).

2. *Ләкин* теркәгече җөмләләр арасында түбәндәге мәгънә мөнәсәбәтләре урнаштыра: а) икенче җөмлә беренче җөмләдән көтелгәннең киресен белдерә. Мәсәлән: *Син адаштың, ләкин син яхшы идең* (Һ. Такташ). *Җилбер-җилбер җил уйнасын, куакларга кагылсын, ләкин алар баса алмый яшь егетнең кайгысын* (М. Җәлил). *Егет ярлы, ләкин үткенлеге зур* (Г. Ибраһимов). *Аның тиз генә Тимери белән тышка чыгасы һәм үз чыбыркысын аныкы белән узыштырып, шартлатып карыйсы килде, ләкин Җаббарның кутәренке әңгәмәсе аны тотып торды* (Ә. Фәйзи); ә) икенче җөмлә беренче җөмләдәге уйны икенче юнәлешкә борып җибәрә, аңа өстәмә ачыклык кертә: *Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә, ләкин һәрбер йөрәк аны яңарта* (Һ. Такташ). *Явым-төшемсез көннәрдә кояш әле матур гына җылыта, ләкин андый җылы көннәр инде бик сирәк була. Хәер, әле дә булса, күңеле әрнеп-әрнеп китә, ләкин инде бу – үлеп бара торган мәхәббәтнең соңгы талпынуы* (И. Гази).

3. *Әмма* теркәгеченең мәгънәсе *ләкин* теркәгеченекенә бик якын: *Ул Зиннәтнең кайтуына үзенең куанамы яки борчыламы икәнен дә белми, әмма йөрәге ашыгып-ашыгып тибә* (Г. Бәширов).

4. *Мәгәр, илләмәгәр* теркәгече 20 нче елларга кадәр язылган әдәбиятта *ләкин* мәгънәсендә очрый: *Байбичәнең җаны әрнүле иде, мәгәр, кабаттан сүз кузгатып, авыруны борчыйсы килмәде* (Г. Ибраһимов). *Ил агасы Байтүрә морза үлем түшәгенә ятты, мәгәр кабилә, партия талашлары эчендә кайнаган карт йөрәге үткен, мие сәламәт иде әле* (Г. Ибраһимов). *Кызларның да, киленнәрнең дә Гайниләр, Гыйльминур җиңгиләр кебек ана арысланнарын җыярмын, илләмәгәр эшләүгә беләкләрегез генә түзсен* (И. Гази).

5. *Тик, бары, фәкать* теркәгечләре чикләүне белдерәләр, ягъни соңгы җөмлә беренче җөмләне мәгънә ягыннан чикләп килә: *Хатын-кызлар авылларына таралдылар, бары чүлмәкләрдәге сөтне кая куярга белмәгән шадра хатын гына нәрсәдер көтә* (К. Нәҗми). *Синең яхшы иде күңелең, тик белмәдең тормыш баткагыннан ялгыз чыгу мөмкин түгелен* (Һ. Такташ). *Анда башка һичбер нәрсә калмады, тик томан да караңгылык!* (Г. Ибраһимов). *Ерак түгел моңаеп утыра ромашка кызы, тик чуклары ак түгел, кан шикелле кып-кызыл* (М. Җәлил). *...Әнкәсе күздән югала, тик колак төбендә тавышы гына ишетелеп тора башлый* (И. Гази). *Шималдан булган бик каты салкын җил без кеби чәнчеп-чәнчеп ала, фәкать ярлылык барчасына сабыр итә* (М. Гафури).

6. *Исә* сүзе дә җөмләләрне каршы куя: *Без Рөстәм белән бардык, Гали исә берүзе башка вагонда барган.*

7. *Аның каравы, аның урынына* сүзләре дә каршылык теркәгечләре урынында йөриләр. Мәсәлән: *Тагын кемнәрнеңдер яңаклары күгәрде, тез башлары суелды, бүрекләре очып төште, ләкин аның каравы барысының да битләре кып-кызыл, күзләре шат иде* (И. Гази). *Ул җирдә, билгеле, икмәк үсми, но аның урынына баткакта тимер мәгъдәне бар, һәм бу кавем тимерчелек эшен эшли башлады* (Г. Тукай).

**Искәрмә:** Үзара шарт фигыль формасы белән бәйләнгән җөмләләр бер-берсенә каршы куелган күренешләрне белдерә алалар. Мәсәлән: *Камчы тәнне генә авырттырса, агулы сүз бәгырьгә тия* (М. Юныс).

**§ 332. Аерым җөмләләре үзара санау интонациясе аша бәйләнгән кушма җөмләләр.** Бу төр кушма җөмләдә, кагыйдә буларак, бертөрле формадагы җөмләләр бәйләнә. Санау интонациясенең мәгънәсе *һәм* мәгънәсе белән, нигездә, туры килә.

Мондый җөмләләр бер үк вакытта булган һәм бер үк вакытта булмаган күренешләрне, вакыйгаларны белдерәләр.

1. Бер үк вакытта параллель булган вакыйгаларны белдерә торган кушма җөмләләр билгеле бер урынны, вакытны, обстановканы тасвирлау өчен яки нинди дә булса бер әйбернең, затның нинди дә булса бер үзенчәлеген санап күрсәтү өчен кулланылалар.

Билгеле бер вакытны тасвирлау өчен, шул вакытта булган вакыйгаларны тезеп күрсәтә. Мәсәлән: *Арыш артыннан ук арпа җитеште, бодай, солы саргая башлады...* (Н. Фәттах). *Берничә көн эчендә юллар*

*такырланды, төзелеш мәйданында тузан болытлары уйный башлады* (Р. Вәлиев).

Билгеле бер урынны, обстановканы тасвирлау өчен, шунда булган күренешләрне тезеп күрсәтә. Мәсәлән: *Кәримәнең фатирында таңга кадәр тәрәзәләрдә балкып ут янды, таңга кадәр гармун, радиола тавышлары ишетелеп торды* (М. Әмир). *Бер чыпчык, авызына йон кабып, оясына алып менеп бара; өй кыегында күгәрченнәр гөрләшәләр; нигез туфрагында тавыклар коена; яшел чирәм өстендә кызыл бозау сузылып ята* (И. Гази).

Объектны яки затны тасвирлау өчен, шуның бер ягын тезеп күрсәтә. Мәсәлән: *Балам ди-ди, бичараның йөзе саргайды, үзе кипте* (Г. Ибраһимов). *Малайның кәефе килгән, авыз ерык иде* (Ф. Хөсни).

Менә шул урын, обстановка, вакыт яки тасвирлана торган объектның бер булуы аерым җөмләләрне бер кушма җөмләгә оештыруның нигезен тәшкил итә.

2. Төрле вакытта булган күренешләрне белдерә торган кушма җөмләләр ике төргә бүленәләр. Бер төрлеләрендә төрле вакытта булган күренешләр санала, аларның үтәлү эзлеклелеге исәпкә алынмый. Мәсәлән: *Көне-төне кар ява, җил ыжгыра*... (Г. Ибраһимов). Икенче төрдәгеләрендә төрле вакытта булган күренешләр булу эзлеклелегендә санап күрсәтелә. Мәсәлән: *Рәйсәнең күзләре зур булып ачылдылар, кулындагы сирень яфраклары җиргә төште* (Г. Әпсәләмов). *Ул шулай дип уйлап өлгерә алмады, аяклары кире чигенделәр* (Г. Ибраһимов). *Кар сулары китеп бетте, җир кипте, киң кыр өстен куе яшел уҗым каплап алды* (И. Гази). *Сәгатьтән артык барган яңгыр туктады, тагын ялтырап кояш чыкты* (Г. Ибраһимов).

Күп кенә тезмә кушма җөмләләр соңгысы алдагысының нәтиҗәсе булып килгән вакыйгаларны да белдерәләр, шуңа күрә алар инде нәтиҗә-сәбәп мөнәсәбәтен белдерүче иярченле кушма җөмләләргә якынаялар, дөресрәге, алар тезмә һәм иярченле кушма җөмләләр арасында торалар. Мәсәлән: *Бу муллага яхшы тәэсир итте, аның йөзе тагын ачылды*... (Г. Ибраһимов).

**§ 333. Аерым җөмләләре үзара каршылык интонациясе аша бәйләнгән кушма җөмләләр.** Мондый җөмләләр каршы куюны һәм кара-каршы куеп чагыштыруны белдерәләр. Каршылык интонациясен беренче очракта *ләкин* белән, икенче очракта *ә* белән алмаштырып була.

1. Бер-берсенә бик нык каршы куелган күренешләрне белдерәләр. Мәсәлән: *Ул йозак төсле миңа – юк ачкычым; я бөек сәт – юк менәргә баскычым* (Г. Тукай). *Анда сугылды, монда сугылды – файда булмады* (Г. Ибраһимов). *Күрше вагон ишеген тартты – ачылмады* (Р. Вәлиев).

2. Бер-берсенә җиңелчә генә каршы куелган күренешләрне белдерәләр. Мондый очракта раслау инкярга каршы куела. Мәсәлән: *Гел генә очып йөреп тә булмый, дымлы һәм гөнаһлы җиргә дә төшәргә туры килә* (Ә. Еники).

3. Кара-каршы куеп чагыштыруны белдерәләр. Бу төр җөмләләр мәкаль һәм әйтемнәрдә бик күп кулланылалар. Мәсәлән: *Белемле үлмәс, белемсез көн күрмәс. Ай күрде, кояш алды. Үпкә – дошман, гакыл – дус. Атлы атын мактар, юләр хатынын мактар.*

## АНАЛИТИК ТА, ТЕЗМӘ ДӘ БУЛГАН КУШМА ҖӨМЛӘЛӘР

**§ 334. Гомуми мәгълүмат.** Без кушма җөмләләрне тезмә һәм иярченле кушма җөмләләргә, ә иярченлеләрен синтетик һәм аналитик кушма җөмләләргә бүлеп өйрәндек. Синтетик кушма җөмләләр белән гади җөмләләр арасында төгәл генә аерма буллмаганын күрдек. Синтетик кушма җөмлә белән гади җөмлә арасында торучы синтаксик төзелмәләр (конструкцияләр) булуын өйрәндек. Синтетик һәм аналитик кушма җөмләләр арасында тора торган төзелмәләр булуына да һәр очракта игътибар итеп бардык. Ә менә тезмә кушма җөмлә белән аналитик кушма җөмлә арасында торучы төзелмәләрне аерым параграф ачып өйрәнергә туры килә, чөнки алар татар сөйләм төзелешендә шактый урын алып торалар.

Кайбер төр кушма җөмләләр аерым җөмләләре арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләре буенча тезмә кушма җөмләгә дә, аналитик кушма җөмләгә дә тартымлык күрсәтәләр. Мәсәлән: *Минем күзләрем бик җете түгел – күрәм* дигән төзелмәдә ике җөмлә арасында каршылык мөнәсәбәте дә, кирелек мөнәсәбәте дә бар. *Минем күзләрем бик җете түгел, шулай да күрәм* дип әйтелсә, җөмләләр арасындагы кирелек мөнәсәбәтен *шулай да* мөнәсәбәтле сүзе белдерә. *Шулай да* сүзе, күрсәтү алмашлыгы белән бирелгән мөнәсәбәтле сүз буларак, баш җөмлә составында килә, ул анда – кире хәл, димәк, *шулай да* мөнәсәбәтле сүзенең төгәл мәгънәсен бирүче беренче җөмлә – иярчен кире ана-

литик җөмлә була. Шулай итеп без бу җөмләне, бер дә шикләнмичә, аналитик җөмлә дип танырга тиеш булабыз.

Шушы ук җөмлә, шул ук мәгънәдә тезмә кушма җөмлә төзи торган *ләкин* теркәгече ярдәмендә дә төзелә ала: *Минем күзләрем бик җете түгел, л ә к и н күрәм.* Аерым җөмләләре тезүче чара ярдәмендә бәйләнгәнлектән, бу җөмләне, бер дә шикләнмичә, тезмә кушма җөмләгә каратабыз.

Шушы ук җөмләдә *ләкин* теркәгече дә, *шулай да* мөнәсәбәтле сүзе дә килергә мөмкин: *Минем күзләрем бик җете түгел, л ә к и н ш у л а й д а күрәм.* Бу синтаксик төзелмәне турыдан-туры тезмә кушма җөмләгә дә, аналитик иярченле кушма җөмләгә дә каратып булмый, бу төзелмә аналитик иярчен дә, тезмә дә булган кушма җөмлә дип танылырга тиеш була. Аларны тезмә һәм аналитик кушма җөмлә арасында торучы төзелмәләр дип тә атыйлар.

Татар сөйләмендә тезмә кушма җөмлә ясауда катнаша торган җыючы теркәгечләр һәм каршылык теркәгечләре бер үк җөмләдә ияртүче аналитик чаралар белән бергә дә кулланыла алалар һәм алар белән бергәләп аналитик та, тезмә дә булган кушма җөмлә төзиләр.

1. Җыючы теркәгечләр төрле ияртүче чара белән бергә кулланылып ясалган кушма җөмләләрдәге аерым җөмләләр арасында төрле мөнәсәбәтләр урнаша.

1) Сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәте: *Бу күл Сөн җирендә иң зур күлләрдән санала иде, һ ә м ш у н ы ң ө ч е н дә ул Диңгез-күл дип атала иде дә* (Н. Фәттах).

2) Вакыт яки урын мөнәсәбәте: *Шулай бик соңга калып кына капкадан килеп керде, һ ә м н ә к ъ ш у л в а к ы т т а төнлеккә бәйдән ычкындырып куелган Актырнак күтәрелеп чыкты* (Г. Ибраһимов). *Монда кар бик иртә ята, һ ә м ш у н д а ел саен чаңгы ярышлары үткәрелә.*

3) Рәвеш, күләм-чама мөнәсәбәтләре: *Атларга өйрәнә башлаган яшь бала н и ч е к йөри, таякларга баскан малайлар да ш у л р ә в е ш л е бер-ике атлыйлар да таяктан сикереп төшәргә мәҗбүр булалар* (А. Шамов).

4) Атрибутлык мөнәсәбәте: *Сүз арасында Хәйдәров исеме телгә алынды, һ ә м м о н ы ң бер сәбәбе бар иде* (Ф. Хөсни).

5) Объектлык мөнәсәбәте: *Алар кичә берничә кеше белән көне буе Казанда булдылар, һ ә м ул ш у н ы үзенең бу эштә катнашмавына*

*сәбәп итеп күрсәтте* (М. Хәсәнов). Биредә мөнәсәбәтле сүз белән бергә *-са* кушымчасы килә алуын да искә төшерик: *Хәлим нәрсә табып к а й т с а , өйдәгеләр ш у ң а риза булып тордылар.* Ләкин биредә *-са* – стилистик чара гына.

6) Хәбәрлекле мөнәсәбәт: *Бергә җырлыйбыз, бергә чәй эчәбез, сугыш башлангач, бер-беребезгә атабыз, һ ә м менә иң гаҗәбе дә ш у л* (К. Тинчурин).

2. Каршылык теркәгечләре төрле ияртүче чара белән бергә кулланылып ясалган кушма җөмләләрдәге аерым җөмләләр арасында шулай ук берничә төр мөнәсәбәт урнаша.

1) Кире-каршылык мөнәсәбәте: *Алар бары да үзе кебек гади кешеләр, л ә к и н ш у л а й д а алардан кемнең дә булса газета битенә калкып чыгуы да ихтимал бит* (Ә. Еники). *Бик мавыктыргыч иде бу хыял, ә м м а ш у л а й д а Мостафинны нидер тота, күңеле ул эшкә бик тартмый* (Ә. Еники).

2) Каршылык-сәбәп мөнәсәбәте: *Сине миңа ярдәмгә җибәрделәр, ә мин ш у л с ә б ә п л е кеше көченнән файдаланучы булып күрендем.*

3) Каршылык-чикләү мөнәсәбәте төрле ияртү мөнәсәбәтләре белән кушыла: *К е м намус белән хезмәт итә, б а р ы ш у л зур хөрмәткә ия була. Ат ш у л д ә р ә җ ә д ә атлыгып тора, т и к дилбегәне генә тотып өлгер* (Г. Ибраһимов).

Бер үк вакытта аналитик та, тезмә дә булган кушма җөмләләр татар синтасисында махсус өйрәнүне көтәләр.

## КАТЛАУЛЫ КУШМА ҖӨМЛӘЛӘР

**§ 335. Гомуми мәгълүмат.** Икедән артык җөмләдән торган кушма җөмлә катлаулы кушма җөмлә дип атала. Алдагы бүлекләрдә җөмләләрнең үзара форма һәм мәгънә ягыннан бәйләнеше тикшерелде. Шуңа күрә мисал итеп, күбесенчә, ике җөмләдән торган кушма җөмләләр китерелделәр. Хәтта икедән артык җөмләдән торган кушма җөмләләрне алганда да, анда бары ике җөмләнең генә үзара форма һәм мәгънә бәйләнеше каралды. Шулай итеп ике генә җөмләдән торган кушма җөмләләрнең, ягъни гади кушма җөмләләрнең төзелеше югарыда тикшерелде. Катлаулы кушма җөмләләрнең исә тулаем төзелеше әле өйрәнелмичә калды.

Катлаулы кушма җөмлә үзенең төзелеше буенча өч төргә бүленә: күп тезмәле кушма җөмлә, күп иярченле кушма җөмлә, катнаш кушма җөмлә.

Күп тезмәле һәм катнаш кушма җөмләләрне яңадан эре төркемнәргә аермыйлар, ә иярченле кушма җөмлә тагын дүрт төргә бүленә: 1) тигез (тиңдәш түгел) иярүле, 2) тиңдәш иярүле, 3) бер-бер артлы иярүле, 4) берничә төр иярүле күп иярченле кушма җөмләләр.

Бу төрләрне схемада күзәтик.




## КҮП ТЕЗМӘЛЕ КУШМА ҖӨМЛӘЛӘР

**§ 336. Бу төр кушма җөмләләрнең төп үзенчәлекләре.** Икедән артык җөмлә үзара бары тезү юлы белән генә бәйләнгән булса, андый җөмләләр күп тезмәле кушма җөмлә төзиләр. Күп тезмәле кушма җөмләләр төзелешләре буенча тикшереләләр.

1. Күп тезмәле кушма җөмләләр арасында тезүле бәйләнешнең бер генә төре: я җыю, я бүлү, я каршылык чаралары гына килә.

1) Җыючы чаралар гына килә: *Җир ыңгырашты, атлар авыр сулый башладылар, сугышчылар өрәңгеләренә бастылар* (М. Максуд).

Күп тезмәле кушма җөмләдәге беренче җөмләләр санау интонациясе белән бәйләнеп, соңгысы *һәм* теркәгече ярдәмендә бәйләнсә, *һәм* теркәгече санап баруның тәмамлануын белдерә. *Хәбибуллин*

*җавапсыз кала, күзләре аның зур булып ачылалар, һәм йөзе сизелерлек дәрәҗәдә агарып китә* (Ә. Еники).

2) Каршылык чаралары гына килә: *Төшендә Хәлимне әнисе чакыра, ә Хәлим аннан кача, ләкин аны тотып китерәләр* (И. Гази). Гадәттә, бер үк каршылык теркәгече кабатланып килми, шуңа күрә биредә *ә, ләкин* теркәгечләре кулланылганнар. Моңа тагын бер мисал: *Син адаштың, л ә к и н син яхшы идең, синең яхшы иде күңелең, т и к белмәдең тормыш баткагыннан ялгыз чыгу мөмкин түгелен* (Һ. Такташ).

3) Бүлгәләү чаралары гына килә: *Әле яңгыр ява, әле кар төшә, әле каты җил исә башлый* (Ф. Хөсни). *Я Садрый абзый сөйләр, я Миргасыйм әйтер, я мин үзем серне ачармын.*

2. Бер үк күп тезмәле кушма җөмләдә берничә төрле тезүле бәйләнеш була, мәсәлән, я җыю һәм каршылык бәйләнеше, я җыю һәм бүлгәләү бәйләнеше, я каршылык һәм җыю бәйләнеше, яисә өч бәйләнеш тә берьюлы була. Мисаллар: *Яңгыр явып үтә дә, ялтырап кояш чыга, ләкин салкын җил һаман туктамый* (И. Гази); *Разведчик ул хуторны картадан табарга маташып карады, ләкин аны табуы бик ансат булып чыкмады, һәм ул, үзенең бернәрсә дә белмәвен күрсәтмәс өчен, бармагы белән күрше өязнең бер җиренә төртте* (А. Шамов).

Бер-берсенә каршы җыючы чара (интонация) аша бәйләнгән җөмләләр, парлап-парлап, бүлгәләү мәгънәсендә тоташкан булырга һәм шул юл белән күп тезмәле кушма җөмлә оештырырга мөмкин: *Урман шаулый – ул колакка керә, самолёт узып китә – аның гөрелтәве дә күңелнең әллә кай төшен кытыклап уза, берәү бик матур итеп җырлый – ул да эзен калдыра* (Г. Бәширов).

Күп тезмәле кушма җөмләдәге җөмләләрнең беренчеләре җыючы чаралар белән бәйләнеп, соңгысы *ә* теркәгече яки *ләкин* теркәгече белән бәйләнгәндә, бу теркәгечләр дә каршы куюның тәмамлануына ишарә итәләр: *Аның әле чәчләре дә кибеп өлгермәгән, ике бите уттай яна, күз төпләре сөремләнеп уелган, ә тыгыз сылу гәүдәсеннән дымлы хуш ис аңкып тора* (Ә. Еники). *Тагын кемнәрнеңдер яңаклары күгәрде, тез башлары суелды, бүрекләре очып төште, ләкин барысының да битләре кып-кызыл, күзләре шат иде* (И. Гази).

Җыючы чаралар ярдәмендә бәйләнгән җөмләләр парлап-парлап үзара каршы куелырга мөмкин: *Бабай бик күп яшь яшәгән, карт ул үзе, ләкин һаман сәламәт ул, матур йөзе* (Г. Тукай).

Күп тезмәле кушма җөмләнең башка төр төзелешләре дә булырга мөмкин.

## КҮП ИЯРЧЕНЛЕ КУШМА ҖӨМЛӘ

**§ 337. Тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмлә.** Ике яки икедән артык иярчен җөмлә бер баш җөмләгә ияреп килә, һәм ул җөмләләр үзара тиңдәш булалар. Менә шундый җөмләләр тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмлә булалар. Мәсәлән:

*Ә никадәр гүзәл булыр иде –*
*Ак кар кунса шигырь юлларыма,*
*Бәс сарыса, яңгыр сибелсә,*
*Каплап алса таңгы алсу томан,*
*Йолдызлардан серләр түгелсә...* (Зөлфәт).

(1) *Бу хәл минем балалык дустым Биктимер башыннан узган бер хәл булганга,* (2) *бу тарихны кешегә сөйләргә Биктимер ризалык бирмәгәнгә күрә,* (3) *хәзергә чаклы мин моны берәүгә дә сөйләми йөрдем* (Ф. Хөсни).

Биредә беренче җөмлә дә, икенчесе дә өченчегә иярәләр, һәм аларның икесе дә сәбәп җөмлә, димәк, алар тиңдәшләр. Аларның схемалары.

I.




II. (...-ганга), (...-мәгәнгә күрә), [ ].

(1) *Таң җилләре искәндә,*
(2) *Үләнгә чык төшкәндә,*
(3) *Чулпан кызым, таң йолдызым,*
*Чабып сиңа кайтыр идем,*
(4) *Гөлләр хуш ис сипкәндә* (М. Җәлил).

I.




II. (...-дә), (...-дә), [ ], (...-дә).

(1) *Буе талчыбыктай,* (2) *үзе уңган,* (3) *шуның белән ул матурлар арасында да үзен кимсетергә юл бирмәде* (Г. Ибраһимов).

I.




II. ( ), ( ), [шуның белән...].

(1) *Шулай да бик җәелеп киттеләр дип булмый,* (2) *чөнки тышта Айдарның аты тынычсызлана,* (3) *ә правление йортында иртәге көнгә наряд алырга дип килгән бригадирлар тирләп утыралар иде* (Ф. Хөсни).

I.




II. [ ], чөнки ( ), ә ( ).

(1) *Узган елгы чирәме инде саргайган,* (2) *быелгысы әле баш калкытып өлгермәгән,* (3) *шулай да ике басу арасындагы бу межа кара җирдә әллә кайдан ук тасмаланып яшәреп ята* (Ф. Хөсни).

I.




II. ( ), ( ), [шулай да...].

(1) *Атна-ун көн эчендә берничә еллык картайды,* (2) *үзе кипте дип* (3) *аптырашалар.* (Г. Ибраһимов).




(1) *Ләкин халыкта кичәге нәшат (шатлык), кичәге җан калмаган инде:* (2) *бүген тын,* (3) *басынкы,* (4) *авыр* (Г. Ибраһимов).

I.




II. [ ] : ( ), ( ), ( ).

(1) *Әллә сыерчыклар бик моңлы сайраганга,* (2) *әллә улының бөтен гомере күз алдыннан узганга, ул бүген аеруча дулкынланды* (Г. Бәширов).

I.




II. (...-га), (...-га), [ ].

Тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмләләрдә иярчен җөмләләр үзара тезүле юл белән бәйләнгән булалар. Ләкин моңа карап алар катнаш кушма җөмләгә кермиләр, чөнки катнаш кушма җөмләдә тезүле юл белән баш җөмләләр бәйләнгән булалар.

**§ 338. Тиңдәш түгел иярүле күп иярченле кушма җөмлә.** Аерым җөмләләре бары ияртү юлы белән генә бәйләнгән җөмләләрнең үзләрен дүрт төргә бүләргә мөмкин дип күрсәттек, 335 § та аның схемасы да бирелде. Дүрт төрнең беренчесе буларак иң башта тиңдәш түгел иярүле күп иярченле кушма җөмлә өйрәнелә.

Ике яки икедән артык иярчен җөмлә бер баш җөмләгә ияреп килә, һәм ул иярчен җөмләләр үзара тиңдәш булмыйлар: *Көндезләрен шундый вак-төяк мәшәкатьләр белән тарта-суза уздырса да, кич җитте исә, күңелне сагышлы моң сара башлый* (Р. Вәлиев). *Ләкин җаны тере һәркем, көне җиткәч, шул янгында дөрлиячәк!* (Зөлфәт).

Схема ясарга җиңел булсын өчен, мисалдагы җөмләләрне нумерлап күрсәтергә кирәк: (1) *Быел игеннәр бик уңган булса да,* (2) *көннәр коры булу сәбәпле,* (3) *ялан эше үз вакытында тәмам булды* (Г. Ибраһимов).

Мондый җөмләләрне телдән анализлагач, аның ике төрле схемасын ясап була. Беренче төр схемада җөмләләр нумер саннары белән күрсәтеләләр, һәм бу нумерлап анализлау дип йөртелә. Икенче төр схема җөмләләрнең урнашу тәртибе буенча ясала. Хәзер әле генә китерелгән җөмләне телдән анализлыйк һәм ике төрле схемасын бирик.

Беренче җөмлә – *Быел игеннәр бик уңган булса да* өченче булып килгән баш җөмләгә иярә, аңа карата синтетик кире җөмлә була. Икенче җөмлә – *Көннәр коры булу сәбәпле* өченче җөмләгә (баш җөмлә-

гә) карата синтетик сәбәп җөмлә була. Шулай итеп бу күп иярченле кушма җөмләдә беренче һәм икенче җөмләләр өченче җөмләгә ияреп киләләр һәм аларның беренчесе – кире җөмлә, икенчесе – сәбәп җөмлә, димәк, алар тиңдәш түгелләр. Менә ни өчен бу җөмлә тиңдәш түгел ияргүле күп иярченле кушма җөмлә дип атала.

Бу тиңдәш түгел иярүле күп иярченле кушма җөмләнең ике төр схемасы болай ясала.

I.




Мондый схеманы ясаганда, квадратлар эченә җөмләләрнең тәртип саннары языла, ук билгесе (→) баш җөмләдән иярчен җөмләгә карап куела, параллель сызыклар (=) җөмләләр арасында тиңдәшлекне белдерәләр, параллель сызыклар кыек сызык белән бозылса (≠), бу билге җөмләләрнең үзара тиңдәш түгеллеген белдерә.

Схема тулы аңлаешлы булсын өчен, квадратларны зуррак ясап, аның эченә җөмләнең тәртип санын гына түгел, аның функциональ төрен дә язалар. Мондый схема төгәлрәк була.

I.




II. (...-са да), (... сәбәпле), [ ].

Бу схемада җөмләләрнең урнашу тәртибе бозылмый, катлаулы кушма җөмлә эчендә, җөмләләр кайсы тәртиптә урнашканнар, схемада да шул ук тәртип саклана; баш җөмлә квадрат җәяләр эченә алына, ә иярчен җөмләләр түгәрәк җәяләргә алыналар, ук билгесе,

беренчесендәге кебек үк, баш җөмләдән иярчен җөмләгә каратыла; параллель сызыклар, авышкан сызык белән бозылган параллель сызыклар гомумән кулланылмыйлар; җөмләләр арасындагы бәйләүче чаралар һәм тыныш билгеләре үзләре язылалар. Теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр җәяләр тышына, башка чаралар җәяләр эчендә язылалар.

Тагын берничә җөмләнең схемасын языйк.

(1) *Көчәнеп, чын көч белән тарта торгач,* (2) *өзелде тезген:* (3) *хуҗа суга төште* (М. Гафури).

I.




II. (...-гач), [ ] : ( ).

(1) *Бөтен дөнья миңа каршы булып та,* (2) *син минем якта булсаң,* (3) *без җиңәрбез* (Г. Ибраһимов).

I.




II. (...-ып та), (...-саң), [ ].

(1) *Әгәр дә инде без, башка өйләргә тукталмыйча, нәкъ менә шушы Мөхәммәди агай өенә тукталганбыз икән,* (2) *моның сере шунда:* (3) *монда Мөнирә тора* (Ф. Хөсни).

I.



II. (Әгәр ...-быз икән), [... шунда] : ( ).

(1) *Кайда ярлы, кайда зарлы, кайда моңлылар була,* (2) *мин шулар янында булам:* (3) *алар белән килешеп була* (М. Гафури).

I.




II. (Кайда...), [... шулар янында...] : ( ).

**§ 339. Бер-бер артлы ияргүле күп иярченле кушма җөмлә.** Күп иярченле кушма җөмләдә иярчен җөмләләр турыдан-туры бер баш җөмләгә түгел, бәлки үзара берсе – икенчесенә (мәсәлән, икенчесе беренчесенә, өченчесе икенчесенә, дүртенчесе өченчесенә һ.б.) ияреп килсәләр, андый ияргүне дәрәҗәле яки бер-бер артлы ияргү диләр: *Гөлләр җылысыннан мантый дөнья, Йолдызлары салкын төн килсә...* (Зөлфәт). *Гасырлар үтеп, чорлар алышынса да, кешеләрнең үзәге бер кала икән* (М. Вәлиев). Шулай итеп, бу төр күп иярченле кушма җөмләдә баш җөмлә дә, иярчен җөмлә дә берничә була, шулай ук бер үк җөмлә берсенә карата баш булса, икенчесенә карата иярчен була.

(1) *Гомердә булмаган нәрсә:* (2) *быел җир бүлешү талаш-тартышсыз үтте,* (3) *чөнки җир шундый әйбәт:* (4) *каян гына бирсәләр дә* (5) *үпкәләрлек түгел* (Г. Ибраһимов).

Дәрәҗәле ияргүле күп иярченле кушма җөмлә схематик рәвештә болай күрсәтелә:

I.




II. [ ] : ( ), чөнки (...шундый...) : (...сә дә), [ ].

Беренче схеманы, тагын да төгәлрәк итеп, түбәндәгечә дә ясарга мөмкин.




Башка мисалларны анализлыйк.

(1) *Беренче кар төшәр алдыннан,* (2) *бер ир бала дөньяга килгәч,* (3) *икесенең дә башлары күккә тиде* (И. Гази).

I.




II. (...-әр алдыннан), (...-гәч), [      ].

(1) *Тик үзенең начар бер гадәте бар:* (2) *кайчан тәмле әйбер пешәр икән дип,* (3) *саклап кына йөри* (Г. Ибраһимов).

I.




II. [... бер...] : (... дип) (      ).

(1) *Кызык шул:* (2) *бергә утырып чәй эчәбез, тәмәке тартабыз,* (3) *приказ булгач,* (2) *шул ук кешеләр өстенә атабыз* (И. Гази).

I.




II. [... шул] : (      ) (...-гач).

(1) *Әтисе әйткән була тагын:* (2) *ашны икмәк белән ашасаң,* (3) *көчең арта* (И. Гази).

I.




II.




**§ 340. Берничә төр ияргүле күп иярченле кушма җөмлә.** Билгеле, күп иярченле кушма җөмләләр бу өч төргә генә сыеп бетә алмыйлар, аларның берничә төре бергә кулланылу очраклары да бар. Мәсәлән, (1) *Бу трагедия үткәнгә,* (2) *хәзер инде байтак еллар кичте,* (3) *шулай да эзе һаман тирән иде әле:* (4) *дошманнар,* (5) *һәр сүз чыккан саен,* (4) *мыскыл итеп телгә алалар* (Г. Ибраһимов) дигән мисалда бер-бер артлы ияргү дә, тиңдәш түгел ияргү дә бар.

Бу катлаулы төзелмәдә 3 нче җөмлә (*шулай да эзе һаман тирән иде әле*) – баш җөмлә, аңа бер яктан 2 нче җөмлә *шулай да* мөнәсәбәтле сүзе аша ияргән, ул кире җөмлә; шул ук 3 нче санны алган баш җөмләгә 4 нче җөмлә күтәрү паузасы аша ияргән, ул – нәтиҗә-аныклагыч җөмлә. Бу өч җөмлә 3, 2, 4 нче җөмләләрне аерып алып карасак, анда бер баш җөмләгә ике җөмлә ияргә, һәм алар тиңдәш түгелләр, димәк, монда тиңдәш түгел ияргү бар. Әгәр 3, 2, 1 нче җөмләләрне алсак, анда 3 нчегә 2 нче иярә, 2 нчегә 1 нче иярә, димәк, биредә бер-бер артлы (дәрәҗәле) ияргү бар. 3 нче, 4 нче, 5 нче җөмләләр арасында да бер-бер артлы ияргү күзәтелә: 3 нчегә – 4 нче, 4 нчегә 5 нче ияргәләр.

Шулай итеп бу җөмләдә тиңдәш түгел ияргү дә, бер-бер артлы (дәрәҗәле) ияргү дә бар, шуңа күрә мондый җөмләләр берничә төр ияргүле күп иярченле кушма җөмлә дип аталалар.

Хәзер бу 5 җөмләдән торган катлаулы төзелмәнең схемасын күзәтик.

I.




II.




Берничә төр иярүле күп иярченле кушма җөмләнең бик күп структур төрләре була. Ешрак очрый торганнары түбәндәгеләр.

1. Бер-бер артлы ияру белән тиңдәш ияру бергә килә. Болар үзләре төрлечә төзеләләр.

1) Бер баш җөмләгә тиңдәш җөмләләр ияреләр, һәм тиңдәшләрнең берсенә иярген җөмлә була: (1) *Чыннан да шулай икән:* (2) *үзе салкын,* (3) *үзе борычлы ширбәттәй,* (4) *эчкәндә юаш кына кебек сизелсә дә, (5) тора-бара, астыртын куәте бармак очларына кадәр килеп җитә* (Ә. Еники).

I.




2) Бер баш җөмләгә ике яки күбрәк җөмлә ияре, шуларның икесенә берьюлы иярген җөмлә килә: (1) *Минемчә, Майпәрвәз дөрес әйтә:* (2) *үз бүлмәң булса,* (3) *яхшы инде ул,* (4) *тормыш ансатракка килә* (Ә. Еники).




3) Бер баш җөмләгә ике-өч җөмлә тиңдәш булып иярә, ул җөмләләрнең үз иярченнәре була: (1) *Бер төрле кешеләр бар:* (2) *син аларга дус булсаң,* (3) *алар каршында галим дә син,* (4) *мөхәррир дә син,* *әмма* (6) *бераз салкынлык булса,* (5) *алар синдә булган фазыйләтне уйларга да куркалар* (Г. Тукай).




Иярүче җөмлә булып кереш җөмлә килергә, ә баш җөмлә башкалары белән тезүле бәйләнештә торырга мөмкин: (1) *Монда безне шул рәвешле икегә бүлделәр:* (2) *түтәй белән Шамил тәтә байларда* (3) *(аның чын исеме Мөхәммәтҗан икән)* (2) *торырга тиеш булды,* (4) *мин дәү апаларда* (5) *(чын исеме – Миңлекәй)* (4) *тора башладым* (Ш. Маннур).




4) Бер баш җөмләгә бер җөмлә ияреп килә һәм иярүченең үз тиңдәш җөмләләре була: (1) *Елгалар, күлләр буеннан сөзәк сырт булып*

*җәелеп киткән киң басулары шундый бәрәкәтлеләр ки,* (2) *вакытында җылы яңгырлар яуса,* (3) *кояшлы аяз көннәр булса,* (4) *бу яланнарның мамык кебек йомшак, күзге төн болытлары кебек куе кара туфраклары ярты дөньяны туйдырырлык нигъмәтләр бирәләр* (Г. Ибраһимов).




2. Тиңдәш түгел иярү белән бер-бер артлы иярү.

1) Бер баш җөмләгә ике-өч тиңдәш түгел җөмлә иярә, боларның берсенә ияргән җөмлә була: (1) *Дулкын башланса,* (2) *илгә ни булса,* (3) *миңа шул дип,* (4) *бүреген басып кия дә авылдаш эшчеләреннән калышмый чыга иде* (Г. Ибраһимов).




2) Бер баш җөмләгә ике-өч тиңдәш түгел җөмлә иярә, аларның һәрберсенә караган иярчен җөмләләре була: (1) *Бу трагедия үткәнгә,* (2) *хәзер инде байтак еллар кичте,* (3) *шулай да эзе һаман тирән иде әле,* (4) *дошманнар,* (5) *һәр сүз чыккан саен,* (4) *мыскыл итеп телгә алалар* (Г. Ибраһимов).




3) Бер баш җөмләгә бер иярчен җөмлә иярә һәм соңгысының үзенә караган ике-өч тиңдәш булмаган иярчен җөмләсе була: (1) *Төбе болай*

*икән:* (2) *Сиражи бу кәгазьне теге* (3) *мин ябылган* (2) *көндә үк әзерләгән дә,* (4) *партиясез татар эшчеләреннән кул куйдырырсың дип,* (2) *Гыйсмәт абзыйга биргән* (Г. Ибраһимов).




3. Тиңдәш иярү белән тиңдәш түгел иярү бергә килә: (1) *Мәзкүр рәвешләр илә һушына китерсәк,* (2) *дус кем,* (3) *дошман кем* – (4) *милләт үзе аңлар* (Г. Тукай).




4. Бер үк җөмләдә бер-бер артлы, тиңдәш түгел иярүләр килә: (1) *Чаршау булгач,* (2) *рәхәт, ичмаса:* (3) *кирәкмәгәндә күтәрелеп тора,* (4) *кеше-фәлән килсә,* (5) *кирәге чыкса,* (6) *мич буеннан стенагача тартып куясың:* (7) *түр як үзенә, мич алды – хатыннар ягы үзенә аерыла* (Г. Ибраһимов).



## КАТНАШ КУШМА ҖӨМЛӘ

**§ 341. Бу төр кушма җөмләләрнең төп үзенчәлекләре.** Катлаулы кушма җөмләдәге аерым җөмләләрнең бер төрләре үзара ияртүле юл белән бәйләнеп, икенче төрләре тезүле юл белән бәйләнсәләр, андый җөмлә катнаш кушма җөмлә дип атала. Катнаш кушма җөмләдә, кагыйдә буларак, баш җөмләләр үзара тезүле юл белән бәйләнәләр. Әгәр бер баш җөмләгә ияргән тиңдәш иярчен җөмләләр булса, ягъни иярчен җөмләләр тезүле юл белән бәйләнсәләр, андый җөмлә катнаш кушма җөмлә булмый, бәлки күп иярченле кушма җөмләгә керә.

Катнаш кушма җөмләләр төрлечә төзелергә мөмкин.

1. Берничә җөмлә үзара тезүле юл белән бәйләнеп, аларның берсенә ияргән бер яки берничә иярчен җөмлә була. Мәсәлән: (1) *Малай бик комачаулый башласа,* (2) *Галиулла аңа зур яшел чикерткә тотып бирә,* (3) *чикерткәне икәүләп камылга арканлап куялар* (Г. Ибраһимов).

Бу җөмләнең схемасы болай була.

I.



Бер сызык (уксыз) җөмләләр арасында тезүле бәйләнешне белдерә.

II. (...-са), [ ], [ ].

(1) *Син адаштың,* (2) *ләкин син яхшы идең,* (3) *синең яхшы иде күңелең,* (4) *тик белмәдең* (5) *тормыш баткагыннан ялгыз чыгу мөмкин түгелен* (Һ. Такташ).

I.



II. [ ], ләкин [ ], [ ] тик [ ] (...ен).

(1) *Яр буйлата бару бик кыенайгач,* (2) *аска төшеп, боз өсләп бармакчы булдылар,* (3) *ләкин боз өстенә су калыкканикән* (Г. Ибраһимов).

I.




II. (...-гач), [ ], ләкин [ ].

2. Үзара тезү юлы белән бәйләнгән җөмләләрнең һәрберсенә караган иярчен җөмләләре булырга мөмкин: (1) *Тагын суытты:* (2) *өй түбәләреннән боз бармаклары салынып төште;* (3) *аяк асты тайгаланып катты:* (4) *кешеләр, кулларын җәеп, биегән сыман йөрделәр* (И. Гази).

I.




II. [ ] : ( ); [ ] : ( ).

(1) *Ләкин моңланган саен, җыр сүзләренең мәгънәсенә ныграк төшенә барган саен,* (2) *күңелдә еллар буе яшеренеп яткан хисләр ургып ташый,* (3) *хисләр ташыган саен,* (4) *өзгәләнебрәк җырлыйсы килә* (Р. Вәлиев).

I.




II. (…саен), [ ], (…саен), [ ].

3. Үзара тезү юлы белән бәйләнгән җөмләләрнең барысына да берьюлы караган иярчен җөмлә була: (1) *Таң алды шундый ягымлы,* (2) *таң нурлары шундый нәфис һәм куанычлы тирбәнәләр иде ки,* (3) *күңел иң кадерле, иң татлы уйларга тартыла* (Г. Бәширов).

I.




II. [... шундый], [... шундый... ки], (    ).

(1) *Ак сәрви чәчәк ата башлау белән,* (2) *йөрәк ашкыныбрак тибә,* (3) *күңел нечкәрә,* (4) *тойгылар сизгерләнә* (М. Юныс).

I.




II. (…-у белән) [    ], [    ], [    ],

4. Бер җөмлә башка бер иярченле яки күп иярченле кушма җөмләгә тезүле юл белән бәйләнә. Иярченле кушма яки күп иярченле кушма җөмләнең үз эчендә ияртүле бәйләнеш булганлыктан, мондый катлаулы кушма җөмлә катнаш кушма җөмлә дип таныла. Мәсәлән: (1) *Бик мавыктыргыч иде бу хыял, әмма* (2) *Мостафинны нидер тота,* (3) *күңеле ул эшкә никтер бик тартмый,* (4) *шуңа күрә тәгаен бер карарга килү аның өчен кыен иде* (Ә. Еники).

I.



II. [ ], әмма ( ), ( ) [шуңа күрә...].

Биредә беренче җөмлә тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмләгә тезүле юл белән бәйләнгән.

Катнаш кушма җөмләнең башка төзелешләре дә еш күзәтелә.

# ТЕКСТ СИНТАКСИСЫ

**§ 342. Гомуми мәгълүмат.** Синтаксис сөйләм төзелеше нормаларын өйрәнә, дигән идек. Бу эшне җиңеләйтү өчен, сөйләмнең төп берәмлеге – ж ө м л ә җентекләп тикшерелә. Шуннан соң җөмләләрнең сөйләмгә оешу юллары, сөйләмнең төзелеше һәрьяклап анализлана. Бу зур бурычның бер өлеше – сөйләмдә мөстәкыйль җөмләләрнең үзара бәйләнүләрен өйрәнү – элек «Синтаксик бөтеннәр» темасында башкарыла иде. Рус теле синтаксисында бу күренеш «Сложное синтаксическое целое», «Связная речь» яки «Высказывание» дигән темада каралып киленде. Чит ил лингвистикасында да сөйләмне өйрәнү проблемасы төрле исемдә төрлечәрәк чишелә иде.

Җөмләне генә түгел, ә текстны, ягъни тоташ сөйләмне, синтаксик өйрәнү рус тел белемендә 40 нчы еллар ахырында башланып китә. Америка лингвистикасында бу эшнең беренче адымы 50 нче еллар башына туры килә. (Бу тарих О.И. Москальскаяның китабында яктыртыла [Москальская, 1981, с. 4–11].) Текстны билгеләү мәсьәләсе И.Р. Гальперинның «Текст как объект лингвистического исследования» китабында күтәрелә [Гальперин, 1981]. Татар тел гыйлемендә, синтаксисның төп өйрәнү объекты буларак, тоташ сөйләм төзелеше шулай ук 50 нче елларда күрсәтелә. Әлеге хезмәтнең авторы шул елларда ук бу мәсьәлә хакында түбәндәге карашны үткәрә: синтаксис фәне тоташ сөйләм төзелешен өйрәнү өчен яши, бары сөйләм төзелешен өйрәнүне тәртипле һәм нигезле итеп алып бару өчен генә сөйләмнең төп берәмлеге – ж ө м л ә аерып чыгарыла һәм җентекләп тикшерелә; җөмләдә сүзләр бәйләнешен өйрәнүне тәртипкә салу өчен генә сүзтезмә аерыла һәм анализлана. Шулай итеп синтаксисның өйрәнү объекты буларак, тоташ сөйләм беренче планда, җөмлә – икенче планда, сүзтезмә – өченче планда тора. Автор сөйләм төзелешен «Синтаксик бөтеннәр», «Җөмләнең актуаль кисәкләре», «Ким җөмләләр» темаларында яктыртырга тырышты.

Ләкин тоташ сөйләмне, ягъни текстны синтаксик өйрәнү рус һәм чит ил лингвистикаларында 60 нчы, 70 нче елларда бик нык киңәеп һәм тирәнәеп китә. Өйрәнү өчен алынган, күп яктан бөтен булган тоташ сөйләм т е к с т дип исемләнә башлый.

Татар синтаксисында текст турында төп мәгълүматларны М. Зәкиевнең 1974 елда чыккан «Хәзерге татар әдәби теле (синтаксис)» дигән китабыннан алырга мөмкин. Анда «Синтаксик бөтеннәр» исеме белән текстта мөстәкыйль җөмләләрнең мәгънә һәм төзелеш ягыннан бәйләнеше, грамматик бәйләнеше өйрәнелә (б. 257–263). 1984 елда чыккан «Хәзерге татар әдәби теле синтаксисы һәм пунктуациясе» дигән китабында М. Зәкиев бу гомуми проблемаларга бәйле рәвештә татар текстының төрләрен һәм аның бөтенлеге проблемаларын тикшерә (б. 199–211). Текст синтаксисы эчендә автор тезем, чит сөйләм мәсьәләләрен дә ачыклый (б. 212–226).

1993 елда Ф.С. Сафиуллина «Текст төзелеше» дигән махсус китап чыгара һәм текстның күп проблемаларын бик бай мисалларда аңлатып бирә.

1992, 1995 елларда татар теленең академик синтаксисы русча басыла. «Татарская грамматика (синтаксис)» дигән III томы М. Зәкиев тарафыннан язылган. Анда да татар сөйләмендә текст проблемалары шактый күп яктан яктырту таба.

**§ 343. Текстның күләмен аңлау турында.** Өйрәнү өчен алынган, эчтәлек һәм структур яктан оешкан тоташ сөйләмне т е к с т дип атыйлар. Текстны өйрәнгәндә, беренче проблема буларак, аның чикләрен, күләмен билгеләү мәсьәләсе алга килеп баса. Бу эшне башкару процессында галимнәр текстны күләм буенча төрләргә дә бүләләр.

Тоташ сөйләмне өйрәнү барышында соңгы елларда зур әсәрләрнең аерым бүлекләре, кыскарак хикәя һәм нәсерләр, аерым мәкаләләр, эш кәгазьләреннән гариза, белешмә, ышаныч язуы, беркетмә һ.б. тулысынча алыналар һәм текст дип йөртеләләр. Шуның белән бергә мондый тоташ сөйләмнең аерым өлешләре дә текст буларак өйрәнелергә мөмкин. Беренче төр тоташ сөйләмне, гадәттә, м а к р о - т е к с т дип, икенче төрен (кыскарагын) м и к р о т е к с т дип атау да кабул ителгән. Микротекстны икенче төрле синтаксик бөтеннәр дип тә йөртәләр. Шулай итеп, текстның ике төрен күрсәтергә мөмкин: синтаксик бөтеннәр (микротекст) һәм зур булмаган тулы әсәрләр,

мәкаләләр (макротекст). Макротекстның мәгънә һәм структур яктан төзеклеге мәсьәләсе әдәбият белеме галимнәрен һәм стилистларны бик күптән кызыксындыра. Гомуми синтаксис фәнендә аңа әле соңгы елларда гына игътибар артты. Татар тел гыйлемендә ул бөтенләй дип әйтерлек өйрәнелмәгән. Бу кулланмага да макротекст турында беренче күзәтүләр генә кертелә.

Микротекст татар синтаксисының төрле темаларында шактый өйрәнелгән. Мәсәлән, синтаксик бөтеннәрне, актуаль кисәкләрне, теземнәрне, чит сөйләмне, ким җөмләне өйрәнү, нигездә, микротекстның аерым үзенчәлекләрен тикшерүгә кайтып кала. Бу китапта без микротекст синтаксисына күбрәк игътибар итәчәкбез, макротекст өйрәнүне киләчәккә калдырабыз.

Текст синтаксисы белән шөгыльләнүче галимнәр абзацны микротекст итеп карау-карамау мәсьәләсендә әле бер уртак фикергә килмәгәннәр. Бу төркем галимнәр аны микротекст (синтаксик бөтен) дип таныйлар, икенчеләре абзац микротекст була алмый, чөнки ул стилистик-композицион күренеш кенә диләр. Ләкин тегеләре дә, болары да соңгы чиктә абзацны текст синтаксисының объектына кертәләр. Безнең өчен шунысы ачык: абзац иң күп очракта аерым микротекст булып оеша, ягъни ул, түгәрәкләнгән бер фикерне әйтү өчен, структур яктан кербөтен тәшкил итә һәм чын, дөрес абзац шулай булырга тиеш тә. Әгәр бу таләпләргә җавап бирмәгән, ягъни микротекст булып оешмаган абзац очрый икән, ул әле абзац микротекст була алмый дигән фикерне әйтергә нигез бирми, бары теге яки бу язучының абзац оештыра белмәве турында гына сөйли. Ләкин абзац белән микротекстны тиңләргә ярамый. Чөнки өйрәнү максатыннан чыгып, бер генә абзац та, кайчакта берничә абзац та микротекст итеп алынырга мөмкин. Аннан соң без әсәрләрдә бер генә җөмләдән торган абзацларны да еш очратабыз. Мондый абзац, билгеле, текст дип алына алмый, чөнки анда мөстәкыйль җөмләләр арасында мәгънәви, структур һәм грамматик бәйләнешне өйрәнү өчен объект булмый.

**§ 344. Текст синтаксисы һәм грамматик категорияләр.** Лингвистиканың тел төзелешен өйрәнә торган бүлекләреннән лексикология, морфология, стилистика текст синтаксисы белән шактый тыгыз бәйләнгәннәр. Мәсәлән, лексикологиянең сүзләр мәгънәсен өйрәнә торган өлеше (семасиология), мәгънәнең барлык нечкәлекләренә дә

керү өчен, җөмләгә генә түгел, бәлки еш кына текстка да мөрәҗәгать итә. Морфологиядә өйрәнелә торган билгелелек-билгесезлек, заман кебек категорияләрнең барлык төр үзенчәлекләре текст эчендә генә тулысынча ачыла ала. Мәсәлән, текст башында беренче мәртәбә телгә алынган әйберләрне атаучы сүзләр билгесезлек күрсәткечләрен алалар яисә билгесез килештә киләләр. Текст уртасындагы җөмләләрдә андый сүзләр, гадәттә, билгелелек формаларын кабул итәләр. Бу җөмләдә заман формасын дөрес сайлау тексттагы янәшә җөмләнең заман формаларына бәйле. Морфологик категорияләр буларак тикшерелә торган ялгызак теркәгечләрнең, теркәгеч сүзләрнең һәм мөнәсәбәтле сүзләрнең функцияләре дә, аларның тексттагы мөстәкыйль җөмләләрне бәйләү үзенчәлекләрен әйтмәсәң, тулы була алмый.

Текст синтаксисы, гомумән, синтаксисның башка өлкәләре белән тагын да тыгызрак мөнәсәбәттә тора. Югарыда әйтелгәнчә, синтаксисның төп максаты – тоташ сөйләм төзелешен өйрәнү. Җөмләне, сүзтезмәләрне төрле яклап тикшерү соңгы чиктә сөйләм төзелешен өйрәнүне тәртипле итеп башкару өчен эшләнә. Синтаксис җөмлә төзелешен өйрәнүдән башлана, тоташ сөйләмне гомумән алып өйрәнү (ягъни текст синтаксисы) белән тәмамлана. Шуңа күрә барлык синтаксик категорияләр текстта гына барлык нечкәлекләре белән ачылалар. Шулардан текст синтаксисы белән бик тыгыз бәйләнгән категорияләрне генә күрсәтик.

1. Синтаксик категория буларак, хәбәрлек һәм модальлек җөмләдә бирелсә дә, барлык үзенчәлекләре белән текстта гына ачыла. Хәбәрлек ул сөйләм эчтәлегенең чынбарлыкка мөнәсәбәте, ягъни сөйләм, сүзләрне үзара бәйләп, сөйләм оештыру өчен генә төзелми (ягъни ул үзмаксат түгел), бәлки сөйләм, билгеле бер фикерне билгеле бер вакыт һәм урынга бәйләп, тыңлаучыга җиткерү, хәбәр итү өчен төзелә. Димәк, сөйләмнең эчтәлеге чынбарлыкка юнәлдерелгән була – сөйләм хәбәрлеккә ия була, ул, барыннан да, элек текстта тулырак бирелә. Модальлек ул сөйләүченең чынбарлыкка – тыңлаучыга, сөйләм эчтәлегенә мөнәсәбәтен сөйләмдә чагылдыру була. Бу синтаксик категория дә текстта ачыграк, тулырак чагыла. Аерым җөмләнең хәбәрлеген һәм модальлеген тулырак билгеләү өчен, ул җөмләне билгеле бер текст эчендә итеп күз алдына китерергә кирәк була.

2. Ким җөмләләр бары текст эчендә генә фикер белдерү ягыннан тулы була алалар, димәк, ким җөмлә үзенчәлекләрен тулысынча өйрәнү дә текст эчендә генә мөмкин («Ким җөмлә» темасын карагыз).

3. Атау җөмләләр, бигрәк тә сүз җөмләләр, текст эчендә генә туа һәм кулланыла алалар. Текстсыз алар бары сүз генә булып калалар. Атау җөмләләрне тезеп куллануны тексттагы субъектлы-предикатлы структураның кысылуы, мәгънәнең тыгызлануы дип караучылар да бар. Чынлап та ул шулай. Мәсәлән, түбәндәге текстның атау җөмләләрен субъектлы-предикатлы итеп үзгәртеп булыр иде, ләкин ул чагында мәгънәне укучыга җиткерү сүлпәнләнә, мәгънә сыеклана.

*Фәхри унҗиде яшьтә Фон-Коллер дигән алпавытка ялчы булып керә. Анда дүрт ел. Аннан солдат. Ел ярым үтми, герман сугышы. Фронт. Карпаттан кичкәндә, Австриядә кала. Аннан дүрт кеше качалар. Икәве эләгә. Бу бер мари егете белән, яраланып, имгәнеп, Россиягә кайтып егыла. Дүрт ай Петербургта лазарет. Шуннан февраль революциясе. Аннан Октябрь. Аннан кызыл фронтлар. Аннан партия-совет эшләре* (Г. Ибраһимов).

4. Җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше элек җөмлә синтаксисында тикшерелде, хәзер дә без аны, сүз тәртибен аңлату өчен, җөмлә синтаксисында калдырдык, ләкин актуаль бүленеш, нигездә, текст проблемасы булып санала. Чөнки сөйләм предметын һәм сөйләм яңалыгын (теманы һәм реманы) белдерүче сүзләрнең бер җөмләдәге урынын тексттагы башка җөмләләрдән чыгып кына дөрес билгеләп була. Димәк, традицион сүз тәртибе проблемасы да, нигездә, текстта гына тулысынча чишелә ала («Актуаль бүленеш һәм телне практик куллану» параграфын карагыз).

5. Теземнәрне һәм чит сөйләм төрләренең сөйләмдә кулланылышын өйрәнүгә килгәндә, бу мәсьәләләр турыдан-туры текст проблемасына карыйлар һәм шуңа күрә текст синтаксисына кертеләләр дә.

## ТЕКСТНЫҢ БӨТЕНЛЕГЕ

**§ 345. Текстның мәгънәви бөтенлеге.** Тоташ текст эчтәлек ягыннан бербөтен төзергә тиеш, ягъни андагы мөстәкыйль җөмләләр тыгыз мәгънә бәйләнешендә торырга һәм барысы да бер уртак теманы ачуга ярдәм итәргә тиешләр. Бу уртак тема текстның мәгънәви үзәге була.

Мәгънәви үзәкне, икенче төрле әйткәндә теманы, тексттагы аерым җөмләләр эчтәлегенең механик җыелмасы итеп кенә карарга ярамый, ул тоташ текст эчтәлегенең гомумиләштерелгән үзәге була. Шул үзәк бөтен бер тексттагы мөстәкыйль җөмләләрне, хәтта абзацларны мәгънәви яктан бәйли, нәтиҗәдә текстның мәгънәви бөтенлеге тәэмин ителә. Мәсәлән, Гадел Кутуйның «Сагыну» нәсерен, тулысынча макротекст итеп, һәрбер абзацын микротекст итеп карарга мөмкин. Биредә макротекст та, микротекст та мәгънәви яктан язучы тарафыннан бик оста, логик эзлекле итеп оештырылган. Шуны күзәтү өчен, нәсерне тулысынча искә төшерик.

*Сагыну*
*(нәсер)*

*Мин чит илдә матур гөлләр, хуш исле чәчәкләр исним. Ләкин күпме генә иснәмим, барыбер һава җитми, сулыш кысыла. Гүя үз илемнең энҗе чәчәкләре түгел, аның әреме дә бүген миңа шифа булыр иде.*

*Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!*

*Мин шаулап аккан елгалардан, тирән коелардан алып, сап-салкын су эчәм. Әмма күпме эчсәм дә, сусавымны баса алмам. Мин үз илемнең борынгы Иделен, тын Донын, якты Арагвасын, шигъри Дим буйларын сагынам. Гүя бу мөкатдәс елгаларның суларын түгел, хәтфә болынлыктагы чишмәләребезнең бер йотым суын да бүген мин ширбәт итеп эчәр идем.*

*Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!*

*Мин Карпат тауларына мендем, Финляндия күлләре янында ял иттем. Ләкин Эльбрус шикелле мәһабәт, Казбек шикелле гүзәл тауларны, үз илемдәге Аккош күледәй сихри күлләрне очратмадым.*

*Синдәгедәй илаһи матурлык, синдәгедәй шагыйранә мәһабәтлек бер җирдә дә юк, туган ил!*

*Мин чит авыллар һәм чит шәһәрләр аша узам. Җиңү мине Берлинга алып бара. Чит ил балалары миңа бәйләм-бәйләм чәчәкләр сузалар, чит ил картлары миңа хөрмәт тәкъдим итәләр, чит ил кызлары миңа җимешләр сузып елмаялар һәм ялваралар:*

*– Син безне үлемнән коткардың, инде кил, чибәр егет, кунак бул, бездә кал! – диләр.*

*Әмма мин елмая алмыйм, чөнки хәмерләре исертми, елмаюлары җылытмый. Мин юлымда дәвам итәм. Мин газиз илемне, аның ямьле бәйрәмнәрен, аның талган аякларны биетә торган хәмерләрен, йөрәккә җылы өргән нечкә билләрен сагынам, гөнаһсыз балаларын күргәндәй булам.*

*Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!*

*Мин горур атлыйм. Чөнки мин чит илдә әсир булып түгел, җиңүче булып йөрим. Миңа һәр йортның капкасы, һәр өйнең ишеге ачык. Ләкин берсенә дә керәсем килми минем. Мин ата-баба корган илемдәге изге йорт турында уйлыйм һәм, шунда тизрәк кайтып керер өчен, Берлинга ашыгам. Берлинга мин илем белән аерылу кайгысын моннан соң һичкайчан татымас өчен чиксез ачу белән барам. Ачуым шулкадәр көчле, сагынуым шундый татлы ки, мин түзмим, җырлап җибәрәм.*

*Иле ямьсез, суы тәмсез,*
*Өйгә кайтасым килә! –*

*дип җырлыйм мин.*

*Без мәйданга керәбез. Поляк яшьләре, безне котлап, үзләренең иң матур җырларын җырлыйлар. Әмма минем күңел еракта. Мин үзебезнең Кызыл мәйданыбызны сагынам һәм туган илдән килгән хатларны укыйм. Дусларым, кардәшләрем миннән, сагынасыңмы, дип сорыйлар. Минем бугазыма төен тыгыла. Мин төенне йота-йота җавап язам:*

*Телеграмм баганасы – олы юлга маяк ул,*
*Сагынасыңмы, дип сорыйсыз – сагынмаган кая ул!*
*Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!*

*Сине сагынган саен миндә көч-дәрт арта, рухым канатлана. Чит илдә йөреп мин ачык аңладым: кеше өчен үз иленнән дә изгерәк, үз иленнән дә кадерлерәк, үз иленнән дә гүзәлрәк ил дөньяда юк ул.*

*Сагынган саен сагынасы килә. Сагынуым шундый көчле булганга, кайтуым да ышанычлы. Кайтыр булмасам, бу кадәр сагынмас идем.*

*Сагындым, бик сагындым сине, изге туган ил!*

Г. Кутуй

Күренгәнчә, әсәрнең төп темасы – туган илне сагыну, язучы аны тагын да кыскартып, гомумиләштереп, «сагыну» дип кенә бирә, менә шул төшенчә макротекстның мәгънәви үзәге була да инде. Мәгънәви

үзәкне (теманы) язучы төрле яктан ача, конкретлаштыра. Аны бер яктан тасвирлау, конкретлаштыру тәмамлангач, макротекстның төп темасын тәшкил итә торган җөмлә – «Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!» җөмләсе кабатлап әйтелә. Шушы мәгънәви үзәкне тәэсирле итеп әйтергә әзерли торган җөмләләр микротекст оештыралар. «Сагыну» нәсерендәге һәрбер микротекстның үз мәгънәви үзәге (темасы) бар, ул мәгънәви үзәкне һәр очракта да язучы логик эзлекле итеп, чит илдә алган тәэсирләрне туган ил истәлеге белән чагыштыру аркылы ачып бирә.

Макротекстның һәм микротекстның темасы буларак, кеше тормышыннан, кешеләр мөнәсәбәтеннән бер өзек, предмет, табигать күренешләре, билгеле бер чор, урын, ниндидер күренешнең, процесснең сәбәбе, нәтиҗәсе, объекты һәм башка яклары алынырга мөмкин. Боларга мисалларны һәрбер әдәби әсәрдән табып була.

**§ 346. Текстның коммуникатив бөтенлеге.** Коммуникатив процесста, ягъни аралашканда, сөйләүченең (язучының) фикере тыңлаучыга (укучыга) җиңелрәк, тулырак аңлашылсын өчен, тексттагы мөстәкыйль җөмләләр арасында мәгънәви яктан логик эзлеклелек булырга тиеш. Текст өлешләренең (мөстәкыйль җөмләләрнең яки абзацларның) мәгънәви эзлеклелеген без үзебезнең синтаксис китапларында «актуаль бүленеш һәм фикер агылышының тәртибе» дигән баш астында тикшереп килдек. Соңгы елларда текст өлешләренең мәгънәви эзлеклелеген рус һәм чит ил лингвистикасында «Текстның коммуникатив бөтенлеге» дип өйрәнә башладылар [Москалькая, 1981, с. 21]. Бу китапта без дә «Текстның коммуникатив бөтенлеге» дигән атама кулланырга булдык.

Текстның коммуникатив бөтенлеге, ягъни андагы мөстәкыйль җөмләләр эчтәлегенең эзлеклелеге, актуаль бүленеш ягыннан караганда, берничә юл белән тормышка ашырыла. Гадирәк мисалларда хәзер шуңа тукталыйк.

Сөйләүче (язучы) тыңлаучыга (укучыга) фикер хәбәр иткәндә, гадәттә таныш булган бер төшенчәне атый һәм шул төшенчә турында нинди дә булса бер яңалык әйтә. Шулай булмаса, ягъни алынган төшенчә турында яңалык әйтелмәсә, сөйләмнең һәм аралашуның кирәге дә булмас иде. Мәсәлән: *Бу – безнең өй. Аның янында зур бакча бар. Бакчада күптөрле гөлләр үсә. Алар матурлар, хуш ислеләр.* Мисалда хәбәр итү түбәндәге эзлеклелектә бара. Сөйләүче кеше иң элек

тыңлаучыга да күренеп торган бинаны *бу* сүзе белән атый, һәм *бу* сөйләм предметы була. Шуның турында *безнең өй* дип яңалык әйтелә. Беренче җөмлә өчен сөйләм яңалыгы булган *безнең өй* икенче җөмләдә (*Аның янында* кисәге) сөйләм предметын белдерә. Бу сөйләм предметы турында *зур бакча* бар дигән яңалык әйтелә. Бу яңалык өченче җөмләдә алдан билгеле булган сөйләм предметы буларак катнаша (*бакчада*) һәм аның турында *күптөрле гөлләр үсә* дигән яңалык әйтелә. Бу яңалык (*гөлләр*, ягъни *алар*) дүртенче җөмләдә сөйләм предметы була, чөнки ул тыңлаучыга алдан таныш. Шул гөлләр турында *матурлар, хуш ислеләр* дип яңалык әйтелә. Әгәр сөйләм предметын *S* (субъект сүзен белдерә) белән, ә сөйләм яңалыгын *P* (предикат сүзен белдерә) белән билгеләсәк, югарыда китерелгән сөйләм мәгънәсенең логик эзлеклелеге түбәндәгечә, буыннары бер-берсенә тоташкан чылбыр кебек, тезелеп киткән:

$$S_1 - P_1 \cdot (P_1{=}S_2) - P_2 \cdot (P_2{=}S_3) - P_3 \cdot (P_3{=}S_4) - P_4$$

Билгеле, фикер бу тәртиптә генә агылмый. Кыскалык өчен, сөйләүче кайбер буыннарны төшереп калдырырга да мөмкин.

Билгеле урынны яки вакытны тасвирлаганда бөтенләй яңа предметлы җөмләләр дә тезелеп китә алалар. Мәсәлән: *Вак яңгыр ($S_1$) сибәли ($P_1$). Үләннәр, яфраклар ($S_2$) юеш ($P_2$). Аяк асты ($S_3$) тайгак, пычрак ($P_3$)* (Г. Ибраһимов). Бу өзектә фикер эзлеклелеге түбәндәге тәртиптә бара: $S_1 - P_1 \cdot S_2 - P_2 \cdot S_3 - P_3$ һ.б. Биредә яңа темалар һәм яңа ремалар вакыйганың билгеле бер вакытка каравы белән тоташтырылганнар. Яңа темалар һәм яңа ремаларны тоташтыру өчен, текстта гомумиләштерүче өзек (яки җөмлә) тә булырга мөмкин.

Җөмлә кисәкләренең әһәмияте ягыннан бүленеше буенча караганда, фикер агылышы тагын түбәндәгечә булырга мөмкин: иң элек сөйләм предметы әйтелә дә, шуның турында бик күптөрле яңалык тезелеп китә. Мәсәлән: *Егет ярлы. Ләкин үткенлеге зур. Гәүдәгә нык. Буйга-сынга таза, килешле.* (Г. Ибраһимов). Мондагы фикер агылышы: $S - P_1 - P_2 - P_3 - P_4$.

Шулай итеп текстта һәрбер җөмләнең тик ике актуаль кисәктән генә торуы мәҗбүри түгел. Күп кенә җөмләләр бары сөйләм яңалыгыннан гына да тора алалар. Сөйләм яңалыгын гына әйтеп сөйләшү диалогларда еш очрый. Мәсәлән:

*Хатынны швейцар каршы алды:*

*– Сез кемгә?*

*– Утыз икенче бүлмәгә. Өйдәдер бит?*

*– Юк.*

*– Кая?*

*– Ячейкага китте* (Г. Ибраһимов).

Бу мисалда хатын белән швейцар арасында сөйләшү сөйләм яңалыкларын әйтү аркылы гына бара. Диалог төзелеше болай:

*– S–P?*

*– P. P?*

*– P.*

*– P?*

*– P.*

Димәк, җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше ягыннан карaганда, текст эчендәге мөстәкыйль җөмләләрнең мәгънәви эзлеклелеге, ягъни текстның коммуникатив бөтенлеге, төрлечә тормышка ашырыла.

Макротекстларда коммуникатив бөтенлекне сөйләм предметы (субъект, тема) һәм сөйләм яңалыгы (предикат, рема) аркылы схемаларда анализлау бик зур урын ала, шуңа күрә бу кулланмада күрсәтелгәннәр белән чикләнергә булдык.

**§ 347. Текстның структур бөтенлеге.** Текст мәгънәви һәм коммуникатив бербөтен тәшкил итә, ягъни текст эчендәге мөстәкыйль җөмләләр мәгънәви яктан бер теманы ачалар, теләсә ничек түгел, логик яктан эзлекле рәвештә ачалар.

Текстның шундый бөтенлеге андагы мөстәкыйль җөмләләр структурасында да чагылыш таба. Тексттагы мөстәкыйль җөмләләр арасындагы структур бәйләнешнең түбәндәге төрләрен күрсәтергә мөмкин.

Бер тоташ текст тәшкил итә торган мөстәкыйль җөмләләрнең гадәттә һәрберсенә дә карый торган уртак кисәк була. Ул уртак кисәк шигъри әсәрләрдә, нәсерләрдә мөстәкыйль җөмләләрнең һәрберсендә дә кабатланып әйтелә һәм җөмләләрнең үзара төзелеш ягыннан бәйләнгән булуын күрсәтеп тора. Мәсәлән, Һ. Такташның «Сыркыды авылы» дигән әсәрендә *җил* сүзе түбәндәгечә кабатлана:

*Җил.*

*Җил – бүген хезмәт батыры.*

*Җил урамда кар көри.*
*Җил молодец!*
*Карт авылны*
*«Ду-у-у» килеп күмеп йөри.*
*Җил бүген ач.*
*Җил ишектән*
*Нан сорап борнын суза.*

Тойгыга артык бай булмаган сөйләмдә уртак кисәк беренче җөмләдә әйтелеп, калганнарында кабатланмый, шулай итеп соңгы җөмләләр беренчесе исәбенә ким булалар. Бу да мөстәкыйль җөмләләр арасында структур бәйләнешнең булуын күрсәтеп тора. Мәсәлән, И. Газиның «Онытылмас еллар» әсәреннән булган бер өзектә Галиулла турында сүз бара. *Галиулла* кисәге беренче җөмләдә әйтелеп, калганнары шуның исәбенә ким булып киләләр. Түбәндә китерелгән текстта кабатланмаган уртак кисәк, өстәлеп, җәяләр эчендә бирелә.

*Галиулла дөньяның әчесен-төчесен җитәрлек татыган кеше ул. (Галиулланың) Атасының семьясы зур иде. Ир балалары бер ул гына булганга күрә, аңа эш талымлап торырга туры килмәде. (Галиулла) Бераз калкынып, егет була башлауга, кешегә ялланып урман кисте, ындыр сукты, печән чапты, таш чыгарды, сал куды. «Җен кебек таза, ат кебек көчле кеше», диләр иде аның турында.*

*(Галиулла) Унтугыз яшь тулар-тулмас шахтага китеп, рәттән икешәр смена эшләде. (Галиулланың) Иптәшләре арасында (аның) «Комсыз Галиулла» дигән исеме чыкты. Егерме өч яшькә кадәр шулай, үзен-үзе белештермичә эшли торгач, (Галиулла) үзенең максатына ирешкән кебек булды...*

Тоташ тексттагы мөстәкыйль җөмләләр өчен уртак булган кисәк, беренче җөмләдә генә әйтелеп, калганнарында алмашлыклар белән дә алмаштырылырга мөмкин. Бу да структур бәйләнешнең бер күренеше була ала. Мәсәлән, А. Шамовның «Ана» әсәрендә *Госман Әхмеров* кисәге беренче җөмләдә әйтелеп, калганнарында аның урынында алмашлыклар килә.

*Г о с м а н  Ә х м е р о в тәрәзә форточкасының көзге җил белән бер ачылып, бер ябылып торуына уянып китте. Башта а н ы форточканың ябылмый калуы гаҗәпләндерде. Аннары у л, аны яңа гына ачылгандыр, әле торырга иртәдер дип уйлап, күзләрен йомды, одея-*

*лын яхшылап ябынды. Көзге иртәнең салкын юеш һавасы, а н ы ң одеялы аркылы үтеп, аз гына туңдыра башлаган иде. У л , кулларын, аякларын җыя төшеп, әнисенең йомшак кына басып кергән аяк тавышын ишетергә хәзерләнде...*

Мөстәкыйль җөмләләрне, абзацларны үзара мәгънә һәм структур яктан бәйләп, уртак кисәкләр генә түгел, бәлки уртак җөмләләр дә киләләр. Бу уртак җөмләләр гадәттә әсәрнең төп темасын, идеясен белдерәләр һәм тойгыга бай булган әсәрләрдә (нәсерләрдә) һәрбер абзац янында кабатланып, аларны үзара структур яктан оештыралар. Мәсәлән, Г. Кутуйның «Сагыну» нәсерендә *Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!* дигән җөмлә, бөтен әсәр буенча кабатланып, аны структур яктан бербөтен итеп оештырып тора (мисалны 345 нче параграфтан карагыз).

Тексттагы берничә мөстәкыйль җөмләнең эчтәлеген гомумиләштереп килгән җөмләләрнең булуы да структур бәйләнешнең бер күренеше булып тора. Андый гомумиләштерүче җөмлә синтаксик бөтеннең башында да, ахырында да торырга мөмкин.

Түбәндәге мисалда гомумиләштерүче абзац башта килгән:

*Ихтыяр инде моңа кадәр дә Зыятдин бабасының язмышы, үткән гомере турында күп ишеткән иде. Әнисе аңа кичләр буе үзенең балачак хатирәләре белән аралаштыра-аралаштыра Бигәшевләр ыруы хакында сөйли торган иде.*

*Бигәшевләр нәселе элек-электән булдыклы, алтын куллы, эшлекле һәм шактый ук кырыс холыклылардан саналган. Әнисенең бабасы Арсланның алты малае булуын, шуларның төпчеге Зыятдин карт икәнен дә белә Ихтыяр. Егерменче елларда шул алты туган берләшеп атауның аскы өлешендә, ике инеш кушылган урында су тегермәне корганнары, соңрак тегермән белән янәшә яргыч һәм сушилка салганнары хакында да ишеткәне бар. Ә менә бабасының нигә дип шушы атауга кереп бикләнгәнен, бар дөньяны онытып, шунда тешетырнагы белән ябышып ятканын, кешеләрдән читләшкәнен аңламый иде. Дөрес, әтисенең бик кызып киткән чакларында «чабаталы морза», «сусыз тегермән», «тегермән өрәге» дип ычкындырганын ишеткәч, бабасын бу атауда нәрсә тотып торганын аңлагандай итә, бабасы белән әтисе арасында язгы ташу суы кебек нindидер үтеп булмый торган аралык ятканын сиземли иде* (Р. Вәлиев).

Түбәндәге мисалда гомумиләштерүче җөмлә башта килгән:

*Петров мине аның тәрҗемәи хәле белән таныштырды. Ул Сакмар суы буенда үскән. Ләкин аңа матур табигать кочагында бәхетле балалык көннәрен татырга туры килмәгән. Ул бик иртә ятим калган. Аңа 9 яшь чакта, әтисе, 13 яшь чакта әнисе үлгән. Мөхәммәтнең ике абыйсы һәм ике сеңлесе булган. Абыйлары, яшь Совет республикасын яклаганда, Кызыл Гвардия сафында корбан булганнар, сеңелләре авырып үлгәннәр. Ул ялгыз калган...* (Г. Кутуй).

Түбәндәге мисалда гомумиләштерүче җөмлә соңыннын аерым абзац булып килгән:

*Төн караңгы. Дөнья тын. Ләкин диңгез шаулый. Диңгез түбәндә кемгәдер ачу белән үкерә. Аның куәтле дулкыннары, тау-тау булып, биек, ташлы, текә ярларга һөҗүм итәләр. Күңелгә шом килә: гүя, менә-менә тагы бер-ике тапкыр ыргып атылачаклар да дөньяны каплап китәчәкләр. Ләкин сезгә куркыныч юк. Дулкын ничаклы каты булса да, ул сезнең биек тау итәгендәге урыныгызга килеп җитә алмаячак. Сезгә тыныч булырга, тәрәзәләрегезне ачып, диңгез тавышын тыңларга да, аннан соң рәхәт-рәхәт тагы йокыгызга чумарга мөмкин.*

*Олы Россия диңгезендә күтәрелгән куәтле революция дулкыннары да илнең караңгы почмакларында яшәгән халыкларның кайбер караңгы катлауларына баштарак менә шулай булып тоелды* (Г. Ибраһимов).

Синтаксик бөтен өчен гомуми җөмлә булып, тасвирлана торган урынны яки вакытны белдерә торган җөмләләр дә килә алалар. Мәсәлән: *Коньякка буе белән салынган өч катлы, киң, озын таш бина. Зур өлгеле киң тәрәзәләренең һәммәсе ерактан балкып торалар. Әйтерсең патша туган көн – шулай бәйрәмдәге кебек куәтле яктыртылганнар. Зур таш бинаның эче үз алдына бер завод, фабрика яки тузган умарта оясы шикелле гөрләп тора. Капкага каршы алты киртләчле таш баскычта әллә ничаклы яшьләр, шәкертләр куышып менеп үтәләр* (Г. Ибраһимов).

*Август чыгып бара иде инде. Вәли абзыйларның ишек алдына бер кеше килеп керде. Өстендә кама тоткан искерәк бишмәт, башында камчат бүрек... Ул йорт уртасында тукталып, «Кай ишеккә керим икән?» – дигән төсле карап торды-торды да, Вәли абзыйларның баскычына килеп, таягы белән ишекне шакыды* (Ә. Фәйзи).

Бер төркем җөмләнең икенче төркемгә каршы куелуы, чагыштырылуы да мөстәкыйль җөмләләрне структур яктан үзара оештырып тора. Мәсәлән, Г. Кутуйның «Сагыну» дигән нәсерендәге һәрбер абзац бертөрле төзелгән: андагы бер группа җөмлә икенче группага каршы куела.

*Без мәйданга керәбез. Поляк яшьләре, безне котлап, үзләренең иң матур җырларын җырлыйлар. Ә м м а минем күңел еракта. Мин үзебезнең Кызыл мәйданыбызны сагынам һәм туган илдән килгән хатларны укыйм…*

*Мин горур атлыйм. Чөнки мин чит илдә әсир булып түгел, җиңүче булып йөрим. Миңа һәр йортның капкасы, һәр өйнең ишеге ачык. Л ә к и н берсенә дә керәсем килми минем. Мин ата-баба корган илемдәге изге йорт турында уйлыйм һәм, шунда тизрәк кайтып керер өчен, Берлинга ашыгам* (Г. Кутуй).

**§ 348. Текстның грамматик бөтенлеге.** Текстның мәгънәви коммуникатив һәм структур бөтенлеген дә гомумән грамматик күренеш итеп карап була, чөнки алар да грамматиканың бер бүлеге булган синтаксиста өйрәнеләләр. Бу урында без, грамматик бөтенлек дип, тексттагы мөстәкыйль җөмләләрнең, абзацларның грамматик чаралар белән бәйләнүләрен атадык.

Тексттагы мөстәкыйль җөмләләр арасында грамматик бәйләнешне белдерүдә синтетик чаралар һәм аналитик чараларның парлылары (*кем–шул, кемгә-шуңа, ни–ни, да–дә* һ.б.) бөтенләй катнашмыйлар. Анда бары аналитик чараларның парсызлары гына (*чөнки, шунлыктан, ләкин, ә* һ.б.) килергә мөмкин.

1. Мөстәкыйль җөмләләр арасында тезүче теркәгечләрнең парсызлары килә:

*Шәнгәрәйнең йөрәген курку алды. Күзеннәр йокы очты. Аягына чабатасын, өстенә чикмәнен киде дә, Гайшә белән комсомол егетне ияртеп, совет йортына китте.*

*Һәм шул төннән эзләү башланды* (Г. Ибраһимов).

*Кайдадыр урамнарда баррикадалар ясала, киң мәйданнар адәм үлекләре белән тулалар… Кан дәрья булып ага… Ләкин болар кайдадыр еракта. Монда тик аның куәтле шаулавы гына килә, шуңардан йөрәккә бераз шом төшә. Тик шул гына. Әмма дулкын үзе килеп җитә алмаячак* (Г. Ибраһимов).

*Аның коңгырт сакалына байтак чал кергән. Яңак буйлары һәм күз төпләрендә шактый тирән җыерчыклар сызылган. Салыныбрак торган куе кашлар астыннан карап торган яшькелт күзләре исә шактый җитез һәм хәйләлесыман ялтырый иделәр* (Ш. Камал).

Бүлүче теркәгеч мөстәкыйль җөмләләрне бәйләүдә катнашмый.

2. Ияртүче теркәгечләрдән бары *чөнки* һәм *гүя* генә мөстәкыйль җөмләләрне бәйләүдә катнаша: *ки, гәрчә, әгәр* бу функциядә йөрмиләр. Мәсәлән: *Мин үз илемнең борынгы Иделен, тын Донын, якты Арагвасын, шигъри Дим буйларын сагынам. Г ү я бу мөкатдәс елгаларның суларын түгел, хәтфә болынлыктагы чишмәләребезнең бер йотым суын да бүген мин ширбәт итеп эчәр идем* (Г. Кутуй). *Искәндәр белән мин күптәннән аерылдым. Шуннан соң берәүгә дә чыкмадым дияр идем, хата булыр. Ч ө н к и рәсемдәге кеше «ирем» булып хисаплана. Балаларым да аңа «әткәй» диләр* (Г. Кутуй).

Мөстәкыйль җөмләләрне бәйләүдә ияртүче теркәгеч сүзләр дә катнаша. Мәсәлән: *Шәһәр уртасы – цирк мәйданы үз алдына шаулап, дулкынланып торган халык диңгезенә әйләнгән иде инде. Әйтерсең башка җирдә тереклек беткән, әйтерсең зур шәһәр үзенең көнлек кайгысын, эшен ташлаган да, тарихның олы мәсьәләләрен чишәр өчен, шул мәйданга килеп тыгылган* (Г. Ибраһимов). *Тегермән канатлары ыңгырашып куйды. Арыш басуы буйлап яшел дулкыннар чапты. Ул да түгел тагын яшен ялтырап, тагын күк чатыр-чотыр итте. Каты яңгыр коеп яварга тотынды* (Н. Фәттах).

3. Мөстәкыйль җөмләләр арасында грамматик бәйләнешне белдереп, ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр дә йөри. Мәсәлән: *Озын кичләрдә Мөхәммәтгариф белән Мәмдүдә, балаларны йокларга яткырып, үзләре булачак балага исем эзләделәр. Ниһаять, дөньяда кем иң якын дус, шуның исемен кушарга булдылар. Ш у ң а к ү р ә әгәр дә кыз булса, Мәмдүдәнең Өчиледә калган иң якын ахирәт дусы Зөһрәнең исемен, ир бала булса, Гарифнең мәдрәсә дусты, аның иң якын кешесе Габдуллаҗанның исемен алырга карар кылынды* (Ә. Фәйзи). *Аның артыннан тагы берничә эшче йөгереп керде. Аннан соң тавышлар да, чыжылдау да тынды. Зур бер аждаһаны үтереп тынычланган кыяфәт белән Нигъмәт абзый, аның артыннан башкалар килеп чыктылар. Ш у л в а к ы т хуҗа өенең баскычы шыгырдап китте...* (Ә. Фәйзи). *Тикшерүче өчен хәзер мәсьәлә ачык. Моңарчы җыелган материаллар*

*буенча кочегарның гаепле булуы турында аның мие үзенә кискен караш эшләп куйган. Ш у л а й  д а  ул төп асылда болай булуга үзе риза түгел. Зур фактлар килеп чыгарлар, Миңлебаев өстенә авып барган гаепне җимереп ташларлар дип өметләнә* (Г. Ибраһимов).

4. Көттерү паузасы да мөстәкыйль җөмләләрне бәйләүдә катнаша. Мәсәлән: *Иген сукканда да Хәлимсез бер адым да атламый* (:) *Ул чүмәләдән көлтә китерешә, ул җәемгә көлтә тезешә, бер кат тәпәчләп чыккач, көлтәләрне әйләндерергә булыша. Әтисе белән әнисе чүмәлә күләгәсендә ял итәргә утыргач, Хәлим, анасының чабагачын алып, үзе дә сугып карый* (И. Гази). *Аның атасы һәрвакыт куркыныч, ләкин рәхәт итеп сөйли* (:) *Имештер, бер кешегә төн уртасында кырда тубал хәтле ут очраган. Якынрак барып караса, ни күзе белән күрсен: бөтенләй ут түгел, ә алтын, көмеш тулган бер казан тора, имеш...* (И. Гази). *Габдулла өйгә керү белән, өч олы кеше аның тирәсендә йөгереп дигәндәй йөрделәр* (:) *Зөһрә апа баздан салкын катык алып керде, каерып икмәк кисте, Нәфисә апа Габдулланы, юындырып, табынга утыртты. Сәгъди абзый аны кыстый-кыстый сыйлады* (Ә. Фәйзи).

Грамматик бәйләнешне белдерүче чаралар (*һәм, ләкин, әмма, чөнки, гүя, шунлыктан, шуңа күрә, шулай да, шуңа карамастан*) алдыннан еш кына нокта куела. Ләкин нокта яки өтер куюга гына аларның кайсы төр җөмләләрне (мөстәкыйль яки мөстәкыйль түгел) бәйләгәнлеген билгеләми. Болар, мөстәкыйль булмаган җөмләләрне бәйләп, кушма җөмлә эчендә килгәндә дә, алар алдыннан нокта куелырга мөмкин. Хикмәт шунда: бу аналитик чаралар ике җөмләне генә бәйләсәләр, кушма җөмлә төзиләр; әгәр бер группа җөмләне икенче группага, яисә бер җөмләне бер группа җөмләгә бәйләсәләр, кушма җөмлә түгел, текст барлыкка китерәләр.

Текст эчендәге бәйләүче чаралар бер җөмләне бер группа җөмләгә, бер төркем җөмләне икенче төркемгә бәйләп кенә калмыйлар, бәлки шул төркем эченә керә торган җөмләләрне дә бергә беректерәләр. Мәсәлән, түбәндәге мисалда *шунлыктан* мөнәсәбәтле сүзе аннан алда һәм соң килгән төркемнәрне үзара бәйләп кенә калмый, бәлки һәр төркем эченә кергән җөмләләрнең бер бөтенгә (текстка) оешуына да булыша:

*Сәхнәдән чыгуга, аны директор, композитор, җырчылар, сәхнә эшчеләре күтәреп алдылар.*

*– Котлыйбыз, Хәят ханым!*

*– Тамашачыларны гына түгел, Сез безне дә сихерләдегез…*

*– Сездән алган ләззәтне аңлатырга сүз җитми, – дип тойгыларын белдерергә ашыктылар.*

*Ш у н л ы к т а н, җырының халыкка барып җитү куанычыннан һәм шушындый минутта үз янында Шакирын күрә алмау кайгысыннан Хәят бер сүз дә әйтә алмады. Күз яшенә чыланган керфекләрен кулъяулыгы белән сөртә-сөртә, җавап итеп, ул елмаюлы караш кына ташлый алды* (Г. Кутуй).

**§ 349. Текст композициясе.** Синтаксис тоташ сөйләм төзелешен өйрәнеп кенә калмый, бәлки тоташ сөйләмне (текстны) дөрес итеп төзергә дә өйрәтә. Менә шуның өчен синтаксис фәнендә текстның композициясе дә игътибарсыз калдырылмый. Текстның билгеле бер эзлеклелектәге план белән оештырылуын аның композициясе дип атыйлар. О.И.Москальскаяның югарыда телгә алынган «Грамматика текста» дигән хезмәтендә әйтелгәнчә, текстның композициясе элек бары әдәбият фәнендә генә карала иде, соңга таба аерым әсәрләр, бүлекләр, параграфлар һәм абзацлар композициясе белән стилистика фәне кызыксына башлый. Кызганычка каршы, татар әдәбият белемендә һәм стилистикасында бу мәсьәләләр һаман да читтә калдырылалар. Синтаксис фәнендә дә (синтаксик бөтеннәрне өйрәнү күптән башланган булса да) текст композициясе турындагы мәсьәләнең моңа кадәр бер дә куелганы булмады.

Хәзер текст синтаксисына игътибар арткач, аның композициясен тикшерми торып, текст теориясен төзү мөмкин түгел. Чөнки текст композициясе, ягъни аның логик эзлекле бер план белән оештырылуы, текстның һәрьяклы бөтенлеген тәэмин итә, икенче төрле әйткәндә, текстны бер тема төзи алмый торган җөмләләр тезмәсеннән аера. Теге яки бу өзекне, бүлекне, кечерәк күләмле тулы әсәрләрне (хикәя, нәсер, мәкалә, мәсәл һ.б.) текст итеп тану өчен, аның, иң элек, теманы ачарлык төзек композициясе (логик эзлекле планы) булырга тиеш, шул нигездә генә текстның мәгънәви, коммуникатив, структур һәм грамматик бөтенлеге тәэмин ителә ала.

Эзлекле композиция макротекстларда гына түгел, микротекстларда да булырга тиеш. Теге яки бу текстның композицион төзелешен күрү өчен аның планын төзеп карарга кирәк. Бу – синтаксиста текст ком-

позициясен өйрәнү өчен шулай эшләнә. Ә текст төзүче (әсәр, мәкалә һ.б.ны язучы), иң элек, я күңелдән, я язма рәвештә әйтергә теләгән фикерне тыңлаучыга тәртипле итеп җиткерүнең эзлекле планын төзергә тиеш, ягъни булачак текстның композициясен булдырырга тиеш. Текстны төзү барышында алдан күз алдына китерелгән композиция тагын да шомартыла, камилләштерелә.

Төгәл, ачык, эзлекле композицияле текстка мисал итеп Г. Кутуйның «Сагыну» нәсерен алырга мөмкин. Ул – үзе бер макротекст һәм берничә микротексттан тора. Текстның төп темасы: туган илне сагыну. Композициясе: 1. а) чит җирдә дә тормышчан, матур күренешләр бар, ә) аларны күңел кабул итә алмый; 2. а) туган илнең шундый ук күренешләре, ә) аларны күңел үз итә; 3. Нәтиҗә: *Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!* Дүрт төрле күренештә шушы композиция дүрт мәртәбә кабатлана да, туган илне сагыну хисенә түбәндәге поэтик гомумиләштерү ясала.

*Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!*

*Сине сагынган саен миндә көч, дәрт арта, рухым канатлана. Чит илдә йөреп, мин ачык аңладым: кеше өчен үз иленнән дә изгерәк, үз иленнән дә кадерлерәк, үз иленнән дә гүзәлрәк ил дөньяда юк ул.*

*Сагынган саен сагынасы килә. Сагынуым шундый көчле булганга, кайтуым да ышанычлы. Кайтыр булмасам, бу кадәр сагынмас идем!*

*Сагындым, бик сагындым сине, изге туган ил!*

Мәкаләнең үз композициясе була. Мисал өчен гыйльми мәкаләнең композициясен китерергә мөмкин: 1) мәкаләнең төп эчтәлеген чагылдыра алырлык исеме, 2) фикернең гомуми куелышы һәм аны исбатлауның торышы, 3) фикернең дөреслеген фактик материаллар анализлау юлы белән раслау, 4) фикернең практикада кулланылуын күрсәтү яисә практика белән аны раслау, 5) гомуми нәтиҗә.

Гаризаның үзенә хас композициясе була: 1) мөрәҗәгать ителә торган кешенең эш урыны, хезмәте, 2) мөрәҗәгать итүченең исеме, фамилиясе, кем булуы, кайдан булуы, 3) гаризада төп сорау, 4) төп сорауны нигезләү, 5) мөрәҗәгать ителә торган кешегә мөнәсәбәт белдерү, 6) имза, 7) дата.

Кечкенә түгәрәк бөтен текстларда композиция бик ачык һәм гади була. Мәсәлән, түбәндәге мәзәкнең композициясен күзәтик.

***Башыңа төшкәч беләсең***

*Шәһәрдә укучы егет җәй көне туган авылына ялга кайткан. Атасы моңарга әйткән:*

*– Улым, безнең бригада бүген печәнгә төшә, тырма ал да минем белән болынга төшәрсең, – дигән.*

*Егетнең бер дә эшлисе килми икән.*

*– Өч елдан бирле шәһәрдә торып онытылып та беткән, нәрсә соң ул тырма? – дигән.*

*Шулай дип узып барышлый, егет өй буена түбәнгә каратып сөяп куелган тырманың тешләренә баскан. Тырма сабы, «шап» иттереп, егетнең маңгаена китереп бәргән. Егет, маңгаен угалап:*

*– Кайсы юньсезе шулай сөяп куйган бу тырманы! – дип, «оныткан» сүзен «исенә төшергән».*

Монда 1) текстның төп эчтәлеге тема итеп бирелгән, шуны ачу өчен, 2) әти белән улы арасындагы диалог, 3) улының «башына төшкән» вакыйга, 4) улының сүзләре аркылы төп нәтиҗә, мораль.

Шул рәвешчә һәрбер микротекстның һәм макротекстның үз композицион схемасы булырга тиеш.

## ТЕЗЕМ

**§ 350. Текстның бер төре буларак тезем.** Традицион синтаксиста тееземгә түбәндәге билгеләмә бирелә. Тиңдәш кисәкләре яки тиңдәш җөмләләре күп булу аркасында, бик нык җәенкеләнгән гади яки кушма җөмләгә т е з е м диләр. Текст тикшерү бурычлары яктылыгында караганда, теземнең өлешләре, бер-берсенә бик тыгыз бәйләнгәнлектән генә, бер гади яки кушма җөмлә итеп языла икән. Тезем ул барлык яктан да бик нык оешкан текст икән. Тезем рәвешендә бирелгән текстта фикер барлык дәлилләре белән хәбәр ителә. Шуңа күрә тезем күләмле эчтәлеккә ия булган фикерләрне җыйнак кына һәм укырга уңайлы итеп бирүдә бик еш кулланыла. Аны без, күбрәк, поэзиядә, сирәгрәк, прозада очратабыз.

Теземдә санау бүлеге һәм төп бүлек була. Санау бүлеге тиңдәш җөмләләр белән дә, тиңдәш кисәкләр белән дә бирелергә мөмкин. Мәсәлән:

*Һич тә күңелем ачылмаслык эчем пошса,*
*Үз-үземне күралмыйча, рухым төшсә,*
*Җәфа чиксәм, йөдәп бетсәм, бу башымны*
*Куялмыйча җанга җылы һичбер төшкә;*
*Хәсрәт соңра хәсрәт килеп алмаш-алмаш,*
*Күңелсез уй белән тәмам әйләнсә баш,*
*Күзләремдә кибеп тә җитмәгән булса*
*Хәзер генә сыгылып-сыгылып еглаган яшь, –*
*Шул вакытта мин кулыма китап алам,*
*Аның изге сәхифәләрен актарам;*
*Рәхәтләнеп китә шунда җаным-тәнем,*
*Шуннан гына дәртләремә дәрман табам*
(Г. Тукай).

дигән теземдә шарт җөмләләр тиңдәш булып килгәннәр.

*Алтын кырлар, үзәнлекләр, үрләр,*
*Кыя ташлы Идел ярлары,*
*Чәчәк үскән урман сукмаклары,*
*Каеннарның талгын шаулавы,*
*Зифа буйлы сылу камышлары,*
*Тургайларның дәртле җырлавы,*
*Кәккүкләрнең моңлы тавышлары,*
*Табигатьнең иркен сулавы –*
*Күз алдымнан китмәс һичбер вакыт,*
*Онытылмаслар гомерем буена...*
(С. Урайский).

дигән теземдә ияләр тиңдәш булып килгәннәр.

Татар телендә тезем бик борынгыдан кулланылган. Аның Орхон-Енисей язмаларында, XIII–XIX йөздә язылган әсәрләрдә бик матур үрнәкләре бар. Хәзерге татар әдәбиятында да (бигрәк тә поэзиясендә) ул бик еш кулланыла.

**§ 351. Тезем бүлекләренең урнашу тәртибе һәм интонацион үзенчәлекләре.** Бу яктан караганда, тезем өч төргә бүленә: төшмә тезем, күтәрелмә тезем һәм катнаш тезем.

Төшмә теземдә иң элек санау бүлеге, аннан соң төп бүлек килә. Санау бүлеге (мәсәлән, Г. Тукайның югарыда китерелгән «Китап»

шигыренең сигез юлы) күтәрелеп баручы интонация белән әйтелә, шуннан соң зур гына пауза ясала һәм төшеп баручы интонация белән төп бүлек укыла. Югарыда китерелгән теземнең икесе дә төшмә теземгә керәләр.

Күтәрелмә теземдә иң элек төп бүлек, аннан соң күтәрелеп баручы интонация белән санау бүлеге әйтелә. Мәсәлән:

*Ә р с е з  д и г ә н  а т ы м  т а р а л м а г а н ,*
*Т и к  а л а с ы н  а л д ы м .*
*Н и  а л д ы м :*
*Күктән – нурлар,*
*Җирдән – тәмнәр,*
*Табигатьтән моң алдым,*
*Каеннан – су,*
*Таңнардан – чык,*
*Кыңгыраудан чың алдым,*
*Әнкәемнән – якты дөнья,*
*Еллардан – көз, яз алдым,*
*Көздән – байлык,*
*Яздан – чәчәк,*
*Сөйгәнемнән наз алдым*

(И. Юзиев).

Катнаш теземдә төп бүлек санау бүлеге эчендә берничә урында кабатлана, шуңа карап интонация дә төрлечә була.

*А н т  и т ә м е н  янган учак белән*
*Утта янып пешкән нан белән,*
*Кара күктә йөзгән йолдыз белән,*
*Хәсрәт чиккән керсез җан белән;*
*А н т  и т ә м е н  көчле диңгез белән,*
*Дулкыннарын кискән җил белән,*
*Җилләргә баш имәс таулар белән.*
*Тауларны йөкләгән җил белән –*
*А н т  и т ә м е н  барысы, барысы белән*

(Ф. Бурнаш).

**§ 352. Теземнәрне төркемләү**. Санау һәм төп бүлекләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтенә һәм санау бүлегенең функциясенә карап, тезем төрләргә бүленә.

1. Санау бүлеге ияләрдән яки ия җөмләләрдән торса, тезем и я т е з е м дип атала:

*Тик караңгы төндә авыл күпереннән чыгып йөгерүем, олаучыларга очравым, алар белән адашып, бер кибән төбендә кунуыбыз, алда бер чиркәүнеңме, мәчет манарасыныңмы ялтыравы, ничектер рус зыяратына барып кереп, шунда тәреләр, кабер ташлары арасында, чыгарга юл тапмый, адашып йөрүем, ачлыктан бик артык хәлсезләнүем, аптырап, хәлсезләнеп, бер баганага сөялеп торуым, күземә нindидер кан күренүе, шуңардан куркуым – әле дә төшемдә кебек кенә исемдә тора* (Г. Ибраһимов).

*Я к ы н м и ң а : тымызык елгаларың,*
*Инешләрең, чишмә, күлләрең,*
*Чәчәк аткан алма бакчаларың,*
*Үрмәләнеп үскән гөлләрең;*
*Я к ы н м и ң а : әвен, кибәннәрең,*
*Болыннарың, иркен кырларың,*
*Томан төшкән яшел үләннәрең*
*Һәм зәңгәрсу торган урманың*
(С. Хәким).

*Нык җелек, нык буын,*
*өрекмәс, тынмас җан,*
*киң офык – киң караш,*
*суынмас кайнар кан*
*сыгылып, сыналып*
*яхшыда, яманда*
*ныгый һәм чистара*
*заманнан заманга!*
(К. Сибгат).

*Бу ныклык, бу сафлык,*
*нәфрәтләр, сөюләр,*
*җаннарның балкышы,*
*янулар, көюләр*

*күкләрдән иңгәнме,*
*кайлардан килгән ул?*

(К. Сибгат).

2. Санау бүлеге хәбәрләрдән яки хәбәр җөмләләрдән торса, тезем х ә б ә р  т е з е м була:

*Алтын, көмештән кыйбат,*
*Актык өлештән кыйбат,*
*Гәүһәр-якуттан кыйбат,*
*Бөтен шатлыктан кыйбат,*
*Энҗе-мәрҗәннән кыйбат,*
*Бөтен нәрсәңнән кыйбат –*
*Т у г а н  и л  һ ә м  т у г а н  җ и р !*

(Ш. Маннур).

3. Санау бүлеге шарт хәлләреннән яки шарт җөмләләрдән торса, тезем ш а р т  т е з е м дип атала:

*Язгы яңгыр тамчылары*
*Игеннәрнең битен юса;*
*Якты яшен камчылары*
*Илдән салкын җилне куса;*
*Басуларда машиналар*
*Күмелерлек ашлык уңса;*
*Эштә тырыш кешеләргә*
*Бәһа булса, хөрмәт булса;*
*Кичләрендә имин йортта*
*Тату гаилә гөрләп торса;*
*Бусагадан читтә сагыш*
*Сагышланып, шүрләп торса, –*
*Шатланам мин, сөенәм мин!*

(Ш. Галиев).

Шарт тезем белән М. Җәлилнең «Мин булырмын», Г. Тукайның «Китап», «Җил тавышы» һ.б. шигырьләре язылганнар.

4. Санау бүлеге кире хәлләр яки кире җөмләләр белән бирелсәләр, тезем к и р е  т е з е м дип атала.

*Күз алдымнан китмәс ул кызларның*
*Буй-сыннары, кая барсам да,*
*Гомер узган саен картайсам да,*
*Кая гына аяк бассам да*
(Н. Баян).

5. Санау бүлеге вакыт хәлләре яки вакыт җөмләләр булса, тезем в а к ы т  т е з е м дип атала:

*Карлар эрегәч,*
*Сулар йөгергәч,*
*Болын яшәреп,*
*Ямьләнеп көлгәч, –*
*Без беркөн шулай,*
*Шушы җырләргә*
*Җыйналып килдек*
*Язгы өмәгә*
(М. Җәлил).

6. Санау бүлеге урын хәлләре яки урын җөмләләр белән бирелсә, тезем у р ы н  т е з е м дип атала:

*Далалардан, кырлардан,*
*Һавалардан, сулардан,*
*Чал тауларның өстеннән,*
*Боз дәрьялар эченнән,*
*Ил чигеннән – постлардан –*
*Җ ы й н а л г а н н а р  б а т ы р л а р,*
*О р д е н л ы л а р,  а с ы л л а р,*
*К а р ш ы л а р г а  и л  б е л ә н*
*З у р  җ и ң е ш л ә р  б ә й р ә м е н*
(Ф. Бурнаш).

7. Санау бүлеге рәвеш хәлләре яки рәвеш җөмләләр белән бирелсә, тезем р ә в е ш  т е з е м дип атала:

*Тамыр җәеп назлы җилләргә,*
*Иркәләнеп язгы җилләрдә,*
*Шикәр алып ләйсән суыннан,*
*Гайрәт алып яшен утыннан,*

*Таң нурыннан алсу төс алып,*
*Кояш яктысыннан көч алып,*
*Хәтерләтеп янтарь тиземен, –*
*Үскән моның татлы йөземе!*
(К. Нәҗми).

8. Санау бүлеге сәбәп хәлләре яки сәбәп җөмләләр белән бирелсә, тезем с ә б ә п  т е з е м  дип атала:

*Начар булганмы*
*Ләкин мылтыгы,*
*Сәбәп булганмы*
*Бәхет юклыгы?*
*Әллә бик начар*
*Күргәнме күзе,*
*Әллә сәләтсез*
*Булганмы үзе?*
*Атса да төбәп,*
*Нинди җәнлеккә,*
*Киткән ядрәсе*
*Һәрвакыт читкә*
(Ә. Исхак).

9. Санау бүлеге максат хәлләре яки максат җөмләләр белән бирелсә, тезем м а к с а т  т е з е м  дип атала:

*Кайгы сөремнәрен уйдан куып,*
*Тынлык кайтсын өчен йортларга,*
*Күлен сагынып кайткан аккош булып,*
*Шатлык килсен өчен картларга;*
*Яшь сылулар, сөйгән егетләрен*
*Каршы алып капка төбендә,*
*Муенына сарылып, вәгъдәләшеп,*
*Хаклы булсын өчен үбәргә;*
*Көр тавышлар яңгырап торсын өчен*
*Мәҗлесләрдә, табын янында,*
*Җәберләнгән җирнең һәр адымын*
*Буя, иптәш, фашист канына!*
(Х. Кәрим)

10. Санау бүлеге тәмамлыклар яки тәмамлык җөмләләр белән бирелсә, тезем тәмамлык тезем дип атала:

*Хуш ис чәчкән арыш башакларын,*
*Яшел кигән бодай җирләрен,*
*Зәңгәр күзле җитен сабакларын,*
*Урманыңның кура җиләген,*
*Болыннарның печән кибәннәрен,*
*Чишмәләрнең татлы суларын,*
*Умарталы гүзәл бакчаларын,*
*Төзек матур авыл юлларын –*
*Күргән саен карап туймыйсың;*
*Син үзеңне менә шушы җирнең,*
*Әкияттәге төсле матур илнең*
*Чын хуҗасы итеп уйлыйсың*
(С. Урайский).

11. Санау бүлеге аергычлар яки аергыч җөмләләр белән бирелсә, тезем аергыч тезем дип атала:

*Ә бит бар кешеләр –*
*шәхесен ватмаган,*
*хаклыкны сатмаган,*
*вөҗданны саклаган*
(Р. Фәйзуллин).

12. Санау бүлеге аныклагычлар яки аныклагыч җөмләләр белән бирелсә, тезем аныклагыч тезем дип атала:

*Бу шәхеснең якты istәлеген*
*Йөрәгендә йөрткән һәр кеше, –*
*Шат тормышлы авыл игенчесе,*
*Атказанган шәһәр эшчесе,*
*Европаны кичкән сугышчылар,*
*Укытучы, шагыйрь, галимнәр,*
*Укучылар, мәктәп балалары,*
*Бер-бер артлы йөзләр һәм меңнәр, –*
*Бертуктаусыз килеп тора һәр көн,*
*Һәр бәйрәмдә, һәрбер еллыкта, –*

*Аның тиңсез гүзәл тормышының*
*Яшьлек таңы аткан бу йортка*
(Ә. Исхак).

13. Санау бүлеге төп бүлеккә тезү юлы белән генә бәйләнгән булса, тезем т е з ү л е  т е з е м дип атала.

*Бездә хәзер ямьле яздыр, иркәм,*
*Көн кояшлы, төннәр айлыдыр,*
*Идел буендагы бакчаларда*
*Сыерчыклар ярсып сайрыйдыр.*
*Кошлар моңы уятадыр сине,*
*Челтәр пәрдәләрне күтәреп,*
*Язгы таңны күзлисеңдер ялгыз*
*Чәчәк аткан гөлләр үтәли, –*
*Ә  б и р е д ә,  б е з  ф а ш и с т л а р  б е л ә н*
*Б у г а з л а ш к а н  у р м а н,  к ы р л а р д а.*
*К ү ң е л  ө ч е н  б е р  г е н ә  к о ш  т а  ю к*
*Я з н ы  х ә т е р л ә т е п  җ ы р л а р г а*
(Ф. Кәрим).

14. Санау бүлеге эндәш сүзләрдән торса, тезем э н д ә ш л е  т е з е м  дип атала:

*И җанымның җаны,*
*Матур ярлар яры,*
*Күзем карасы,*
*Бәгърем пәрасы,*
*Былбыл баласы,*
*Йөрәгем дәвасы, –*
*С и н  г е н ә  м и н е м*
*К о я ш л ы  к ө н е м*
(Ш. Маннур).

# ЧИТ СӨЙЛӘМЛЕ ТЕКСТ

**§ 353. Гомуми мәгълүмат.** Традицион синтаксис кулланмаларында һәм махсус тикшеренүләрдә чит сөйләмле текст текст буларак тикшерелми, бәлки аның чит сөйләм өлеше генә аерып алып өйрәнелә иде.

Хәзерге чор синтаксисларында чит сөйләм бары чит сөйләм буларак тикшерелсә дә, аның текст эчендәге урынына, башка җөмләләр белән бәйләнешенә аеруча игътибар ителә. Чөнки чит сөйләмне текстка кертү хикәяләүдә аерым җанлылык тудыра, персонажны сөйләү, уйлау ягыннан да тасвирлый.

Текст эченә килеп кергән башка кеше сүзләре чит сөйләм дип атала. Башка кеше сүзләре булып, сөйләүченең кайчандыр әйткән үз сүзләре дә килергә мөмкин. Чит сөйләм әйтелгән яки әйтелергә мөмкин булган сүзләрдән, уйлардан, тойгылардан тора.

Чит сөйләмле текст ике өлешкә бүленә: чит сөйләм һәм автор сөйләме. Чит сөйләм телдә өч төрле формада – туры сөйләм, кыек сөйләм һәм уртак сөйләм формаларында бирелә. Бу төрләрне схематик рәвештә түбәндәгечә күрсәтергә була.




## ТУРЫ СӨЙЛӘМ

**§ 354. Туры сөйләмнең үзенчәлекләре.** Үзгәртелмичә кулланылган чит сөйләм туры сөйләм дип атала. Туры сөйләм диалог, монолог, цитата дигән төрләргә бүленә.

Язма әдәби телдә, бигрәк тә матур әдәбият стилендә, туры сөйләмнең иң күп кулланылган төре – диалог. Ике яки берничә кешенең үзара сөйләшүе формасында бирелгән туры сөйләм диалог дип исемләнә. Диалог гадәттә үзенә бер кечкенә текст төзи.

Мәсәлән:

*– Сиңа кайсы якка барырга кирәк, туган? – ди урта яшьләрдәге бер ир, үзе белән янәшә торган егеткә карап.*

*– Совхозга, – дип җавап бирә егет.*

*– Анда кемең бар?*

*– Абыем.*

*– Фамилиясе?*

*– Сәлмәнов.*

*– Директормы әллә?*

*– Әйе.*

*– Ә-ә-ә, беләм...* (Г. Галиев).

*Ә инде кабинетына кергән кешеләр бер-бер артлы үзләренең аһ-зарларын сөйли, таләпләрен куя башлагач, хәлнең никадәр катлаулы булуы тагын да ныграк ачыклана төште:*

*– Цементның сыйфаты начар, маркасы туры килми.*

*– Юллар машина йөрерлек түгел, трактор белән тарттырабыз.*

*– Әзер продукция складын су баскан.*

*– Вентиляция эшләми.*

*– Эшче көчләр җитми* (Р. Вәлиев).

Беренче мисалда ике кешенең кара-каршы сөйләшүе, икенчесендә күп кешеләр сөйләме бирелгән.

Диалог эчендә аерым кеше сүзләре р е п л и к а дип йөртелә, алар мөмкин кадәр ким булалар, ягъни бары сөйләм яңалыгын белдерүче сүзләрдән генә торалар.

Персонажның үз-үзенә, башка берәүгә яисә халыкка мөрәҗәгать ителгән сөйләме м о н о л о г дип атала. Монолог туры сөйләм булсын өчен, аның янында автор сүзләре дә килергә тиеш. Автор сүзләре белән бергә ул бер текст тәшкил итә. Мәсәлән: *Нурислам, Ихтыярны бу сәер халәтеннән чыгару өчен, сүз башларга ашыкты:*

*– Мин сезне таныштырырга да онытканмын бит әле. Безнең кунагыбыз – шәһәр төзелеш идарәсе инженеры Ихтыяр Батыршин булыр. Бүгенге көндә без аның белән бер төркем консерваторларга каршы аяусыз көрәшәбез. Һәм якын киләчәктә, һичшиксез, җиңәчәкбез. Мине бу бөек җиңүләргә рухландырып торучы алиһәм – район газетасы хезмәткәре һәм дә шуннан бушаган арада минем хәләл җефетем ролен башкаручы Сәбилә ханым Фарукшина* (Р. Вәлиев).

Язма әсәрләрдән алынган туры сөйләм цитата дип атала. Мисал: *Г. Тукай: «Дөресен әйткәндә, халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул», – дип язган.* Цитата һәрчак куштырнаклар эченә алына, ә диалогларда куштырнаклар гадәттә куелмый, монологта исә алар куелырга мөмкин. Әйтелмәгән фикер туры сөйләм булып килсә, куштырнаклар куелалар.

Туры сөйләмне автор сөйләменә бәйләүчеләр булып, әйтүгә һәм уйлауга бәйләнешле фигыльләр йөри, иң активлары – *ди, дип, дигән* кебек сүзләр.

**§ 355. Туры сөйләм һәм автор сөйләме арасындагы мөнәсәбәт.** Туры сөйләм белән автор сөйләме арасында күбрәк объектлык мөнәсәбәте була, ягъни туры сөйләм автор сөйләменең тәмамлыгы функциясен үти. Мәсәлән:

*– Төнлә тау башында кемнәр йөри икән ул? – диде Галиулла* (И. Гази).

*– Соң сез анда нишлисез? – ди карт* (Ш. Камал).

*Дип* сүзе белән бәйләнгәндә, туры сөйләм автор сүзләренә карата рәвеш хәле функциясендә дә, тәмамлык функциясендә дә килә. Мәсәлән: *Ул коңгырт тышлы куен дәфтәрен алып, аның бит башына:*

*– «Беренче чор...» – дип язып куйды* (Г. Бәширов). Биредә *нәрсә дип язды?* яки *ничек дип язды?* соравын куеп була.

*– Мостафа төнге сменадамы әллә? – дип сорады Халявин* (К. Нәҗми). Биредә дә *нәрсә сорады?* яки *ничек дип сорады?* сорауларын куярга була.

*Дигән* сүзе белән бәйләнгәндә, туры сөйләм автор сөйләменә карата аергыч функциясен үти. Мәсәлән: *Якуп риза булды. Тик шулай да аның күңеленә «Дуамалрак нәрсә түгелме бу? Бөтен эшне бозып ташламасын» дигән шик килде* (И. Гази). *Ул «Мин кечкенә кеше, мине белмәсләр» кебек сүзләр сөйләде* (М. Корбангалиев).

Сирәк кенә булса да, туры сөйләм автор сүзләренә карата вакыт хәле ролендә дә килергә мөмкин. Мәсәлән:

*Якын гына, көлешә-көлешә,*
*Егет белән кыз үтте.*
*Кыз, «Төн узгач, норма тулгач»,*
*Очрашу вәгъдә итте.*

**§ 356. Туры сөйләм һәм автор сөйләменең урыннары.** Боларның үзара урнашу тәртипләре күптөрле була. Аларны гомуми күләмдә генә булса да белү стилистика һәм пунктуация өчен аеруча кирәк.

Туры сөйләмнең һәм автор сүзләренең урнашу тәртибен өч очракка бүлеп карау уңайлы.

**Беренче очрак.** Автор сөйләме дә, туры сөйләм дә бүленмичә, бөтен килеш килә. Туры сөйләм автор сөйләменнән соң урнаша:

*Габдулла әйтеп куйды:*

*– Ә нигә ул кайтмый?* (Ә. Фәйзи).

*Юлдашев дәвам итте:*

*– Сез яшь белгеч, Сафин.*

Туры сөйләм автор сүзләре алдыннан килә.

*– Кайдан таптыгыз моны? – диде Нуруллин* (А. Шамов).

*– Берсен дә качырмаска! – диде командир* (Г. Бәширов).

*– Авылыгыз тимер юлдан еракмы? – дип сорады Искәндәр* (Р. Вәлиев).

**Икенче очрак.** Туры сөйләм автор сөйләме арасына килеп керә. Мәсәлән: *Әхмәди:*

*– Башланды, егетләр, башланды! – дип башкалар артыннан йөгерде* (Г. Бәширов).

*Фәезханов,... миңа булган ихтирамын тагын да көчәйтә төшеп:*

*– Мөмкин булса, әйтегез әле, сез моны кайдан алып яздыгыз? – дип сорады* (Г. Галиев).

*Гафур сүзен дәвам итеп:*

*– Һичнинди кулъязма күргәнем юк, – диде* (К. Нәҗми).

**Өченче очрак.** Туры сөйләм автор сөйләме белән бүленә. Автор сөйләме туры сөйләмнең төрле урынына килеп керергә мөмкин. Тыныш билгеләрен дөрес кую өчен, бу урынның нәрсә белән характерлануын да белергә кирәк. Шуңа күрә бу очракта туры сөйләмне автор сөйләменнән башка һәм аның белән параллель куеп күрсәтәбез. Биредә өч очрак була: автор сөйләме туры сөйләмнең 1) тыныш билгесе куелмый яисә өтер, нокталы өтер, ике нокта куела торган; 2) нокта куела торган; 3) сорау яки өндәү (тойгы) билгесе куела торган урыннарына килеп керә ала. Шуңа күрә мисаллар өч пункт белән биреләләр.

| Автор сөйләменнән башка | Автор сөйләме белән |
| --- | --- |
| 1) *Уку кешене кеше итә.* | *«Уку, – диде ул, – кешене кеше итә».* |
| *Ниһаять, без килеп җиттек.* | *«Ниһаять, – ди ул, – без килеп җиттек».* |
| *Мин кайтырмын, ә син ашыкма.* | *«Мин кайтырмын, – ди Нуруллин, – ә син ашыкма».* |
| *Шунысы ачык: син бармаска тиеш.* | *«Шунысы ачык, – ди ул, – син бармаска тиеш».* |
| 2) *Минем эш кечкенә. Мин тимерче.* | *«Минем эш кечкенә, – ди Мостафа. – Мин тимерче»* (К. Насыйри). |
| 3) *Аптырадыңмыни, шәйтан! Давыл кузгалса, невод салдырмыйлар аны!* | *«Аптырадыңмыни, шәйтан! – диде Сафа. – Давыл кузгалса, невод салдырмыйлар аны!»* (Ш. Камал). |
| *Ә, аны әйтәсеңме? Ул кайтмады.* | *«Ә, аны әйтәсеңме? – диде Әхмәди. – Ул кайтмады»* (Г. Бәширов). |

## КЫЕК СӨЙЛӘМ

**§ 357. Кыек сөйләмнең төп үзенчәлекләре.** Үзгәртелеп кулланылган чит сөйләм кыек сөйләм дип атала. Кыек сөйләм туры сөйләмгә бик якын торырга да, аннан бик нык аерылырга да мөмкин, хәтта кайчакта җөмләдән кыек сөйләмне табып билгеләү дә кыен була. Мәсәлән: *«Ул Урта Азиядәме, Кавказ ягындамы туган», – диләр.* Бу туры сөйләмне кыек сөйләмгә төрле дәрәҗәдә үзгәртергә мөмкин: *Ул Урта Азиядәме, Кавказдамы туган янәсе.* Биредә туры сөйләмнең сүзләре дә, сүз тәртибе дә үзгәрмәгән, ләкин аның модаль төсмере үзгәргән, автор аңа ирония өстәгән, шуңа күрә ул кыек сөйләм дип танылa. Чит сөйләмне махсус өйрәнгән Х. Курбатов аны модальлек категориясенә бәйле кыек сөйләм дип атый. Аны без модаль кыек сөйләм дип алу ягында торабыз.

*Аны Урта Азиядәме, Кавказ ягындамы туган диләр.* Бу мисалдагы кыек сөйләм, туры сөйләм белән чагыштырганда, шактый үзгәргән: ия тәмамлыкка әйләнгән (*ул – аны*). Ләкин бу кыек сөйләмнең туры

сөйләмгә якын яклары күп калган әле: күп өлеше үзгәрешсез һәм туры сөйләмдәге кебек *диләр* сүзе бар. Мондый кыек сөйләмнәрне Х. Курбатов аналитик типтагы кыек сөйләм дип атый. Кыскалык өчен, аларны аналитик кыек сөйләм дип атау бик җиткән.

*Аның Урта Азиядәме, Кавказдамы туганлыгын сөйлиләр.* Бу мисалда кыек сөйләм, туры сөйләм белән чагыштырганда, бик нык үзгәргән: ия дә, хәбәр дә тәмамлыкка (*ул – аның; туган – туганлыгын*) әйләнгән. Х. Курбатов боларны синтетик типтагы кыек сөйләм дип йөртә. Без аны синтетик кыек сөйләм дип атаячакбыз.

Синтетик кыек сөйләмнәрне кайчакта аерып тану да кыен була. Мәсәлән: *«Мин заводта эшлим», – дип сөйләде Гаяз* (М. Гали) җөмләсендәге туры сөйләмне кыек сөйләмгә түбәндәгечә әйләндерсәк, аны тануы җиңел: *Гаяз үзенең заводта эшләвен әйтте.* Ә шушы ук җөмләне түбәндәгечәрәк үзгәртсәң, аннан кыек сөйләм табуы да кыен: *Гаяз үзенең заводта эшләве турында сөйләде.* Бу җөмләдәге кыек сөйләмне туры сөйләмгә дөрес әйләндерү дә мөмкин түгел. Шуңа күрә соңгы очракны кыек сөйләм дип санамау яхшырак.

Тагын бер мисал. *Вәли каралган чакта, воинский начальник, аның аркасына сугып:*

*– Молодец, брат, молодец! – диде...* (Ш. Камал).

Кыек сөйләмдә персонаж сөйләменең төп өлеше, үзгәртелсә дә, сакланырга тиеш. Мәсәлән: *Вәли каралган чакта, воинский начальник, аның аркасына сугып, Вәлинең молодец булуын кат-кат әйтте.*

Туры сөйләмгә әйләндереп карау өчен, бер сүз дә табылмаса, андый җөмләдә кыек сөйләм дә булмый. Мәсәлән: *Вәли каралган чакта, воинский начальник, аның аркасына суга-суга мактады.* Монысында кыек сөйләм юк.

**§ 358. Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерү.** Тел белән практик рәвештә эш иткәндә, туры сөйләмле җөмләләрне кыек сөйләмле җөмләләргә яки киресенчә үзгәртеп төзергә туры килә. Мондый стилистик үзгәртүләр бик күптөрле булалар. Мәсәлән, бер туры сөйләмне кыек сөйләмнең барлык төрләренә дә әйләндереп була. Туры сөйләмне модаль һәм аналитик кыек сөйләмнәргә үзгәртеп төзү бернинди кыенлык тудырмый, шуңа күрә аларны биредә махсус тикшереп тормыйбыз, туры сөйләмне синтетик кыек сөйләмгә әйләндерү үрнәкләрен һәм кыскача нәтиҗәләрен бирәбез.

Туры сөйләмне синтетик кыек сөйләмгә әйләндерүдә төп өч очрак бар.

**Беренче очрак:**

| | |
|---|---|
| 1. *Нәсимә:*<br>*– Тигәнәле кызы мин, – диде* (Ш. Камал). | *Нәсимә үзенең Тигәнәле кызы булуын әйтте.* |
| 2. *– Без әле бетермичә кайтмыйбыз, – дидем мин.* | *Мин үзебезнең әле бетермичә кайтмавыбызны әйттем.* |
| 3. *Мәдинә:*<br>*– Сез килергә тиеш, – диде.* | *Мәдинә безнең килергә тиешлекне әйтте.* |

Аермалар:

| | |
|---|---|
| 1. Ия: *мин* | *үзенең* |
| Хәбәр: *кызы* | *кызы булуын* |
| 2. Ия: *без* | *үзебезнең* |
| Хәбәр: *кайтмыйбыз* | *кайтмавыбызны* |
| 3. Ия: *сез* | *безнең* |
| Хәбәр: *килергә тиеш* | *килергә тиешлекне* |

Нәтиҗә: Хикәя җөмлә формасындагы туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндергәндә, ия иялек килешендәге тәмамлыкка әйләнә, хәбәр, исемләшеп, төшем килешен ала. Туры сөйләмнең хәбәре составында фигыль булмаса, аңа *булуын, икәнен, булганлыгын, икәнлеген* кебек сүзләр өстәлә.

**Икенче очрак:**

| | |
|---|---|
| *Ул абый әйтте:*<br>*– Сез суның аргы ягына чыгыгыз!* (Г. Бәширов) | *Ул абый безгә суның аргы ягына чыгарга кушты (боерды, үтенде).* |

Аермалар:

| | |
|---|---|
| Ия: *сез* | *безгә* |
| Хәбәр: *чыгыгыз* | *чыгарга кушты, (боерды, үтенде)* |

Боеру җөмлә булган туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндергәндә, ия юнәлеш килешендәге тәмамлыкка әйләнә, хәбәр инфинитив формасын алып, аңа *кушты*, *боерды*, *үтенде* кебек сүзләр өстәлә.

**Өченче очрак:**

| | |
|---|---|
| 1. *Айсылу:* – *Кая киттең болай, Мәрьям?* (Г. Бәширов) | *Айсылу Мәрьямнең кая китүен сорады (белеште).* |
| 2. *Биктимер:* – *Сез әле кайтасызмы? – дип сорады.* | *Биктимер безнең кайту-кайтмавыбызны сорады.* |
| 3. – *Габдулла өйдәме? – дип сорады ул.* | *Ул Габдулланың өйдәме-түгелме икәнлеге турында сорады.* |

Аермалар:

| | |
|---|---|
| 1. Ия юк. | |
| Эндәш сүз: *Мәрьям* | *Мәрьямнең* |
| Хәбәр: *киттең* | *китүен* |
| 2. Ия: *сез* | *безнең* |
| Хәбәр: *кайтасызмы* | *кайту-кайтмавыбызны* |
| 3. Ия: *Габдулла* | *Габдулланың* |
| Хәбәр: *өйдәме* | *өйдәме-түгелме икәнлеге турында* |

Сорау җөмлә формасындагы туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндергәндә, ия яки эндәш сүз, иялек килешен алып, тәмамлыкка әйләнә, хәбәр, исемләшеп, төшем килешен ала, яисә, исемләшеп, *турында (хакында)* сүзе белән килә.

## УРТАК СӨЙЛӘМ

**§ 359. Уртак сөйләмнең төп үзенчәлекләре.** Уртак сөйләм автор һәм персонаж (чит кеше) өчен уртак, ягъни уртак сөйләмне автор да, персонаж да әйтә булып чыга. Дөресрәге, персонажның уйлары, күргән-белгәннәре автор исеменнән, ләкин тулысынча яки өлешчә персонажның үз сүзләре белән, үз карашлары белән бирелә. Уртак сөйләмнең мондый үзенчәлеккә ия булуы хикәя стиленә аеруча җанлылык кертә, аның эмоциональ көчен, образлылыгын арттыра. Уртак сөйләм персонажның эчке кичерешләрен, уй-тойгыларын тасвирлауда уңай стилистик алым – сурәтләү чарасы булып санала. Шуңа күрә ул хәзерге матур әдәбиятта киң кулланыла да. Мәсәлән:

*Карчыкның соргылт күзләре сагыш белән томаланды, моңсу уйлары рәхәт истәлекләр дөньясына алып киттеләр.*

*Әйе, бу костюмны Газиз киңәшмәдән киеп кайткан иде. Һай, күңелле дә чак иде, инде дә рәхәт заманнар*

*иде! Кайтып чәй эчкәннән соң акрын гына әнә шул ян тәрәзә янына барып басты... Малайга ниндидер зур уй төшкән... Малайның күңеле урынында түгел. Хәдичә түти улындагы бу зур үзгәрешне бер карау белән сизсә дә, үзе башлап берни дә әйтмәде...* (Г. Бәширов).

Уртак сөйләм автор контекстына, гадәттә, чит сөйләм башлану турында хәбәр итүче автор сүзләреннән тыш кына килеп керә. Уртак сөйләм башланыр алдыннан яки аның азагыннан *уйлады, уйлап торды, уйланды, күз алдына китерде* һ.б.ш. сүзләр кайбер очракларда гына кулланыла.

*Каюм, китапны бер укып чыкканнан соң, бераз уйланып торды. Көтепханәдә шул мәсьәләгә карата рәтлерәк китап юк микән? Һич хәтеренә төшерә алмады. Димәк, юк. Хәер, булса да, файдасы булыр иде микән? Ул томанлыкларның ни өчен әйләнүе һәм дә зерә кызу әйләнүләренең һәм шулай ук аларның утка әверелүләренең сәбәпләрен яхшы аңлау өчен, химия составларын һәм физика законнарын белергә кирәк бит. Ә Каюмда ул як йомшаграк, хәтта бик йомшак диярлек...* (Ш. Камал).

*Күпме вакыт узгандыр, ике-өч аймы, әллә артыкмы, шул ук стена тагын телгә килде. Ничек итеп аңларга соң? Бәлки, ул бик кирәкле һәм Мостафаның хәленә ниндидер ачыклык кертүче хәбәрне тапшырадыр... Шул турыда баш ватып утырганда, Мостафаны төрмә конторасына допроска алып киттеләр* (К. Нәҗми).

Уртак сөйләмнең сүзлек составына, гомумән алганда, туры сөйләмдәге кебек үк үзенчәлекләр хас. Анда төрле-төрле эмоциональ сүзләр, кисәкчәләр һәм ымлыклар булырга мөмкин. Мәсәлән:

*Нәфисә, толым очларын бер сүтеп, бер үрә-үрә, зур коңгырт күзләре белән ап-ачык һәм тыныч кына итеп әнкәсенә карап тора.*

*Юк, Нәфисә үзендә һичбер гаеп сизми. Аның вөҗданы пакь, аның Газиз истәлегенә яисә үз намусына тузан кадәр генә дә күләгә төшергәне юк! Һич!* (Г. Бәширов).

*Ул тәрәзә канатларын ачты. Ух! Иркен бушлык! Ул саф каралҗым күк йөзе! Ул гәүһәр кисәкләре кебек ялтыраган хәтсез күп йолдызлар! – Ул шул күренешкә карап торып уйга калды...* (Ш. Камал).

## ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

Абдуллаев А.З. Сложноподчиненное предложение в современном азербайджанском языке: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. – Баку, 1963.

Абдуллаев А.З. К эволюции синтаксического строя тюркских языков // Учен. зап. Азерб. гос. ун-та. – Сер. яз. и лит., 1967. – № 1.

Абдуллаев К.М. Проблемы синтаксиса простого предложения в азербайджанском языке. – Баку, 1983.

Абдурахманов Г.А. Исследование по старотюркскому синтаксису (XI в.). – М., 1967.

Абдурахманов Г.А. Основы синтаксиса сложного предложения современного узбекского литературного языка: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. – АН Узб. ССР. – Ташкент, 1960.

Абдурахманов Х. Синтаксические особенности узбекских народных пословиц: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. – Ташкент, 1969.

Аганин Р.А. Повторы и однокоренные парные сочетания в современном турецком языке. – М., 1959.

Агишев Х.Г. Синтаксические сочетания однокоренных слов в русском и татарском языках: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1970.

Адилов М.И. Синтаксико-конструктивные повторы в азербайджанском языке // Вопросы тюркских языков и взаимоотношения их с другими языками. – Баку, 1972.

Адмони В.Г. Введение в синтаксис современного немецкого языка. – М., 1955.

Адмони В.Г. Сложноспаенное предложение в тюркских языках: (Заметки нетюрколога) // Советская тюркология. – 1982. – № 3.

Азисова М.С. Таксис в современном татарском литературном языке: дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2004. – 175 с.

Акимова Г.Н. Новые явления в синтаксическом строе современного русского языка. – Л., 1982.

Алиев У.Б. Синтаксис карачаево-балкарского языка. – М., 1973.

Алпаров Г. Сайланма хезмәтләр: Татар грамматикасы һәм гомуми тел. – Казан, 1945.

Амиров Г.С. Из сопоставительного синтаксиса русского и татарского языков: Приложение в современном русском языке сопоставительно с татарским. – Казань, 1961.

Андреев И.А. Структура простого предложения современного чувашского языка: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. – М., 1970.

Андриевская О.Б. Проблемы экспрессивного синтаксиса: (На материале английского языка). – М., 1984.

Античные теории языка и стиля. – М.-Л., 1936.

Арутюнова Н.Д. Предложение и его смысл. – М., 1976.

Архангельский А. Грамматика народно-татарского языка. – Оренбург, 1894.

Архангельский П.А. К изучению периодической речи // Русский язык в школе. – 1950. – № 3.

Асылгараев Ш.Н. Синтагматическое членение татарской речи: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1968.

Атнагулов С., Алпаров Г. Грамматика. Икенче кисәк: Синтаксис. – Казан, 1934.

Ахманова О.С., Микаэлян П.Б. Современные синтаксические теории. – М., 1963.

Ахматов И.Х. Нечленимые предложения // Исследования по карачаево-балкарскому языку. Ч. I. – Нальчик, 1977.

Ахматов И.Х. Проблемы семантического анализа простого предложения. – Нальчик, 1979.

Ахматов И.Х. Структурно-семантические модели простого предложения в современном карачаево-балкарском языке. – Нальчик, 1983.

Ахмеров К.З. Синтаксис простого предложения в башкирском языке: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. – Уфа, 1968.

Ашмарин Н.И. Опыт исследования чувашского синтаксиса, Ч. I. – Казань, 1903; Ч. II. – Симбирск, 1923.

Әхмәр К. Башкорт телендә тезмә кушма һөйләм синтаксисе. – Уфа, 1957.

Байрамова Л.К., Сафиуллина Ф.С. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. – Казань, 1989.

Балакаев М.Б. Основные вопросы синтаксиса простого предложения в современном казахском языке: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. – Алма-Ата, 1950.

Балакаев М.Б. Современный казахский язык: Синтаксис словосочетания и простого предложения. – Алма-Ата, 1959.

Балли Ш. Общая лингвистика и вопросы французского языка. – М., 1955.

Балтаева Р.М. Интонационная структура общего вопроса в современном татарском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1973.

Бангуоглу Тахсин. Tahsin Banguoљlu. Tћrkµenin Grameri. – Ankara, 1990.

Бархударов Л.С. и Колшанский Г.В. К проблеме структуры сложного предложения // Сб. статей по языкознанию: (Профессору МГУ академику В.В. Виноградову в день его 60-летия). – М., 1958.

Баскаков Н.А. Историко-типологическая характеристика структуры тюркских языков. – М., 1975.

Батманов И.А. Способы выражения синтаксических отношений в киргизском языке. – Фрунзе, 1940.

Бенвенист Э. Относительное предложение как проблема общего синтаксиса // Бенвенист Э. Общая лингвитика. – М., 1973.

Бердалиев А. Семантико-сигнификативная парадигматика и синтагматические отношения в конструкциях сложноподчиненного предложения узбекского литературного языка: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. – Ташкент, 1989.

Бердымуратов К. Придаточные предложения в каракалпакском языке и их структура // Учен. зап. каракалп. пед. ин-та. – Нукус, 1957.
Березин И.Н. Практическое руководство к изучению татарского языка Г. Махмудова // Министерство народного просвещения. – 1858. – XCVII.
Бертагаев Т.А. Синтаксис современного монгольского языка в сравнительном освещении: Простое предложение. – М., 1964.
Беседина-Невзорова В.П. Членение речи на ритмические единицы // Учен. зап. Харьковского ун-та. – Т. 101; Труды филологического факультета. – Т. 7. – 1959.
Билялова А.А. Вариантность и факультативность в татарском языке (В сопоставлении с русским и английским языками): дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2004. – 217 с.
Билялова А.А. Системно-функциональное описание факультативности как языкового феномена: на материале татарского, русского и английского языков: дис. ... д-ра филол. наук. – Казань, 2011. – 360 с.
Богородицкий В.А. Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками. – Изд. 2. – Казань, 1953.
Бондарко А.В. Грамматическая категория и контекст. – Л., 1971.
Бондарко А.В. Функциональная грамматика. – М., 1984.
Боровков А.К. Природа турецкого изафета // Акад. Н.Я. Марру. – Л., 1935.
Будагова З.И. Простое предложение в современном азербайджанском языке. – Баку, 1963.
Будде Е.Ф. Основы синтаксиса русского языка. – Казань, 1913.
Булыгина Т.В. Пражская лингвистическая школа // Основные направления структурализма. – М., 1964.
Бухтиярова Н.С. Абзац в научном и художественном тексте // Стилистико-грамматические черты научной литературы. – М., 1970.
Валгина Н.С. Синтаксис современного русского языка. – М., 1973.
Валиева Л.Г. Семантика и репрезентация каузальности в татарском литературном языке: дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2012. – 171 с.
Ванникова Ю.В. Синтаксические особенности русской речи: (Явление парцелляции). – М., 1969.
Вәлиди Җ. Татар теленең грамматикасы. – Казан, 1919.
Виноградов В.В. О категории модальности и модальных словах в русском языке // Труды ИРЯз АН СССР. – Т. 2. – М.-Л., 1950.
Виноградов В.В. Основные вопросы синтаксиса предложения: (На материале русского языка) // Вопросы грамматического строя. – М., 1955.
Виноградов В.В. Понятие системы в синтаксисе русского языка // Вопросы синтаксиса современного русского языка. – М., 1950.
Гаджиева Н.З. Основные пути развития синтаксической структуры тюркских языков. – М., 1973.
Гаджиева Н.З., Серебренников Б.А. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков: Синтаксис. – М., 1986.
Гак В.Г. Теоретическая грамматика французского языка: Синтаксис. – М., 1981.

Галкина-Федорук Е.М. Безличные предложения в современном русском языке. – М., 1958.

Галкина-Федорук Е.М., Горшкова К.Б., Шанский Н.М. Современный русский язык: синтаксис. – М.: Учпедгиз, 1958.

Галлямов Ф.Г. Лексико-грамматические особенности повторов в современном татарском языке: автореф. дис. ...канд. филол. наук. – Казань, 1983.

Галлямов Ф.Г. Синтаксис осложненного простого предложения в татарском языке. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2006. – 296 с.

69. Галлямов Ф.Г. Структурно-семантическое осложнение простого предложения в татарском языке: дис. ... д-ра филол. наук / Башкир. гос. ун-т. – Елабуга, 2007. – 398 с.

Гальперин И.Р. Текст как объект лингвистического исследования. – М., 1981.

Гамәли тел сабаклары: (Практические уроки языка). – III. – Казан, 1925.

Гиганов И. Грамматика татарского языка. – Петербург, 1801.

Гордлевский Вл. Грамматика турецкого языка: (Морфология и синтаксис). – М.,1928.

Грамматика алтайского языка, составленная членами алтайской миссии. – Казань, 1869.

Грамматика азербайджанского языка. Ч. II.: Синтаксис. – Баку, 1959. – (На азерб. яз.).

Грамматика казахского языка. Ч. II. – Алма-Ата, 1967. – (На казах. яз.).

Грамматика карачаево-балкарского языка: Фонетика, морфология, синтаксис. – Нальчик, 1976.

Грамматика современного башкирского литературного языка. – М., 1981.

Грунина Э.А. Некоторые вопросы синтаксиса сложноподчиненного предложения в современном литературном узбекском языке // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков: Синтаксис. – III. – М., 1961.

Девкин В.Д. Диалог: Немецкая разговорная речь. – М., 1981.

Демесинова Н.Х. Развитие синтаксиса современного казахского языка. – Алма-Ата, 1974.

Дикушина О.И. Какой единицей является синтагма? // Ученые зап. ЛГУ. – № 283. – Серия филол. наук. – Вып. 56. – 1961.

Дмитриев Н.К. Строй турецкого языка. – Ленинград, 1939.

Доблаев О.П. Логико-психологический анализ текста. – Саратов, 1969.

Дьорфер. Doerfer G. Рецензия на книгу Д.Фокоша-Фукса «Rolle der Syntax in der Frage nach Sprachverwandschaft» // Ural-altaische Jahrbücher. – Bd. 36. – 1965.

Җәләй Л. Гади һәм кушма җөмлә төшенчәсен аныклауга карата // Совет мәктәбе. – 1951. – № 5.

Зайнетдинов М.Ф. Русские предложные глагольные словосочетания с именами существительными и их эквиваленты в татарском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1972.

Закиев М.З. Синтаксический строй татарского языка. – Казань, 1963.

Закиев М.З., Зиннатуллина К.З., Ибрагимов С.М. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. Часть III.: Сложное предложение. – Казань, 1977.

Закиев М.З., Сафиуллина Ф.С. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. Ч. I: Простое предложение. – Казань, 1977.

Закиев М.З., Сафиуллина Ф.С. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. Ч. II: Простое предложение. – Казань, 1977.

Закиев М.З. Проблемы структуры простого предложения татарского языка: Учебное пособие. – Казань, 1987.

Закиев М.З. Татарская грамматика. III том: Синтаксис. – Казань, 1992; 1995.

Зәкиев М.З. Татар теле: Учебник для 7–8 кл. – 10-е издание. – Казань, 1985.

Зәкиев М.З. Татар синтаксисы: Югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2005. – 399 б.

Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. Синтаксис. – Казан, 1958.

Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле синтаксисы. – Казан, 1963.

Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле: синтаксис. – Казан, 1966.

Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле: Синтаксис: Студентлар һәм укытучылар өчен. – Казан, 1974.

Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле синтаксисы һәм пунктуациясе. – Казан, 1984.

Зиннатуллина К.З. Залоги глагола в современном татарском литрературном языке. – Казань, 1969.

Золотова Г.А. О регулярных реализациях моделей предложения // Вопросы языкознания. – 1969. – № 1.

Золотова Г.А. Очерк функционального синтаксиса русского языка. – М., 1973.

Ибрагимова М.Ю. Ирреальная модальность и средства ее передачи в татарском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1975.

Ибраһимов Г. Татар нәхүе. – Казань, 1911.

Ибраһимов С.М. Татар телендә аналитик төзелмәләр. – Казан, 1964.

Ибраһимов С.М. Татар телендә синтаксик синонимнар. – Казан, 1976.

Ибраһимов С.М. Синтаксик стилистика. – Казан, 1989.

Иванов М. Татарская грамматика. – Казань, 1842.

Иванов С.Н. К проблеме придаточных предложений в тюркских языках: (Изъяснительные причастные конструкции в узбекском языке и вопрос о трансформациях) // Тюркологический сборник 1977 г. – М., 1981.

Илия Л.И. Синтаксис современного французского языка. – М., 1962.

Иманаев Ш. Татар теленең нәхү вә сарыфы. – Казан, 1910.

Исследования по синтаксису тюркских языков: (Сборник статей) / Отв. редактор Убрятова Е.И. – М., 1962.

Казем-Бек М.А. Общая грамматика турецко-татарского языка. – Казань, 1846.

Кандинский Б.С. Целый текст, как интонационная структура // Ученые записки МГПИИЯ. – Т. 42. – М., 1968.

Киекбаев Дж. Г. Башкорт телендә периодтар // Башкортстан укытусыһы. – 1953. – № 3.

Колосова Т.А., Черемисина М.И. О терминах и понятиях описания семантики синтаксических единиц // Синтаксическая и лексическая семантика. – Новосибирск, 1986.

Колшанский Г.В. Логика и структура языка. – М., 1965.
Кононов А.Н. Грамматика современного турецкого литературного языка. – М.-Л., 1956.
Кононов А.Н. О сложноподчиненном бессоюзном предложении в турецком языке // Краткие сообщения ин-та востоковедения АН СССР. – 22. – 1956.
Копнин П.В. Природа суждения и формы выражения его в языке // Мышление и язык / Под ред. Д.П.Горского. – М., 1957.
Корбангалиев М., Бәдигъ Х. Ана теле нәхүе. – Казан, 1919.
Кордабаев Т.Р. Синтаксис казахского языка на материале XVI–XX веков. – Алма-Ата, 1967.
Котвич В.В. Исследования по алтайским языкам. – М., 1962.
Корш Е.Ф. Способы относительного подчинения. – М., 1877.
Курбатов Х. Татар теленең синтаксис һәм стилистика мәсьәләләре. – Казан, 1956.
Курилович Е. О методах внутренней реконструкции // Новое в лингвистике. – Вып. 4. – М., 1965.
Лингвистика текста: Материалы научной конференции. – М., 1974.
Ломтев Т.П. Структура предложения в современном русском языке. – М., 1979.
Майзель С.С. Изафет в турецком языке. – М.-Л., 1957.
Максуди Һ. Төрки нәхүе. – Казан, 1910.
Мартине А. Структурные вариации в языке // Новое в лингвистике. – Вып. 4. – М., 1965.
Мартынов В.В. Категории языка. – М., 1982.
Матезиус В. О так называемом актуальном членении предложения // Пражский лингвистический кружок. – М., 1967.
Махмудов М. Практическое руководство к изучению татарского языка. – Казань, 1857.
Махмудов Н.М. Семантико-синтаксическая ассиметрия в простом предложении узбекского языка: автореф. дис. ...д-ра филол. наук. – Ташкент, 1984.
Мелиоранский П.М. Краткая грамматика казак-киргизского языка. II: Синтаксис. – СПб., 1897.
Мещанинов И.И. Члены предложения и части речи. – М.-Л., 1945.
Москальская О.И. Грамматика текста. – М., 1981.
Москальская О.И. Проблемы системного описания синтаксиса. – М., 1974.
Мостафа Ә. Төрки нәхүе. – Казан, 1914.
Муасир Азәрбајҗан дили. III чилд: Синтаксис. – Бакы, 1981.
Мусаев К. О глагольно-именных конструкциях в современном казахском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – М., 1956.
Мусаев К.М. Грамматика караимского языка. – М., 1956.
Набиуллина Г.А. Синтаксис сложного предложения в татарских пословицах: По трехтомному сборнику Н. Исанбета «Татар халык мәкальләре»: дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2002. – 262 с.
Насилов В.М. Аффиксы включения // Вопросы языка и литературы стран Востока. – М., 1958.

Насилов Д.М. Проблемы тюркской аспектологии: Акциональность. – Л., 1989.

Насыри К. Краткая татарская грамматика, изложенная в примерах. – Казань, 1860.

Насыйри К. Әнмүзәҗ. – Казан, 1895.

Нугайбәк Г. Төрлек. – Казан, 1911.

Общее языкознание: Внутренняя структура языка. – М., 1972.

Падучева Е.В. О семантике синтаксиса. – М., 1974.

Падучева Е.В. Структура абзаца // Труды по знаковым системам. – Вып. 2. – Тарту, 1965.

Панфилов В.З. Взаимоотношение языка и мышления. – М., 1971.

Панфилов В.З. Грамматика и логика. – М.-Л., 1963.

Панфилов В.З. Роль модальности в конструировании предложения и суждения // Вопросы языкознания. – 1977. – № 4.

Петерсон М.Н. Очерк синтаксиса русского языка. – М., 1923.

Пешковский А.М. Русский синтаксис в научном освещении. – М., 1956.

Поварисов С.Ш. Сравнение в татарском языке: (В лексико-грамматическом и стилистическом планах): автореф. дис. ...канд. филол. наук. – Уфа, 1965.

Покровская Л.А. Синтаксис гагаузского языка в сравнительном освещении. – М., 1978.

Попова И.А. Неполные предложения в современном русском языке // Труды Ин-та языкознания. – Т. 2. – 1953.

Поспелов Н.С. О грамматической природе сложного предложения // Вопросы синтаксиса современного русского языка. – М., 1950.

Поспелов Н.С. Проблема сложного синтаксического целого в современном русском языке // Уч. зап. МГУ. – Вып. 137. – Труды кафедры русского языка, кн. 2. – 1948.

Поцелуевский А.П. Основы синтаксиса туркменского литературного языка. – Ашхабад, 1943.

Распопов И.П. Актуальное членение предложения. – Уфа, 1961.

Распопов И.П. Строение простого предложения в современном русском языке. – М., 1970.

Расулов Р. Глаголы состояния в узбекском языке и их валентность: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. – Ташкент, 1989.

Рахимова Л.М. Исследование аналитических конструкций в грамматиках татарского языка XX века: дис. … канд. филол. наук. – Казань, 2001. – 210 с.

Рахматуллина Л.Л. Сложноподчиненные предложения с придаточным времени в башкирском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Уфа, 1981.

Руднев А.Г. Синтаксис осложненного предложения. – М., 1959.

Русская грамматика. 2.: Синтаксис. – Прага, 1979.

Русская грамматика. Том II: Синтаксис. – АН СССР. Институт русского языка. – М., 1982.

Сабиров К. Татар телендә тыныш билгеләре. Татгосиздат, Казан, 1956,

Сагдиева Р.К. Аффиксы как средства выражения конкретизирующих отношений в татарском языке: дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2000.

Саитбатталов Г. Синтаксис сложного предложения башкирского языка. – Уфа, 1961. – (На баш. яз.).

Санжеев Г.Д. Синтаксис бурят-монгольского языка. – Улан-Удэ, 1940.

Сартбаев К. Некоторые спорные вопросы сложноподчиненного предложения киргизского языка // Труды ин-та языка и лит-ры АН Кирг. ССР. – Вып. 6. – 1956.

Сауранбаев Н.Т. Основные способы связи составных частей в сложноподчиненном предложении // Вопросы грамматики тюркских языков. – Алма-Ата, 1958.

Сафиуллина Ф.С. Развитие синтаксического строя татарского языка в советский период. – Казань, 1990.

Сафиуллина Ф.С. Развитие синтаксического строя татарского литературного языка, XX в.: дис. ... д-ра филол. наук в форме науч. докл. – Казань, 2000. – 116 с.

Сафиуллина Ф.С. Синтаксис татарской разговорной речи. – Казань, 1978.

Сафиуллина Ф.С. Соотношение актуального и грамматического членений предложения и словорасположение в татарском языке // Татар тел белеме мәсьәләләре. Бишенче китап. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1972. – Б. 43–85

Сафиуллина Ф.С. Татар әдәби телендә өстәлмә конструкцияләр // Татар тел белеме мәсьәләләре. Дүртенче китап. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1972. – Б. 61–76.

Сафиуллина Ф.С. Татар телендә сүз тәртибе. – Казан, 1974.

Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше. – Казан, 1993.

Сафиуллина Ф.С. Учет актуального членения предложения при переводе с русского языка на татарский // Татар тел белеме мәсьәләләре. Бишенче китап. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1972. – Б. 22–42.

Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. – 2 басма. – Казан: Мәгариф, 2002, 2006.

Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле: Лексикология, фразеология, фонетика, графика һәм орфография, орфоэпия, сүз ясалышы, морфология, синтаксис. – Казан, 1994.

Сәгъди Г. Телебез нәхүе. – Казан, 1914.

Севортян Э.В. Некоторые вопросы сложноподчиненного предложения в тюркских языках // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. Т. III: Синтаксис. – М., 1961.

Сепир Эд. Язык: Введение в изучение речи. – М.-Л., 1934.

Серебренников Б.А., Гаджиева Н.З. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. – Баку, 1979.

Сибагатов Р.Г. Основные признаки предложения. – Уфа, 1980.

Сибагатов Р.Г. Теория предикативности: (На материале татарского языка). – Саратов, 1984.

Ситдикова Ф.Б. Способы передачи имплицитной информации в татарском литературном языке: дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2007. – 200 с.

Смирницкий А.И. Синтаксис английского языка. – М., 1957.

Современный татарский литературный язык. Лексикология, фонетика, морфология. М.: Наука, 1969.

Современный татарский литературный язык: Синтаксис: (Авторы: синтаксиса – М.З. Закиев, форм передачи чужой речи – Х.Р. Курбатов). – М., 1971.

Современный узбекский литературный язык. Ч. II: Синтаксис. – Ташкент, 1966. – (На узб. яз).

Современный уйгурский язык. Ч. II: Морфология и синтаксис. – Алма-Ата, 1960. – (На уйг. яз).

Соегов М. Развитие синтаксической системы туркменского литературного языка в советскую эпоху. – Ашхабад, 1991.

Таванец П.В. Суждение и его виды. – М., 1953.

Тенишев Э.Р. Строй саларского языка. – М., 1976.

Тугушева Л.Ю. О конструктивных особенностях определительных словосочетаний в татарском языке // Вопросы грамматики: (К 75-летию акад. И.И. Мещанинова). – М.-Л., 1960.

Туркмен дилиниң грамматикасы. II бөлүм: Синтаксис словосочетания и простого предложения. – Ашхабад, 1977.

Тыбыкова А.Т. Притяжательные словосочетания алтайского языка, построенные по схеме третьего изафета // Синтаксическая и лексическая семантика. – Новосибирск, 1986.

Убрятова Е.И. Исследования по синтаксису якутского языка. Ч. I: Простое предложение. – М., 1950.

Убрятова Е.И. Исследования по синтаксису якутского языка: Сложное предложение. – Новосибирск, 1976.

Уринбаев Б. Синтаксический строй узбекской разговорной речи. – Ташкент, 1978.

Фатихов Ә.Х. Башкорт һәм татар телләрендә кушма һүйләмдәрзең кайһы бер үзенсәлектәре. – Өфө, 1962.

Фәезханов Габделгалләм. Татар телигә кыскача гыйльми сарыф. – Казан, 1887.

Фейзханов Х. Краткая учебная грамматика татарского языка. – СПб., 1862.

Фигуровский И.А. От синтаксиса отдельного предложения к синтаксису целого текста // Русский язык в школе. – № 3. – 1948.

Фокош-Фукс. Fokos-Fuchs D.R. Rolle der Syntax in der Frage nach Spachverwandschaft. – Wiesbaden, 1962.

Халилов А.А. Синтаксическая роль указательных местоимений в азербайджанском и татарском языках: автореф. дис. ...канд. филол. наук. – Казань, 1974.

Хальфин И. Азбука и грамматика татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов. – Казань, 1809.

Хангильдин В.Н. Татар теле грамматикасы. – Казань, 1959.

Харисова Н.Р. Глагольно-глагольные словосочетания в современном татарском литературном языке: дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2004. – 209 с.

Чариев А. Синтаксико-семантические признаки родительного падежа в узбекском и английском языках. – Ташкент, 1990.

Шакирова Н.Х. Структурно-семантические модели многочленных смешанных сложных предложений в современном татарском литературном языке: дис. ... канд. филол. наук. – Тобольск, 2006. – 166 с.

Шәйхразиева З.В., Максимов Н.В. Кушма җөмлә синтаксисы: күнегүләр: югары уку йортлары студентлары өчен. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 109 с.

Шведова Н.Ю. Структурные схемы предложения и их регулярные реализации // Грамматика современного русского языка. – М., 1970.

Ширалиев М.Ш. Проблема сложноподчиненного предложения // Вопросы грамматики тюркских языков. – Алма-Ата, 1958.

Ширалиев М.Ш. Сложноподчиненные предложения в азербайджанском языке // Вопросы языкознания. – 1956. – № 1.

Шотт. Schott W. Versuch uber die tatarischen Sprachen. – Berlin, 1830.

Щербак А.М. Грамматика староузбекского языка. – М.-Л., 1962.

Энгельс Ф. Анти-Дюринг. – М., 1953.

Юлдашев А.А. Соотношение деепричастных и личных форм глагола в тюркских языках. – М., 1977.

Юсупов Р.А. Тәрҗемә һәм тел культурасы. – Казан, 1978.

Янсаева Л.А. Диалектный синтаксис татарского языка: простое предложение: дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2008. – 204 с.

Ярцева В.Н. Контрастивная грамматика. – М., 1981.

## ЭЧТӘЛЕК

**СҮЗ БАШЫ** . . . . . . . . . . 5
**КЕРЕШ** . . . . . . . . . . 7
***Сөйләм төзелеше системасы турындагы фән буларак синтаксис*** . 7
§ 1. Синтаксис һәм аның төп өйрәнү объекты . . . . . . . . . . 7
§ 2. Сөйләм, фикер, әйтү максаты, чынбарлык, сөйләүче һәм тыңлаучы . . . . . . . . . . 8
§ 3. Синтаксис һәм логика, сөйләм һәм фикерләү арасында мөнәсәбәт . . . . . . . . . . 11
§ 4. Сөйләмнең төп үзенчәлеге: хәбәрлек һәм модальлек . . . . . . 13
§ 5. Сөйләм берәмлекләре . . . . . . . . . . 14
§ 6. Җөмләнең төп үзенчәлеге булган хәбәрлек һәм модальлекнең белдерелүе . . . . . . . . . . 15
§ 7. Синтаксис фәнендә төрле юнәлешләр . . . . . . . . . . 17
***Татар синтаксис фәненең кыскача тарихы*** . . . . . . . . . . 19
§ 8. Милләт формалашу чорында татар синтаксисы фәне . . . . . 19
§ 9. Милләт формалашкач, синтаксис фәненең үсеше . . . . . . . 24
§ 10. Милли күтәрелеш елларында татар синтаксисы фәне . . . . 27
§ 11. Бердәм совет халкын төзергә омтылу чорында татар синтаксисы фәне . . . . . . . . . . 27
§ 12. Татар синтаксисының гыйльми-методик кулланмалар, монографияләр һәм академик грамматикалар төзү барышында үсеше . . . . . . . . . . 38
**ГАДИ ҖӨМЛӘ СИНТАКСИСЫ** . . . . . . . . . . 43
§ 13. «Гади җөмлә» бүлекләре турында гомуми мәгълүмат . . . . 43
***Интонация һәм аның сөйләмдәге роле*** . . . . . . . . . . 43
§ 14. Интонация турында гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . 43
§ 15. Фраза басымы . . . . . . . . . . 44
§ 16. Пауза . . . . . . . . . . 44
§ 17. Логик басым . . . . . . . . . . 44
§ 18. Тойгы басымы . . . . . . . . . . 44
§ 19. Сөйләм көе . . . . . . . . . . 45
§ 20. Интонациянең башка төрләре . . . . . . . . . . 46

**Җөмләдә сүзләр бәйләнеше** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
§ 21. Сүзләрнең үзара бәйләнеш төрләре һәм аларның сөйләм оештырудагы рольләре . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
§ 22. Хәбәрлекле мөнәсәбәтне белдерүче чаралар . . . . . . . . . . 49
§ 23. Төгәлләүле мөнәсәбәтне белдерүче чаралар . . . . . . . . . . 50
§ 24. Аныклаулы мөнәсәбәтне белдерүче чаралар . . . . . . . . . . 53
§ 25 Ярашу, башкарылу, янәшәлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
§ 26 Тезүле бәйләнешне белдерүче чаралар . . . . . . . . . . . . 55
§ 27 Сүзләр бәйләнешен өйрәнү тәртибе . . . . . . . . . . . . . . 56
***Сүзтезмә*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
§ 28. Сүзтезмә турында гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . 57
§ 29. Сүзтезмәләрне өйрәнү тарихыннан . . . . . . . . . . . . . . 58
§ 30. Сүзтезмәләрнең төрләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
§ 31. Өйрәнү бурычларыннан чыгып сүзтезмәләрне төркемләү . . 60
Фигыль сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
Исемле фигыль сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
§ 32 Исемле фигыль сүзтезмәләрдә ияртүче кисәкләр . . . . . . 61
Фигыльнең исемне төрле кушымчалар аша ияртүе нәтиҗәсендә ясалган сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . 61
§ 33. Бәйләүче чара – *-ны/-не* . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
§ 34. Бәйләүче чара – янәшә тору яки лексик мәгънә . . . . . . 62
§ 35. Бәйләүче чара – *-га/-гә* . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
§ 36. Бәйләүче чара – *-дан/-дән/-тан/-тән/-нан/-нән* . . . . . . 63
§ 37. Бәйләүче чара – *-да/-дә/-та/-тә* . . . . . . . . . . . . 64
Фигыльнең исемне төрле ярдәмлекләр аша ияртүе нәтиҗәсендә ясалган сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . 64
§ 38. Бәйләүче чара – *белән* бәйлеге . . . . . . . . . . . . . 64
§ 39. Бәйләүче чара – *өчен* бәйлеге . . . . . . . . . . . . . 64
§ 40. Бәйләүче чара – *кебек, шикелле, төсле* яки *сыман* бәйлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
§ 41. Бәйләүче чара – *кадәр, хәтле, тикле* яки *чаклы* бәйлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
§ 42. Бәйләүче чара – башка төр бәйлекләр . . . . . . . . . . 65
§ 43. Бәйләүче чара – төрле ярдәмлекләр . . . . . . . . . . . 66
Санлы фигыль сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
§ 44. Бу төр сүзтезмәләрнең төп үзенчәлекләре . . . . . . . . . 67
Рәвешле һәм сыйфатлы фигыль сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . 68
§ 45. Бу төр сүзтезмәләрнең төп үзенчәлекләре . . . . . . . . . 68
Фигыльле фигыль сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
§ 46. Хәл фигыльле фигыль сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . 69
§ 47. Шарт фигыльле фигыль сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . 69

§ 48. Исем фигыльле һәм инфинитивлы фигыль сүзтезмәләр . . 70
§ 49. Сыйфат фигыльле фигыль сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . 70
Исем сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Исемле исем сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
§ 50. Исемнең исемгә иялек килеш аша ияртүеннән ясалган сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
§ 51. Исемнең исемгә янәшә тору һәм тартым кушымчасы аша ияртүеннән ясалган сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . 71
§ 52. Исемнең исемне янәшә тору чарасы аша ияртүеннән ясалган сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
§ 53. Исемнең исемне башка чаралар аша ияртүеннән ясалган сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Сыйфатлы һәм рәвешле исем сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . 73
§ 54. Ияртүче кисәге төп сыйфат яки төп рәвеш булган исем сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
§ 55. Ияртүче кисәге ясалма сыйфат һәм ясалма рәвеш булган исем сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Санлы исем сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
§ 56. Санлы исем сүзтезмәләрнең төп үзенчәлекләре . . . . . . 74
Фигыльле исем сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
§ 57. Сыйфат фигыльле һәм инфинитивлы исем сүзтезмәләр . 74
Хәбәрлек сүзле исем сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
§ 58. Бу төр сүзтезмәләрнең кайбер үзенчәлекләре . . . . . . . 75
Сыйфат сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
Исемле сыйфат сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
§ 59. Сыйфатның исемне юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килеше кушымчалары аша ияртүеннән ясалган сүзтезмәләр . . 75
§ 60. Сыйфатның исемне ярдәмлекләр аша ияртүе нәтиҗәсендә ясалган сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . 75
Рәвешле сыйфат сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
§ 61. Бу төр сүзтезмәләренең үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . 76
Фигыльле сыйфат сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
§ 62. Бу төр сүзтезмәләренең үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . 76
Алмашлык сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
§ 63. Алмашлык сүзтезмәләренең үзенчәлекләре . . . . . . . . 76
Сан сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
§ 64. Бу төр сүзтезмәләренең үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . 77
Рәвеш сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
§ 65. Рәвеш сүзтезмәләрнең үзенчәлеге . . . . . . . . . . . . . . 77
Хәбәрлек сүз сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
§ 66. Бу төр сүзтезмәләренең үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . 77

Сүзтезмәләргә анализ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
§ 67. Сүзтезмәләрне җөмләдән аерып алу һәм анализлау алымнары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Сүзтезмәләрнең семантик төркемнәре . . . . . . . . . . . 80
§ 68. Гомуми мәгълүмат һәм семантик төркемнәр . . . . . . . 80
**Җөмлә кисәкләре** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 89
§ 69. Җөмлә кисәкләре турында гомуми мәгълүмат . . . . . . 89
***Логик-грамматик кисәкләр*** . . . . . . . . . . . . . . . . 90
§ 70. Логик-грамматик кисәкләр турындагы өйрәтмәнең барлыкка килүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
§ 71. Татар телендә җөмлә кисәкләре . . . . . . . . . . . . . 92
Баш кисәкләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
§ 72. Баш кисәкләр турында гомуми мәгълүмат . . . . . . . 93
Ике составлы җөмләдә баш кисәкләр . . . . . . . . . . . 94
Ия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94
§ 73. Ия турында гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . 94
§ 74. Иянең төп мәгънәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94
§ 75. Иянең бирелеше һәм аның төрләре . . . . . . . . . . 95
Хәбәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
§ 76. Хәбәр турында гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . 96
Фигыль хәбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Гади фигыль хәбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
§ 77. Хикәя фигыльләр белән бирелгән гади хәбәрләр . . . 97
§ 78. Боерык фигыльләр белән бирелгән хәбәрләр . . . . . 98
§ 79. *-ачак* һәм *-ган* формасындагы фигыльләр белән бирелгән хәбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99
§ 80. Шарт һәм теләк фигыльләр белән бирелгән хәбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100
§ 81. Дәрәҗә формасындагы фигыльләр белән бирелгән хәбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
§ 82. Төрле юнәлештәге фигыльләр белән бирелгән хәбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
Тезмә фигыль хәбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
§ 83. Тезмә фигыль хәбәрләрнең бирелеше . . . . . . . . 103
Кушма фигыль хәбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Сөйләүченең процесска мөнәсәбәтен (модаль мәгънә) белдерүче хәбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
§ 84. Боеру, үтенүне белдерүче кушма хәбәрләр . . . . . 104
§ 85. Теләкне белдерүче кушма хәбәрләр . . . . . . . . . 105
§ 86. Ниятләүне белдерүче кушма хәбәрләр . . . . . . . 105
§ 87. Шартны белдерүче кушма хәбәрләр . . . . . . . . 106

§ 88. Үкенүне белдерүче кушма хәбәрләр . . . . . . . 106
§ 89. Иронияне белдерүче кушма хәбәрләр . . . . . . 106
§ 90. Мөмкинлекне белдерүче кушма хәбәрләр . . . . . 106
§ 91. Гаҗәпләнүне, икеләнүне белдерүче кушма хәбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
§ 92. Ихтималны белдерүче кушма хәбәрләр . . . . . . 107
§ 93. Сынауны белдерүче кушма хәбәрләр . . . . . . . 107
§ 94. Хикәяләүне белдерүче кушма хәбәрләр . . . . . . 107
Процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә үтәлүен белдерүче кушма фигыль хәбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
§ 95. Процессның башлану дәрәҗәсен белдерүче кушма хәбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
§ 96. Процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә дәвам итүен белдерүче кушма хәбәрләр . . . . . . . . . . . . 109
§ 97. Процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә тәмамлануын белдерүче кушма хәбәрләр . . . . . . . . 111
Заман белдерүче кушма фигыль хәбәрләр . . . . . . . . 113
§ 98. Бу төр хәбәрләрнең үзенчәлекләре . . . . . . . . . 113
Эзлекле яки параллель процессларны белдерүче кушма фигыль хәбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
§ 99. Бу төр хәбәрләрнең үзенчәлекләре . . . . . . . . . 114
Исем хәбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
Гади исем хәбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
§ 100. Гади исем хәбәрләрнең бирелеше һәм мәгънәләре . 114
§ 101. Хәбәрлек сүзләр белән бирелгән хәбәрләр . . . . . 115
Тезмә исем хәбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
§ 102. Тезмә исем хәбәрләрнең бирелеше . . . . . . . . 116
Кушма исем хәбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
§ 103. Кушма исем хәбәрнең төп мәгънәләре һәм бирелеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Ия белән хәбәр арасында бәйләнеш һәм аны белдерүче чаралар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
§ 104. Фигыль хәбәрнең ия белән ярашуы . . . . . . . 117
§ 105. Исем хәбәрнең ия белән ярашуы . . . . . . . . . 118
§ 106. Хәбәрнең ия белән санда ярашуы . . . . . . . . . 119
§ 107. Хәбәрнең тиңдәш ияләр белән ярашуы . . . . . . 120
**Бер составлы җөмләләрдә** баш кисәкләр . . . . . . . . . 120
§ 108. Бер составлы җөмләнең баш кисәге турында гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
Иясез җөмлә (фигыль җөмлә) . . . . . . . . . . . . . . . 122
Билгеле үтәүчеле җөмлә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122

§ 109. Билгеле үтәүчеле җөмләнең гомуми үзенчәлекләре . 122
§ 110. Баш кисәге бары инфинитив белән генә бирелгән бер составлы җөмлә (инфинитив җөмлә) . . . 123
§ 111. Баш кисәге инфинитив һәм төрле ярдәмлек сүзләр белән бирелгән бер составлы җөмлә (инфинитив җөмлә) . . . 124
§ 112. Баш кисәге сыйфат фигыль булган бер составлы җөмләләр . . . 125
§ 113. Баш кисәге исем фигыль булган бер составлы җөмләләр . . . 127
§ 114. Баш кисәге төшем яки кайтым юнәлешендәге фигыль булган бер составлы җөмләләр . . . 127
Билгесез үтәүчеле җөмлә . . . 128
§ 115. Билгесез үтәүчеле, гомуми үтәүчеле, үтәүчесез җөмләләр турында . . . 128
§ 116. Билгесез үтәүчеле җөмләнең баш кисәкләре . . . 129
Атау җөмләләр . . . 131
§ 117. Атау җөмләләрнең төп үзенчәлекләре . . . 131
Сүз җөмләләр . . . 134
§ 118. Сүз җөмләләрнең төп үзенчәлекләре . . . 134
Иярчен кисәкләр . . . 135
§ 119. Гомуми мәгълүмат . . . 135
Аергыч . . . 137
§ 120. Гомуми мәгълүмат . . . 137
Исем белән бирелгән аергычлар . . . 137
§ 121. Аерылмышка иялек килеше һәм тартым кушымчасы ярдәмендә ияргән аергыч . . . 137
§ 122. Аерылмышка янәшә тору һәм тартым кушымчасы ярдәмендә ияргән аергыч . . . 139
§ 123. Аерылмышка янәшә тору чарасы аша бәйләнгән аергыч . . . 140
§ 124. Аерылмышка чыгыш килеше кушымчасы аша ияргән аергыч . . . 140
§ 125. Аерылмышка төрле ярдәмлекләр аша ияргән аергыч . . . 140
Сыйфатлар, рәвешләр, саннар, хәбәрлек сүзләр белән бирелгән аергычлар . . . 142
§ 126. Ясалма сыйфатлар һәм ясалма рәвешләр белән бирелгән аергычлар . . . 142
§ 127. Төп сыйфат һәм рәвешләр белән бирелгән аергычлар . . . 143

§ 128. Саннар белән бирелгән аергычлар . . . . . . . . . 143
§ 129. Хәбәрлек сүзләр белән бирелгән аергычлар . . . . 144
Фигыльләр белән бирелгән аергычлар . . . . . . . . . . 144
§ 130. Сыйфат фигыль белән бирелгән аергычлар . . . . 144
§ 131. Инфинитив белән бирелгән аергыч . . . . . . . . 144
Тәмамлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
§ 132. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
Туры тәмамлыклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
§ 133. Ияртүче кисәккә төшем килеше формасы аша бәйләнгән туры тәмамлыклар . . . . . . . . . . . . . . 145
§ 134. Ияртүче кисәккә янәшә тору чарасы аша бәйләнгән туры тәмамлыклар . . . . . . . . . . . . . . 146
§ 135. Ияртүче кисәккә чыгыш килеше һәм кайбер бәйлекләр аша бәйләнгән туры тәмамлыклар . . . . . . 146
Кыек тәмамлыклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
§ 136. Үзенә процесс турыдан-туры кагылмаган объектны белдерүче кыек тәмамлыклар . . . . . . . . . . 147
§ 137. Үтәүчене яки нинди дә булса хәлне кичерүче затны (әйберне) белдерә торган кыек тәмамлыклар . . . 148
Хәлләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
§ 138. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
§ 139. Урын хәле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
§ 140. Вакыт хәле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
§ 141. Рәвеш хәле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
§ 142. Күләм хәле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
§ 143. Максат хәле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
§ 144. Сәбәп хәле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
§ 145. Кире хәл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
§ 146. Шарт хәле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Аныклагыч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
§ 147. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
Фигыльдән башка сүзләр белән бирелгән аныклагычлар . 158
§ 148. Гомуми төшенчә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
§ 149. Мәгънә күләме аныкланмыш мәгънәсе белән бер үк булган аныклагыч . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
§ 150. Мәгънә күләме аныкланмыш мәгънәсеннән таррак булган аныклагычлар . . . . . . . . . . . . . . . 160
Фигыльләр белән бирелгән аныклагычлар . . . . . . . . 160
§ 151. Бу төр аныклагычларның үзенчәлекләре . . . . . 160
Модаль кисәкләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
§ 152. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161

Эндәш сүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
§ 153. Эндәш сүзләрнең үзенчәлекләре . . . . . . . . . 162
Кереш сүзләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
§ 154. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . 164
§ 155. Кереш сүзләрнең төрле сүз төркемнәре белән
бирелүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
§ 156. Кереш сүзләрне мәгънә ягыннан төркемләү . . . . 166
***Структур һәм семантик кисәкләр*** . . . . . . . . . . . . 168
§ 157. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
§ 158. Структур кисәкләр турында . . . . . . . . . . . . . 169
§ 159. Семантик кисәкләр турында . . . . . . . . . . . . 172
§ 160. Предикат һәм аның төрләре . . . . . . . . . . . . 174
§ 161. Субъект һәм аның төрләре . . . . . . . . . . . . . 175
§ 162. Объект һәм аның төрләре . . . . . . . . . . . . . 177
§ 163. Атрибут һәм аның төрләре . . . . . . . . . . . . . 180
§ 164. Ачыклагыч һәм аның төрләре . . . . . . . . . . . 183
***Тиңдәш кисәкләр*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 184
§ 165. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . 184
§ 166. Җөмлә кисәкләренең тиңдәш булуы өчен төп шарт . 185
§ 167. Җөмләнең барлык кисәкләре дә тиңдәш була . . . . 185
§ 168. Тиңдәш кисәкләрне үзара теркәүче чаралар . . . . . 186
§ 169. Тиңдәш кисәкләрнең «ярашу» мәсьәләсе . . . . . . 188
§ 170. Тиңдәш кисәкләр янында гомумиләштерүче сүзләр . . 189
***Синтагматик кисәкләр*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . 190
§ 171. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . . 190
§ 172. Синтагма һәм аның өйрәнелү дәрәҗәсе . . . . . . . . 191
§ 173. Синтагма, сөйләм такты, сулыш группасы һәм
цезура . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 192
§ 174. Синтагма һәм сүзтезмә . . . . . . . . . . . . . . . 193
§ 175. Җөмлә кисәкләренең аерым синтагма төзи алмый
торган очраклары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 194
§ 176. Җөмлә кисәкләренең аерым синтагма төзи торган
очраклары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 195
**Аерымланган иярчен кисәкләр** . . . . . . . . . . 196
§ 177. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . 196
Аерымланган аергычлар . . . . . . . . . . . . . . . . . 198
§ 178. Аерымланган аергычларның үзенчәлекләре . . . . . 198
Аерымланган тәмамлыклар . . . . . . . . . . . . . . . 198
§ 179. Аерымланган тәмамлыклар буламы? . . . . . . . . . 198
Аерымланган хәлләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 199
§ 180. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . 199

§ 181. Аерымланган рәвеш хәлләре . . . . . . . . . . . . 200
§ 182. Аерымланган күләм хәлләре . . . . . . . . . . . 201
§ 183. Аерымланган вакыт хәлләре . . . . . . . . . . . 201
§ 184. Аерымланган максат хәлләре . . . . . . . . . . . 201
§ 185. Аерымланган сәбәп хәлләре . . . . . . . . . . . 202
§ 186. Аерымланган кире хәлләр . . . . . . . . . . . 202
§ 187. Аерымланган шарт хәлләре . . . . . . . . . . . 202
*Актуаль кисәкләр* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 202
§ 188. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . 202
§ 189. Актуаль кисәкләрнең урыны . . . . . . . . . . . 204
§ 190. Актуаль бүленеш һәм телне практик куллану . . . . . 205
**Җөмләдә сүз тәртибе** . . . . . . . . . . . . . . . . . . 207
§ 191. Сүз тәртибенең роле . . . . . . . . . . . . . . . 207
§ 192. Төрле стильләрдә сүз тәртибен билгеләүче факторлар . 208
§ 193. Сүзләрнең уңай тәртибе . . . . . . . . . . . . . 209
§ 194. Сүзләрнең кире тәртибе . . . . . . . . . . . . . 211
**Җөмлә кисәкләренең урыны** . . . . . . . . . . . . . . . 212
§ 195. Хәбәрнең урыны . . . . . . . . . . . . . . . . . 212
§ 196. Иянең урыны . . . . . . . . . . . . . . . . . . 212
§ 197. Аергычның урыны . . . . . . . . . . . . . . . . 213
§ 198. Тәмамлык һәм хәлләрнең урыны . . . . . . . . . . 214
§ 199. Аныклагычның урыны . . . . . . . . . . . . . . . 215
§ 200. Модаль кисәкләрнең урыны . . . . . . . . . . . . 215
§ 201. Тиңдәш кисәкләрнең урыны . . . . . . . . . . . . 216
*Өстәлмәләр* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 216
§ 202. Сөйләмә телдәге сүз тәртибенең әдәби телгә үтеп керүе нәтиҗәсендә формалашкан күренеш буларак өстәлмәләр . 216
§ 203. Өстәлмәнең мәгънә йөкләнеше һәм аның билгеләмәсе . 217
§ 204. Өстәлмәләрне өйрәнүнең кыскача тарихы . . . . . . 218
§ 205. Өстәлмәләр һәм ким җөмләләр . . . . . . . . . . . 219
§ 206. Өстәлмәләр һәм инверсион кисәкләр . . . . . . . . . 220
§ 207. Өстәлмәләрнең кулланылышы һәм төрләре . . . . . . 221
*Детерминантлар* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 223
§ 208. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . 223
§ 209. Тәмамлыкларның детерминант булып килүләре . . . . 225
§ 210. Хәлләрнең детерминант булып килүләре . . . . . . 227
**Гади җөмлә модельләре** . . . . . . . . . . . . . . . . . 228
§ 211. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . 228
***Гади җөмләнең грамматик модельләре*** . . . . . . . . . . 230
§ 212. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . 230
§ 213. Модельләрне билгеләгәндә нәрсәләр исәпкә алына? . . . 232

§ 214. Хәбәре төрләнешле фигыль белән бирелгән
ике составлы модель . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 233
§ 215. Хәбәре төрләнешсез фигыль белән бирелгән
ике составлы модельләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 235
§ 216. Хәбәре *тиеш, мөмкин, кирәк, ал* сүзләрен алган
фигыльләр белән бирелгән ике составлы модельләр . . . . . . 237
§ 217. Хәбәре *бул* янында килгән фигыль белән бирелгән
ике составлы модельләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 237
§ 218. Хәбәре *ит* сүзен алган фигыльләр белән бирелгән
ике составлы модельләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 239
§ 219. Хәбәре *кирәк, ярый, бар/юк* сүзләре белән бирелгән
ике составлы модельләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 240
§ 220. Исем хәбәрле ике составлы модельләр . . . . . . 240
§ 221. Субъекты ия булып формалашмаган бер составлы
модель . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 241
§ 222. Баш кисәге хәбәр дип таныла алмый торган
бер составлы модельләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 241
§ 223. Баш кисәге төрле фигыльләр белән бирелеп,
үтәүчесе читләтелгән бер составлы модельләр . . . . . . . . 243
§ 224. Баш кисәге төрле фигыльләр, ә үтәүчесе юнәлеш
яки иялек килешендәге сүз белән бирелгән бер составлы
модельләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 243
§ 225. Баш кисәге исемнәр белән бирелгән бер составлы
модельләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 244
§ 226. Җәенкеләнми торган баш кисәкле бер составлы
модель . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 244
§ 227. Фразеологик модельләр . . . . . . . . . . . . . 244
§ 228. Җыйнак җөмлә модельләрен бергә туплап күрсәтү . . 245
***Гади җөмлә модельләренең грамматик формалары***
***һәм парадигмалары*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 248
§ 229. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . 248
§ 230. Җөмлә модельләренең зат-сан формалары
һәм аларның парадигмасы . . . . . . . . . . . . . . . . . 250
§ 231. Җөмлә модельләренең юнәлеш формалары
һәм аларның парадигмасы . . . . . . . . . . . . . . . . . 252
Гади җөмләнең наклонение буенча формалары
һәм парадигмалары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 254
§ 232. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . 254
Синтаксик индикатив формалары һәм парадигмалары . . . 255
§ 233. Җөмлә модельләренең заман формалары
һәм аларның парадигмасы . . . . . . . . . . . . . . 255

§ 234. Төрле җөмлә модельләренең заман формаларында килүләре . . . . . . . . . . . . . . . . 258
§ 235. Җөмлә модельләренең күзәтелгәнлек/күзәтелмәгәнлек формалары һәм аларның парадигмалары . 260
Синтаксик ирреаль наклонение формалары һәм парадигмалары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 263
§ 236. Җөмлә модельләренең шартлы теләк, шарт, боерык, теләк наклонениесе формалары . . . . . 263
§ 237. Җөмлә модельләренең үзенчәлекле наклонение формалары һәм барлык төр наклонениеләр парадигмасы . 266
***Гади җөмлә модельләренең стилистик формалары*** . . . . . . . . 269
§ 238. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 269
§ 239. Гади җөмлә модельләренең модаль мәгънә белдерүче лексик чаралар ярдәмендә стилистик төрләнешләре . . . . . 270
§ 240. Гади җөмлә модельләренең дәрәҗәне, параллельлек һәм эзлеклелекне белдерүче ярым мөстәкыйль фигыльләр ярдәмендә стилистик төрләнешләре . . . . . . . . . . . . 272
§ 241. Гади җөмлә модельләренең тулылык/кимлеккә нигезләнгән стилистик төрләнеше . . . . . . . . . . . . 274
***Гади җөмләнең структур-семантик модельләре*** . . . . . . . . . 275
§ 242. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 275
§ 243. Ике составлы җыйнак җөмләнең структур-семантик модельләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 278
§ 244. Ике составлы җәенке җөмләнең структур-семантик модельләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 280
§ 245. Бер составлы җыйнак җөмләләрнең структур-семантик модельләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 282
**Гади җөмлә төрләре** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 285
§ 246. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 285
***Раслау һәм инкяр җөмләләр*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 287
§ 247. Раслау җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 287
§ 248. Инкяр җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 287
§ 249. Раслау һәм инкяр җөмләләрне үзгәртеп төзүдә антонимнарның роле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 289
***Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре*** . . . . . . . . . . . . . . 290
§ 250. Хикәя җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 290
§ 251. Сорау җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 291
§ 252. Боеру җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 294
§ 253. Тойгылы җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 295
***Ким җөмләләр*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 298
§ 254. Мәсьәләнең кыскача тарихы . . . . . . . . . . . . . . . 298

§ 255. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . 299
§ 256. Тулы җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 300
§ 257. Ким җөмләләрнең кимлек сәбәбенә бәйле төрләре . . . 301
§ 258. Кайсы кисәкнең кулланылмавына карап ким җөмләләрнең төрләре . . . . . . . . . . . . . . . . 302
§ 259. Ким җөмләләрнең кулланылышы . . . . . . . . . . . 303
**Бер ярым хәбәрлекле җөмләләр** . . . . . . . . . . . . . . 304
§ 260. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . 304
§ 261. Тел чаралары белән бирелмәгән хәбәрлек ярым хәбәрлек дип таныла алмый . . . . . . . . . . . . . 305
§ 262. Бер ярым хәбәрлекле җөмләләр турында гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 306
§ 263. Бер ярым хәбәрлекле җөмләләр асимметрик булалармы? 307
Ярым хәбәрлегә төрле кисәкләр аша бирелгән гади җөмләләр . 308
§ 264. Ярым хәбәрлек тиңдәш кисәкләр ярдәмендә бирелә . . 308
§ 265. Ярым хәбәрлек исем фигыль һәм инфинитив белән бирелгән кисәкләр ярдәмендә белдерелә . . . . . . . 310
§ 266. Ярым хәбәрлек сыйфат фигыльләр һәм хәл фигыльләр белән бирелгән кисәкләр ярдәмендә белдерелә . . 311
§ 267. Ярым хәбәрлек *-лык*, *-гысыз* кушымчаларын алган сүзләр һәм хәбәрлек сүзләр белән бирелгән кисәкләр ярдәмендә белдерелә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 312
§ 268. Ярым хәбәрлек аныклагычлар һәм өстәлмәләр белән бирелә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 313
Ярым хәбәрлегә кушымчалар һәм бәйлекләр аша бирелгән гади җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 314
§ 269. Ярым хәбәрлек төшем юнәлеше кушымчасы аша бирелә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 314
§ 270. Ярым хәбәрлек уртаклык юнәлеше кушымчасы аша бирелә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 315
§ 271. Ярым хәбәрлек йөкләтү юнәлеше кушымчасы аша бирелә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 316
§ 272. Ярым хәбәрлек чагыштыру кушымчасы яки бәйлекләре аша бирелә . . . . . . . . . . . . . . . . . 317
**Хәбәрлек һәм модальлек** . . . . . . . . . . . . . . . . . 318
§ 273. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . 318
§ 274. Хәбәрлекнең төп билгеләре . . . . . . . . . . . . . 320
§ 275. Модальлекнең төп билгеләре . . . . . . . . . . . . 321
§ 276. Модальлекнең синтаксик фразеологизмнарда бирелеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 323
§ 277. Модальлекнең кабатлаулар ярдәмендә бирелеше . . . . 324

**КУШМА ҖӨМЛӘ СИНТАКСИСЫ** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 329
§ 278. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 329
§ 279. Кушма җөмләне семиотик билгеләү мәсьәләсе . . . . . 330
§ 280. Кушма җөмләне грамматик билгеләү мәсьәләсе . . . . 332
§ 281. Кушма җөмләне гади җөмләдән аеру юллары . . . . . . 333
§ 282. Кушма җөмләләрне төрләргә бүлү мәсьәләсе . . . . . . 336
§ 283. Кушма җөмләләрне төрләргә бүлүнең кайбер үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 340
§ 284. Җөмләләрнең үзара грамматик һәм структур бәйләнешенә карата . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 342
**Гади кушма җөмләләр** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 344
***Иярченле кушма җөмләләр*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 344
Синтетик кушма җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 344
§ 285. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 344
§ 286. Синтетик җөмләләрнең төп үзенчәлекләре . . . . . . 346
§ 287. Синтетик җөмләләрне баш җөмләгә ияртүче чаралар . 348
Синтетик җөмләләрне хәбәр булып килгән сүзгә карап төркемләү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 350
§ 288. Хәбәре исем фигыль белән бирелгән синтетик җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 350
§ 289. Хәбәре *-асы, -а торган, -ыр/-мас* формаларындагы сыйфат фигыль белән бирелгән синтетик җөмләләр . . . 353
§ 290. Хәбәре *-ган* формасындагы сыйфат фигыль белән бирелгән синтетик җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . 355
§ 291. Хәбәре хәбәрлек сүзләр белән бирелгән синтетик җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 358
§ 292. Хәбәре сыйфат яки рәвеш белән бирелгән синтетик җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 360
§ 293. Хәбәре *-лык/-лек* кушымчасы ярдәмендә ясалган сүзләр белән бирелгән синтетик җөмләләр . . . . . . . . . 361
§ 294. Хәбәре инфинитив белән бирелгән синтетик җөмләләр . 364
§ 295. Хәбәре хәл фигыльләр белән бирелгән синтетик җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 364
§ 296. Хәбәре шарт фигыль белән бирелгән синтетик җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 367
§ 297. Хәбәре III зат берлек сандагы боерык фигыль белән бирелгән синтетик җөмләләр . . . . . . . . . . . . 369
§ 298. *Күренә, тоела* кебек баш җөмләгә *кебек*, *сыман* яки *шикелле* бәйлеге аша ияргән синтетик җөмләләр . . . 369
Аналитик кушма җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 370
§ 299. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 370

Аналитик җөмләләрне баш җөмләгә ияртү чаралары буенча төркемләү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 372
Баш җөмләгә хәбәр бөтенлеген бозмый торган кушымчалар аша ияргән аналитик җөмләләр . . . . . . . . 372
§ 300. Бу төр җөмләләрнең төп үзенчәлекләре . . . . . . . 372
Баш җөмләгә хәбәр бөтенлеген бозмый торган бәйлек-теркәгеч сүзләр аша ияргән аналитик җөмләләр . . . 373
§ 301. Бу төр җөмләләрнең төп үзенчәлекләре . . . . . . 373
Баш җөмләгә ияртүче теркәгеч яки теркәгеч сүз аша ияргән аналитик җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . 378
§ 302. Бу төр җөмләләрнең төп үзенчәлекләре . . . . . . . 378
Баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр аша ияргән аналитик җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 382
§ 303. Аналитик җөмләне баш җөмләгә ияртүче мөнәсәбәтле сүзләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . 382
§ 304. Татар телендәге мөнәсәбәтле сүзләрнең рус телендәге мөнәсәбәтле сүзләр белән охшаш һәм аермалы яклары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 388
§ 305. Баш җөмләгә төп ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр аша ияргән аналитик җөмләләр . . . . . . . . . . . . 391
§ 306. Баш җөмләгә парлы мөнәсәбәтле сүзләр аша ияргән аналитик җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 395
§ 307. Баш җөмләгә алынма ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр аша ияргән аналитик җөмләләр . . . . . . . . . . . . 399
Баш җөмләгә интонацион чаралар аша ияргән аналитик җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 401
§ 308. Интонацион бәйләүче чаралар һәм аларның семантикасы мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . 401
§ 309. Баш җөмләгә көттерү паузасы аша ияргән аналитик җөмләнең функциональ үзенчәлекләре . . . . . . 404
Иярчен җөмләләрне функциональ төркемләү һәм аларны үзгәртеп төзү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 408
§ 310. Җөмләнең функциональ төрләре һәм трансформацион синтаксис турында гомуми мәгълүмат . . 408
§ 311. Иярченле кушма җөмләләрне үзгәртеп төзү . . . . . 410
§ 312. Аналитик кушма җөмләне синтетик төзелмәгә әйләндерү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 412
§ 313. Синтетик төзелмәләрне аналитик кушма җөмләләргә әйләндерү . . . . . . . . . . . . . . . . . . 414
§ 314. Иярчен ия җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү . . . 415
§ 315. Иярчен хәбәр җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү . 418

§ 316. Иярчен тәмамлык җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү . 420
§ 317. Иярчен аергыч җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү . 423
§ 318. Иярчен вакыт җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү . 425
§ 319. Иярчен урын җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү . 428
§ 320. Иярчен рәвеш җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү . 430
§ 321. Иярчен күләм җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү . 433
§ 322. Иярчен сәбәп җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү . 435
§ 323. Иярчен максат җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү . 438
§ 324. Иярчен шарт җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү . 438
§ 325. Иярчен кире җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү . 440
§ 326. Иярчен аныклагыч җөмләләр һәм аларны үзгәртеп төзү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 442
§ 327. Иярчен кереш җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . 443
***Тезмә кушма җөмләләр*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 446
§ 328. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 446
§ 329. Аерым җөмләләре үзара җыючы теркәгечләр аша бәйләнгән тезмә кушма җөмләләр . . . . . . . . . . . . . 447
§ 330. Аерым җөмләләре үзара бүлүче теркәгечләре аша бәйләнгән тезмә кушма җөмләләр . . . . . . . . . . . 448
§ 331. Аерым җөмләләре үзара каршылык теркәгечләре аша бәйләнгән тезмә кушма җөмләләр . . . . . . . . . . . 449
§ 332. Аерым җөмләләре үзара санау интонациясе аша бәйләнгән кушма җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 450
§ 333. Аерым җөмләләре үзара каршылык интонациясе аша бәйләнгән кушма җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . 451
Аналитик та, тезмә дә булган кушма җөмләләр . . . . . . . . . 452
§ 334. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 452
**Катлаулы кушма җөмләләр** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 454
§ 335. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 454
***Күп тезмәле кушма җөмлә*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 455
§ 336. Бу төр кушма җөмләләрнең төп үзенчәлекләре . . . . . 455
***Күп иярченле кушма җөмлә*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . 457
§ 337. Тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмлә . . . . . . 457
§ 338. Тиңдәш түгел иярүле күп иярченле кушма җөмлә . . . . . 460
§ 339. Бер-бер артлы иярүле күп иярченле кушма җөмлә . . . . 463
§ 340. Берничә төр иярүле күп иярченле кушма җөмлә . . . . . . 465
***Катнаш кушма җөмлә*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 470
§ 341. Бу төр кушма җөмләләрнең төп үзенчәлекләре . . . . . 470
**ТЕКСТ СИНТАКСИСЫ** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 474
§ 342. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 474
§ 343. Текстның күләмен аңлау турында . . . . . . . . . . . . 475

§ 344. Текст синтаксисы һәм грамматик категорияләр . . . . . . 476
***Текстның бөтенлеге*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 478
§ 345. Текстның мәгънәви бөтенлеге . . . . . . . . . . . . . 478
§ 346. Текстның коммуникатив бөтенлеге . . . . . . . . . . . 481
§ 347. Текстның структур бөтенлеге . . . . . . . . . . . . . . . 483
§ 348. Текстның грамматик бөтенлеге . . . . . . . . . . . . . 487
§ 349. Текст композициясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 490
**Тезем** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 492
§ 350. Текстның бер төре буларак тезем . . . . . . . . . . . 492
§ 351. Тезем бүлекләренең урнашу тәртибе һәм интонацион үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 493
§ 352. Тиземнәрне төркемләү . . . . . . . . . . . . . . . . . . 495
**Чит сөйләмле текст** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 501
§ 353. Гомуми мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 501
Туры сөйләм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 501
§ 354. Туры сөйләмнең үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . 501
§ 355. Туры сөйләм һәм автор сөйләме арасындагы мөнәсәбәт . . 503
§ 356. Туры сөйләм һәм автор сөйләменең урыннары . . . . . . 504
Кыек сөйләм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 505
§ 357. Кыек сөйләмнең төп үзенчәлекләр . . . . . . . . . . . 505
§ 358. Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерү . . . . . . . . 506
Уртак сөйләм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 508
§ 359. Уртак сөйләмнең төп үзенчәлекләре . . . . . . . . . . 508
Файдаланылган әдәбият исемлеге . . . . . . . . . . . . . . . . 510

Научное издание

**ТАТАРСКАЯ ГРАММАТИКА**

**Том III**

(на татарском языке)

Редактор *Я.М. Абдулкадырова*
Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*

Подписано в печать: 22.12.2017.
Формат 60×84 $^1/_{16}$. Гарнитура «Times».
Бумага офсетная, печать офсетная.
Усл.-печ. л. 31,2. Уч.-изд. л. 25,5.
Тираж 1000. Заказ №

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, г. Казань, ул. К. Маркса, 12